




**Хикәяләр, новеллалар**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос=Тат)-44
Х 87

**Айдар Хәлим**

Х 87 Кыйбла: Хикәяләр, новеллалар. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2005. — 382 б., рәсеме белән.

Бары тик хикәяләрдән генә торган бу китап бер-берсенә асыл җеп белән бәйләнгән мәрҗәннәр дисбесен хәтерләтә. Без аны бүгенге татар әдәбиятының бер матур үрнәге буларак тәкъдим итәбез.

ISBN 5 -298-04164-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Айдар Хәлим, 2005

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

## КҮҢЕЛНЕ КУЗГАТКАН МОҢ

*Айдар Хәлим прозасының нигезендә тирән моң ята. Татарга гына хас булган, бары тик татар җаны гына аңлый, шуны гына тетрәтә торган тирән моң. Агата Кристи, Джек Лондон, Раймонд Чандлер, Джеймс Хэдли Чейз әсәрләрен, О'Генри новеллаларын укып күнеккән бүгенге көн укучысы, ихтимал, үз милләтенең бәхете өчен кайнарланып көрәшкән, дуамал адымнарга бара-бара кыйналган, әмма максаты куйкан юлдан баш тартмыйча һаман алга барган бу әдип иҗатының асыл мәгънәсенә беренче укылышта ук төшенеп тә бетмәс. Тик шулай да, язучының нәфис прозасын беренче тапкыр кулына алган укучыга мөрәҗәгать итеп, мин: «Хөрмәтле укучы! Син, бәлки, интригалы сюжет, экзотик вакыйгалар, ыгы-зыгылы дөнья агышын оныттыра торган маҗаралар эченә кереп югалырга телисеңдер, шулай җанга тынычлык табып, ял итәргә күнеккәнсеңдер? Ләкин бу алдаучан тынычлык — җаннарның йокымсырау халәте артында күңелнең чын таләбе — яшәүнең асыл мәгънәсен аңлауга булган омтылыш та бар. Иртәме-соңмы һәр җан шул таләп белән уяначак. Соңга калганчы, бүген уяну хәерлерәк. Синең кулыңда уйландырып ята торган чын сәнгать әсәрләре. Аларны укымыйча гына киштәгә алып куярга ашыкма», — дип әйтер идем.*

*Тормышының бик авыр һәм киеренке бер минутында, кыйналып һәм тапталып, рәхимсез рәвештә эзәрлекләнеп, төшенкелеккә бирелергә тиешле бер чакта үзенең көндәлегенә әдип менә бу юлларны язып куя:* ***«Әле бит минем дөньяны үземдә булган тел һәм үзем кичергән кичереш белән нәфис әдәбият — прозада ачасым бар. Минем бит әле «Айдар Хәлим прозасы»н тудырасым бар!..»*** *Әгәр дә мин яшькә төелеп «Өч аяклы ат»ны, фикер тирәнлегенә таң калып «Татар вакыты» романын укымаган булсам, бер юл да диярлек чын проза әсәре иҗат итмәгән килеш көндәлегенә мондый юллар язып куйган авторны тәкәббер-амбициоз бер шәхес дип бәяләр идем. Инде бүген килеп язучының күпсанлы хикәяләрен, повесть һәм романын укыган, алардагы күпчелек фикер-идеяләр белән*

*килешкән, күпмедер дәрәҗәдә аның иҗат планнары һәм максаты белән танышкан бер укучысы буларак XXI гасыр башында шаһитлык бирә алам — туачагы туксанынчы ел бусагасында игълан ителгән Айдар Хәлим прозасы бар! Нибары дистә-дистә ел ярымнар вакыт эчендә һәркайсы әдәби вакыйгага булып кабул ителерлек проза әсәрләрен берbegin бер артлы әдәби табынга куя алган әдипнең иҗат программасы, үзенчәлекле манифесты булган икән көндәлеккә язган юллары. Үз алдына куйган олы максаты! Талантны бары тик олы максатлар, милләткә хезмәт итү идеясе йөртергә тиеш. Шул идея хакына үз мәнфәгатьләрен онытып көрәшә белгәннәр генә җиңүче! 1989 еллар ахырында публицистикасы белән бөтен СССРны тетрәткән, шигъри мәйданда ат уйнаткан, драматургиядә кискен борылыш ясау нияте белән ике оригиналь әсәр язып, аларны сәхнәгә күтәрү өчен авыр, гаугалы көрәш алып барган һәм үзе белән тарткалашкан системаны калтыратырлык-куркытырлык җиңүләргә ирешкән әдипнең прозаны үзенең «өченче батырлыгым» дип игълан итүенең төбендә Аллаһ тарафыннан бирелгән талантының күпкырлылыгын аңлау ята иде. Бу тәкәбберлек түгел, дөреслектә, үзе язган әсәрнең даһилыгына төшенеп һәм таң калып: «Ай да Пушкин! Ай да сукин сын!» — дип кычкырган шагыйрь горурлыгы, «Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул», — дип белдерергә җөрьәт иткән гарьле-вәкарьле Тукайның үз дәрәҗәсен төгәл белүе күләмендәге вәкарь, талантның үз көченә ышануы гына иде. Айдар Хәлимнең иҗаттагы батырлыгын һәм уңышын менә шундый ышаныч һәм олпат максатлар тәэмин итте.*

*Биредә без сүзне бары тик әдәбиятның бик тә серле хасиятләргә ия булган хикәя жанры турында гына алып барырбыз. Әлеге жанрның серле куәте шунда: теләсә кайсы иҗатчы укучыны үз артыннан ияртерлек һәм уйландырырлык тылсымга ия булган хикәя иҗат итә алмый. Роман, повесть кебек күләмле жанрларны чагыштырмача җиңел ияргәннәргә дә ашыгып кына ачылырга яратмый әле ул хикәя дигәнең. Дөрес, үзен прозаик дип исәпләгән һәр әдип азмы-күпме бу жанрда каләм тибрәтмичә калмый. Әмма хикәя язу ул әле үзеңне хикәя остасы дип таныту дигән сүз түгел. Айдар Хәлим үзенең каләме белән хикәяне хәрәкәтләндерүче эчке яшерен көчләрне оста тойган, жанрның хасиятенә төшенгән бәхетле язучы булып чыкты. Бик тә лирик исемле «Кылганнар чәчкә атканда», «Трофей ашъяулык», «Җырлар вакыт», «Берлинга хат», яңгырашы белән үк сискәндереп җибәрә торган «Казыктагы тальян», «Кара кышта», публицистик аһәң белән өретелгән «Эңгер»,*

*«Авылдаш», сатирик пафос белән кушылган фаҗигане сурәтләүче «Сандугач белән Карлыгач» һәм, ниһаять, Рәсәй чынбарлыгы өчен типик чынбарлыкка әверелгән, ә чынлыкта кыргыйлыгы ягыннан урта гасырлар вәхшилегеннән уздыручы вакыйгалар тезмәсеннән торган драманы үзәккә куйган «Кыйбла» — әдип каләменнән соңгы елларда чыккан хикәяләрнең тулы булмаган исемлеге менә шулардан гыйбарәт. Бу һәм монда исемнәре саналмаган башка күп кенә хикәяләрнең тематик диапазоннары никадәр генә киң, персонажларының яшәү даирәсе һәм мохите ничаклы гына төрле булмасын, күпчелек очракларда аларны уртак эчтәлек — милли фаҗиганең төрле ракурсларда, төрле төсмерләрдә сурәтләнеше берләштерә. Нәфис прозадагы үзенең төп иҗат принцибын автор «Сандугач белән Карлыгач» хикәясенең финал өлешендә укучыга менә бу рәвешле җиткерә: «Безнең милләтнең сәнгате юк, — дип пышылдадым мин үз-үземә. — Үз фаҗигасен тасвирлый алган тирән сәнгате юк. Сәнгатьсез халык кына шулай була ала».*

*Фаҗиганең сәнгатьчә сурәтләнеше... Бу катлаулы бурыч Айдар Хәлим каләме тарафыннан осталарча башкарыла. Югарыда искә алынган «Сандугач белән Карлыгач»ны гына алып карыйк. Милләтнең иң зур фаҗигасе — чын татарга хас яшәү рәвешен югалтып кавем буларак котылгысыз рәвештә үзгәрүгә таба баруы тасвирлана әлеге хикәядә. Юк, юк, бу урыслашу түгел, бу, йомшак кына итеп әйткәндә, мутантлашу, гыйфрит бер кавем рәвешен алып, табигый сыйфатларны тулысынча югалту, гайре табигый кыяфәткә керү, эчке һәм тышкы бөтенлектән баш тарту. Хикәянең сюжеты беренче карашка бик тә гади вакыйгалардан төзелгән. Печән өстендә авылга кунакка кайткан язучы Зәригәткә бригадир абыйсы Иниль йортында бик тә тәмле телле, бер-берсенә «сандугачым-карлыгачым» дип кенә эндәшүче ирле-хатынлы бер пар белән табындаш булырга туры килә. Яшәешкә үз карашы, үз фәлсәфәсе булган бу яңа танышларына Зәригәт берара сокланып та куя. «Инде егерме биш-утыз еллап бергә гомер кичергән, балалар үстереп, ачысын-төчесен бергә татыган ир белән хатынның әле һаман бер-берсенә яшь-җилкенчәкләрчә «сандугачым-карлыгачым» дип эндәшүләре мине бөтенләй буынсыз, һушсыз иткән иде», — ди ул хикәяләүнең урта бер җирендә. Вакыйгаларның табигый агышын яңа танышның бик тә сәер исеме генә бозып тора. Фронтка китәр алдыннан әтисе — Сәлимгәрәй абзый кушып калдырган Психология исемен бик тә горур йөртә әлеге бәндә. Дөрес, ул аны кыскартып, мәгънәсен һәм яңгырашын тагын да тупасландырып кулланырга ярата. Исеменең мәгънәсезлегендә үзенчә мәгънә күрә, үз фәлсә-*

*фәсе белән дәлилли әлеге адәм. Ул гына да түгел, биш улына берсеннән-берсе мәгънәсезрәк исемнәр тагып, шул мәгънәсезлеккә чын күңелдән кинәнеп-шатланып, тәм табып яши бу татар фамилияле агай. Сәгать, Музсәгать, Минут, Секунд, Стрелка исемнәре аның сатирик портретын тагын да тулыландыралар, гыйфрит натурасын ачыклый төшәләр. Персонажларның чын йөзе «ызнаминитый бисәтель»не дә кунакка алып кайту юлына чыккач ачыклана: табын артындагы ягымлылык, итагатьлелек, мөлаемлык кебек сыйфатлар ирдә дә, хатында да юкка чыга, персонажларның телендәге «сандугачым-карлыгачым»ны «Сбулыч! Падлы! Сбинжә! Әтәлге!» сүзләре алмаштыра. Бер үк персонаж портретының ике төрле ситуациядә сурәтләнешенә генә игътибар итик. Псих Сәлимгәрәевичның хатыны Зәлифәне — табын артында утырганда теле чат балдан гына торган ханымны — автор Зәригәт күзләре белән менә болайрак күрә: «...хатынның тешләре кайрак белән кайралгандай ак, уң күзе бераз гына кылый икән; әмма бу кылыйлык уймак кебек җыйнак гәүдәле Зәлифәнең түгәрәк йөзенә гарип җитешсезлек түгел, киресенчә, — иң сәере дә шунда! — тирән, яшеренеп яткан моңсулык, ниндидер кызгандыручан камиллек һәм теләктәшлек өсти; ул кешегә турыдан текәлеп һәм чәнчелеп карамый, бәбкәләрен саклап йокымсыраган каз кебек, күзләрен җәһәт кенә ачып һәм ябып ала. Бу мизгелдә аның күз кырыйларында коңгырт сөрмә, куе моңсулык чагыла». Ситуация алышынып, инде персонажлар чын йөзе белән ачылганда, героиняга бәя дә менә мондыйрак үзгәреш кичерә: «Ире белән тигез эчкән, авызыннан аңкыган суган һәм хәмер исе белән бөтен яланны тутырган сандугач...». Портретларның кискен алмашынуы, сатирик гротеск дәрәҗәсенә җиткерелгән соңгы бәя, «сандугач» сүзенә салынган ачы ирония — хикәя сюжетына яткан фаҗигане чагылдыручы сәнгати чаралар, авторның аяусыз чынбарлыктан күз яшьләре белән көлүе. Язучының сәнгатьчә теле бередә милли фаҗиганең масштабын һәм тамырларын күрсәтү юлларын эзли һәм таба да: туган халкының аянычлы язмышын ул «мул уңыш хакына очкычлардан сиптерелгән агудан корыган Имәнлек урманы» белән тиңли. Зәригәтнең абыйсы Иниль Нәҗмиевич җырлаган моңлы көй «теләктәшлек тапмыйча корыган ботакларга, корыган ботаклардан корыган кәүсәләргә, корыган кәүсәләрдән корыган тамырларга үтеп зеңли...». Бу метафорик сурәт артында меңләгән Псих Сәлимгәрәевич, меңләгән Зәлифәләрнең язмышы шәйләнә, әйе, алар кайчандыр имән кебек нык халыкның уллары һәм кызлары иде, ләкин хәмер сазлыгына, табигый булмаган яшәү рәвешенә*

*кереп батып, исем-яфракларын да, рухи тамырларын да җуйдылар, үзләре уйлап тапкан исемнәр кебек үк котсыз, мәгънәсез бер затка әверелделәр.*

*«Сандугач белән Карлыгач»тагы тема «Авылдаш»та да дәвам иттерелә. Закир абзый һәм Фатыйха абыстайның «беренче һәм соңгы сөенече» булып дөньяга килгән, Тольятти шәһәрендә өйләнеп, Мәкәримов фамилиясен җиңел генә, «суща фурмы» гына хатыны фамилиясе Макаренкога алыштырган Сөендек-Саша язмышы әлеге хикәядә. Сөендек фаҗигасе, аның, язучы сүзләре белән әйтсәк, «оптимизм аша килгән идиотизмы» аның бабасы, «шәп чапмаска, Николай чалгысы бит ул!» — дип, чалгыны мактаган өчен генә «Себер китеп башы черегән» Суфиян мулла трагедиясеннән башлангандыр, ихтимал. Тамырларның киселүе, традицияләрнең бетерелүе, милли деградациянең мәйданга чыгуы... Нәтиҗәдә үз фамилиясен этикә биргән Сөендекнең татар җәмгыяте белән аралашу «нәбхәдимесен күрмәве», «садикмадик, сәтсиәл защита», фатир алу-киңәйтү мәсьәләләрен җиңел хәл итү өчен русча яңгырашлы фамилиягә мөкиббән китүе, әмма олыгая барган саен нәрсәдер җитмәвен, күңел бушлыгын тоеп эчкечелеккә бирелүе. Кыскасы, мөртәт татарлар депрессиясе. Бу депрессиядән, күңелдәге бушлыктан котылу өчен уйлап чыгарган ялган фәлсәфә дә ярдәм итмәгәнлектән, геройның күңелендә көчәя баручы сагыштан курку хисе уянган. Сөендек һәм аның кебекләрне кабергәчә газаплаячак хис бу! Фаҗигале финал — мөртәтлекнең, ятларның яшәү рәвешенә табынганнарның типик киләчәге. Мондый киләчәкне Айдар Хәлим «Теге малай» хикәясендә янә бер тапкыр тасвирлаячак, телдән, милләттән ваз кичүнең нәкъ менә имансызлык белән бәйле икәнлеген раслаячак. Мәчет манарасын кисеп кайтышлый Кәлимулла хәзрәт ихатасына кереп:*

*Яңаны алга куйыйк!*
*Искелекне без тыйыйк!*
*Муллаларның күзләренә*
*Кургаш эретеп койыйк! —*

*дип җырлаган Сәфәргалинең, телен онытып, Сашага әйләнүе, гомеренең азагында ерактагы Хабаровск каласында, гаиләсе тарафыннан читкә кагылып, авыру килеш картлар йортына тапшырылуы — милләтнең адашкан балаларын еллар артында көтеп торучы драма менә шул.*

*«Эңгер» хикәясендә маңкортлык җирлегендәге милли драма үзенең документаль төгәллеге белән башка яктанрак ачыла. Совет кешеләре, ягъни homosovetikusлар җәмгыяте тәрбияләгән, үзен һәрвакытта да хаклы дип санарга өйрәтелгән башбаштак җитәкченең КамАЗ төзелешендә эшкә*

*дип килгән яшүсмер егетне бары тик татарча сөйләшкәне өчен генә күзен чыгарганчы кыйнап ташлавы әсәр фокусындагы төп вакыйганы тәшкил итә. Җанны өшетерлек бу күренешне Айдар Хәлим каләме натуралистик төгәллек белән тасвирлый. Натуралистик сурәт хикәянең төп максатына хезмәт итүе белән бу очракта үзен аклый. Татар егетен кыйнаган Таракановның ерткыч натурасы, һәр репликасы, гамәлләре аек акылга сыймаслык булуга карамастан ышандыра, ситуациянең «бармактан суырылган» вакыйгадан корылмавына совет чорының «удар төзелешләре» аша узган һәркем шаһитлык бирә ала. Бирелә ситуациянең корылышы, аны хәрәкәткә китерүче фәлсәфә типик. Шул фәлсәфә Тараканов кебекләрнең психологиясенә әйләнгән, аларның үз-үзләрен тотуының кагыйдәсенә әверелгән. Бу кагыйдәне мәшһүр рус мәсәлчесе Крылов XIX гасырда ук фаш итә: «У сильного всегда бессильный виноват», — ди. Көчлеләрнең үзләрен һәрвакыт хаклы дип тоюлары XX гасыр ахыры — өченче меңьеллык башында Россиякүләм һәм хәтта дөньякүләм канлы вакыйгалар тезмәсе китереп чыгармадымыни? Чечен ит турагычы нигезендә Таракановлар фәлсәфәсе ятмыймыни? Үзен яклап мескен рәвештә генә сүз әйтергә базган авыл егетенең вәхшиләрчә кыйналу эпизодын гына укып карагыз, сез анда яндырылган һәм таланган, канга батырылган Кавказ авыллары, Әфган һәм Гыйрак торак пунктлары фаҗигасенең прелюдиясен күрерсез.*

*Никадәр генә канны өшетерлек һәм җанны тетрәндерерлек булмасын, «Әңгер» хикәясенең үзәк идеясе Тараканов фәлсәфәсен ачу, аның психологиясен хәрәкәткә китерүче көчләрне күрсәтү белән генә чикләнми (бу кадәресе генә дә үтә мөһим, әлбәттә). Әсәрдә төп урынны безнең милләттәшләребез арасында совет чорында әрсез чүп үләннәре кебек шытып чыккан типларны тасвирлау алып тора. Гегель Әфләтүнович Фәләхов — шундый типларның сәнгатьчә гәүдәләнеше, ифрат тормышчан натура. Типны сурәтләгәндә, әдип бу юлы да фотографик төгәллек белән эш йөртә. Ихтимал, аңа моның өчен гомумиләштерү, индивидуаль сыйфатларны бөртекләп җыеп, бергә туплау кебек алымнар белән эш итеп мәшәкатьләнергә дә кирәк булмагандыр. Чөнки Әфләтүнович-Платонычлар гадәттә шаблон натуралы, стандарт кыяфәтле булалар. Совет чынбарлыгы аларны уртак калыпка салып коеп кына торды, аларның «өлкән туган»ның һәр гамәлен алкышларга әзер торган психологиясен төгәл алгоритмнар ярдәмендә формалаштырды. Болар яңа шартлар өчен яхшылап әвәләнгән, әйбәтләп шомартылган типлар, «яңа кеше тәрбияләү» дигән демагогия корбаннары. Күзе агып чыккан үсмер егетне*

*гәүдәсе белән каплап-яклап азапланган журналист Җәүдәтне якасыннан эләктереп торгызырга тырышучы Платоныч авызыннан чыккан сүзләр советча яңа кеше тәрбияләү технологиясенең ни рәвешле баруын күрсәтәләр: «Чүп белән чүп булмагыз, Җәүдәт иптәш! Авыл сарыгы өчен КамАЗда гади процедура бит бу... Без монда җинаятьчелекнең тамырын шулай итеп корытмасак, яңа кешене бервакытта да тәрбияли алмаячакбыз». Советча яңа кеше образы, homosovetikus тибы, кешелеклелек, миллилек, гаделлек төшенчәләреннән мәхрүм ителгән синтетик натуралар — хикәянең үзәк фикере менә шулар тирәсендә төенләнгән. «Эңгер» исеменең бер мәгънә тармагы да шул типларның караңгылыгы, сукыр калебле булулары белән бәйләнгән. Аларның соңгы чор вәкиле, авылда «шул ук партия, шул ук партия дисциплинасы, шул ук взнос» булуы белән горурланган «һәр колхозникка зарплата исәбеннән сабантуйга берәр ящик аракы» бирүе белән мактанган колхоз рәисе Сабир — милләттәге совет кешесе сыйфатларының дәвамлы булуын дәлилләүче персонаж.*

*Айдар Хәлим — хикәя кысаларында образның киң эчке дөньясын, аның калебендә барган үзгәрешләрне, ул үзгәрешләрнең сәбәбен сыйдыра алган, үткән гасырның утызынчы елларыннан башлап бүгенге көнгәчә татар җаны нидән сыкрануын, социаль эчтәлекле фаҗиганең шәхси драма белән ни рәвешле үрелүен сурәтләгән каләм иясе. Бу җәһәттән аның «Казыктагы тальян» хикәясе игътибарны җәлеп итә. Каләм ияләре тарафыннан күп тапкырлар тасвирланган чор сурәте... Биредә яңача эчтәлек, кабатланмаган типлар, оригиналь образлар тудыру кыен бурычлардан. Күп тапкырлар өйрәнелгән дәвер портретын тудырганда, уртак сызыклар, кайбер штрихларның тәңгәллеге гаҗәпмени. Менә шул тәңгәллекнең яңа якларын эзләү, чор өчен артык гадәтигә әйләнгән вакыйгалар тезмәсенә башкача күзлектән карау — Айдар Хәлим хикәяләренең төп хасияте, минемчә, шунда. «Казыктагы тальян» хикәясендә әдип чор вакыйгаларына бәяне уналты яшьлек үсмер малай күңелендәге кичерешләр аша бирә. Вакыт-вакыт авторның аналитик каләме кайбер публицистик гомумиләштерүләр ясап куйгаласа да (бу да әдип прозасына хас бер сыйфат), хикәядә нигездә аның персонажы Бәгърем (исемнең оригинальлегенә, аның яңгырашына гына игътибар итегез!) хисе, аның күңелендә барган эзләнүләр, лирик чигенешләр ясыйясый, үзалдына куйган катлаулы сорауларга җавап табарга омтылышлары урын алган.*

*Бәгърем — Сәфәргали, Платоныч, Сөендекләрнең антиподы, Айдар Хәлим прозасында милләтнең асыл сыйфатла-*

*рын, аның бүгенгә кадәр сакланып килгән уңай потенциалын үзендә туплаган образлар галереясыннан бер персонаж, якты тип. Егетлек, ирлек, булдыклылык, эшлеклелек кебек татарда мактала торган сыйфатлар иясе. Язучы тарафыннан бу очракта да персонажның исеменә аерым бер эмоциональ һәм мәгънәви йөк йөкләтелгән. «...аның исемендә үк ниндидер гүзәл сер, әйтеп бетелмәгән мәгънә, матур шөбһә, хәтта куркыныч фаҗига яшеренгән иде», — ди автор бу турыда. Миңа калса, Айдар Хәлим персонажларының исемнәре үзләре аерым игътибар таләп итә торган бер дөнья. Алар үзләре бер сюжет, алар үзләре бер вакыйга. Бигрәк тә традицион булмаган, гадәтилек кысасыннан берникадәр читтәрәк торган исемнәр. Сөендекне генә алып карыйк. Бу исемдә никадәр өмет һәм фаҗига, шатлык һәм хәсрәт яшеренгән. Улларына бу исемне кушкан әти-әнинең сөенече һәм өмете нинди булгандыр. Сөендек исеме янәшәсендә Фатыйха абыстайның улы һәм килененә, оныкларына, мәһәргә, бүләккә, истәлеккә дип, асалы паласлар суккан, аларны чын сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткергән ананың фаҗигасе берничә тапкыр арта, калкурак булып күренә башлый. Әллә никадәр лирик интонацияләр яшеренгән Бәгърем исеме дә шулай. Алты бала табып, бишесен югалткан, соңгысын тапканда күп кан югалтудан үзе дә дөнья белән бәхилләшкән ананың соңгы өмете, соңгы теләге булып кушылган исем ул. Бәгърем авылда аерым статуска ия. Беренчедән, ул тома ятим; икенчедән, «Бәгъремне аны... барлык авыл имезгән»; өченчедән, ул гармунчы, «бик тә кирәк кеше», һәм барыннан да бигрәк, әлбәттә, исем. Мәгънәсенә үк чиксез якынлык, өзелеп ярату салынган исем йөрткән бу егетне кире кагу, инкяр итү мөмкин түгел. Хикәянең сюжеты Бәгърем яшерен генә, хәтта әле үзе дә сизмичә яратып йөргән, «авылның тарихка кererлек беренче чибәре» булган күрше кызы Разияның кияүгә чыгуы, туй озату өчен гармунчы буларак Бәгъремнең дә чакырылуына бәйле вакыйгалардан туган эчке каршылык — коллизиягә корылган. Күңелендә барган эчке көрәшнең нилектән икәнен үзе дә аңлап бетермәгән яшүсмер егет, «тормышның иң гади, иң катгый кануннарын аңлый алмый өзгәләнә», шуның нәтиҗәсендә персонажның эчке дөньясында хәрәкәткә килгән уй-тойгылар агышында чор сурәте, сугыштан соңгы чор «фронт ятимнәре»нең фаҗигале язмышына кагылышлы хәл-вакыйгалар: ачлыктан котылу өчен авылдан ун чакрымдагы «Питырпаул кахуллары» җиренә черек бәрәңге эзләп барып йөрүләр, черек бәрәңгене үзләре түгел малларына да ашатмаган кахуллар тарафыннан кимсетелү-кыйналулар, ачык йөз күрсәтеп, кукуруз икмәге һәм сөт белән сыйлаган «кахулның һичшиксез*

*татар булу-булмавы турында» бәхәсләшеп кайтулар, авыл халкы башына көтелмәгән бәла булып килеп төшкән утызменче Айсин тарафыннан каһәрләнүләр, урманга ботакка барган җирдән палищщик Госманның балтаны алып калуы. Айдар Хәлим каләме герой күңелендә барган кичерешләр тезмәсен бик тә тәфсилләп, вәземләп тасвирлый, комментарий-шәрехләүсез генә ясалган лирик сурәт: туй күренешләре, Бәгърем хәтерендә уянган истәлекләр нигезендә акрын гына үткән гасырның илленче елларында татар халкы кичергән фаҗига мәйданга чыга. Фаҗиганең асылы халык күргән авырлыклар, кимсетелүләрдә түгел, милләтнең акрын гына кавем буларак тискәре якка үзгәреш кичереп ятуында. Авылга Айсин алып килгән дуңгыз фермасында эшләргә акрынлап күнегүләр, ачыган бал эчү традициясенең һаман да тирәнгәрәк үтеп керүе нәтиҗәсендә кешеләрнең табигый матурлыкларын югалтулары, тышкы кыяфәт белән бергә калебтә дә котылгысыз рәвештә барлыкка килгән үзгәрешләр, Бәгърем теле белән бу үзгәрешләргә бирелгән бәя: «Болай барсак, кая барып, нинди чокырларга очарбыз? Гыймакай карт әйткән ахырзаман Дәҗҗалы шушы стаканда түгелме? Дәҗҗал шушы мөлаем, шаян картның үзендә, безнең барыбызның да күңелендә аягын салындырып утырмаганмы?»*

*Язучының фикере кайчак вак детальләргә, эпизодик персонажларга салынган, шуңа да һәр ситуация, һәр реплика төбенә төшеп уйлануны таләп итә, игътибар сорый. Төнге мунчага бисмилла әйтәсе урынга «Сталин» дип кычкырып керүче Бәгъремнең беркатлы ышануын гына алып карагыз. Кешегә табынган, юлбашчылардан кумир ясаган җәмгыятьнең мәҗүси гыйбадәте түгелме бу?! Мең еллык ислами традицияләре булган милләтнең асыл хакыйкатьтән читләшә төшеп, үзенең чын йөзен югалтып маймыллаша баруы түгелме? Сөендекләр, Гегель Әфләтүновичлар, Псих Сәлимгәрәевичлар милләтнең бәгыренә урнашып, тамыр җәеп барган яңа мәҗүси-советчыл традицияләр җирлегендә үсеп чыкмадылармы? Исерек Сәбәхетдиннең туйда:*

> *Ике төркемгә бүлене-е-е-п,*
> *Маймылла-а-а-р күңел ач-ча-а-а-а, —*

*дип сузган җыры очраклымы? Айдар Хәлим прозасы аналитик укылышны сорый. Анда метафорик мәгънәләрнең шактый ук бай җыелмасы, кинаяһәм мәгънәне тел төбенә яшерү кебек алымнар белән еш очрашасың. Бәгърем кичергән күңел җәрәхәте ул бер кешенең фаҗигасе генә түгел, язучының сәнгатьчә теле безгә шул хакта сөйли кебек.*

*Һәр юлыннан кан саркып торган «Кыйбла» хикәясе —*

*утызынчы-кырыгынчы елларның драматик вакыйгалары, җәмгыятьтә кыргыйлык һәм вәхшилекнең чәчәк ату хроникасы. Биредә эпик сурәтләү, вакыйгаларның документаль фильм экранындагы кебек еш алышынуы өстенлекне алган. Алтмыш-җитмеш еллык чор сурәтләнешен сыйдырган хикәя өчен бу, ихтимал, табигый күренештер. Өтәләү Зариф тарафыннан куркытылган, шуңа күрә догасын сәке астына качып укый башлаган җиде-сигез яшьлек Гарифулла — Садретдин мәзиннең улы — совет хакимияте әзерләгән коточкыч сынаулар аша узып, картлык яшенә җиткән. Кыйбласын югалткан, башка замандашлары кебек үк диненнән ваз кичкән картның язмышы гыйбрәтле һәм тетрәндерерлек. Кулга алынудан куркып, гаиләсе белән йорттан чыгып качкан Садретдин мәзин һәм аның балаларының тәкъдире ГУЛАГ лагерьларына эләккәннәрнекеннән һич тә ким булмый. Малсыз һәм йорт-җирсез калган мөһаҗирләр килеп туктаган, төрмә кануннары өстенлек иткән Чалкар станцасы Садретдин мәзин һәм Мәүлидә абыстай, аларның ике баласы өчен каберлеккә әйләнә. Сынны катырырлык натуралистик сурәт — чорның реалистик картинасын укучы күз алдына бастыру өчен язучы сайлаган ысул менә шундый. «...урамнарда корсаклары күпкән, йөзләре шешенгән, күз чокырларын бет һәм эрен баскан үле һәм тере гәүдәләр аунап ята; тирәләрендә өер-өер күселәр кайнаша; һавада нindидер сасы куыклар, селәгәй тамчылары очып йөри; шундый ук шешенгән һәм күзләре акаеп бетләгән, билгә кадәр шәрә калган бәндәләр, бер-берсен авызларыннан очкан мөһмәләт, тәкерек белән агулап, корсаклары гөптәй, аяклары җептәй нindидер шәүләләр, тимер башлы таяклар, чукмарлы камчылар, тимер чылбырлар белән коралланып алып, үзләрен-үзләре кыйный, кара канга туздырып җәзалый һәм әллә нинди авазлар чыгарып, җир тырнап, мәйдан тирәли гү килә...» Көнбатышның натуралистик мәктәбенә нигез салучы әдипләре мондый трагик картиналар, мондый кан өшерлек вакыйгалар сурәтләү турында хыялландылармы икән?! Чалкарны кырып салган ваба эпидемиясеннән исән калган Гарифулла һәм аның хатыны Өммегөлсемнең моннан соңгы язмышы да көнләшерлек түгел. Совет кешеләренә язган «төсе-башы качкан, эче-карыны киселгән заманнар»ның иң ачы язмышын кичерү: Бөек Ватан сугышында яралану һәм әсирлек газаплары, һәм качкынлык михнәтләрен үтү, армия контрразведкасында «фашистлар да сава алмаган эчәгеләрнең савылуы», сугыштан соң үзең теләгән эшкә урнаша алмау, инде еллар тынычлангач, болгавыр чор үтеп киткәч, оныкларның телдән һәм традицияләрдән ваз кичүен күреп сызлану. Утызынчы елларда*

*мәчет манарасын кисеп төшергән Өтәләү Зарифның йөзенә төкергән, шул сәбәпле илен-йортын ташлап китәргә мәҗбүр булган Садретдин мәзиннең оныкларының уллары-кызлары туган телне белми, «А когда она умрет?» — дип сорау бирә картәнисенең алка-беләзекләренә кызыккан кызчык. Татарның фаҗигасе ул кичергән михнәтләрдә түгел, менә шушындый алмашынуда бит. Чорның касәфәтен исән-имин иман белән уза алмауда. Сабый чакта сәке астына качып дога кылган Гарифулла үзе дә иманын югалткан, шәһәдәт кәлимәсенең мәгънәсен аңламаган меңнәрчә замандашлары кебек: «Гомереңне иблискә табындырып үткәрсеннәр дә, инде гүр якасына җиткәч кенә намазлык өстенә менү, кемнәрдер кебек, кичә коммунист булып, бүген ишанга әйләнү — моннан да зуррак иблислек бармы?» — дигән тамырдан ялгыш фәлсәфә белән соңгы елларын үткәреп ята. Фаҗига менә шунда — кыйбланы югалтуда. Әмма әсәр мондый тоташ караңгы буяулардан гына тормый. Өметле, якты финал — Гарифулланың Әкчин станцасында, тугач та озак тормый үлгән беренче улы күмелгән урында, бердәнбер илаһ булган Аллаһы Тәгаләгә иман китереп сәҗдәгә егылуы — «Кыйбла» хикәясенең төп кыйммәте менә шул. Уяну һәм дөрес кыйбланы табу — әле безнең күп милләттәшләребезнең калебендәге канәгатьләндерелмәгән ихтыяҗ. Шул ихтыяҗын канәгатьләндереп җиһанга шәһәдәт кәлимәсе белән аваз салган Гарифулла калебендәге татлы үзгәрешне генә карыйк:*

*« — Аллаһы Тәгалә бар! Галәмдә бер Алладан башка Алла юктыр! — дип кычкырып җибәргәнен ул сизми дә калды. — Аллаһы Тәгалә, барлык гөнаһларымны ярлыка! Мине рәнҗеткәннәргә дә якты вә ачык юл күрсәт, ялгышларыннан арындыр! Мине рәнҗеткәннәргә мин рәнҗемим, әгәр алар, шайтаннан котыртылып, ни сәбәпледер миңа рәнҗи икән, Ходай Тәгалә, сиңа ялварсыннар!..*

*Аңа рәхәт иде. Кайчандыр кеше булып туып һәм тәрбияләнеп, партиягә кермичә, шул ук партия тарафыннан котылгысыз рәвештә сугышчыга, азат итәм дип басып алучыга әверелдерелгән, таш базларында да җанын издермичә ташчы-интеллегент булып кала алган Гарифулла гүяки бүген яңадан үзенең төп сыйфаты — кешелегенә кайта иде...»*

*Хикәянең соңгы юлларыннан күңелне кузгата торган якты моң сирпелә. Айдар Хәлимнең күп хикәяләренә хас үзенчәлек бу. Аеруча соңгы елларда иҗат ителгән лирик хикәяләрендә бу моң көчле яңгыраш ала. Фаҗигане якты итеп тәгәлләүнең матур үрнәге белән без «Өч аяклы ат» повестенда ук очрашкан идек. Күләме белән кечкенә, әмма гыйбрәтле язмышлар сыйдырган «Ыгдыбыгды чокыры» хикәясенең юлларыннан да саркый ул моң. Җәрәхәтле күңел-*

*ләрнең матурлыгы, самими мөнәсәбәтләрнең бөеклеге булып та яңгырый ул, үткәннәр турында уйлану, киләчәккә өметләр булып та ишетелә. Унбер яшьлек Кадерҗанның «ярман җирен дә»ге абыйсы Әхмәтҗанга язган хатын гына укып карагыз: хәерчелек, ачлык, ялангачлык, шуларның капма-каршысы булган никадәрле күңел көрлеге, самимилек белән өретелгән тапкырлык, үз хәлеңә сабырлык белән шөкер итә белү зирәклеге, хәлеңнең аянычлыгын уйламыйча бүтәннәр турында кайгырту, хәтта дошманга да хәерле теләктә булу. Тарихта тиңе булмаган геноцид шартларында исән калуның бердәнбер юлы шушы түгелме? Яки, киресенчә, шундый самими беркатлылык харап итмәдеме безнең милләтне? «Берлинга хат» хикәясенең һәр юлы, һәр җөмләсе коммунистик идеологиянең халык җилкәсенә никадәрле газаплы йөк булып төшүен, кот очарлык югалтуларга китерүен фаш итә, гаепләү акты булып яңгырый. Әдип фаш итүнең иң кулай ысулын тапкан, чөнки һәркем белә: сабый теле белән хакыйкать сөйли. Хикәя авторының унбер яшьлек бала хатының табигый стилен бирә алу осталыгы да сокландыра, хат исә үзенең аяусыз фактлары белән тетрәндерә, еракта калган тарихның ачы хакыйкатен раслаучы документка әверелә. «...Әле халхуз блгадиры Әмир абзый, трахтыр блгадиры Гани абзый, читават Әүдагый абзыйларны, андыйларның иге-чиге юк — ярты авылны кулга алдылар. Әмир абзый, чәчүгә төшкән трахтырисларны кызганып, берәр пот иген өләшкән булган. Пркаруллар килделәр дә, йорттан йортка упыска кереп, игеннең булганын-булмаганын кырып-себереп алдылар. Минебай, Ярый бабайларның былтыр көз бал сатып алган игеннәрен дә кәнфискәвәйт иттеләр. Безгә дә керде упыс. Хет чакыр, хет акыр — безнеке такыр...»*

*Өзекнең соңгы җөмләсенә генә игътибар итегез: сабыйлар эчкерсезлеге генә шундый катлы-катлы мәгънәне бирә ала. Кара шатлык, мескен бәхет, сагышлы сөенеч, әрнүле ләззәт турында укырга була аннан. Кайгы хакында шатлык белән сөйләү куәсе бары тик балаларга гына бирелгән. Кырыгынчы елларның кара фаҗигасе турында бәян иткәндә, «Шатҗан Кадерҗан» стилен сайлау — әдипнең табышы. Язучының бер хикәя эчендә бер стильдән икенчесенә күчү таланты да сокландыра. Публицист Айдар Хәлим сөйләме белән бала образына кергән әдипнең нәфис стиле янәшәлеге авторның иҗади егәре, персонажның индивидуаль сөйләмен бирү потенциалының зурлыгын күрсәтә.*

*Сабыйлар теленең җорлыгы, тапкырлыгы, дөньяга бала күзләре белән караудан ясалган ачышлар, хак бәя, эчкерсез омтылышлар, бала күңеле аша узган чор панорамасы язу-*

*чының «Кылганнар чәчкә атканда», «Трофей ашъяулык», «Тегe малай» хикәяләрен туплаган циклына да хас. Әсәрләрнең үзәгендә психологик анализ остасы булган әдип тарафыннан яратып эшләнгән Канәгать образы. Әлеге образ үзендә милләтнең гүзәл сыйфатларын туплаган, күпмедер дәрәҗәдә ул «Казыктагы тальян»дагы Бәгъремне, «Өч аяклы ат»тагы Кәбирне хәтерләтә. Хикәяләрнең сюжеты нигездә тышкы вакыйгалар тәэсирендә барган кичерешләр хәрәкәте буларак үстерелә. Караңгы, фаҗигале чорның дәһшәтле вакыйгалары сигез-тугыз яшьлек бала күңеле аша үткәрелеп, якты төсләр белән баетылып укучыга тәкъдим ителә. Беренче карашка, драма йомшартыла кебек. Ләкин укучының сизгер күңеле тоя: ачы хәсрәт, түзеп булмаслык шартлар авырлыгы безнең милләткә хас булган түземлек, сабырлык катламы астына яшерелгән. Хикәяләрдә әдип бу юлы публицистик комментарийлардан баш тарта, максатына нәфис әдәби сурәт, нечкә сызыклар, персонажның күңел тибрәлешен тасвирлау аркылы ирешә. Биредә һәр деталь күп нәрсә турында хәбәр итә, һәр диалог, өзек-өзек һәр реплика артында мәгънә тирәнлеге укыла, күп кенә очракларда подтекст текстка караганда күбрәк сөйли. Талантның сәнгать теле белән сөйләү потенциалы хикәя юлларына тулысынча салынган. «Кылганнар чәчкә атканда» хикәясеннән Миңсылу-Миңзыя диалогын гына алып карыйк:*

*« — Миңсылу сеңлем... Мин бит Габделәхәдне сигез ел... сигез ел юньләп күргәнем юк! Кем өчен җир сөргән дә, кем өчен кан койган ул?.. М-ба... м-ба... Башта кахул җирләрен, аннан латыйш җирләрен, аннан фин җирләрен азат итте, аннан бу сугышка китте... Балалар аталарын күрмичә үстеләр бит, Илаһым!.. М-ба-мба...*

*— Сезнеке исән әле, Миңзыя түтки.. М-ба-мба... Көткәнсең — көт... Исән булса, бер кайтыр. Әнә, тере булгач, кара солы... җиде елдан да... алабута җитмеш елдан да җир тырмап чыга, ди...*

*— Без бит, Миңсылу сеңлем, кара түгел — ак солы! Ак солы! Маңгаем агындагы миңем генә кара минем... Мин үзем ап-ак, сеңлем!.. Безгә кешенеке... юк!.. — Ул тагын үксеп куйды. — Без алабута түгел — ак бодай күмәче идек!..*

*— Габделәхәд соңгы хатын Колыма дигән җирдән... Ун елын утырып чыккач... мәңгелеккә шунда сөргенгә калырга придписанҗә, дигән... (Миңзыя түтки тыела алмыйча тагын да үксеп алды)... И-и, сеңлем... Мине дә чакырачакмын, дигән... Барырга микән?... Үземне дә, балаларны да төрмәгә тыкмаслар микән?*

*— Юкны сөйләмә, безнең вылач моңа юл куймас. Бармый диме, түтки! Бармый диме! Үзең — ир, балаларың ата каде-*

*рен күреп үсәр, түтки... Рөхсәт ителсә, тай, ычкын, сыптырып сал син моннан, түтки! Колымада... алтын комы дисең. Алтын комы юган җирдә... моннан да начар булмас әле...»*

*Сабыр, түзем татар хатыннарының шауламыйча гына, зарларын бөтен дөньяга түкмичә генә үзара сөйләшуләрендә никадәр драма, подтекст артына яшерелгән күпме хәсрәт! Бу әңгәмәне йокы аралаш тыңлап яткан Канәгать күкрәгендәге «Безнең эшебез гадел, без җиңдек» дигән язулы бакыр медальнең әдәби деталь буларак функциясе дә шушы диалогтан соң тагын да ачыклана төшә.*

*Совет власте алып барган сәясәт тарафыннан рәхимсез изелгән, толлык газабын кичергән, әмма үзендәге иң матур сыйфатларны саклап калган, иманын, динен сатмаган татар хатын-кызларының якты образы Айдар Хәлим прозасында игътибар үзәгендә. «Өч аяклы ат»тагы Сания, «Кыйбла»дагы Өммегөлсем, «Кылганнар чәчкә атканда», «Трофей ашъяулык»тагы Миңсылулар совет чоры әдәбиятындагы Нәфисә, Миңлекамаллардан принципиаль аермалык белән сурәтләнгәннәр. Сүз биредә диаметраль капма-каршылык турында түгел, ә образларның тулы канлы һәм табигый итеп бирелеше турында бара. Үткән гасырның кырыгынчы еллар хатын-кызы тибы идеология таләбе белән чикләнмәгән авторда эчке бөтенлегендә сурәтләнеш тапкан. Бу инде Такташ һәм Кутуй Галияләре кебек хатын-кыз азатлыгы дигән демагогия корбаны түгел. Социалистик казарма шартларында чамадан тыш изелгән, хаксызга кыерсытылган, шулай да күңел матурлыгын, рухи нык-лыкны югалтмаган, ерткыч система тарафыннан кимсетелгән, әмма үзенең чын бәясен онытмаган, ир хакы, бала хакы дигән изге төшенчәләргә тугрылыгын саклаган хатын-кыз образы. Айдар Хәлимдә образның иң беренче чиратта ана буларак сурәтләнеше алгы планга чыга. Язучы үзе әдәби мәйданга чыгарган хатын-кыз персонажларының прототибы әнисе Миңлесорур Шиһаб кызы Хисамованы тирән хөрмәт һәм олы ярату белән искә ала. Шикләнмичә әйтергә мөмкин: әдип каләме белән сурәтләнгән ана образының бөеклеге, чынлыгы, ышандыру көче, табигыйлеге авторның үз әнисенә булган олы мәхәббәте белән тыгыз бәйләнгән.*

*Сиксәненче елларның уртасында сәяси мәйданда үзен башбирмәс көрәшче итеп таныткан Айдар Хәлимне күпләр аңлап бетермәделәр, милли хәрәкәттә катнашканда үз мәнфәгатьләрен алга куйган бәндәләр белән бутадылар, милләтләр арасында каршылык китереп чыгаруда гаепләргә тырышучылыр булды. Туган халкы өчен иң кискен минутларда аваз салган әдипнең тавышын өнәмәүчеләр дә җитәрлек иде. Шундый минутлар була: үзен татар әдибе*

*дип санаган шәхескә эндәшмичә калырга һич ярамый. Шул чакларда сәяси мәйданда давыллы һәм гаугалы итеп хакыйкатьне игълан иткән әдипкә астыртын каршылык күрсәтеп, тынычлык саклаучы булып күренергә тырышучыларның гамәле артында үз мәнфәгатьләре ятканлыгы иртәме-соңмы милләткә фаш була, тарих һәрнәрсәне үз урынына куя. Чын әдипнең фидакарьлеге артында исә гаделлек хисе ята. Айдар Хәлим милләтчелеге нигезенә балачактан ук тәрбияләнгән хакыйкатькә омтылыш салынган. Шушы сыйфат аңа беркайчан да тынгылык бирми, совет чорында ук сәяси эзәрлекләнүләр аша узып чыныккан әдип әле бүген дә актив көрәш мәйданында, һәм аның көрәше милләтләргә каршы түгел, ә икейөзле сәясәткә каршы юнәлтелгән. «Көнбагыш чәчкәсе» хикәясе аның менә шушы көрәшенең максаты, шуңа хәрәкәт бирүче тойгы-хисләр турындагы гүзәл поэма, баллада булып укыла. Хикәя элеккеге СССР территориясендә яшәгән барлык халыклар теленә дә тәрҗемә итеп таратылырлык идеягә нигезләнгән. Чын милләтчелек һәм интернационализм идеяләре белән сугарылган бу әсәр укучы күңелендә тиешле яңгыраш табар дип ышанам.*

*Сүзне без моң дип башлаган идек. Моң... Бу сүзне тәрҗемә итеп булмый диләр. Шулай да мин бүген «Татар вакыты» романын, «Өч аяклы ат»ны һәм бу җыентыкка кергән лирик хикәяләрне дөнья телләренә тәрҗемә итеп таратыр идем. Татар моңы булып яңгырасын иде алар башка милләт вәкилләренең дә күңелендә.*

*Рәшит Фәтхрахманов,*
филология фәннәре
кандидаты

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

# КАЛЕБ ЯРАТЫЛГАНДА

## КЫЛГАННАР ЧӘЧКӘ АТКАНДА

*Баязит авылыннан якын кардәшем, мәгърифәтче Мөхәммәт абзый Рәфикый истәлегенә*

### I

Халык телендә «тастымаллык» дип аталган шадра тукымадан, кулдан, эре атлатып тегелгән һәм әле беренче тапкыр гына киелгән ак күлмәк, кызыл киҗеле кыска киндер ыштан белән өстен-башын бөтәйтеп алган һәм шул ыштаны белән болдырдан торып барлык ихатаны кызыл әләм кебек кызарткан Канәгать, тәкате бетеп, ачык ишеккә кычкырды:

— Озак мыштырдыйсың, инәй!

— Әй, шушыны! — Мич арасында ни сәбәпледер озаграк азапланган әнисенең өзгәләнгән тавышы ачык ишек аша тышка саркылды. — Бер нәрсәне телеңә алсаң, нәкъ атаң мәрхүм кебек, өзмисең дә куймыйсың... Уттай эш өстендә бала-чага җаена тырай тибеп йөрергә, мин дә инде, юләр!.. Башына тай типкән, дип, шул минем ишеләр турында әйтәләрдер инде!..

Әнисенең «уттай эш өсте» дигәне бер яктан бигүк дөреслеккә туры килеп тә бетми кебек. Әле авылда печән өсте тәмамланмаган, урак өсте башланмаган чагыштырмача бер тыныч аралык. Канәгатьнең ике абзасы да печәндә. Салучин яланында. Куна ятып эшлиләр. Әнисенең: «Бәрәңге төпләрен күмеп бетергәч тә, сине Миңзыя түткиләргә Җидегәнгә алып барам», — дигән сүзе бар иде шул. «Түткигә илтәсе кәҗә мамыгым да киезләнеп бетә инде», — дип тә өстәгән иде. Менә ул, нибары сигезе тулып, тугызга чыгып килгән Канәгать Сибгатуллин абзагыз, берүзе дип әйтерлек, уналты сутый бакчаны күмдереп чыкты. Монда, әгәр күрергә теләсәң, һәр бәрәңге төбендә аның күз алмалары тәгәрәп ята. Кичләрен, калхуз эшеннән бушаган араларда, аңа әнисе белән абзыйлары да ярдәм иткәләште, әлбәттә. Әнисеннән зур ярдәм өмет итү

оят иде. Ул бит — уразада. Көне буе янган кояш астында авызына бер тәгам азык, бер йотым су алмыйча, балавыздай эреп, телләрен аркылы тешләп, иреннәрен җир кебек чатнатып, йөзләрен челлә ялкынында ялкынландырып кайта ул. Кайтып кергәндә йөзеннән гүя парә-парә челлә ялкыны коела да, шул ялкыннан капкага, бар ихатага, йорт-җиргә ут каба. Аны кызганудан Канәгатьнең елыйсы, тагын да ныграк тырышып эшлисе килә башлый. Кайтып керә әнисе, тик урын өстенә егылмый. Тагын да шул бәрәңгесенә йә үзенең башка бихисап дөнья мәшәкатьләренә тотына. Ничекләр генә түзә, ә?!

Уразадагы кешегә көне буе үз төкреген дә йотарга ярамый, ди, бит.

Бер сорарга иде — нигә тота икән ул үзен җәфалап шул ураза дигәннәрен?

Шул бәрәңге җирен казу, аннан орлыкны утырту, озак та үтми бакчаны басып киткән билчән, эт эчәгесеннән арындыру, бәрәңгене утау-йомшарту, төпләрен күмү, казып чыгару, чүпләү, эресен эрегә, вагын вакка аерып берәмтекләп кышлыкка базга салу өчен Канәгатьнең күргән җикләре! Туфракта иске орлыктан яңа бәрәңге үрчетү аңа күктә яңа йолдыз үстерү белән бердер кебек. Йолдызлар да күктә казандагы бәрәңге кебек ярмаланып кайныйлар. Бакчадан шалтырап кар базына сикереп төшкәнче, бәрәңге чынлап та йолдыз бәясенә басадыр, билләһи. Бәрәңге — татарның тормыш әлифбасы, әйе, әлифбасы — әле генә беренче сыйныфны тәмамлаган Канәгать «Әлифба»ның нәрсә икәнлеген бик яхшы белә, шуны исегездән чыгармагыз! — саны-сыйфаты, кушуы-алуы, бүлүе-тапкырлавы икән ул. Их, бу ачлыкның михнәтләре... Язгы аклы-карада чабатаңда бер пот балчык өстерәп, туң җирне казып-чокып, кияргә чабатаң да булмаса, бозлардан бозларга яланаяк сикереп, салкынның утлы өермәсендә табаннарны пешерә-пешерә черек бәрәңге эзләп үтә бит аларның көннәре, тәмам карага, тау, болын яшеленә басканчы. Их, яшелләнә башлаган тау борынына аяк басу, беренче юаларны авыз итү өчен шул тауларга йөгереп менүләр!.. Их, әниләре — тол хатыннар, абзыйлары — ятим малай, үсмерләрнең, эшкә киткәнче һәм кайткач, өмәләр ясап, җыйнаулашып шул җирне казып чыгып, туфракны йөрәк җылысы белән җылытып, орлыклык бәрәңге утыртулар, җир астыннан борау кебек боргалана-боргалана яшькелт-шәмәхә үсентеләрнең борынлап чыгуын көтүләр, аннан аларны якты күздән үткәзеп, чүпләрен утап, ике, өч, теләсәләр, көчләреннән килсә, ун кат китмән белән эшкәртеп, йомшартып, төпләрен күмдереп чыгулар!..

Канәгатьнең иң канәгать чагы — бәрәңгенең Канәгать турында оныткан, аның барлыгын-юклыгын тәмам хәтереннән чыгарып, чәчкә аткан, бераздан бизәкле тукыма кебек

шау чәчкәдә утырган чагы. Бу чорда бәрәңгенең күзгә күренмәс күзләре ниндидер мәхәббәт томаны белән томанлана, ниндидер сөрмәле рәшә белән өртелә. Гүя барлык бакча, һәр бәрәңге сабагы, укытучылары Гаяз абый кебек зең-зең килеп, аклы, зәңгәрсу, күксел-көрән, шәмәхә мандолиннарда зеңгелди! Бакча җырлый! Канәгать белә: тирән күзле бәрәңгеләр бары тик зәңгәр чәчкә генә ата. Их, ул чәчкәләрнең зифа көязлеге, иркә сылулыгы, үзләренә генә хас серкәле һәм тиз уалучан матурлыгы! Канәгатьнең мондый сирәк, нәфис чәчкәләрне хәтта Кралов урманнарында да күргәне булмады. Аның бәрәңге чәчкәләрен Балкызның чәчләренә кадыйсы килеп китте. Балкызны кем дисезме?

Бар инде шунда бер кыз,
Исеме аның — Балкыз, —

дип, шигырь дә чыгарган иде әле ул. Бергә укыйлар. Быел беренче сыйныфны бетерделәр.

Хак булса, бәрәңге чәчкәсенең матурайта торган шаукымы да бар, ди. Хак булса, Әби патша җәй көннәрендә, бәрәңге чәчкә аткан чорда, үзен уратып алган сарай кызларына чәчләренә бәрәңге чәчкәләре кадап килергә куша торган булган, ди...

Исе юк бу чәчкәләрнең. Исләрен тойыйм дип иснәсәң, аклы-көмеш серкәләре борын очыңны гына серкәли. Аның каравы баздагы бәрәңгенең үзенчәлекле исе бар, базда озаграк булсаң, агуланырга да мөмкин. Шуңа күрә базда озак мыштырдарга, андагы бәрәңге исен иснәргә яратмый Канәгать. Әмма бәрәңге исен яратмаса да, бүгенге көндә, дөрес, аларның базларында кызык өчен генә иснәп карарлык та бәрәңгеләре юк.

Кәҗә майларын чыгарганчы эшләде быелгы җәйдә Канәгать. Гел-гел кояш астында булып, шунысын аңлады: бәрәңге бакчасында шәүлә дә, күләгә дә була алмый икән. Анда син үзеңә-үзең шәүлә дә, күләгә дә. Анда йә якты, йә караңгы. Йә эссе, йә салкын. Әйе, күзләренә күренә, төнлә төшләренә кереп йөдәтә аның бу бәрәңге төпләре! Быелгы җәе дә бик коры килде шул. Яңгыр бөтенләй диярлек яумады. Туфракка кизәнү белән китмән астыннан туфрак түгел — порхылдап коры тузан оча, тузан! Җир аның әнисенең иреннәре кебек чатнады. Урыны-урыны белән ат тояклары, арба тәгәрмәчләре төшеп китәрлек булып ярылды. Күптән түгел котырып бер яңгыр явып үткән иде үтүен, шуннан соң көеп саргайган таулар да яшелләнеп китте, бәрәңгеләр дә көч-хәл алды.

Әнисен көткән малай болдырдан тагын бер тапкыр бәрәңге бакчасына күз ташлады һәм горурланып куйды: тере кәртинкә инде, кәртинкә! Шау чәчкәдә. Кем бакчасы дигәндә, ул: «Мин — Канәгать абзый бакчасы!» — дип кычкы-

рып тора. Бәрәңгеләрнең һәр төбе соңлап яуган яңгырлар белән бергә аның күз яше һәм тир тамчысы белән сугарылган. Һәм ул — күрегез! — әнисе белән Җидегәнгә кунакка бәрәңгеләре котырып чәчкә аткан чакта бара!..

Чәчкәләре коелгач, бакча, куе яшел түскә кереп, күп балалы ана сыман моңсулана. Гүя Бәрәңге Анасы балалары белән аерылышуны сизенә. Канәгать бу аралыкны бигүк өнәп бетерми. Бу чорда аның үзенә дә күңелсез булып китә. Әйе, атна-унбиш көн үтми, бәрәңгеләрнең канатларын каера-каера, аларның төбен актара, яшь, бала бәрәңгеләрен ашый да башлыйлар. Канәгатьнең мондыйларны яткырып камчы белән суктырасы килә. Хәер, ул аңлый: болар барысы да юклыктан, ачлыктан бит. Күпләр, чоланнарында умачлык оны, базларында ашка салырлык та бәрәңгесе, чөгендере калмаганнар, шулай иртә, әле чәчкәдә килеш керешә бәрәңге төпләрен ботарларга. Чыга, чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, чыпчык күкәе кадәр булса да бәрәңге малайлары чыккалый инде шунда. Аның өлкән абзыйсы Галәветдин бакчаны болай тота-каба гына ботарлаттырмый. Быел ул энекәшләренә юан уклау гына күрсәтте: «Менә, чамалыйсызмы, кардәшләр? Әгәр чамаламасагыз, кардәшләр, сыртыгызда шарт сындырачакмын. Шунысын чамалагыз, кардәшләр!»

Абзыйлары аңа һәр иртәдә боерып кына китәләр: «Менә сиңа, энекәш, утыз ызан. Хет көл, хет үл — без кичен кайтуга күмелгән генә булсын». Ә ашарга? Ашарга ни... шул бакча башындагы чөгендер яфрагыннан пешерелгән боламык инде. Бар гаилә шул боламыкта гомер кичерә. Канәгать еларга да иткәндәй итә, әмма елап ни майтарасың? Әтиләре сугышта ятып калды. Уртанчы абзыйлары исә үткән кышның ачлыгында кинәт кенә үлеп китте. Аны духтырга алып бара алмадылар, духтырлар үзләре дә килмәде. Бабайлар, «сукыр эчәк түгел микән бу?» дип, кырык ясин чыкканнан соң, таң алдыннан китте дә барды. Менә аның әле кигән кызыл ыштаны да шул абзыйсының җеназасында хәергә килгән байлык...

Җәйнең тимерне дә эретеп агызырлык челләсендә башын ат башыдай эре, салкын суда чылатылган әрекмән яфрагы белән каплап алды да күмде дә күмде ул бәрәңге ызаннарын. Күз аллары томалана, башлары әйләнеп, күңелләре уйный башласа, беразга гына күләгәгә кереп торды. Моны малайга кырык градуслы эсседә иген басуы утаган әнисе өйрәтте.

Менә шундый тырышлык белән үтәп чыга торган булды ул абзыйларының көндәлек боерыгын. Бер тапкыр, өч кенә ызанны күмеп җиткермәгән өчен, өлкән абзыйсы кече абзыйсына: «Сугып очыр син аны, елмаеп барып төшсен!» — дип кенә җикерде. Салып очыруын очырмады аны кече абзыйсы, әмма арка сыртына берничә тапкыр каеш белән та-

мызды. Канәгать аңлый: аның абзыйлары ифрат та әйбәт кешеләр, алар шул дөнья кытлыгыннан гына шулай дәҗҗалланалар. Юклыктан, яратудан, бары яратудан гына тәпәләп алалар аны абзыйлары. Әнә бит Галәветдин абзыкае кичә кич, ягъни ул бәрәңгеләрне күмеп бетергән кичтә, Кыяметдиннәрдән алып торган гармунын тышка чыгарып, тупсага утырды да, Канәгать энекәшен «гетти-гетти-геттигә»гә биетте, аннары күкрәгенә әнисенең даһи Сталин башы төшкән Җиңү мидалын такты. Ул мидал әле дә малайның күкрәгендә. Күрәсезме сез? Анда нәрсәкәй язылганын ул укып та бирә ала: «На-ше дел-ло пр-ра-вое мы поб-бед-дил-ли…» Аның белән җиз мидал да Җидегәнгә бара, димәк ки.

Әле әнисенә Җидегәнгә барасы ял көнен дә блгадир Лотфыйдан шул абзыйлары алып бирде. «Безнең шундый тырыш энекәшебезне, инәй, Җидегәнгә алып барып күрсәтеп кайт!» — диделәр дә эшкә киттеләр.

— Сиңа гүләйт тә гүләйт инде… — Әнисе сөйләнә-сөйләнә өйдән чыкты. Тупсадан төшкәндә кинәттән туктады да кире күтәрелә башлады. — Тукта, балам!.. Чак-чак ишегебезне бикләмичә китеп бармаганбыз бит, Ходаем! Биклик! Бикләми буламы? Бар, берәр нәмәрсә алып бир!..

Канәгать болдырдан җиргә сикерде дә, утынлыктан каен чыбыгы алып бирде.

Әнисе келәне элдереп, бикнең бөҗрасына чыбык тыкты.

— Менә булды. Бөтенләй юк ише түгел. Дус бар — дошман бар дигәндәй…

Сөйләнә-сөйләнә алар калтайган канатлары белән икесе ике якка чалшаеп торган урыс капка аша урамга чыктылар да, уңга борылып, ат юлы янәшәсендәге бәбкә үләне өстеннән салынган такыр сукмак буйлап киттеләр.

Ниһаять, сәяхәткә чыгу шатлыгын кая куярга белмәгән Канәгать әнисен күздән кичерде. Нишләп шулкадәр дә матур икән ул? Аның иякләре, күзләре, бит алмалары, әллә аяк атлаулары матурмы, моны аерып кына әйтә алмый Канәгать. Матур инде, бик матур. Бары шул гына. Әнисенә нәрсә кисә дә килешә. Кып итеп кенә тора. Нишләп шулай икән ул? Алкаларын, чулпыларын тагарга да, көмеш беләзекләрен кияргә дә онытмаган. Шул алка-беләзекләреннән бүген бөтенләй нурланып, матурланып киткән. Гүя басудан сусапкөеп, йөзеннән кисәк-кисәк кояш көекләре коелып кайткан уразалы Миңсылу, калхузчы Миңсылу түгел, ә бәлки, Айдан төшкән Зөһрә кыз! Гүя балтырган, кузгалак, кычыткан, чөгендер яфрагы кебек урман-ялан, бакча үләне белән түгел, ә бәлки гөбернатырлар, янараллар ашый торган затлы манпачилар белән тукланган солтанбикә!

Ничек түзә икән ул? Телләре кибеп, эштән кайткач та, ул

«авыз ачарга» ашыкмый, авыз ачар сәгатен көтеп, Канәгатьне ияртә дә Өязе буена китә. Улын сакка куя да, берәр «кеше-кара күренсә, тамак кырырсың» диеп, ат күмелерлек таллыклар, зәһәрләрен коеп утырган чәчкәле кычытканнар, ат кузгалаклары артында яшеренеп, агымсуы аяк йөзенә генә чыгып торган елгада су коена. Ничек коена? Аннан, көне буе сусыз торып-торып, ничек итеп йотым су да капмыйча, шул суның эчендә... су керергә мөмкин икән ул, ә?

Әйе, чынлап та матур шул аның әнисе. Малай тәртәдәге ат янында уйнаклаган колын кебек, икенче якка сикереп чыкты да аңа тагын бер тапкыр карап куйды: әнисе беркайчан да киенми-ясанмый. Буянмый. Махсус елмаймый. Әмма гел генә елмаеп торган кебек. Бу елмаю аның йөзеннән йоклаганда да китми. Менә әле дә аның йөзендәге кояшлы сагыш, кояш челләсе кунакка гына кия торган вак яшел чәчкәле күлмәген, нәзек путасын, хәтта ап-ак йон оекларын, елтыр кәвешләрен дә яктырткан. Чәчләрен ипле генә итеп уртадан аерып үргән дә, кара төрткеле ак яулыгын сыерчыклатып, алкалы колакларын тышта калдырып бәйләгән. Чәчүргечләрдән төшкән дүрт чулпысы атлаган саен зең-зең итеп аваз салып куя...

Әнисе кулындагы ап-ак болытка охшаган зур төенчектә — кәҗә мамыгы. Анысы да капма-каршы чалынып ак яулыкка төйнәлгән. Аларның Чибәркәй дигән мамык кәҗәләре бар. Күзләре зәп-зәңгәр. Ул абзардан чыгу белән бөтен ихатага ямь керә. Мамыгы да зәңгәрсу, дөресрәге, күксел-зәңгәр. Канәгатьләр белән бер сыйныфта укыган Балкызның да күзләре шундый күксел-зәңгәр бит. Ул да Канәгать кебек сугыш ятимәсе. Канәгатьнең, ярый әле, әнисе бар. Әмма картинәсе, картатасы юк. Балкызның янында әнисе юк, әмма картинәсе, картатасы бар. Аның әнисе кайдадыр еракта, бик еракта урман кисеп, турф чыгарып йөри диме шунда...

Әнә Йомры Гариф малае Әгъләметдин читәннәренә зур колаклы сары самавыр булып эленгән дә Канәгатьне күзәтә. Алар авылда бер булып ел да шалкан чәчәләр. Аның шалкан ашап күбенгән корсагы да самавыр корсагына охшаган. Ә бәрәңгеләре әле һаман да чүп эчендә утыра икән.

Сизә Канәгать, тегенең беләсе килә.

— Кая барасың, әй?

Белми торсын әле. Канәгать аның каршыннан башын да бормыйча, керфеген дә какмыйча үтеп китте.

— Беркая да бармыйм әле, әй.

Шулай үтеп китәргә хакы бар. Бәрәңгесен күмеп бетерсен иң элек. Күкрәгендә даһи Сталин төшкән мидалы да юк. Тастымаллыктан тегелгән ак күлмәк тә, тезгә генә җитеп торган гарадскуй кызыл ыштан да тәтеми аңарга. Аннан,

Канәгать аталы балаларны бик өнәп тә бетерми. Әллә ниндиләр алар. Менә Әгъләметдин дә шундый. Ат кунасына йөрми. Үпкәчел. Үпкәләтсәң, иренен салындыра да, ирене белән урам себерә башлый...

Баш очыннан гына, «Кая пар-рас-сыз?» дигәндәй, пырылдап чыпчыклар өере очып үтте.

Өязенең аргы ягында урнашкан ихатасыннан Бәдигыльямалның Кыяметдине дә атылып килеп чыкты. Чыкты да катып та калды. Канәгатьнең дусты ул. Аларның күреге пышкылдап торган гармуны бар. Авылда бердәнбер гармун. Шуңа күрә барыбер көй чыгара. Галәветдин абзыйсы биеткән гармун аларныкы бит инде. Кайвакыт абзыйлары Кыяметдиннәргә йә бакчаларын казыша, йә урманнан корысары утын төшерә дә, тегеләр шул хакка аңа берничә көнгә гармуннарын биреп тора.

— Кая барасың, әй?

— Тогочка, — дип җавап бирде эре генә Канәгать.

«Тогоч» — «теге оч» дигән сүз. Канәгать сизенә, монысының да кызыл ыштан турында беләсе килә. Монысы да күпне белми торсын әле. Тиз картаер югыйсә. Шушы бер сүзле җавап белән әңгәмәне ябып, Канәгать юлын дәвам итте. Әмма үзсүзле Кыяметдиннең бәйрәмчә киенеп, әнисе белән каядыр китеп барган малайны озаграк сөйләштерәсе, нинди йомышка чыгуын белеп каласы килә иде, күрәсең.

— Яңа ыштаның котлы булсын, әй.

— Ыштан түгел, чалбар.

— Барыбер инде...

— Бер дә барыбер түгел, — дип җавап бирде Канәгать. Аннан дусы Кыяметдинне кызганып, өстәп куйды: — Коллык, әй. Сиңа да бирсен Ходай.

Шулай диде дә — борынын күтәреп үтеп тә китте. Бар, тот син хәзер Канәгатьне.

Сәбәхетдиннәр күпере турысыннан үтеп, казыклары кычытканнар эченнән чалыш-полыш тырпаеп торган читәннәр буйлап Җидегәнгә таба юл алдылар.

Аңа юлда әнисе белән рәхәт тә, читен дә. Әнисе аны талгын адымнары белән тоткарлап килә.

Авыл кырыена җитеп, оч-очларындагы тишекләреннән сүс көлтәсе сыман аксыл төтен чыгарып янып яткан күмер һәм эзбиз базлары янына җиткәч, кызурак барасы, кем әйтмешли, тупсадан тизрәк түргә үтәсе, кыскасы, бәрәңге бакчасыннан гайре башка бернәрсә күрмәгән һәм киң дөньяны тизрәк танырга хыялланган малай, күкрәгендә кайнаган хисләргә урын табарга теләп, йөгерә башлады.

Йөгерә торгач, ул таныш куш өянкесе белән каршылаган Өязе үзәненә дә килеп җитте. Юньләбрәк караса: өянкеләр-

нең елгадан чыгып торган юан тамырларына тешләре белән килеп кадалган тимер тырмалар ята. Алар янында тияклә-ре-ниләре белән ат дирбияләре. «Кичә Нәгыйм абзый тырмадан кайтканда, атлары дулап китеп тырмасыз кайткан, дип сөйләгәннәр иде, хак икән»,— дип уйлап алды малай. Бу тырма, тияк-дирбияләрне нигә һаман килеп алмыйлар, калхузга кирәк түгел микәнни?

Елга үзәне буйлап бераз өстәрәк каяндыр югарыдан гөбертәп ишелеп төшкән су тавышы биләп алды аны. Әйе, анда, югарыдарак, шарлама бар. Канәгать чуерташлар өстеннән чорлый-чорлый агып яткан агымга керде. Су тубыкка җиткәч, ул нишләптер туктап калды. Ары таба барса да, елганың тирәнлеге шуннан артмас иде артуын, һы, шәүләсе күренми! Төшлеккә җиткән кояш астында казык кебек туры торган гәүдәнең шәүләсез булуын малай белә белүен. Ул көлемсерәп куйды. Һы, монда да төшке бәрәңге бакчасындагы кебек шәүлә юк икән!.. Шәүләсез кояш!.. Кинәт ул аяк чәлтерләрен төрле яклап нәрсәнеңдер кымтый, кытыклый башлавын тойды. Караса — йөзләгән вак балык челбәрәләре аның балтырларын сырып алганнар да, әниләренең корсагы астыннан имчәк эзләгән сукыр песи балалары кебек, кечтеки авызлары, борыннары, мыеклары белән аны кымтыпмы-кымтыйлар, капшапмы-капшыйлар! Челбәрәләрне тотарга теләгәндәй хәрәкәт ясап, казыктай туры гәүдәсен сындырып, аз гына бөгелгәндәй, су өстенә иелгәндәй итте — аның кинәт барлыкка килгән шәүләсеннән өреккән челбәрәләр елт итеп юкка да чыктылар. Гаҗәп бит: аның шул ук туры гәүдәсе аз гына иелү белән шәүләгә әйләнде һәм бернинди явызлык, бернинди гамәл кылмаган килеш тә тере җаннарга курку салды. Тере җаннарның бер гаепсезгә аңардан куркулары аның үзен үк шөбһәгә төшерде. Шәүләнең бу сыйфаты малайны шаклар катырды. Адәм баласының кушылган эшне эшләми калдырып та шәүләгә сылтау, шәүләнең еш кына дәлилсез өркетү, үзеңнән үзеңне куркыту мөмкинлекләре аны киләчәктә гомере буе борчый һәм кара кайгыларга сала торган чыганакка әйләнәчәген ул белми иде әле...

Әгәр ул балык тотарга теләсәме? Әнә теге, әле аңардан югарыдагы агымда шаулап, аска гөбердәп сикереп төшкән шарламадан «Менә болай!» кочак-кочак (Үз-үзе белән сөйләшкән малай үзе дә сизмәстән колачларын җәеп җибәрде!) тота алачак! «Кочак-кочак» дигән гыйбарәдән кәефе килеп, пырхылдап көлеп җибәрде. Әйе, бу оч малайлары түбән очныкылар кебек балыкны кармаклап азапланмыйлар. Әнә шул шарламага баралар да, ыштаннарын-күлмәкләрен салып, шарлама астына керәләр һәм су агымы ясаган казанга кулларын тыгалар да...

Шул манзараны күз алдына китергән малай агымсуда чаптыр-чоптыр килеп югарыга таба менеп китте...

Елгасы кечкенә, тавыш-тынсыз акса да, ул ясаган шарламаның тавышы ифрат та зур, гаугалы һәм галәмәт иде. Агым биредә чынлап та чиләк, казан сыман чокыр хасил иткән. Күрәсең, биредә югарыдан сикергән агымсуны меңләгән куыклар белән богырдата, агып килгән суны өстәмә һава, азык микъдары белән баета, нәтиҗәдә бу һава һәм азык балыклар өчен аеруча уңайлы яшәү шартлары тудыра. Ике биек яр арасында бикләнеп гөпелдәгән шарлама тавышы якынайган саен, аның колаклары тона барды һәм менә ул, ниһаять, килеп җитте. Култыкларына кадәр җиңнәрен сызганды да, биеклектән үзләренчә урра кычкырып аска сикергән агымсулар шарламасының казанына кулларын тыкты...

Һава куыклары чыгарып кайнаган казанга дыңгычлап тулган балыктан кул тыгарлык та урын юк, андагы балыкны хет сабы шартлап сынганчы яссы көрәк белән төяргә мөмкин иде. Кулларын иркәләп чәүмәшкән вак балык боткасын ул ике кулының бармаклары белән сөзгечләп укмаштырды да кушучын кояшка чыгарды. Анда терекөмеш — тирә-якка сикерешә-сикерешә тере балыклар уйнаклый!..

Малайның аларны элеккечә өенә алып кайтып, сөттә-йомыркада куырасы килде. Әмма моның өчен бүген бөтенләй мөмкинлек юк иде. Иртәгә килеп китәр әле. Теләсә, табасы белән сөзеп тә чыгарыр, шунда ук куырып та ашар.

Канәгать кулында калган балыкларны су өстенә сипте дә, урыны-урыны белән чылана төшкән күлмәген юеш кулы белән сыйпаштырып, кире куш өянке янына ашыкты. Әнисе аны ташлап китә күрмәсен тагын.

Өязенең түбәнге агымында эре балыклар да бар, алар бары тик шәһәрдән кайткан кармакларга һәм бары тик шәһәрдән кайткан сартауай җимнәргә генә каба. Канәгать берничә тапкыр үзе ясаган тимерчыбык кармаклар белән селәүчәнгә кармак салып карады — бар, тиз генә каба ди сиңа эре балык, ыжламады да.

Әнисе кичүгә җитеп кенә килә иде.

Әле генә «кочак-кочак» балык тоткан малай оекларын, елтыр кәвешләрен кулына тотып, яланаяк кичү кичкән, инде хәзер яр буендагы орылы ак ташта киенеп утырган әнисенә эчендәге куанычларын җиткерергә ашыкты:

— Инәй, ә, инәй!

— Нәрсә, балам?

— Безнең Өязе нинди зур елга, әйеме?

— Таптың тагын елга! Елга димәсәң, хәтере калыр... — Ниндидер уйлар белән борчылган ана йөрәксеп сөйләп китте: — Үләргә яткан кешенең каны кадәр генә типченеп ята

инде шунда... Нәкъ үзебез кебек. Ни эше корысын, ни үзе корысын...

Канәгатькә бу бер дә ошамады.

— Юк, елга! Безнең Өязе — елга!

Уңына-сулына карамыйча киенеп, бөтәеп утырган әнисе, улының хәтерен калдырырмын дигән уйны башына да китермичә, борын астыннан гына мыгырдануын дәвам итте:

— Монда килеп утырган ата-бабаларыбызны әйтер идем... Тәүбә вә әтәүби иляһым!.. Җире — сазлык, елгасы — ни үлми, ни терелми. Чумып чыгарлык бер чоңгылы юк... Кем әйтмешли, ага шунда кибәр-кипмәс, сүнәр-сүнмәс, шиңәр-шиңмәс...

— Безнең Өязе — зур елга! — дип кычкырып җибәрде малай, чын-чынлап үпкәләгән тавыш белән. — Безнең Өязе — диңгез ул, дәрья ул!..

— Дөресе, инеш инде ул, улым, — дип, җибәргән хатасын төзәтергә тырышты ана. — Башка якларда мондый инешләрне чишмә дә, кизләү дә диләр.

— Юк, бернинди чишмә дә, кизләү дә түгел. — Канәгать үз дәлилләре белән «һөҗүмгә» күчте. — Сезнең чишмә һәм кизләүләрегездә балык үрчеми. Аларның суы суык. Безнең Өязе җылыкай. Шуңа күрә анда кочак-кочак балык! Әйдә, алып барып күрсәтәм!..

## II

— Әссәламегаләйкемнәр!..

Аваз килгән якка борылсалар — Миңлегазиз бабай. Чишмә Башы Миңлегазиз карт. Үлән яшеле йоккан чабаталарын исәпләмәгәндә, кигән киеменең барысы да актан. Изүе сулдан калдырылып тегелгән озын, тир тозында, кояш нурында һәм кер селтесендә тосләре, хәтта кайчандыр кара булган буйлары, төрткеләре, бизәкләре дә ашалып, агарып беткән киң җилкәле, җилпуч итәкле җитен күлмәге дә, озын тулаекларына кыстырып киелгән, күп юудан җилсенеп, уңып беткән киң төпле ыштаны да, күзенә кадәр батырып киелгән киез эшләпәсе дә, мөселманча калдырылып түгәрәкләнгән сакал-мыеклары, хәтта курысы суеп төшерелгән юкагач юл таягы да актан иде аның. Ул гынамы? Сул кулын сугышта бөтенләй өздергән, яралы, тезеннән каткан уң аягын исә ничектер читләтеп, ярымтүгәрәк ясап уратып атлаган картның гадәттә җилфердәп торган буш җиңенең очына бүген нindидер елтыр кыллары белән буранлап торган үлән бәйләнгән. Канәгатьнең уйлавынча, ил буйлап хәл белеп йөрүче Хозыр Ильяс нәкъ менә шушы Газиз бабасы кебек булырга тиеш иде.

— Исәнме, Газиз бабай! — дип сәламләде аны малай.

— Вәгаләйкемәссәлам, Миңлегазиз абзый! — диде әнисе.

— Кая юнәлдегез болай, Миңсылу карендәш? — Карт, кояштан сакланып, кулларын каш өстенә куйды. — Карамал базарына түгелдер бит? Малайны да ияртеп, димен.

— Кая ди инде ул безгә базар юлларын таптарга, Миңлегазиз абзый, — дип, әнисе зарлангандай итте. — Сатарга малыбыз, алырга хәлебез юк. Менә Җидегәнгә барасы иттек әле. Агылыйга-тагылый... — Әнисе аңа ымлап, сүзендә бераз арттырып та җибәрде. — Җыландай телләремне чыгарып әйттем — калмый бит. Ярар, ураза бәйрәме алдыннан бераз дөнья күреп кайтсын...

— Ә-ә-ә, менә монысы мәслихәт, бик мәслихәт!.. Савaплы юлга чыккансыз, карендәш! Монавы уч төбендә генә торган Җидегәнне дә күрсәтмичәме? — Карт әнисенең фикерен күтәреп алды. — Хәзер бит аларның башлары башаклан-ган, йомрыланган чаклары... Хәер, Канәгать улымның башы болай да йомры инде аның, ә? — Ул кеткелдәп көлде. — Кара әле, Миңсылу карендәш, малаең бит бакчагызны ничек кенәләр тиз китмәнләп чыкты, ә? Олылар эшли алмаган эшне, ә? Шундый тырыш кешегә Җидегән кадәр Җидегәнне күрсәтми диме? — Ул Канәгатьне күкләргә чөеп мактарга тотынды. — Укытырга кирәк аны, Миңсылу карендәш! Соңгы тавыгыңны сатып булса да, укытырга кирәк. Әфисәр булсын!.. Димнәмир, акбәкәт булсын!.. Быррач, палищщик булсын!.. Күр дә тор, зур кеше чыгачак аңардан. Аның йомры башы, ишетәсеңме, Керимел сәгате кебек тек-тек итеп тора!..

Карт колагын җилгә куйгандай итеп, тагын да кеткелдәде, исән кул яссуы белән дөпелдәтә-дөпелдәтә Канәгатьнең аркасыннан сөйде.

Аның белән бергә вак чуерташлар өстендә дерелдәп таягы да кеткелдәп көлде.

— Рәхмәт, Миңлегазиз абзый. Анысын инде кистереп кенә әйтеп булмый. Аттан ала да туа, кола да туа дигәндәй... Менә аталары гына...

Әнисенең тавышы өзелде.

Карт, бугазыннан «кых» дигән аваз чыгарып, карашын түбән төшерде.

— Син үзең каян киләсең соң? — диде әнисе, ниһаять, тамагындагы төерне йотып җибәргәндәй итеп. — Болай иртәләп...

— Иртәләп, дип... Сәхәр ашадым да, урманга киттем. Печәнлектә бераз чабасы җирем калган иде... Шунда мендем дә, иртәнге — сабах намазымны укып, тәпәлисе печәнне тәпәләп бетердем, иншалла. Аннан... — Карт эчендәген әйталмаган төсле тыелып торды. — Аннан нәрсә... минекен беләсез, шул чишмәләр инде... Печән өстендә йөрергә бөтен-

ләй форсат тимәгән иде... Атна-ун көнгә бер барып күрмәсәм, ташлар басып киткәндер, җылап яталардыр кебек. Шуларны карап кайтып килешем.

Картның җиң очына бәйләнгән сәер ефәк үлән учмасы бөҗраларыннан кояш нурларында әлҗе-мәлҗе килеп көмеш коела иде. Малайның бу хакта сорыйсы килгәнлеген сизгән кебек, Миңлегазиз бабай үзе үк аңлатырга керешге.

— Кылган бу. Ата-бабалардан исән калган, сирәк кылганнар. «Көмеш кылган» дип атала алар. Чәчкә атканнар, балакайларым. Кылган үләненең югалган хәтерне кире кайтара торган шифасы бар, дигән борынгылар...

— Һы! — диде Канәгать аптырап.

— Кылган чәчкә атамыни ул, Миңлегазиз абзы-ы-ый? — диде сузып әнисе.

— Ата шул. Дөрес, сирәк чәчкә ата. Елына карап. Аллаһы Тәгаләнең бар нәрсәсе дә могҗиза бит: явымлы елларда кылган чәчкә атмый, ә менә быел җәйдә нибары бер яңгыр булды — чәчкә аткан... Бар далага шаркылдап көлеп утыралар!.. Еллар хәерле булыр, Ходай кушса!.. Савытка куям мин аларны. Тәрәз төбенә...

— Ә кая аларның чәчкәсе? — дип сорады күңеле һаман тынычланмаган Канәгать.

— Бәй, менә шушы бөҗра-бөҗра булып айдарланган көмеш кыллар кылганның чәчкәсе була да инде...

— Һы. Кызык икән.

— Бер очратканда сорап калыйм әле, Миңлегазиз абзый, — диде әнисе, җилдә уйнаклаган кылган сабакларыннан күзен алмыйча. — Шул чишмәләрне караганың өчен силсәүиттән берәр өлеш чыгармыйлармы? Берәр пот иген, агач труттин белән булса да түләмиләрме, диюем...

— Түли!.. Таптың тагын!.. — Карт тагын таягы белән бергә кеткелдәп көлде. — Чишмәләрне караган өчен налук салмасалар ярый әле!.. Аллаһәппәргә йөрим. Аннан, бирәсе бурыч өчен түләү сорап йөреп булмый бит. Табигатькә дә күз-колак кирәк. Сугыш та бетте, сазлык киптерәбез дип, тугайларга, чишмәләргә, иген мәйданы арттырабыз, ялгызак агачларны төплибез дип, урманнарга каршы наступлинҗә* башланды. Бер кулым, бер аягым исән чакта, хет чишмәләрне караштырып калыйм, ичмасам. Барысының да авызларын ихаталап алдым. Тын юлларын киңәйттем. Абайлыйсызмы, мондый коры елда да Өязедә су кимеми? Мул гына бит, ә?

Карт таяк очы белән су агымында уйнады.

Канәгатьнең эчендә нәрсәдер «елк» итеп куйды.

---

* Һөҗүм.

— Өлеш, дигәннән. Чыгардылар... Кхе-кхе... Шунысына да куанам. Элек минем нинди генә кушаматларым юк иде — Карун Газиз, Ялгызак Газиз, Гарип Газиз, Аяксыз Газиз, Чатан Газиз, Чулак Газиз... Чишмәләрне сөрдерү, малдан таптатудан туктыйк, дип, күп чәпчи торгач, үземә «Чишмә Башы Газиз» дигән ләкапне дә өстәп чәпәделәр дә куйдылар! Тегеләрен оныттылар, мин сезгә әйтим!.. — Бабалары бу юлы таягын гәүдәсенә сөяп, исән кулы белән яшьле күзләрен сөртә-сөртә рәхәтләнеп, ләззәтләнеп көлде. — Чулак Газизләр онытылды! Чишмә Башы Газиз генә калды. Халыкка рәхмәт, халык һәйбәт безнең!..

Карт сөйләгәнне малай йотлыгып тыңлады. Аның күзләре ялкынлана, бит алмалары алсуланып яна иде. Чишмә Башы Газиз кушаматының хак мәгънәсе турында элек уйлап та карамаган бит ул, почык борын!

«Чишмә Башы Газиз бабасы шушы үзе була бит инде!» Аның әле үз янәшәсендә таяк очы белән агымсуларны чайпалтып торуыннан файдаланып, малайның әнисе белән ике арада булган бәхәсне чишеп каласы килде.

— Газиз бабай! — Ул, тәмам батыраеп китеп, алгарак чыкты. — Газиз бабай, менә син әйт әле, безнең Өязе елгамы, әллә чишмә генәме?

Карт авызын ачкан килеш катып калды.

Ул сораудан тынсыз иде.

— Әйттем бит, моның башы Мәскәү Керимеле, дип. Мондый сораугa тота-каба гына җавап бирү шүтке түгел. — Карт авыз тирәләрен, сакал-мыекларын сарган тир бөрчекләрен кул аркасы белән сөртеп алды. Өянке күләгәсенәрәк ышыкланып, сүзен дәвам итте: — Ну, рәхмәт. Эр-рәхмәт, яме! Безнең авылдан миңа мондый сорауны биргән кеше син беренче әле. Күр дә тор, Миңсылу карендәш, мондый сорауны биргән кеше бик зур кеше булачак!.. — Ул малайга якын килеп, күзләренә текәлде. Аның белән бергә Канәгать янына тирбәлә-тирбәлә картның буш җиңендәге көмеш кылганнар учмасы да килде. — Менә син үзең әйт әле, кияү белән кәләш... гаиләме, түгелме?

— Син бигрәк инде, Миңлегазиз абзый, — дип каршы төште әнисе. — Сигезенче яше белән барган бала каян белсен инде аны?

— Тукта, карендәш, тукта. Алай димә. Зиһен көчәнергә тиеш. Ул шунда гына эшли, ялкаулыкка өйрәнми. Йә, йә!..

— Г-а-и-л-ә, — диде малай, авазларны авызыннан берәмберәм сытып чыгарып.

— Түгел шул, түгел, мин сиңа әйтим! Кияү белән кәләш — алар бары тик кияү белән кәләш кенә! Кечкенә сабыйлары... ягъни мәсәлән, синең кебек малайкалары булгач кына

әйләнә алар гаиләгә. Әгәр шул малайка булмый икән, алар кияү белән кәләш булып картаялар, мин сиңа әйтим. Вәт!..

Миңлегазиз бабасы авыр итеп тын алды.

— Елгалар да шулай. Чишмә ялгыз акканда ул әле чишмә генә... Аңа башка чишмәләр дә кушылгач, елгага әверелә. Менә безнең Өязе чишмәсе дә үзенә нәкъ сез бара торган Җидегән авылын яңгыратып утырган Аюлы Кул, Әнәч Кулы, Тукмак Кул чишмәләре кушылгач кына елгага әверелгән. Чишмәләрнең суы никадәр мул, саф булса, елгалар да шулкадәр мул, саф сулы була... Өязе!.. — Карт ниндидер тирән сагышлану белән уфырып тын алды. — Җир йөзендә бу кадәр алыплар, акыллы кешеләр үстерә торган бүтән бер генә елга да юк! Бу ни өчен шулай дип уйлыйсыз? Аның суында адәмзатның миенә кирәк булган сирәк металлар күп... Алтын-көмеш күп!.. Өязе, безнең Өязе... Безнең өчен иң зур елга ул. Ул безнең диңгез, дәрья... Юк, акиян!.. Аны буган буаларда тегермән куласалары әйләнә, еликтыр станцалары эшли. Әгәр теләсәк, без анда парахутлар да йөздерә алабыз!..

— Әйттем бит! Әйттем бит!.. Өязе безнең өчен иң зур елга, дәрья!.. — Малай, кулларын чәбәкәйләп, Миңлегазиз карт тирәләй биеде. — Чишмәләр каян барлыкка килә?

— Чишмәләрме? Алар да кешеләр кебек туалар һәм үләләр. Аларны да Ходай Тәгалә яраткан... — Бабай бераз уйланып торды. — Коръәннең «Бәкарә» сүрәсендә чишмәләр ярытылуы турында менә нәрсә диелә: «Муса пәйгамбәр таягы берлә ташка орды, таштан унике чишмә агып чыкты, чөнки алар унике кавем-кабилә иделәр. Һәр кабилә үзенең чишмәсен белде...» Менә синең чишмәң — шушы Өязе була инде. Син аны белергә, мәңге хөрмәтләргә һәм мәңге онытмаска тиешсең...

Болар барысы да Канәгать өчен серле китап укуга тиң иде. Ул бабасыннан күбрәк белеп калырга тырышты.

— Бабай, ә, бабай! Әйт әле, менә... иген ничек үсә? Кешеләр үзләре үсә, шулай бит? Иген бит ул үсәргә кеше түгел? Шулаймы?

— Җитте инде сиңа, — дип, җиңелчә битәрләп алды улын ана. — Бер сораша башласаң, чиген белмисең. Миңлегазиз бабаң бит сиңа прафисыр да, Әфләтүн* хәзрәтләре дә түгел...

— Тәүбә, диген, улым! Кешеләр үзләре генә үсә алмый. Менә сине, мәсәлән... — Карт малайның әнисенә караш ташлады. — Әниең үстерә, шулай бит? Әниеңне дә, сине

---

* П л а т о н — безнең эрага кадәр 428–348 елларда яшәгән бөек грек фикер иясе.

дә, мине дә, игенне дә Ходай Тәгалә яраткан һәм Ходай Тәгалә үстерә. Иген бөртеге дә кеше кебек тере җан ул. Аның да әнисе бар.

— Кем?

— Җир-ана. Шуңа күрә Җиргә Җир-ана диләр дә.

«Мәктәптә нигә бу хакта сөйләмиләр икән? — дип уйлап алды Канәгать. — Шушы хакта гына сөйләсәләр дә, дәресләр күпкә мавыктыргычрак үткән булыр иде...»

— Кешеләр җирне беренче тапкыр сука белән сөргәндә, Җир-ана бик нык җылаган, ди. Авырткан аның тәне. Ходай Тәгалә аңа әйткән: «Син әлегә түз. Кешеләрне азыкландыр. Аякка бастыр. Җылыт. Ашат. Киендер. Үстер. Яшәсеннәр, матур, батыр булсыннар, ата-аналарына, Ватаннарына шатлык-бәхет китерсеннәр. Үз көннәре җиткәч, алар барысы да сиңа мәет булып кайтырлар һәм синдә туфрак-балчыкка әйләнерләр...» Бу чынлап та шулай, улым. Кеше дөньяга килә һәм китә.

Канәгатькә эссе көндә суык булып китте.

— Үләме?.. Кеше барыбер... үләргә тиешмени? Кеше үлемсез булып калалмыймыни? Минем үлемсез буласым килә!..

— Тәүбә, диген! Адәм баласы бары тик җаны, эшләгән эшләре белән генә үлемсез була ала.

Малайның йөзе яктырды.

— Тәне белән — юк, үлемсез булалмый.

Малайның йөзе караңгыланды.

— Үлемсезлекнең кызыгы юк, улым. Үлемсез кеше имансыз кеше булган булыр иде. Үлеме бар кеше тормышта тереләр алдында, ахирәттә Ходай Тәгалә алдында бурычлы. Шуңа күрә адәм баласы үз гомерендә кешеләрне рәнҗетмәскә бурычлы.

Бурычсыз тормыш мәгънәсез... Барыгыз, бар, юлыгызда булыгыз! — дип куа башлады карт аларны, кинәт кенә уянып киткәндәй. — Мин сөйләрмен ул, минем тел сөяксез ул!.. Кхе-кхе...

Өянке күләгәсеннән чыгып, ул үзе дә авылга таба юнәлде. Әмма аны әнисенең соравы туктатты:

— Гает намазы кайчан икән, Миңлегазиз абзый?

— Бүген сишәмбеме әле? Сишәмбе. Быел ике бәйрәм рәттән туры килә икән бит. Гаетне җомга алдыннан, атнакич иртән укыла, диделәр, кардәшем. Бәйрәмнәр мөбарәк булсын!

— Шулай була күрсен, Газиз бабай! Исән бул, Газиз бабай!

— Сау бул, Канәгать улым. Сәламәт бул. Хәерле юл сезгә!..

## III

Газиз бабасы белән сөйләшүдән ифрат тирән шаукым алган малай, үзе белән бергә әнисе дә барлыгын онытып, алга томырылды. Бераз киткәч борылып карасa — бабасын гүя җир йоткан, ә әнисе уң кулындагы ак болыт сыман ак төенчеген култыгына кыстырып тугай юлыннан килә иде.

Канәгать бабасы турында уйланды. Гаҗәп кызык кеше икән бу Чишмә Башы Газиз карт. Чалгы сабын сул кулының буш җиңенә бәйләп куеп, бер кул белән печән чаба, ялгызы сыер асрый, сава, сөтен аерта, маен яза, дигәннәр иде — хак икән, әй. Бу кылганнар учмасын бер кулы белән ничегрәк итеп җиң очына төйнәде икән ул? Мондый чакларда аны теше белән төйни, диләр. Ул гынамы, сөйләүләренчә, шул исән кулы белән арбага печән, утын, бүрәнә төйи, печән йөген хәтта берьялгызы бастырыклап арканлый икән. Анысы да дөрестер — тәмам ышанды Канәгать. Якыннанрак кызыксынсаң, чабатасын да үзе тукыйдыр әле ул. Җәен-кышын буш вакытларында күрше авылларга йөреп, әйтем-мәкальләр, төрле риваятьләр, шәҗәрәләр җыя дип тә сөйлиләр иде — монысы да рас икән. Авылда Газиз картның хатыннан уңмавы турында да сүзләр ишетелгәли. Шул ук Җидегәндә аның менә егерме ел инде бер килеп, бер китеп йөри торган хатыны да бар, имеш. Әйе, өлкәннәр халкын аңлап бетмәссең, аларның күңел ишекләре Канәгатьләр ишеге кебек чыбык белән генә бикләнми. Аларның йозак эчендә йозак, тозак эчендә тозак. Ә менә Газиз бабасының күптән түгел, дөньяда бер мөслимә артыр дип, күрше чуаш авылыннан хатынлыкка бер чуаш хатынын алып килүе чынында да дөрес. Дөресендә дә чын. Аларны бергә моннан берничә көн элек авыл лавкасында Канәгать үз күзләре белән күргән иде. Авылда «Татардан хатын табалмаган Газиз» турында чираттагы гайбәт чыккач, бабалары, имеш, чуашлар чукынмаган халык, алар шул ук төрки-татар, дип җавап биргән, имеш. Газиз бабалары чуаш хатыны белән никах укыткан, имеш. Барысын да белә бу халык, белмәгәне юк бу халыкның!..

Йөгергән уңайга малай «Нинди заман, нинди кешеләр!» дип горурланып куйды. Канәгатьләр буыны алар кебек нык һәм максатчан була алыр микән?

Өязе ярлары җәясеннән ук булып атылып чыккач та, Канәгать алдында ике яктан да таулар култыклап алып барган тугайның иркен күренеше ачылды. Малай тыны кыса башлаганчы чапты-чапты да туктап әнисен көтте, хәле беткәнче чапты-чапты да туктап әнисен көтте. Шулай итеп үтәсе юлы да сизелмичәрәк үтә торды. Кайчандыр сугышка кадәр киндер ашы, җитен чәчелеп, чөгендер, суган, мал тормасы утыр-

тылып, үзендә дөрес чәчү әйләнеше саклаган җир, сугыш һәм аңардан соңрак чорда чәчелми торып нәселсезләнгән, әле булса нәкъ сугыштан чыккан кешеләр кебек аңшайган, урыны-урыны белән үзен урман кебек басып киткән кырлы курай, ат кузгалагы, әче гөрләпәләр, тагын да әллә ниткән эт эчәгеләре, билчән, кузаклы һәм кузаксыз, күзәнәкле һәм күзәнәксез үлән-үсемлек кыргыйлашкан халәттә гомер сөреп ята иде...

Тугайны мең төрле үсемлекләрнең һәм чәчкәләрнең куе хуш исе биләгән. Тынына шушы хуш исләр капкан Канәгать бары тик аска — аяк астыннан йомгак кебек сүтелә барган юлга карап йөгерде дә йөгерде. Ул җирдә йөкле һәм йөксез кырмыскаларны, купшы күбәләкләрне, үз кабырчыкларына качкан әкәм-төкәмнәрне күрмичә узып китте, ә инде туктаган, әнисен көткән арада, аларны кулларына алып сыйпады, иснәде һәм алар белән кеше телендә сөйләште.

Менә юлны урталай кисеп, саран гына саркыган суы белән җирне юешләтеп яткан Тукмак Кулы чишмәсе аша чыккач, юл тауга таба үрли башлады. Канәгать тагын артка борылып карады: ак төенчекле әнисе әле тугайның уртасына гына җитеп килә икән. Ул, үзен сынап, тауга бер тында йөгереп менү бурычын куйды: менә алса — егет, менә алмаса — җебек.

Ерак арага йөгерә торган йөгерешчеләр кебек терсәкләрен ян-якларына җөпләп очлады һәм «һу!» дигән аваз чыгарып тирән тын алды да тауга үрмәли башлады. Аның белән бергә күкрәгендә леп-леп килеп мидалы да үрмәләде. Ул юлдан читкә карамаска тиеш. Караса — уй бүленә. Уй бүленсә — кәеф үзгәрә. Кәеф үзгәрсә — теләк үзгәрә. Теләк үзгәрсә — хезмәт үзгәрә. Менә аның тыны кыса башлады. Юк, ул тиз генә бирешмәячәк. Тагын йөз адым. Йөз ыргылыш. Тыны тәмам кысты. Юк, ул болай гына чигенмәячәк. Малай офык читенә күз сирпеп алды — әле тауның өченче, соңгы өлеше үтелмәгән. Тын кысуын онытырга тырышып, ул Өязенең башта гади генә чишмә булуы, аннан аңа Аюлы Кул, Тукмак Кулы, Әнәч Кулы чишмәләре дә кушылгач, акиянга әйләнүе турында уйларга тырышты.

Малай алга, юл артка шуышты. Гүя алар сабантуйда аркан белән тартышалар иде.

Ун ыргылыш. Тагын ун ыргылыш.

Тирләгән йөзен, чәчләрен сафландырып йомшак җил исте.

Туктады. Карашын юлдан күтәрде. Зур итеп күзләрен ачты.

Канәгать тауга менеп җиткән һәм кызыл ыштаны белән аның түбәсенә кызыл әләм булып кадакланган иде.

Ул ат юлыннан чыкты, тауның биек чокаймәсенә басып, карашын ерак-еракларга юнәлтте — аңардан дистә чакрымнарда офыклар ачыла һәм бу офыклар бөҗрадан бөҗрага

күчеп алышына иде. Кайдадыр сулда — Смородин, Олы Кәркәле, турыда — Таукай-Гәйнә, Тәтер-Арыслан, уңда — Хлебороб, Корманай, Кыргыз-Миякә, артта — Өязебаш, Өршәкбаш-Карамалы, Әнәч авыллары, аларны уратып алган карурманнар, елгалар-күлләр аша карашын ерак-еракларлардагы Ырымбур тарафларыннан үзенә таба түгәрәктән түгәрәккә тарайтып, кечерәйтеп килде-килде дә, туган авылы Колтамакта тукталып, тирән итеп тын алды.

Аның өчен Җирнең кендеге нәкъ шушы Колтамакта иде.

Әнә шул кендектән чыккан һәм яшел яланнар аша нечкә генә тасма булып сузылган юлдан кулына тоткан ак төенчегендә алга-артка атынып, шушы түгәрәк дөньяның хуҗасы булган әнисе — җыйнаклардан да җыйнак, тыйнаклардан да тыйнак, уймаклардан да уймак, матурлардан да матур әнисе килә.

Болар барысы да Канәгатьнең байлыгы иде.

Аның күкрәген сихри хисләр биләп алды.

Ул кулларын җәйде һәм Колтамактагы Миңлегазиз бабайлары ишетелерлек итеп кычкырып җибәрде:

— Әс-сә-ла-ме-га-ләй-ке-е-ем!..

Җавап бирүче булмады.

Нинди иркен, нинди киң, нинди матур иде аны тудырган-үстергән Туган Иле!..

Бераз гына түбәндәрәк кемдер нәзек кенә итеп сызгырды.

Тирә-ягында беркем дә юк иде.

Сызгыру башка тарафлардан да кабатланды.

Малай бар гәүдәсе белән очлыкүзгә әйләнде.

Ни күзе белән күрсен, йомраннар, берсе нәкъ ул килгән юлның читендә, икенчесе алар белән ике арада, нәкъ кеше, нәкъ Канәгатьнең үзе кебек, юк, дөрес түгел, намазга азан әйткән азанчы картлар сыман, кул яссулары белән колак яфракларын ышыклап, тегендә һәм монда арт аякларына басканнар да, йомраннар, якты соры йомраннар, гүя малайның үзенә үк сызгырып, үзенә үк исәнлек авазы салып, бер-берсе белән хәбәрләшепме-хәбәрләшеп маташалар!

«Биредә йомраннар оясы икән».

Форсаты һәм янында дуслары булган булса, ул элеккечә, гадәттәгечә, елгадан су ташып, аларны ояларыннан гөргеләп чыгарган, эһ дигәнче тунаган һәм тиресен иске-москы, сөяксанак җыючы Суфиян бабаларына тапшырып, ун тиен акча да юнәткән булыр иде.

Бу йомраннар да аның байлыгы иде.

Канәгать ике бармагын авызына тыгып, әче итеп сызгырып җибәрде.

Йомраннар шундук гаип булды.

Тагын сызгырды. Аскы теш казнасының алдагы бер сы-

ник теше күренеп калды. Аны быел, кыш таудан чана шуганда баганага бәрелеп сындырган иде ул.

Талгын гына җил исте. Дала тирбәлеп алды. Канәгатьнең шәрә балтырларын нәрсәдер, бая елгадагы вак балыклар сыман, кытыклап куйды. Малай еракларга түгел, үзе басып торган түгәрәк даирәгә, үзе яшәп азапланган боҗрага илтифат итте һәм үзенең ачышыннан һушын югалткандай катып калды.

Әнекәйгенәм!

Таулы дала бер офыктан икенче офыкка Газиз бабасының буш җиңсәсендәге кылганнар кебек миллионлаган көмеш учмалар белән кыйралып тирбәлә иде!

Кылганнар чәчкә аткан!

Синең бәрәңге чәчкәләрең генә нәрсә ул!

Биек нәселле, эре төпле кылганнар арасыннан башы калкынып күренгән малай үзен бер караганда аксыл-яшькелт, икенче караганда тулаем аксыл-куе яшел, өченче караганда яшькелт-соры көмеш булып дулкынланып, тирбәлеп, башта алга, аннан артка мәтәлгән, бер-берсен әбәкләп куышкан, сөеп һәм сөешеп алга йөгергән, аннан артка чигенеп чайкалган диңгездә итеп хис итте.

Бу дала диңгезе сабын күбеге белән күбекләнгән иде.

Түгәрәк-түгәрәк сиртмәләр белән сиртмәләнгән, боҗралар белән боҗраланган, бөдрәләр белән бөдрәләнгән нәзек кыллы мамыклардан йомшак нурлар ургылып чыга да, кылган очларының каурый, әтәч койрыгы сыман солтаннары барлык тарафны сабын күбеге белән күбекли. Сабакларның астагы һәм өстәге буыннарыннан ургаланып-сыргаланып күтәрелгән, як-якка бүселеп чыккан йомшак-зәңгәрсу кыллар, солтаннар, чуклар, калфаклар, чачаклар көмеш рәшә булып бар тарафларга чайкала. Бу солтаннарны, бу чукларны, бу калфакларны кызлар нигә чәчләренә кадамый да, нигә алар белән чәчләрен чачакламый икән? Хәтерлерәк булырлар иде. Әллә аларның чәчкә аткан кылганнарны күргәннәре юкмы?

Сабаклардан як-якка нindидер сөрмәле сызык булып сурылып чыккан нәзек кылларны кояш якты бәрхет чүкечләр белән чүкегән дә, тамчылы нурлар, алтынсу зәркән, көмеш нәкыш белән каеган. Нурларда төсләрен үзгәртеп, бу зәркәннәр әүмәкләшеп уйнаклый, күзгә күренмәс төсләрдә бер-берсенә кагылып зеңлиләр, чеңлиләр иде!

Кызык икән бу дөнья дигәнең! Бер бөгәле икенче бөгәл эченә керә дә утыра. Чәчкә аткан бәрәңге боҗрасыннан чәчкә аткан кылганнар боҗрасына кереп чумарга бер адым икән! Кем уйлаган?!

Йә Ходай, шушы көмеш моңнар, шушы көмеш кыяклар, шушы көмеш сөрмәле чыңнар, җепселләр аталамы чәчкәләр

дип? Кылганнарның чәчкәләре кая? Кая бу чәчкәләрнең таҗлары? Таңда яшәү алып килүче чыкларны тутыра торган күңел савытлары кая?

Канәгать үзе дә сизмәстән куллары белән кылганнарны өерелдерде. Кыяк кыякка, зәркән зәркәнгә кагылып зеңгелдәде. Иелеп иснәп карады — кылганнар коры дала, бераз гына сусыл тамыр исеннән башка бернинди дә ис белән дә аңкымый иде.

Шулчак малайның кылган чәчкәләрен кемгәдер бик тә якын, бик тә якын кешесенә бүләк итәсе килеп китте. Әнисенә! Әнисенә, әлбәттә! Йөзе җитдиләнеп калды. Сәбәбе дә бар икән шул. Аның бит әле әнисенә бер тапкыр да чәчкә бүләк иткәне юк икән. Шулай да бу гына аз тоелды. Әнисе бит аның янында, янәшәсендә! Аның чәчкә бүләк итәрлек берәрерактагырак якын кешесе юкмы? Шулчак... теге, аннан бер генә партага алда утырган чем-кара Балкыз исенә төште. Әйе, Балкызга да бүләк итәргә тиеш ул чәчкәләрне! Исеме ничек кызык, ә? Балкыз. Аның балы бар микәнни? Малай көлемсерәде. Аның шул Балкызга гел генә карап торасы, гел генә аның белән әбәкле уйныйсы, гел генә майлап тараган чәчләреннән тартасы килә. Нигә шулай икән ул?

Ул Балкызга да кылганнар бәйләме җыярга карар итте. Теләсә чәченә такыя итеп үрер, теләсә калфак, чук-чачак итеп кадар, теләсә, Газиз бабай кебек, савытта тәрәзә төбенә куяр. Аның йөрәге күкрәгенән атылып чыгардай булып типте. Ул бүләк өчен саклык белән генә капшанып һәм сыйпанып, иң матур, иң бөдрә, иң йомшак, иң елтылдык, иң сыгылмалы, иң купшы, иң көмеш зәркәнле, тагын да әллә нинди иң-иңнәрне өзеп карады. Әмма сабаклар сүс тегәрҗеп кебек ныклы булып чыкты. Өзелми иде алар. Алар сыек сынлы, тыштан мамык кебек йомшак күренсәләр дә, эчтән ифрат та үзәкле, нык, каты бәдәнле, һич кенә дә бирешмәс җан икәннәр. Малай аларны сабакларыннан бер омтылышта сындырырга итте. Эш болай да барып чыкмады. Ниһаять, ул сабакларны, солтаннарны сул кулы белән өстән тотып, уң кулы белән астан черт итеп кенә сындыра башлады. Озак та үтми аның күкрәге ниндидер сабырлык белән тирбәлгән көмеш солтаннар белән тулды. Ул җыелган бәйләмне икегә бүлде һәм шул ук кылганнарның үзле сабаклары белән бәҗралатып бәйләде. Ике кулында ике бәйләм барлыкка килде.

Шулчак сискәнеп, тирә-якка колак салды. Гүя кемдер аны күзәтә иде. Кылган төпләре мең төрле авазларда чекерт-чекерт килеп чекерти, зеңгелди, зеңли, сайрый, сыкрый, гөрли — җырлый икән! Ходайның йөзләгән төр үләннәре, үсемлекләре һәм чәчкәләре, йөзләгән төр чикерткәләре, кетнәкичләре, үрмәкүчләре, күбәләкләре, кырмыскалары, нечкә-

билләре, энә караклары — барысы да, барысы да нәкъ укытучы Гаяз абыйлары кебек нечкә билле мандолиннарда уйный һәм кояшлы гомер кичерәләр икән!

Бу куанычтан аның йөрәге галәмгә ашты.

Ул күккә карады.

Малайның алгы теш казнасындагы сынган теше кояшка күренеп калды.

Күктә, нәкъ Канәгатьнең баш очында, өстә, бик өстә, кара нокта булып бер кара козгын эленеп алган да кымшанмыйча бер урында тора да тора. Ул шаккатты: аны күзәткән бу козгынны күк гөмбәзендә гүя ниндидер бер чит көч тотып тора. Гүя ул бар дөньяны алдау өчен мәңгелек тирән уйда йотылган. Аңа киләчәкнең барысы да билгеле, шуңа күрә ул юк-барга илтифат итеп вакланып та, канатларын кымшатып та маташмый. Гүя бу козгын аша исемсез, яшерен, кара битлек кигән кемдер Канәгатьләр әле ишетеп тә белмәгән ерак Парижлар, Нью-Йорклардагы акча биржалары, караңгы бүлмәләрдән пышын-пышын килеп, шушы миллион Канәгатьләрнең генә түгел, миллион йомраннарның, кылганнарның, барча үләннәрнең һәм тере җаннарның язмышларын, аларның бәхетле йә бәхетсез булачагын алдан ук хәл итә иде...

Малай яңадан күккә карады. Козгын урынында иде.

Гүя козгын кыяфәтендәге гыйфрит, иреннәрен чатнатып ураза тоткан әниләренең бердәнбер гает бәйрәмнәрен урларга килгән...

Әмма ул тыныч, шөбһәсез һәм... шунысы кызык, бу козгыннан һич кенә дә курыкмый иде. Әйтерсең ниндидер икенче бер көч аңа ышаныч өсти һәм бу ышаныч аның маңгаеннан нурлар булып балкып чыга.

Шулай да бу борчылу аның ашказанының тегермән ташларын әйләндерде. Өзелеп-өзелеп ашыйсы килә башлады. Кылганнар арасында тамак ялгарлык бернинди үлән әсәре — кымызлык, кузгалак, балтырган, сарана, җиләк сыман нәрсә күзгә чалынмады. Тау кырлачында аларның булуы мөмкин дә түгел иде. Ул кылганны төбеннән үк өзде. Сытылып яшел сөт чыкты. Тәмләп карады — үлән сөте баллы иде. Аның янәшәсендә сарут һәм кылган кыякларыннан, үлән төкләреннән талгын искән җилдә аксыл серкәләр оча, алар берьюлы тын алып, дулкынланып, баллы җил, баллы дулкын хасил итә һәм ашау теләген тагын да көчәйтә иде.

«Тизрәк Җидегәнгә барырга кирәк. Анда кунак малаен сыйламый калмаслар».

Әнисе куып җитеп киләдер. Юлга чыгарга кирәк.

Әмма аның бу матурлыктан аерыласы килмәде.

Аяк очларына басып, тау астына караш ташлады. Әнисе-

нең сыерчыклатып бәйләгән ак яулыгы тау түбәсеннән калкына да югала, калкына да югала. Менеп җитеп килә икән шул. Ике кулына да көмеш бәйләм тоткан малай, уйнаклап алга чабып барганнан соң, кире чаптырып килеп, кылганнар арасыннан саркылып чыкты да әнисенә килеп сыенды:

— Инәй, инәй! Кылганнар чәчкә аткан!..

— Ярар, атса, — диде әнисе, аңа карамыйча да авыр тын алып. — Әйбәт булган.

Их, шушы өлкәннәр! Бигрәк җитдиләр инде. Әнисенең җавабы аны һич кенә дә канәгатьләндермәде. Ул аның икенче ягына сикереп чыкты.

— Кылганнар чәчкә аткан, — дим. — Кылганнар!..

— Сөйләмә юкны. Кылганнар чәчкә атмый. Мыек кына чыгара.

— Чәчкә ата! Газиз бабай дөрес әйткән! Менә!.. — Малай бер бәйләм әнисенә суздьт. — Монысы сиңа!..

Авыл җирендә туып яшәгән анасының — булачак киявеннән хәтта яшьлегендә дә бүләккә чәчкә алу гадәтенә өйрәнмәгән авыл кызының — авызы ерылып китте, күңеле өзелердәй булып нечкәрде.

— И-и-и, сабыем! — Ул көмеш кылганнар бәйләмен кулына алды да малаеның аркасыннан сөйде. — Әнисенә чәчкәләр җыйган бит ул!.. Рәхмәт инде! Ә монысы кемгә?

— Монысымы? Монысы... Монысы Балкызга!..

Әнисенең йөзенә кызыллык бәрде.

— Яратасыңмыни?

Малай пешкән алма кебек кып-кызыл булды. Ул бу сүзне тоя, тик аңламый иде.

— Кит әле, әллә нәрсәләр сөйлисең!..

— Кайтканда җыяр идең әле, — дигән булды әнисе юри генә.

— Анысы бит аның кайтканда, ә монысы — барганда.

— Монысын Миңзыя түтигә бирик тә, Балкызга кайтканда җыярсың.

— Юк. Кайтканда җыймыйм.

— Ул чакта Миңзыя түтигә минекен бирик тә, кайтканда миңа җыярбыз.

— Ярар.

Әнисе белән килешүенә куанган малай үзенең гадәттәге сорауларын бирә башлады:

— Кылганнарның исеме нигә «кылган» икән ул, инәй? Алар нәрсә кылган? Ә нигә «кылмаган» түгел? Алар нәрсә кылган да, без нәрсәне кылмаган?

— Җитә калды инде сиңа, хәзер башымны катырырсың. Колтамакка кайткач, Миңлегазиз абзыйдан сорарсың, яме.

Ана белән бала менә шулай чөкердәшә-чөкердәшә Өязе

буйлап «Т» хәрефе рәвешендә тезелгән уймак кебек кечкенә, җыйнак өйләре, хәтта урман авызына капланып ук утырган өйләренең салам түбәләре белән дә нурланып яткан Җидегән авылына килеп керделәр.

Биредә әле чишмәлеген дә югалтмаган, елга да булып җитмәгән Өязедә ике су тегермәне тоткан кечкенә авылга кергәч тә, сулга борылып, түбән таба төшә башладылар. Аларны ләңләң килеп сыер имчәге чаклы зур имчәкле ана эт озата барды, тора-бара бу ләңгә ана этнең бөтен нәселе иярде һәм колакны вау-вауга салды.

— Китегез, кит! — дип, кулындагы чыбык белән куарга итте аларны әнисе, үзалдына сөйләнә-сөйләнә. — Калхуз этләре түгел, калхузга кермәгән этләрдер болар!..

Этләр артта калуга колак яфракларын икенче бер илаһи шау, икенче бер бөек дөпелдәү басты. Гүя бу көч югарыдан аһылдап, лаф орып түбәнгә сикерә һәм үзен-үзе кызганмыйча чәлпәрәмә килә иде.

— Инәй, нәрсә дөпелди ул?

— Боларның чишмәләре шулай дөпелди. Аюлы Кул чишмәсе. Миңлегазиз бабаң әйткән чишмә менә шушы була инде...

— Барып карыйк.

— Тукта инде. Соңыннан.

— Ә нигә Аюлы Кул? Аюның кулы... Әй, кулның аюы буламыни?

Килеп җитүләреннән кәефе килгән малай әнисе янәшәсеннән аю кебек лап-лап атлаган уңайга шаркылдап көлде.

— Уф, бетмәс сорауларың булды инде! Ичмасам, кеше авылында тынгы бирер идең... Безнең якларда урманлы тау, үзән битләүләрен «кул» диләр. Кул аясы... — Анасы уч төбен күрсәтте. — Кул яссуы кебек ачык җир, аңладыңмы? Бу урманнарда аюлар булганга күрә, Аюлы Кул дип атаганнар...

Әнисенең соңгы сүзләреннән соң малай күзгә күренеп үсте.

— Аюлары... әле дә бармы?

— Бар ди. Баллы табаклар күтәреп, сине көтәләр ди.

— Әйдә, барып карыйк! — Канәгать сикергәләп куйды. — Балын ялыйк!

— И-и-и, исәр!..

Малай рәхәтләнеп, авызын колагына тоташтырып көлде. Әнисе аны яратканга гына «исәр» ди бит ул.

Алар читән ихаталы, җилкапкалы йортка килеп җиткәндә, тирә-ягындагы бер көтү тавыкларын «көш-көш-шү»ләп, кулына болгау чүлмәге күтәреп һәм ике каш арасындагы кара төрткеле миңе белән бар тирә-якны яктыртып, бер апа килеп чыкты.

— Миңзыя түтки!
— Миңсылу сеңлем!
Бер мизгелгә югалып калган Миңзыя түтки нишләргә белмичәрәк торды да, һушына килеп, болгаулы чүлмәген җиргә куеп, алъяпкычының арты белән кулларын сөрткәләде дә, Канәгатьнең әнисен кочаклап алды:
— Уч төбендә торып та күрешә алмыйбыз, Илаһым! Исәнме-саумы, Миңсылу сеңлем!..
Ул елап җибәрде.
— Исәнме, Миңзыя түтки!.. Үзең дә килеп чыкмыйсың, ичмасам!..
— Исәнме, Миңзыя түтки, — диде чак кына ишетелерлек итеп Канәгать тә.
Әнисенә ияреп тутасын Канәгать тә «түтки» ди.
Түткие моңа бер дә ачуланмый. Киресенчә, болай әйтү аңа ошый гына бугай.
Авыллары чынлап та күршедә генә ятса да, авыр калхуз эшендә изелеп, теләгән чакларында очрашудан да мәхрүм кыз туганнар кочаклашып күрештеләр һәм керфек очларындагы яшь бөртекләрен күрсәтмәскә тырышып, аларны кул аркалары белән җилгә кактылар.
Алар күрешкән-исәнләшкән арада, Канәгать җиргә сеңеп таушалган читән аша түткиләренең бәрәңге бакчаларына күз ташлап өлгерде. Башка бакчалардан аермалы буларак, боларның кара-кучкылланып, ниндидер бер ятимлек белән моңсуланып яткан бәрәңгеләрендә бер генә чәчкә дә күзгә чалынмады. «Йә чәчкә атканнар, йә ата да башламаганнар».
— Рәхмәт инде, Миңсылу, үзең белән төпчегең-колынчагыңны да иярткәнсең. Бигрәкләр генә дә Гыйззетдин кияүгә охшаган бит әле ул, тьфу-тьфу, күзләре дә, кияүнеке кебек зәңгәр, таҗыраеп торалар... Кара әле, гирруй бит бу, гирруй! Күкрәгендә мидал! — Түткиләре аны кочагына алып сөйде дә сөйде. Аннан әнисенә карап алды. — Юк, юк, борчылма, минем күзем каты түгел, минем күзем тими. Бүдәнәдән — май, ябалактан — йон, эткә-кошка тоттырма!.. Атасы гына бу көннәрне күрәлмәде, мәрхүм... Йә, нишләп урамда торабыз әле без, тиле кеше шикелле? Әйдәгез, керик! — Ул борылган уңайдан бармак очы белән чеметеп кенә җирдәге болгау чүлмәген әләктереп алды.
— Әйдәгез өйгә!..
Алар яртылаш җиргә ауган капка аша үтеп болдырга күтәрелделәр.
— Йә, улым, чәчкәләреңне түткиеңә бир инде, — диде әнисе.
Канәгать уң кулындагы бәйләмен түткиенә тапшырды.
— Бу сиңа, Миңзыя түтки!..

— И-и-и, Илаһым! Рәхмәтләр инде сиңа, колынчагым!.. Кылганнар шулай ук чачаклангандыни инде? Яратам мин чачаклы кылганнарны! Нинди матурлар!.. Эш өстендә сәхрәгә дә чыгып булмый. Ярый әле, бүген блгадир, гает көненә дөньяларыгызны юыштырыгыз, дип, көн биргән иде, рәхмәт төшкере... Сез киләсе булганга икән. Менә әле йорт-җиремне бераз юыштыргандай иттем дә... тавыкларыма кычыткан төеп, болгау сибеп керим әле дип чыккан идем — сез!.. Рәхмәт төшкереләр!..

Түткиләре алар килгән шатлыктан нишләргә белми, туганнарын өерелтә-өерелтә дүрт почмаклы бүрәнә өйнең әллә саманнан, әллә таштан салынып акшарланган алгы ягына алып керде.

Анда җәннәт салкыны иде.

Юлдан арып килгән малайның бу җиләслектәге бүкән утыргычка утыруы белән үтереп йокысы килә башласа да, түткисенең эчке яктан чикыл-чикыл китереп чыгарган кашык-табак тавышы аны шундук айнытты, инде тагын ашыйсыны китереп эче боргалана башлаган Канәгать күз аяларын киереп бер могҗиза көтте. Менә Миңзыя түткие әнисе белән сөйләшә-сөйләшә базларының авызын ачты, лапылдап базларына сикереп төште, ниндидер кызыл чүлмәкнең — әйе, Канәгать белә, чүлмәк кызыл булырга тиеш! — капкачын күтәрде, калак тавышлары чыгарып, тагын да чупылдый, чикылдый башлады.

Түткие сөйләгән сүзләрнең кайберләре баз авызында йотылып кала да, кайберләре өлешләтә генә ишетелеп куя. Әмма Канәгатьнең барлык күңел гамәле теге чикылдаган савытларда иде.

— Балалар исән-саулар, шөкер... Олысы трахтырда плугар... бәләкәе ындыр... (Сүзе ишетелми калды.) Чакырткannары... (Сүзе ишетелми калды.) Нишләсәләр дә... Сбулычлар инде...

— Чү-чү, түтки...

— Мин болай гына бит. Баздан гына бит.

— Пинсә юк шул. Фрунтта үлгәнлегенә ыспрафкы китерергә кушалар. Әллә һәлак булган, әллә булмаган, диләр. Пахарункасын югалтканбыз лабаса!.. (Монысы — әнисе.)

Менә, ниһаять, Миңзыя түтки теге кара миң төрткесе белән дөньяны яктыртып баз авызыннан килеп чыкты. Ул апак, каты ярмалы, ишелергә торган, өстенә әле үзләнеп-куерып та бетмәгән сыек каймак та салынган катыклы әлүмин савытны Канәгать алдына китереп куйды. Малайның авыз сулары килде. Катыкка тыгып куелган агач кашык уңгасулга янтаймый туры басып тора иде. «Вәт, катыгы да катыгы, ичмасам. Боларның сыерлары да бар икән. Безнеке былтыр кыш зыянлады. Аксыз калдык».

Ашарга ярый микән дигәндәй, ул тирә-ягына каранды.

— Аша, колынчагым, аша, — диде түткие, аның алдына бер түтәрәм кара ипи дә куеп.

Катык белән кара ипине җәһәт кенә урынына менгезеп куйгач, аннан аерым бер канәгатьлек белән кикереп тә җибәргәч, таш келәтнең җәннәт салкынында аны тагын йокы басты. Бер якка тәмам кыйшая, читкә янтая барган малайны әнисе шундук күреп алды.

— Габделәхәднең толыбы... Фрунтка китәрдән алда гына Яңгырчы мачтырыннан тектергән иде. — Ишетелер-ишетелмәс кенә әйтелгән «Габделәхәд» дигән сүзендә «б» һәм «д» авазларына ләззәтле басымнар ясап сөйләнә-сөйләнә, Миңзыя түтки инде сүнеп үк барган малайга шундагы сәке сыман ятак өстенә урын түшәде. Әнисе аны күтәреп килгәндәй алып килде дә урын өстенә салды. — Менә монысы кыска туны... Бәрән тиресеннән тектергәниек. Балалар алмашлап кия...

«Балалары бар икән, — дип уйлап алды, басып барган йокысы аралаш. — Нәкъ безнең кебек икән. Без дә әтәйнең бәрән тунын алмашлап киябез бит...»

## IV

Әүвәлдә аның колагына әнисе белән Миңзыя түтки сөйләшкән нәрсәләр, баздан ишетелгәндәй, кергәләп-чыккалап алды. Алар бу Габделәхәд дигән кешенең — аңлашылуынча, ул Миңзыя түткинең ире була, күрәсең, — ниндидер «плингә» төшеп, ниндидер әмрикләр кулына эләгеп, безнекеләргә тапшырылуы, аннан безнекеләрнең аны ун елга төрмәгә утыртулары турында пышын-пышын сөйләштеләр. Кеше-кара ишетеп, юк өчен баш китә күрмәсен дигәндәй, Миңзыя түтки ихатага чыгып, тәрәзә капкачларын ябып, ишек бауларын нygытып керде. Алар бу тынлыкта да үз сүзләренә үзләре ышанмаган аһәң, шик-шөбһә саклап, ярым билгеле ымлыклар, пышылдаулар ярдәмендә дә аңлаша иделәр...

Ниһаять, малай йокының тирән упкынына чумды. Аның белән бергә йөгереп һәм чабып, тауларга менеп һәм таулардан төшеп арыган кечкенә йомры аяк чәлтерләре дә, бүген иртәдән бирле табигать көмешеннән чыга алмаган нәзек кенә бармаклы куллары да, хәтта куе ат кылы кебек елтыр кара, юан чәч бөртекләре дә, күкрәгендә сары мидалы да чалышаеп йокыга талды.

Аның колагы түбәндә генә үзенә чакырып дөпелдәгән Аюлы Кул чишмәсен дә, әниләре сөйләшкәнен дә ишетми иде ул хәзер.

Бала йокысы! Сабый йокысы! Фәрештә йокысы!

Көмеш моңнар! Көмеш томаннар! Якты хыяллар!

Бала йокысы кебек тирән, бала йокысы кебек нәзберек-сизгер, бала йокысы кебек татлы тагын нәрсә бар икән дөньяда?!

Менә ул тынычсызланып куйды. Нык талчыккан чакларында аякларын көзән җыера торган гадәте бар иде. Җыерчыкланып тынычсызлану йөзендә дә чагылып алды.

Бүген бик тә күпне күргән, бик тә күпне ишеткән малай саташа да, төшләр дә күрә башлаган иде...

Ниндидер өмә, имеш. Читән үрәләр. Талчыбыклары көмештән. Талларның яфраклары да көмештән. Газиз бабасы буш күлмәк җиңен җилләрдә җилфердәтеп исән кулы белән казык кага, имеш. Канәгать атасына талчыбыклар биреп тора. Атасы, әйе, аның йөзен дә күрмәгән атасы, үзе хәрби димнәрүчке, гәләфи чалбардан, көмеш талчыбыклардан көмеш читән үрә. Үргәндә талчыбыклардан көмеш яфраклар коела. Шунда ук быгыр-быгыр килеп казан кайнап утыра. Анда үтә күренмәле су, имеш. Кинәттән атасы өстеннән димнәрүчкеләрен сала башлый.

— Нигә чишенәсең, әтәй? — ди, имеш, аңа Канәгать.

— Бәй, сезгә ашарга кирәк бит, — ди атасы. — Чумып карыйм әле, төбендә берәр бәрәңгесе юк микән...

Шундук караңгы төн, имеш. Йомры Гарифның Никтуган Әгъләметдине казаннан чүмеч белән кайнар су алып җиргә сибә, җирне пешекли башлый. Газиз бабасы тагын да монда, имеш. Ул Әгъләметдинне тотып алып, кычыткан белән чактыра, имеш: «Төнлә йоклаганда башкача Җир-ананың өстенә кайнар су сипмәссеңме? Аның тәнен пешермәссеңме? — дип әйтә, имеш. — Ул да синең кебек йокыда бит!»

Сеңелкәшләр ихатага чыгып йорт-җир, бакча-ихаталарны караштырып, үз мәшәкатьләрен күреп кергәндә, кочакларында коры-сары утын да күтәреп керделәр. Учак астына ут алып, өйлә намазларын укып алдылар.

Канәгать йоклады да йоклады.

Аның борынына өйнең эчке ягыннан ачык ишек аша чыккан куе тәмле ис кергәндәй итте. Бу ис аның үзәкләренә төште. Йокысы шактый тирән булганы күрә ул бу истән уяна да һәм аңардан котыла да алмый иде. Бу халәт аны тагын да саташулар аралыгына алып керде. Әнә... әб-бәү!.. Ниндидер җен-пәриләр күрше малайлары Зәригатьне ишегалларындагы баганага бәйләгәннәр дә каеш чыбыркы белән яралар. Шунда ук бертуган абыйсы Мөхәммәт Зәригатьнең телен сандалга чыгарып салган да төя: «Бүтән урлашмыйсыңмы? Бүтән урлашмыйсыңмы?»

Әйе, быел язын Зәригать кәҗәнкә тәрәзәләре аша эчкә үтеп, Канәгатьләрнең бәрәңге кәлҗемәләрен сыпыртып чыккан иде шул. Шуның өчен Мөхәммәт абыйлары аны, арбага

бәйләп, каеш чыбыркы белән тунаган иде... Канәгатькә кызганыч ул Зәригать, бик тә кызганыч... Ул йөгереп бара, уткүршесен коткарырга итә, әмма Мөхәммәт абзыйлары, күзләрен алартып, Канәгатьнең үзенә ташлана: «Ят әле менә монда! Ызаннарыңны күмеп бетермәгәнсең! Катыкка дип аертылган сөтне урлап эчкәнсең!..»

Ул тартыша башлый. Юк, ул теге татлы, борыннан кереп, эчтәге, баш миендәге әллә ниткән катламнарны актара торган истән генә тартыша икән.

Малай уянгандай итеп, төптән, исерек карашы белән бик төптән тирә-якны сөзеп ала. Йокының вак күзле ятьмәсе аша әнисенең мөлаем тавышы саркылгандай итә. Әллә чытыр-чытыр янган учак тавышы, әллә уңайсызрак утырганга күрә, Миңзыя түткинең тавышы начаррак ишетелә... Сөйләшкәндә ниндидер авазлар, ниндидер «мба-мба»лар хасил итеп, йотыла, аңлашылмыйча уалып юкка чыга... Шунда ук кайсыдыр үксеп тә куя...

— Миңсылу сеңлем... Мин бит Габделәхәдне сигез ел... сигез ел юньләп күргәнем юк! Кем өчен җир сөргән дә, кем өчен кан койган ул?.. М-ба... м-ба... Башта кахул җирләрен, аннан латыйш җирләрен, аннан фин җирләрен азат итте, аннан бу сугышка китте... Балалар аталарын күрмичә үстеләр бит, Илаһым!.. М-ба-м-ба...

— Сезнеке исән әле, Миңзыя түтки... Көткәнсең — көт... Исән булса, бер кайтыр. Әнә, тере булгач, кара солы... мба-мба... җиде елдан да... алабута җитмеш елдан да җир тырмап чыга, ди...

— Без бит, Миңсылу сеңлем, кара түгел — ак солы! Ак солы! Маңгаем агындагы миңем генә кара минем... Мин үзем ап-ак, сеңлем!.. Безгә кешенеке... юк!.. — Ул тагын үксеп куйды. — Без алабута түгел — ак бодай күмәче идек!..

— Шулай да бит... Нишләргә соң...

Малайның сикереп торасы һәм дөньяга иң матур, иң сөйкемле булган әнисенә, каш араларындагы кара миңе белән бар дөньяны яктырткан Миңзыя түткиенә: «Юк, без кара солы түгел, без — ак Солы, без алабута түгел — без ак Күмәч!» — дип кычкырып сөрән саласы килә, тик тавышы гына чыкмый.

— Габделәхәд соңгы хатын Колыма дигән җирдән... Ун елын утырып чыккач... мәңгелеккә шунда сөргенгә калырга придписанҗә, дигән... (Миңзыя түтки тыела алмыйча тагын да үксеп алды.) ...И-и, сеңлем... Мине дә чакырачакмын, дигән... Барырга микән?.. Үземне дә, балаларны да төрмәгә тыкмаслар микән?

— Юкны сөйләмә, безнең вылач моңа юл куймас. Бармый диме, түтки! Бармый диме! Үзең — ир, балаларың ата кадерен күреп үсәр, түтки... Рөхсәт ителсә, тай, ычкын, сыптырып сал

син моннан, түтки!.. Колымада... алтын комы дисең. Алтын комы юган җирдә... моннан да начар булмас әле...

Канәгатьнең тын юлларындагы һәр төктә теге баягы татлы, ашказанын әйләндерә-тулгандыра, талак бизләрен суыра, зиһенне томалый торган хыялый серле ис тагын да яңарып көчәйде. Башта ул йокы аралаш үзенең яңа, кабатланмас, көтелмәгәнчә булуы белән бимазалады, аннан торганы белән үзләренеке, якыннан, касык астыннан чыккан таныш, гадәти булуына инандырды да, аннан тагын бу иснең бүген, бу минутта мөмкин була алмаска тиешле булып та булуы белән гаҗәпсендерде. Чыннан да, эчке өйнең мич арасыннан, казан тирәсеннән юл алып, авыр томан сыман идәнгә сарылып, салкын һава белән кушылганнан соң тагын да куерып, түзеп тора алмас дәрәҗәгә җитеп сагындырган ис иде ул.

Ис кенә дә түгел, бер могҗиза һәм маҗара иде.

Бу ис шулкадәр якын һәм ул аны шулкадәр ярата иде ки, әмма шунысы: никадәр якын күргән һәм яраткан саен, ул аның нинди ис, нәрсә исе булуын шулкадәр аңлата алмыйча газаплана иде.

Бу тәм, бу бәһасез ямь һәм гамь, яшәү белән үлем арасындагы урталыктан үтә торган бердәнбер гомер җебе иде. Бу җеп һәм бу тәм яралган җирдә үлем чигенә. Бу җеп һәм бу тәм күзгә күренми, телдә тоелмый башласа, иң тәүдә телнең, аннан илнең үзен үлем биләп ала. Бу җеп һәм бу тәм юлчы аркасындагы капчыкта да, кесәдәге янчыкта да, туфракта да, балчыкта да үлемсез, ул кипкән-коры килеш тә, чи-сулы килеш тә, хәтта кара туфракта черегән килеш тә адәм баласын үтерми саклый торган могҗиза иде... Бу ис ашказанындагы барча бизләрне кояшка чыгарып барлый, актара, күңелләрне били, авыз суларын агыза иде...

Малай уянды.

Күзләрен ачарга итте дә, беравыкка түзеп, ачмыйча ята бирде. Үзе өчен гадәти булмаган җылы йоннар, йомшак тиреләр арасында май кебек эреп ятуының ләззәтен озайтасы килде. Шулчак үзенең кайда ятуын исенә төшерде. Колак салды: тышта Аюлы Кул чишмәсе гөрелди, ябык ишек аша тавыклар кыртлавы, әтәчнең, адашып, кытаклап куйганы, әниләренең эчке якта һаман быдыр-быдыр сөйләшкәне ишетелә.

Аның тәкате калмады. Чыдамы чыгырдан чыкты. Ниһаять, танау тишекләреннән йөрәк тамырларына кадәр үтеп йөдәткән, алгысыткан һәм ярсыткан, идән буйлап ишек аша авыр, әмма нечкә, нәзек йөк булып килгән бу җанга якын, газиз, кадерле, сөйкемле исне тагын бер кат күкрәге тулганчы, тыны җиткәнче иснәде дә, тун астында киерелеп, кычкырып җибәрде:

— Бәрәңге пешердегез мәллә?!

— Әйе, колынчагым, — диде Миңзыя түткие. — Пешердек шул. Яңа бәрәңге пешердек…

Өстендәге тунны җилгәреп ташлап, сикереп торды.

Торуы булды — башы әйләнеп китте: әйе, өй эче, аның бар почмаклары, идән, түшәм ярыклары, тәрәзә яңаклары, ташкеләтне хәтерләткән алгы якның чөйләрендәге вак-төяк төенчекләр, капчыклар, кирәк-ярак әйбер, сугым элә торган тиякләр, бер сүз белән әйткәндә, һәрнәрсә яңа, әле генә пешеп өлгергән яшь, беренче бәрәңгенең күңел кылларына кагыла торган әчкелтем-төчкелтем рухияте белән сугарылган иде.

Яшь бәрәңге! Чынмы? Каян? Ничек? Мөмкинме?

Малай кызарынды, бүртенде, бер гарьлегенә, бер куанычына урын тапмый уйланды: ул әле бәрәңгеләрен күмдереп кенә килде, монда исә яшь бәрәңгене инде ашап яталар! Димәк, биредә, Җидегәндә, бәрәңгене аңардан да иртәрәк өлгертүчеләр бар?!

Әнисе аны болдырга алып чыгып комгандагы салкынча су белән битен-кулын чайкаттырды.

— Әле бәрәңгене чокып караганыбыз юк иде, әниең белән икәүләп сынамакчы булдык, — диде Миңсылу түтие, аның алдына тәмле булар бөркеп торган яшь бәрәңгеле коштабакны куеп. — Синең хөрмәтеңә! Кул артың җиңел икән!.. Әйдә, кайнар килеш тамак туклык ит әле… Мин хәзер! — Ул мич арасына кереп китеп аннан тирән җәйпегә салынган баягы сыек каймакны алып чыкты. — Менә… манып кына аша әле, колынчагым. Син бит минем туганнан туганым, син бит сеңлемнең улы! — Ул аны тагын бер тапкыр аркасыннан сөеп алды. — Син бит безнең тере Гыйззетдин кияү!..

«Боларның чынлап та сыерлары бар икән. Ә без аксыз калдык».

Малай авыз эченнән генә бисмилласын әйтеп, азыкны менгезә башлады.

Өсләрендәге күлмәк-кабыклары ныгып та җитмәгән, шуңа күрә кайберләре казанда кайнаганда ук «чишенгән», йә булмаса, ала-кола калган зәңгәр, тавык йомыркасыннан эрерәк күрән бәрәңгеләр чынлап та телеңне йотар дәрәҗәдә тәмле иде. Аеруча каймакка манып ашагач!..

Сусыл, йомры бәрәңгеләрне төелә-төелә тамагына озатканда, гүя аңа кемдер нидер пышылдагандай булды. Малай югарыга карады. Анда кырып юган сары түшәм генә икән. Бернинди күк тә, козгын-фәлән дә юк. Як-ягына каранды. Тик нишләптер табында ул… берүзе генә иде. Табакның төбе дә такыраеп килә икән менәтерәк. Уңайсыз ук булып китте.

— Инәй... Инәй... — дигән булды ул, үзен акларга теләгәндәй мышкылдап. — Утырыгыз инде... суына бит...

«Бәрәңге бетә бит» димәде, «суына бит» дигән булды.

— Без бит уразада, улым... — диде әнисе, чак кына ишетелерлек итеп. — Аша, аша, безнең өчен борчылма...

Малай гарьлегеннән телен тешләде. Әй, шулай бит әле, тишек баш. Инәләре уразада бит. Аңа арт яклары белән утырып алганнар да, берни булмагандай, кипкән иреннәреннән ялкын коя-коя, куначадагы күгәрченнәр кебек гөрләшәләр дә гөрләшәләр. Табактагы бәрәңгедә генә түгел, моңа кадәр булса, ун мәртәбә яңартылып эчелә торган һәм әле дә бары тик кунак малае өчен генә үкереп кайнап утырган самавыр да кирәкми иде аларга хәзер.

Ниһаять, Канәгать тамак туклык итеп, аерым бер канәгатьлек белән амин тотты. Аның үз гомерендә бу кадәр тәмле бәрәңге ашаганы юк иде әле.

Кинәт лепкәсеннән нур ташкыны ургылып чыккандай булды. Болай булганы юк иде бит. Тамагына нindидер төер тыгылгандай итте. Йотып җибәрергә теләп, урынында калкынды да, бөек бер куркуга төшкән һәм илаһи нурга уралган төс-кыяфәт белән йөгереп килеп әнисен кочаклады:

— Инәй!.. Инәй, дим!..

— Нәрсә булды, балам? — диде ана шөбһәгә төшеп.

— Мин дә синең белән ураза тота башлыйм!..

— Кара син аны, рәхмәт төшкере! — диде Миңзыя түткие, куанычын кая куярга да белмичә. — Хәерле сәгатьтә, колынчагым!..

— Нәрсә, бер-бер хәл булды мәллә? — дип сорады әнисе, әле һаман да төшенеп җитә алмыйча. — Берәр яман төш күрдең мәллә?

— Төш тә күрдем... Тик яман түгел. Әти, бәрәңге эзләп, суы кайнап утырган казанга чумды...

— Тәүбә-тәүбә, балакаем, ни сөйлисең син? Төш — убыр, ди, түтки, әллә Гыйззетдин исән микән?! Гает намазыннан соң атап хәер бирергә кирәк... — Әнисе улына сиздермичә генә түткиенә баш какты. — Каян килә сиңа мондый уйлар? Ураза тәмамланып килә бит инде... Гает намазына бер генә көн калды лабаса.

— Калса ни. Бер генә көн булса да тотам. Бүген кич синең белән авыз ачам да...

— Ярар, улым, ярар. Бергә авыз ачарбыз... — Күзләре дымланган әнисе киң итеп елмаеп җибәрде. — Ходайга рәхмәт, балама иман керде бит, түтки!.. Синең тупсаңда!..

Канәгатькә рәхәт булып китте. Аның күзләренә яшь тамчысы бәрде.

Күзләре яшәреп очкынланган Миңзыя түтки, куаны-

чыннан ни әйтергә дә белмичә, теленә килгән бер сүзне тәкрарлады:

— Ә син бездә кал, Канәгать! Минем өч улым бар! Уйнарсыз, төнлә лапас башындагы куышта кунарсыз!.. Әкиятләр сөйләп!.. Йолдызлар санап!..

Ул елмаерга итте. Әмма бу елмаю авызы читендә катып калды.

Әйе, як-якларына канатлар үсеп чыккан Канәгатьнең уенда хәзер Җидегәндә калу түгел, тизрәк Колтамакка кайту иде. Ул үзен бик тә көчле тойды. Аның күз алдына үзләренең калтайган такталы капкасы, җимерек ташкеләте, җимерек кар базы, авып-түнеп барган лапаслы абзарлары, келәсенә чыбык тыгып киткән өйләре килде. Аның тәрәзә аша кош булып очып чыгасы һәм барлык авылларны йорт почмакларыннан күтәреп, урамнары-урамнары белән тагын да матуррак, тагын да иркенрәк, тагын да яшелрәк — беркайчан да беркайчан бернинди пычрак, бернинди нәҗес алмаячак урынга күчереп утыртасы килде... «Без үлә торган халыкмы? — дип кычкырасы килде аның галәмгә. — Без — үлемсез халык!»

— Инәй, кайтабызмы? — диде малай, хәзер үк өзелеп кайтасы килеп. — Кайтыйк инде!..

Ул чынлап та биш чакрымда торып калган Ватанын мәңге күрмәгәндәй сагынган иде. Аның күкрәге нур белән тулды. Бу нур аны киң галәмгә чакыра иде.

— Менә хәзер түтки белән үзебез алып килгән мамыкны гына караштырып алабыз да... Бар, булмаса, урамга чыгып йөрештер...

— Аюлы Кул чишмәсенә барып килим?

— Бар, бар. Тик урманның эченә керәсе булма, яме. — Әнисе ярым шаяртып өстәде. — Анда аюлар бар.

— Коштабакларындагы кәрәзле бал белән мине көтәләр, әйеме?

Малай урамга чыгып йөгерде.

Аны чишмәнең колак тондыргыч симфониясе каршылады.

Инде менә юл таягы кебек туры, төзек, көн челләсендә янган, какча, кара-кучкыл, иптәшләре шуңа күрә дә «кырмыска» дип йөрткән малайның гәүдәсе баюга таба барган кояшның нурлары астында сорау билгесе сыман шәүлә калдырып, түбәнгә, колак яфракларында галәмнәр шавы булып яңгыраган Аюлы Кул чишмәсенә таба җилдерде.

Аның белән бергә кызыл ыштан да һәм күкрәгендә «Безнең эшебез гадел, без җиңдек» дип язылган бакыр мидал да җилдерә иде...

*Март, 2003 ел.*
*Чалпы авылы, Азнакай*

# ТЕГЕ МАЛАЙ

*Татар «Әлифба»сы авторлары — Рәмзия апам Вәлитовага һәм Сәләй җизни Вәгыйзовлар истәлегенә*

Малай уянды.

Күзләрен ачыр-ачмастан колак салды: четерт-четерт... черт-черт... четерт-четерт... черт-черт...

Яна икән. Ул беләː мичтә каен утыны гына шулай четерт-четерт килеп яна. Әнисе мичне ягып та җибәргән икән. Таң аткан, күрәсең. Юк, атып җитмәгән шикелле. Кургаш кебек авыр күз кабакларын көч-хәл белән бер-берсеннән аерып, Канәгать керфекләрен күтәрә төште һәм йокылы карашын тәрәзәләргә ташлады. Аз булса да суыктан, ярсу җилләрдән саклар дип, төнгелеккә ябыла торган капкачларның ярыклары аша өйгә таң яктысы сызылмаган иде әле. Озакламый менә-менә сызылачак ул якты. Батачак төн белән атачак таң арасы шулай сизелмәстән, күз ачып йомганчы алышына да куя. Мич авызыннан төшеп, стеналарда уйнаган ялкын шәүләләре урынында оеп яткан малайның сул күз кырыенда чагылды, колагына инде шарт-шорт яна башлаган мич алдыннан пышын-пышын сөйләшү авазлары саркылды.

Шул инде, шул. Мәрфуга түтиләре кергән. Тулы исеме Гөлмәрфуга. Әниләренә ияреп, алар да Мәрфуга диләр. Әнисенең әхие, җан дусы, димәк. Мондый әхирәт дусларны бу якта шулай кыскартып «әхи» генә диләр. Алар өйдәш хатыннар кебек гел бергә. Эштә дә, ашта да. Көненә берничә мәртәбә очрашып, чөкер-чөкер килмәсәләр, аларның халыкта «Миңсылу Мәрфугада, парлап бара суга да» дигән даннары да таралмаган булыр иде. Хәер, ике ихата аша гына гомер иткән бу ике гаиләне бергә, бер гаилә булып яшиләр, дип тә әйтеп булган булыр иде, әгәренки хуҗалыклары аерым булып, салымны аерым, «җан башыннан һәм мал башыннан» түләмәсәләр. Миңсылуның өч, Мәрфуганың ике сугыш ятиме — барысы да балтырган ашап бәләк кебек тыгыз малайлар — кайчагында кайсыларында уйнап «котырсалар», шул йортта кунып та калалар. Күрше малайлар кичәге кичке суыкта тышка чыгып йөрмичә, үзләрендә кунып калганнар да, әниләре исә, менә таң атар-атмастан, караңгыда күзен тырнап, хәл белешергә, авылда төн эчендә булып өлгергән яңалыкларны уртаклашырга кереп тә җиткән...

— Әйкәем!.. Теге Малайның «Теге Малае» кайтып төшкән, ди...

— Сәфәргалиемени? Кит аннан! — диде әнисе. — Авылыгызга төкермим дә, дип чыгып киткән иде, тәки кайткан диген, ә?

— Әйе, җиде-сигез ел чамасы кайтмаган, ди, әйкәем.

— Шул чама бардыр шул. Гыймранның бүресе улый икән, болай булгач. Бай кайткандыр инде... Аны бит әрмедә зафышклад булып эшкә калган дип сөйләгәннәр иде.

— Зафышклад?! Әрмедә зафышклад була димени? — Гөлмәрфуга түти кеткелдәп көлеп алды. — Макарунник ди бит ул!..

— Макарунник? Анысы кем тагы-ы-ын? — диде әнисе сузып. — Әллә нәрсәләр беләсең син, әхи. Ашый торган нәрсәме соң ул?

— Ашый торгандырмы, ул кадәресен белмим, әйкәем, — дип, Гөлмәрфуга түти бар белгәнен бушата башлады. — Әрмегә егерме биш елга ялланып, өстәмә хезмәткә калучыларны шулай макарунник дип атыйлар икән ди бит, әйкәем. Аларга акчаны да, без күрмәгән-ишетмәгән маргрун-макарун дигәннәрен дә төяп бирәләр, ди... Атасы Мактанчык Гыймранның былтыр эскерт салганда сөйләп торганын үз колакларым белән ишеттем, әйкәем. Теге Малайдан хат килде, ди бу, макарунга калдым, ваянныйлардан ваянныйларга акча ташыйм, сикрит пушты ташыйм, тамак тук, өс бөтен, мул яшим, мул ашыйм, ашап бетерә алмаганын малга ташлыйм, дип язган, ди. Кигән киемем көн дә хыр-рум, командирлар белән бергә дваятажный йортта тор-рам, дип язган, ди. Теге Малаеның авылда йөреп киткән кызы Гөлчирәгә ишеттерсеннәр дипме шунда, ярманы бик эредән ярдырды Гыймран. Теге Малай «Авылга кайтып булырмы-юкмы, өйләндем, исеме Мәрия Мәкәриевнә, бик тә кулютурнай хатын, ата-анасы бик бай кешеләр, бакчаларында ун төрле йөзем, әфлисун, хөрмә, алма агачлары сыгылып утыра», — дип язган, ди, бу...

Малайның авыз сулары килде.

— Бай кайттымы микән соң?

— Анысын ук белмим, — диде Мәрфуга түти. — Марҗасы белән кайткан, ди.

— Бай кайткан инде, алай булгач. Гыймранның авызы ерылган икән. Җыеп та алалмыйдыр инде... Кара әле, әхи, синең шул макарун дигәннәрен ашап караганың булдымы? Ниндирәк нәрсә икән ул? Теге Малай аны вагуны белән апкайткандыр инде, әйеме?

Канәгатькә болар җитә калды. Аның тирә-ягын елтыр кәгазьләргә төрелгән йөземнәр, әфлисуннар, хөрмәләр, алмалар, манпачилар, кәнфитләр, беренче тапкыр ишеткән һәм, уйлавынча, тәмле, бик тә тәмле булырга тиешле марҗалар, маргрун-макаруннар биләп алды. Аның фикеренчә, Теге Малай бу кадәр азыкларны ваянный машиналарга төяп алып кайткан булырга тиеш иде...

Канәгатьнең бер генә минутка да кичектермичә Теге Ма-

лайны күрәсе һәм аңардан үзенең кайтуы хөрмәтенә сөенче күчтәнәче аласы килде. Әйе, бар алар ягында кайткан кунак куанычыннан сөенче алу йоласы. Сөенчене хәбәр иткән кешегә — балаларга инде аеруча — беркем караңгы йөз күрсәтми, киресенчә, куанычыннан нишләргә белмичә, татлы ризык, тәм-том белән рәхмәтли.

Теге Малайларга барырга кирәк!

Ул шундый карарга килде.

Кәефе килеп һәм йокысын куып, кат-кат киерелде.

Моның өчен барлык гадәти һәм гадәттән тыш сәбәпләр дә бар иде.

Беренчедән, аның Теге Малайны күрәсе килә. Моның гаебе бармы? Юк. Күрергә тиеш. Әйткән-беткән. Теге Малаен авызыннан да төшермәгәне, аның хәрби хезмәттән язган һәр адымын халыкка шундый ук хәрби төгәллек, алай гына да түгел, хәтта күпкә «төгәлрәк» итеп арттырып, күпертеп җиткереп торганы өчен авылдашлары моңа кадәр Мактанчык Гыймран кушаматлы Гыймранның инде үзен дә Теге Малай дип атый башладылар. Теге Малайның дәрәҗәсе, атасы сөйләвенчә, генералдан да ким булмаска тиеш. Алар ничегрәк киенә, сөйләшә икән? Югыйсә Гыймран бабай язын һәм көзен, җәен һәм кышын, урамда һәм ындыр табагында, урманда һәм яланда, капка төбендә һәм кәнсәләр каршында нәзек кенә итеп махрасын төреп авызына эләр, дөньяга күркә чукышы сыман очлы, күркә кикриге сыман кызыл танавы буйлап карар һәм кәефе килгән саен черек тешләре аша «черт» тә «черт» төкерек сиптереп һаман да шул бер сүзне сөйләр: «Теге Малайдан хат килде. Ай-бай, ничек кенә өлгерә, диген. Вәрүниждән Мәскәүгә күчергәннәр. Ыззванҗасын тагын да күтәргәннәр. Баш сын так харуш, так харуш, нихту такы ни харуш, дигәннәр...» «Теге Малайның хәбәре бар иде әле... Монысын Владивәстүктән язган, шайтан алгыры, һич кенә дә бер урында тотмыйлар үзен. Ә кәк же? Хәрби үчинҗәләрдә беренче урынны алган өчен маршал Жуков Теге Малайны сәгать белән бүләкләгән бит». «Теге Малайның командирыннан хат килде. Маладис, Гыймран Сөләйманович, фыстафка кебек малай выростали, дип язган...»

Кыскасы, авыл Теге Малайның һәр адымын, һәр сулышын Теге Малайның үзеннән дә алда белеп, сизеп тора иде. Шуңа күрә ул авылдашлары, бигрәк тә, тизрәк үсеп җитеп, Теге Малай кебек булу турында хыялланган малайлар өчен нур балкышындагы бер каһарманга әверелгән иде. Шуңа күрә Канәгатьнең Теге Малайның үзен күрергә хыяллануы һәм, һич кенә дә икеләнмичә, барып күрергә карар итүе, бик тә табигый, бик тә дәрәҗәле бер адым буларак бәяләнергә хаклы иде.

Мондый катгый адым өчен икенче бер хәлиткеч сәбәп тә

бар иде шул. Бу инде Канәгатьнең үз нәфсесенә кагыла. Ул бүген якшәмбе — ял, мәктәп эшләми торган көн икәнен искә төшерде. Чырае караңгыланып алды. Аның әле дус малайлары, авылдашлары күрмәгән яңа чабаталары бар бит. Дөресен генә әйткәндә, кичен йокларга яткач, әле Теге Малайның кайтып киләсен бөтенләй белә дә алмаган Канәгать, моны алдан сизенгән кебек, иртән торгач, яңа чабаталарын ничегрәк кияргә, тулаекларын ничегрәк сыдырып салырга, аларны кешелек дөньясына ничек матуррак итеп күрсәтергә дип планнар, хыяллар корып ятты-ятты да йокысын качырды. Ул төне буе уяулы-саташулы булып, күңеленнән сарык бәрәнедәй ап-ак, йомшак тулаекларын бер астан, бер өстән сыдырды, балавыз кебек сары, яңа чабаталарын нәзек, нечкә киндерәләреннән бер бәйләп, бер чиште, бер киде, бер салды...

Яңа чабата кию — Канәгать өчен үзе бер зур бәйрәм. Өлкән абзыйсы Ташкент якларына бәхет эзләп чыгып киткәч, аңа чабата ясаучы калмады. Уртанчы абзыйсы чабаталарны үзе өчен генә тукый да, алар тәмам тузып, маршал Буд͏̦нный кебек мыекларын тирә-якка җибәреп, таушалып, чачакланып беткәч кенә бирә энекәшенә аякларыннан салып. Әле ул абзыйсы сәкенең үрге очында өстенә чүпрәк палас ябынып, мышный-мышный йоклап ята. Әнисе Канәгатькә чабаталарны Галимулла бабасыннан ясата. Бер дистә йомырка — ике пар чабата. Галимулла бабасы аңа чабаталарны вак атламлы, солдатлар кебек тигез рәтле итеп тукый. Аннан, кулдан сатып алынган «гарадскуй» чабаталар бөтенләй икенче төрле матур була бит ул, җәмәгать!..

Күрсен Теге Малай, күрсен бар авыл Канәгатьнең яңа чабаталарын!..

Әгәр бүген — якшәмбе көнне дә күрсәтмәсә, иртәгә — дүшәмбегә кадәр ничек түзмәк кирәк?!

Теге Малайны барып күрү, сөенчесен алу өчен әле без белмәгән өченче сәбәп тә бар иде. Монысы — Балкыз. Алар менә икенче ел инде бергә укыйлар. Балкыз әнә шул Теге Малайның сугышта һәлак булган абзасының кызы. Ни сәбәпледер ул Дим буендагы Канбәк авылында әнисе белән түгел, ә менә Өязе буенда урнашкан Колтамак авылындагы карт атасы Гыймранда яши. Аларның тәрәзә төбендә Канәгатьнең үткән җәйдә Җидегән тугаеннан алып кайтып биргән кылганнар учмасы көмешләнеп утыра. Балкызның әнисе, сөйләүләренчә, ел саен гирбауатся итеп кайдадыр Урал урманнарына китеп торф чыгара, урман кисә икән дә аннан кызына матур-матур күлмәкләр, чәчүргеч тасмалар, кечкенә елтыр галошлар җибәрә икән. Шулайдыр шул. Балкыз бигрәк матур, бигрәк купшы киенә. Кайбер чакта яңа күл-

мәкләрен күрсәтеп өлгерә алмагач, ул аларны озын тәнәфестә дә алыштырып киеп килә. Әнисе аның янына килеп-китеп кенә йөри. Ешрак кышкы якта килә ул. Күптән түгел, ай күрде, кояш алды дигәндәй, тагын да күренеп китте әле ул. Аны Канәгать үзе дә күреп калды.

Балкызның әнисе Тәнзилә түтигә бигрәк тә охшаган икән. Икесе дә чутыр кебек яндырып торган чем-каралар. Сумаладан чыкканнар диярсең. Балкыз турында уйлауга Канәгатьнең кәефе тагын да күтәрелеп китте. Әгәр Теге Малай «Нигә килдең?» дип сораса, ул: «Балкыздан өйгә бирелгән эшне белергә килдем», — диячәк.

Боларына өстәп, әнисе дә, хәтта беркем дә уйламый торган дүртенче сәбәп тә бар иде. Канәгатьнең әтисе — авыл мөгаллиме, сугышка киткәнче авылның барлык балаларын укыткан бит. Теге Малайны да. Аны атасына охшатып таныр микән? «Кара әле, син Гыйззетдин абзый улы түгелме?» — диячәк ул менә, күр дә тор. Аны да бит атасына суеп каплаган кебек охшаш диләр югыйсә.

Канәгать тагын да тәрәзәләргә күз сирпеп алды. Тәрәзә капкачы ярыклары аша таң яктысы керә башлаган иде. Рамнарны сарган бәс агарып күренә. Тышта мотлак зәмһәрир суыктыр. Ул колакларын сагайтты. Мич аралыгыннан пышылдашкан тавышлар ишетелми иде. Мәрфуга түти чыгып киткән, күрәсең.

«Вакыт! — диде малай үзенә. — Нәрсә йокы симертеп ятасың?»

Ул атасыннан калган ак тун астыннан чирканып өйнең салкынаеп оеган һавасына чыкты. Өстенә аксыл күлмәк, эчтән озын балаклы киндер ыштан, тышыннан үткән җәйдә генә үз җилкәсендә тау кырлачларында үсә торган челектән себеркеләр бәйләп, аларны иске-москы җыючы Суфиян картка тапшырып, шул акчага тектергән һәм ярсу җилләрдә җилфер-җилфер килеп торган кара сатин шарабарын киеп алды. Аннан сәке өстенә менеп, спут башында песигә түшәк булып хезмәт иткән оекбаш, тулаекларын алды, сәке астыннан өф итеп саклаган, яңа акча, затлы күн кебек шыгырдап торган чабаталарын тартып чыгарды һәм көчәнә-көчәнә киенә башлады. Аның мыш-мыш киенүен күреп, әнисе сагаеп калды:

— Кая җыенасың?

Малай киенүен дәвам итте.

Инде тулаекларын сыдырып салган, киндерә очларын бәйләп, тулаек бөкләме астында купшы итеп яшереп калдырган, шарабар балакларын тышкарак чыгарып җилфердәтеп куйган һәм, хәзер килеп, идәндә яңа чабаталарына шыгырдата-шыгырдата сынау үткәргән, монысы гына җитмәгәч, эченнән такмак әйтеп, биеп тә азапланган төпчек улына әнисе мич

арасында ялкынланып янган йөзен яктыртып, соравын яңадан кабатлады:

— Кая җыендың, дим? Мәскәү тарафларына... кәнсирт куярга бармыйсыңдыр бит?

Шулай киная белән үзәккә үтә белә аның әнисе.

Әмма Канәгатьнең әле кинаяләп торырга вакыты юк.

— Теге Малай кайткан икән, — диде ул, яңалыкны күптән ишеткән кыяфәт белән.

— Каян белдең әле аны? Ырадиудан әйтмәгәннәрдер бит?

— Ишеттем инде. Сөенчесен алырга барам.

— Кит аннан! Йөрмә кысыр көек булып. Чабата туздырып!..

— Барам.

— Сөенчене бит аны кайтып килгән кешедән алда йөгереп барып алалар. Теге Малай кайткан бит инде. Хәзер өендә гырлап йоклап та ятадыр әле...

— Барам. — Канәгать агач чөйдәге малахай бүреге, кыска сырмасын алып кия башлады. — Минем Теге Малайны күрәсем килә.

Баласының алдына алганын эшләмичә калдырмаганын белгән ана артык сүз көрәштермичә кул гына селтәде.

Канәгать яңа чабаталарының шат шыгырдауларыннан ләззәтләнеп, өйалды аша тышка чыкты. Аны тышта коры йолдызлары белән шыгырдап торган күк йөзе һәм куяннарны сикертерлек ыжгыр суык каршылады.

Атасыннан соң бер якка янтаерга өлгергән урыс капканың тимер келәсен кулларын өттерә-өттерә күтәреп, арыбире, сирәк-саяк кына тычкан утлары белән мезләп торган урамга чыкты, кисәк кенә уңга борылды, йон бияләйләрен кия-кия көнбатышка таба атлады.

Бар дөньяның, үзен әйләндереп алган тирә-якның гамәлдә ап-ак булып, вакытлы төн караңгылыгының әлегә эреп өлгермәве аркасында, ахрысы, караңгылыкның үзеннән дә караңгырак күренә торган бер илаһи мизгеле иде.Җир йөзендә кояш барлыкка бар, тик әлегә аның яктысы Колтамакка килеп җитмәгән кебек. Суык икән шул. Читән каертмаларындагы талчыбыклар да шартлап ярыла. Февральнең нәзек телле чүкече казыкларның кар өстеннән төртке-төрткe булып калкынган очларын зифа итеп чүкегән, читән ихаталар эчендәге салам түбәле, кечкенә, уенчык сыман җыйнак өйчекләрнең кайберләрендә генә элҗе-мелҗе килеп крәчин утлары янгалаштырып җемелди.

Күк гөмбәзе Канәгатьнең баш очында гына икегә ярылган иде: көнчыгышы коры, көмеш серкәләре коелып торган йолдызлар белән тулган; каяндыр кылыч кебек ак чарларда чарланып чыккан ай Шәрифҗан картлар күпере тапкы-

рында туктаган да, гүя Өязедән чыгып, Тукайның «Су анасы»н укый-укый, күкнең шыгрым тулган һәм шылт та итми катып калган йолдызлы яртысын ятьмә итеп тартып бара; көнбатышы исә әйтерсең бары тик югары катламнарда гына яратылган җилләр-агымнар астында ниндидер фаҗигаи төсләргә кереп, секунд саен рәвешләрен шайтаный үзгәртеп, тагын да фаҗигалерәк, тагын да кара-кучкыл, карарак, тагын да куркынычрак сурәтле болытлар белән каплана бара...

Канәгатькә бу болытлар хәзер үк күкнең гөмбәзен басып китәр һәм анда сыңар йолдыз да, бер караганда кылычка, икенче караганда әнисенең алтын алкасына охшаган ай да калмас кебек тоелды. Аңа куркыныч булып китте. Читтән караганда, ак карлар өстеннән атлар салган чана юлында яңа чабаталарын сайратып, аларның сыкрау моңнарына сокланып атлаган малай гүя хәзер инде үзе шул айны һәм йолдызларны ятьмә итеп тартып, фаҗигале болытларның шайтаный авызына кереп баргандай күренә иде...

Көйдереп-көйдереп алган суыктан котылырга теләп, ул бияләйләре белән бит алмаларын капларга тырышты. Шәрифҗан картлар күпере аша чыккач та, аны эре өянкеләр, меңләгән чыбыклары белән кар эченнән һавага кадалып торган таллыклар каршылады. «Балыклар кышын кайда яши икән? — дип уйлап куйды ул. Аннан үзенә-үзе аңлатты: — Боз астында, әлбәттә. Боз астында... Алар анда ничек үлми икән соң?» Аннан үзен тынычландырды: «Яшиләрдер инде берәр ничек итеп. Менә мин яшим бит.Үлмим бит».

Шушы Бәләкәй Камиләләр яныннан үткәндә аның хәтерендә гел генә бер истәлек яңара. Былтыр язын бер галәмәт күренешкә тап булды ул монда. Кояш җылыта башлау белән бу таллар шундук балалыйлар — сап-сары песибашлар чыгарып чәчкә аталар. Ул песибашларны Канәгатьнең күп тапкырлар ашаганы да бар — баллы алар. Шулай бер тапкыр борылыштан үтеп барганда... караса, инде кояшта агарып, шикәр кебек эреп, җепшеп яткан кар өсте әле генә песибашлар чыгарып чәчкә аткан таллар сап-сары булган! Аларны кышкы баздан кояшка чыгарып куйган ач бал кортлары чормап алган! Баллы таллар кортларны алдап чәчкә ата тора, ач бал кортлары балга алданып, ак карларга килеп егыла тора, егыла тора!..

«Исәннәр микән әле ул кортлар? — Караңгыдагы талларны күз карашлары белән капшап, ул үзен тынычландырды. — Кая китсен ди алар, исән булмыйча. Менә мин исән бит әле».

Көнбатышка таба барган, Өязе елгасының таулар белән каелган үзәненә кергән саен, гүя ай белән йолдызлар артта калган, ә караңгылык көчәйгән сыман тоелды. Бу таң караңгылыгының соңгы көчәнүләре иде, күрәсең. Җәһәт адым-

нар белән Теге Малайларга якынлашып барган Канәгать Гыймран бабасына бәйле бер вакыйганы исенә төшереп, көлемсерәп куйды. Аны авылда мәзәк итеп сөйлиләр. Кайчандыр сугышка кадәр була бу вакыйга. Гомумән алганда эчкерсез, кешегә зыянсыз, әмма сөйләгәндә мактанырга, артыгын шыттырырга яраткан Гыймран бабалары, җитмеш чакрымлык юл үтеп, еллаган үгезен салым исәбенә Раевка ит комбинатына алып бара. Үгезне суйдырырга рөхсәт ителүе турында авыл советыннан ыспрафкы да юнәтә. Баргач, карасалар, писер ыспрафкыга «үгез» дип язасы урынга «Гыймран» дип язган, ә Гыймран алган ыспрафкасын укып чыгарга оныткан икән. Баксаң, анда: «... авыл советы Сәйфелмөлеков Гыймранны... суеп иткә тапшырырга рөхсәт бирә», — дип язылган!..

Тәгәрәп-тәгәрәп көләләр сугымчылар, әмма барыбер малның башын рөхсәтсез тиешле бүкәнгә үткәрмиләр. Гыймран абзагыз, атын, үгезен Раевкадагы авылдашларына калдырып торып, Әкчин станцалары аша туган Колтамагына муезларда гына җилдереп кайтып килмәсенме!..

Яктыра. Яктырып ук килә. Тәмам яктырып килә. Әнә Теге Малайларның морҗасыннан чыккан төтеннәре дә күренде. Күктән әле генә коела башлаган ярмалы сыкының ап-ак тукымасында тегеләр морҗасыннан күтәрелгән төтен аеруча төз, аеруча туры, сабан артыннан калган буразна кебек аеруча чем-кара күренде. «Төтеннәре туры чыга, чынлап та бай кайткан бу». Ике якларында да утлары яна. Балкыз торды микән әле?

Теге Малайларның салам түбәле, алты почмаклы, җыйнак рәшәткә уратып алган йортларының болдырының келәсе, шатлыкка каршы, эчке яктан бикле түгел иде. Чабаталарындагы карларын тупсадагы чыптага каккалап, үз артыннан тышкы келәне челтердәтеп элдереп, Канәгать эчкә үтте. Аны тәмле итле аш, ниндидер кәнфитле-манпачилы ят хуш исләр, иренеп кенә янган асылмалы җиделе лампаның сүрән яктысы каршылады.

Алгы якта беркем дә юк иде.

Эчтә кемнәрдер кыштырдашты һәм мыгырдашты.

Күп тә үтмәде, уртадагы ишекнең ике канаты да шәрран яра ачылып китте. Аннан түгәрәк ак ипи зурлыгындагы имчәкләрен түшләренә асылындырып төшергән, бәрәңге танаулы юан бер хатын килеп чыкты.

Мондый нәрсәне беренче мәртәбә күргән Канәгать оятыннан карашын түбән төшерде. Хатынның кулында бернинди әфлисун да, хөрмә дә күренми иде.

Хатын үз артыннан ишек канатларын тыгыз итеп япты да малайга карап катты. Гүя ул аны җеп итеп энә күзеннән үткәрә иде.

— Исәнмесез...

Хатын җавап бирмәде.

— Сөенчегез котлы булсын!..

Бүреген кара күмердәй кашларына кадәр үк төшереп кигән, ямьшек танаулы, өстендәге изрәп беткән сырмасын атасыннан калган хәрби аеллы каеш белән кысып буган, ап-ак тулаекларын шарабар балаклары өстеннән сыдырып салып кигән, инде хәтфә карларның чабаталарында эри башлап, идәнгә сала башлаган эзләрен кая куярга да белми торган малайны ул, күрәсең, тагын да нәрсә быкылдар, нәрсә сорар дип көтте. Дөресен генә әйткәндә, бөтенләй таныш булмаган татар мохитенә кичә кичен генә килен булып төшкән бу хатын көтмәгәндә генә, шул ук иртәдә, җитмәсә, таң атар-атмастан, шушындый очрашудан бераз югалып та калган иде.

Малай исә, сөенче күчтәнәче алырга килгән кеше буларак, сүзне һәм гамәлне аңардан көтте.

Хатынның карашы чабаталарда туктап калганлыгын чамалап, Канәгать аның белән, үзен элеккеге күршеләре Сәхап карт урынына куеп, күңеленнән генә бәхәсләшеп тә алды. «Юк, апа җаным, күзләреңне тоҗырайтма, безнең халык элек беркайчан да чабата кимәгән, — диде ул, Сәхап картның халыкта канатлы сүзгә әйләнгән сүзләрен кабатлап. — Чабатага безне калхуз гына куып кертте». Шушы сүзләре өчен гаиләсе белән Себер киткән һәм әле дә булса әйләнеп кайтмаган Сәхап бабасы турында әйтәсе килеп китте аның. Әйтмәде. Әйталмады.

Түшләренә ишелеп төшкән имчәкләрен әле булса җыештырып алмаган хатын әле һаман да аңа карап тора иде.

— Балкыз уянды мәле? — диде ул, ниһаять, һушын җыеп. — Өйгә бирелгән эшне белергә дип килгән идем...

Хатын иңбашларын сикертте.

— Саша, тут твои пришли.

Һәм кереп китте.

Ишекләр яңадан шап итеп ябылды.

«Марҗа дигәннәре, Мәрия Мәкәриевнә дигәннәре шушы буладыр инде». Фәйрүзә әбисе белән Гыймран бабасы кайда иделәр икән? Нишләп алар өйдә күренмиләр? Әллә Теге Малайлары марҗа киленнәре белән кайткач, күршеләренә кереп кундылар микән? Үз өйләренә сыймаганнармы?

Канәгать көтәргә, атасының укыткан укучысын күрергә булды. Теге Малай чыкмыйча булмас. Әнә бит эчке якта тагын да мыгыр-мыгыр килделәр. Әгәр ул үзе күренмәсә, аның янына Балкыз булса да чыгарга тиеш ләбаса!..

Малай аякларын алыштырып басты.

Эчке якта кемнеңдер чыштыр-чыштыр, шыгыр-шыгыр килеп киенеп мәшәкатьләнгәне ишетелде. «Минем яңа чабаталар кебек шыгырдый бу. Әллә Теге Малай әрмедән дә

яңа чабаталар киеп кайтканмы?» «Юк, — дип, үзенә каршы төште Канәгать. — Болар чыштыр-чыштыр килеп күчтәнәчкә дигән елтыр кәнфитләрне актаралар булыр».

Ишек катында басып торган һәр минут малайга көннәр, айлар кебек озын тоелды.

Ниһаять, канатлы ишекләр киерелеп һәм күгәнендә чыелдап ачылып китте, аннан көзгедәй караеп яктырган күн итекләрендә шыгырдый-шыгырдый, кыска буйлы, баздагы бәрәңге кебек соргылт кабыклы, шыткан күзле, сирәк сары мыеклы, өстенә ике рәтенең дә һәр төймәсе эләктерелгән хәрби китель кигән, аны ялтырап торган каеш белән буган, гәләфи чалбарының бүлтәйгән канатлары белән ишек арасын, төрле мидал, ялтыр-йолтыр тимер-томырлар белән күкрәк арасын тутырган, кыркып алынган сары чәче өстеннән биек кикрикле хәрби фуражка эләктереп алган адәмзат күренде. Ул хәрби күргәзмәгә, буй күрсәтергә әзерләнгән сыман төзек, купшы һәм үтүкләнгән иде.

Кулы буш иде.

Теге Малай Канәгатькә, исәнләшмичә генә, борын буеннан гына сөзеп карады.

Бу малай да сәлам бирмәде.

Бу малай Теге Малайны игътибар белән күздән кичерде.

Ул аның сугыш яланнарында ятып калган газиз атасының шушы авылда туып үскән укучысы иде. Хәрби дәрәҗәләрдә, чиннарда аңышмаса да, авылга килә башлаган хәрби кинолардан ул иңнәрдәге пагуннарның* нәрсә икәнен чамалаган Канәгать Теге Малайның таң иртәсендә аның өчен буй күрсәтергә баргандагы шикелле тырышып-тырышып кигән мундирының иңнәрендәге пагуннарда нәзек кенә ике сызыкны шәйләп алды. «Йолдызлар түгел, нәзек сызыклар, — дип нәтиҗә ясады ул үзенә. — Макарун дигәннәре шушылар буладыр, күрәсең, башкача моңарда макарун дип аталырлык бернинди ят нәрсә күзгә чалынмый».

Яшь, Теге Малайдан күпкә яшь, хәтта аңа уллыкка яраган Канәгать бу соргылт кабыклы адәмзатның, кайчандыр аның кебек үк малай булган бәндәнең, авыл мәчетен кисүче әтрәк әләмгә астан арканга бәйләп балта-пычкы биреп торуын, манара кисеп кайтышлый, коткыдан Кәлимулла хәзрәт ихатасына кереп:

Яңаны алга куйыйк!
Искелекне без тыйыйк!
Муллаларның күзләренә
Кургаш эретеп койыйк! —

дип җырлаганын белми иде, әлбәттә.

---

* Погон — хәрбиләрнең дәрәҗә билгеләре куела торган иңсәсе.

Теге Малай әле җиде ел тарткан хәрби хезмәтеннән соң туган авылына беренче тапкыр һәм өстәвенә беренче тапкыр марҗа хатын белән кайтып, әле беренче иртәдә беренче булып авылдашлары алдында күренүенә искиткеч зур әһәмият биреп, үз көязлегеннән үзе ләззәт алгандай, ишек катында керфек тә какмыйча торды-торды да, борын буеннан гына эндәшкәндәй итте:

— Ты... пошто... пришла, мәльчик?

Бу малай бернәрсә дә төшенмәде. Әле икенче сыйныфта гына укып маташып, урыс телен бары тик бишенчедә генә өйрәнә башлаячак иде шул әле ул. Аның күзләре яшь белән тулды. Гүя ул телсез, кояшсыз калган иде. Канәгать һава җитмәгән балык сыман авызын киң ачып нәрсәдер эндәшергә итте, әмма тамак төбеннән, кисеп алынган кызыл ит кисәге булып, «э-э!» итеп кече теле генә күренеп калды. Чыгып китәсе килсә дә, китми торды, түзде — ул чыгып китүне әдәпсезлеккә санады. Әле яңа гына башланып килгән гомерендә күпкә иртә өлгереп, ул беренче тапкыр кеше хатасы өчен кешене түгел, инде турыдан-туры үзен, бары тик үзен гаепләде.

— Ти пәйми, мәльчик, әтнәке... — дип аңлата башлады соргылт кабыклы адәмзат. — Птамушты я бит сим лит ни бивал нә рудинә... Па татарсеки забил бит...

Канәгатьнең җанында нәрсәдер өзелде.

Ул ишекне ябып та тормыйча тышка атылды.

Инде яктырып килгән һавада тырпаеп күренгән рәшәткәләр аша барс сыман урамга сикерде.

Урам буш иде. Күк гөмбәзендәге болытлар тагын да алгарак күченеп, тагын да караеп ачыкланганнар.

Ул үзенең ни эшләгәнен, нигә йөгергәнен, кая йөгергәнен белмичә йөгерә башлады. Гүя аның колакларында аяклары гына түгел, йөрәкләре дә дөпелди иде. Кинәт ул тимерлек каршында менге атлар бәйли торган куш өянке төбенә туктады да, өянкене кочаклап, үксеп елап җибәрде:

— Әти!.. Әти!.. Әти!..

Күпме вакыт үткәндер, ул үзенең сырма кесәсенә кемнеңдер кулы тыгылуыннан айнып китте.

Әйләнеп караса — Балкыз.

— Сиңа сөенче күчтәнәче...

Канәгать кулын кесәсенә тыкты һәм аннан елтыр кәгазьгә төрелгән бер кәнфит һәм ике кечкенә керәндил чыгарды.

Малай аларны карга ыргытырга итте дә, тукталып калып, Балкызның уң кулын үзенә тартып алды һәм күчтәнәчләрне яшен тизлеге белән учына салды:

— Мә, кәнфит-керәндилләреңне Теге Малаегызга бирерсең!..

Һәм авыл урамы буйлап түбәнгә таба йөгерде.

— Канәгать, тукта-а-а-а! Тукта-а-а-а!..

Өстендәге бишмәтенең сәдәпләрен дә эләктереп, башына яулык та ыргытып өлгермәгән кыз бала, ачык изүләрендә, иңенә таралып төшкән шомырт-кара чәчләрендә җил уйнатып, Канәгать артыннан көнчыгышка чаба иде.

Һавада 1953 елның кышы иде.

Бу кышның ак карлары өстеннән йөгергән ике керсез йөрәк әле нибары икенче генә сыйныфта укып йөриләр иде...

...Ул заманнардан инде исәпсез-хисапсыз сулар акты. Фәйрүзә әби белән Гыйммран бабай дөньяда күптән юклар. Авылда аларның каберләрен яд итәрлек балалары да калмаган бугай.

Теге Малай да, Мәрия Мәкәриевнә дә шул кайтуларыннан соң авылда бүтән күренмәделәр. Исәнме Теге Малай — түгелме, нәселе бармы-юкмы, бу хакта моңа кадәр беркем бернәрсә белми иде. Күптән түгел, авыл хакимиятенә Хабарау каласыннан Мәрия Мәкәриевнәдән хат килгән булган икән. Имеш, Мәрия Мәкәриевнә: *«Сәфәргалине җен сукты, ярты ягы йөреми, мондый хәлдә аны тәрбияләргә минем дә, балаларның да хәленнән килми, туганнары, чыбык очлары исән булса, килеп алсыннар, югыйсә Сәфәргали Гыймрановичны картлар йортына тапшырачакбыз»*, — дип язган, диделәр.

Теге алты почмаклы, салам түбәле бүрәнә өй дә юк инде. Аның урынында, телевизор антеннасын күккә тырпайтып, яңа кирпеч йорт утыра, анда яңа кешеләр яши.

Куш өянке, инде бик нык картайса да, исән әле.

Әмма аңа хәзер беркем дә атлар бәйләми.

*27 март, 2003 ел.*
*Чалпы авылы. Азнакай*

## ТРОФЕЙ АШЪЯУЛЫК

*Кыргый демократия корбаны, җырчы*
*Таһир Якупов истәлегенә*

1946 елның тугызынчы маенда булды бу хәл.

Кояш төшлектән узып баюга таба килә иде инде. Көчхәл белән эчкә үтеп, ишек яңагына сөялгән әнисен Канәгать, билләһи, таный алмый торды: аның йөзе качкан, күз төпләрен божра-божра зәңгәр түгәрәкләр ураткан иде.

Канәгать тыны бетеп сорады:

— Нәрсә булды, инәй?

Әнисе исә, җавап бирәсе урында, кулындагы төргәген тавышсыз-тынсыз гына сәке өстенә почмакка томырды һәм:

— И-их, улыкаем! — дигән үзәк өзгеч аваз чыгарып, сәке өстенә сыгылып төште дә үксеп елый башлады.

Әнисенең елаганын авыр кичерә Канәгать. Мондый чакта гүя өйнең бүрәнәләре дә ыңгырашкан кебек.

Бу юлы да өйнең эчен авыр халәт басты.

Кабаттан сорашырга иткән малай телен тыйды — ярсуы үтә төшсен, дип уйлады ул. Моны гына аңларлык яшьтә иде инде. Күрәсең, кемдер аның газиз әнкәсен рәхимсез рәнҗеткән дә йөрәген кузгаткан, шуңа күрә аңа бу мизгелдә һич кенә дә комачауламау, туйганчы елау, рәнҗешне, эчендә тупланган гарьлекне тулаемы белән тышка чыгару кирәк иде...

Малай бер үк вакытта үзе дә газаплы уйларга талды. Әнисе белән нәрсә булырга мөмкин? Алар бит бүген иртән генә ярыйсы гына кәеф белән чыгып киттеләр. Әйе, әйе, бүген иртән генә. Әле атасы әнисенә бүләк итеп сугышка кадәр үк тектергән, әмма соңгы елларда, атасы сугышта һәлак булганнан соң бөтенләй бер тапкыр да өстенә салмаган эре чәчкәле яшелсу күлмәген, күлмәге өстеннән өч бәби итәк типчеп тегелгән алъяпкычларын да сандык төбеннән чыгарып, хатын-кызларга хас булганча, киенеп-ясанып, бөтәнеп-төзәтенеп — Канәгать әнисенең бу кадәр матур икәнлеген күз алдына да китерә алмый иде! — үзе кебек солдатка булган Мәрфуга ахирәте белән күрше авылга Бөек Җиңү бәйрәменең бер еллыгы уңаеннан үткәрелгән җыелышка киттеләр. Сугыштан исән-сау кайтучыларга, тол калган ятимә хатыннарга Германиянең үзеннән килгән кәнтрибүтси малы — трофей бүләкләр дә таратыла икән дигән хәбәр күз ачып йомганчы таралгач, ул гына дисеңме, бу хәбәрне раслап, авыл советы мөһер басылган махсус чакыру да төшергәч, бәләкәй авыл умарта күче кебек гөж килде, менә бүген, иртә таңнан бар авыл, аеруча солдатка хатыннар, алтын тавы көткәндәй, урыннарыннан кубарылып, олы авыл белән ике арада яткан тауның сукмакларына сибелде...

Беренче үргә кадәр барып, Канәгать үзе аларны озатып калган иде бит. Анысы шулаен шулай, «малай, тишек калай, бидрә төпләргә ярай» дигәндәй, әйе, анысы болай да аңлашыла. Әмма менә әлегесе гаҗәп бит әле аның. Канәгать хәтерли, әнисе ишектән чыгар алдыннан гына:

— Мондыен җыелышка... болай актан, бәйрәмчә киенеп бару да ярамый торган эштер инде ул, адәм тәганәсе... — диеп, кисәктән генә туктап калды. — Марҗалар сыман, карадан киенеп барсаң, бездә, татар-мөселманда андый йола юк... Ирем һәлак булганга куангандай, бәйрәмчә киенеп, тантанага барыйм микәнни... — Аның дәһшәттә янып торган күзләре нишләргә белми йөгерешә. — Бар әле, улым, яңадан укып

кара әле, бәлки, чакыруларында «тантаналы утырыш» түгел, «кайгылы утырыш» дигәннәрдер?

Канәгать авыл советы писаре язган һәм әле өстәл өстендә яткан чакыруны яңадан күзеннән йөгертеп чыкты.

— Монда «тантаналы җыелыш» дигәннәр...

— Тантаналы дисең инде... — Әнисе ишек төбендә таптанды. — Чынында кайгы... мәтам җыелышы да инде... Бармаган да булыр идем, һаман да шул липутатлыгым бар... Кем килмәгән, дисәләр, липутат Миңсылу килмәгән, диярләр. Аларның битләрен юмаган бит... Сайлау җиткән саен, еландай телемне чыгарып, инде бу чираттан үткәрегез әле, дип инәләм, тагын сайлыйлар да гөнаһка кертәләр, Илаһым...

Бөек Җиңү бәйрәменең бер еллыгы иртәсендә менә шулай нәрсәнедер алдан сизенеп, өзгәләнә-өзгәләнә юлга чыккан әнисе менә хәзер шул ук Бөек Җиңү бәйрәменең кояшы инде баюга якынаеп барганда, как сәкегә капланып алган да, кулбашлары белән тартыша-тартыша һәм, авылдашлары сизмәсен-ишетмәсен дигәндәй, тыела-тыела елап ята... Нәрсә булган?

Малай көтте дә көтте.

Бу минутлар аңа бик озын тоелды.

Ниһаять, әнисе урыннан күтәрелде, мышык-мышык килеп, борын, күз тирәләрен итәгенең эчке ягы белән сөрткәләде, аннан, өйдә Канәгатьнең барлыгын да оныткандай итеп, карашларын бер ноктага текәп уйга талды. Аның күп тапкырлар игътибар иткәне бар: ниндидер әһәмиятле мәсьәләне чишәр, җаваплы адымны ясар, гомумән, ниндидер бер хәлиткеч карарга килер алдыннан әнисе менә шулай тере сын сыман катып кала да, тирән уй чоңгылына чума. Бу уй гына түгел, бу җанның зары, җанның чыгы коелган, йөрәкнең шулай итеп сәҗдәгә киткән мизгеле; бу минутта ул гүя үзен уратып алган һәр кемсәне, һәр нәрсәне онытып, ниндидер Бөек Рух белән киңәшә; бу минутта ул гүя җиргә, дөньяга, тормышка аларның йөзләгән шартлылыклары, катлаулары, чоңгыллары аша туры, чәнчеп карый, хәятны үтә күренмәле итеп күрә һәм ниндидер хиссияти истәлекләр, ядкарьләр кайнарында яңа фикер, яңа уй, яңа акыл туплау ләззәте кичерә; мондый халәттә аның керфек очлары калтыранып-калтыранып ала, йөз чалымнары, нечкәреп, хисләнеп китеп, якты сагышка чума, тагын да матурлана, маңгай агы тагын да яктыра, күз аллары, карашлары аны богаулаган зынҗырлардан арынып киткәндәй була...

Малай көтте.

Менә хәзер. Менә хәзер. Чишелер. Ачыкланыр.

Уй сәҗдәсеннән арынып, әнисе, ниһаять, теге тормыштан бу тормышка — чынбарлыкка кайтты һәм өнсез карашын Канәгатькә төбәде:

— Нигә миңа алай карыйсың, улым?
— Һы. Нәрсә булды икән дим.
Әнисенең авыз читләрендә елак елмаю ยралды, ул сүзсез генә урыныннан күтәрелде, итәкләрен рәтли-рәтли, сәке өстенә бая үзе атып бәргән аксыл тукыманы кыргый җанвар — козгын баласы тоткандай кулына алды һәм, чукый күрмәсен дигәндәй, курка-курка гына эләктереп бер омтылыш белән җилпеп җибәрде. Кат-кат бөкләнгән аксыл тукыма хатын кулында талпынып җилпенде һәм аннан алтынсу-сары путаллы, чит-читләре кыска-кыска чуклар белән чукланган кикеле ашъяулык хасил булды. Ул кичке шәфәкъ йөзгән өй эчен яктыртып җибәрде...
— Менә бит алар безгә, җиңүчеләргә, нәрсә бүләк иткәннәр!..
— Нинди матур!.. — Куанычын кая куярга белмәгән малай кычкырып җибәрде. — Нинди матур, ин-нәй!..
Әнисенең төсе үзгәрде, аның күзләре аларып киткәндәй булды. Эсселе-суыклы булып, улын утлы караш белән көйдереп алды:
— Шуны да күрмәскә... Күзең чыкмагандыр бит!.. — Гомерендә бер мәртәбә улына болай каты бәрелмәгән ана, бу сүзләреннән соң нишләргә белми, телен тешләде һәм гаебен йомшартырга теләп булса кирәк, тукыманы яңадан бер тапкыр селкеп, кояшка күрсәтте. — Менә бирегә кара, улыкаем! Үзәккә кара!.. Уртасына кара... Германнан безгә бүләккә дип шушы тишек чүпрәкне алып кайтканнар... Атаң башы хакына... Башкомандыщий Ысталин исеменнән... Күрәселәрем бар икән, Илаһым!..
Канәгать игътибар белән тукыманың үзәгенә карады һәм анда кояшның үзен күреп тынсыз калды: алтынсу-сары путал белән йөгертелгән ашъяулык — эскәтернең нәкъ уртасы гүя бер җанварның үткен тешләре белән чәйнәлеп өзгәләнгән һәм умырып алынган иде...
— Ыә! — Нәрсәдер эндәшергә иткән Канәгатьнең авызыннан әйтәсе сүзе бары тик бер мәгънәсез ымлык булып кына чыкты. — Ыә!..
Әнисе ул арада тагын сәкегә бөгелеп төште һәм инде бернинди тыелусыз сыктый-сыктый елый башлады...
Өйдәге тынлыкта әнкәсенең өзгәләнгән тавышы һаваны шартлар хәлгә җиткерде.
Канәгать әнисенең елавын тыныч кына тыңлый да, ташлап чыгып та китә алмый иде.
— Мондый бүләкләре белән ярама тоз салмаган булсалар иде дә бит... Ул бит болай да әрни!.. Әрни!.. Аһ, әрни!.. Миннән, фронтта ирен җуйган солдаткадан... ятим балалар анасыннан... болай көләргә кем аларга нинди хокук

биргән?! Мин бит аларга бүләк сорап бармадым... Нигә алар миннән көләләр?.. Нигә алар минем соңгы кояшымның да эчен тишеп, эчәгеләрен актаралар?!

Идән уртасында бөрешеп калган малай башындагы сигез өлгеле кәпәче белән гүя кара эшләпәле кадакка охшап сайгакка сеңешкән һәм әнисенең тозлы күз яшендә күгәргән иде. Аның әнисен бик тә елавыннан туктатасы килде. Бик тә. Бик тә. Әмма мондый чарасы юк иде. Елап туйганнан соң әнисе болай да туктарга тиеш булса да, ул әле генә туктарга уйламый иде шул. Шулчак ачык ишек аша тыштан Мыштым килеп керде. Канәгатьләрнең ак мыеклы ата песие. Бер тавыш-тынсыз йөри, хәтта тычканнарны өн дә чыгармыйча тота белгәне өчен аңа Канәгать Мыштым дигән кушамат таккан иде. Мыштымны барлык авыл белә. Дөньяларын тычкан баса башласа, күрше-күлән, хәтта түбән очтан да килеп, Мыштымны кунакка алып китәләр. Ләкин ул анда озак кунакламый, бурычын үтәгәч, мыштым гына кайта да керә. Менә әле дә, тупса аша үтеп, үзенең тамагын туйдыручысының фаҗигале халәттә булуын аңлап алгандай, җәһәт кенә сәкегә сикереп менде һәм тартыша-тартыша елаган хуҗабикәсенең кулбашына сырты белән сөйкәлеп ятты.

Канәгатькә рәхәт булып китте. Гүя әнисенә күкләрдән ярдәм килде. Алар инде икәү генә түгел, өчәү бит.

— Бүген ач-ялангач гаиләмне, бер умачлык оны да булмаган өстәлемне Гитлер өстәленнән калган, ниместән таланган тишек ашъяулык белән капларга кушалармы, имансызлар? Гитлерына ләгънәт! Ыcталиннан бүләк, имеш. Ыcталинына ләгънәт!.. Ирләребезнең башына җитте... Безнең ирләрне дөмектергәч, нигә үзе дә фронтта дөмекмәгән?!

— Чү-чү, инәй!..

— Силсәүитен, Зөлкарнәен әйтер идем!.. Ачларга черек ашъяулык тарата!.. Шушы балага бирәр күлмәклек сатин бирер иде, ичмасам...

Ямау өстендә булган ямаулы күлмәге эчендә әле генә янган-пешкән Канәгать бу сүзләрдән соң өши башлагандай булды.

Әнисе һаман елый, песи һаман аңа елышып йокымсырагандай итә иде.

— Кәнтрибүтси, имеш! Троф-фей, имеш! Таланган чүпрәк! Кирәкми ул миңа... Кайгырмыйм — гарьләнәм!.. Үз сандыгымда күпме бирнә чүпрәкләрем тасланган килеш ята... Көнгә чыгарырга сәбәбе генә юк!..

— Инәй... Инәй... — диде чак кына ишетелерлек итеп Канәгать. — Тынычлан...

Ләкин әнисе көтелмәгән рәнҗештән тәмам ярсыган иде шул.

— Һичкемнеке түгел, шул силсәүит Зөлкарнәйнең генә

этлеге бу... Ул да мир җилкәсен байтак кимерде дә симерде... Бәй, тишек чүпрәк белән авызымны томаларга итәләр... Томалатырмын мин аларга!.. Фронтовик Сабирҗан хатыны әле мин!.. Бәй, узган сиссидә безнең авылда чучка фермасы оештыруга каршы чыккан идем, яратмадылар!.. Күрсәтмәне өстән төшкән, диләр. Төшсә ни! Өстән төшсә, без аны астан аткарабыз!.. Бакчаларны кистерүгә притоф (против) чыктым — яратмадылар! Өстәмә заемга притоф чыктым — яратмадылар!.. Өязе ярны ашап, йорт нигезләренә җитеп килә, ярны ныгытыйк, тегермәнебез юк, су тегермәне салыйк, дидем — яратмадылар!.. Сайлауларда липутат итәләр дә, авызымны бикләп, сүз әйттермиләр!..

— Инәй... Инәй... Тынычлан...

Малай песиләре Мыштым кебек мыштым гына килеп, әнисенең уң як иңбашына сарылды. Алар хәзер сәкедә өчәү иде.

— Без ятимнәр өстеннән, башлары шәһит киткәннәрнең изге хәтереннән көлгән өчен телләре корысын! Аяк-куллары, тән әгъзалары череп аксын бәдбәхетләрнең!.. Ярабби, ярабби, Илаһым!.. Кылган явызлыклары үзләренә кайтсын!.. Ашаган ризыклары тамакларына аркылы торсын!.. Яткан урыннарын хур кылсын, мал-туарларын мур кырсын, Илаһым!.. — дип бәргәләнде әнисе. Аның белән бергә гүя малай үзе дә бәргәләнә иде. — Муеннары асларына килсен!.. Оятсызлар, җирбитләр!.. Үзләре көнлеккә, атлары көрчеккә калсын!.. Ярабби, ярабби, Илаһым!.. Ләгънәт, ләгънәт, ләгънәт!..

Әнисенең сыктавына түземе бетеп, үзенә урын тапмаган малай, ялт итеп урыныннан күтәрелде. Гаиләгә килгән кайгыны гүя аңардан да тирәнрәк аңлаган Мыштым әнисенең иңсәсенә сеңешеп, аны һаман да юаткан һәм җылыткан сыман иде. Канәгатькә нидер булды. Ул баһадирларча олыгаеп турайды. Ул песи түгел — адәм баласы иде шул. Тышка карады. Күзе утынлыктагы түмәр өстендәге балтага төште. Ул кызарып баюга барган кояш нурларында ялкынланып яна иде. Аның башына бик тә куркыныч, баш китәр уй килде: ул, Ватан азатлыгы өчен сугышларда батырларча һәлак булган, атасының үлемтек кәгазенә кул куйган полковник Борисов язуынча, «иң кискен минутта батальонны һөҗүмгә күтәргән» лейтенант Зиннәтулла Сабирҗановның улы Канәгать, шушы балтаны кичке шәфәкъның кызыл баткагыннан суырып ала, силсәүиткә бара, атасының һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булган башка авылдашларының изге хәтерен җиргә салып таптаганы, аларның ата-аналарын, балаларын, хатыннарын рәнҗеткәне өчен, силсәүитнең тәрәзәләрен, өстәл-урындыкларын вата-кыра утынлык ясый һәм сәүит рәисе Зөлкарнәйнең башын түмәргә сала да эһ тә итми чаба да өзә...

Малай яшен тизлеге белән тышка атылып чыкты. Ишегалдында җим эзләп интеккән чыпчыклар өере, пырылдап һәм артларыннан тузан туздырып, һавага күтәрелде.

Ул балтаны шәфәкъ алсуындагы түмәрдән бер омтылыш белән суырып чыгарырга итте, әмма сигез яшьлек сабыйның моңа көче җитмәде.

Шулчак каяндыр килеп чыккан этләре Матрос түмәр янында маташкан дусты, яшьтәше Канәгать янына чабып килде, койрыкларын болгаштырып сырпаланды һәм, берәр афәт сизенгәндәй, ярсып-ярсып өрә башлады.

— Пыш-шул!..

Малай тагын көчәнде һәм, ниһаять, балтаны тартып чыгарды.

— Син нәрсә, юләрләндең мәллә?!

Әнисе аның кулыннан балтасын тартып алды, утыннар арасына ыргытты да, йомшак җиренә сизелерлек итеп кенә тамызды:

— Ягыласы булма! Тәүбә, диген!..

Кеше-кара ишетә-күрә күрмәсен дигәндәй, әнисе аны бөтереп алып, тавышсыз-тынсыз гына артыннан эткәли-төрткәли, өйгә алып керде һәм сандык өстенә утыртты:

— Менә шушында гына утыр! Тының чыкмасын!.. Безгә болай да каныкканнар, күрмисеңмени?.. Заманы нинди — кешеләре шундый... Алла сакласын!..

Песи әле һаман сәке өстендә, хәзер инде теге трофей ашъяулык өстенә сузылып яткан иде. Күзләре йомык. Йоклый, имеш. Малай белә, ул шулай кыланган гына була. Чынлыкта исә ул аларны тыңлап ята. Канәгатьнең күңеленә җылы керде. Әнисе тынычланган иде. Аны бит утынлыкка ниндидер үзе белештермәгән көч шул әнисен тынычландыра алмаганга күрә генә урыныннан күтәреп ыргыткан иде...

— Алла сакласын!.. Алла сакласын!.. — Үзенең көндәлек халәтенә кайтып, чынлап та тынычланган әнисе, гадәтенчә, укына һәм инде бар тирә-якны тынычландыра башлады. — Һич кенә дә гаепсез кешеләрне минем авызымнан каргыш, гөнаһларга батырган сугышын әйтер идем!.. Бу гөнаһта Зөлкарнәйнең нинди генәләр гаебе булсын инде? Ул нинди мир җилкәсен ашаган кеше булсын инде, ә? Мин дә инде... Авызын ачса, үпкәсе күренеп тора бит аның. Коры таякка калган каммун бит ул!.. Минем Зиннәтуллам белән бергә сугышка китеп, кулын өздереп кайтты. Ифрат та һәйбәт кеше, шулай бит, улым? Аның бәләкәе синең белән укыймы әле, улым?

Әнисе аңа карамый да. Ул шулай аңа эндәшкән булып үз-үзе белән сөйләшә генә.

— Мин дә инде... Катырак бәрелдем бугай... Әгәр ана-

вы тишек чүпрәк... — Ул сәке өстенә канатларын җәеп очып төшкән алтынсу-сары ашъяулыкка караш ташлады. — Германның үзеннән, Ысталинның үзеннән үк килгән икән, димәк, аның тишек-тошыклы булуында Зөлкарнәйнең бернинди катнашы да юк. Кем белә, бәлки, аны силсәүит сәркатибе Зөлхәбирә алыштырып куйгандыр? Аның да бит, ай-яй, липутат буласы килә!.. Алсын үзенә, әнә Германның ул черек чүпрәгендә безнең песиебез йоклый, шулай бит, улым !.. — Әнисе җиңел генә кеткелдәп алды. — Кара әле, бер кызгач, Ысталинга да өлеш чыгардым бит әле... Ысталин, Ысталин, ашамасаң кыстамыйм... — Әнисе бераз уйланып торгандай итте. — Ысталин булмаса, бар, мондый сугышта җиңеп чыгар идең! Төбеннән тоттырдылар ди сиңа мондый бөек җиңүне. И-и-и Ходаем, бер гаепсезләргә каргыш аттым түгелме?.. Үзең ярлыка!.. Зөлкарнәйгә дә, даһи Ысталинга да озын гомерләр, тиешле җир-җиһаннар, каргышсыз маллар бир!.. Исән генә була күрсеннәр!..

Әнисе мич арасына кереп, голт-голт су йотып, сусавын басып чыкты.

Инде ачуы тәмам басылгандыр дип торганда гына, ул йокымсырап яткан Мыштымны өстеннән җилләп төшереп, ашъяулыкны яңадан алды һәм игътибар белән карый-капшый башлады.

— Бәй, бәй, ничек була икән инде ул? Германнан Мәскәүгә, Мәскәүдән Уфага, Уфадан Кыргыз-Миякәгә, Кыргыз-Миякәдән олы авылга алып кайтканда, олы авылда аны бүләк итеп тапшырырга әзерләгәндә аларны юньле-рәтле тикшермәделәр микәнни? — дип аптырады әнисе. — Әллә киресенчә, шулай кулдан-кулга күчә-күчә, тикшерелә-тикшерелә тишекләнеп беткәнме ул? Әллә бу тишек эскәтерне төргәккә чынлап та пумалабаш Зөлхәбирә тыкканмы? Аларның арасында бернинди дә низаг юк инде югыйсә. Зөлхәбирә әле силсәүиткә күптән түгел килгән кызкай, кияүгә дә чыкмаган... Ә нигә Миңсылу үзе сүтеп карамады төргәкне? Зөлкарнәй кулыннан алгач та? Шунда ук, клуб залында? Кешеләр, бигрәк тә районнан килгән нәчәлникләр алдында уңайсызланды шул. Башкалар да ачып карамагач. Мондый сирәк трофей, кәнтрибүтси маллары белән бүләкләнеп өйрәнмәгәч...

Алар, аның кебек ятимә хатыннар, клубтан чыгып, авылларына кайтыр юлга төшкәч, ул гынамы, үзләренә бирелгән бүләкләрне, кемнеңдер тәкъдиме буенча, тау үрендә яткан Бүләк урманына җиткәч кенә ачып карарга булдылар. Түземнәре җитәрме, имеш. Тол хатыннар бу сирәк мизгелне мөмкин кадәр сузарга, бу ләззәтне мөмкин кадәр озынайтырга тырыштылар, һәм менә... Миңсылу өчен ул түзем дигәннәре Бүләк урманына кадәр җитте дә һәм шунда ук бетте

дә. Һәр солдатканың исем-фамилиясе язылган төргәкләр эченнән шәльяулыклар, ефәк шарфлар, күлмәклек тукымалар, бәйләм оеклар арасыннан Миңсылуның иң әтрәфлы бүләк саналган алтынсу-сары путаллы ашъяулыгын таратып җибәрүгә аның эченнән, нәкъ уртасыннан буш арба сыман кояш үзе тәгәрәп килеп чыккач, Миңсылуның йөрәгендә ниндидер җеп өзелде. Нибары «Ыә!» иткән аваз чыгарып, аһәңе йотылды. Бүләк үрендә ятыплар елады ул. Бу гаделсезлектән ярсыган хатыннар олы авылга кире барырга, районнан килгән нәчәлникләр, Зөлкарнәйнең битенә төкереп, бүләкләрен йөзләренә бәреп кайтырга кирәк дип тавышланып та маташканнар иде. Киремә борыла да башлаганнар иде. Юк, бу бәладән, бу гыйсъяннан Аллаһу үзе коткарды аларны. Ятим-ятимә балаларны кемнәргә калдырырлар иде?! Бу башкитәр тәкъдимгә Миңсылу үзе каршы төште. Үзе туктатты. Юк, кемнәндер куркудан түгел, ахирәтләрендә чүпрәк хакына кешелек инабәте какшанудан, вакланудан шикләнде. Ул бит... алар үзләре сайлап куйган, аларны үзе сакларга тиешле иң ышанычлы кеше — депутат иде...

Аның хәле бетте, дәрманы таралып, тез буыннары өзлекте. Әхирәтләре Миңсылуны күтәреп диярлек алып кайттылар.

Менә шулай алды Миңсылуның тынычлыгын Германнан килгән трофей бүләк.

Тишек ашъяулык өстеннән әле генә Миңсылу үзе җилгәреп төшергән песиләре Мыштым сандык өстенә күчкән дә, инде хәзер сыртын Канәгатькә терәп яткан икән. Әгәр дә күзе песиләренә төшмәсә, ул улының монда икәнен, бәлки, абайламаган да булыр иде. Уңайсыз булып китте. Атасының тере сыны булып каршыдагы сандык өстендә сүзсез генә утырган улын күрүгә аның куллары үзләре дә сизмәстән тәүбәгә кушырылды...

Ачуын, нәфрәтен кая куярга белми кайнаган, кемне дисез, халыкларның атасы Бөек Ысталинның үзен каһәрләү чигенә җитеп каһәрләгән, аннан, бәлки, бөтенләй гаепсез булган, фронттан кулсыз кайтып, тол хатыннар белән авыл сукасын бергә тарткан Зөлкарнәй кардәшенә урынсыз бәддога органы өчен үкенгән хатынның гарьлеге килеп, бит алмалары яна, кызыша башлады. Күзләреннән тәгәрәгән яшьләре аның йөзен пешерде, һәлак булган ире өчен ничә ел Гитлерны, фашизмны каһәрләгән тол хатын шушы ашъяулыкның тишеге аша кояшны күргәннән соң үз гомерендә беренче мәртәбә бөек юлбашчысы Ысталинны, «авызын ачса, үпкәсе күренеп торган» авылдашы, иренең дусты Зөлкарнәйне, аның нәселен каргады, ләгънәтләде түгелме? Ләхәүлә вә лә куәтә!.. Булган хәлме? Тәүбә вә тәүби, Илаһым!..

Ул калхуз коллыгыннан азат минутларда гына, башка-

лардан качып кына намаз укый торган урынына сыгылып төште, кыйбласына борылды, бер сәҗдәгә китеп, бер рөкүгъка торып, ләгънәтен кире кайтара башлады:

— И Ходаем! Гөнаһларга батырдылар бит... Хаксызга ләгънәтләгән, каргаган булсам, гөнаһларымны үзең ярлыка!.. Гөнаһларымны гафу әйлә, җәһәннәм утыннан сакла, дөньяга вә ахирәткә бөтен гамәлләребезне дөреслә!.. Ләгънәтләремне, авыр сүзләремне кире кайтар, кәлимәсен кәлимәгә аер, юкка чыгар!.. Мине, атамны вә анамны, хәләл җефетем Зиннәтулламны вә балаларымны, вә барча мөселман өммәтен кыямәт көнендә рәхмәтең илә гафу әйлә!.. Мин, мөселман хатыны, хаксызга каргап, гөнаһ җыйган булсам, мең тәүбә, тәүбә, тәүбә, Илаһым!.. Коръән Шәрифнең йөз дә ундүрт сүрәсе, алты мең дә алты йөз дә алтмыш алты аяте берлә иман китерәм!..

Әнисенә ияреп, малай да амин тотты.

Әнисе аягына басты.

— Төшегез.

Канәгать сандык өстеннән шуып төште. Аның артыннан Мыштым да идәнгә сикерде.

— Моны болай калдырырга ярамый, — диде ниндидер катгый карарга килгән әнисе. — Бу дәүләткүләм җинаять.

Нишләргә итә ул?

Миңсылу биксез сандыкны киң ачып, капкачын диварга терәде һәм аның эчендә актарына башлады. Сандыктан озак хәрәкәтсез яткан тукыма, кием-салымга хас булган нафталин, хушбуй, иннек-кершән исләре бөркелеп чыкты. Озак та үтми сандык янәшәсенә атасының киелми яткан күлмәк-чалбары, мамык һәм көзге бәрән йонынннан бәйләнгән оекбаш, бияләй-пирчәткеләре, ак һәм кара шарфлар, тасланып куелган чүпләмле сөлгеләр, тәрәзә башлары, чыбылдыклар, чаршаулар, тәрәзә пәрдәләре, тастымаллар, ашъяулыклар, мендәр каплары, дебеттән чигелгән кулъяулыклар, кечкенә келәмнәр, япмалар, күкрәкчәләр, бала искеләре — тагын да әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр өелә барды...

Сандык янына кара чәйнек кебек утырып алган Мыштым ниндидер ялынган тавыш чыгарып мияулады.

Миңсылу икенче бер кадерле нәрсәне эзли иде, күрәсең. Менә ул сандык эченнән, астан, иң астан күзнең явын алырдай ап-ак, иң вак тәрәш аша тукылган чүпләмле ашъяулык тартып чыгарды. Аның шикәрдәй ак төсеннән барлык йорт эче яктырып киткәндәй булды.

— Менә алар!.. Мин аларны үземнең күз нурларым белән эрләдем дә, суктым да, чиктем дә!.. Мин аларны Зиннәтуллам кайтыр диеп саклый идем — болай булгач, кайтасы юк икән!.. — Хатынның күкрәгендә нәрсәдер «Ыә!» итеп

куйды. — Безгә Гитлердан калган тишек ашъяулык кирәкми, шулай бит, улым?! Без аларга үзебезнекен җибәрәбез, шулай бит, улым?! Миңа, татар хатынына, инәче низзә!.. Монда Германына да, Мәскәвенә дә җитәрлек!..

Ишегалдында Матрос әллә үзен уратып алган чыпчыкларга, әллә баеп барган кояшка өрде дә тынып калды.

Миңсылу әле үзе аңлап җиткермәгән, соңгы сугыштан соң яралган яңа күренеш — ике дөнья, ике система бүләген: үзенең ирен үтерүчеләр иленнән килгән тишек трофей ашъяулыкны һәм һәлак ителгән ирнең Туган Ватанындагы хатынының үз куллары белән чәчкән, суккан, талкыган, эрләгән, салкын чишмәләрдә юган, киптергән, тукыган җитен тукымадан тегелгән ашъяулыкны, аларга өстәп Зиннәтулласының бер пар оек-бияләен, ак шарфын да бергә бер төргәккә бисмилла әйтеп төрде.

Аны төн йокысы алмады.

Иртәгә авыл советына баргач нәрсә әйтәчәген кат-кат уйлады да тагын бер кат уйлады. Уйлый торгач, уйлары берсе өстенә берсе бөҗраланып, һаман да шул элеккеге фикергә урап кайта торган булдылар.

Менә 1946 елның 10 май таңы атты.

Көтү кугач, ана баласын уятты. Алар корыдан гына чәй эчтеләр.

Төенчеген тотып чыгарга әзерләнгән әнисенә Канәгать аптырап калды.

— Син кая?

Әнисе эндәшми-тындашмый елтыр кәвешләрен кия башлады.

Малай соравын кабатлады.

— Бәй, мин сиңа әйтмәдеммени әле? — диде әнисе, аптырагандай итеп. — Силсәүиткә барабыз, улым. Ярлы булсам да, буем гарьле!.. Әйдә, җыен. Синнән дә ышанычлы дуәкәмәт, синнән дә яхшырак шаһит булмастыр. Кирәк икән, бу төенчек белән силсәүитенә генә түгел, Мәскәү Керимеленә дә, Германына да барырбыз. Бездә атаңа Верховный Башкомандыщий Ысталиннан килгән рәхмәт хаты һәм медаль бар!..

Канәгать куанычыннан әнисенә карады. Аларның карашлары очрашты. Әнисенең йөзе беркайчан да булмагандай нурлы, инсафлы, күңеле сәҗдәдә иде. Малайга көч иңде. Бу мизгелдә әнисе аның өчен җирдән гүя Алып Батыр булып күтәрелгән иде.

Улын җитәкләгән ана арт капкадан гына чыгып, кулдан казылган, әмма әлегә орлыгы булмау сәбәпле утыртылмый яткан бәрәңге җирендә берсе эрзин кәвеш, икенчесе ялан аяклы пар эз калдырып, Кәркәлетау аша олы авылга илткән текә сукмакка таба юнәлделәр.

Канәгать артына борылып карады.

Моңа кадәр беркайчан да борчаклары пешмәгән Мыштым белән Матрос, тупсага менеп утырып, койрыклары белән тактага суга-суга, Миңсылуны һәм Канәгатьне тупса түреннән озатып калган булганнар икән.

— Әйдүк, кара чәйнүк! — дип ирештерде аларны малай.

Аннан, таугa менә башлагач, елмаеп, кулын болгады.

Ни дисәң дә, Матрос Канәгатькә атасыннан мирас булып калган, җитмәсә, аның белән бер елгы да булган җан иясе иде. Песиләре Мыштым исә аңардан биш яшькә бәләкәйрәк иде. Менә шул гына.

*11 август, 2003 ел*

## КИТАП

*Беренче укытучым Кәримә апа Газнанова истәлегенә*

Минем кызыклы китап укыганда, бер угры сыман, тирәяккә каранып, ашыгып, юл аша, хәтта бит аша «сикереп» укый торган гадәтем бар.

Бу һич кенә дә сәбәпсез түгел, әлбәттә.

Мин сезгә менә шул хакта сөйләргә телим дә инде.

...Китап!

Бу сүзнең үзендә генә дә никадәр сер һәм дәрман саклана!..

Китапның якты битләреннән, акка кара белән чигелгән, ягъни борынгычарак әйтсәк, «ташка басылган» хәрефләреннән адәм баласы никадәр акыл-хиссият ала, аң-зиһен туплый, рәнҗетелеп, эзәрлекләнеп һәм кимсетелеп, җан тамырлары өзлегер, шартлар хәлләргә җиткәндә никадәр түземсабырлыклар таба, үзендә көч, омтылыш, ихтыяр бушаган, әллә алга барырга, әллә чигенергә, әллә уңга, әллә сулга борылырга дип аптырап торган, югалып калган мәлләрдә адәм баласы ошбу гади генә, Бохаралардан килгән ефәк җеп тә түгел, ә бәлки, Идел, Агыйдел, Сакмар буйларында үскән гади киндер, йә булмаса, җитен тегәрҗеп белән төпләнгән, еш кына безнең милләтебездә яңгырлар астында саргайган төссез сары кәгазьгә басылган бу Китаптан никадәр гаярьлек, ышаныч һәм кодрәт актарып чыгара!..

Җир йөзендә эзәрлекләнүчеләрне беренче булып Китап яклый, чөнки Китап Җир йөзендә үзе иң беренче эзәрлекләнүче.

Минем шуңа күрә генә дә Китапны бәләкәй хәрефтән язарга хакым юк.

Китап! Китабеннас!

Хәзрәти Китап! Галиәссәламе аль Китаби!..

«Китап» дим дә, тагын бер мәртәбә «Аһ, Китап!» дип өзелеп куям.

Китап шундый илһам һәм рух хәзинәседер ки, ул булганда ач зиһенең белемгә, ач калебең иманга, ач карының азыкка, ач күзең нурга ия булачак. Китапның үзенә тарту, күңелне арбау, сихерләү һәм шаукымландыру сәләте азыктан, акчадан һәм магниттан көчлерәк. Мин моны үземнән беләм. Китап диңгездән тирәнрәк, галәмнән биегрәк. Ул Аллаһы Тәгаләнең адәм баласына биргән иң бөек рух Һәдиясе. Юкка гына «Коръән» сүзе гарәпчәдән «Китап» дигәнне аңлатмый. Юкка гынамы Изге Китап бөтенләй укый-яза белмәгән Мөхәммәт галәйһиссәлам хәзрәтләренең якты калебе, чиста, якты тын юлы аша иңгән. Моның белән Ходай Тәгалә Китапның рухын белемнән һәм «бары тик белемнән» генә өстен куйган. Белем — иман. Әгәр Мөхәммәт пәйгамбәр укыйяза белгән булса, кешеләр Коръәннең аңа Ходай Тәгаләдән иңгәнлегенә ышанмаган булырлар иде. Пәйгамбәребез үзенә тарафдарлар — сәхабәләр дә туплый алмаган булыр иде. Әгәр Пәйгамбәребез Китапны «үзе язып» иңдергән булса, яза белгән һәркем Китап язып караган булыр иде. Менә бит ничек. Китапсыз иманлы була алып, Китап белән белемсезимансыз була алырга мөмкин. Карагыз, бернинди гыйльләтләргә бәйләмичә, озын җөмләләр һәм исемнәр биреп, озынозак аңлатып тормыйча, Ходай Тәгалә Пәйгамбәребезнең энҗе тешләре аша аны бер генә галәми төшенчә — «Коръән», ягъни «Китап» төшенчәсе белән нурландырган.

Коръән, ягъни Изге Китап барлыкка килгәннән һәм мөселман өммәте балигъ булганнан соң, һәр мөселман гамәли тормышта «Китап куша» — «Китап кушмый» дигән төшенчәләр арасында яшәгән. «Куша» белән «Кушмый» арасы — бу инде «Шәригать» дигән гаделлек фәненең инсанлы кануннарын тәшкил иткән. Җир шарындагы алты миллиард адәмзатның өчтән бер өлешен алып торган мөселман өммәте бүген дә шушы «Китап куша» — «Китап кушмый» аралыгында, ягъни җинаять — хөкем, гөнаһ-тәүбә арасында тәрәккыят итә. Кайда, кайсы дини өммәттә бар бу кадәр Китапка сәҗдә кыйлу?!

Боларны мин «үтеп барышлый» гына тәкрарлыйм.

Әмма — Китап!.. Аһ, Китап!..

Телемә якты сүз, калебемә изге иман, күзләремә хәреф тану кодрәте килгәч, мин ул Китапны диңгезләр төбенә төшеп тә, галәмнәр күгенә менеп тә алырга риза идем. Мин аның нурлы рәвешен күрү, хәрефләрен уку, авазларын ишетү һәм башкаларга ишеттерү, вакыйгаларын гөманлау өчен,

ач торырга, зәмһәрир суыкларда туңарга, җәйге челләдә янарга-көяргә, бозлы яңгырларда бозланып катарга, әче җилдавылларда теткәләнергә әзер идем...

Әмма, әмма...

Күз алдыгызга китерегез.

...Кырыгынчы еллар азагы, илленче еллар башы...

Хәзер инде «үткән егерменче гасырның...» дип өстәргә туры килә.

Әйе, күз алдыгызга китерегез. Ырымбур белән Көньяк Уралның баганасыз чигендә диярлек, тауларның аһ-ваһ килеп сыкрана-сыкрана далаларга әверелә башлаган тәңгәлендә, тирән, мосафир кайсы яктан килсә дә, таулар һәм урманнар артында ятканга күрә алмыйча килгән һәм, ниһаять, күзе алдында кинәттән пәйда булып, чокырга таш кебек ишелеп төшкән кечкенә авыл... Анда ай Такташның тәүфыйклы песие сыман көне-төне битен юа. Анда йөзьяшәр өянкеләр мәңгелек тәһарәттә булып, догалы сәҗдәгә оеган... Ул заманда бүгенге кебек күзләребезне бетләтеп, үзебезне үтләтеп беткән телевизоры да, хәтта иң тәртипле, чагыштырмача тотнаклы саналган радиосы да юк иде әле. Телеграф, телефон, кампитер, интернет кебек гыйльләләрне сөйләп тә торасы юк инде. Иң кызганычы — Китап юк. Булганын сугыш тартып алган да расхутка чыгарган, яңасын исә кичә генә урнашкан тыныч тормыш әлегә бастырып өлгермәгән. Кая ди ул көтепханә!.. Кая ди ул уку заллары, журналлар, газеталар, шахмат-шашкалар!.. Коръән юк. Ярамый. Дин юк. Ярамый. «Иман шарты» юк. Ярамый. Тыелганнар.

Әмма белемгә, Китапка сусап, ачыгып, йотлыгып, бар дөньяга шар ачылган йөрәк бар. Чит-ят яклардан, шайтани затлардан, көтелмәгән тарафлардан зарарланмаган җан вә тән бар. Иман бар. Кәтрә дә агу белән агуланмаган, зәһәрле ачу белән ачуланмаган, әче тоз, бирәнлек ашламасы, мин-минлек микробыннан затсызланмаган саф чишмәләр, якты алкымлы агымсулар, уңдырышлы чем-кара туфраклар бар. Саф, биек һавалар иҗат итеп, шул һаваларны зәңгәрләгән калын-калын карурманнар, болыннарны елтылдатып, бүген чемченгән хуш исле үләннән иртәгә чыжылдап торган кымызга актан-ак сөт җитештергән елкылар, адәмзатка рәхмәтле мал-туар, кош-корт бар. Хәмер, аракы дигән нәрсәне күрмәгән, сирак-сарак, кешедән яшереп кенә салгалый торган ике-өч «зимагур»ны исәпләмәгәндә, тәмәке тартмаган, наркотик дигән нәрсәне әле тагын да илле ел белмәс вә ишетмәс, якты, киң күңелле, тырыш, җырлы-моңлы, беркатлы вә эчкерсез, хәйләсез вә бик тә шаян, җор сүзле, көлгәндә тәгәрәп көлә торган халык бар. Аллага шөкер, барысы да «бар», тик нишләргә кирәк, Китап галәйһиссәлам генә юк. Коръән-дога сөреп чыгарылып, дөнь-

яви Китапсыз-әсбапсыз булса да, рәхмәт төшкере, туган телендә эшләп килгән дүрт сыйныфлы мәктәп бар.

Борынгыдан затлы, баш бирмәс нәсел, борынгыдан укымышлы, аксөяк нәсел каны кычкыра да кычкыра:

— Китап кирәк!.. Китап кирәк!.. Китап кирәк!..

Әйе, күк капусы ачылган, уянган зиһен, кош баласы сыман, азык сорый. Китап төшләремә кереп йөдәтә. Мин китаплар кочаклап каядыр качам. Чөнки өнемдә мине Китап өчен, хәреф өчен эзәрлеклиләр. Бу эзәрлекләү гомер буе дәвам итәр, дип кем уйлаган ул заманнарда. Әйе, өнемдә, Китап эзләп, картәтәйләрнең чормаларын актара башладым мин. Яшерелгән кылыч белән бергә «Коръән», «Кыйсса-әльәнбия»ләр килеп чыга, ләкин мин телсез, аларны укый алмыйм. Гарәп имлясы һәм теле тыелган. Укый алмаганым өчен гарьләнеп, мин үксеп елыйм. Миңа бары тик урыс имлясы белән генә укырга рөхсәт ителгән. Бу имляда укый да беләм белүен, бик укыр да идем, әмма... Китап юк!..

Хәтерем һәрнәрсәне бер кат уку белән ятлап ала. Борынгылар теле белән әйткәндә, бикли. Хәтерем бикли һәм шундук яттан сөйлим дә. Бу күренешне «абсолют хәтер» диләр икән.

Рәхимҗан абзый янына тимерчелеккә бара башладым. Ул тәмәке тарта, махрасын төрү өчен район гәзитәсе алдыра. Мин тимерчелек эченә үтеп, күрек гөжгелдәтеп, учактагы күмерләрдә ут саклап торам. Рәхимҗан абзый, кәефе килсә, миңа кесәсеннән тәмәке төрергә ертып алу өчен уңайлы булсын дип кат-кат бөкләнгән гәзитен дә биреп тора укырга. Бирмәсә, мин аның төпчек ыргытканын көтеп торам. Төпчекне алам, тәмәкесен коям, чит-читләре көйгән гәзит кисәгендә мин бихисап яңалыкларны беләм: Бөек Сталинны саткан халык дошманы Берия атылган икән. Минем гаделлек сөйгән калебем шашып сикерә: дөрес иткәннәр. Ленин-Сталин эше үлемсез. Рәхимҗан абзый тагын төпчеген төкерә: безнекеләр үзебезнең беренче совет атом бомбасын шартлатканнар. Ул бик һәйбәт, бер шартлаганда иң күп кешене үтерә торган бомба, ди. Кияргә ыштан, ашарга бәрәңгебез булмаса да, мин чиксез куанам. Бик тә уңышлы чыккан икән атом бомбасын сынаулар. Ур-р-а-а! Димәк, агрессорлар безне беркайчан да җиңә алмаячак.

Озакламый Рәхимҗан абзый төпчекләре генә канәгатьләндерми башлый мине. Мин сыйныфташым Тимерханнарга иярләшәм. Аның сугыштан аяксыз кайткан әтисе Латыйп абзый авылда берДәнбер кеше булып Уфадан «Кызыл Таң» гәзите алдыра. Ләкин Тимерхан миңа гәзитне укырга бушка бирми. Язын мин, барлы-юклы киемемне ертып, өянке башларыннан карга күкәйләре алып төшәргә тиешмен. Нәсел

турында кайгырткан каргалар, күкәйләрен бирмәс өчен, минем өстә кар-кар өерелеп, башымны чукыйлар, ә мин кәпәчемә аларның җылы күкәйләрен тутырам. Тимерхан өянке төбенә байларча гына оялап ала да, баш бармагы белән генә чиртеп, күкәй агы эчә, ә мин ул күкәй эчкәнче гәзит укыйм. Әһә, җир йөзендә Әкрәм Вәли дигән бик шәп журналист, Сәгыйть Агиш дигән бик шәп язучы, Тимер Арыслан дигән эчләрне катырып көлдерә торган шагыйрь бар икән. Җәен-көзен ул гәзитен бәрәңге утырту, аны утау, күмү, казып чыгарып, базга ташу хакына, кышын, мал астындагы тизәкне тазарту ялына биреп тора. Ул да канәгать, мин дә канәгать. Шулай итеп, дөньяда иң якты хәрефләр шахтасыннан яктылык казып чыгару өчен, мин Тимерханга гомеремдә беренче тапкыр ялчы, ягъни батрак булып ялланам һәм кояш йә төшлеккә җиткәнче, йә кояш батканчы ук укырга гәзитен алып торам...

Бу гына да җитми башлый миңа. Аннан, Тимерхан белән бәргәләшеп алган көннәрдә, миңа аларның өйләренә бөтенләй хут юк. Китап ашарга сорамый, мин аның үзен «ашау» өчен теләсә нинди адымга барырга да әзер идем. Инәйнең киштәдә эленеп торган эре алсу шакмаклы асалы паласы арасыннан егерме тиенлек тимер акча чәлдереп, үземнән зуррак сыйныфларда укыган балаларның уку әсбапларын «сатып алып» укыйм. Кайберләренең миңа бирмәгәне хәтердә.

Безнең авылда мәктәбе дә башлангыч кына иде шул. Һәм кайчакта, балалар күп булганлыктан, күрәсең, кайбер сыйныфлар төштән соң да укый иде. Хәтердә, мин үземнән югары сыйныфлар укыган бүлмәләргә алдан килеп, мич арасына кереп, үземне утын түмәрләре белән күренмәслек итеп каплап, аларның акыллы дәресләрен тыңлап утыра идем. Кайчак укучылар сыйныфларының мич арасында бөтенләй икенче «дошман сыйныф вәкиле — ышпиун» барлыгын укытучыларына хәбәр итәләр, куян кебек колагымнан тартып чыгарып, мине җәмәгатьчелеккә күрсәтәләр һәм, йомшак җиремә каты кагылып, урамга чыгарып җибәрәләр иде...

Ул заманнарда һәр авылдан бер-ике хәллерәк кешенең балалары Кыргыз-Миякә, Тәтер, Бузат, Җилдәр кебек зур авылларның урта мәктәпләрендә укый торганнар иде. Мондыйлар бездә дә бар иде. Мин аларга һаман да шул ниндидер «хезмәт» күрсәтеп, моңа кадәр үземә бөтенләй таныш булмаган, колагым ишетмәгән «Астрономия», «Физика», «Химия», «Зоология» кебек уку әсбапларын алып торып, алардан урасын урган, мөмкин булган һәммә фикер уйдыгын, акыл сумитен, хис чеметемнәрен дә чүпләп чыктым бит, мин сезгә әйтим.

Онытып торам икән ләбаса. Мин язмамның башында үземнең китап укыганда ашыгу гадәтем барлыгының серен сөйләмәкче идем бит. Шуны аңлатып китим әле. Эш шунда

ки, минем бертуган абзыем миннән дүрт сыйныф алдан укыды, ягъни мин беренчене тәмамлаганда, ул инде безнең авыл мәктәбеннән Олы Кәркәдәнең бишенче сыйныфына менгән иде. Безнең бәләкәй авыл түбәндә, олы авыл үрдә ятканлыктан, бездә «мендем», «төштем» дип сөйлиләр. Дөрес, абзыемның миннән алда укып баруы бер яктан миңа бик яхшы тәэсир итте. Абзыем бытыр-бытыр килеп татарча-урысча шигырь ятлаганда, минем фотографик, әле урысча бер генә сүз дә белмәгән хәтерем, шигырьләрьне шундук бикләп ала иде. Шуңа күрә хәзрәти Тукайның «И туган тел, и матур тел»ләрен, «Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән»нәрен, Такташның «Мокамай»ларын, ул гынамы, хәзрәти Пушкинның үзем бер сүзен аңламаган, өтер-нокта дигән нәрсәне белмәгән «Бурямглоюнебокроетвихриснежныекрутятокакзбираназабоеттозаплачеткакдитя»ләрен вакытыннан алда шартлатып ятлаган идем…

Хәтердә, 1951 елның Совет Армиясе көнендә без, укучылар, авыл халкына кәнсирт күрсәттек. Анда укытучыбызның тырышлыгы аркасында иң күп «сөйләгән» әртис мин булып чыктым. Мин, инде икенче сыйныф укучысы, ул кичәдә җиденче сыйныфларның уку китабыннан укытучым сайлап биргән йөз сиксән куплет Кызыл Армияне мактаган «үлемсез» халык җырларын яттан укыдым. Текстлары нинди иде аларның, текстлары!

Биек тауның башларында
Тезелеп үсә әнисләр.
Тезелеп үскән әнис кебек,
Яшәсен коммунистлар.

Безнең авыл исемнәре
Әлмия дә Калмия.
Дошманнарны җиңеп чыкты
Данлы Кызыл Армия…

Йә Ходa, ничек кенәләр түзгәннәр! Инде шушы яшемдә гафу итә күрсәләр иде!

Олы авыл мәктәбендә укучылар, мәктәптә зу-у-ур көтепханә бар, дип мактансалар да, миңа бу зу-у-ур көтепханәдән әллә ни өлеш чыкмады. Бертуган абзыем, гомумән алганда, бик тә изге, кеше өчен өзелеп торган адәмзат, нинди дер бер карахтер сәерлегеннәнме, әллә бер шаянлык, очраклы кәсәфәттән чыгыпмы, әллә бер балаларча «өлкән» булып кыйланудан, энесен спартан рухта тәрбияләргә тырышуданмы (һәрхәлдә, мин моның явызлыктан, күңел тупаслыгыннан түгеллегенә иманым камил), минем Китап укып утыруымны ифрат та яратмады. Мин хәзер килеп бу хакта уйланам да, ул еллар күзлегеннән чыгып карап, абзыем мине бары тик эшләгән хәлдә генә күз алдына китерә алгандыр һәм, бәлки, заманына күрә үзен хак-

лы санагандыр дип уйлыйм. Кыскасы, олы авыл мәктәбе көтепханәсеннән ул чорның мавыктыргыч калын-калын «Одерда яз», «Рубанюклар гаиләсе», «Алтын Йолдыз кавалеры», «Ак каен»нарын алып кайткан абзыем китапларын үзе укый-укый да, урамга чыкканда, яшереп чыгып китә, әгәр мин аларны табып, укып утыруымны күрсә... кыйный иде.

Әйе, мин бу «гаепләрем» өчен каешны күп ашасам да, абзыема үпкәләмимим, куанам гына — шулай итеп, ул миндә Китапка булган мәхәббәтне тагын да үстергән, арттырган. Рәхмәт төшсен аңа. Алга китеп булса да әйтим, бу тумыштан ифрат та талантлы, җырлы-моңлы, гармунчы кеше, миңа әле дә шундый спартанчарак караш та тора. Ул мине бик яратса да, аның әле булса минем бер генә әсәремә карата да үз фикерен белдергәне юк. Ярый, монысы башка мәсьәлә. Менә шундый шартларда «укыганымны күрә күрмәсеннәр, күрсәләр, тартып алачаклар» дип, уңга-сулга каранып укып, «ялт-йолт Хәлим» буларак тәрбияләнеп үскәнмен, хәрефләрне, җөмләләрне, хәтта битләрне сикереп үтеп, диагональ буенча ашыгып «йотарга» өйрәнгәнмен. Бер күзем китапта, бер күзем капкада. Абзый күренү белән — ялт! — китапны урынына илтеп куям. Тартып алмасыннар дип, Китап яшерү, хәтта үземнән-үзем яшерү әле булса минем гадәтемдә сакланган. Төнлә җен-пәриләр, шайтан-шүрәлеләр күтәреп китмәсен дип, мин сабый чакта шәхси китапларымны, уку әсбапларымны инәй, абзый күрмәгәндә баш астыма салып ята идем. Миңа әле дә йокларга ятар алдыннан яшерәсе китабым калмады микән дигән уй килә дә, көлемсерәп куям...

Икенче сыйныфны тәмамлагач булса кирәк, безнең бәләкәй авылда олы авыл жидееллык мәктәбенең көтепханәсеннән күчмә көтепханә төшереп маташтылар. Җәйге каникуллар чорына гына, әлбәттә. Авылыбызның иске кәнсәләр бинасының, сайлаудан сайлауга гына мунчала күргән идәннәрен кыргычлап юдылар, тупса сайгаклары исә балавыздай саргаеп кипteләр. Без, балалар, аның ачылуын түземсезлек белән көттек. Авылыбызда үз көтепханәбез бар — акылга сыярлык нәрсәме?! Ул көннәрдә мин, үз гомеремдә көтепханә дигән сихри дөньяны бер тапкыр да күрмәгән сабый, төнлә төшләремдә мәрмәр Китап сарайлары күреп, саташып, кайнар тирдә уянып китә торган идем. Мин төшемдә төрле төстәге, идәннән түшәмгә кадәр җиткән ат кадәр зур, шырпы кабы кадәр генә уймак кечкенә Китаплар, кәгазь Китаплар, таш Китаплар, алтын Китаплар, көмеш Китаплар күрә идем. Китапкярлар аларны укырга биргәндә ат башы кадәр йозакларын ачып бирәләр дә кире куйганда тагын да бикләп куялар, имеш.

Әйе, төште теге көтепханә безгә. Минем төшемдә йозаклы китап күрүем дөрескә чыкты диярлек. Менә мин ул кө-

тепханәгә беренче тапкыр аяк басам. Йөрәгем дөрс-дөрс тибә. Балавыз сымак сары тупсада безне Хозыр Ильяска, Әбүгалисинага охшап актан киенгән озын буйлы көтепханәче бабай каршы ала. Аякта каталарыгыз булса, салдыра, булмаса, ялан аякларны юеш чүпрәккә сөрттерә. Үзе бер сүз эндәшми. Елмаймый. Шундук синнән алда кәнсәләрнең салкын күләгәсенә кереп чума. Ә син, көтепханә күрергә теләп эчкә үткән кеше, яңа капкага карап шаккаткан кәҗә бәтие кебек, Китап белән синең араны бүлгән каршылык — тәбәнәк кенә такта коймачык алдында туктап каласың. Аннан, күзең караңгыга ияләшкәч, алдыңда бихисап Китап күреп, авызыңны җыя алмый торасың. Шул мизгелдә сине җиргә төшереп теге Хозыр Ильяс кебек ак Бабай, елмаймый-нитми, китаплар артыннан килеп чыга һәм синең кулыңа озынлыгы ике метрдан да ким булмаган очлы таяк тоттыра:

— Йә, мыштым, — ди ул, көлемсерәп кенә карап. — Укырга Китап алып тору өчен, аның янына үтүнең, кул белән капшап карауның һич кенә дә кирәге юк. Китап — галим, телсез мөгаллим. Таягыңның очы белән төртеп күрсәт, кайсы китап кирәк?

Безгә таяк очы белән генә китап сайлаткан кеше карт коммунист, пенсиядәге укытучы Минегали Кәримов дигән адәмзат буласы икән...

Мин сайланып тормыйм. Миңа барысы да кирәк. Минем бу көтепханәдән алган беренче Китабым Казанда Кави Нәҗми мөхәррирлегендә чыккан «Көннәр һәм төннәр» дигән җыентык булыр...

— Китапсыз өй — ишәк абзары! — ди көтепханәдән чакканда Хозыр Ильяс.— Әмма Китапны укыгач озак яткырмагыз, китерегез! Тәгам тән үстерә, китап күңел үстерә!..

Мин мондагы китапларны умырып укый гына башлауга, көтепханәбез, җәйге каникуллар тәмамлану сәбәпле, очлы таяклары-ниләре белән кинәт кенә олы авыл тарафларына ничек төште шулай очты да китте.

Шулай итеп, авылыбызда мин укымаган һәм ятламаган бер кәгазь кисәге, бер язу, бер чакыру-шигарь калмады. Аптырагач, мин Өязе буендагы өянкеләр, урманнарыбыздагы имән, каен, юкә, өрәңге яфракларын кояшка куеп «укый» башладым. Яфрактагы тамырларны укып була икән. Мин үләннәргә, үсемлекләргә, агачларга сарылдым...

Китап дөньясы тәмам кипте, корыды.

Өченчегә укуга төшкәч, кышкы чилләдә, миңа үз гомеремдә беренче тапкыр Хәзрәти Китап хакына хәер соранырга туры килде.

Хәзер, «демократия» килгәч, кешеләр Китап укудан, дәүләт исә Китап бастыру өчен акча бирүдән туктагач, мин, фә-

кыйрегез, мирдән акча сорана-сорана, дистәләгән Китап чыгаргач, шундый фикергә киләм — илленче еллар башында, моннан нәкъ илле ел элек галәйһиссәлам Китап хакына акча теләнүем минем беренче тапкыр акча «хаҗәте» — «спонсор» эзләвем булган лабаса!..

...Февраль урталары булгандыр. Безнең яңа укытучыларыбыз («абый-апа» дип өйрәнгәч, исемнәре дә хәтердә калмаган) — аларны, милләтләре белән башкорт булган ирле-хатынлы кешеләрне, беренче укытучыбыз Кәримә апа Мәскәү нефтьгаз институтын тәмамлаган ире, авылдашыбыз Минеяр абый Газнанов янына Уфага китеп баргач, районнан ашык-пошык, уку елы башлангач кына китергәннәр иде — безгә, өченче сыйныфта укучы кырыклап балага Миякәдән биш кенә данә туган телдән «Уку китабы» кайтуын, аларның 85 тиенлек хак белән бары тик яхшы укучыларга гына сатылачагын хәбәр иттеләр. Без авыр итеп тын алдык. Укылган исемлектә әлегә кадәр бер генә дүртле дә алмыйча укучы мин — фәкыйрегез дә бар иде. Укытучыбыз китапны, аның беренче битләрен ялт иттереп күрсәтеп тә алды. Аның матурлыгы да матурлыгы! Тышлыгын ачкач та, эчке битендә Сөембикә манарасы сурәте, аннан аста «Казан, Татарстан китап нәшрияты», арткы ягына «Камил Якуб исемендәге китап басу комбинаты» дип язылган бу Китапның хуш исләре бар бүлмәгә таралды.

Казан!.. Китап!.. Китап!.. Казан!..

Бу ике исем безнең өчен изге һәм бертигез иде.

Әмма, җәмәгать, китапны ничегрәк итеп кулга төшерергә? 85 тиен акчаның бер генә тиене дә минем кесәдә юк һәм булмаячак та иде. Асалы палас арасына тыгылган учым буш чыкты. Җәй көне булган булса, бәлки, инәй бирмәсә, тавык йомыркаларын урлап сатып булса да алып булган булыр иде ул Китапны. Юньле-рәтле ашатырына булмагач, беренче чиллә суыгында, бу елда барлы-юклы тавыкларыбыз да кырылган иде...

Уйлый, баш вата торгач, әмәлен таптым бугай.

Һәм менә ничек.

Үткән җәйдә Әнвәр дигән малайга бишенче-алтынчы сыйныфлар өчен абзыем үзенең урыс әдәбияты буенча эт талаган сыман теткәләнеп беткән «Хрестоматия» китабын биргән идеме? Биргән иде. Без аңа акча алган идекме? Юк, алмаган идек. Мин ул иске Китапны абзыем бушка биргән булса да, саткан дип исәпли һәм шуңа нәкъ сиксән биш тиен хак сорап бара аламмы? Алам. Әнвәрнең әтисе бармы? Бар. Латыйп абзый кебек сугыштан аяксыз кайткан, әмма шул килеш тә тракторда эшләгән Сабир абзый Әнвәрнең әтисе түгелме? Әнвәрнең әтисе!.. Минем әтием бармы? Юк. Мин сугыш ятимеме? Сугыш ятиме.

Кыскасы, мин Әнвәрләргә барырга булдым. Куып чыгармаслар әле. Чыгарсалар, Китап хакына барысына да түзәргә мөмкин.

Әмма мин Әнвәрләрнең өйләренең ишеге кайсы яктан ачылганын да белмим. Этләре булса? Болай да теткәләнеп беткән бишмәтемне тасма-тасмага калдырып таласа? Этеннән дә бигрәк... Әнвәрләре өйдә булса? Китапны сатып алмадым, алар аны миңа бушка бирделәр, дисә?

«Тамак тәмугка кертә» дигәннәре шушыдыр инде. Киттем мин Әнвәрләрнең Кәркәле буенда утырган өйләренә. Күз алдымда һәм телемдә бары тик «Уку китабы». Бары тик Казан... Бары тик Камил Якуб...

Ишегалларына килеп керү белән кызыл телле соры эт амалап та алды, мин болдырга сикереп тә өлгердем. Тыным беткән йөрәгем дөрс-дөрс типкән хәлдә мин Әнвәрләргә килеп тә кердем. Килеп тә кердем, ишек катына бастым да. Ишек төбендә торам да торам, торам да торам. Башымда кыршылып беткән кырпу бүрек. Аякта чачакланып беткән чабата. Күзләр яна. Танау тишекләре, киңәеп китеп, мышмыш сулый. Маңгайга басылып киелгән бүрек астыннан мыштым гына тирә-яккә, эчке бүлмә ягына күз сирпеп алам. Бәхеткә каршы, Сабир абзый, иң мөһиме теге «дошман» Әнвәрләре өйдә юк иде. Минеямал апа алгы яктан эчке якка, эчке яктан алгы якка үткәләп-сүткәләп тора. Миңа игътибар да итми. Гүя мин юк. Миңа ай торган, ел торган сыман озак тоела. Каршымда гына арты белән мичкә терәтеп куелган олы сандык.Ул елтыр калай белән шакмаклап бизәлгән. Мондый сандыкларны минем туй озатканда күргәнем бар. Ул, күрәсең, Минеямал апаның бирнә сандыгыдыр. Һәм ул бик байдыр. Басып торам. Утыр, диюче юк. Торам. Чыгып кит, диюче юк. Тора торгач, минем чабаталардан эреп аккан кар суы шул сандык астына кереп китте. Сизә, чабатамдагы кар да сизә — бу сандык чынлап та бик бай, акчалы һәм маллы булырга тиеш. Бүрекне уңга да, сулга да кырынайтып карыйм. Хәтердә, өйдә кичке караңгылык куера башлагач — бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр — инде булмас, тәртәләрне кирегә борырга кирәк, дип торганда, Минеямал апа:

— Ни йомыш иде, улым? — дип сорамасынмы!

Ни куаныч! Миңа хәзер, теге Хозыр Ильяс әйтмешли, китапсыз өй — ишәк абзары! Сораучы булса, сорауга җавап бирүче күптән әзер инде. Сораучы гына булсын. Әйе, Китап — белем чишмәсе. Китап — галим, телсез мөгаллим. Китап өйрәткән мәкальләр һәм ысуллар белән шыплап тулган безнең баш миебезнең көнбагыш мәмәйләре, беләсегез килсә! Без, ягъни Кәркәлетамак башлангыч мәктәбенең өченче сыйныф укучысы Фәлән Фәләнев, эһ тә итмичә, безнең куа-

нычыбызга каршы, безнең бу изге ниятебезгә шушы минутта бик зур зыян салу мөмкинлеге булган Әнвәр кардәшебезнең өйдә булмавыннан файдаланып, үзебезнең һич тә юкка йөремәвебез, ә бәлки, аларның уллары Фәлән Фәләневнең, үткән җәйнең яшькелт-тымызык бер көнендә безнең борадәребез Фәлән Фәләневтән урыс әдәбияты буенча ка-а-алы-ы-ын бер «Хрестоматия» китабын сиксән биш тиенгә сатып алуы, әмма кардәшебез Фәлән Фәләневнең,ягъни аларның улларының, бу акчаны безгә билгеле булмаган сәбәпләр буенча әле һаман да кайтарып бирмәве, шуның аркасында безнең, Кәркәлетамак башлангыч мәктәбенең шыр бишлегә укый торган укучысының, мәктәбебезгә биш кенә данәдә кайткан «Уку китабы»н сатып ала алмавыбыз турында бәйнә-бәйнә хәбәр итәбез...

Бу кадәр үзәкләргә төшеп аңлатуга Минеямал апа түзә алмаган, күрәсең.

Соңыннан, озак еллар үткәч, белермен: аны, ягъни ул чакта уналты яшькә кереп килгән Минеямалны, ике казык — бер таяктай коры коммун — силсәүит рәисенә кияүгә бирмәгәне өчен гаиләсе-ние белән нахакка Урал урманнарына куылган «кулак» Сәхаб абзыйның кызы, Кама елгасы буйлап салларны оста агызганы өчен ударникка чыгып, шушы «хезмәт җиңүләре хакына», Пермь урманнарында атасын җирләп булса да, туган якларына әнисен, барча туганнарын сөйрәп кайта, җан сөйгәне Сабир абзый белән кавыша, кыска вакытта йорт бетереп керә алган сирәк хатын — Минеямал апа булган икән ул.

— Анысы шулаен шулайдыр инде, улым, — диде Минеямал апа, минем озакка сузылган гозерне тыңлагач. — «Карга баласы төп чокыр, мулла баласы китап укыр», — дип, юкка гына әйтмәгән борынгылар... Китапның белмәгәне юк бит аның... — Ул, керфекләрен җем-җем китереп, миңа карап бераз уйланып торды да, кинәт кенә сорап куйды: — Ул «Уку китабы» күпме тора, диден әле син?

— Сиксән биш тиен, Минеямал апа! — дип кычкырып җибәрдем мин, карашларымны чабатамның сулары агып кергән сандык астыннан күтәрмичә. — Сиксән биш тиен тора инде ул югыйсә... — Үзем исә беренче тапкыр хәер сорашканым өчен чөгендердәй кызарганмын. — Сиксән биш тиен...

— Ә-ә-ә, сиксән биш тиенмени? — дип, кабат сораган булды Минеямал апа, эшнең нәрсәдә икәнен төшенеп алып. — Сиксән биш тиен генә булса... Аны гына тырыштырып карарга мөмкиндер ул!..

Инде, Ходаем, Әнвәрләре генә кайтып кермәсә ярар иде!..

Мин бу минутта нишләптер өйдә миннән башка бер генә

ир затының булмавын тели идем. Ирләр булса, мондагы дөнья, мондагы тормыш, ни өчендер, катыланыр, кырысланыр, һәрхәлдә, минем файдага булмас кебек иде.

Минеямал апа минем каршымда гына торган теге шакмак бизәкле бирнә сандыгының кул яссуыдай зур, йозаксыз элгечен ачты — ни күзем белән күрим! — ышанасызмы, буш, бөтенләй буш, бары тик җилләр белән яңгырап, шыңгырдап торган сандыкның ак тукыма җәелгән төбендә бер өем бакыр биш тиенлекләр ята иде...

Алар, бәлки, миңа гына шулай күп күренгәндер, һәрхәлдә, анда ике-өч кушуч бакыр акча булгандыр, билләһи.

Минеямал апа миңа шул өемнән нәкъ унҗиде данә биш тиенлек санап бирде, һәм мин, кулыма һөдһөд кошы кунган фәкыйрь, рәхмәт әйтергә дә, саубуллашырга да җөрьәт итмичә, акчамны кире тартып ала күрмәсеннәр дигәндәй, тупса аша, тупсадан кызыл телле эт аша теткәләнеп, урамга атылдым.

Казан. Китап. Китап. Казан.

Тышка атылдым да, өстенә кемдер яңа тизәк китереп аударган Кәркәле күперләре, көрт, кар таулары аша бер сикереп, ике атлап, дулкынлануымнан тыным бетеп, укытучыларыбыз яшәгән фатирга — сыйныфташым Минехай Рәфыйковларга килеп тә кердем. Килеп кердем дә, анда танавым эченә ярып кергән бодай ипие исе белән котылгысыз очрашып, түрдә, сәкедә, мамык мендәрләр өстенә аккош балалары кебек тезеп куелган ап-ак, түгәрәк, күперенке бодай күмәчләрен күреп, тынсыз калдым. Карынымдагы барча ач тегермән ташлары әйләнгәләп, күз алларым караңгыланып китте. Әмма «Китапсыз өй — ишәк абзары», «Китап — галим, телсез мөгаллим», «Карга баласы төп чукыр, мулла баласы Китап укыр» икәнлеген тагын бер мәртәбә исемә төшерсәм дә, әгәр үземнән «Сиңа ипи кирәкме, әллә китапмы?» дип сорасалар, нәрсә әйтергә белми, тәүбә-тәүбә, ымсынып кала күрмим, дип куркып, бар йортны яңгыратып кычкырдым:

— Миңа «Уку китабы» кирәк иде!..

Хәзер хәтерләмим, укытучыларыбызның кайсысы акчаны санап алгандыр, кайсысы Китапны биргәндер.

Минем бу Китапны песи баласы сыман кочагыма кочып, урамга чыгып ычкынуымны, күземә ак-кара күрсәтмичә, шул «песине» кочкан килеш өйгә сыпыртуымны. Өязе елгасы аша күперне, инде кулым Китапка да тиенгәч, Хәзрәти Тукайның, Кисекбашы кебек «чапкан трамвайларны узып» сикереп кенә үтүемне укучым күз алдына китерә торгандыр.

Өйгә килеп тә керәм, юеш чабаталарымны кайсын кая салып та ыргытам һәм бердәнбер җылы урын — мич башындагы спутка менеп ятам, Китапның очраклы гына битен ачам, анда «Сталин белән Ворошилов Царицын фронтында»

дигән хикәяне күргәч, тынсыз калып укып, ике юлбашчының сурәтләреннән илһам алып, аларның безне 1918 елда aклардан азат иткәннәре өчен чиксез куанычкичерәм. Ничек куанмыйсың ди? Безне бит гел генә азат итәләр. Әгәр башкалар булмаса, безне кемнәр кемнәрдән азат итәр иде? Һәм мин бу хакта, әйтегез, каян беләм? Китаптан, Казан чыгарган Китаптан беләм бит. Бу үзе генә дә бер могҗиза түгелме?

Мин үз гомеремдә Җир шары буйлап Китап күтәреп күп чаптым. Ләкин беркайчан да туган авылым урамы буйлап Китап күтәреп чапкан ләззәтне татый алмадым.

Бүген, Китап дигән изге җан иҗтимагый үсеш, алга китеш, камиллекнең төп факторы булудан туктап, халык Китап дигән изге чишмә зәмзәмен эчүдән бизгән чорда, кайчандыр тугыз яшемдә «Уку китабы» кочаклап чапкан чагым минем өчен иң бәхетле минутларым булып күз алдыма килә.

*14 август, 2003 ел*

## КАЛЕБ ЯРАТЫЛГАНДА

*(Нәсер)*

*Анам-газизәм Миңлесорур Шиһаб кызы һәм аның гомерлек ахирәте Садыйка түти истәлегенә*

Ул чакта мин әле бик тә бәләкәй идем.

Яшем дә дүрттән-биштән, күп дигәндә алтыдан узмагандыр. Мәктәпкә төшмәгән булуым ачык хәтердә.

Менә шул сабыйлыгым чыгып җитмәгәнгә, ахрысы, күз алдымдагы манзара-күренешләр дә өзек-өзек, кисәк-кисәк кенә сакланган. Әнә Өязетауның вак мал салган кыек сукмаклы битләүләре гармун күреге сыман боргалана-боргалана Кырлыган инешенә килеп туктап, тауның астында эре карамалар күләгәсендә текә яр булып ишелгән җирендә кәҗәсарыкларның өтерге сыман очлы тояклары астында тапталып, чөбердәп аккан сидек, кара борчак булып шыбыр-шыбыр коелган тизәк белән кушылудан изелеп, эзләнеп шомарган һәм каралган җирдә мал туплавы. Көн кичкә авышкан инде, кояш яктысы юан кәүсәле карамаларның калын ябалдашлары каплаган туплауның кара көзгесендә куерып, саранланганнан-саранлана бара. Көтү күптән инде туплаудан кубарылып китеп барган. Әни белән Садыйка түти сарыкларының чалыштырып тышауланган чәлтерләренә тезләнеп алганнар да, кырт-кырт иткән кайчы тавышы һәм кичке һа-

вада кыр казлары сыман каңгылдашкан аһәңнәр чыгарып, йон кыркалар. Бу ак йоннар куллары өстеннән ак болытлар булып ак җәймәгә актарылып төшә. Әнә бездән аста Кырлыганның Мендәрле Кул чишмәсе койган урыныннан киңәеп һәм сазланып киткән агымы, күзге кыйпылчыкларын хәтерләтеп, күзләрне чагылдыра-чагылдыра ялтырап ята...

Кырлыганның чын тарихи исеме «Кырылган» икәнен халык белә. Кырылган елгасы башында кайчандыр безнең бабаларыбыз кырылган. Әмма күпне күргән, күпне тавышсызөнсез йоткан халкыбыз инеш исемен бераз йомшартып «Кырлыган» дип йөртә...

Хәтерләгән нәрсәләрем, бер караганда, менә шулар. Менә шулар, дидем дә уйга калдым. Шул гынамы? Шул гынамы?! Булмас ла... Ә менә андагы мал яткан, мал ашаган, мал күшәгән, кыскасы, мал яшәгән сихри күләгәдә — туплауда, әнә шул туплауга табынга гына хас булган исләр, ерткыч кошкорт, төлке-бүреләрдән өркүдән яфракларга сеңгән аһ-ваһлар, э-элдәү-мэ-элдәү, мекертәүләр, көтүчеләрнең йөзләгән һауһауы, чыбыркы шартлаткан авазлар бары тик малдан, аеруча вак малдан ярала һәм тирә-юньгә сеңә торган серле әчелек — әрем, сөт-катык, әйрән, гөжелдәп торган кымыз, сөзмәэремчек, каймак һәм башка дистәләгән мал агы ризыкларының әчкелтем-төчкелтем тәмнәрен һәм хуш исләрен — әйе, әйе, хуш исләрен! — онытырлыкмы?! Ә менә күңелендә алтмыш елга якын йөреткән һәм, инде килеп, гомер азагында булса да кәгазьгә төшереп калдырырга мәҗбүр иткән илаһи тетрәнүне кая куясың? Беренче тапкыр мин бит бу хикәятнәсерне «Идел» дигән исем белән әле 1962 елда, егерме генә яшьлек чагымда, Колупаевка авылының карлы танкодром яланнарында яза да башлаган идем. Йа Хода, инде шуңа да кырык бер ел үтеп киттеме?

Андагы тойган-кичергәннәремне, күргәннәремне сурәтләргә көч-куәтем җитәрме? Минем кулларым калтырый, йөрәгем дөпелди башлый. Йа Хода, мәдәт бир!..

...Караңгы төшкән. Әни белән Садыйка түти, кырыккан йоннарын төенчеккә төйнәп, төенчекләрен баш өсләренә куйганнар да, бездән бераз гына алдан баралар. Ни күрәм? Каршыбыздагы караңгыда йөзгән Кәркәлетау артыннан алтын табак сыман тулып күтәрелгән Ай гүя аларның иңнәре арасына сыенып утырган да гәүдәләре белән төенчекләрен бербөтен сын итеп яктырткан... «Бездән бераз гына алдарак» диюем шуннандыр ки: Ай нурының ак сөтендә төчкерә-төчкерә әниләр белән минем арада сарыклар теркелди. Безнең ике ак, Садыйка түтинең ике кара сарыгы. Әниләр йоннарының агын карага, карасын акка алышалар. Кулына карама чыбык тотып һәм ялан аяклары белән тузанда лепер-

лепер килеп, сарыклар артыннан мин, фәкыйрегез — дүртбиш яшьлек малай кисәге теркелдим...

Безне янәшәбездән Кырлыганның гүя тегендә-монда ыргытылган күзге кыйпылчыклары озата бара. Табигатьнең билбавы бушана — ул төнге йокыга талырга әзерләнә. Атлаган арада вакыт-вакыт колакка әниләренең чәчүргечләрендәге чулпы зеңгелдәүләре, юл буендагы үләннәрдән чикерткәләр сайравы саркылып куя. Чикерткәләр шулай чикертчикерт килеп Ай нурыннан алтын нәкыш чигәләр, күрәсең.

Шулчак әни белән Садыйка түти икесе бер тавышка җырлый башлый:

> Идел бит ул, тирән бит ул,
> Идел бит ул, күл бит ул...

Җырга мин дә кушылырга итәм — көен белгән кебек булсам да, сүзләрен белмим икән. Тыным да чыкмый. Тавышымда әниләрдәге көмеш тә юк. Бу кадәр тирән моң кайларда яралып, кайлардан чыга икән? Сандугач булмаса да, кеше нигә сандугачтан да артыграк итеп сайрый-җырлый ала? Ничек итеп? Бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике кеше — әни һәм Садыйка түти — бу кадәр охшаш тавыш, бу кадәр охшаш мәкам белән ничекләр итеп бу кадәр ипле һәм бергә көйли ала?

Әйе, алар бер-берсенә бер дә охшамаган: әни озынча, төз, какча гәүдәле булса, Садыйка түти моның киресе — кыска, тулы гәүдәле, әни — кара-коңгырт, Садыйка түти зәңгәр күзле. Әни — кеткелдәп, Садыйка түти гөргелдәп көлә. Әнинең алкалары алтынсу сары, Садыйка түтинең көмештән. Әнинең чулпылары икәү, Садыйка түтинеке дүртәү...

Тик нигә моңнары бертөрле? Нигә моңнары бер-берсен шулай суйган да каплаган?

Охшаганлыклары шунда бетәдер дә, бәлки. Бетмәсәләр, бәлки, охшаган һәм охшамаган яклары бергә үрелеп барадыр? Мәсәлән, Садыйка түтинең уллары икәү генә. Вәкил һәм Камил. Ә без дүртәү. Булганда, умырып ашыйбыз, умырып киябез, җимертеп эшлибез. Гомумән алганда, алар да ач, без дә ач инде. Без ике гаилә бер гаилә кебек бердәм яшәсәк тә, йортларыбыз, көткән дөньяларыбыз аерым. Маллар да. Маллар диюем ташка үлчим инде анысы. Садыйка түтинең дә ике сарык, бер кәҗә, безнең дә ике сарык, бер кәҗә. Аларның сарыклары да ике саулык, бер тәкә бәрән бәрәнләсә, безнекеләр дә ике тәкә, бер саулык бәрәнлиләр. Аларның да сыерлары ала, безнең сыер да ала иде. Үткән елда аларның сыеры да калхузның бүрткән орлыгында күбенеп зыянлады, безнеке дә шул ук бүрткән орлыктан китеп барды. Вәкилләр дә корчаңгы белән чирләде, без дә корчаң-

гы белән җәфаландык. Вәкилләр дә чәчәктән җик күрде, без дә чәчәктән иза чиктек. Былтыргы кышкы челләдә аларның да ике тавыгы, безнең дә ике тавыгыбыз туңып үлде. Әй, санасаң, охшаган яклар күп инде ул. Санамыйм әле. Юк, берсен генә әйтми булмый икән шул. Аларның әтиләре дә сугышта һәлак булды, безнеке дә. Аермалары шунда гына: Вәкилләрнеке — сугыш башында, Смоленски дигән җирдә, безнеке — сугыш азагында, Чехословакия дигән җирдә.

Аннан менә монысын ничек итеп әйтмисең инде. Әни дә тырыш калхузчы, Садыйка түти дә. Тик менә хезмәтенә күрә ашлыгы гына тими. Шул тырышлыклары аркасында гына бит инде алар, башкалар кебек, йон кырку өчен бригадирдан аерым көн сорап, сарыкларын көтүдән калдырып маташмадылар, тоттылар да, көн азагында, туп-туры басудан мал туплавына килделәр, килделәр дә, бар тирә-якка кырт-кырт кайчы авазлары чыгарып, сарыкларының йоннарын да алдылар.

Идел дип җырлыйлар. Нәрсә була икән ул Идел дигәннәре? Алай тирән дә, җитмәсә, күл дә булгач, ул бөтенләй дә ашый торган нәрсә түгелдер инде. Бер юлы Идел дә, күл дә булганы өчен шулкадәр моңлы микән бу җыр?

Караңгы төн, томанлы көн,
Без аерылган көн бит у-у-ул...

Нишләп әле генә тирән күл булган Иделдән караңгы төн, томанлы көннәр килеп чыкты соң әле? Нинди томан? Бүгенге иртәдәге сыман якты, җылы, сөтле томанмы? Күршебез Ярыяхмәт бабай, кура җиләкләре нәкъ шушындый томанда пешә, ди. Шушындый кура җиләк пешә торган томан булса, бик шәп бит бу югыйсә. Нишләп караңгы төн тагын? Әнә, әлеге төн кебек, әниләрнең билләренә кадәр төшкән төн караңгысымы?

Кинәт минем зиһенемдә нәрсәдер ялт итә дә, мин очып киткәндәй булам. Мизгел эчендә бар тирә-як яктыра да сүнә. Гүяки шул мәлдә күк гөмбәзе авыраеп китеп, безнең өскә ишелә, без гүя җирдәге бар тереклек — елгалар һәм күлләр, таулар һәм урманнар, агачлар һәм үләннәр, кешеләр һәм җанварлар — канатланабыз, канатларыбызны кагып, бу авырлыкны җиңел генә итеп өстебездән җилләп төшерәбез һәм барыбыз бер тавышка җырлый башлыйбыз:

Без аерылган көн бит у-у-ул...

Һәм мин... Һәм мин шулчак нәрсә күрәм! Йә мәрхабә! Дөньяның нинди рәссамы моны сурәтли алыр иде икән? Әйе, әгәр сез күз алдына китерә алсагыз, китерегез. Садый-

ка түтинең һәм әнинең иңнәре арасына кереп кунаклаган Ай аларның кайчандыр аерым булган сыннарын хәзер бер тын, бер җан итеп бер сынга әверелдергән: алар киләчәктә, мин үсеп җиткәч, дөньяның иң атаклы музейларында очратачак сирәк сәнгать мирасы — борынгы Мисыр, Юнан, Вавилон, Бөек Болгар, Бакчасарай мәдәни катламнарында сакланып кала алган ике яктан да тоткалы алтын кәүшән — чүкеп ясалган алтын амфораны хәтерләтәләр иде. Айдан төшкән көмеш нурлар элпәсе, аларның гәүдәләрен тыштан биләп алып, әнә-әнә, уң яктан караганда, Садыйка түтинең башы өстенә куелган төенчеге, аннан бер үк вакытта төенчеген тоткан уң беләге, аннан иңсәсе буйлап биленә кадәр төшә дә, караңгылыкка кереп чума; әнинеке исә сул яклап шулай ук башындагы төенчеге, төенчекне тоткан сул беләге, аннан иңсәсе буйлап килә-килә дә, бил турысына килеп җиткәч, шулай ук караңгылыкка төшеп югала... Искиткеч матур манзара иде бу. Мин беләм, мин күз алдына китерәм, Садыйка түтинең һәм әнинең буш булган сул һәм уң куллары исә түбәндә, кайчыларын кысып тоткан халәттә, караңгылыкны сөзеп, алга баралар...

Алар җырлаган Иделнең караңгы төне шундый буладыр, күрәсең. Арттан караганда ярты гәүдәбез, сарыкларныкыннан башка, әлбәттә, көмеш путал белән камалган булса да, без вакыт-вакыт кара упкынга төшеп чумарбыз кебек. Авылыбыз чокырда урнашкан булып, без шул чокырга инде якынаеп та килгәч, безнең гәүдәләребезнең өске өлеше айның көмеш нурында, аскы өлеше төн караңгылыгында яши мәллә, дип уйланам мин. Юктыр ла! Безнең авыл җир йөзендәге иң якты авыл. Крәчин яктырталмаган урынны алар көндез күз нуры, төнлә йөрәк белән яктырталар. Андагы кешеләр дә иң акыллы, иң сабыр, иң җырлы, иң моңлы кешеләр!..

Чокырга кергән саен, караңгылык куера, димәк, без чынлап та авыл башына ук җитеп киләбездер. Минем авылга кадәр дәвам итәчәк алтын араны ни сәбәпледер озайтасым килә. Хәзер исә уйлыйм-уйлыйм да, мондый сиземләү бер дә юкка булмаган икән дигән нәтиҗә ясыйм. Бу якын ара, бу санаулы адымнар минем өчен гомеремнең гомуммилли мәгънәсенә әверелер дип кем уйлаган?!

Әйе, әниләрнең Ай яктысы яктырткан гәүдә сызмалары бу мизгелдә үзләре, үзләре, үзләре үк ике яктан да тоткалы алтын кәүшән — Мисыр амфорасының үзе, үзе, үзе иде!..

Идел ярларына басып,
Карап тордым Иделгә...

Ярларына басып карап торгач, димәк, Идел дигәннәре йә елга, йә диңгез, йә диңгездән дә зур дәрья булырга тиештер.

Кинәт мин үземне шул дәрьяның ярында басып торган пәһлеван итеп хис итәм. Миңа биниһая көч керә. Гүя күк капусы яңадан ачыла һәм аннан Ходай Тәгаләнең язмыш чыклары коела. Күкрәгемдәге янартауларны тетрәтеп, йөрәгем кузгала. Дәрт-дәрманым таша. Мин нindидер алтынчы тойгы белән тоям: миндә, күп дигәндә биш яшьлек сабый күкрәгендә, өстәмә йөрәк, җанымда өстәмә җан, канымда өстәмә кан ярала. Иман уяна. Гарьлек калка. Гөман сызыла. Җанга Вөҗдан сугарыла. Калеб яратыла...

Хәзер аңлавымча, бу мизгелдә мин вөҗдан канатларында очканмын. Калеб гөмбәзе астында яши башлаганмын. Калеб — бик тә киң мәгънәгә ия булган төшенчә. Әйе, Илаһым, ул — калеб. Бер гөмбәз астындагы йөрәк, җан, вөҗдан дигән сүз. Әйе, ул йөрәк тә, җан да, иман да, намус та, вөҗдан да, хис тә, акыл да, даһилык та. Бәлки, аны, юнан фәлсәфәсеннән чыгып, нибары бер генә сүз «henium», ягъни һәр кеше, һәр адәмзат өчен хас булган «даһилык уяну» дип кенә атап булган булыр иде. Әмма, бр-р-р! Бездә, татарда, «даһилык» төшенчәсенә бик турыдан, артык беркатлы карап өйрәнелгәнлектән, ул сүзне һич кенә дә кулланасым килмәгән иде. Әмма, нишләтсәгез дә, әйтмичә булмый: бар, бар андый сирәк мизгел адәм баласы язмышында. Бу «Мин даһи!», «Мин пәйгамбәр!» дип күкрәк кагу түгел. Бу гамәлдән Ходай сакласын. Бу, әгәр шулай әйтергә яраса, чын кеше булуга дәгъва итү сыманрак халәттер. Аны, бәлки, «акыл утыру, балигъ булу» дип тә гадиләштерергә мөмкиндер. Һәркемнең үз даһилыгы үз калебенә, үз иманына, үз вөҗданына тигез. Шуңа күрә мондый мизгел һәр кеше гомерендә үзенчә кабатланадыр. Иртәрәк, соңрак? Көчлерәк, көчсезрәк, йомшаграк? Хислерәк, тупасрак? Киңрәк, масштаблырак, таррак һәм накыйсрак?

Кан тамырларына илһам, көч булып йөгергән калеб — иман, вөҗдан, көч, акыл, хиссият сабый зиһендә кешелек хакына изгелек кылу теләген тудыра...

Әйе, мин көчле. Әйе, мин хисле. Әйе, мин мәхәббәтле. Мин беркемнән дә курыкмыйм. Тик бер Ходайдан һәм ул бар иткән табигатьтән генә көчле түгел. Мин бер Ходайдан гына куркам. Мин, шушы мизгелдә тузан иләп теркелдәгән сарыклар артыннан барган бала, әйткәнемчә, нindидер алтынчы тойгы белән беренче тапкыр үземдә нindидер илаһи көчкә ия булган пәйгамбәри җан барлыгын, киләчәктә үземнең нindидер кабатланмас, башкаларныкына һич тә охшамас язмыш бәндәсе булачагымны тоям. Минем изелгәннәрне яклыйсым, залимнәрне кыйныйсым килеп китә. Зиһенемдә безне озатып барган һәр үлән кыягы шәмдәл булып яктыра, минем тәнем меңләгән тере күзәнәкләр белән сулый — бу

күзәнәкләрдә миңа аһәң биргән елга-инешләрнең, миңа көч биргән игеннәрнең, телемә тәм биргән җиләк-җимешләрнең, буыннарыма дәрман биргән мал агының дәрте-яктысы кергәндәй була.

Мин нишләп ятим булыйм?! Миндә вөҗдан бар!

Иманын сатмас өчен башын югалтыр дәрәҗәдә батыр кешеләргә дә, кансыз, кызгану белмәгән имансыз кешеләргә дә «ул йөрәксез бит» дип әйтүләре исемә төшә дә, миңа күңелсез булып китә.

Елыйсым килеп куя.

Ләкин мин тешемне кысып булса да еламыйм.

Ятимнәрне мин үзем яклый алам! Шул мизгелдән башлап мин үземне кызганганнарны яратмый башлыйм. Әгәр берәр әби: «И-и, ятим бала бит син!» — дип, аркамнан кагып сөя башласа, мин сырт чәнечкеләрен тырпайтам. Мин ятим түгел! Минем әнием, абзыйларым бар. Менә әле ике арада төчкеренеп кайткан мал-туарым — сарыкларым бар. Әниләрнең иңен көмеш путал белән чорнаган Аем бар. Вөҗданым, калебем бар. Мин үзем кешеләрне яклый алам. Мин үзем изелгәннәрне, рәнҗетелгәннәрне, ятим-ятимәләрне якларга бурычлымын! Әнә Айны гына ал. Ул да ятим. Ул да ялгыз. Әмма ул бар дөньяны яктырта. Бәлки, дөньядагы бар яктылык ятимлек моңыннан киләдер?

Минем язмыш башкалар исәбенә данланган һәм батырайган язмыш булмас. Минем башкалардан үземне юаттырасы түгел, ә үземнең башкаларны юатасым килер. Бу инану, бу ышану шулкадәр көчле булыр ки, мин хәтта бу вакыйгаларга егерме ел үткәч, бар дөньяны юату тойгысыннан тилереп, «Кайсыгызны юатыйм?» дигән шигырь язармын. Буш, ялган, алдак юату түгел, көрәш аша өмет уяту, нәтиҗә аша чын юату минем тормышымның мәгънәсен тәшкил итәр. Мин барасы юлларга якты шәмдәлләр тезеп, әүвәлдә Вөҗдан чыгар. «Вөҗдансыз, имансыз, мәхәббәтсез» — минем өчен соңгы чиктәге сүгенү сүзенә әйләнер. Буш, ялганчы кешеләр минем дошманыма әверелер. Мин андыйларны алдан ук, исләреннән үк тоеп юлдан алып очырырмын йә урап үтәрмен. Кем анда ятимнәрне изә? Издермәбез! Кем анда кеше гәүдәләреннән күпер тезә? Тездермәбез! Намус һәм гарьлек. Хезмәт һәм иман. Бу минуттан башлап кемнәрдер минем белән уйнамас, кемнәрдер мине яратмас, кайчакларда мине бөтен дөнья яратмас, сөйкемсез сөяккә әйләнгән, миннән бөтен дөнья баш тарткан, бөтен галәм этләре миңа өргән кебек тоелыр. Ике ут арасында ут булып янган шушы тойгы гомер буе дәвам итәр. Мәхәббәт белән нәфрәт арасы — бер адым. «Ярый әле, дөньяда мин бар» белән «Дөньяга ник тудым?» арасында үтәр бу гомер. Мөлаемлык һәм сөй-

кемсезлек, мәхәббәтлелек һәм мәхәббәтсезлек мин яккан, яндырган учакның кисәүләренә әйләнер. Әмма шушы ара үзе үк милләттә миңа карата яралган садә ихтирамның йөрәген, дәрманын, куәтен, көчен, вөҗданын — калебен тәшкил итәр. Мондый хәятның төбендә өч көч — тере иман, тере табигать, тере мал ятар. Мин йөрәкнең янмаган өлешләрен калдырмам. Мин аңлармын: кешелекне бәхетле итәргә тырышу өчен көрәш юлында килгән сынаулар кемнеңдер минем белән «уйнаудан» баш тартуыннан күпкә өстен һәм күпкә ләззәтлерәк икән...

Шушы мизгелдән башлап мине дан һәм байлык кызыксындырмас. Миндә беркайчан да кара көнчелек, кешегә аяк чалу дигән нәрсә булмас. Шушындый сабырлык өстемә таутау даннар ишелеп төшкәндә дә мине саклар — мактаудан шашмамын, хурлаудан сынмамын. Авыр сүздән сыгылмамын, дошманга да кара коелмамын, дусларым кадереннән уелмамын. Шул мизгелдән башлап мин үземдә гаять тә зур һәм мәңгелек үзгәреш кичерермен: кеше мактаганда, мин күккә күтәрелмәмен, ә калебем — вөҗданым белән җиргә түбәнәеп, туфракка сеңә торган булып китәрмен. Җиргә елышырмын. Җиргә сыгынырмын.

Кырлыганның көзгедәй якты кыйпылчыклары Ай яктысында күзгә күренеп ишәя. Бу инешнең авылга таба саегая барып сазлану һәм сызлану ишарәте. Ай инде безнең башларыбызны гына яктырта. Гәүдәбезнең калган өлешләре караңгыда. Димәк, без авылга — туган чокырыбызга кереп тә җиткәнбез бугай.

Минем кайгыларымны да
Илтеп сал дип диңгезгә-ә-ә... —

дип җырлана җырда кайгы турында.

Нинди кайгы? Нигә кайгы? Җыр кайгыртырга түгел, дәртләндерергә тиеш! Минем кайгырасым килми. Кулымда хәерхаһ чыбыгы бар. Минем шушы чыбык белән бар дөньяны куалыйсым, хәят-тормышны үзгәртәсем, яхшыртасым, иманга китерәсем, калебкә утыртасым — юатасым һәм үстерәсем килә.

Без барабыз. Иделләргә таба.

Алда — иңнәрендәге Айдан төшкән нурлар айкалышында ике тоткалы алтын кәүшән савыт — амфораны хәтерләткән ике ятимә җырчы, ике тормыш сакчысы, ике киләчәк көрәшчесе — газиз әнием һәм аның гомерлек ахирәте Садыйка түти, уртада юл тузанында төчкергән сарыклар, иң артта — кулына карама чыбык тоткан мин — булачак колыгыз Айдар Хәлим киләм...

*3 — 7 август, 2003 ел*

# ҖЫРЛАР ВАКЫТ

*Халык җырчысы Илһам Шакировка*

Вакытың җитте.
Җырлар вакытың җитте.
Кемдер шулай дип пышылдады кебек.

Чәлтерләренә кадәр чебиләгән аякларын өянкенең тирән буразналы каерыларына сыдыртмаска тырышып, Сәгъдәт югарыга үрмәләде. Әмма ничек кенә тырышмасын, ара-тирә әнә шул ермаклы каерыга ышкылып, балтырларындагы кызгылт җепселләре тоз сипкәндәй әчетеп-әчетеп ала. Елның елында, аеруча җәйнең матур кичләрендә, шушы өянкегә кунаклап үсте бит ул. Быелын инде әйтәсе дә юк, әллә нишләде: өянкесенә сандугач кебек куна да сайрый, куна да сайрый. Ботакларның берсеннән икенчесенә бик тә җайлы, бик тә җиңел күчә, — менә әле дә үзенә генә билгеле хәрәкәтләр ясап, куначасына менеп тә җитте. Моннан да биегрәк үрләргә ярамаганлыгын аңлый Сәгъдәт. Артык югарыга ымсынып, сыек ботакка кунакласаң, чәнчелеп төшкәнеңне көт тә тор.

Сәгъдәтнең авылы — көмеш өянкеләр, бөдрә таллыклар төбәге. Аларның үз ихаталарында гына да өч карт өянке үсә, әмма монысы, ул кунаклый торганы, уалы кәүсәсе белән читәнне урамга этәреп чыгарганы — иң яратканы. Ул, әлбәттә, моннан йөз еллар элек, ерак Борһан бабасы утырткан заманда, ихатаның эчендә үк булгандыр. Гомер үтү белән, күрәсең, өянке картайган, авыр карынга узган, калынаеп җәелгән һәм читәнне берничә карышка урам якка этеп чыгарган. Күп мәртәбәләр югарыдан күреп, Сәгъдәт үзе инанды: аның өянкесе Югары очның иң биек, иң мәртәбәле өянкесе. Аннан бөтен авылны күреп була. Юанлыкка да Сәгъдәт колачы белән дүрт колач тарта ул. Аннан хәтта Түбән очның да иң очында яшәгән Сөмбелләрнең өе күренә. Әгәр аларның Колтамагы Өязе үзәнендә, тирән чокырда ятмаса, күз күремен биек таулар, кара урманнар каплап тормаса, ул, бәлки, әнисенең туып үскән авылы Бузатны, кан-кардәшләре тамырланган Тәтер-Арысланнарны да күрә алган булыр иде. Күрше авыллар аларны «Колтамак» дип тә сырлап тормыйлар, «Чокыр» диеп кенә җиффәрәләр, оятсызлар. Колтамаклардан да хәерчерәк Теләнчетамаклар да бар инде югыйсә. Әйе, Колтамак — чокырда. Әмма алтын чокырда ул, егетләр. Сәгъдәт моны бөтен җаны, тәнендәге һәр күзәнәге, һәр тамыры белән тоя.

Аннан тагын да бер кызык һәм сәер сыйфаты бар Сәгъдәт өянкесенең. Башка өянкеләр чегән таборы сыман кара

карга оялары белән караеп, карга тавышлары белән каркылдап торса, Сәгъдәтнекенә нишләптер оя кормыйлар. Яратмыйлармы? Сәгъдәтне көнлиләрме? Әллә башка берәр ырымы-сырымы, исе-косы, таты-заты бармы тагын? Сәгъдәтнең шуннан төшми җырлаганы ошамый мәллә аларга? Әй, юләр дисәң дә юләр инде мин, дип уйлап куйды малай. Соң, җырчы булган кешегә өянке башына менеп җырламаса, җирдә урын беткәнме? Җырчының өянкегә кунаклап җырлаганын кемнең күргәне-ишеткәне бар? Нишләсен соң ул шулай биеккә менеп, офыкларга текәлеп җырларга яраткач? Сәгате дә суга — җырлар вакыты да җитә. Ул тәүлекләр буе ач, сусыз утыра ала, ә менә вакыты җиткәч җырламыйча һич кенәләр дә түзә алмый. Уңайлы булсын, бер урында озак утырудан тәне оеп, җырларга комачауламасын дип, ул ботак атламасына тактадан кунача сыман нәмәстәкәй дә әмәлләп куйды.

Җыр — аның яшәү рәвеше һәм холкы. Ә бит аңардан көлгән малайларның апа-абыйлары кышкы зәмһәрир суыкларда аны, ун яшеннән башлап, чыптага төреп, бәләкәй чанага утыртып, аулак өйләргә алып китәләр, сәке өстенә, мендәргә кунаклаталар, һәм ул, күзләрен йомып, аларга сәгатьләр буе такмак әйтеп биетә:

Әннә-гидер-генәме,
Гармунчыгыз өйдәме?
Өйдә булса, килсен әле,
Биетеп китсен әле...

Гармунчыгыз өйдәме, имеш. Бар, таптың ди гармунны бүгенге авылда! Шулай, көн саен кичләтеп, халыкның яланнан кайтып, ихатасында вак-төяк эшләр караштырган, көтү каршыларга җыенган «буш» вакытларында өянкегә менеп җырлау гадәте йокты аңа. Иңнәренә, фасылына карап, чалгы-тырма, көрәк-сәнәк күтәргән ятим җиңгиләр, сабыйлар һәм апалар, үсмер кызлар һәм егетләр, урамнан үтеп барышлый, Сәгъдәт өянкесен сырып алалар һәм үтенечләрен яудыра башлыйлар. Фәләнне җырла, төгәнне җырла! Патифундыр ул! Ырымбур далаларыннан Өязе үзәне буйлап күтәрелгән хуш исле, исерткеч әрем исе, серкәләнгән арыш исләре кушыла Сәгъдәт тавышына. Өянкесеннән төшә башласа, аны кире куып менгерәләр:

— Йә, чукынма инде, җырла берне генә! Югыйсә китмибез!

Һәм китмиләр дә. Лап итеп читән буендагы ташларга килеп утыралар.

Үти аларның үтенечләрен Сәгъдәт. Өянкесеннән тәгәрәп төшкәнче җырлый. Аеруча «Шөгер»не яраталар. Каткат җырлаталар әле күптән түгел генә таралган бу көйне.

Әллә каян гына килеп тә чыга, күңелләрне әсир дә итә бит ул яңа җыр. Тик нигә «Шөгер» аның исеме? Ниткән «Шөгер»? Югыйсә аны башка якларда «Гүзәлем» дип тә йөртәләр, ди. Колтамаклар аны бары тик «Шөгер» генә диләр.

Җырлый башлар алдыннан аңа әллә нәрсә була: ниндидер АК САКАЛЛЫ БАБАЙ аңа күзләрен йомарга куша. Күктә ул үзе. Кулына ниндидер китап тоткан. Менә шул чакта маңгай күзләре түгел, йөрәге күрә башлый аның. Шулай итмәсә, күзләрен дөньяга шар ачып җырласа, җырында ялганлар, моңында ялгышыр кебек тоела. Җыруын тәмамлаганчы, ул түбәнгә — җирдәгеләргә карамый. Белә, сизенә ул — ятимә җиңгиләр яшьләрен алъяпкыч чите белән сөртеп елыйлар. Нидән елыйлар? Сәгъдәтне кызганыпмы? — Унике яшеннән узып кына барган үсмер әлегә язмыш дигән упкынның төбен чамалый алмый иде. Яшьрәкләр, авызларын ачып, тынсыз торалар. Сәгъдәтнең беркемне дә елатасы килми, киресенчә, күңелләрен күтәрәсе, юатасы, үзе ашкан биеклекләргә аштырасы килә. Ә тегеләр тыела алмый елыйлар. Аннан үзенең дә үзен кызганучыларны кызганып елыйсы, җыруны өзәсе килә башлый. Ничәмә-ничә тапкыр шулай булды бит инде! Һәм Сәгъдәт җыруын тәмамламыйча түбәнгә карамаска ант итте. Гадәттә, җыруын тәмамлауга, җирдән, түбәннән аңа мактау ишетелә:

— Афәрин, Сәгъдәт! Вәт тавыш дисәң дә тавыш!..

— Кирәкми безгә багана башындагы җансыз ырадиу! Аяклы ырадиуыбыз — Сәгъдәтебез исән булсын!..

— Бу көмеш бугазны балтырган шулпасыннан бал белән майга күчерсәң, ничек кенә җырламас иде, ә? — Монысын инде күршесе Титак Тәкетдин карт сиптерә. — Укытып та кайтарсаң, ә? Тәк, тәк!..

Үзенең җырларын җыру дип атарга да Тәкетдин карт акыл бирде.

— Җырга аның озын көе дә, кыска көе дә, әтәк-сәтәк такмагы да кирә, энем, — диде ул Сәгъдәткә. — Синеке — җыру-у!.. Озын, җырып чыга алмаслык борылышлар, вәт!..

Сәгъдәт мондый мактау-сыктауларга битараф. Мактыйлармы, әллә яманлап хурлыйлармы, аның өчен барыбер иде. Ул бит мактау хакына түгел, җыру хакына җырлый. Җырламыйча түзә алмый, чөнки сәгате суга...

Ә менә «өянкедәге ырадиу» дигәннәрен кабул итә, ярата ул. Бу канатлы ләкап аңа ниндидер түгәрәк көч, горурлык өсти. Колтамакларда күрше Әнәч, Ишле, Качаган, Җилдәрләрдәге шикелле, өйләрдә дә, багана башларында да ырадиу бытырдап утырмый. Бар юанычлары менә шул «өянке ырадиусы».

Сәкесенә кунаклап алган Сәгъдәт күк йөзен күздән ки-

черде. Бу кадәр чиста зәңгәрлекне каян ала икән ул? Анда бер генә чүп ишарәте булса! Кәркәле таудагы Имәнлек урманнарына таба тезелеп киткән ап-ак, каурый сыман болытларның нәзберек камиллеген кара син! Гүя кояш алсулыгына манчылып, алар яңа җыру яза. Бәрәңгеләр, сабантуйга чыккан кызлар кебек аллы-гөлле киенеп, шау чәчкәдә оеган. Бу сәхрә гөж килеп тора: урман аша гына яткан Хлебороб хахулларының әрсез, эре кортлары тубал-тубал булып өерелеп, чәчкә күзләреннән бүгенге көннең соңгы балын эскәкләп җыя. «Безнең чәчкәләрнең күпме балы, күпме моңы, күпме буяулары читкә китә, — дип уйлап алды малай. — Колтамак халкы нигә умарта асрарга һәвәс түгел икән?» Менә үссен генә, ул үзе кортлар үрчетәчәк!

Әнә Миңсорур түтинең улы Вәрис, корсагын тырныйтырный, Өязе буеннан кайтып килә. Ачыккан, күрәсең. Карыны ач — корсагында кисәү агач. Өенә кереп китте. Бар, тутырып куйганнар ди сиңа анда. Әнә уң яктагы күршеләре Хуәдәр Низамының берсеннән-берсе кече Гадәния, Хәмдия, Сәрия, Рәмзия, Хәнияләре бәбкә үләненә түгәрәкләнеп утырган да бишташлы уйный. Сбердлау урманнарыннан аякларына ырматиз эләктереп кайткан уллары Миңнетдин, арба үрәчәсенә чалкан ятып, каз мае сыланган балтырларын кояш нурында мунча кертә. Сөякләре кибә, ди, аның. Юкагач кебек шалтырап кибә, ди. Сул як күршесе Тәкетдин карт «уфалла» арбасы янына чатанлап килде дә шакылдый башлады. Туң чүкеч тавышы ихата буен басып киткән биек киндер, кычытканнарга саңгырауланып сеңә. Сәгъдәт бу картның исемен дә белми, һәрвакыт «тәк, тәк» дип нәтиҗә ясарга яратканга күрә аны авылдашлары «Тәкетдин» дип кенә атый. Урам аша яткан күршесе Лотфулланың йорт морҗасыннан, җитмәсә мунчасыннан да, кара аркан булып ишелеп, төтен чыга. Мунча да ягып җибәргән, әйгенәм. Әлеге сәгатьтә Югары очта чыккан бердәнбер тере төтен. Күршесенең гадәтләрен яхшы белгән Сәгъдәт, берәр әкәмәт хәл була икән бүген, дип уйлап алды.

Җырлар вакытың җитте!

Гүя кемдер шундый әмер бирде.

Малай, авыз эче кипшенеп, коргаксып китмәгәнме дип, теле белән аңкавын капшады, йомшак кына итеп йөткереп куйды. Тирән сулыш алып, тынын чыгарды.

Һәм — тынып калды.

Йөрәге тыныч алкымда тибә иде.

Ниһаять, авылының иң биек өянкесенә кунаклаган унике яшьлек ятим күзләрен йомды да җырлап җибәрде:

Сарман буйкайлары
тугай-туга-ай-ай-ай…

— Гай-гай-гай!.. — дип, еракლардан кайтаваз алды бу аһәң.
— Ай-ай-ай!.. — дип өзлекте әрәмәләрдә бу аһәң.
Гүя Өязе буйларының меңләгән карт өянкесенең, меңләгән яшь тал туйрасының семәрләнгән көмеше, кыллы кыңгырауларда зеңгелдәп, коелып төште һәм бу көмеш, үзенә урын таба алмагандай, тыкрыкларга тулышып буылды, аннан буаны ерып, Кәркәле тауларындагы ефәк кылганнарда тирбәлде; гүя меңләгән сөлектәй ир-ат һәм хатын-кыз, берсе-берсенә җепсез бәйләнеп, Өязе тугайларында пакуска төште, аларның таң чыгында тагын да яшәргән, тагын да яктырган, каты кондырак үлән балавызында тагын да чарлана, үткенләнә төшкән чалгылары үзе бер симфония, үзе бер бөек операга торырлык җыру-пакусны бергәләп иҗат итә иде... Кеше моңының, аның мөмкинлегенең хисапсыз күп төсен, кеше аһәңенең, аның тирәнлекләренең иң аскы катламнарыннан иң өске катламнарына кадәр актарган, өзгәләгән, ялгаган бу гайрәтле, иркен, ефәк кебек йомшак, бәрхет кебек шома, ниндидер бер ихтыяр, көч, куәт белән сугарылган тавыш, бәлки, Җир шарына бер генә тапкыр туган бердәнбер бүләк булгандыр... Ул көчәнми, тамак ярмый, бары тик тын ала, димәк, яши генә иде.
Әйе, Сәгъдәт җыруны җырламый, бары тик җырлап яши. Ул сабый күңеле белән аңлый: җырлыйм дип җырлау үзе үк ясалмалык түгелме? Сабый сизенә: ул җырлаганда, кояш кына яктыртудан туктамый, ә калган бар тереклек — үләннәр, агачлар үсүләреннән, ә челтер чишмәләр агудан туктап тора кебек.
Ай-ай-ай!..
Куе, урман кебек үрә баскан үлән ахылдап һәм ухылдап ава, ә моң исә, керфекләргә бары тик яшь булып кына типкән моң — халыкның фаҗигале, бәхетсез язмышыннан гына бар була алган илаһи бәхет, илаһи кәүсәр чишмә, кояш күзе белән шомартылган чуерташлар, ямь-яшел су асты үсемлекләре өстеннән терекөмештәй жуылдап ага һәм бер-беренә ифрат дәрәҗәдә тәңгәл килә, бер-берсен тартып, киләчәккә алып бара торган авазлар бердәмлеген хасил итеп, шушы байлыкны беркемгә дә бирмәскә теләгәндәй, пакусларга килеп каплана:

Бер тугае аның анды-ы-ыз-лы-ы-ык...

«Андызлы-ы-ык» сүзенең соңгы авазлары, кыр казларыдай кыйгак-кыйгаклап, күкнең зәңгәр тукымасын җилпеде.
Малай күзен ачты.
Тәкетдин карт, хәлдән тайган кеше сыман, бер кулы белән читән казыгына тотынган да, икенче кулы белән каткан

колак яфрагын каплап, оеп калган. Гүя ул үзе һавадан сихәтле моң эчә, аның алдында, читән аша, шул ук моңны эчеп, тузанлы карлыганнары да кызарып карая иде...

«Андызлы-ы-ык» сүзенең соңгы авазлары күк гөмбәзеннән йөкле олаулар кебек шаңгырдап төшкән мәлендә абзардан, кулына әле генә чалынган, әмма җаны чыгып бетмәгән кара тавык тотып, Лотфулла абзый килеп чыкты һәм моң ташкынынннан туктап калды. Кичке кояшның кайнар селтесендә күзләре киселеп камашты, күрәсең, ул икенче кул яссуын күзләре өстенә күдрүк итеп куйды һәм өянкедәге карачкыга кычкырды:

— Җырла, быр-рат, җырла! — Болдырына күтәрелешли кулын болгады. — Урнаш ашарга керерсең!..

Кулындагы тавыгы соңгы мәртәбә тартышты да сүнде.

Лотфулла өенә кереп китте.

«Чынлап та бер-бер хәл була икән бүген, — дип уйлады малай кабаттан. — Тавык суеп, урнаш пешерсә, булмый кала диме?»

Лотфулла шактый кызмача, безнең як теле белән әйткәндә, төшрифүн иде.

Әкәмәтнең дә әкәмәте ул Лотфулла абзыкай.

Утызынчы еллар азагында Таҗикстан якларына чыгып киткән иде. Аннары ниндидер кырын эше өчен Колымада алтын комы юып маташкан, имеш. Иләгенә әллә алтын коелмаган, әллә туган ягын сагынган, ул авылына кайткан да җәмәгатьле булган. Колхозга кермичә дөнья көтә. Ә менә хатыны — колхозда. Шуңа күрә мыек астыннан гына елмаеп, «Ударнитса Миңниса» дип атый ул аны. Басмада очрашкан ике кирегә беткән кәҗә тәкәсе кебек яшиләр алар колхоз белән. Мөгезгә мөгез. «Күмәк көч» — Лотфулланы, ә Лотфулла «Күмәк көч»не чәнчелдерә алмый. Әмма «Күмәк көч»кә якты йөз күрсәтми инде Лотфулла — монысы рас. Җәй дип тормый, кыш дип тормый, каядыр райпром төзелешләренә, Эстәрлебаш якларына чыгып китеп, айлар буе урман кисә, бурасын бурый, кирпечен суга да, авылына кайтып, ун-унбиш көн буе үкертеп эчә. Аннан тагын чыгып олага. Авылда аңардан башка эчкән кеше юк. Озын буйлы, текә күкрәкле, зәңгәр күзләре дөньяны тишеп, үтә караган, кешегә ачык, ярдәмчел, кунакчыл, баскан җирендә ташны изгән, тимерне өзгән, җәмәгате белән еш кына тавышланып алырга яраткан Лотфулланы халык «Зимагур» дип атый.

Төшрифүн көннәрендә аның берьялгызы урнаш пешереп, үзен кунак итә торган гадәте бар. Тавыкмы, казмы, күркәме — күзенә нәрсә эләгә — тота да чала, йолкый, пешекли, камыр баса, тукмачын кисә, ашын пешерә һәм, үзенә-үзе җырлап биреп, кәеф-сафа кора. Былтыр җәй ул Сәгъдәтне дә

кунак итте. Сасы «сәмигулласын» эчмәде. Нечкә камырдан бөгәлләр ясап, тышына «ЫСЫСЫСЫР» дип язылган катламасын ашамады түгел, ашады.

Моңлы гына лай бала да
түгел иде-е-е-ем...

Моң! Аһ, халык моңы!

Бар микән дөньяда синнән дә серлерәк һәм ләззәтлерәк нәрсә!

Кайда, кемнәр, нинди тирәнлекләргә төшеп кискән синең очкыннарыңны? Нинди биеклекләргә күтәрелеп, сине бар иткән дә нинди таңнарда, нинди көннәрдә һәм төннәрдә нинди кыллар, нинди үткәргечләр аша сине Җир шарына тарата алган?! Аһ, туган моңнар, якты хәсрәт, эңгер-меңгерле шатлыклар! Сезнең үзәк чыганагыгыз — беләк белән йөрәктән туган бердәм хезмәт, сезнең ике канатыгыз — мәхәббәт һәм нәфрәт! Аһ, туган моңнар, туган аһәңнәр! Никадәр даһи булган саен, сез шулкадәр гади, чөнки сез — хезмәт. Никадәр илаһи булган саен, сез шулкадәр эчкерсез, чөнки сез — хезмәт. Менә ни өчен сезнең мәхәббәт нәфрәткә тиң!..

Баеп барган кояшның нәкъ үзәгенә кереп оялаган Сәгъдәт үрелеп Түбән очка караш ташлады. Сөмбелләрнең Бурлытау итәгендә утырган өйләре җәүһәрдәй җемелдәп күренә иде. Бәлки, чынлап та җәүһәрдәндер ул? Кызлар яшәгән урын башкача була аламы? Их, бер генә тапкыр күрергә иде Сөмбелләрнең өй эчен! Ишетелә микән кызкайга Сәгъдәтнең җырулары? Ишетелде ди сиңа!..

Алар бер сыйныфта укыйлар. Ак киҗе-мамык тукымага вак кына кара борчаклар төшкән күлмәк, аягына бәйләгән оеклар өстеннән Донбасстагы абыйсы җибәргән кечтеки генә ялтыр галушлар кигән, чәчләрен уртадан ачып, майлап тараган, аннан толымнарының очына тәңкә урынына алсу тасмалар чачаклаган кызкайны бик тә ошата, бик тә... ярата шул Сәгъдәт. Башка малайлардан кыерсыттырмый, кая басса, кая барса — карашы белән озата бара һәм каршы ала. Өянкенең иң биеген сайлап, шунда менеп сайравы да Сөмбел өчен генә бит инде! Быел кыш пасилка да салды әле ул аңа. Һи-и, пасилка дигәне дә адәм мәсхәрәсе — танау кычытмаслык тәм-том инде шунда. Әнисенең бертуган сеңлесе Шәрифә апа Сбердлау якларында урман кискән җиреннән бик татлы бернәрсә җибәрде. Ул «кәнфит» дип атала икән. Аны ничек кенәләр итеп Сөмбелгә авыз иттермисең?! Чәй эчкәндә әнисе биргән кәнфитне үз авызыннан өзеп җыеп барды да, менә шул дүрт почмаклы, тәмлеләрдән-тәмле дүрт кәнфитне шырпы кабына салды, капка Фәния апасының чигү чигә торган төсле җепләрен дә бераз чәлдереп тыгарга онытмады.

Бәлки, Сөмбел Сәгъдәткә кульяулык чигәр? Аннан шырпы кабының тышына: «ЫСЫСЫСЫР. КОЛТАМАК. Түбән оч. Сабирова Сөмбелгә — Сәгъдәттән», — дип, эре хәрефләр белән язды һәм тәнәфестә, вакытын кулай китереп, Сөмбелнең кесәсенә шудырды да төшерде. Ул көнне Сөмбел ике фәннән бишле алды, йөзе кояштай якты, бите алмадай алсу, маладис, куанычын башкаларга сиздермәде, чукынчык кызыкай! Җәйге ялга чыкканнан соң аның Сөмбелне күргәне-очратканы да юк. Их, бер күрәсе иде дә бит аны!..

Моңландыра икән ялгыз-лы-ы-ыык!..

Имән урманнары өстендә баюга барган кояш, гүя шул агач кәүсәләрен ягып, чуен кайната иде. Кояшның кызган кылларында гөләп-кызарып янган урманга туры карап та булмый. Әйтерсең кичке шәфәкъ — кичке таң Сәгъдәтнең моң кояшында, ә Сәгъдәт исә кояш шәфәгында дөрләп яна иде. Нурлар түбәндә, үзәнлектә яткан өянкеләрнең ябалдашларын алсу челтәр белән каплап, җем-җем кайнаша, бергә укмаша, яңадан тарала, бии. Үзәнгә, туфракның үзенә төшеп җитә алмыйча суынган бу нурлар, инде түбәннән күтәрелеп оеган дым, сусыл тын белән очрашып, һаваны сафландыргаппан-сафландыра бара. Бу сафлыкта — тере дөнья — сабыйның үзәк өзгеч моңы, сусыл кузгалакларда әчегән үлән кымызы, кычыткан зәһәре, әрем, эт эчәгесе, каз катламасы, пәйгамбәр сагызының хуш исләре белән бергә кушылып, сулыш юлларын иркә кытыклый; көн белән төнне кавыштыру ниятендә пәйда булган барлык төр чебен, озынборын, кигәвеннәр, үрмәкүчләр, коңгызлар, Аллаһы Тәгаләнең башка барлык бөҗәкләренең канатлары гүя сабый моңында җилпенеп зеңли һәм яшәешнең мәңге борчулы тынычлыгын тагын бер тапкыр раслый иде...

Нинди матур Сәгъдәтнең туган авылы!..

Ул беркайчан да моннан китмәячәк. Ул хәтта абзардагы тезгә җиткән тиресне дә чит илгә алыштырмаячак. Әле быел җәй башында гына Уфага китеп бармавына куанып бетә алмый. Яшь җырчыларны эзләп килгәннәр, имеш. Ниндидер прафисырларга тыңлаттылар. Шулар арасыннан берсе, композитор Мәсәлим Вәлиев диделәрме, чатябеште бит моңа: «Сирәк талант! Алып китәбез, бөтен дөнья таң калачак! — ди бу. — Башта Уфада, аннан Мәскәүдә укытачакбыз. Сәгъдәтнең урыны опера сәхнәсендә!» Анысы ниткән «упыра»-дыр инде тагын. Алып китми тор әле, абзыкайгынам. Бу мәсьәләне монда икенче прафисырлар — әнисе һәм апасы хәл итә. Һәм дә... һәм дә... Сөмбел. Апасы дөрес әйтә, җырчы булырга теләсәң, укымыйча да булып була. Укытып җырчыларны бозалар гына...

Сарман буйкайлары тугай-тугай,
Тугаенда сайрый бер тургай-а-а-ай...

Монавы кадәр матурлыкны ничек ташлап китмәк кирәк? Монавы өянкене? Кемдә бар мондый биек сәхнә? Бу кадәр акыллы тамашачылар? Сәгъдәт, кояш күзенә — шәфәкъның нәкъ үзәгенә кереп, тирә-ягына нурлар шаукымы тараткан, пәйгамбәрләр башыдай нурланган башын артка чөйде. Кемнәр, нинди көчләр иҗат итә икән мондый гүзәл сурәтләрне? Алар да укыган кешеләрме? Ап-ак, үтә күренмәле каурый болытлар тезмәсен кем шулай зифа рәтләргә тезә, күк зәңгәрендә чайкатып, кояш нурларында аунатып, алсу путалга ала һәм төрле төсләргә буялган гармун күреге кебек дерелдәтеп тора? Теге Ак Сакаллы Бабаймы? Иң кирәк вакытында гына килә ул Бабай Сәгъдәтнең зиһененә. Китабын тотып, аякларын бөкләп, болытка менеп утырган ул. Сәгъдәткә нинди халәттә нинди адым ясарга кирәклеген пышылдап әйтеп тора...
Табигатьнең, димәк, Ходай Тәгаләнең камилләрдән-камил, серлеләрдән дә серле җимеше, таң калдырырлык иҗатчысы, аның унике яшьлек кенә моң чишмәсе, әле үзенең кем икәнлеген дә белмичә, бары тик шушы гади булмаган галәми сораулар белән өзгәләнә һәм җәфалана иде...

Иртәсен дә сайрый, кич тә сайрый...

Кинәт ул Кәркәле күпере төбендәге биек өянкегә кунаклаган кара өтерне абайлады. Әйе... ул өтер... Якуп иде, билләһи! Кладаушик Ярулла малае Кара Якуп!

Саргаеп ла-а-а...

Сәгъдәтнең тавышы сынды, йотылды, гүя кемдер җыр тукымасын үткен пычак белән урталай телде.

...үлсен...

Һәм ул «ди бугай» дигән соңгы сүзендәге соңгы энҗесен коеп өлгермичә туктап калды. Өзелде. Көн кызуында өши башлап, тәненә бала йоннары калкып чыккан, калтыранган Сәгъдәт үзен тиз кулга алды һәм колакларын шомрайтты. Күпер төбендәге өянкедән көчәнеп җырланган җыр яңгырады:

Фирдәвескәй, кара күзкәй,
Ай нуры бар йөзеңдә-ә-әй...

Кара Якуп — Сәгъдәтнең сыйныфташы. Белми, аңламый малай: нинди сәбәпләр, нинди мәнфәгатьләр белән каныкты ул Сәгъдәткә? Буй-сынга төгәл, туп кебек түгәрәк,

тыгыз тәнле, кара-кучкыл йөзле, кара күзләре карашыннан тирә-якка корымнар коелып торган Якуп — Түбән очның җырчысы. Ике яшькә өлкәнрәк. Күпләрдән көчлерәк, куәтлерәк тә. Тәнәфестә малайларны бер өемгә өя дә ташлый ул. Икенчедә ике, өченчедә ике ел утырып, быел дүртенчедән дә күчми калды. Тавышы Сәгъдәтнеке кебек көчле бәрхет тавыш түгел түгелен, әмма үзенә хас моңы, заты бар: ничектер карлыккан, суынып чыккан аһәңдә «Фирдәвескәй» кебек кыска тынлы җырларны коеп кына куя ул. Җырчы кешегә мәйдан тар түгел дә бит, әмма бәла дә шунда: урын җитми, күрәсең. Бер сыйныфта укысалар да, аның Якуп белән чәкәләшкәне юк; мәктәп кәнсиртләрендә бергә җырлыйлар югыйсә. Мәгәр шунысы хак: Түбән оч җырчысы, җитмәсә, шуңа өстәп, Сөмбелнең ут күршесе дә булган Якуп менә ике ай чамасы инде, кич җитте исә, үзенең очын ташлап, Югары очка күченә, Кәркәле инеше буендагы өянкесенә атланып ала да нәкъ Сәгъдәт җырлаган сәгатьләрдә ярыш ачып җибәрә. Сәгъдәт моңа игътибар да итми, ә менә Якуп игътибар итә. Эштән кайтучы авылдашлар Сәгъдәт өянкесен уратып алалар да туктаусыз кул чабалар, Якуп өянкесе каршында алар йә бөтенләй туктап тормый, йә «ә-ә, бу да җырлап азаплана икән» дигәндәй, адымнарын сүлпәнәйтеп, кулларын тирбәтеп кенә үтеп китәләр. Күп тә үтми, ул Сәгъдәт өянкесенең төбен үк басып ала башлады. Килә дә урынында тыпырдарга, кычкырынырга-җикеренергә тотына:

— Җырлама! Җырлама, дим! Җырлама!!!

Мондый кыланышның һичбер сәбәбен аңламаган Сәгъдәт башлаган җыруын тәмамламыйча туктамый, әлбәттә. Бу исә Якупны тагын да ярсыта. Ул, ятып, йодрыклары белән җирне төя башлый:

— Җырлама, бур! Әтигә әйтәм! Җырлама, хәерче!..

Сәгъдәт чигәсендәге авыртудан чак кына кычкырып җибәрмәде. Караса, әнекәйгенәм: Якуп тагын килгән, астан таш ыргыта!

— Төш! — ди ул ажгырынып. — Төш, дим! Бур Юныс малае! Бур Юныс малае!..

Ул чигәсеннән саркыган канын сөртеп алды. Биектәге Сәгъдәткә түбәндәге хәлләр бик мәзәк тоелды. Нәрсә тели бу Якуп? Аны берәрсе котыртамы әллә? Әле күптән түгел генә өйрәнә башлаган «Хафизалам-иркәм»не «акбур» таулардан тагын бер кат уратуы булды, Якуп, бумасы тоткандай, җиргә гөрселдәде, тырнаклары белән җирне тырнап, йодрыклары белән төеп, шушы төш, шушы өянке төбенә тамырланырга теләгәндәй һәм тамырлана алмавына гарьләнепме шунда, ауный, тәгәри, нindидер аңлашылмаган ымлыклар, аһылдаулар хасил итеп, башын җиргә ора башлады:

— Ыг-гы-гы, ва-вах-вах!.. Псиүә — тух-тух-трах-вах-вах-вах!..

Әллә чынлап та бумасы тотты микән? Шомга төшеп агарынган Сәгъдәт, башлаган җыруын ярты юлда тәмамлап, аны-моны уйламыйча, өянкесеннән аска таба шуышты һәм, ниһаять, сикереп төшеп, өенә керде дә аннан авызы ашалып беткән чуен чүмечтә салкын су алып чыкты.

Якуп һаман җирдә бәргәләнә иде.

— Тор, Якуп. Мә, эч. Тынычлан. Бүген җырламам.

Үсмер берни булмагандай урыныннан сикереп тә торды, Сәгъдәтнең чүмечен бәреп тә очырды.

— Мин синнән матуррак җырлыйм! — диде ул, телен күрсәтеп. — Мин барыбер синнән матуррак җырлыйм!

Бу сүзләрдән Сәгъдәтнең зиһене яктырып китте.

— Әйе, син миннән матуррак җырлыйсың. — Малай шулчак Якупның кара көнчелек белән чирләгәнен аңлады. — Теләсәң, хәзер җырла. Мин тыңлармын.

— Әле син миннән көләсеңме, мөчтән?! — Якуп аның тирәсендә тилгән кебек канатларын җәеп әйләнә башлады. — Әйдә, көрәшәбез! Кем кемне җиңә, шул иң яхшы җырчы була!..

Сәгъдәтне шундук бөтереп алды, ташлы җиргә дә деңкетте. Беравыкка күз аллары караңгыланып киткән малай бу хәлдән гарьләнеп, ыңгыраша-ыңгыраша урыныннан күтәрелде һәм җан ачуы белән Якупка ташланды. Тыныч, кояш нурында оеп калган авылда ике малай — ир күәсе сугыша иде. Көчләр тигез түгел иде шул. Буйга Кара Якуптан калышмаса да, әйткәнебезчә, яшь ягыннан бәләкәйрәк, көч-куәт ягыннан кайтышрак иде шул Сәгъдәт. Аннан ул мондый кансыз алышка җаны-тәне белән әзер дә түгел иде. Карашыннан коелган кара шаукымнар белән бар тирәне биләп алган, күз эчләре кызарып аларган Якуп тез белән аның эченә утыртты, яңадан күтәреп алды һәм, урында янтаеп китеп, иңе аша очырды. Башы белән буразна катысына барып төшкән корбанын шундук котырган эт кебек талый, таптый, изә башлады:

— Менә сиңа! Менә сиңа! Безнең авылда бүтән җырламассың! Сөмбелгә бүтән пасилка салмассың! Уфа прафисырларына йөрмәссең!..

Калганы төштә кебек кенә. Ярый әле, Тәкетдин бабай күреп калган. Нәрсә белән тәмамланган булыр иде бу вәхши бәйге? Түр урманнарыннан үткәндә, арба тәгәрмәченең дөбердәвеннән аңына килде ул. Янында әнисе дә утыра икән. Райүзәккә, бальниска алып баралар икән аны. Унбиш көнләп ятты ап-ак бүлмәдә. Баш мие селкенгән, умыртка сөяге зарарланган, диделәр. Рәхмәт инде дәвалаучы апаларга. Аякка бастырдылар тәки. Авылга кайткач, әнисе аны нинди

генә им-том белән имләмәде дә нинди генә төнәтмәләрдә утыртмады! Әлегә, шөкер, зарары сизелми-сизелүен. Алдагысын Алла белә дигәндәй. Бальниста ятканда да, Колтамакка кайткач та, аны һаман да шул сораулар борчыды: Якупның болай хәшәрәт кылануы бары тик җырчылык көнчелегеннән генә киләме? Әллә ул чынлап та бик шәп җырлыймы? Әллә Сөмбелдән көнләшәме? Кеше яратса, нигә көнләшергә? Әллә тагын берәрсе, елан агуы йоттырып, котыртамы? Пасилка салуы турында Сөмбел үзе сөйләгәнме, әллә җиткергәннәрме? Болар кемнәрдәндер сорашып кына белә торган серләр түгел иде бит. Кара син аны: «Безнең авылда җырламассың!» — диме? Сәгъдәтне иң нык тетрәндергәне шул булды. Кайда җырласын ди ул, Колтамакта да җырламагач? Кемнең юлына аркылы төшә, кемнең бугазына баса ул?

Соңгы соравына ул җавабын тапты да шикелле.

— Якупның әти-әнисе белә микән бу хәлне? — дип сорады ул әнисе белән апасыннан.

— Белмиме соң! — диде әнисе. — Мин сине бальниска салып кайткач та, авыл советына бардым. Анда Якупның әтисен дә чакырттылар.

— Нәрсә диделәр соң?

— Эшне зурга җибәрмәскә иде, диделәр. Үзегез килешегез, диделәр.

— Килештегезме соң?

— Кладаушик Ярулла безгә... — Әнисе карашын аска яшерде. — Бер капчык бодай китергәние...

— Колхоз келәтеннәнме?

— Анысы безгә караңгы инде...

— Караңгы?! Аның каравы миңа бик тә якты! Алгансыз, димәк?! Димәк, сез мине бер капчык чүпле бодайга саттыгыз?! — Шушы минутта бер башка үскән малай ирләр адымы белән өстәлгә таба атлады һәм кибеп-коргаксып утырган балчык чүлмәкне алды да идәнгә орды. — Кая ул атхут?! Кая ул? Яндырам! Өязегә агызам!..

Ул атылып тышка чыкты.

— Юк-юк, үскәнем, алмадык! — дип кочаклады аны Фәния апасы. — Ант итеп әйтәм, алмадык!..

— Карагыз аны!

Ул тагын өянкесенә менде. Караңгылык җирне биләгәч, эре йолдызлар кабынып, күк гөмбәзе чигүле ашъяулыкка охшагач кына төште ул җиргә. Бу кичтә ул «Хафизаламиркәм»нең, иске «Кара урман»ның әлегә кадәр ала алмаган борылышларын, чоңгылларына кереп югала торган әйләнешләрен үзенә буйсындырды. Татар җыруының серле кайтаваз кануннарын ачты, түбәннән югарыга, югарыдан түбәнгә күчү юлларына, атлы һәм җәяүле кичүләренә күперләр салды.

...Кара Якуп «Фирдәвескәй»дән «Зимагурлар»га күчеп, инде анысын да икенче кат урырга тотынды. Димәк, Кара Якуп Сәгъдәт бальнистан чыкканнан соң ярышырга килгән? Малайның бу ярышны кабул итми хәле юк иде. Аның баягы «Сарман»ы, «саргаеп ла» дигән тәгъбирдән соң «үләм ди бугай» дигән тәгъбирне җырлап өлгермичә өзелгән иде. Ул яңадан «Сарман»ны башларга уйлаган иде, ләкин уеннан кире кайтты. Бер җырдан гына түгел, ул үз-үзеннән дә туя, күрәсе килми.

Ул тирән итеп тын алды. Үпкәләрен алдында яткан озын, газаплы юлны бер генә түгел, ике тапкыр үтәргә җитәрлек итеп һава белән тутырды. Карыны ач малай рәвешле моңын саф һава белән туендырды, һәм яңгыр көтеп шартларга җиткән, кояшы каплана башлаган үсемлекләр, өянкеләр астыннан күтәрелгән шәфәкъ җиләсе белән бераз җилләнә, суына төшкән һава офыктан офыккача урталай ярылып чайкалды...

Кара да гыналай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә-ә-әй-әй...

Әй-әй-әй!..

Авазлар эссе һавада, яфракларга ишелеп төшеп, тирбәлүен дәвам итте.

Җыр. Халык җыры!

Сәгъдәт җырлый! Сәгъдәт «Кара урман»ны җырлый!..

Бу җыруның бары тик фаҗигадән соң гына тууы мөмкин иде. Гүя көтелмәгән кыйралыш, коточкыч җиңелүдән соң арбаларга сабыйларын, хатыннарын, карт-коры ата-аналарын, казан-таганнарын, уттан исән чыккан кәрзин-кәрзин китапларын төягән качаклар караңгы төннәрдә, атларын һау-һаулап, урманнарның үрләреннән күтәрелә...

Сәгъдәт җырлый! Сәгъдәт «Кара урман»ны җырлый!..

Алда бернинди ут әсәре күренми. Өмет булып баш очында бары тик Зөһрә йолдыз гына яна. «Үтә-әр-гә-әй». Үтәргә-әй-әй шул. Их, шул әй-әйләр! Шушы «әй-әй» катламнарыннан басылып, үтеп чыга алмый, үзе дә җиргә әйләнгән, җирдән үзе үк тамырыннан шытып чыккан, әй-әй. Бөдрә таллар өянкеләр булып картайган да ауган, картайган да ауган, әй-әй. Тамырларны чит гаскәр, чит баскак, чит кавем-тел таптаган; никадәр нык тапталса, шулкадәр түземлерәк булган ул һәм шушы ук түзем, басынкылык көндәлек тормышта мактаулы каршылыкка, арба тәгәрмәченә тагылган аркылы таякка әйләнгән. Мактаулы, түзем, хурлыклы коллык белән килешеп яшәү сыйфатына әверелгән... Сәгъдәт җырлый! Сәгъдәт «Кара урман»ны җырлый!..

Үзенең бөтен кайгысын, аһ-зарын ул баскынчысына каршы көрәшкә түгел, ә җанны һәм тәнне изә торган кара хез-

мәткә һәм бөек юатучысы булган моңга юнәлткән. Бары тик хезмәттә һәм моңда көндәшсез җиңүче булып калган. Адәм баласы Җир шарын бер очтан икенче очка, бер полюстан икенче полюска тишеп чыгарга мөмкин, ә менә татар моңының тирәнлекләренә төшеп җитүе мөмкин түгел. Чөнки ул чиксез кыйралганнар — тигезсез яуда җиңелеп, хезмәттә һәм моңда беркайчан да җиңелмәгәннәр моңы. Менә ни өчен аның «кара да гыналай урман»ы Уфага барып юлыкканчы, «караңгы төн»е инде Казанга барып ирешкән була...

Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым кушкаен,
Әй-й-й,
Сагынам сине, дускаем.

Җыруы белән тәмам әсәрләнгән Сәгъдәт, ниндидер шапылдау тавышларыннан уянып киткәндәй, күзен ачты. Өянкене уратып алган апалар, абзыйлар кул чабалар икән. Шулай ук яланнан да кайттылар микәнни? Араларында апасы белән әнисе елмая. И-и, нинди матурлар, кояшлылар алар! Борынына гүяки хуш исле печән, җиләк, урман шифалыклары килеп бәрелде. Кәркәле буе өянкесендәге теге кара өтер һаман да утыра, бу юлы «Сары сандугач микән, кара карлыгач микән аны үстергән әнкәсе»н әйттерә иде.

— «Озата барма»ны суз, Сәгъдәт! — диде итәгенә баласы кереп уралган Тәүзиха апа. — Аннан «Сибелә чәчәк»не!..

— Чәчәкләрегез сибелми торсын әле, сибеләселәре сибелгән, — дип каршы төште аңа Җиде Авыз Мостафа абзый. — Син кызлар җырын түгел, ирләр җырын — «Герман көе»н җиффәр, туганкай!..

— Синдә малайлар күп булгач, кызларга сан юк инде... Ха-ха-ха!

— Аллага шөкер, дистәгә икәү генә тулмый, ярдәм итегез, — дип җаваплады тегеләрне Мостафа. — Уллы кеше — гөбернатыр, кызлы кеше — посып ятыр!

— Бер дә посып ятмыйбыз әле! Үзебезгә күрә тырышабыз, — диде игезәк кызларын ике беләгенә алган Сәгыйдә җиңги, лач-лоч сагыз чәйнәп. — «Шөгер»не җырла, Сәгъдәт. Аннан да уздыра алмыйсың, җаныем!..

— Тәк, тәк... — дип нокта куйды бу шаян әрепләшүгә Тәкетдин карт. — Син, күрше, берсен дә тыңлама. Мине генә тыңла. «Кара урман»ыңны дәвам ит. Әтү син аны соңгы вакытта бөтенләй оныткан идең. Ул безгә көтү каршылаганчы җитәчәк...

Заманалар авыр, еллар ябык, —

дип дәвам итте Сәгъдәт.

Әйе, ул аны соңгы тапкыр Тугызынчы май — Җиңү көнендә җырлаган иде. Беркайчан да онытмас: ул сәгатьтә коеп кояшлы яңгыр яуды. Бу якларда аны «сукыр тавык» дип атыйлар. Өянкенең калын, биш илле тирәнлегендәге каерысының буразналары буйлап гөбердәп җылы яңгыр суы ага, ә менә энәсеннән җебенә кадәр чыланган Сәгъдәт җырлый. Әйтерсең карт өянке җылый! Кичә генә канкойгыч сугыштан исән чыгып та, гомере буе, гасырлар буе изелгән, үзләрен эзәрлекләгән рухи һәм матди камалыштан, коллыктан, басынкы фәкыйрьлектән чыга алмаган, бүген исә аннан чыгу чараларын эзләү бурычыннан тәмам ваз кичкән, алданган, үзе яуланып алынган, шуңа күрә яулап алынган «азатлыкның» нинди азатлык, кем өчен азатлык булуын да тиешенчә аңлый, бәяли алмаган, әмма шул «азатлык» хакына кичә генә ирләрен, туганнарын корбан иткән, гамәлдә бүген дә чалдыра килгән җиңгиләр һәм әбиләр, сеңелләр һәм апалар күлмәк җиңнәре, алъяпкыч итәкләре белән яшьләрен сөртә, ә ир-ат күзләрен бер ноктага төбәп катып калган һәм бу гомуми, күмәк сынны көтү кайту гына түгел — тьфу, тьфу! — яңа сугыш чыгу хәбәре белән дә урыныннан кузгатып, өстерәп тә алып китә алмас иде кебек...

— Сания, син нинди бәхетле! — диеште хатыннар. — Балаларың шундый сәләтле, үзләре — чибәр!..

— Үзенең йөзе чытык кына булса да, балалары мираусай аның! — диде Җиде Авыз Мостафа, Сәгъдәткә дә ишетелсен дип кычкырып. — Карама беләккә, кара йөрәккә!..

— Күзләре сөрмәле, буй-сыны сокланып йөрмәле!..

Монысы хак, Саниядән дә шат кеше юк иде бу минутта. Мостафа дөрес әйтә, Ходай Тәгалә аның үзенә сылу гәүдә дә, матур кыяфәт тә бирмәгән. Әмма, аталарына охшап, балалары берсеннән-берсе фасун. Сигез кош очырып, икесен генә саклап кала алды бит. Фәниясе әнә буйга җитеп килә, күз тимәсен, бит алмаларыннан тирә-якка кайнарлык бәреп тора, зур күзләреннән сөрмәләре коелып тора! Сәгъдәтен, асыл алмасын, инде әйтәсе дә юк. Шундый ук зәңгәр күзле, шундый ук сөрмәле, озын кара керфекле. Кыска туры борынлы. Ап-ак тешләре көнбагыш төше кебек актырып тора!

Шәфәкъ инде алсу катык кебек куерып килә иде.

Күпер төбендәге өянкедә «козгын» һаман утыра һәм, колакка шәйләнүенчә, «Баламишкин»ны гыжгыта.

Сәгъдәт җыруының:

Дус-иш кирәк лә... —

дигән өлешен башлаган мәлдә генә, кинәт Лотфулла ихата-

сында ыгы-зыгы купты. Тышкы ишекне шәррән яра җилгәреп, аннан өсте-башы тузган Миңниса җиңги йөгереп чыкты:

— Коткарыгыз! Пыч-чактан үткәз-зә!..

Ул абзар кырыйлатып бәрәңге бакчасына таба йөгерде. Аның артыннан күзләре аларган, изүе ачык эчке күлмәк чабуларын җилфердәтеп, Лотфулла атылып чыкты да абзарга томырылды.

— Үткәзәм, марҗа-а-а! Үткәз-зә-ә-әм!..

Аның кулында әллә шәфәкъ алсуында алланып күренгән озын пычак, әллә сабан карлавы иде.

...дөньялар көтәргә-ә-әй...

— Әй-әй-әй! — Авазлар әрәмәләр арасындагы җиләс һавада сөрлекте. — Әй-әй-әй!..

Һәм шып туктады.

— Бар, Миңсорур, туктат! — дип кычкырды Тәүзиха. — Син — липутат, бу — синең эшең!

— Ирләр, нәрсә карап каттыгыз?! — Депутат Миңсорур түгәрәктә чәбәләнеп йөри иде. — Минем көчем җитәмени аңа?

— Фрунтта мондыйларнымы? Фруннта мондыйларны, их! — диде шулчак франтауай Шәркый абзый. — Нинди матур җырны өзде, швайн!.. Эчкән саен пычак белән шаяра...

Шәркый, үзе артыннан бер төркем үсмерләрне ияртеп, Лотфулла ихатасына ташланды.

— Әнә бәхетле хатыннарның кыйнарга ирләре бар, ичмасам! — диде уены-чыны белән бергә Сәгыйдә җиңги. — Ирем булса, мин җәелеп яткан булыр идем — мә, кыйна, тапта, из, тик ирем генә бул!.. Ә монда — бер кочак бала, кулда — тырма!..

Әле генә гомуми, мәңге бердәм сынны тәшкил иткән, урыннарыннан трактор белән дә тарттырып булмаслык, бер-берсенә уртак язмыш, уртак ут, җир-су, тормыш җимеше белән ябышкан җәмәгать — чатан Тәкетдин, ике аягы да юкәгачтай кипшенгән Миңнетдин, Җиде Авыз Мостафа, итәкләренә бала-чагалары сарылган Сәгыйдә, Тәүзихалар, өркегән сарык өере сыман таш-түмгәкләр аша ыргып, буза купкан җиргә ябырылдылар.

Өянке астында аны-моны аңышмаган, танау асларын сөртергә яннарында әниләре дә булмаган биш-алты сабый гына торып калды.

Тик ике җырчы гына урыннарыннан кузгалмады. «Җырлар вакытны җылап үткәрәбез, — дип уйлады Сәгъдәт. — Әкәмәт халык без». Күпер төбеннән Кара Якупның өзелеккән тавышы чәчрәде:

Бас әле, Өммегөлсем,
Идәннәре бөгелсен...

Сәгъдәт җавапсыз кала алмады.

Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым пар усак.
Ә-ә-әй,
Дус булаек аерылса-а-ак...

Авазлар тугайларга барып адашып кире кайтты, әмма ихатада гауга туктамады. Ике тарафтан агылган ике моң, Лотфулланың ишегалдында кавышып, челпәрәмә килде. Кое баганасыдай озын Лотфулла, хатынын тапмый, абзардан йөгереп чыкты, аннан бакчага каерды, ызаннар арасына бәрәңге чәчкәсе кебек сеңешкән Миңнисаны анда да күрмичә, кире ихатага дулап килеп керде дә юлына тап булган Ырматиз Миңлетдинне селтәп тә очырды.

— Тотып бәйлик үзен! Аркан китерегез!..

Шәркый Лотфуллага каршы ташланды.

Чатан Тәкетдин титаклый-титаклый өенә таба йөгерде.

Җыр ике яктан да туктаган иде.

Җырчылар өянкеләре башыннан Лотфулла күрсәткән киноны онытылып карый иде.

Лотфулла, гәүдәсе ягыннан үзеннән калышмаган, сугышларда утны-суны кичкән Шәркыйдан шүрләгәндәй, янга янтайды һәм аның канат астыннан диярлек сөзелеп чыгып, тупсасына сикерәм дигәндә Мостафага тап булып, аны типте. Әмма Мостафа аның аягыннан эләктереп алды, тегесе абынды, һәм өстенә берничә ир менеп атланды.

— Ме-ен-нә ар-ка-а-ан! — Тәкетдиннең йөгереп хәле беткән иде. — Атны да ауда-рыр-лы-ы-ык!..

Шәркый Лотфулланың беләзеген келәшчәдәй кысты, пычак, хәлсез коштай, җиргә килеп төште. Куллары артка каерылган Лотфулланы абзар катындагы ат бәйли торган баганага таба өстерәделәр.

— Авылда күрелмәгән хәл! — Тәкетдин үзенә урын таба алмый йөренде. — Их, яшь чагым булса... Лотфулла күрше, эчәсең икән, буеңа сеңдер син аны! Болай итеп, аны... урыс та эчми!..

Лотфулла җиде катлы итеп сүгенде.

Ишегалды, аю биеткәндәй, халык белән тулган иде.

— Кеше түгел, дуңгыз син! — диде Шәркый, Лотфулланы баганага бәйләп. — Швайн!..

— Тәк... Тәк... Тәк... Әнә шулай, әнә шулай! — Тәкетдин карт, бәйләүчеләргә куәт биреп, туктаусыз тәкелдәде. — Ну, Лотфулла энекәш, тәүфыйк дигән нәрсә юк инде синдә, ә?

— Сезнең кебек, булмаган тәүфыйкны күбәйтә алмыйм! — дип, төкерекләрен чәчте ул. — Булганы үземнеке. Чатан тәре!..

— Үземнеке түгел, үзебезнеке! Без колхозда изелгәндә, син эшләмичә дә колхоз малын ашап ятасың...

— Колхоз малын ашап азапланмыйм, эчәм мин, эчәм, чатан тәре, ишеттеңме? Мин сезнең ише Труттинсез Нуретдин түгел. Булдыра алсаң, син дә аша, син дә урлаш!

— Лотфулла энекәш, аны урлашырга дигәндә... мин дә булдырам... — Тәкетдин аны тирәләп титаклый иде. — Тик, күрәсең, урлаганымны күтәрергә генә хәлемнән килми... Аяк юк, аяк!..

Халык тагын көлешеп алды.

Күпер төбендәге өянкедән җиз иләкләрдә иләнгән авазлар сыгылды:

Фирдәвескәй, кара күзкәй,
Ай нуры бар йөзеңдә...

— Сәгъдәт җырлый! — диде кемдер.

— Ахмак син! Сәгъдәт шулай җырлыймы? — диде сүгенүеннән туктаган Лотфулла тыныч кына. — Сәгъдәт әле җырламый шул... Ул җырласамы?! Мин... дөньясын актарам! — Ул, арканны өзәрдәй булып, багананы шыгырдатты. — Кладаушик Ярулла малае Якуп ул. Туже җырчы, кәнишне, әмма кая ди ул минем күршемә җитәргә! Сәгъдәтебезне дә шул имгәтте бит инде... Күземә генә күренсен, башын өзәм мин аның!

Халык җанланып куйды.

Күршесенең һаман да тынычлана алмавына борчылган, бер караганда, ямьсез тиргәшкән, икенче караганда, тиле кебек, көлешкән-шаулашкан гавәмне ничек кенә булса да уңай якка үзгәртергә хыялланган, үзенең көчсезлегеннән үзе гаҗиз булып, нишләргә дә белми, өянкесендә бәргәләнгән Сәгъдәт, бер кулы белән Лотфулланың җилкапкасына тотынып, икенче кулын иңендәге тырмасына салган һәм ниндидер бер битараф рәвештә аңа арты белән баскан Сөмбелне күреп алды. Бар тараф буталды. Колаклар җил тавышын ишетердәй булып ачылды. Дөнья ят авазлардан арынды, һәм ул үзенең җырлап җибәргәнен сизми дә калды:

Әй, гүзәлем, камышлы күл,
Шул бит безнең су юлы.
Кара кашым, сандугачым,
Бик сагындым бу юлы...

— «Шөгер»! «Шөгер»! — дип өзгәләнде Лотфулла. Гүя ул ыңгыраша иде. — Җырла, быр-рат!..

Барча халык, Лотфулланы онытып, Сәгъдәткә таба борылды. Әйтерсең ул Карга боткасыннан соң коргаксып яргаланган җир белән бергә зарыгып яңгыр көтә иде.

— Үзәкләремне өзә шушы җыр! — Сәгыйдә җиңги читәнгә сыгылып төште. — Сугышның азагында гына... җиңү борынлаганда гына... тол калдым бит!..

— Үзебезнең Сәгъдәт бит ул!

— Төшеп җырла, Сәгъдәт!

— Сыздыра тек сыздыра...

Кичке таң нурында дөрләгән галәм офыклардан офыкларгача айкалды-чайкалды. Юк, кешеләр, адәм балалары бу бөек могҗиза алдында үзләренең никадәр юк нәрсә, вак, кешелексез мәшәкатьләр, очсыз мәшгулиять белән шөгыльләнергә мәҗбүр булулары өчен үкенмәде дә, оялмады да. Тормыш үз буразнасында дәвам итә иде. Алар әле бу адымга өлгереп җитмәгән, йә булмаса, өлгереп ары узган һәм бары тик моңнан әсир генә иде. Гомерләре буе камышлы күл буйларыннан озатышсалар да, алар гүя сөю-сөелү мизгелләрен беренче тапкыр, инде җыр могҗизасы аша кичерәләр иде. Бу кадәр өзгәләнү, бу кадәр тирәнлек, бу кадәр нечкә зәвык йөрәкнең, тамакның, күкрәкнең нинди төеннәрендә яралуы мөмкин? Нигә бөек моң иясе — сандугач — кешечә сөйләшә-аңлаша белми, ә менә кеше, адәмзат сөйләшә-аңлаша да һәм сандугачлардан арттырып җырлый-сайрый да белә? «Кара кашым, сандугачым», — ди бит ул, Илаһи. Сүзләре генә дә ничек сайрап тора бит! «Җимерек кашым, дуңгыз күзем», — дими, Ходай сакласын. Димәк, яшәүнең мәгънәсе — ярату? Димәк, кеше үзе — сөюдән хасил булган илаһи ярату чыганагы? Яшәсен ярату — мең тапкыр сайрау һәм мәңгелек кодрәт!

Бик сагындым бу юлы...

— Төш, Сәгъдәт! — дип кычкырды күз яшеннән буылган Лотфулла. — Төш, сбулыч, төшеп җырласаң, туктыйм да куям!..

— Хәзер, син исерек янына төште ди!.. Түбәнсенде ди!..

Сәгъдәткә дә төшсә үзен түбәнсетер кебек күренде. Башкаларны күтәрәм дип, түбәнсенергә ярыймы?

Бу газаплы икеләнү аны гомере буе җәфалар, эзәрлекләр, әмма кискен хәлләрдә гел генә мәхәббәте коткарып калыр.

Бу юлы да нәкъ шулай булды.

Ак Сакаллы Бабай аны югарыдан ярлыкап тора иде.

Аның Сөмбелен бик тә, бик тә күрәсе килә иде шул!

Әгәр Сөмбел теге вакыйгаларны ишеткән булса, аның хәлен белергә тиеш иде. Тукта, нишләп әле ул, моңа кадәр Сәгъдәтләргә эз дә басмаган кыз бала, аларга килергә тиеш? Оялмыйчамы? Кеше-фәлән күрүдән дә курыкмыйчамы? «Озата барсам, кеше күрер, хуш, исән бул, гүзәлем», — диелмимени «Шөгер»дә? Озата барасы килә лә ул, тик нишләргә —

кеше күрә бит? Ә нигә Сәгъдәт үзе бармады Сөмбел янына? Оялуданмы? Тыйнаклыктан гынамы? Үшәнлектән, мондый уйның бөтенләй зиһенгә килә алмавыннан түгелме? Шул оялуны, шул тыйнаклыкны бөтен авыл алдында җыеп, Сөмбеленә күрену, Сөмбеленә ишетелү өчен менмәдеме ул өянке башына? Кара Якупны да шул ук тойгы китермәдеме Кәркәле буендагы өянкегә? Шушы урынсыз оялу, тартыну, тыйнак, тавыш-тынсыз булып кыланудан гына тыя алмыйча азапланалар түгелме Лотфулланы? Бергәләп билен бөктерсәләр, телен чукесәләр, болай йөгәнсезләнер идеме зимагур?

Менә хәзер аны йөгәнләү Сәгъдәтнең берүзе өстенә төшә.

— Ул төшә! — дип шаулаштылар ихата эчендә. — Күрәсезме, төшә!

Өстенә изүе ачык киндер күлмәк, тезләре кырык кат ямалган малюскин чалбар, чебиле аякларына нимес балалары аягыннан күчкән, табаннары тапталып беткән иске трофей сандали эләктереп алган Сәгъдәт җай гына урам аша чыкты. Аның җете зәңгәр күзләре зурайганнан-зурая, зиһене яктыра, җаны-калебе тагын да моңсулана барды. Авылдашларының карашлары кояшны озата барган көнбагыш таҗы кебек аңа таба борыла, гәүдәләре исә, үзләре дә сизмичә, Сәгъдәт артыннан Лотфуллага таба әйләнә иде. Җилкапка каршында, аннан да эчкәрәк үтеп туктап калган алтмыштагылар, кем әйтмешли, алтыдагысына юл бирде. Сәгъдәт, үтеп барышлый, Сөмбел күлмәгенең бер борчагыннан иркә генә итеп чеметеп алды. Балалары чорнап алган Лотфулла колачларын җәяргә омтылып талпынды:

— Эр-рәх-мәт, күрше! Менә син кеше дисәң дә кеше ичмасам. Югыйсә монда... йөз грамм күтәрерлек тә ахламун юк! Җырла, быр-рат!

«Җырлыйммы соң?» дигәндәй, ул Сөмбелгә караш ташлады. Тегесе сиздермичә генә башын какты.

— Нәрсәне җырлыйм соң, Лотфулла абзый?

— Сөйләп торасың тагын!

Ул җырлый башларга дип авызын ачты, әмма тавышы чыкмады. Моң тирәнгә качкан, йотылган иде.

Нәрсәдер җитми, нәрсәдер артык иде Сәгъдәткә. Бугаз төере кече телгә диярлек күтәрелеп туктаган да калган. Лотфулланы яңадан күздән кичергәч, аны тир басты.

— Арканын чишмәссезме? — диде Сәгъдәт, бизгәк тоткандай калтыранып. — Әтү тавыш чыкмый...

Ирләр Лотфуллага таба томырылды.

— Юк, чишмәгез... — Лотфулла баганасында бәргәләнә башлады. — Чишмәгез, дим... Һәркемнең үз баганасы бар... Бөеклек һәм хурлык баганасы... Бу минем хурлык баганам, җәмәгать... Үтенәм, чишмәгез!..

— Чишегез... — диде Сәгъдәт пышылдап кына. — Мин бәйле кешеләр өчен җырлый алмыйм.

Ирләр Лотфуллага якынайды.

— Не падха-ди, зар-реж-жу!.. — Лотфулла инде акыра иде. — Не пад-хад-ди!..

Менә чишелгән, әмма сүтелмәгән аркан бәҗралары шапылдап җиргә төште.

Шулай да Лотфулла аны атлап чыкмады. Кадакка кадакланган пәйгамбәр кебек, күзләрен йомып, урынында калды.

— Мин җырчы, тик җырлый гына белмим. Мин шагыйрь, тик яза гына алмыйм. Их!..

— Урлаша беләсең! — диде кое баганасына сөялгән Шәркый.

— Ахмак син. Шәркый абзый, менә нәрсә. Монда сиңа фронт түгел. Без монда — ирекле!.. Командовать итмә...

Ул лач итеп читкә төкерде.

Сәгъдәт Лотфулла өенең нигезенә утырды һәм күзләрен йомды... Шулчак көмеш бугаздан киек казлар кәрваны очып чыкты.

Әй, гүзәлем, кара кашым,
Сайраган сандугачым...

Өязе үзәннәре буйлап Ырымбур далаларыннан җил исте, бар тирә-юнь әремнең әчкелтем хәмер исләре белән тулышты. Гади, төп мәгънәсе «гүзәлем» дигән сүздә тупланган бу моңда авыл тәрәзәләре тупсаларында яран гөл чәчкә атты, караңгы төннәрдә кызларның аулак өйгә кертүләрен үтенеп, егетләр тальяннарын шыгырдатты, туң тәрәзәләрдә ут алынды, басуларда башаклар баш кысты, кайдадыр агымсулардан чайпылдап саллар акты, урманнардан, шахталардан, сугыш кырларыннан авылдашларның мәңгелеккә хушлашу авазлары яңгырады. Бер кечкенә, кеше күзе күрә алмас ноктадан чыккан моң, шәфәкъ алсуында кайралып, үзенең яшәү рәвешен эзли, салам түбәле, киндерле, игенсез тегермәнле, атсыз арбалы авылны шифалы учларында тирбәтә иде...

Татар моңы!

Кадерсез моң!

Авыл сүзсез генә үкси иде.

Озата барсам, кеше күрер,
Хуш, исән бул, җанашым...

Сәгъдәт шул авылның мәңгелек сагы астында җырлый иде.

Малай шулчак халыктан бераз читтәрәк басып торган Кара Якупны — үзенең Түбән очтагы шәүләсен, мәңгелек көнчелек чыганагын һәм бары тик табигать кенә тудыра алган талант күләгәсен күреп алды.

Ул тешләрен шыгырдатып елмайды.

Лотфулла урыныннан кузгалды, аның артыннан дүрт угланы да иярде. Куркытмаска тырышкандай, җай гына Миңнисага таба атлады һәм алдына килеп тезләнде.

— Нишлим соң, Миңниса? Яратам бит мин сине... Яратканга гына шулай кыланам мин... Үбәсем генә килгән иде!

— Һи-и, Миңниса, тиле дә инде үзең! — дип эләктереп алды Лотфулланың соңгы сүзләрен Саҗидә җиңги. — Ирең сораганда... Шулай ярамый инде!

Беркем көлмәде.

— Ничава сибә, ярата! — Шәркый шаркылдап көлеп җибәрде. — Яланнан кайткан хатынын пычак белән ярата! Вах-вах-вах!..

— Аңламыйсың син, Шәркый җизни! — Бу юлы аңа Лотфулла «җизни» дип эндәште. — Фронтны үткәнсең, тик ни өчен үткәнеңне аңламагансың. Мәхәббәт түгел, нәфрәт төяп кайткансың син авылыңа. Ни гаебем бар? Ярату, быр-рат, пычак очында ул!.. Әнә, күрәсеңме? — Ул, Шәркыйның каршына ук килеп, Имәнлек өстендә ялкынланып баеп барган кояшка күрсәтте. — Сине көтеп бата ул! Сине көтеп көйри!.. Син — фронтны үткән кол! Мин... мин... кол түгел! — Ул Сәгъдәт каршына килеп тезләнде. — Рәхмәт, энекәш... син мине, Колыма жиганнарын пычакка элгән зимагурны әсир иттең. Ә мин сине җырчы, бөек җырчы итәчәкмен! — Ул авылдашлары арасында бөтерелә башлады. — Сез аңлыйсызмы кемне үстергәнегезне? Сез, ягъни без, колтамаклар, дөньяга бөек җырчыны тудырганбыз! Без аны Мәскәүдә, Парижда укытачакбыз, шулай бит? Сыерым синеке! Дөньям синеке! Йә сиңа бирәм, йә яндырам, билләһи!..

Авылдашлары аңа ничек дип тә җавап кайтармадылар.

— Гарьлегегез, ихтыяр көчегез юк сезнең. Яшәсен тирес! Яшәсен кара тирес эчендәге көрән корт! Сезнең өчен гарьләнеп алам бит мин кулыма ул пычакны... Ә шулай да мин сездән күпкә бәхетлерәк! Минем биисем килә! — Ул балаларын колачы астыннан этеп чыгарды. — Биегез, балалар!

Рәз, дуа, читири,
Бездә кызлар хитири.
Яулыгын артка бәйләгән,
Башларында бет йөри!..

Лотфулла бөҗра ясап бии, балалары аның тирәсендә тузан туздырып сикеренә иде.

— Тыпырдап биегез, канальялар! Тыпырдап биегез!

Балалар тыпырдап бии башлады.

Их, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Без ашыйбыз каз-үрдәк!..

— Сиңа ни... — диде тыныч кына көлемсерәп Миңниса. — Урнаш пешерергә булса, үрдәк тә дүдәк инде... Тавыкларга чират!..

Халык мөкиббән китеп көлде.

— Көт-тү кайт-та-а-а! — дип сөрән салды кемдер. Бу сугыш башлану тревогасына тиң иде. Сәгъдәт халыкның комга сеңгән су кебек таралганын сизми дә калды. Җилкапка төбендә Сөмбел белән Кара Якуп кына торып калганнар икән. Тырмасын һаман да иңеннән төшермәгән Сөмбел Якупка якын килде һәм күзләрендә чакматаш чаткылары чатнатып тирги башлады:

— Сиңа җырлар өчен мәйдан беткәнмени? Гафу да үтенмисең, ә?

— Мин аңардан ким җырчы түгел! — диде Якуп, сүзләрен теш арасыннан гына сөзеп чыгарып. — Ул безнең Түбән очка килеп җырламасын.

Якуп әлеге Сәгъдәтнең атаклы җырчы булып җитешәчәген, аның Колтамакның Түбән очларында гына түгел, ҖИР ШАРЫНЫҢ барлык Югары һәм Түбән очларында җырлаячагын күз алдына китерә алмый иде.

Якуп китеп барды.

Сөмбел белән Сәгъдәт урамга чыкты.

— Озатма, — диде Сөмбел. — Кеше күрер.

— Күрсә соң... — диде Сәгъдәт, авызын җыя алмыйча елмаеп. — Мин бит ни... Күпергә хәтле генә...

Һәм алар, кичке таңның тузанлы нурында коенып, Кәркәле күперенә таба атладылар.

*Алабуга — Уфа — Чаллы*

# САНЫЙ БАШЛАГАНДА

## САНЫЙ БАШЛАГАНДА

Зирәкнең күзенә йокы кермәде.

Әле беренче сыйныфта укып азаплана башлаган гына булса да, ул инде хәзер унга кадәр саный да белә. Ул аны укытучысыннан башка да белгән булган икән. Көчәнеп караса, ул, бәлки, уннан ары да саный беләдер әле. Әмма вакытыннан алда көчәнәсе, эчкә керәсе килми аның. Әле шул белгәнеңне генә дә хәтердә ныгытасы бар бит.

Шул хәтер хакында гына уйлаган диярсең. Әйе, шул хакта гына уйлаган диярсең, иген тутырылган капчык сыман кыска буйлы, билсез укытучы Кәримә апалары, өстәле артыннан чак-чак күренеп, аларга өйгә эш бирде: ун таякчыктан торган санагыч ясарга. Шул таякчыкларны җеп белән бергә беркетергә. Шул таякчыкларны иртәгә мәктәпкә алып килергә.

Кушылганнарның барысын да эшләде Зирәк. Өязе буена барып, иң сомгыл, иң нәзек, әмма дә ки иң шома, каерысында бер генә җыерчык, яра әсәре дә булмаган талчыбыкларны сайлап алды, аларны бармак озынлыгында итеп кисте, аннан аларның башларыннан, бер илле ара калдырып, киртләп чыкты. Аннан, сугыш янбалиты сыман, бер аягы череп аска таба сөрлеккән өстәлләре тартмасында актарынып, кулга эләккән йомгактан тегәрҗеп сүтеп алып, шушы таякчыкларны бергә беркетте. Матур гына килеп чыкты бу санагыч дигән нәмәстәкәй. Үз эшенә үзе сокланган малай санагычны үзе белән урынга алып яткан иде. Ул шушы ук талчыбыклар сыман сомгыл, нәзек, шома бармаклары белән санагыч таякчыкларын кат-кат сыйпады...

Тик шунысы гына: бигүк тигез килеп чыкмаган икән таякчыклар. Берсе озынрак, берсе кыскарак икән, чурту матыр. Әй, укытучылары моңа игътибар да итмәс әле, бәлки,

дип уйлап алды малай. Әнә туган авыллары Колтамакта да барысы да тигез түгел. Сугыштан яралы аягын сөйрәп кенә түгел, суык та тидереп кайтып, көне-төне йөткергән уң як күршеләре Фәтхулла абзыйсын гына ал. Кое баганасы сыман озын ул. Ә менә сул як күршеләре Мөхтәрәм абзый кул таягы сыман кыска, мин сиңа әйтим. Әллә шул кул таягына охшаган булганга да ярдәмчел микән ул һәркемгә Мөхтәрәм абзыйлары? Кешегә ярдәмгә килергә дигәндә йөгереп кенә тора. Кушаматы да Йөгерек, әй-йеме?

Бу чагыштырудан канәгать булган Зирәкнең санагыч таякчыкларын да кешеләр белән чагыштырасы, аларга исем бирәсе һәм шул ысул белән унга кадәр саннарны беркайчан да онытмаслык итеп хәтеренә сеңдерәсе килде...

Малай колакка сагайды. Өй эче караңгы, анда шылт иткән тавыш та ишетелми иде.

«Монысы инәй, — дип уйлады ул, үзалдына беренче таякчыкны капшап. — Монысы инәй булыр». Малай янә сагайды. Әнисе аның белән янәшәдә, аның белән шул ук бер чүпрәк палас астында тигез генә тын алып йоклый. Арый инде ул. Бик тә арый. Бөртекле игеннәрне урып өлгермәделәр, әниләрен Өязе тугайларындагы киндерне йолкырга куып төшерделәр. Андагы җир нәкъ аның тәне кебек таш тек таш инде. Киндернең төбе белән бергә томрау-томрау кәс умырылып чыга. Киндер йолкырга балачага да йөри. Зирәкнең исә Өязе тугаеннан кайтып кергәне дә юк. Һи-и-и, андагы киндернең бетәрлеге бармы? Аны тартканда, көч килеп, маңгайдан утлы очкыннар чәчри башлый.

«Монысы әтәй», — дип пышылдады ул, үзалдына икенче таякчыкны барлап. Әмма шундук телсез калды: таякчыгы кулында булса да, әткәсе янында юк иде шул аның... Исән булмаган, ягъни үлгән кешегә таякчык билгеләргә ярыймы икән соң? Кеше нигә үлә икән ул, әй? Палас асты суынып киткәндәй булды. Малай, ут табарга теләгәндәй, чакматаштай, аякларының берсен икенчесенә ышкып куйды. Аякларына кадәр суынган иде шул. Ул атасын тавышсыз-тынсыз гына таякчыклар хисабыннан сызды. Сугыштан кайтмады бит. Кешеләр нигә сугыша икән ул, әй? Әби-сәбиләр аңа «ятим» диләр. Нигә ятим? Зирәк үзе һич кенә дә аңламый: нигә ятим? Нәрсә соң ул ятимлек? Әнисе бар, туганнары бар. Кояш бар. Таң ата да кич була. Ә менә атасы юк. Күрәсең, шулай кирәк булгандыр. Димәк, атасы үләргә тиеш булган. Күрәсең, бәрәңге бакчалары башында келәт сыман кечкенә өйдә гомер кичергән күршеләре Мөсаббиха әбисе әйтмешли, тәкъдир китабында шулай язылгандыр...

«Монысы Зөмәрә апа. Матур апа, — дип, иреннәрен кыбырдатты Зирәк, икенче таякчыкка хуҗа сайлап. — Кайчан кайтыр икән ул?» Малай җансыз талчыбык кисәген аерым бер иркәлек белән сыйпаштырды. Гүя чыбыкка җан керде. Ул тере иде. Күзләренә яшь бәреп чыкты хәтта. Бигрәк ярата шул ул Матур апасын. Бертуганнары арасында бердәнбер кыз бит ул. Былтыр унҗидесе генә тулып өлгергән апаларын силсәүит Пирме якларына урман кисәргә җибәрде. «Бармыйм!» — дип зар җылады ул. Аны һәм авылның аның кебек унҗиде кызын Әкчүн станцасына милитсия белән алып киттеләр. Зирәк наган дигән ата торган нәрсәне беренче тапкыр шул милитсия билендә күрде. Бу юлы наган атмады атуын. Сәфәргә шулай җылашып китсәләр дә, матур хатлар яза аның Матур апасы. Яңа җирдә өйрәнеп киләләр икән. Урысчалары такыр булгач, былгадирлар аларга командыларны татарча гына кычкыралар, ди. Яхшы эшләгәне өчен пачутни грамыт биргәннәр. Анысы нәрсәдер инде. Берәр өс киеме кебек нәмәстә микән? Шулайдыр. Хатында язуынча, анда, Пирме урманнарында, акча урынына кием-салым, тукыма, эрзин калушлар бирәләр, ди бит. Урман кисәргә, турыфка киткән кызлар кияүгә чыгар алдыннан шунда киенеп кайталар, ди. Алай гынамы, тукыманы төргәк-төргәк муезларга төяп кайтаралар, имеш. Шулай гына була күрсен иде. Аның Матур апасының да кияүгә чыгасы бар бит...

Әй, сагынды да инде ул Матур апасын! Шул сагынуыннан тәкате калмагач, ул һәр кичтә, көтү кайткач, Өязе тауларына менеп кычкыра торган булды: «К-а-а-айт, Матур апа, ка-а-а-айт!»

«Монысы Зөлкарнәй абкай», — диде ул, өченче таякчыкны капшап. Йоклаганда иң кырыйда һәм чүпрәк паласның читен генә ябынып йоклаучы абкае әле һаман кайтмаган иде. Шулай төн уртасына кадәр аулакта, кызлар янында бөтереләә инде ул. Иртәсен тора алмый җәфалана, әнисе аны Зирәктән колагына самавыр торбасына кычкыртып торгыза. Зирәк бу торбага әллә кайда әллә кайчан ишеткән шигырьне кычкыра:

Тор, тор, тора тор,  
Авыл кызлары матур.  
Нигә матур булмасын,  
Көн дә май ашый бит ул...

— Кит, малай актыгы!.. — ди абкае, аңа ачулангандай итеп. Куллары белән тирә-якны капшый-капшый тора теге, күзләрен уа-уа болдырга юынырга чыга, үзе һаман йоклый, чурту матыр. Нинди йокы буладыр инде бу кадәр. Абкайлары капкалап алган арада, Зирәк калхузның ат абзарыннан Сары Бияне алып кайта. Кичә кич, калхуз камытын

салганнан соң, инде калхузчының үзенә кара төндә Кралов урманнарыннан таштай авыр бүрәнәләр сөйрәп кайтып, ял итеп тә өлгермәгән Сары Бия дә аягүрә йоклый әле. Күзләреннән яшь ага малкайның. Күз алкаларын ак тоз элпәсе, бу элпәне чебен-черки уратып алган. Алар ләззәтләнеп ат күзләрендәге тозлы яшьне чүмерәләр. Инде күзләре тәмам ачылып өлгергән абкайлары, сызгыра-сызгыра, Сары Бияне җигеп ала да ындыр табагына китә. Йокысыннан уянган ат та, абкае да җилкапкадан ап-ару гына чыгалар. Шунда молотилкада иген суктыралар алар. Шуңа күрә зур абкаен Зирәкнең юньле-рәтле күргәне дә юк. Ай бирә, кояш ала дигәндәй.

Аның әле, сез белмисез генә, Йәгъфәр дигән кече абкае да бар. Кинәт тышта каты җил кузгалгандай, бу җил тәрәзә капкачларын шыгырдатып каккандай булды. Палас астындагы җылы тагын да каядыр югалгандай итте.

Зирәк тәне белән җыерылып куйды.

«Монысы Йәгъфәр абкае була». Малай бармагы белән дүртенче таякчык өстеннән капшанып үтте.

Ул Зирәктән дүрт яшькә зур. Каты сүзле, каты куллы аның кече абкае. Зөлкарнәй абкаена һич кенә дә охшамаган ул, әй. Гел генә кулыннан сорый, эше булмаса, тота да Зирәкне кыйный башлый. Бәлки, шулай кирәктер дә инде. Аннан, Йәгъфәр абкае кыйнаганнан гына, Зирәккә бернәрсә дә булмый бит. Таш кебек каты, эрзин кебек сикеренеп тора бит аның тәне. Абкасының шуңа ачуы килә бугай. Елый-елый да туктый ул. Аңа чынлап та бернәрсә дә булмый. Зирәк аңлый: Йәгъфәр абкае бары тик аның яхшы булуын теләп, кайчагында прусты яратып кына кыйный, шулай бит, әй? Малай уң колагын шомрайтты.

Аның сул ягында тыныч кына тын алып әнисе черем итсә, уң ягында исә, мендәренә борыны белән кадалып, Йәгъфәр абкае йоклый. Шуңа күрә авыр тын ала, бар өйгә ишетелерлек итеп мыш-мыш килә ул. «Яхшылап ят», — дип, абкаен уятса? Юк, кирәкми. Йә тагын җене кузгалып, кыйный башлар.

«Монысы Зөфәр абкае була». Зирәк бармакларын бишенче таякчык өстеннән шудырды. Малайның яткан урынында авызы ерылды. Зөфәр абкае гадәттәгечә тавыш-тынсыз гына яши. Аның йокысы да үзе кебек гаҗәп тыныч. Гүя ул биредә бөтенләй юк. Нишләп булмасын ди, бар ул, бар, Зирәк һавадагы тынлыктан аның тын алышын тоя, сизә, хәтта ишетә, тик анык дип атап кына әйтә алмый. Шундый инде аның Зөфәр абкае: үзе күренми, әмма ул анда бар. Йәгъфәрдән ике яшькә генә өлкәнрәк. Ул гел генә укый. Укый да укый. Кушаматы Прафисыр. Анысы нәрсә буладыр инде тагын. Берәр төрле зур кеше буладыр инде ул прафисыр дигәннәре. Ни өчен дигәндә, Йәгъфәр абкае Зө-

фәр абкаеннан шүрли. Шүрли генә диме, курка. Курка гынамы, астына шыр җибәрә. Тегесенең Зирәккә атланып алып кыйный башлавы гына була, Зөфәр әллә каян килеп тә чыга, төпчек энекәшен томшык очыннан йолып та ала. Йәгъфәр абкаеның кушаматы да Тилгән шул. Тилгәннәр дә тавык чебешләрен, каз бәбкәләрен чыркылдатып алып китәләр бит... Ачуы канмаган Йәгъфәр үз үчен алмый калмый: Зирәккә йодрык катысы белән үтеп барышлый булса да төртеп ала...

Бертуганнары шуның белән вәссәлам иде. Малай авызын каплап иснәде. Әмма йокысы килми иде. Әле тагын да биш таякчыгы бар. Алтынчы таякчыкка хуҗа эзләп, авылны әйләнеп чыкты. Ул зиһене белән, яңадан ихаталарына кайтып кереп, мал абзарына үтте. «Сыер... сыер... — дип кабатлады ул. — Сыер бит аларга актан-ак сөт, мал агы бирә. Бәлки, алтынчы таякчык аңа билгеләнергә тиештер?»

Зирәк күзләрен чытырдатып йомды. Аһ, онытып тора икән: быел яз, Өязедә ташу киткәндә, аларның сыерлары Майка бозаулый алмады бит. Тагын шунысы кызык: ул сыер малына ни өчен марҗа исемнәре кушалар икән? Майка, Манька, Танька, Зайка?..

Әй, үсә төшкәч барысын да белер әле.

Сыерны суеп өлгерделәр өлгерүен. Итен түләнмәгән салым исәбенә тапшырдылар. Ул итләр әллә кемнәрнең ашказаннарыннан үтеп юкка чыккандыр инде хәзер. Абзарда тагын да бер сарык, ике кәҗә малы, алты тавык, бер әтәч бар барлыкка... Юк, юк!.. Санагыч таякчыкларын сарыкка, тавыкка ваклый диме?!

Көтмәгәндә малайның зиһене яктырып куйды.

«Алтынчы таякчык мин үзем булырга тиешле».

Алтынчы таякчыкка ул үзен тәгаенләде.

Үзе өчен үзендә бернинди дә кызык тапмагач, ул үзендә тукталып та тормады.

Җиденче... Җиденче... Бертуганнардан кала. Җиденче таяк бердәнбер һәм бик тә изге кеше өлешенә чыгарга тиеш иде.

Зирәк авылдагы чыбык очларына кадәр булган барлык якын һәм ерак кардәшләрен барлап чыкты. Әмма ул алар арасында җиденче таякка тиң булырлык изге кешене тапмады. Гүяки аның өчен авылдагы туганнары арасында туганнары юк иде.

«Таптым!» Зирәк чак-чак кына кычкырып җибәрмәде.

Җиденче таяк булырга тиешле иң изге кеше аның өчен кул яссуы кадәр генә ак, түм-түгәрәк сакаллы, мөлаемнардан мөлаем йөзле Нәбиулла бабасы иде...

Язгы кояш нурлары астында яшәрә башлаган тауларда чемченеп йөрсеннәр дип иртән көтүгә куылган сыер малы кичен, елга аша кире авылга кайтырга чыкканда гына, еры-

лып киткән ташуга агып китмәсенме! Яр буен мал бакырышы һәм кеше акырышы басты. Кышны чагыштырмача хәлле чыккан маллар кайсы ничек яр катысына аяк басып маташканда, ике сыер, шул исәптән Зирәкләрнеке, бар тирәгә җан ачысы белән бакырып, ажгырып аккан бозлар ташкынында бүленеп калды...

Үрдәге күпер түбәненнән ташуның икенче дулкыны якынлаша иде.

Ярга җыелган кешеләр «аһ» итте. Зирәкнең акылын җуйган әнисе тегендә чапты, монда чапты, әмма беркем дә ярдан ярдәм көткән малларга ярдәмгә ашыкмады. Кирәк чакта яннарында бер генә абкае да юк иде, ичмасам!.. Сыерларын коткарырга диеп бозлы ташуга кереп барган малайны ниндидер «каты кул» ярга алып селтәде:

— Йөрмә аяк астында буталып!..

Шулчак — ни күрсеннәр! — Нәбиулла бабалары батакалка, йөзә-атлый ташуга кереп китте һәм озак та үтми, малкайларның арт саннары өстендә кулындагы камчысыннан очкыннар чәчрәтә-чәчрәтә, һау-һаулап куып, бу якка таба алып килә башлады. Шулчак йорт урыны кадәр җәйпәк боз Нәбиулла бабасын каплагандай булды. Халык икенче тапкыр «аһ» итте. Бер мизгелгә ул югалып торды. Менә маллар, тезләрен каната-каната боз өстендә шуып һәм ат сыман пошкырынып, ярга күтәрелә башладылар. Алар артыннан бер кулында камчы уйнатып, икенче кулы белән Майканың койрыгына ябышкан Нәбиулла да су астыннан калкып чыкты...

Нәбиулла бабасының батырлыгына таң калган иде шул чакта Зирәк.

— Ыстәлинга язарга кирәк! — диде кемдер. — Нәбигә орден тиеш!..

Хәтерли ул: әнисе йөгереп килеп Нәбиулла бабасына рәхмәт әйтергә дә өлгермәде. Гүя Хозыр Ильяс булып юкка чыкты ул.

Юкка чыга диме? Нәкъ шул Хозыр Ильяс кебек күренеп күренмичә авылда яши ул. Кирәк чакта, нәкъ шул ташудагы сымак, өскә калка да чыга. Әнисенең нинди дә булса дөнья мәшәкате, йомышы яралса, йөгерә дә шул Нәбиулла бабасына бара. Ә ул, кырык эше кырылып ятса да, килеп җитә. Менә былтыр көзге кара яңгырда аларның череп беткән тәрәзә рамнарын кем яңалар белән алыштырды? Кем ватыгыннан җил өргән, кайбер ватыкларына иске чүпрәк тыгылган бу тәрәзәләргә зәңгәр күзле яңа пыялалар куйды? Нәбиулла бабалары! Куллары алтын бит аның. Бу пыялалардан гүя барлык урамга зәңгәр нурлар тарала торган булып китте.

Чынлап та Нәбиулла бабасына орден тиеш. Язарга гына өйрәнсен: Зирәк, Нәбиулла бабасына орден сорап, Ысталин бабасына барыбер хат язачак. Ул орденны Ворошилов, Буденныйлар үзләре Колтамакның үзенә барыбер китереп тапшырачаклар, Алла боерса!..

Туганлык ул кан ягыннан гына туган булуда гына түгел икән. Туганлык ул изге күңелле, ярдәмчел булуда икән...

Палас астында әнисе белән абкайларының тыныч тын алышта йоклауларын тыңлап яткан Зирәккә моңсу булып китте. Аның шул минутта Нәбиулла бабасын күрәсе һәм бар дөнья алдында бертуганы дип хәбәр итәсе килде. Житмәсә, санагычның тагын да өч таякчыгы хужаларын көтә иде әле...

Менә таң гына атсын, иртәгә иртән, беренче эше итеп, ул Нәбиулла бабасына йөгереп барачак һәм аны бертуган картатасы итеп игълан итәчәк.

Анысы, ярар, хәл дә иткелде ди. Ә менә сигезенче таякчык кем? Кемнеке?

Кояш! Кояш! Кояшныкы ул!

Малайның чүпрәк палас астыннан чыгасы һәм Җир шары буйлап йөгерәсе килде. Күңеленнән ул Өязе таулары артыннан йөгерә башлады. Өязе таулары артыннан йөгерү аның өчен чынлап та Җир шары буйлап йөгерү иде.

Тугызынчы таякчык кемнеке?

Монысы җиңел хәл ителде: Айныкы ул, Айныкы!

Сабыйның садә зиһенендә шул Ай кунаклаган ниндидер биек багана хасил булды.

Унынчысы кемгә тәгаен? Кемнеке, ягъни мәсәлән?

Унга кадәр саный белгән һәм хәтта ары таба санарга өйрәнү өчен санагыч та ясаган малай төн уртасында һәм абкайлары белән әнисе уртасында, яткан җирендә керфек тә какмый, унынчы таякчыкка иясен эзли иде. Ләззәтләнеп, илһамланып эзли иде ул аны...

Кинәт аның зиһене яктырып куйды.

Күз алдына үз сыйныфларында аңардан бер генә партага алда утыручы кыз килеп басты. Үзе кебек, аның исеме дә бик матур: Сәгыйдә. Юк, Сәгыйдә матур гына да түгел, мөлаем ул, мөлаем. Мәктәпләрендәге бер генә кыз да чәчләрен аның кебек майлап тарамый, бер генә кыз да аның кебек өчтән үрелгән толымының очына алсу күбәләк бәйләмәгән. Бу канатлы күбәләк аны әллә кайларга очыртып алып китәр кебек. Кечкенә аякларына ак бәйләм оек өстеннән кигән эрзин калушлары да майланган сыман ялтырап тора. Зирәкнең кайчакта ул калушларны учына алып сыйпап карыйсы килә. Сәгыйдә... Мөлаем кыз Сәгыйдә...

Унынчы таякчыкны ул сыйныфташ кыз Сәгыйдәгә бирде.

Малай кәефе килеп елмайды. Бу елмаюда бәхет һәм якты өмет үзе яктырган иде. Күп тә үтми аның йөзендә бу елмаю гүзәл бер сын рәвешендә сынланып катып калды.

Талчыбыктан ясалган санагыч, кулларыннан шуып, күкрәгенә төште. Баш миенең искиткеч зур көч салып эшләгәненнән соң арып һәм талчыгып, ул тирән йокыга талды.

Сентябрь уртасының караңгы төнендә сәгатьнең ничә икәнен аларның берсе дә белми иде. Зирәкләр генәме? Күпләр, бик күпләр белми иде гамәлдәге вакытны.

Ни өчен дигәндә, йөз йорт-ихатадан торган Колтамак авылында сәгать бары тик Нәбиулла бабайда гына иде.

*24.02.2002*

## БЕРЕНЧЕ УКУЧЫ

*Марсель Галиев*

Янган-Тау курорты китапханәсенең уку залында, иртәдән бирле шытыр-шытыр китереп почмак кимергән тычканны исәпләмәгәндә, галәми тынлык хөкем сөрә иде. Дегеттән чыккан сыман күкерт-кара йөзле, бүрәнәдән юан муенлы, җәйге челләдә дә эшләпәсен муенына кадәр батырып кигән карт, китап киштәсендә озак казынганнан соң, ниһаять, бармак ыргаклары белән «Здоровье» журналының берничә санын суырып чыгарып, култык астына кыстырды да, бик тә канәгать, тәкәллефле кыяфәт белән:

— Булды бу! Таптым мин аларны! — дип, ишеккә таба юнәлде.

— Туктап торыгыз, бабай, — диде китапханәче кыз, өстәле тартмасыннан өр-яңа формуляр чыгарып. — Фамилиягез ничек?

— Ә минем фамилиям сиңа нигә кирәк? — Карт, чыгып барган җиреннән кисәк кенә туктап, китапханәче катына килде. Аның болай да кызгылт ярылы, хәзер инде тәмам кан баскан күзләре кызга текәлгән иде. — Мин бит монда дәваланам, һәм, мин сиңа әйтим, беренче тапкыр!..

— Бәй, — диде кызкай, үзенең гадәти бер укучы белән эш итүенә бер дә икеләнмичә. — Әдәбиятны без кеше кулына теркәмичә бирә алмыйбыз...

— Һы. Кызык икән. Фамилиям ни... Фамилиям Габидуллин инде ул...

— Исемегез?

— Фамилиясе булгач, исеме нигә инде аның тагын? Бик кыздырсаң, журналларыңны алмый да куярмын әле! Миңа аннан бал һәм кычытканның файдасы турында язмалар гына кирәк... Югыйсә чурту мәтри!.. — Ул кулындагы журналларын ыргытып бәргәндәй хәрәкәт ясады.

— Менә әкәмәт кеше булып чыктыгыз әле сез, — диде кыз, көяләнә төшеп. — Исемегез ничек, дим...

— Исем ни... Исемем Галимҗан инде ул...

— Әтиегезнең исеме? Туган елыгыз? Милләтегез? Белемегез?

— Тукта әле, кызым! — диде карт, тәмам шик-шөбһәгә батып. — Фамилиямне, исемемне әйттерден, инде хәзер әти мәрхүмнең... Милләтемнең... — Аның тавышы калтыранды. — Аларның монда ни катнашы бар? Монда хөкем залы түгелдер лә?

— Кызмагыз, бабакай, кабатлап әйтәм, бездә шундый тәртип. Мин бит сезнең кулыгызга бәһасез байлык — китап кадәр китап тапшырам. Әтиегезнең исеме?

— Әтинең... Әтинең исеме ни... Сабирҗан иде... Соловки лагерьларында... — Картның күзләренә яшь тыгылды. — Сөякләре череп, көл булгандыр инде мәрхүмкәйнең...

Бүлмәдә уңайсыз тынлык урнашты. Бары тик тычканның гына тырышып-тырмашып сайгак башын кимергән тавышы ишетелә.

— Кайсы корпуста яшисез соң? — Формаль гамәл кушканча, чокчынырга мәҗбүр кызкай, инде үзенең дә дымланган күзләрен чылт-чылт йомып, формаль формулярны тутыруын дәвам итте. — Кайсы корпуста яшисез?

— Әйтмим! И вчу тут! Үз гомеремдә бер мәртәбә ялга килеп, ниндидер гыйпыу белешмәләрен тутыртырга минем башыма тай типмәгән әле! Әти мәрхүмнең сөякләре... — Ул, кесәсеннән ашъяулык кадәр кулъяулык чыгарып, тирен сөртте. — Әйтмим дигәч әйтмим!

Алар, басма өстендә бер-берсенә юл бирмәгән ике кәҗә тәкәсе сыман мөгезләрен текәшеп, тынып калдылар. Бүлмәне сузынкы моңсулык биләп алды.

— Алайса, яшәгән адресыгызны әйтегез...

— Һы. Нәрсә, мине урлар-нитәр дип уйлыйсыңмы? Шикләнәсеңме? Ышанмыйсыңмы?

— Әйтәм бит, бездә тәртип шундый, дип! — диде кыз, елар чиккә җитеп. — Кем белә, бәлки, югалтырсыз? Китермәссез? Кем белгән, бәлки, үлеп китәрсез? Ул чакта алар өчен мин кесәмнән чыгарып түлимме?

— Мин?! Минме китермим? Минме үлеп китәм? Юк, үлмим мин! Гомеремне озайту өчен алам да бит инде мин бу язмаларны! — Ул, хәле бетеп, якындагы урындыкка утырды.— Син кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме соң? Мин үз гомеремдә кешенең энәсенә дә кагылмадым, сеңелкәем... Ишекләрем дә биксез минем... Шуңа күрә халык таккан кушаматым да Биксез Галимҗан минем, аңлыйсыңмы? Алай бик кирәк икән, яз — моннан җиде чакрымда яткан ут күршегез Малаяз авылыннан мин!..

— Урамыгыз?

— Урамы юк. Малаяз. И вчу тут!..

— Татар Малаязыннанмыни?

— Шуннан дип йөз мәртәбә әйттем түгелме соң?

— Хәзер менә монда имзагызны салыгыз.

— Әүвәлендә укып чык. Нәрсәләр сырладың икән...

Кыз теркәгәнен тәфсилләп укып чыкты. Карт исә, бик тә җентекләп, хәрефен хәрефкә үреп, кул куйды. Чыгып китәргә дигәндә генә тукталып, урынында таптанды һәм сорап куйды:

— Ә менә синең фамилияң ничек була?

— Әхмәдиева.

— Исемең? Әтиеңнең исеме?

— Минем исемем сезгә нигә кирәк инде? — диде кыз, көлемсерәп һәм күзләрендә яшьлек дәртен чатнатып. — Сайрангөл булам...

— Кирәк шул, Сайрангөлем! — диде карт шаяртып. — Нишләп әле минеке генә кирәк, ә синеке кирәкми ди? Бәлки, мин синең белән никахка барырга җыенамдыр? — Ул җәелеп китеп көлде. Аңа ияреп, Сайрангөл дә елмайды. — Бәлки, син дә югалырсың, егылып үләрсең, ә?

— Авызыгыздан җил алсын, бабай!

— Менә шулай шул! — Картның дегеттән чыккан сыман күкерт-кара йөзе ничектер яктырган, шәлберәйгән бит алмалары кан белан тулышып алсуланган иде. — Син нәсел-нәсәбемне тикшермәгән булсаң, мин китапларны иртәгә үк китергән булыр идем... Болай булгач, китермим дә куям! — Ул тагын кеткелдәп көлде. — Юк, юк, курыкма. Биксез Галимҗан лабаса мин! Ярлы булсам да, буем гарьле, кызым! Байлык — бер айлык, фәкыйрьлек — гомерлек! Әти карт әйтмешли, фәкыйрьлектән дә зур байлык юк. Кадерен белеп тотсаң, мәңгелеккә җитә...

Аның күзләре дә язгы офык кебек яктырган иде.

Ул янә кеткелдәп көлде һәм ишеккә таба юнәлде.

*Янган-Тау, Башкортстан*
*1995*

# БУЛАЧАК ӘРТИС

*Тәтер-Арыслан авылыннан яшьлек дустым*

*Фәрит Арыслановка*

Бу вакыйга егерменче гасырның азагында булды.

Җитмеш йортында йөз дә уналты пенсионер яшәгән Саклау авылының тугыз баладан торган сигез сыйныфлы мәктәбендә Беренче май бәйрәменә кызу әзерлек башланды. Сигез сыйныфлы мәктәпнең унсигез укытучысы, әзерлек барышына яшь карчыга күзе белән кадалып, аны көне-төне киеренке контрольдә тотты. Беренче сыйныф укытучысы Кәримә сыйныфның иң яхшы һәм бердәнбер укучысы Шакирҗанга «Май» дигән шигырьне ятларга бирде. Сигез юллы, әллә нинди зур шагыйрьләр түгел, теләсә авылның татарча җөмлә төзи ала торган һәр әүхәтгалие язган, шуның белән бала зиһененә тиз сеңгән бу искиткеч нәфис әсәрне Шакирҗан эт куак төбен сугарганчы ятлады да куйды:

Менә тагын шат яз килде,
Кулда чәчәк бәйләме.
Яшәсен, яшәсен
Беренче май бәйрәме!..

Бетте Шакирҗанга тыныч көннәр. Картәнисе белән картәтисе, әтисе белән әнисе, туган-тумачасы, күрше-күләннәре, бөтендөнья прлетарларының бердәмлеге көнен бәйрәм итүне ун көнгә алдан башлаган авыл җәмәгатьчелеге табын артында дисезме, урамда дисезме, иртән торгач, кич йокыга ятар алдыннан дисезме — малайдан бу шигырьне ятлаттылар да ятлаттылар. Кадерле мирасны шулкадәр яхшы үзләштергән Шакирҗанның бу кадәр кабатлаудан ике күзе йөз унсигезгә, бер авызы ун авызга әйләнгән иде. Мондый җәзага ул шулкадәр өйрәнеп китте ки, шигырьне ятлатырга теләүчеләрнең авыз ачуын да көттермичә, алар урам башында күренү белән сиптерде дә сиптерде:

Менә тагын шат яз килде,
Кулда чәчәк бәйләме...

Менә Беренче май җитте. Көн салкынча, кояшсыз булса да, җәмәгатьчелек күк йөзендә кояш юклыгын абайламады — аны партия җылыта иде.

Көндезге ундүрт сәгатьтә халык кечкенә мәдәният йортына бәйрәм концерты карарга җыелды. Аны алып бару беренче сыйныф укытучысы Кәримәгә йөкләнгән иде. Үзенең иң сөекле һәм бердәнбер укучысы Шакирҗанга сүзне ул аерым бер горурлык, хәтта, әйтер идем, гасабилык белән бирде:

— Хәзер беренче сыйныфның иң яхшы укучысы Шакирҗан Газизов сезгә «Май» дигән шигырьне укып ишеттерәчәк!..

Менә сәхнәгә өр-яңа кием кигән, помидорга охшап тулышкан һәм кызарып алсуланган Шакирҗан чыкты һәм залда утыручыларның колак пәрдәләрен шартлап ярылырлык итеп аваз салды:

— «Май»!..

Халык шым калды. Кинәт Шакирҗан залда үзеннән бу шигырьне укыта-укыта җәфалаган, алай гына дисезме, үт куыгын сыткан әтисенең һәм әнисенең, картәтисенең һәм картәнисенең аңа текәлеп чекрәйгән күзләрен күрде.

— «Май»...

Малай, аякларында таптанып, тиргә төште. Ул шигырьне оныткан һәм, ничек кенә көчәнсә дә, исенә төшерә алмыйча җәфалана иде...

— «Май»...

Хәл чыннан да мөшкел иде. Әмма зал көтте. Киеренкелек тирәнәйгәннән-тирәнәйде, анда чебен очкан тавыш ишетелә иде. Батып барган трактор кебек, дүртенче тапкыр көчәнеп тә, саздан чыга алмагач:

— «Ма-а-а-ай»!.. — дип акырып җылап, сәхнә артына чыгып китте.

Зал көләргә дә, җыларга да белмәде. Куркыныч тынлык иде бу.

— Ачыккан безнең Шакирҗан, — диде кемдер.

Зал хәзер рәхәтләнеп көлде. Бер җиңгинең ыштан эрзинкәсе шартлап өзелде.

— Менә күреп торыгыз, — диде тамашага кызмача килгән тракторчы Гапсаттар. — Ул милләтебезнең иң яхшы әртисе булачак! Яңа Айрат Арслан чыгачак аңардан!

Зал котырып кул чапты.

*Янган-Тау, Башкортстан*
*24.08.95*

## НУЛЬ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

*Балачак дустым Кыям Мифтахов истәлегенә*

Тәнзиләнең шатлыгы эченә сыймый иде.

Математика буенча өйгә бирелгән эшенә укытучы апалары бишле билгесе куйган. Ул гына дисезме: дәфтәре битенә кызыл кара белән «Молодец!» дип язып та куйган, җитмәсә. Моңа кара Кама түбәнлегендә яткан зур шәһәрдә өч сыйныф урысча укып, хәзер исә Мамадышта яңадан өченче сыйныф-

ка — инде татар телендә укып йөргән Тәнзилә һич кенә дә аңлап җиткерми: ул «молодец» дигән сүзнең татарчасы юк микәнни? Бардыр инде ул, нишләп булмасын. Бу хакта ул дәү әнисеннән дә, дәү әтисеннән дә сорады. Бар, диләр. Нишләп булмасын, диләр. Әйтик, «булдыргансың!», «яхшы»,«бик яхшы», «зур үс!» һәм башкалар, һәм башкалар. Әй, анда гынамыни мәсьәлә! Мәсьәлә бит аның татар мәктәбендә беренче бишлесен алуында! Моның серләрен дәү әнисе белән дәү әтисе һәм, әлбәттә инде, Тәнзилә үзе генә белә...

Әйе, Кама түбәнлегендә урнашкан шәһәрнең теге зу-у-ур коридорларында балалар котырудан тузан болытлары йөзгән мәктәбендә ул гына бишлегә укый иде дә бит. Хәлләр көтмәгәндә генә үзгәреп киткәч, берни дә эшләп булмый икән шул. Нәкъ дәү әтисе җырлаган җырдагыча: «башкайларга төшкән язмышларны сыпырып ташлап булмый кул белән...» Аңа туган мәктәбендә «өмет», ягъни «надежда» дигән ләкап тә тагып өлгергәннәр иде югыйсә. Әйе-әйе, әнисе сөйләвенчә, мәктәп директоры Фаина Лазаревна ата-аналар җыелышында, имеш, математика буенча мәсьәләләрне компьютер тизлегендә чишүче, ул әйтмешли, «математик форматта» фикерләүче Тәнзиләне «Мәктәпнең өмете»дип атаган, имеш... Бәлки, әнисе аны үсендерү өчен үзе генә уйлап чыгаргандыр моны, алар, өлкәннәр, кызык халык бит...

«Бисмилләһир-рахманир-рахим». Кинәт кенә аның теленә шушы сүзләр килде. Менә шундый шатлыклы һәм авыр вакытларында әллә каян килә дә чыга алар, мондый сәер, мондый тиз ятлана торган сүзләр. Тәнзилә аңлап та җиткерми — нидән шулай бу? Аның күзләренә яшь тамчысы сирпелде.

Аяк астында, җырлар җырлап, кар шыгырдады.

Бу кар яшь, садә, якты, башланып килгән кышның беренче, ноябрь кары иде. Тәнзилә туктады да, нәзек алсу бармаклары белән сыпырып, учына бер учлам кар алды. Кар эри, аның көмеш тамчылары бармак араларын суытып саркый иде. Бу тойгыдан аның күзләренә икенче тапкыр яшь бәрде.

Кар бөртеге дә кеше кебек тере икән. Туа, яши һәм үлә. Бишле алган Тәнзилә әле менә бүген беренче мәртәбә шунысын да аңлады.

Ул Карл Маркс урамы буйлап үзләре яшәгән Лев Толстой урамына таба төшә башлады. Аркасындагы әсбаплар букчасын, дәү әтисе әйтүенчә, французлардан кергән сүзләр белән «рюкзак», «ранец» дип тә атыйлар икән. Әмма дәү әтисе аны «бишле капчыгы» дип йөртә. Нигә «букча»? Нигә «капчык» түгел? «Капчык» диюләре Тәнзиләгә ошый төшә. Анда, «кап»та, ниндидер сер бар кебек. Кап плюс чык. Каплап чык. Җитмәсә, капчыкның тышына йолдыз сурәте дә төшерелгән. Нигә төшергәннәр икән ул йолдызны? Бүген

аңа йолдызлы капчыгы көндәгегә караганда авыррак тоела. Нигә җиңел булырга тиеш соң әле ул?! Ул бит анда берьюлы ике бишле һәм ике «молодец»ны алып кайтып килә.

Бу фикер аңа ифрат та ошады. Кызчык, кәефе килеп, елмаеп куйды.

Көн якты, күңелдәге уйлар якты иде.

Чиксезлекнең үзен кочып карарга теләгәндәй, кыз күз карашларын аста җәелеп яткан Нократ аша ерак офыкларга төбәде. Әле кичә генә зәңгәрләнеп агып яткан елга, һавалар кинәт кенә суытып җибәргәнлектән, ашыга-ашыга көмешләнә, агымы талгынлана, авыраеп куера, шулай куера барып туңа да иде ул булса кирәк. Бүген исә Нократ өстендә кӧтелмәгән балкыш. Куе кара болытлар артындагы көзге кояш беренче кышкы суыкларга буйсынырга теләмәгәндәй, болыт катламнары арасыннан ачык аралыклар табып, шулай капшана-капшана, табигатьне җылытырга тели, күрәсең. Җиргә урыны-урыны белән генә үтә алган кояш нурларыннан һавада энҗе утраулар хасил булган. Болай итеп җемелдәшкән утрауларны Тәнзиләнең теге Кама түбәнлегендә урнашкан шәһәрдә һич кенә дә күргәне юк иде, билләһи.

Нинди матурлык! Нинди чисталык! Нинди энҗе яктылык!..

Кызкай тирән итеп сулыш алды. Аңа моңсу булып китте. Әйе, ул шат һәм соңгы ике елда беренче тапкыр үзеннән үзе канәгать иде. Беренче бишлесе аңа каяндыр еpактан, теге дөньядан килгән сәер, сихри бер ымлык, ул үзе генә белгән ишарә иде. Математика кадәр математикадан бишле ала башлагач, ул аларны нигә башка фәннәрдән дә ала башламаска тиеш?! Урыс теленнән ул болай да начар түгел. Татар теленә килсәк... Әлегә бераз кыенлыклар бар барлыкка, әмма, дәү әнисе әйтүенчә, Ходай Тәгаләнең кодрәте киң — булыр, татар теленнән дә бишлеләре булыр, башкаларны куып җитәр, Алла боерса. Дәү әтисе дә, элеккеге укытучы, ярдәм итәргә әзер. Әзер генәме? Йөгереп тора! Бар куркытканы шул физкультура кала инде...

Аның кечкенә йөрәккәе «елк» итеп тыпырчынып алды, күз аллары караңгылангандай итте... Кызкайның йөзеннән бер мизгелгә генә кара шәүләләр чагылып үтте.

Тәнзилә бу хакта уйламаска тырышты.

Аның үзенең мәңгегә шат каласы, ә җир йөзен исә мәңге якты калдырасы, шушы энҗе дулкыннарда мәңге тирбәләсе килә иде...

Укытучы апалары бик мөлаем бит аларның. Тырышмас җирдән дә тырышып укыйсың. Ипле генә сөйләп, сөйкемле генә сыйпап укыта һәм эшләтә белә ул аларны. Еш кына көтелмәгән сораулар да биргәләп куя ул. Мәсәлән, менә бүген соңгы дәрестә: «Балалар, иллене иллегә тапкырлагач, күп-

ме була?» — дип сорамасынмы! Күпләр аны җиңел генә хәл иттем дип уйлады.

— Ике мең дә биш йөз, апа, ике мең дә биш йөз, әлбәттә!

— Дөрес, — диде апалары. — Ә менә ике мең биш йөзне нульгә тапкырлагач, күпме була?

Укучыларның мондый гамәл өстендә баш ватып караганнары да булмаган икән. Барча сыйныф колакларын шомрайтты. Күзләр бер ноктага текәлеп оеды. Баш миләренең киеренке эшләвеннән булса кирәк, класс бүлмәсе җылынып китте. Анда җылыткыч торбаларыннан бүлк-бүлк итеп аккан су тавышы гына ишетелә иде.

— Нуль була... — диде Тәнзилә, үзеннән ары китмичә өзлеккән аһәң белән. — Нуль була, апа...

Бу «нуль» дигән сүз пышылдап кына әйтелсә дә, ул гүяки бар дөньяга ишетелеп яңгырады.

— Нишләп нуль булсын? — дип шаулашты балалар. — Һы, нуль!

— Ха-ха-ха!.. Ике мең биш йөз юкка чыга димени?

— Син үзең нуль!.. — Кемнәрдер кеткелдәп тә алды. — Хи-хи-хи...

— Молодец, Тәнзилә!.. — диде апалары. — Нуль. Бары тик нульгә тапкырланган хәлдә теләсә нинди зур сан да нульгә әверелә...

Менә шушы бер кечкенә буш түгәрәк, буш боҗра, ягъни шушы гади нуль канатлар үстерде аңа бүген. Калын-калын болыт катламнары арасыннан Нократ өстенә ишелеп төшкән энҗе нурлар да шушы эче буш нуль боҗрасыннан чыгып бииләр бит инде. Югыйсә Тәнзилә моннан ике ел элек үлгән иде бит инде...

Аның елыйсылары килеп китте.

Еламаска тырышып, ул иренен тешләде.

Әйе, нәкъ шулай — үлгән иде ул. 1998 елның 30 декабрендә әнисе белән Яңа ел бәйрәмен дәү әтисе белән дәү әниләрендә каршылау өчен Мамадышка кайтып барганда, нәкъ әнә шул «Морты борылышы» янында коточкыч юл һәлакәтенә эләктеләр алар. Ниндидер очлы нәрсә белән бәрелешеп, шул очлы нәрсәнең күз алларында очкын шарлары яктыртып, башына ук кереп киткәнен хәтерләгәндәй итә Тәнзилә. Бәлки, хәтерләмидер дә. Әнисе сөйләгәннән генә күзаллыйдыр...

Юк, ул бернәрсә дә хәтерләми. Башкасын хәтерләми. Хәтерсезлек упкынына очканын гына хәтерли...

Соңыннан, һаман да шул әнисенең сөйләве буенча, Мамадыш шифаханәсендә, аңына килә алмыйча, егерме көн яткан ул. Аннан аны махсус вертолет белән — «Вертолет... вертолет... — дип уйланды кызкай. — Бу сүзнең татарчасы ничек икән?» — Казанга озатканнар. Бары тик кырыгынчы

көнендә генә күзен ачкан ул. Юк, монысы дөрес түгел, күзен ачмаган — аңына гына килгән дисәң, дөресрәк булыр. Чөнки күзне ачу өчен бик күп көч кирәк. Ике айга якын бары тик шул имезлектән генә саркыган тавык шулпасын йотар-йотмас, тәнендә җаны да булыр-булмас хәлдә гомер кичергән сабый балага күз кабакларын күтәрерлек көч каян килсен ди?! Дөресен әйткәндә, үзенең ничек аңга килүен дә хәтерләми ул. Анысы да шул әнисе авызыннан.

— Бармагымны кыс... Аңыңда булсаң... Мине ишетсәң... Мине яратсаң... Сабыем... Күз нурым... Бәгърем!.. Бармагымны кыс!.. Кулың белән минем бармагымны кыс!..— Әнисе онытылып китеп, җан ачуы белән барлык шифаханәгә шәрран ярып, кычкырып җибәрә! — Кыс инде!.. Ишетәсеңме син!.. Үлдең мәллә, Раббым?!

Һәм әнисе үзен тотып торган табиблар кулына ава.

Уколлар кадап үз хәленә кайтарылган әнисе бу шөгыльне тагын да, тагын да кабатлаган. Кат-кат. Моны табиблар махсус шулай кыландырганнар. Шулай кирәк булган.

Әйе, хәтерли Тәнзилә: кинәт кенә зиһене ачылгандай була — һәм аның кардай салкын бармаклары эчендә яңа савылган сөт сыман ниндидер җылымса нәрсә бар, имеш. Күз алдында ниндидер буш түгәрәк, буш боҗра сурәтләнә, имеш. Аннан бу боҗрада ниндидер шәүлә хасил була, имеш... Анда, ниһаять, әнисенең чырае яктыра, имеш. Ә менә Тәнзиләнең кулында чыннан да әнисенең бармагы, имеш.

Болар барысы да төштә кебек кенә.

Аңына килгәнлеге үзенә дә ачыклана төшкәч, бик тә кысарга тырышты ул әнисенең бармагын. Әнисе аңа еракта чылтырап аккан чишмә тавышларын хәтерләтеп эндәшә:

— Рәхмәт, сабыем... Рәхмәт, балакаем... Без исән! Без яшибез!..

Аңа җавап итеп ул җир йөзендәге бу иң кадерле бармакны хәле җиткәнче тагын да, тагын да кысарга тырыша Тәнзилә.

— Ул исән!.. — дип кычкырып җибәрә әнисе һәм башкалар ишетмәсен дигәндәй, шундук куллары белән авызын каплый. Аннан пышылдап кына кызчыгына эндәшә. — Ярабби, Ходай... Ярабби, Ходай...

Бик тә авыр фаҗигагә тарыган булганнар икән алар. Өч автомобиль бәрелешкән. Ике кеше шунда ук җан биргән. Ә менә алар исән калган! Могҗиза, Ходай Тәгаләдән килгән кодрәт түгелме? Ярый әле, тән җәрәхәтләре алып булса да, әнисе исән калган. Ул исән калмаган булса, Тәнзиләне болай өф-өф итеп кем караган булыр иде?

Ә менә Тәнзилә үзе...

Авыр истәлекләрдән котылырга теләгәндәй, ул, баруыннан туктап, кинәт кенә бер сәер сикереш ясап куйды. Әйе,

ул бит хәзер йөри генә ала түгел, сикерә дә ала. Физкультурадан да бишлеләр яулаячак ул, Алла боерса!..

Онытылырлыкмы бу көннәр? Нигә сикермәсен, сикерә ул. Шатлыгыннан сикерә. Күпме кайгылар кичерде аның әнисе, дәү әнисе белән дәү әтисе һәм барча туганнары бу фаҗига аркасында? Күпме көч, күпме түзем, күпме акча түкте алар аның тазалыгын кире кайтару өчен? Кемнәр генә, нинди кешеләр генә катнашмады аны үлем авызыннан йолып калу өчен көрәштә? Барлык Мамадыш!.. Барлык Татарстан!.. Барча халыклар — татарлар, урыслар, чуашлар, яһүдләр... Аңлатып бирерлекме, сөйләп бетерерлекме?

Бары тик әтисе генә күренмәде аның янында. Алар әнисе белән аерылышканнар. Әйтүләренчә, ул эчәргә яраткан. Хәтта әнисен дә эчәргә өйрәтергә маташкан. Аның әнисен эчерерсең, бар! Шуннан инде аерылышканнар. Ул, Тәнзилә, янына килмәгәне өчен әтисен гаепләми. Ул, бәлки, белми дә калгандыр. Шулай булгандыр да. Белгән булса, килми калмас иде, шулай бит? Үскәч, әтисен эзләп табар һәм бу хакта сорашыр әле...

Аның маңгай агыннан өстәрәк тәңгәлдә баш сөяге җимерелгән булган. Сигез сантиметрга сигез сантиметр. Алтмыш дүрт квадрат сантиметр була инде ул. Шул урынны табиблар алтын сыгылма белән ямадылар. Хәзер, аякка баскач, Тәнзилә үзалдына гына үзеннән үзе көлгәләп тә куйган була — әйе, ул гел бишлегә генә укырга тиеш. Бурычлы. Чөнки аның башы алтыннан. Әйе, ул нуль эченнән килеп чыккан Алтынбаш.

Ул пырхылдап көлеп җибәрә...

Операциядән соң, аңына килеп күзләрен ачкач, иң тәүдә әнисен, аннан дәү әнисен күреп елмайды ул. Тегеләрнең күзләренә пылт итеп яшь чыкты.Тәнзилә башта аңламыйчарак торды — берәр төрле хәвеф-хәтәр юктыр бит?

Шифаханәдә әнисе белән — ике, дәү әнисе белән ике ай ятты ул. Шунда дәү әнисе аны бисмиллага да өйрәтте. Теге буш бөҗрадан аны бары тик Алла бабайның гына исән-сау алып чыгуын сөйләде. Шуңа күрә, җир йөзендә нәрсә эшләсәң дә, эшеңне бисмилла әйтеп башларга өйрән, диде. Шулай булса, юлың да уңар, үзең дә булган булырсың, диде. Моңа кадәр бу хакта бернәрсә дә белмәгән Тәнзилә моңа үзе дә ышанды. Чынлап та шулай икән ләбаса! Ходай Тәгалә аны чынлап та аякка бастырды. Ул аны ике елдан соң булса да, мәктәпкә, туган татар мәктәбенә — яңадан шул ук өченче сыйныфка алып килде. Башта карышкан кебегрәк булган иде, хәзер инде куанып бетәлми. Әнисенең аны үзе яныннан — Кама түбәнлегендәге шәһәрдән җибәрәсе килмәде. Дәү әнисе белән дәү әтисе әнисен аны үзләре янында калдырырга димләделәр. Ни өчен дигәндә, әнисе бит химкомбинатта бик зур эштә эшли. Ә монда, Мамадышта, карар, укытыр,

ашатыр кешеләре бар. Шулай бит? Аны, туган телен саклар өчен, татар мәктәбенә бирергә булдылар. Чынлап та бик әйбәт булды әле ул татар мәктәбе. Тыныч. Рәхәт. Тәртип. Беркем башка менми. Тузан куптармый. Укытучылар белән укучылар бер-берсе өчен өзелеп торалар. Теге Кама түбәнлегендәге мәктәп түгел инде. Биредә андагы тәртипсезлек тә, сүгеш-сүгенеш тә, затсыз кычкырыш та юк.

Бүген Тәнзиләгә бар дөнья яңа күренде. Урамнар да, йортлар да. Хәтта энҗе нурларда җемелдәгән офыклар да. Хәер, Тәнзилә үзе дә яңа бит. Өстендә яп-яңа күлмәк. Яп-яңа тун. Аркасында яп-яңа китап капчыгы. Ул үзе өчен яп-яңа мәктәптә туган телендә укый. Әй, онытып тора тагын, аның бит җисеме генә түгел, исеме дә яңа!

Ул тугач та, әнисе белән әтисе Владимир, аңа бигүк уйлап җиткермичә, ниндидер җиде ят һәм кыланчык Элеонора исемен кушкан булганнар. Бу фаҗигагә тарыганнан соң дәү әнисе, мулла бабайны чакыртып, аңа яңа исем куштырган. Исем туе үткәргәннәр. Халкыбызның йоласы шундый икән. Яңа исем кушканнан соң, адәм баласы тизрәк аякка баса, аны бәла-каза да читләтеп уза, ди.

Тәнзилә диләр аңа хәзер. Кызкай үзе дә сизмичә аваз салды:

— Тә-ә-ән-зи-ил-лә-ә-әү!..

Ишетәсезме, кышкы һавада кыллар кебек зеңләп тора!

Ярата ул үзенең яңа исемен. Ул беркайчан да иске шыксыз исеменә кире кайтмаячак. Җисеме кушмый. Теге үзе исән чыккан бозра, нуль бозрасы да кушмый.

Кызчык тагын да бер тапкыр Нократ өстендә тирбәлгән энҗедәй офыкларга карады.

Алар хәзер аккош каурые шикелле бераз гына алсулана төшкәннәр.

Аяк астында яшь кар шыгырдады. Һава саф, сулыш иркен иде.

Кинәт кояш күктәге болыт тауларын нәкъ Тәнзиләнең алтын башы турысында тишеп чыгып, аның үзен дә алсу нурларга төрде.

Арттан караганда ул янып барган йолдызташ-кометага охшаган иде.

Алда, ике урам кисешкән чатта, аларның нуль эченнән чыккан кебек яшел капкалары күренде.

Тәнзилә елмаеп җибәрде.

Аңа бүген шушы яшел капка да шатланачак.

Ул бу капка аша беренче тапкыр математика буенча алган бишлесе белән үтәчәк.

*Чаллы*
*Ноябрь, 2000*

# УЯНЫП АҢЛАШУ

*Гәрәй Рәхимгә*

Рәсәй мөселманнарының Уфадагы үзәк Диния нәзариятенең кабул итү бүлмәсенә башына бик тә мескин куян бүрек, өстенә әллә озын бишмәт, әллә тышлы тун, аягына әллә җылы читекне хәтерләткән итек, әллә итеккә охшаган җылы читек кигән, килеш-килбәте, изелгәнлеге әллә кайлардан «Мин Рәсәйнең фәлән татар авылыннан исән калган мөселманмын!» дип кычкырып торган адәмзат килеп керде. Алтмышлардан үтсә дә, әле җитмешкә җиткәнче җитмеш тапкыр утырып уйланачак бу шактый мыкты, таза гәүдәле мөслим гадәттән тыш дәрәҗәдә дулкынланган иде.

— Нишләргә инде, Мөхәммәт хәзрәт?! — диде ул, юньләрәтле сәламләшергә дә онытып. — Менә бит, ә? Мәчет төзи башлыйбыз дип торганда гына... Мәхәлләбез акчасын итек кунычына тыгып, расхут кенәгәсен кулына тоттырып, нәзарияткә, ягъни сезгә җибәргән идек. Әмма чарасыздан кире кайтты — юлда биш-алты фуляган өстемә ташланып, талап алдылар, ди... Нишләргә дә белмибез, Мөхәммәт хәзрәт...

— Сүбхәнәкел лаһүммә!.. Милициягә-фәләнгә явитсә булдыгызмы соң? — диде нәзариятнең җаваплы сәркатибе Мөхәммәт хәзрәт, иң гавами җөмләне дә, гадәтенчә, һәрдаим, җае килгән саен дини җәүһәрләр белән сипләп. Бу кыйланудан түгел, кырыс мәҗбүрияттән чыгып эшләнгәнлектән, лөгатендәге мондый чуарлык аңа бик тә килешә иде. Тумыштан тирән акыллы булган, гаиләсендә һәм мәктәптә мәдәни тәрбия алган бу әфәнде табиби фәннәр кандидаты булуына карамастан, ислах, ягъни яңарыш җилләре исә башлагач, ата-бабалары рухы алдында тирән җаваплылык һәм динне аякка бастыруны беренче чираттагы бурычы итеп тоеп, нәзарият оештырган мәдрәсәне уңышлы тәмамлап, мөфти хәзрәтләре чакыруы буенча шушында ук эшкә калган яшь хәзрәт иде.

— Милициягә? — диде абзый, инде кулына күчкән куян бүреген туктаусыз изгәләп. — Бармый диме? Бардык. Әмма әлегә бернинди хәбәр-хәтер юк...

— Ягез, бер дога... — Мөхәммәт хәзрәт, аңына килеп, кулларын кушырды. — Аллаһүмә салли гәлә Мүхәммәдин үә гәлә әли Мухаммәд. Кәмә салләйтә гәлә...

Догасын тәмамлау белән хәзрәт абзыйга урын күрсәтсә дә, ул малайларча басып торуын дәвам итте.

— Мәчет төзи башлыйбыз дип торганда гына... Гөнаһ шомлыгына!..

Бу хәзрәтнең ачуын кабартты, күрәсең.

— Башлыйбыз дип торганда гына, имеш! — Ул, көтелмә-

гән усаллык белән карашыннан ут чәчрәтеп, абзыйның сүзләрен кабатлады. — Ишкәнсез инде ишәк чумарын!.. Моңа бит беркем дә ышанмаячак. Көпә-көндез талап киттеләр дигәгә кем ышансын, ә, Закирҗан мөхтәсиб? — «Мөхтәсиб» исемен ишетү белән әле генә микроскоп белән карасаң да күренмәслек булып идәнгә сеңгән абзый баһадир рәвешенә кереп үсте. Мөхәммәт хәзрәт, бераз йомшарып, әлбәттә, укымышлы мулласы, мөхтәсибе булмау аркасында гына мөхтәсиб бурычларын үз өстенә алган гади авыл мужигын болай олылауның нечкәлекләрен белә иде. — Талап алуларын ничек расларга соң, Закирҗан мөхтәсиб?

Һәм сәркатип бер мизгелгә тынып калды. Нәзарияттә эшләү чорында мондый хәл белән беренче тапкыр очрашканга күрә, ул уйлый иде. Аннан, болай итеп талануга башындагы бер генә компьютеры да, Гиббс-Гельмгольц тигезләмәсе генә түгел, Эйнштейнның чагыштырмалылык кануннары да анык җавап бирә алмагач, ул, аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума дигәндәй, башына килгән иң мескин, иң бетеренгән сорауны бирергә тиеш тапты:

— Сездә соң... җыелган вакыф акчасына исәп-хисап барамы?

— Бара, хәзрәт. Без, башка кеше таба алмагач, хисапчы итеп шул Әхкәметдин картны тәгаенләп торган идек. Югыйсә башкаларга бөтенләй ышаныч юк — мошенник өстендә мошенник...

— Монысы ышанычыгызны аклаган булып чыга, шулаймы?

— Акламады шул, акламады...

— Расход-приход кәгазьләрегез сакланганмы соң? — «С» авазына аеруча басым ясап, хәзрәт теш арасыннан гына ысылдады. Бу ысылдау җикеренүдән дә яманрак иде.

— Юк шул, — диде Закирҗан мөхтәсиб. Аның теле тотлыкты, тез башлары калтыранып куйды. — Ырасхут кәгазьләрен комыклар, прихут кәгазьләрен тычкан ашады, хәзрәт...

— ?! — Мөхәммәт хәзрәтнең авызы сулга чалшайды. Тын юлына бөке утырган кыяфәт белән ул катып калды. Бераздан, зиһенен җыеп, көч-хәл белән генә телгә килде. — Әллаһүммә иннә нәстәгинүкә үә нәстәгирүкә! Шуннан, шуннан, мөхтәсиб?

— Шуннан шул инде... — Мөхтәсиб хәзрәтнең колак төбенә иелеп, нәрсәдер пышылдый гына башлаган иде, хәзрәт аны шундук читкә этәрде:

— Туктагыз әле, кем, Закирҗан абый! Пышын-пышын сөйләшергә, без бит монда Тәлгать Таҗетдин хәзрәтләренә каршы фетнә күтәрергә җыенмыйбыз! Кычкырып сөйләгез, әлхасыйль, монда башка адәм заты юк лабаса!

— Мәчет төзи башлыйбыз дип торганда гына!.. — дип,

гадәттән тыш кычкырып сөйли башлады мөхтәсиб. — Мәчет төзи...

Мөхәммәт хәзрәт кашларын җыерды:

— Ипләбрәк. Колакка катмаганмын...

— Шуннан... Шуннан шул инде... Үзенә күрә мөхтәсибәт кантуры сыман нәмәстәкәй дә, җомга намазларын үткәрү өчен гыйбадәт йорты кебек куышыбыз да булыр диеп, колхозның ат алачыгындагы җимерек өен кулайлаштырган идек. — Ул тавышын берничә децибелга киметсә дә, тасвиры, артык дулкынланудан булса кирәк, тагын да сырлырак, тагын да мәзәгрәк чыга иде. — Шул нәмәстәкәйдә, ягъни мәсәлән, мәчеттә, хисапчыбыз, авылның ялгызак карты...

— Төшерәме? — диде Мөхәммәт хәзрәт, түземе бетеп.

— Төшерә генәме? Кайчагында эчкәли дә...

— Сволочь. Тәмәке дә тартамы?

— Тарта гына дисезме...

— Сволочь.

— Нәкъ әнә шул тәмәке аркасында инде, хәзрәт! — Мәсьәләнең чишелешенә килеп җиткән мөхтәсибнең күзләре бермә-бер ачылып, зураеп китте. — Әхкәметдинебез, эш артында талчыгып-нитеп китсәң, баш астына салырмын дип, каз мамыгыннан ясалган колак мендәрен китергән иде... Расхут белән прихутны аерыр өчен, исерекбаш, расхут кәгазьләрен бөкләп, мамык мендәргә тыккан, мин сезгә әйтим! Ә менә прихут кәгазьләрен сигәрит капчыгына салып, яшереп куйган булган. Беркөнне иртән килсә, ни күзе белән күрсен — гыйбадәт өе каз мамыгы белән тулган! Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк, хәзрәт, комыклар, дөнья туздырып, колак мендәрен, тычканнар капчыгы-ние белән тәмәкесен ашаган! Могҗиза!..

Пырхылдап көлеп җибәрүдән чак тыелып, хәзрәт авызын кулы белән каплады:

— Тәббәт йәдәә әбии ләһәбиүвәтәббе!* Ул адәм актыгы «Бәкара» сүрәсен беләме соң?

— Нинди «Бәкара» сүрәсе ди ул, хәзрәт... Аны мин дә белмим. «Ясин» сүрәсен ятлап маташтым маташуын, әмма хәтер дигәнең хәзер — төпсез чиләк...

— Мәхәлләгез белән җыелыш үткәреп, югалту турында бирәр документ кебек нәрсә кораштырыгыз инде, — диде хәзрәт. — Болай бит бөтенләй кеше көлкесе. Акча алдырдым, таладылар дигәнгә генә ышанырлык заманмы?

— Безнең акчабыз исән-сау ла ул... — диде мөхтәсиб, берни дә булмагандай. — Акчасы бит итек кунычында калган. Акчасы бит исән аның...

— Туктагыз, нәрсәсен алдырган соң ул алай булгач?! —

---

* Ике кулы корысын (*гарәп.*).

Мөхәммәт хәзрәтнең күзләре тагын да маңгаена сикерде. Ул үзенең кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. — Ходай хакы өчен аңлат, абзый!

— Расхут-прихутлары язылган амбар кенәгәсен кулыннан алдырган ул, хәзрәт!

Җаваплы сәркатип бу юлы, тәкатеннән ычкынып, шаркылдап көлеп җибәрде.

— Нигә көләсез?! — дип аптырады гүя амбар кенәгәсе белән бергә көлү сәләтен дә югалткан Закирҗан мөхтәсиб. — Нигә көләсез?

— Базар мөнәсәбәтләренә үрмәләп кергән заманда... комыклар каз мамыгы ашый, сычканнар тәмәке тарталар икән, дип көләм, абзый! — Хәзрәт әйләнмәле урындыгында бер тапкыр әйләнеп чыкты. — Мөселман мәгыйшәтендә генә түгел, кяфер мәгыйшәтендә дә күрелмәгән вәсвәсә бу!

Әмма мөхтәсибнең үз алтысы — алты иде:

— Без мәчетне барыбер төзиячәкбез, хәзрәт! Барлык комыкларга үч итеп! — Ул бу сүзләрне шундый ышаныч белән әйтте ки, гүя ул Ходай Тәгалә тарафыннан җиргә шуның өчен генә җибәрелгән сәхәбә иде. — Балаларыбыз безнең кебек надан калмас, Алла боерса! «Бәкара» сүрәсен дә яттан белер, Алла боерса!

— Амин!

Алар озак итеп дога кылды. Хәзрәт «Бәкара» сүрәсеннән «Аятел көрси»не, мөхтәсиб исә үзе белгән «Ясин» сүрәсенең башлам өлешен укыды.

Аларның икесенең дә күңелләре бер иде.

*Янган-Тау, Башкортстан*
*20.08.95*

## ГАБДЕЛГАФУР ХӘЗРӘТ ШАТЛЫГЫ

Иртәнге сәгатьләр иде.

Чәй эчкәннән соң, гадәтемчә, тәрәзә янына килеп, тышка күз ташладым: тормышның хәрәкәтләнгәне хәрәкәтләнә, хәрәкәтләнмәгәне урынында тора икән. Кинәт минем килбәтсез, ифрат та шөкәтсез, «П» хәрефе кебек почмаклатып салынган зур шәһәр йортының биектәге катыннан төшкән карашыма, аста, җир өстендә калкавыч кебек талпынган яшел җиләнле бер адәмзат сыны чалынды. Тукта, тукта, көзге салкын яңгырдан соң кара көзгедәй ялтырап яткан асфальттан болан баласыдай тасырдап, безнең Габделгафур хәзрәтебез килеп ята түгелме?

Мин үзем дә сизмәстән тәрәзәгә капландым.

Әйе, шул, нәкъ үзе!

Әнә безнең яшь, әле оешып кына килгән «Сөембикә» атлы мәхәлләбезнең шулай ук үзе кебек яшь имамының җептәй нәзек кара мыегы һаваны кисеп, телеп үк килә, мин сезләргә әйтим. Чибәр, үз бурычын бик тә теләп, җаны-тәне белән бирелеп башкара торган кеше ул безнең Габделгафур хәзрәтебез. Чит-ят тарафларда, иленнән-теленнән аеры үссә дә, газизә әбкәсе ярдәмендә телен, ата-бабаның гореф-гадәтен, динен онытмаган, сабый чактан ук намазга баскан, ятимлеге аркасында заманында югары белем алалмыйча калган бу яшь дин әһеле бөек бер сусау берлә дөньяви гыйлемгә сусап яшәгән инсан иде. Шуңа күрә ул быел Чаллы педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керде. Андыйларның, беләсез, дуслары белән бергә дошманнары да булмыйча булмый. Әмма бүген аның атлавында ниндидер бихисап дәрт, күзгә бәрелеп торган чәм, ирлек кодрәте һәм фани дөньяның бөек бер мәшәкате чагыла иде. Йөзенә җыеп алалмаслык дәрәҗәдә елмаю җәелгән, чалмалы бүрке бер якка янтаеп төшкән. Җилән җиңнәренең тырпаеп чыккан куллары канатлар сыман ике тарафка яткан. Ул хәтта ки атламый — оча иде. Оча гынамы? Ук булып атылып бара-бара да, дәрт-дәрманына урын таба алмагандай, туктап кала, аннан, тирә-ягына «Сез мине күрәсездер инде» дигән сыман киная ыргытып, яңадан атлавын дәвам итә...

Бу кадәр дә ашкыну, бу кадәр дә талпыну өчен хәзрәтебез тормышында ниндидер зур вакыйга булырга тиеш иде.

Кинәт, миемне яктыртып, моннан бер атна чамасы элек булган бер кечкенә вакыйга хәтеремә төште. Тукта, син нәрсә? Кечкенә була диме? Кеше кадәр кеше тууы бит бу. Вакыйга бу һәм вакыйганың да ниндие әле! Мин айнып китәм. Үткән җомга намазыннан соң ул миңа: «Җәмәгатемнең соңгы сәгатьләре җитеп килә, бала табу йортына илтеп кайту өчен машина кирәк иде», — дигәч, мин аңа зур разыйлык белән машинамны биреп торган идем.

Тукта, бәлки, минем тагын да берәр ярдәмем кирәктер? Бәлки, ана һәм бала белән бер-бер хәл булгандыр? Аннан, белешергә дә кирәк бит инде, бала мотлак тугандыр!..

Мин җилтәрәзәмне ачам һәм кычкырам:

— Әссәламегаләйкем, Габделгафур хәзрәт!

Ул туктады, тавышның кайсы тарафтан килгәнлеген чамалау өчен тирә-ягына каранды, мин тагын да юнәлеш авазы бирдем, һәм ул, ниһаять, карашы белән биеклекне сөзеп, мине абайлап алды:

— Ә-ә-ә, сез икәнсез! Вәгаләйкемәссәлам! Сез бу йортта яшисезмени? Белми идем!..

— Әйе! — дим мин. — Әйдәгез, чәй эчәргә!

— Юк, рәхмәт! — ди бу. — Мин бик зур мәшәкать белән йөрим бит әле!..

— Нинди мәшәкать? Мөмкин булса, мәшәкатегезнең уртасында булыймчы!

— И-и, мөмкин, нигә мөмкин булмасын!.. Әле сез ишетмәдегез дәмени?!

— Юк, — мин әйтәм, — каян ишетим ди? Әле йокыдан торып, чәй генә эчеп маташам...

— Һы, — диде хәзрәт, үзе әйтәчәк яңалыкны әле һаман да белмичә яшәүләренә аптыраган, хәтта ки бераз үпкәләгән кыяфәттә. — Шундый вакыйга, шундый вакыйга, мин сезгә әйтим!

— Нинди вакыйга, әйтегез инде!

Хәзрәт, башкалар ишетмәсен дигәндәй, як-ягына карангалап алды.

— Минем улым туды бит! Малай бар бит, малай!.. Хәзер шуны алып кайтырга машина кирәк иде, шуны эзләп китеп баруым!

— Котлыйм, хәзрәт, чын күңелдән котлыйм! — дидем мин, чын күңелдән шатланып. — Милләтебез һәм динебез хакына асыл бер көрәшче булсын!.. Амин!..

Мин тәрәзә аша, хәзрәт исә баскан урынында дога кылып, амин тоттык.

— Нәрсә, минем машинаны аласызмы соң? — дип сорыйм мин. — Кара «Волга» барамы?

— И-и-и, кара «Волга»... Нишләп бармасын инде!.. Көлеп әйтмәсәгез, тәүбә-тәүбә... Хәер, без хатынны шул кара «Волга» белән илтеп куйганыек бит инде... — ди ул, хәтеренә төшереп. — Шуннан соң ике сәгать тә үтмәде Ходай Тәгалә миңа малай бирде... Хәерле булды ул сезнең кара «Волга»гыз... Шул ук «Волга»да көмәндә чагында алып барган малайны хәзер инде дөньяга чыккан чагында алып та кайтырга кирәктер бит инде, иншалла!.. Шул ук «Волга»-да!.. Кхе-кхе-кхе...

Хәзрәт кәефе килеп кеткелди.

Мин аңа каршыбызда кечкенә манарасы күренеп торган мәхәлләбез мәчетенә кайтып бер ун минут көтеп утыруын үтенәм һәм атланган тәрәзәмнән төшәм.

Карыйм, күрәм: хәзрәт мәчеткә таба җил канатларында оча гына.

Мин телефоннан үземне йөртүче егеткә шылтырата башлыйм.

*Чаллы*
*30 октябрь, 1999 ел*

# ГАДӘТТӘН ТЫШ ВАКЫЙГА*

*Артист Рәшит Сабировка*

Социалистик ярыш ялкынында янып, үзләре теләгән микъдарда имгәнеп һәм ватылып, тиз генә арада сәламәтлекләрен аякка бастырырга теләп, Янган-Тау курортына килгән мөселман кардәшләребез!

Ышанычлы чыганаклар хәбәр итүенчә, җир астыннан ургылып чыккан кайнар парлар белән дәвалау мунчасы иртәгә гадәттәге режимда эшләячәк. «Туктагыз әле, — диярсез сез. — Мунча нигә әле гадәттәгечә эшләмәскә тиеш? Анда бер-бер хәл булды мәллә?»

Булды шул, булды, мөселман кардәшләребез. Аһ, сезнең Янган-Тау курортында булганыгыз юк? Сез җир астыннан килгән кайнар пар белән дәвалау мунчасының нәрсә икәнен дә белмисез? Ул чакта кечкенә генә аңлатма биреп китик. Мунча дигәчтен дә, ул, әйткәнебезчә, су салып чыжлаган пар чыгара торган мунча түгел. Анда кеше сыярлык кечкенә бүлемтекләргә, ягъни кабиналарга кереп утырасың да кораб мачтасы кебек шагыр-шогыр килә башлаган буыннарыңны, умыртка сөякләреңне кыздырасың. Бүген нәкъ әнә шул бүлемтекләрнең берсендә... Аһ, йөрәгем калтырый, тез башларым дерелди... Ходай Тәгалә, мөддәт бир!.. Әйе, җәмәгать, бүген нәкъ унҗиде сәгать ноль-ноль минутта анда, беренчедән, җир йөзендә күрелмәгән гадәттән тыш вакыйга, ягъни Башкортстанның гына түгел, бөтен Рәсәй Сәламәтлек саклау министрлыгын хафаларга төшерерлек кыйралыш булган булса, икенчедән, анда көрәш, авырлык күтәрү буенча дөнья пәһлеваннары — Карәхмәтләр, Жаботинскийларның да борынына чиртерлек рекорд куелды. Аһ, үз күзләребез белән күргән кеше буларак, бик тә борчылабыз һәм дулкынланабыз, мөселман кардәшләребез, бу кадәр битабигый вакыйганы сурәтләү өчен тел ачкычларыбыз җитәр микән? Йә Ходай Тәгалә, йөрәгебезгә дәрт, күкрәгебезгә көч бир, тән шәрифләребезгә канат куй! Ярый, илаһи ният кыйлдым ирмәккә, сезләргә сөйләп бирмәккә...

Мунчаның дәваланучыларны кабул итү бүлмәсе хезмәткәре гадәттәгечә кычкырып игълан итте:

— Ирләр — сул якка! Уналтынчы кабина — Хафизов, унҗиденче — Хәлимов, унсигезенче — Сәмигуллин!..

Сул як бүлмәгә үтеп, күз ачып йомганчы чишендек һәм, муеннарыбызга урау өчен тастымал алырга дип, капчыкларга кулны гына тыккан идек — ләхәүлә вәлә куәтә! — мунча эчендә нәрсәдер кубарылды, аһылдап гөрселдәде һәм чаж-чож ки-

*Беренче тапкыр Янган-Тау курортында дәваланучылар белән очрашуда укылды. (*Автор.*)

леп чышылдады. Ул гына да түгел, иләмсез авазлар чыгарып, кемнәрнеңдер ярдәм сорап кычкырган тавышлары ишетелде. Без, анадан тума калган алты чираттагы мунча керүче, нәрсә булды икән дип, мунча эченә атылдык. Атылдык та килеп тә кердек, килеп тә кердек һәм менә нәрсә күрдек: буе ике метр, авырлыгы соңгы вакытларда 138 килограммга җиткән пәһлеван, Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты, җөмһүриятләребез алдындагы зур хезмәтләре өчен зарплатасыз калган, шушы шартларда да сәхнәбездә көчәнмичә җырлаган җырчыбыз Фән Вәлиәхмәтов, үзе кызынып утырган, аңардан соң мин керергә тиеш булган унҗиденче кабинадан чыга алмыйча, янәшәдәге уналтынчы һәм унсигезенче кабиналарда сөякләрен кыздырган һәм авырлыклары белән, арттырып әйтсәк, 50–60 килограммнан артмаган ике совет пенсионерын да кабиналары-ниләре, аларга тагылган коммуникацияләре-ниләре, ниндидер торбалар, задвижкалары-ниләре, муеннарына уралган төсле тастымалллары-ниләре белән бергә күтәреп, идән уртасында йөреп ята. Киптерелгән әчтерхан балыгын, ягъни сыра эчкәндә ифрат та кәттә булган вобланы хәтерләткән ике социалистик ярыш алдынгысы — пенсионер абзый, кабинадан асылынган килеш, келәшчә саплары сыман нәзегәеп калган аяк чәлтерләрен үрсәләндереп ялвара:

— Кот-ка-ры-гыз! Пин-сә а-ла-сы көн-дә ге-нә!..

— Жил-син пин-сә-не күтәр-гәч ке-ннә!.. — дип хырылдады икенчесе. — Я-шә-те-гезз!..

Без, алты ир заты, нәрсә эшләргә белми катып калдык. Гадәттән тыш шартларда да салкын канлылыгын югалтмаган җырчыбыз гына тыныч иде. Болай да бүрәнәдәй юан, кабина тишегендә буылудан инде тагын да бүртенгән һәм кан белән тулышкан муенын аз гына да кымшата алмаган хәлдә дә эндәшерлек хәл тапты:

— Пенсионерларны коткарыгыз, иптәш Хәлимов. Мин үлмәм ул... — Коелып төшмәсләрме дип, күрәсең, җырчы урынында сикергәләнде, әмма, шайтан алгыры, коелмады совет пенсионерлары; тозакка кереп капкан ветераннарның кулларын тышка чыгарып, капкачны ачарга мөмкинлекләре дә, хәлләре дә юк иде...

Без, әйткәнемчә, анадан тума алты ир заты, бәхетсезләргә ярдәмгә ташландык. Әмма коралсыз-нисез без нәрсә генә майтара ала идек, ә, мөселман кардәшләр? Кемдер, оят җирен тас белән каплап, шәрә килеш ярдәм сорап чыгып йөгерде — кире кергәндә, ул оят җирен кулы белән генә каплаган иде, ниндидер бер явыз хатын, аның тасын тартып алган, күрәсең, — тулды халык, тулды халык, мин сезгә әйтим, бу хатын-кыз дигәнең бигрәк тә оятсыз икән, яраткан җырчыбыз Фән Вәлиәхмәтовны шәрә килеш тә күреп калыйк дип, берсенең

өстенә берсе менеп, берсен-берсе таптап-имгәтеп, бу буш тамашадан ләззәтләнә иде...

— Анда карар нәрсә калмаган инде, — диде җырчы, электкеге тынычлык белән мүк кебек куе, бөдрә чәчле башын эре генә итеп артка чөеп. — Минем андагы борауны май бөргән, җәмәгать...

— Алай димә, Фән, алай димә! — дип чәрелдәп кычкырып җибәрде ниндидер бер хатын. Ул симез ирләрне социаль яклау җәмгыятеннән иде, күрәсең.— Карар җирең бар әле синең, бар!..

Беркем көлмәде. Фаҗига бик тирән һәм тетрәткеч иде.

Хәбәр яшен тизлеге белән барып җиткән, күрәсең, шул ук минутта мунчага баш табиб Хурамшин җитәкчелегендә барлык медперсонал кулларына газ баллоннары, чүкеч-кувалдалар, ломнар, кыскычлар, кискечләр, тагын әллә нәмәстәкәйләр күтәреп, алдан сварка аппараты этәреп, дистәләгән слесарь, сварщик һәм тагын да әллә кемсәләр килеп керде. Селәүчән кебек нәзек, каен чаукасы кебек озын һәм ак йөзле, җил иссә, җирнең икенче ярымшарына очып барып төшәрдәй слесарь абзыйның җан көченә Фән Вәлиәхмәт кабинасына кувалда белән тондыруы булды — ике пенсионер ботагыннан очкан усак яфрагы кебек идәнгә коелды. Аларны биредә танышып өлгергән әбиләре шундук хәстәрлекле кочакларына алды. Җырчыбыз әле һаман да бу тозактан котылмаган иде.

— Нәрсә карап каттыгыз?! — диде кемдер. — Җырчыбызны күрә торып үтертәбезмени? Татарстанга — Шәймиевкә, Милләтләр Оешмасына — Бутрос Галигә хәбәр итәргә кирәк!

Һәм ул телефон-автомат эзләп чыгып йөгерде.

Арадан икенче бер каһарман табылды. Теге саламторхан слесарь белән бергә икесенең берьюлы кабинаның ике канатына кувалда белән кундыруы булды — пар торбалары-ниләре, коммуникацияләре-ниләре белән бергә өч кабина идәнгә төшеп гөрселдәде.

Милләт иркен тын алды. Җырчы, агымлы елмаеп:

— Җәмәгатьчелеккә рәхмәт, — диде. — Сезнең ярдәм белән йөз илле граммга кимедем, кардәшләр. — Аннан, миңа карап: — Иптәш Хәлимов, сезгә дә рәхмәт, — диде. — Бүген кич концертка килегез, яме? Контрамарка калса, бушка кертербез, яме?

Ышанычлы чыганаклар хәбәр итүенчә, кичке егерме бер сәгатькә мунчада ремонт тәмамланган. Иртәгә ул гадәттәгечә эшләячәк. Әмма телефон-автомат эзләп чыгып киткән абзыйның гына кайтканы юк әле. Аны бөтен Рәсәй буйлап эзләү оештырылган, ди.

*1995*
*Янган-Тау, Башкортстан*

# ТЕЛЕГРАММА*

Дөресен генә әйткәндә, минем, аның белән дусларча мөнәсәбәттә булуыма карамастан, Тәнзилә турында сорашканым булмады. Хәрби хезмәт чорында мин аны ярыйсы гына өйрәндем: көндәлек эшләре турында синең белән күпме кирәк гәп сатар, әмма аның турында — ләм-мим. Күрәсең, мәхәббәт мәсьәләсендә сүз йөрткәндә, аның күңелендә ниндидер гауга туа, һәм шул аңлашылмас эчке гауга, эчке көч аңа бу турыда сөйләргә бирми. Сорасаң да, зәңгәр, матур күзләрен челт-челт йомып:

— Башка нәрсә турында сүз беткәнмени? — дип кенә куя.

Куштирәктән аңа күптән хат юк. Һәр көнне, хат көтеп, хат алмагач, иске хатларын актарырга тотына. Шаяртканны яратмый.

— Белмим, Галим,— диләр иде аңа кайчак иптәшләре, тегенең нечкә кылларына кагылып, — агроном кыз сине көтәр микән? Чыннан да, Куштирәктә егетләр беткәнмени? Ни дисәң дә, өч ел өч көн түгел...

Соңга таба бөтенләй сыза башлады егетебез. Сирәк сөйләшә. Хәтердә, ул көнне безнең взвод каравылда иде. Җәйге яңгырда җиңелчә генә чыланып алган Галим смена белән каравылдан кайтып керде. Гадәте буенча майлы чүпрәк белән автоматын сөртеп пирамидага куйганнан соң, тын гына чыгып китте. Мине тәртипсез уйлар борчый башлады. Нәрсәгә үзен бик сәер тота ул? Нәрсәне яшерә? Бәлки, иптәшләренә ачуы бардыр? Нарда яткан пилоткамны эләктереп, тавышсыз-тынсыз гына аның янына чыктым.

Җәй көне яңгырдан соң көннең матурлыгын сөйләп торасы да юк инде. Баш түбәсенә күтәрелеп җиткән кояш иркә нурлары белән дөньяны алтынга манган. Чардакка кунган күгәрченнәр гөрләшә-гөрләшә су эчә. Әгәр дә терсәкләре белән рәшәткәгә таянган, өстенә яшел гимнастерка кигән мәһабәт егет шушында тормаса, мин бу матурлыкны бер яклы, ярты матурлык дип кенә атар идем.

Мин алҗыган, төнен йокысыз үткәргән кеше тавышы белән җырланган җыр ишеттем. Ул безнең якларда бик тә таралган җыр иде:

Иртә томан, кич томан,
Шул томанның эчләреннән...

Эш нәрсәдә икәнен бик тиз төшенеп алдым. Уйлаганым дөрес булып чыкты. Шундый һәйбәт, кояшлы көндә кеше-

---

* Язучының беренче хикәясе.

нең «иртә томан, кич томан» дип моңланып торуы нәрсә хакында сөйли соң?!

— Их, Тәнзилә, — мин әйтәм, — егетне кызганырга иде бераз...

Аның хат язмавына ачуландым. Кулымнан килсә, мин ул кызкайны хәзер үк иптәшләр хөкеменә тапшырган булыр идем...

Ә ул җырлый да җырлый.

Моңлана да моңлана.

Шул томанның әчләреннән
Килеп чыгарсың сыма-а-ан...

Кайчан таралыр бу томан? Безгә кояш, кояш кирәк бит! Кайчан бу соры томан егет йөрәгеннән үзенең пәрдәсен алыр? Ярсыган тойгылар, тышаусыз җибәргән тайдай, миңа тынгылык бирми. «Егете армиядә ил алдындагы бурычын үти, ә кызы...»

...Хәрби шәһәрчектәге агачлар шәфәкъ нурына күмелеп, рота гадәттәге мәшәкатьләр белән шөгыльләнеп ятканда, казармада дневальныйның көр тавышы яңгырады:

— Рәҗәпов, телеграмма!

— Рәҗәпов, телеграмма!

Телеграмма... Бу сүзне ишеткәндә солдат гәүдәсе аша электр шаукымы үткәндәй була — кыска гына, ташка басылган сүзләрнең көтелмәгән хәбәр алып килүе мөмкин бит. Нәкъ Галим белән дә шулай булды. Башыннан яшен тизлегендә уй йөгереп үтте: «Әллә өйдә бер-бер хәл булганмы?.. Ә бәлки, Тәнзилә?..»

Бүлмә ишеген ябарга да оныткан Рәҗәпов дневальный янына ашыкты.

Юк, бездә хатны, шатлыклы хәбәрне иясенә болай тиз, «очсыз» гына бирмиләр. Солдат теле белән әйткәндә, «ашны эшләп ашарга кирәк». Еллар буе саклanып килгән йола, буйсынмый хәлең юк. Гадәтенчә башын арткарак салып, кәҗә сыман текә тыпырдап, Рәҗәпов кечкенә туры борынын мәзәк көтүче дневальный каршына китереп үк куйды. Шундый матур, ипле итеп шапылдау тавышы ишетелеп калды!..

Галимнең танау очлары әчетеп алды.

Иптәшләренең көлү тавышлары астында Галим, әчеткән борынын ышкырга да онытып, телеграммага күз йөгертте. Йөзенең кинәт шатлыклы үзгәрүен күреп, иптәшләре эшнең нәрсәдә икәнлеген аңладылар.

— Тәнзилә... Тәнзилә... — дип пышылдады егетнең иреннәре онытылып. — Мин шулай буласын көткән идем...

...Күзлеген борын очына ук төшереп кигән, чал чәчле, олы

яшьләрдәге телефонист хатын, игътибар белән бер Галимгә, бер телеграммага караш ташлаганнан соң, аңа телефон будкасына кереп сабыр итәргә кушты.

Телефон трубкасы. Бер караганда, бик тә гади әйбер ул. Армия сафларына аяк басканчы, Галимнең аны күп мәртәбәләр күргәне, кулына алганы, хәтта сөйләшкәне дә булгандыр, әмма әлеге кебек кадерләп, Яңа ел чыршысының тиз уалучан уенчыгын кулына алган кебек тотканы булмагандыр. Нидер кыштырдады бугай... Юк, шулай тоелган гына икән... Нишләп бик озак тоташтырмыйлар әле?!

Ниһаять, трубкадан телефонистның «Сөйләшегез!» дигән боерыгы ишетелде.

— Тәнзиләкәй, синме бу?

— Мин...

Ул аның тавышын ишетте. Сөйгәненең бөтен тын алышын, йөрәк тибешен күңеленең барлык тирәнлеге белән аңларга теләгән Галим трубканы сытардай итеп кысты.

— Тәнзилә, Тәнзилә... — диде ул, берничә мәртәбә кабатлап, — әйтче, кадерлем, нигә хатыңны туктаттың? Синнән еракта яшәүнең минем өчен ничек кыйммәткә төшүен аңламыйсыңмыни?

Телефон чыбыклары аша ике йөрәк тоташты. Ике гаепсез йөрәк, бер-берсеннән гаеп эзләп, аңлашырга керештеләр.

Кадерле укучым!

Аларның йөрәк серләрен тыңлап тору безнең өчен кирәк эшме?

Бу юлларны язучы, моны кирәксез дип санап, нибары кыска гына аңлатма бирергә кирәк дигән нәтиҗәгә килде.

Тәнзилә, авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаган кыз, хезмәт практикасыннан соң, Мәскәүдә Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясенә имтихан бирүен хәбәр итте. Имтихан нәтиҗәләре билгеле булмый торып, хат язмаска карар иткән икән.

Инде Галимгә килик.

«Шундый кадерле минутларны юк-бар сүз боткасы куертып харап итәм, — дип битәрләп алды үзен солдат. Шуннан көтмәгәндә сорап куйды. — Тәнзилә, Тәнзилә... әйт әле, безнең Талгын Чишмә буенда быел иген үстеме?»

Менә сиңа мә! «Сүз юктан сүз булсын»мы бу? Ул бит бөтенләй икенче нәрсә турында әйтергә теләгән иде. Эссе булып китте. Хурлык, Галим, хурлык, малай. Кукуруз икән быел Талгын Чишмә басуында. Тәнзиләнең әйтүенчә, күп көч салганнар, ди, шуңа кукурузы да котырып уңган, ди.

Отпуск турында сораганда, артык сабыр кыйланды егет. Тәнзилә «Кайчан кайтасың?» дигәч, Галим өзеп берни дә әйтмәде. Көтәргә кушты. Бәлки, шулай кирәк булгандыр.

Күптән түгел, Танкистлар көне бәйрәменә багышланган кичәдә полк командиры, Галим Рәҗәповны алдынгылар рәтендә санап, аңа кыска сроклы отпуск та игълан иткән иде. Юк, ышандыру ярамый. Хәрби хезмәт бит бу. Кем белә, бәлки, иртәгә үк хәлләр үзгәреп китәр?

...Куштирәк кызы белән саубуллашып, телеграфтан чыкканда, җир өстенә караңгылык иңә башлаган иде. Галим үзендә искиткеч җанлану сизде, әйтерсең йөрәккә кереп утырган таш Талгын Чишмәнең бер йотым шифалы суы белән эреп юкка чыкты.

...Иделдән салкынча җил исте. Күктәге йолдызлар бик күңелле итеп бер-берсенә күз кысыштылар.

Галим өчен барлык йолдызлардан да яктырак, якынрак бер йолдыз бар. Ул — җирдә.

*Декабрь, 1962*
*Самара*
*«Җиңү байрагы», 5 декабрь, 1962 ел*
*Бәләбәй*

## ЫГДЫБЫГДЫ ЧОКЫРЫ

*Айрат Арсланга*

Корманай авылында, Бөек Ватан сугышы башлангач, Ленинградтан килеп, шунда бөтенләйгә төпләнеп калган ифрат та мөлаем марҗа әбисе Анна Афанасьевна Копосова яши. Утызынчы еллар азагында өйләнешкән ире, троцкизмда гаепләнеп, кулга алынган һәм хәбәрсез югалган, шуның нәтиҗәсендә бер баласыз калган Анна апа, шәһәр бик каты тупка тотыла башлагач, дөбер-шатыр китерелеп, моңа кадәр күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән Башкортостанга озатылды. Район үзәгендә аларны авылларга тараттылар. Анна Афанасьевна исә менә шушы йорт саны йөздән артмаган татар авылы Корманайга эләкте. Беренче ике елын солдатка Гайния апада өйдәш яшәп, мәктәптә урыс теле укытты, аннары авыл советы яшь мөгаллимәне хуҗалары кырык җиденче ел ачлыгында Урта Азиягә күчеп киткән йортка кертте. Менә шул заманнардан алып яши Анна Афанасьевна Корманайда. Кияүгә дә чыкмады, туган ягына да кайтып китмәде. Әллә чит-ят авылда кичергән газаплы, әмма истәлекле вакыйгалар һәм еллар, әллә мондагы киң күңелле, беркатлы, бердәм һәм җор күңелле халык, әллә, шуларына өстәп, авылны уратып алган гүзәл табигать, әллә шулар барысы бергә биләп алган иде җан түрен, һәрхәлдә, шунысы хак: ташламады Корманай-

ны Анна апа. Үз телен, гореф-гадәтләрен онытмаса да, шактый татарлашкан иде ул. Телне белә, белә генә дисезме — су кебек эчә. Татарның аш-суын әзерләүдә, бар, син аның белән ярышып кара! Авылдашлары аны үз итте, бәйрәмнәрдә табынынннан калдырмады. Мөселман бәйрәмнәрендә катнашып, Анна Афанасьевна үзе дә аш-суга җыя торган булып китте...

Ул беркайчан да сыер асрап азапланмады. Ялгыз башына бер көрмәк сөт-катыкны аңа авылдашлары бушка да кертә иде. Әмма ул кәҗәсез яшәмәде. Кәҗә малында Геродот акылы күреп ярата иде ул аларны. Аннары, әйткәндәй, ифрат та игелекле, файдалы бит ул кәҗә дигәнең. «Саусаң — сөте, суйсаң — ите, мамыклары нәстәкәй!» — дип кенә җибәрә иде, малкайларны сыйпап. Менә быел да, кысыр калуына карамастан, көненә ике литрдан да ким сөт бирми аның Василисасы! Шулай иде дә бит, әмма сөеклесе узган кичтә кайтмады да куйды. Бер-бер хәл булды мәллә диеп, ул, төн караңгылыгын ерып, авыл тирәсен әйләнеп тә чыкты — табылмады Василиса; иртә белән, халык көтү куганда, бар малны күзеннән үткәрде — юк, күзенә чалынмады кәҗәкәй; көтүче Мисбахетдиннән дә сорашты — чират инде икенче көн аныкы икән — «Анка түти, кичә кәҗәң көтүдә булды!» — диеп чатнатып әйтеп тора анысы да...

Нәрсәдер сизенеп, җаны әрни Анна Афанасьевнаның. Өйдә тынгы таба алмый, ул менә тагын кәҗәсен эзләргә чыкты. Үзе тыкрыгыннан үзәк урамга борылганда гына, ул кайчандыр җылы почмак биргән, дүрт малай үстереп, читкә таратып, моннан берничә ел элек кенә Салават шәһәреннән бөтенләйгә авылга кайтып төпләнгән төпчек улы тәрбиясендә яшәүче, тулы тырыс белән җиләк күтәреп кайтып килүче һәм зәңгәр кәшемир яулыгын татар әбиләренчә алга бәйләп, үзе дә зәңгәр күзле кипкән мәтрүшкәгә охшап калган Гайния карчыкка тап булды. Гадәтенчә саф татарча сөйләшкән Анна Афанасьевна бүген, дулкынлануыннан һәм кәефсез булуыннан, күрәсең, Гайния карчыкка, үзе дә сизмәстән, урысча итеп:

— Козу потеряла, Гайния, — диде. — Ты мою козу не встречала?

— Их, Әнке, бидал шул, бидал, — ди теге заманнарда Анна Афанасьевнадан шактый гына урысча сукаларга өйрәнгән Гайния карчык, үз телен вата-җимерә. — Ягуд пашул, тбуй кәҗә бидал. Чурнай мәсти тбуй кәҗә бит, тәк бит?

— Черной масти? — диде тәмам хәвефкә төшкән Анна Афанасьевна. — Кара төстә, дисең? Әйт тизрәк, кайда күрдең?

— Чурнай мәсти, — дип раслады тагын Гайния карчык. Анна Афанасьевна торган саен татарчага күчә барганда, үзенең тирән белемен күрсәтеп калырга тырышкандай, ул торган саен урысчага күчте. — Нүжәли, думал, Әнкә кәҗә? Прауай

уха ризаный бит, тәк бит, Әнке? — Ул, үзенең уң колагын күрсәтергә дип хәрәкәт ясаганда, урманнан ияреп кайткан бөҗәкне яулыгыннан селтәп төшерде. — Прауай уха кырт-кырт дилал, тәк бит?

— Так! — диде Анна Афанасьевна, түземсезлек белән. — Ә кайда күрдең син аны, Гайния?

— Вәт там бит Ыгдыбыгды чокыры жис? — дип, карчык кулы белән авыл уртасындагы үтеп йөрү өчен бик тә уңайсыз тарафка күрсәтте.

— НКВД чокыры?

— Дә! Дә! Я ыспал и ыслушал: нүчью кәҗә «мә-мә, мә-мә» кричал. Там бит нүчью булк бивал. Кәҗә булк сыел. Кәҗә умирал. Кәҗә три ыраз «мә-мә» кричал. Әйдә, туда пашул!

Сиксәнгә җитеп барса да, һаман теремек булган һәм көн арбасын хәтерләткән Гайния карчык җитмештән узган Анна Афанасьевнаны җитәкләп, очырта-очырта чокырга таба алып китте.

Бу чокырның халык телендә ике исеме бар: сугышка чаклы аны «Җен ярган чокыр» дисәләр, сугыш вакытында аңа «НКВД чокыры» дигән куркыныч исем ябышып калды. Бу исемне телгә алганда, Гайния карчыкның арка үзәгендә бозлы өянәк кузгалгандай була. Дүрт баласының газиз әтисе, хәләл җефете Гали истәлеге белән бәйле бу котны качыра торган атама...

Кырык икенче елның кышында, фронтка китәр алдыннан, Алкин лагеренда хәрби әзерлек үткән Галие, — мәрхүмкәй, авыр туфраклары җиңел булсын! — әйе, үз гомерендә бер генә тапкыр да туган Корманаеннан чыкмаган, юашлардан да юаш, изгеләрдән дә изге күңелле, бәхетсезлегенә каршы, укый-яза да белмәгән Галие — сөякләре нинди тарафларда череде икән мәрхүмкәйнең! — әйе, лагерьдагы ачлыктан бер тире һәм сөяккә калып, үзе сөйләп өлгергәненчә, гыйнварның зәмһәрир суыкларында, көн саен унбиш чакрымдагы урманнан, өстенә җылы әрмис бушлаты-шинеле түгел, бердәнбер һәм анысы да өтәләнеп беткән димнәрүчкә кигән иңнәрендә чи агач ташып, күпме генә яксалар да, җылына алмаган зимләнкәләрендә тәмам туңып сулган һәм командирларының коточкыч мәсхәрәләүләренә түзә алмыйча, бахыркай, авылга качып кайткан иде...

— Атсалар атарлар, Гайния, мин сугышка бармыйм! — дип кырт кисте Галие.

Өч кенә көн бергә булып калдылар алар. Төпчек уллары Әхтәм менә шул кара көннәрнең якты истәлеге инде. Ыгдыбыгдылар Галине нәкъ әнә шул чокырда эләктерделәр дә инде. Шул китүеннән кайтмады ул. Үлеме йә хәбәрсез югалуы турындагы язуы да килмәде мескенкәйнең. «Дезертир гаиләсе» дигән гомерлек ләкабе генә ябешеп калды.

Түзде анысына Гайния. Әле дә түзә. Һәм әле дә көтә. «Бәлки, исәндер, ә?!» Менә ничәнче тапкыр телеп үтә бу өмет тол хатынның җанын. Шул чордан алып атый башладылар «Җен ярган чокыр»ны «Ыгдыбыгды чокыры» диеп...

Авылның чүп-чары, иске-москысы, мал үләксәсе ташлана торгач, үләт чокырына әйләнеп, тирә-ягын урман биеклегендәге кычыткан, ат кузгалагы һәм тас кадәр әрекмәннәр үсә анда. Гайния әби, шуларны ера-ера, Анна Афанасьевнаны чокырның төбенә үк алып төште. Анна Афанасьевна ни күзе белән күрсен, андагы зәңгәр ташларны каны белән сугарып, бугазыннан алып карынына кадәр ботарланган Василисасы ята иде... Үз халкының онытылган гадәте җанының ниндидер төпкелләреннән күтәрелде, күрәсең, ул кыргый көч белән җирне тырнап елый башлады. Кәҗәнең берсе мәгърипкә, берсе мәшрикъка караган күзләрен үбә, башын сыйпый, аннары тагын үбә, тагын сыйпый иде. Барлык җир йөзендә аның шатлыкларын һәм кайгыларын белгән бердәнбер җан иясе белән хушлашуы иде бу...

— Василиса, милая моя... Крошка моя, единственная моя!..

— Ыспакуй, Әнке, ыспакуй... — Гайния карчык аны юатырга тырышты. Тел байлыгы җитмәгәнлектән һәм бу очракта юату мөмкин булмаганлыктан, күрәсең, аның сөйләгәне бер үк сүзләрне кабатлауга кайтып кала иде. — Я ыспал и ыслушал, Әнке... Кинәттән нүчью кәҗә кричал. Тәм бит булк бивал. Кәҗә булк сыел. Кәҗә три ыраз «мә-мә, мә-мә!» кричал...

— «Ма-ма!» кричала?! — диде айнып китеп һәм җылавыннан туктап Анна Афанасьевна. — Она, значит, «Мама!» кричала... Ах, бедненькая моя!.. Ә ул, бәлки, «Анна!», «Әннә!» кычкырган, Гайния? Ул мине чакырган?!

— Ничауа, Әнке, не тужуй. Умирал артыннан умирал булып булмый. Кәҗә — каза. Каза ушел — нувай кәҗә пришел...

— Ничек, яңа кәҗә? — дип гаҗәпләнде Анна Афанасьевна һәм, хәле бетеп, янындагы ташка лып утырды. — Ничек, яңа кәҗә?

— Дә, дә, нувай кәҗә шул! Нашенский бит читири кәҗә, тәк бит? Два пухавай, два малакавай, тәк бит? Сигутны жы сынку сказал һәм әтнә малакавай кәҗә сиңа биргән. Ягнүнкеләре дә бар, әтнә саулык, әтнә мужик...

— Рәхмәт сиңа, Гайния, — диде күзләре яшьләнгән Анна Афанасьевна. — Мин бит сездән болай да күп изгелек күрдем, Гайния!.. — Ул күзләрендәге яшьне кул аркасы белән сөртеп алды. — А Василису-то хоронить итәргә кирәк...

— Храним, храним, не тужуй! — диде Гайния карчык, аны урыныннан җилтерәтеп торгызып. — Әйдә, бездә эсби-

жий ягод белән чәй пивал да, нашенский лапата вҗәл дә, вмичты хранит пошел!..

...Кояш, тирә-якны шәфәкъ алтынына күмеп, Сатлыкай урманнарына төшеп барганда, Гайния карчык белән Анна Афанасьевна, тау битләвендә атынчак кебек атынып һәм һәркайсы үз күңелендәге доганы укып, кәҗәне җир куенына тапшырдылар.

Икесе ике милләттән, икесе ике диннән булып та, затрухлары бер булган бу ике бәхетсез карчыкның уртак фаҗигасе шушы Ыгдыбыгды чокырыннан чыккан, икесенең дә сәгадәт кояшы шушы Ыгдыбыгды чокырында сүнгән иде...

*1995*

## КАРА КЫШТА

*Шагыйрь Тимер Арыслан истәлегенә*

— Дай сюда топор!

Аклы-каралы җирдән чана өстерәп килгән кыз күзләрен күтәреп караса, алдында ниндидер җайдак күреп, чыраена эссе капты. Чак-чак кына һушын югалтмады. Шик тә юк, урман каравылчысы иде бу. Үзеннән-үзе теленә килгән догасын укыганнан соң гына бераз айныгандай итте Карлыгач. Беренче булып күзенә ташланганы шул: алдында — аклы-каралы каен урманы, кола ат, ат өстендә йөнтәс аюдай адәм, мылтыгының көпшәсе аркасыннан тырпаеп тора. Кыз, керпе кебек бер йодрык булып бөреште. Карлыгач канатыдай кыйгач сызык кашлары астыннан тирә-ягына нәфрәтле ут көлтәләре чыгарып караган чем-кара күзләре генә җемелди иде аның. Инде кул сузымында гына яткан урман эченнән каравылчының килеп чыкканын, аның үзенә якынлашканын ничек кенәләр күрмәгән дә, ничек кенәләр абайламаган ул, ачыгавыз?

Карлыгач сүзләрнең мәгънәсен төшенеп өлгермәде, урман каравылчысы атыннан сикереп төште, шәп-шәп адымнар белән аның янына килде, күз ачып йомганчы бәләкәй чана үрәчәсенә тыгылган балтасын алып, аны ат сыртындагы аркылы капчыгына салып та куйды.

Аннан ул кыздан нәрсә хакындадыр кат-кат сорашты.

Кыз бернәрсә дә аңламады. Ул урысча белми иде. Шулай да каравылчының аның кайсы авылдан икәнлеген сораганлыгын абайлап, җавабында бер генә сүзне кабатлады:

— Мерәс... Мерәс... Мерәс...

— Из Мрясово, говоришь? — Ул, яңадан кызның янына ук килеп, чананы туган авылы Мерәскә таба каратып борып куйды:

— Иди!..

Битләрен дә кыл баскан бу аю кебек йөнтәс адәмзаттан сасы көмешкә исе килеп бәрелде. Кызкайның йөрәге күкрәк читлеген җимереп чыгардай булып типте. Инде хәзер балтасыннан соң аның үзенә ябыша дип куркуы табанына киткән Карлыгач, читкә тартылып, йодрыктан ноктага әверелеп кечерәйде. Бу мизгелдә ул үзен рәнҗетүченең бугазын чәйнәргә дә әзер бер җанварны хәтерләтә иде.

Каравылчы кулындагы камчы сабы белән яңадан авылына төртеп күрсәтте:

— Иди, иди!..

Атына атланып китеп тә барды.

Нәрсә эшләргә белмәгән кызкай кычкырып еларга итте, әмма тыелып калды. Каравылчының кире килүе һәм өстәвенә аны камчылавы да мөмкин иде.

Өйнең төп һәм бердәнбер кыйммәтле милке булган балта ат өстендә китеп барды.

Аның өйгә утынсыз кайтырга хакы юк иде.

Карлыгач, бер авыл, бер күздән югалып барган җайдак ягына карап, чабаталары астында эрегән аклы-каралы карда таптанды...

Кар чынлап та аклы-кара иде. Быел кыш явым-төшем бик аз булды. Урыны-урыны белән җир өстеннән тырпаеп торган былтыргы кара-кура, әремнәрне дә күмеп китә алмады. Февраль уртасында көтмәгәндә генә яуган яңгырдан әле кичә генә ап-ак булып яткан җир өсте аклы-каралы булды да куйды.

Менә, ниһаять, ул, чачакланып туза башлаган чабата башларын теләр-теләмәс кенә өстерәп, авыл ягына таба борылды. Чабаталары авылга борылса да, үкчәләре, гәүдәсе әле һаман да урман ягына караган иде. Кояш яктысының әсәрен дә калдырмый ашап, күкне басып алган кара кургаш болытларда, авыр ачылган төрмә ишекләрен хәтерләтеп, нәрсәдер шыгырдады. Карлыгачның авылга таба атлыйсы килми иде. Куе караңгы һавада көннең мизгелен дә белерлек түгел. Кара кыш иде бу. Чын кара кыш. Бу кышны кара кыш дип атау өчен башка сәбәпләре дә бар иде, әлбәттә. Вакытны сузарга тырышкандай, кыз уйланып калды: иртәнме, төшме, әллә кичкә табамы әле бу? Карлыгачларның өендә сәгатьләре юк. Кая ди аларга сәгать?! Авылда булмаганны! Халык гел кояшка карап кына яши. Хәзер күк йөзеннән кояш яктысы да юкка чыккач, вакытны чамалау да читен. Аңа бит күз бәйләнгәнче кайтып җитәргә кирәк. Урманга утынга юнәлгәндә, төшке уникеләр чамасы булгандыр. Авыл белән урман арасындагы биш чакрымлык араны аклы-карада чана тартып килә-килә, бер-ике сәгать вакыт үтеп тә киткәндер, мөгаен. Әле кичке караңгы төшкәнче, тагын да өч-дүрт сәгать вакыт булырга кирәк...

Кыз, авыр уфырып, авылга таба ике-өч адым атлап азапланды да туктады. Буш чана авыр, чанадан да бигрәк язмыш авыр иде, ахрысы. Әйе, Карлыгач өчен бу минутта төялгән чана буш чанадан күпкә җиңелрәк булган булыр иде, әлбәттә. Буш чана белән кайту гарьлегеннән тешләрен кысып, ул иренен тешләде. Үзенең бу кадәр бәхетсез һәм хокуксыз булганы өчен юл читендә бер-берсенә орынып үскән өч орылы каеннан да оялып куйды ул.

Кемдер кычкыргандай тоелды. Кызкай артына борылып карады. Урман каравылчысы, кире борылып, аңа таба килә иде.

Карлыгачның тагын да нәрсә булыр икән дип куркудан мескенлеккә төшкән карашы буш чана канатларында катып калды. Тояк тавышларын инде колак төбендә дөпелдәтеп, ат аңа терәлеп диярлек килеп туктады. Кулындагы феләжкесеннән каравылчы голт-голт китереп нәрсәдер йоткалады. Аннан лапылдап җиргә сикереп төште. Тирәнлеге киез итегенең йөзенә дә чыгар-чыкмас карда һаман да шул аклыкаралы эз калдырып, ул каеннар янына үтте һәм атын тезгеннәннән бәйләп куйды. Шуннан соң ат сыртындагы капчыгында карманып, аннан ялт иттереп Карлыгачның якты йөзле балтасын чыгарды да, икенче кулы белән чананы тартып, урманга таба юнәлде. Карлыгач та сүзсез генә аның артыннан сөйрәлде. Урманчы бераз эчкәрәк кереп корыган-ауган аклы-каралы каен агачларын җыйнаштыра, кулындагы балтасы белән ялт-йолт килеп, иске коры-сарының кисәсен кисә, сындырасын сындыра, аударасын аудара торып, чанага төйи башлады. Аркасыннан салмый калдырган мылтыгы иелгәндә бер килеп атылып китәр дә, көпшәсеннән гөлт итеп ут чыгар төсле тоела иде Карлыгачка. Кызкай үзе дә төяшергә дип ярдәм итмәкче булган иде, кулы белән генә ишарәләде теге: «Кирәкми. Урыныңда тор».

Кыз бала үз күзләренә үзе ышанмый да һәм моның нәрсә белән бетәчәген күз алдына да китерә алмый иде.

Җир йөзендә аның турында кайгыртучы кеше булуы, җитмәсә, бу кайгыртучының бөтенләй көтелмәгән тарафтан килеп чыгуы могҗиза һәм бары тик могҗиза иде. Монавындый кара кышта бөтенләй чит кеше синең өчен бүре базына да төшәргә әзер торсын әле!..

Аның әле генә сөмсерләре коелып торган йөзе яктырып китте. Әче җилләрдә талана-талана җепләре сирәкләнеп чыптага әйләнгән шәленә ничектер чалшаеп кереп качкан йөзе көтмәгәндә тулган ай сыман түгәрәкләнде, алсуланып нурланды, нәзек кыйгач кашлары тагын да кыйгачланды, куркуыннан кара нурлар коелып торган күзләреннән өмет шаукымнары бөркелде. Аның тулы йөзе шәленең кара корша-

выннан гүяки ай кебек галибанә яктырып тышка чыкты һәм ул мизгел эчендә тәмам бетеренгән кызчыктан Дим буйларының гүзәлләрдән дә гүзәл бер башкорт сылуына әверелде. Әле килеп аның чанасына утын төяп азапланган урман каравылчысы турында моннан берничә минут элек кенә начар уйлый алганы өчен оялды Карлыгач, менәтерәк. Юк, әйбәт кеше бит ул!.. Әйбәтнең дә нindие генә әле!.. Әнә төйи бит, төйи!.. Урман каравылчысы аңа үзе утын төйи! Күрелгән хәлме?! Үзенә түгел, кешегә, бер ятимә башкорт кызына төйи!.. Куанычыннан кычкырып җибәргәнен дә сизмәде: Каттегат һәм Скагеррак!.. Тукта, монысы нәрсә тагын? Каттегат һәм Скагеррак. Каттегат һәм Скагеррак... Әй, исенә төште, географик атамалар бит әле алар. Үзенә ошаганнары аның атналар буе теленнән төшми. Күптән түгел генә Куала-Лумпур белән Танарариве дигән калаларның исемен шулай теленә төер чыкканчы кабатлап йөрде. Каттегат белән Скагерракка килсәк, Балтыйк һәм Төньяк диңгезләр арасындагы култыклар бит алар. Карлыгачның карашы моңсуланды. Шунысы мәзәк, бу култыклар арасындагы өске төче су катламы көньяктан төньякка, астагы тозлы су катламы төньяктан көньякка ага. Кызык бит: диңгез бер, агым ике һәм капма-каршы!.. Карлыгачлар географиядән төньяк диңгезләрне өйрәнгәндә, шушы кабатланмас атамалар аның хәтеренә сеңделәр дә калдылар. Бигрәк ярата бит ул географияне!.. Әйе, андагы кызыклы, сәер атамаларны көннәр буе кабатлап йөри ул. Күңеле күтәренке чакларда бу атамалар үзләре үк телгә сикерә: Каттегат, Скагеррак! Әйтерсең баш очыннан кыр казлары үтә: кыйгак-кыйгак!.. Кат-те-гат, Ска-гер-рак! Кат-те-гат, Ска-гер-рак!

Бит алмаларына кадәр кыл баскан аю кыяфәтле йөнтәс урыс аңа хәзер алай ук ямьсез дә күренмәде. Ул хәтта мөлаем да иде әле.

Кинәттән кызкайның йөзеннән шомлану шәүләсе чагылып үтте... Тукта әле, ни дип тырышып ята бу урыс? Нәрсә хакына балтасын тартып алды да, нәрсә хакына шул ук балта белән утын кисеп, аның чанасына төйи башлады? Бәлки, урманчының бер гади авыл кызының өстеннән көләсе киләдер? Ул аны, бәлки, мәсхәрәләргә җыенадыр? Бәлки, бу манзара өн түгел, төш кенәдер? Ул тагын да бер мәртәбә күзләрен киеребрәк карады: әйе, ышансаң ышан, ышанмасаң ышанма, каравылчы, җан-фәрман килеп, аның чанасына утын төяп йөри! Каттегат һәм Скагеррак!.. Кыйгак-кыйгак!..

Туган авылындагы тәрәзәләре генә түгел, почмакларына кадәр туңган өйләрендә апалары алып кайтачак утынны көткән дүрт энесе һәм сеңлесе искә төште. Алар хәзер суынган мичкә сыгынып, ничек кенә булса да аркаларын җылытырга тыры-

шалардыр, әниләре дә өйдә юк, ичмасам. Ул ябык ындыр табагында көлтә чабагачлый. «Әгәр эшкә чыкмасаң, фронт законнары нигезендә башың трибунал китәчәк!» — дип янады аңа бүген персидәтел Килдехуҗа. Әниләре үги шул аларның. Карлыгачтан унике яшькә генә өлкәнрәк ул. Үз әниләре, өч бала калдырып, сугыш алдыннан гына үлеп китте. Аталары, урман каравылчысы булып эшкә урнашып, үзеннән күпкә яшьрәк хатынга өйләнде һәм гаиләсен менә шушы Юргавыл урманы эчендәге кордонга күчереп алып килде. Бераз гына эчтәрәк ул кордон. Өстәвенә үги әниләренең дә әтисеннән баласы булды. Әмма Карлыгачның зур куанычы бар: какмый-сукмый аларны үги әниләре. Күрә торып бала аермый.

Кызкай муенын сузып тау сөзәгеннән түбәнгә карап алды. Сагынудан түгел, әлбәттә. Әрнүдән. Күз чокырлары мөлдерәмә яшь белән тулды. Сөзәктән төшкәч тә, сулга борылып, урман эченә керүгә һәм бераз баруга биек-биек каеннар арасыннан калкып чыга торган иске кордон ихатасын күз алдына китерде ул. Җаны өшеп куйды. Бу йорт аның өчен тәмугның тәмугы булды. Яшь хатыны һәм урманы мәшәкатьләренә башыннан кереп чумган аталары балалары белән бер йортта яшәсә дә, балаларыннан аерылган иде: ул аларның барлыгын да белмәде. Берүзенә дүрт сабыйны тәрбияләү унөч яшьлек Карлыгач өстенә төште. Аяклары, куллары, йөрәк тамырлары өзелде аның, үзеннән зуррак тормыш йөген тартып. Ул туйганчы йокы да, ашау да күрмәде. Җәйге челләдә яфраклары пешенеп сыгылган каеннарның яшел алкалы ботакларын нәрсә дисең син? Карлыгачның чәч толымнары бит алар! Юргавыл урманы аланнарындагы эре таҗлы ак чәчкәләрне кемгә охшатасың син? Карлыгачның һәрчак уяу күзләре бит алар! Шул ук аланнардагы песи башлы сарутларны нәрсә дисең син? Карлыгачның күз керфекләре бит алар! Мәктәпкә киткәнче йорт эшләрен бетереп өлгерсен дип, үги әнисе аны таң сарысы белән уята. Күзләрне тырнап ачарга да өлгермисең, боерыклар ява башлый: «Үзебезгә дә, тавыкларга да ашарга пешереп куй! Казларны, күркәләрне, үрдәкләрне дә болгаусыз калдыра күрмә! Көненә җитәрлек итеп утын ярып өйгә кертеп куй! Сыерларны Зәбих акланына, сарык-кәҗәләрне Мәлих акланына илтеп куй! Керләрне уып эл! Фәлән итеп куй! Төгән итеп куй!» Карлыгач почмакка барып җылый да эшенә тотына, почмакка барып җылый да эшенә тотына...

Әтисе сугышка китәр алдыннан гаиләне берьялгызы карурман эчендә калдырмады, Мерәстәге иске йортына кайтарды. Менә инде аталары да юк аларның. Моннан ике ай чамасы элек кенә кара хәбәр килде: кайдадыр Смоленск тирәсендә батырларча һәлак булган. Кызкайның күзләреннән гөрләп

яшь ага башлады. (Карлыгач күз кырые белән генә карап алды — каравылчы утын төяүне тәмамлап ук килә иде.)

Карлыгач бу минутта атасын сагынып зар елады. Ничек кенә каты куллы һәм бәгырьсез булмасын, җир йөзендә аның үз атасын алыштырырлык башка беркем дә юк иде бу минутта.

Ярый әле, үги булса да әниләре бар. Аның Алмабикә апаена бернинди үпкәсе юк. Аталары фронтта һәлак булып, нибары егерме алты яшендә иреннән тол калган яшь хатын әллә никадәр дә явыз була алган, аларны ташлап та кача алган булыр иде, шулай бит? Карлыгач боларны гына аңлый инде хәзер. Үги аналары аларга яхшылык кына тели. Аталары кебек, ул да таләпчән, каты куллы, мөгамәләдә каттый булса да, дуамал һәм акылсыз түгел. Аталары юк дип, үгиләрне какмый-сукмый, шунысына рәхмәт. Ул балаларын елның дүрт мизгелендә дә тигез эшләргә өйрәтә. Дөнья авырлыгыннан түземе бетеп, уңга-сулга янтаймый, тәртәне шарт сындырмый. Шунысына рәхмәт. Сабый чагында изелеп, ишелеп, бишек йокысы белән йоклар урында йомык күзләр белән таң сарысында маллар куган Карлыгач боларын да аңлый. Үги әниләре аларны үз баласы кебек тигез карый. Үзе хакында халыктан «Фәлән-фәләннәрнең әниләре үги икән» дигәнне ишетсә, утырыплар елый. «Үги ана» дигәнне ишетәсе дә килми. Әгәр ишетә калса, җене котыра. «Тудырган ана түгел — үстергән ана!» — дип кенә җибәрә ул. Бәлки, шулайдыр да. Бермәлне кемгәдер «Минем әнием үги бит» дигәне өчен Карлыгачны шартлатып курыс белән каезладымы? Каезлады. «Нәрсә, мин сездән тамак аераммы? Мин сездән кием аераммы? Әллә мин сезнең атагызны анагыздан аертып килгәнме?» — дип сүкте ул аны. Һәм, әйтергә кирәк, дөрес сүкте. Юк, нәрсә генә әйтсәләр дә әйбәт ул Алмабикә апай. Әйбәт. Укып китеп, кеше булса, ул беренче бүләге итеп Алмабикә апаена чуклы шәльяулык алып бирәчәк. (Кыз сискәнеп куйды: урманчы инде чанадагы йөкне бәйли дә башлаган иде.)

Карлыгачны яңа шикләр биләп алды. Бәлки әле, тырыша-тырыша чанасын бәйләп маташкан каравылчы сугышка кадәр бу кызның әтисенең дә, нәкъ үзе кебек, урманчы булып эшләгәнен беләдер? Бәлки, шуның өчен генә дә теләктәшлек күрсәтеп ярдәм итәдер? Никадәр дә яхшы кеше!.. Никадәр дә иманлы кеше!.. Бәлки, ул үзе дә элек бу кыз яшәгән кордонда яшидер? Их, телләрен аңласа иде! Сорашыр иде. Юк, бу хакта белмидер ул, дип кырт кисте кызкай. Үз гомерендә беренче мәртәбә күргән урман каравылчысы, җитмәсә, чит кавем, урыс кешесе, аңардан бернәрсә сораштырмыйча, каян белсен бу кызкайның сугыш яланнарында ятып калган урманчы Килдеголның кызы икәнлеген?! Белми, әлбәттә!.. Ул прусты гына әйбәт кеше!..

«Юк, бу юкка түгел, — дип, үзе белән бәхәскә керде күп тә үтми Карлыгач. — Сугыш бара бит, сугыш. Бер учаклык утын өчен башлар төрмәгә киткән хәтәр заманда урман каравылчысының болай кылануының бер сәбәбе булмый булмас. Полещик халкы хәзер ирсез-егетсез калган ятим авылларда янарал булып яшиләр. Закон аларныкы. Уңаена тормасаң, атып үтерүе дә ихтимал». Аннан кызкайга тагын яңа фикер килде. «Каравылчының аны мәсхәрәлисе, көләсе, ягъни шушы йөкне ат урынына тарттырып, кордонга — аның күз яшьләре түшәлеп яткан мәхәббәтсез һәм мәрхәмәтсез кордонга йә лесхозның үзенә илттерәсе килә мәллә?» Бераздан аны икенче фикер борчый башлады. «Бәлки, аның шушындый кара кышта чана тарттырып, аклы-каралы каен утынын сугыш яланының үзенә үк илттереп куйдырасы киләдер?» Кыз эсселесуыклы булып китте. Әле генә мөлаем күренгән каравылчы инде тагын битләрен кыл баскан йөнтәс аюга әверелде. Юк, әгәр кирәк икән, ул бу йөкне тартып илле чакрымдагы Дәүләкәнгә, кирәк икән, атасы һәлак булган Смоленскиның сугыш яланнарына кадәр барса барыр, әмма моннан ярты чакрымда яткан кордонга бармас. Аның бу кордонны күрәсе килми. Канлы, әмма гадел сугышка барса барыр, ләкин мәрхәмәтсез һәм гаделсез, ялган иминлек, ялган тынычлык хөкем сөргән кордонга таба аяк та атламас. — Ул билен бәйләгән билбавын капшады. — Әгәр... бик ачуны китерсәләр... әнә ярсу җилләрдә ярсып утырган аклы-каралы каеннар янына барыр да, аларның орысына басып, элмәккә керер...»

Тәүбә-тәүбә, Илаһым!

Каравылчы йөкне аркасыннан тырпаеп торган мылтык көбәге белән бергә этәреп чыгаргандай этәреп урман авызына чыгарды да чананы Мерәс ягына каратып борып куйды. «Юк, моңарда бернинди дә начар уй булмастай күренә, — дип уйлап алды Карлыгач. — Чананы авылга каратып куйгач, димәк, миңа китәргә рөхсәт итә, димәк, ул миңа ярдәм итәргә генә теләгән. Бу ихластан да яхшы кеше». Кызкайга яңадан канатлар үсте. Кыйгак-кыйгак!.. Каттегат, Скагеррак!..

Урманчы, зур эш бетергәндәй киерелеп, тирән тын алды. Карлыгачка карап елмайгандай итте. Бу елмаюдан кызның эченә тагын да җылы керде. Аклы-кара каенга бәйләнгән ат хуҗасын күреп тынычсызланды һәм пошкырып куйды. Урман авызында торган урманчы, нәрсәдер исенә төшкәндәй кыбырсып китеп, кыр сумкасының авызын черт итеп аелыннан ычкындырды, аннан яссы феләжкке чыгарып, бугазыннан гына голт-голт китереп теге нәрсәне эчте. Авыз эченнән генә мекердәп, мыгырданып алды. Бар тирә-якны тагын сасы ис басты. Ул феләжкесен кыр сумкасына төшерде, авызын шулай ук чертләтеп япты һәм чана бавын алырга кушып Карлыгачка

ишарәләде. Кызкай бауны алырга дип иелгәндә генә, каравылчы кыргый җанвар кебек аның өстенә сикерде һәм аны, көчләп кыскалый башлап, утын йөге өстенә егып салырга тырышты.

Мондый адымны һич кенә дә көтмәгән Карлыгачның җанында таулар кузгатып, әллә нинди табигый көчләр актарылдылар. Ул үзен үбәргә дип омтылган йөнтәс аюның юылмаган озын сакалын ике яктан ике кулы белән җитен талкыгандай итеп тартты һәм, аны-моны уйламыйча, җан көче белән уң кулының сыртына тешләрен батырды. Каравылчы акырып җибәрде һәм Карлыгачны кочагыннан ычкындырды.

Бер кулы белән кансырап торган икенче кулын каплаган каравылчы һәм үз батырлыгына үзе хәйран калган Карлыгачның карашлары очрашты. Бу карашлардан гүя чакматашка чакматаш орынды һәм очкын яралды. Каравылчы аңлады. Ул, хәлиткеч адымнар белән атлап, йөк янына килде, Карлыгачка тагын да бер тапкыр көлемсерәү катыш мәсхәрәле караш ташлады да аркан астына тыгылган балтаны алды, аннан тагын «Күрербез, нишли алырсың икән?» дигән сыман башын кыегайтып, аты янына барды, тезгенен чишеп, атланып алды да тау сөзәгенең иң югары ноктасына менеп һәйкәлдәй басты. Авылга таба борылды һәм яңа тамаша көтә башлады.

Кызның эчендә үч һәм гарьлек көйрәде.

Ул, аяк табаннарына ныклы нигез эзләп, аклы-кара җирдә чабаталары белән капшанды. Аяк бармаклары лычкылдап куйды. Тулаекларга су үткән иде. Чана бавын сул иңбашыннан үткәрде һәм, аның очын сул кулына кат-кат урап, уң кулы белән дә чат ябышып, алга талпынды. Йөк урыныннан кузгалмады. Каравылчы аны кыз бала тарта алмаслык итеп төягән иде. Карлыгач, барлык ихтыярын һәм көчен туплап, тагын бер мәртәбә талпынды. Беркайчан да бу кадәр авыр йөкне күрмәгән-кичермәгән чана, кеше кебек тоемлап, табаннары һәм үрәчәләре белән бергә ыңгыраша-ыңгыраша урыныннан кузгалып китте. Аяк астыннан башка бернәрсәне шәйләмәгән Карлыгач бу йөкне Җир шарын тарткандай тартып йөкле юл — иманлы юлга чыкты. Бу аның кемнәрдер тарафыннан көчләп төялгән һәм, үзе теләмәсә дә, мәңгелеккә тартып барырга тиеш булган шәхсән йөге — язмыш йөге иде, күрәсең. Йөк кимемәде, киресенчә, авырайганнан авырайды, ә Карлыгач аклы-каралы юлыннан үз көче белән күз яшьләрен коя-коя барды да барды. Бу кадәр көчәнүдән булса кирәк, әллә күзенә шулай күренде — юлның ике ягыннан да кызыл чигәле куяннар йөгерешә башлады. Әйе, бу кадәр сарыф ителгән көчтән, кайнарлыктан, эчәгеләргә кадәр һәм бу кадәр яну, көю, тупланудан вакыт-вакыт аның күз алмалары шартлап, чокырларыннан атылып чыга һәм аклы-кара

җиргә коелып калган кебек була иде. Ул, туктап, йөкнең артык өлешен бушатырга да уйлады, әмма тартынды, курыкты, әгәр туктаган хәлдә, теге йөнтәс аю аны, хәзер үк артыннан куып килеп җитеп, мәсхәрәли башлар кебек тоелды. Аның үзенә ул алга барган саен каравылчыдан ерагаймый, ә, киресенчә, аңа якынайган сыман күренеп куркуга төшә иде...

Ниһаять, туктап, ул сак кына, сиздермичә генә артына караш ташлады.

Урман каравылчысы һаман да шул сөзәк түбәсендә атлы казак булып каткан да бу тарафларга таба карап тора. Аркасыннан һаман да шул мылтыгының көпшәсе тырпайган. Кулында балта. Карлыгачның балтасы...

Әмма аңа хәзер бу тимер кисәге түгел, утын, туганнары һәм үги әнисе көткән утын кадерлерәк иде. Утын аның өчен яшәү уты белән бер иде. Бу урыс, рәхмәт төшкере, аңа яшәргә, яшәп торырга утын, гомер җылысы бирде түгелме? Аңа, бәлки, бер дә рәнҗемәскә, ә бары тик рәхмәт кенә әйтергә кирәктер?

Чана бавын сул иңеннән уң иңенә күчереп, ул тагын кузгалды.

Каравылчының куып җитүеннән уттан курыккан кебек курыккан кыз аңа карурманда бушка утын төяп биргән кешене чын-чыннан кызгана башлады. Ул бит бүген үз гомерендә беренче тапкыр кеше канын чыгарды, һәм бу кан аңа бушка утын төяп биргән урман каравылчысының каны булып чыкты. Илаһым, үзең рәхим әйлә!.. Урман каравылчысы эчкән теге нәрсәсеннән агуланмасмы? Үлеп китмәсме? Үз теләге белән эчкәч, ул бит бу сасы нәрсәне һич кенә дә рәхәт тормыштан эчмидер, бәлки? Бәлки, аны да җәфалыйлардыр, изәләрдер? Бәлки, ул да Карлыгач кебекләрне изү, балтасыз итү кайгысыннан эчәдер? Бәлки, аның үзенә ярдәм, җылы сүз кирәктер? Өенә кайтып җитә алырмы? Юлында егылып калмасмы? Тукта, бу урысның урман эчендәге шыксыз кордоныннан кала чын өе, үзе салган өе бар микән?

«Әнә теге, әнә теге борылышка кадәр генә түз, Карлыгач, — дип пышылдады үзенә-үзе кызкай. — Шул борылыш кына аларны бер-берсен күрә алмаслык итеп аерачак».

Бер-берсен күрә алмаслык итеп аеру өчен алар арасында кискен борылыш кирәк иде шул. Шундый борылыштан соң гына чана өчен атлы казак, атлы казак өчен чана күздән югалачак. Мерәскә дә дүрт чакрым чамасы гына калачак, Алла боерса.

Кинәттән һавада кемнеңдер каһкаһә белән көлгән тавышы яңгырагандай булды.

Кызкай ялт иттереп артына борылды. Шөкер, анда беркем юк иде. Бу гасаби көлүдән күк гөмбәзеннән иске сары көрпә коелгандай тоелды. Карлыгачка гүя икенче көч, икенче

илһам, икенче, өстәмә тын кергәндәй булды. Ул йөкне элеккечә метекләп түгел, эре адымнар белән сөйри башлады.

Ә йөк исә чынында ифрат та авыр икән шул. Атасы исән чакта, аның мондый авыр йөкне беркайчан да сөйрәгәне булмагандыр. Менә ул теге борылышка да җитте. Туктап, инде соңгы тапкыр артына карады.

Каравылчы һаман да ат өстендә, һаман да биектә, һаман да атлы казак сыман инде аз гына ачыла башлаган офыктан мылтыгы белән тырпаеп тора. Әмма бу юлы аның рәвешендә аерма бар иде — бу юлы ул уң кулын терсәгеннән бөккән дә феләжкесендәге сыеклыкны тагын авызына коеп азаплана...

Ул урыс иде.

Карлыгач тирән итеп сулыш алды. Балтаны аңардан кире кайтарасы булыр. Балта урыста калмаска тиеш. Бәлки, үлем хәбәре дөрескә чыкмыйча, атасы кайтса, балталарын тиз көндә кире дә кайтарырлар әле?..

Ул, яңадан чанасына җигелеп, аяк очлары белән аклыкара җиргә кадалды. Көч-хәл белән урыныннан кузгалып, ул, ниһаять, борылыштан борылды да, кара кышның ак-каралы карларыннан үз эзен салып, йөген туган авылына таба сөйри башлады.

Хәзер чаналы атлыны, атлы чаналыны чынлап та күзеннән югалткан иде.

*15–22 июнь, 2003 ел.*
*Ахангаран, Үзбәкстан*

## СӘҮИТ СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ

Үзем газетада эшләсәм дә, шимбә-якшәмбе көннәрендә шәһәргә күтәрелеп, үземнеке кебек алдакчы газеталарны сатып ала торган гадәтем бар. Кем ныграк алдый, кайсы артыграк шыттырганны чагыштырып карар өчен. «Күтәрелеп» дигәнем шул: Уфаның Нижгарудка төшкәндә иң ташландык «сыерчык оялары», чүп-чар чәчкәлегендә җәһәннәмгә сөрелгән гидайлар яши торган Ущелье бистәсендә гомер кичерәм мин. Менә бүген дә «Ущелье урамнарында бурларның уңганнары»н «Баламишкин» көенә көйләп, Ущельедан сөекле Уфамызга күтәрелеп, Красин урамы — аны татар әбиләре Кәрәчин урамы диләр — почмагындагы киоскка чиратка бастым. Рухи азыкка, эсбижий хәбәрләргә сусаган, тик торудан чарасыз бичара күз карашым лачын кош булып тирә-якны сөзә, айкый башлады. Күрәм, бер катлы

агач кибет белән киоск арасында сыеныр урын табып, ике марҗа әбисе сәүдә ачып җибәргәннәр: берсе — кура җиләге, икенчесе карлыган сата. Сатарга җыенган, һәрхәлдә. Әлеге сатып алучылары бинокль белән карасаң да күренми, әлбәттә. Карлыган сатучы шыксыз озын, үтәләй күренердәй булып какланган, кипшенгән карчык юкагач сыман озын аякларын сузып ниндидер түмгәкләргә куеп утырган да җыерылып күтәрелгән итәге астындагы ыштан төбенә дөньяви мультфильм күрсәтә. Кура җиләге сатучысы бер читтәрәк басып тора, үзе вакыт-вакыт бәбкәләрен саклаган ана каз кебек урында таптанып, биештереп ала. Лупа сыман калын пыялалы күзлеге танавының очына ук шуып төшкән, читтән караганда, үзенә күрә түгел, ярыйсы гына укымышлы дама күренә. Ул бер стакан җиләген, газетага җәеп, тигез таш өстенә куйган, газетасының бер башын, очып китмәсен дип, кечкәнтәй таш кисәге, икенче башын сиртмәле үлчәве белән бастырган.

— Яулыгыңны юньләбрәк бәйләр идең, — диде «дама» мультфильм күрсәтеп утырганына. — Югыйсә бөтенләй мөселман әбикалары кебек булгансың. — Тегесе аны тыңлап төзәтенә, кара яулыгын күзенә төшереп бәйли башлады. «Дама» йөгереп килде һәм аның кофтасының төймәләрен эләктереп куйды. — Салкын тидерә күрмә тагын. Бүген җиле суык кына...

— Син үзеңне кара, — диде мультфильм күрсәтүче, утырган урыныннан гына тегесен үзеннән җибәрмичә пинжәк каптырмаларын каптырып. — Ашыгыбрак чыгып киттек шул. Сезоны бит аның, сезоны!..

Әбиләр яңадан үз позицияләрен алдылар. Офыкта сатып алучы һаман да шәйләнми һәм сигналлар да бирми иде.

Бер-берсенә карата шулкадәр игътибарлы, хәтта мәхәббәтле бу әбиләрне мин сеңлекәшләр, йә булмаса, туганнан туганнар, һичьюгы, озак еллар бер йортта, бер ихатада яшәгән ут күршеләрдер дип уйлап өлгердем.

— Мильтон уңнан! — диде кипшенгән әбекәй, оператив хәбәр биреп. — Җыештыр, Марусь!..

Үзе шундук җыерылган итәге белән кечкенә җиләк чиләген һәм стаканын каплады да, кесәсеннән кечкенә «Псалтырь» чыгарып, дикъкать белән дин нигезләрен өйрәнә башлады. Аның күзләре бур песинеке кебек йөренә иде.

«Дама» стаканын ялт итеп кулына алды да, борылам дигәндә, күзлеге төшеп китеп, җиләкле савытына абынып, аударды да куйды. Әмма җыештырынып торырга соң иде инде: конфискациядән исән калган стаканын җиң эченә яшереп, киоск артына барып посты.

Кызыл сызыклы фуражка, һаваны кисеп, игътибарсыз гына үтеп китте.

Кипшенгән әбинең чиләге һәм стаканы итәк астыннан яңадан якты көнгә чыкты. Күзлеклесе таза җиләкләрен туфрак белән бутамаска тырышып, учлап-учлап яңадан чиләгенә тутырды, туфрак белән буталганнарын авызына озата барды. Ниһаять, ул иске урынына килеп басты, әйберләренең барысын да, берни булмагандай, кире урнаштырды.

Кинәттән җил күтәрелде. Дөресен әйткәндә, өермә иде ул. Күзлекленең җиләге һәм сиртмәле үлчәве куелган газета кисәге дүрт яклап кыбырсып куйды.

— Үлчәвеңне эчкәрәк күчер, очып китә бит, — диде кипшенгән карчык. — Күрәсеңме, ничек өерелтә.

Тегесенең милиционер тудырган мәшәкатьтән башы каткан иде, күрәсең. Ул тимерне кулына алды һәм ялт итеп эчке халат кесәсенә салып та куйды. Аннан шул ук газетаны ниндидер авыр нәрсә белән бастыру өчен тирә-ягыннан нәрсәдер караштырды.

— Ярык баш! — дип, аңлатма бирде кипшенгән карчык ахирәтенең бу кыланышына. — Тимер үлчәү очканчы, без очып китәрбез әле!..

Күзлекле «дама», якында гына андый авыр нәрсә күренмәгәч, күл эчендә куас сатып утырган хатын янына барып, юынтык суда аунап яткан бетон кисәген көч-хәл белән куптарып алды, күтәреп килде һәм бер кырые белән генә газета читен бастырып куйды.

— Ярык баш! Әллә ычкынгансың инде? — дип битәрләде тегене кипшенгән әби. — Куйма дим, пычрак бит ул! — Һәм иренмичә, урыныннан күтәрелеп, кайдадыр кибет артындагы төзелеш мәйданыннан тап-таза кирпеч күтәреп чыкты.

— Күпме гомер пычрак суда аунап яткан бетон бит ул! — Һәм бетон кисәген көч-хәл белән урыныннан шудырып, газетаны кирпеч белән бастырды. — Менә, ичмасам, булды!

Икесе дә, иске позицияләрен алып, бер мизгелгә тын калдылар. Офыкта сатып алучылар шытып чыгарга уйламый да иде.

— Нәрсә, син үзең китергән кирпечне бик чиста дип уйлыйсыңмы? — диде күзлекле. — Аңа кемнәр генә төкермәгән дә, кемнәр генә сугармаган һәм кәкәй итмәгән?! — Һәм ул кирпечне куас сатучының күленә томырды.

Куас сатучы авызларын чалшайтып бик каты сүгенде һәм йодрык күрсәтте.

Кипшенгән әбинең күзләре акаеп каткан иде. Гүя аның тын юлына сөяк аркылы торган иде.

Күзлекле үзенең бетонын яңадан урынына китереп куйды:

— Мин аны гына сайлый беләм инде, дускаем!

— Ә-әй, синең белән сату итеп буламы! — Кипшенгән әби пырт итеп урыныннан йолкынды һәм җиләген күтәреп

юл аша завод капкасы каршына китте. — Минем яныма киләсе булма! Менә кайт кына әле, мин сиңа күрмәгәнеңне күрсәтермен!..

— Сез газета алмыйсыз мәллә? — диде миңа арттан кемдер, касыгыма төртеп.

Баксаң, әбиләр белән мавыгып, мин чиратымның килеп җиткәнен дә сизми калганмын икән.

*26 август, 1974 ел*

## МИЛИЦИОНЕР ҮЛЕМЕ

*Композитор Зиннур Гыйбадуллин үтенеченә*

Кырык ел гомерен милиция хезмәтенә биргән Сәлах абзый тирә-як җиргә төшеп җитмәстән боз булып каткан февраль иртәсендә, пртакул аныклыгы белән әйтсәк, җиде сәгать илле җиде минутта, якыннары өчен ыгы-зыгысыз, мәшәкатьсез рәвештә, киресенчә, парадка баргандай елмаеп китеп барды. Ликбез заманнарында, мич аралары-коридорлары белән исәпләгәндә, биш сыйныфны көч-хәл белән тәмамлап, совет милициясенә очраклы килеп юлыккан, сугыш фронтларын үткән, үз тырышлыгы, акылы, хезмәттә бәдавамлылыгы нәтиҗәсендә гади постовойдан җинаятьләрне ачу бүлеге башлыгына кадәр күтәрелгән, районның «Коммунизмга» газетасе язуынча, «җәмәгатьчелекнең тынычлыгы хакына үз-үзен аямаган», җинаятьчеләрнең имансыздан да имансыз, ташбашларыннан да ташбашларына каты бәгырьле, нахакка эләккән, риясыз, фидаиләргә карата теләктәш булып, үлчәнми әйтелгән сүз өчен баш киткән теге хәтәр заманнарда дистәләрчә кеше гомерен саклап калган, инде, шул ук газит язуынча, «лаеклы ялга чыгып», район үзәге Әлшәйдә тыныч кына яшәп яткан Сәлах абзыйның, аңлыйсыздыр, дуслары да күп, дошманнары да җитәрлек иде.

Өстенә ак җәймә ташланган көзгедә куерып, көн кичкә авышканда, мәрхүмнең баш очында утырган бабайларның догасын бүлеп, урта бүлмәгә аякларына таш табанлы авыр чүсинкиләр, өстенә җиз каптырмалы озын кара тун, башына бүреген батырып кигән, аның колакчыннарын исә ияк астына төшереп, аерым бер иҗтиһат белән томалап бәйләгән Ямалетдин килеп керде:

— Саумы, иптәш Кәримов! — дип сәлам бирде ул мәрхүмгә. Әллә аңардан сәламенә каршы сәлам ала алмагач, әллә шуны ала алмавына куанып, ул ат абзарындагы сыман иркен һәм бәйсез хәрәкәтләр белән кулындагы йомры башлы таягын караватка ыргытты. Таяк авыз эченнән «Әмәнтү»

догасын пышылдап утырган Бикасап картның тезенә килеп бәрелде дә шакылдап идәнгә төште. Ямалетдин өчен бу кайгылы куышта беркем дә юк иде шикелле. Әллә ул кешеләрне күрергә, аларның барлыгын исәпкә алмаска тырыша идеме? Ул мәрхүмнең берсе-берсенә төкәтеп куелган ике өстәлгә куелган гәүдә тирәсен, шундагы урындыкларны дөбер-шатыр китереп урап чыкты да, чукрак сыман, уң кулын бүрек колакчынында тоткынлыкта булган колагына куеп, тирәякны тыңлады, аннан, җитмеш яшькә җитеп, әле дә, Аллага шөкер, карчыгадай үткер, күрсәләр дә күрмәгәнгә салышкан күзләре белән мәетнең йөзенә кадалды:

— Китеп бардың, ызначит, иптәш Кәримов?! Шулай, эш тә бетә, баш та китә, иптәш Кәримов! Синең дә урамга сыймаган чакларың бар иде, иптәш Кәримов! — Халык сөйләвенчә, көне-төне зирек суы эчеп, канын бозган һәм, фронттан котылып калып, сугыш елларында солдаткаларны чиратка салып яшәгән, сугыштан соңгы елларда ат урлау, гомумән, угрылык белән көн күргән, ниһаять, кара төннәрнең берсендә Түр урманнары уртасында урланган аты-ние белән Сәлах кулына кабып, биш ел утырып чыккан Ямалетдин, бүген килеп, «мильтон Сәлах»тан шулай үч ала иде. — Картлар килгәлиме соң? — Тавыш-тын ишетелмәгәч, кешеләрне тагын да күрмәмешкә салышып, кычкырып эндәште. — Ә-әй, бармы соң бу йортта адәм заты?

— Ба-ар, Ямалетдин, ба-а-ар, — диде аның янында яшь тал кебек тынсыз басып торган Сәрби җиңги, мәрхүмнең җәмәгате. — Аллага шөкер, өебездән кеше өзелми...

— Әйдә, утыр, Ямалетдин, безнең белән дога кыл, — диде картлардан кемдер.

— Кая ди монда утырып торырга?! — дип эләктереп алды үз гомерендә дога кылуның нәрсә икәнен белмәгән Ямалетдин, бик тә эшлекле кыяфәт белән. Аннан идәндә карлы пималарыннан коңгырт эзләр калдырып йөренгәләде. — Эш күп, җәмәгать! Иптәш Кәримовны кабергә тапшырасы бар, әйе! Күрегез инде, үләр көнен дә тапкан бит, ә? — Ул шаркылдап көлгәндәй итте һәм, яхшы ат кебек, авызын һавага шакарды, чишелмәгән бүрек колакчыннары арасында бүре тешедәй эре черегән тешләре саргаеп яктырды. — Тышта кырык градус салкын. — Ишетсен дигәндәй, иелә биреп, ул, борылып, мәет тарафына кычкырды. — Иптәш Кәримов, сиңа кабер дә казып булмый! — Аннан үкенгәндәй итеп уфырды. — Хәер, син хәзер ишетмисең инде... Җир ике метрга туңган, мин сезгә әйтим... Ун кеше көне буе нибары сиксән ике сантиметрга гына төшә алдылар. Аптырагач, бораулы «Беларусь» тракторы алып килдек, иптәш Кәримов. Нибары алты тишек тишүе булды, боравы шартлап сынды, иптәш Кәримов!

Үлгәннәр өчен гомер дигәнең чиксезгә әйләнсә дә, тереләр өчен һәр үлем вакыт кытлыгы алып килә. Вакытның нәкъ менә шундый кытлыгында, өйнең алгы ягында, әтиләре әле урын өстендә яткан чагында хәбәр алып, аның белән бәхилләшергә дип, кайсы кичә, кайсы төнлә, кайсы бүген көндез — мәрхүмнең җан тәслименнән соң кайтып төшкән балаларыннан, оныкларыннан үзенә күрә бер тәшкилят оештырып, әниләренең һәм картәниләренең ахирәте Ләйлебәдәр карчык тешсез авызларын ләштер-лөштер китереп сөйләнә иде:

— Бигрәк кенәләр дә изге җанлы кеше иде Сәлахетдин мәрхүмкәем!.. Әлхәмдү лилләһи раббил галәмин... Караңгы гүрләрен фәрештәләр яктыртсын! Ярабби Ходай... Хәтергә төшкәндә сөйлим әле, балалар... Хәзер бит аның хәтер дигәне дә крылуска әйләнде... — Гомере буе Ишле авылында яшәп, моннан ун ел чамасы гына элек өлкән улына — Әлшәйгә күчеп килгән Ләйлебәдәр әбиләре башка очрашуларда «склероз» кебек чит-ят сүзне шулай матур, зиһен җитмәслек итеп «крылус»ка әйләндереп әйтсә, алар, әлбәттә, шаркылдап, шаркылдап кына дисезме, тәгәрәп-тәгәрәп көлгән булырлар иде. Әмма сәгате бу түгел. Нишлисең, яңача белем алалмаган, әмма дөнья сәясәтен безнең күп кенә прафисырларыбыздан тирәнрәк белгән карчык читләрнең ялтыравык сүзләрен шулай оста итеп чишендерә, үзенчә киендерә һәм иң зыялы кешеләребезне дә ушсыз калдыра белә. Аның телендә генә шулай гүзәл итеп прополис «првәлис»кә, Штирлиц «шприс»кә, склад «ышклад»ка, мультфильм «лутфильм»гә, наркомат «наркоман»га, Мичурин «бичүри»гә, Меркурий «миркорый»га әйләнә. Балалар бүген көлмиләр. Аларның йөзендә бүген тирән хәсрәт...

— Әтиегез ифрат кыналар да һәйбәт кеше иде, балалар! — Ышандыру көче тагын да көчлерәк булсын дип, күрәсең, ул башын дерелдәтеп, астан югарыга чөйде. — Адәм башы черек бәрәңгедән дә очсыз торган чорларда, әйе, шундый әтбитстбиннәй эшләрдә эшләп, беркемне дә рәнҗетмәде. Мин аны беренче тапкыр Миякә үзәлэтерендә күрдем. Ул шунда миннән дапрус алды. Халхузда бәрәннәр карый идем... Ирем Хәйдәр, авыр туфрагы җиңел булсын, фруntta... Өйдә анадан тума өч бала. Берсе бишектә, икесе ишегалдында, ыштансыз күтләрендәге чалабашка агач мылтык асып, шарт-шорт килеп, кулакларны атып йөриләр. Испәлнител килә. «Әйдә, сине кәнсәләргә чакыралар. Бик зур кешеләр килгән». Барам.

— Җиңги, — диләр монда районнан ук кубарылып килгән әллә кемнәр. — Нигә салымнарыгызны түләмисез? Аңлыйсызмы, сезнең салымнарның түләнмәве аркасында гына сугыш һаман бетми тора!..

— Хәйдәр абыегыз фруntta сугыш бетәрлек кенә акча

эшлидер әле, — дим. — Нәрсә, лакандагы черек бәрәңге кабыгы белән түлимме мин аларны?

Бер атна вакыт биреп, кисәтеп һәм янап, кайтарып җибәрәләр, һич кенәләр дә онытмам. Урак өсте. Басулар тулы көлтә зуратлары. Ферсидәтелгә берәр пот арыш сорап бардым. «Фрунт иген көтә, Ләйлебәдәр җиңги, — ди бу. — Фрунт заданиесен үти алсак, бирербез». Шул көннәрдә җизниегезнең үлем хәбәрен алдым. Хәзер инде силсәүит Талип чакырта. Җизниегезнең батырларча һәлак булуы хакына берәр жалунья, пасуби кебек нәмәстәкәй бирәләр икән бу дип йөгереп барам. Әмма төнгә каршы бу. Нигә пасубине төнгә каршы бирәләр? Шунда ук авылның агач каммуны Ибрай. Аннан тагы ике кәнтәй... Ничек әле? Көндез эштә, кич хлупта, дип җырлыйлармы? Нәкъ әнә шул көндез эштә, кич хлупта була торган ике камсамун кыз, тфү-тфү, әйттем исә кайттым, авыл кәнтәйләре!..

— Фрунтта синеке генә кырылмый, Ләйлебәдәр җиңги, — ди миңа Талип, чыпчык күзен чекрәйтеп. — Барыбызныкы да кырыла. Салымнарыгызны кайчан түлисез?

— Кырылмый шул! — дим мин, ачуымнан чәчрәп чыгып. — Ышталин чуен базда качып яткач, бер дә кырылмады әле, безнеке генә кырылды!..

Шуннан нәрсә булды дисезме, бәбкәйләрем? Бүлмәдә асылынып торган Маркыс, Ингелес, Лилин, Ышталин фәртритләре алдында таяк кебек катып калдылар болар. Шартлатып бикләп алдылар ишекне. Каммун Ибрай шылтыратты Миякәгә. Тыштан сак куеп, калдырдылар мине төн кунага. Таң белән гыпыудан бер яшь егет килде. «Минем белән балаларымны да алыгыз, — дип җылыйм. — Аларны монда кем карар?» «Сәвит влачы мәрхәмәтле, — ди бу миңа. — Ул ятим итмәс! Без аларны барыбер хунтра кулында калдырмаячакбыз!»

Алып киттеләр мине Миякәгә. Бер атна утырдым мин үзәләтердә. Көне-төне дапрус бара. Соңгысында — өчәү. Араларыннан берсе, чәчен кыска итеп алдырганы, кара-кучкыл йөзле, каш өстендә миңе дә бар, миңа мөлаем карый төсле. Эчемә җылы кереп китте.

— Син Ышталинны хурлагансың, — ди боларның бер битсезе. — Дөресен әйт, хурладыңмы?

— Юк, Ышталинга мин әшәке сүз әйтмәдем, — дим. — Салымын да түләр идем, лакандагы черек бәрәңге кабыгына кадәр алып чыгып киттеләр. Ирем фрунтта һәлак булды. Өйдә өч балам ач утыра. Зинһар өчен, балаларым хакына коткарыгыз! — Үзем җылыйм, җылыйм!

Болар күрше бүлмәгә чыгып китәләр. Киңәшкә-мазарга, күрәсең. Күп тә үтми, минем янга әнә теге мөлаем кеше ке-

рә. Кара-кучкыл йөзле, каш өстендә миңе дә бар, бу хакта әйттемме, балалар?..

— Бар, җиңги, кайт, — ди бу. — Монда булуың турында беркемгә дә сөйләмә, ярыймы? Үзеңне җәберләүчеләргә дә каршы эндәшмә. Балаларыңны сакла, авылны да ташлама...

Ул кеше сезнең әтиегез һәм картәтиегез иде, балалар! Авыр туфраккайлары мамыктай җиңел булсын!..

Минем нинди тизлек белән үзәләтердән чыгып йөгергәнемне һәм нинди тизлек белән, егерме чакрымны йөгереп, Ишлегә кайтуымны күз алдыгызга китерәсез микән, бәбкәйләрем? Эрәкитә инде, эрәкитә!.. Шул котылуымнан котылдым да... Балаларымны да үстердем, Аллага шөкер. Барысы да исән-саулар. Авылны да ташламадым. Югыйсә Ташкин якларына чыгып таярга дигән уй да юк түгел иде...

Алгы яктан чүмәлә сыман караеп, кара туны белән артыннан төнне дә өстерәп һәм таягы белән идәнне чукып, Ямалетдин килеп чыкты:

— Ничек күмәбез? Борынгычамы, әллә сәвитчәме? Ни дисәң дә, районның пачутлы мильтоны бит ул...

— Борынгыча булыр инде, Ямалетдин, — диде чак ишетелерлек итеп кенә Сәрби җиңги.

— Ярар, алай булгач. — Кара пималарыннан эрегән кардан идәнгә ташбакадай эзләр салып, Ямалетдин тупсага таба юнәлде. — Тапкан бит үләр көнен, ә? Тышта кырык градус суык... «Беларусь»ның боравы сынды, мин сезгә әйтим...

Ул чыкты. Өй һавасы сафланып, яктырып калды.

*1995 ел.*
*Уфа*

## САНДУГАЧ БЕЛӘН КАРЛЫГАЧ

*Тимер Арыслан истәлегенә*

Менә шундый-шундый хәлләр, җәмәгать: сез ничектер, без, мәсәлән, печән өстен тәмамладык. Ягъни басыла-басыла, авызы белән җиргә капланган кара чүлмәк рәвешенә кергән соңгы чүмәләне эш бетергән кешеләрчә масаю белән төяп — ул фурман үрәчәсеннән әллә ни күтәрелмәде дә — атыбызны Әнәч кулы түбәсеннән лөрт-лөрт юырта-юырта, без авыл урамыннан Шәрифҗан күперенә килеп кердек.

— Кара әле, анавы матай безнең капка төбенә туктаган түгелме? — диде абзый, күпер төбендәге карт тирәкләрдән уңга борылгач, үз йортын күреп. — Һич кенәләр дә кунак-

санак белән маташасым килми. Якты күздә сине дә Ишлегә чыгарып ыргытасы бар...

Әйе, минем абзыйның күзе очлы аның: бишекле яшел мотоцикл көпчәген безнең рәшәткәгә төртеп туктаган иде. Мине Ишлегә «чыгарып ыргытуы» турында да дөрес сөйли абзыкай. Иртәгә таң тишеге белән Уфага китәргә, аның өчен... Аның өчен тагын бер «аның өчен»не гамәлгә ашыру мотлак: калын урман-таулар аша бездән җиде чакрымдагы Стәрле — Уфа юлында яткан Ишле авылына барып, нәкъ иртәнге алтыда үтә торган автобуска өлгерү мөһим. Шуңа күрә без, мине кичләтеп, Ишлегә, әтиемнең бертуган апасы Бәдриямал әбигә куна чыгару турында сөйләшеп килешкән идек...

Симез бүксәсен сөйри алмас хәлгә килгән сугым казы кебек як-якка янтаеп, чокырлы-чакырлы юлдан тәгәрәгән йөгебезне ихатага бору белән капка эчтән ачыла башлады, аралыктан башына күзлекле яшел мотокаска кигән, шуның белән генә дә бакага охшап торган, әфлисун йөзле, табак битле ят адәм күренде һәм капка канатларын ике тарафка этәреп җибәрде:

— Пжалыст, Иниль Нәҗмиеч!.. Көт-тәбез!..

— Ә-ә-ә, Псих Сәлимгәрәевич икән... Исәнме! — Абзый, йөк өстеннән сәлам биреп, атын лапаска таба юнәлтте. — Әйтәм-мәйтәм, тәм тәмәйтә, кунак бар икән!.. — Аның сүзләре ишегалдына сибелгән ком-таштан шыгырдап тәгәрәгән тәгәрмәч тавышлары астында йотыла иде. — Минем теге ни... Танавым зур булгач, кунак исен әллә каян сизәм, малай!..

Кемнең нигә «псих», кемнең нигә «псих» түгеллеген сорашып торырга форсат юк иде. «Булса да булыр, әмма мондый исем булмас», — дип уйларга гына өлгердем мин. Йөктән сикереп төшеп, кунаклар белән күрештек. Әйе, кунаклар дип күплектә әйтүем дә хак булып чыкты — чөнки шунда ук карлыган бакчасыннан үзара сөйләшә-сөйләшә, ягылган мич белән мунча арасында йөреп йөзләре алсуланган җиңги белән бергә килеп чыккан кырык-кырык биш яшьләрдәге, кечкенә буйлы, балкалагы кебек җыйнак гәүдәле Зәлифә ханым — әлеге, кем әле, тфү-тфү, әйттем исә кайттым! — әйе, әлеге Псих Сәлимгәрәевичнең җәмәгате икән. Алар ихатага әле генә килеп кергәннәр, күрәсең; көн җылы булуга карамастан, әле өсләреннән салып өлгермәгән сырмалары, пардан киелгән бакабаш-мотокаскалары тирәсендә сәфәр җилләре бөтерелә иде...

— Күптән күрешкән дә юк, Иниль Нәҗмиеч... — Ир майлы карашы белән абзыйга текәлде. — Аннан... үзең беләсең, кем йомышсыз — шул тормышсыз дигәндәй, синә бер йомыш та килеп чыкты әле, ызнаһит!..

— Йомышың без генә йомышларлык йомыш булса,

йомышлыйбыз аны, Псих Сәлимгәрәевич. — Гадәттә кешенең җисеменә түгел, исеменә дә таләпчән абзый мине сәерсендергән «Псих»ны инде бу юлы да авыз тутырып кабатлады. — Билгеле, тырай тибеп йөрмисеңдер...

Атны тугарган арада мин чынлап та аптырашта, бәлки, үз гомеремдә беренче тапкыр телсез хәлдә идем: әгәр мәҗлес артында да утырырга туры килсә, миңа, җәелеп китеп сөйләшергә яраткан каләмкяргә, бу адәмзатка «Псих» дип мөрәҗәгать итәргә туры килер микәнни, билләһи газыйм?! Исемме бу, әллә тагылган кушамат, ләкап кенәме? Аннан... «Сәлимгәрәевич» бит әле, шайтан алгыры. Үзенә күрә берәр урындагы, әллә урыныннан очкан түрәме? Минем абзыйны, инде менә егерме елдан артык бригадир булып эшләгән кешене, авылдашлар ихтирам белән «Нәҗмиевич» дип йөртәләр. Хәер, тәүге чорда ул моңа ярым шаяны-ярым чыны белән үзе дә мәҗбүр итә иде. Әйтик, әгәр кемсәләр: «Иниль туган, Иниль энекәш, Иниль», — дип, кулларын иңгә сала башласалар, ул: «Мин сезгә Иниль туган түгел, мине гади генә итеп Иниль Нәҗмиевич дип йөртегез», — дип шып туктата иде. Ә бу кем? Җәфалы уйлардан мине тагын да камыт-ыңгырчакларны чөйләргә элеп маташкан абзый коткарды:

— Ничек соң, Псих Сәлимгәрәевич, урман үсәме?

— Үсми кая барсын ул? Урман — фурман түгел, тәгәрмәчсез! — Ир сирәк япун тешләрен ыржайтып көлде. — Урынында безләрне көтеп утыра... Нәкъ җырдагыча:

Урман шаулап үсә,
Псих сатып эчә,
Ботаклары кала махмырга...

Ул тагын теш ыржайтып көлде.

Аңлашылганча, ул үз исеменнән канәгать иде. Псих Сәлимгәрәевич район үзәге Кыргыз-Миякәгә терәлеп, соңгы елларда аның белән кушылып ук барган РТС утарында яши, урман хуҗалыгында өлкән техник булып эшли икән.

— Энекәшең тач үзең, ә? Теге ызнаминитый бисәтель энекәшең Зәригәт шушы була инде, ызнаһит? Моның башы — йомырка!..

— Әйе, — диде абзый җавабында, кырыс кына. — Нәкъ үзе. Әйдәгез, өйгә үтик, ник катып калдык?

— Кил әле, Зәригәт кардәш, тагын бер мәртәбә күрешик! — Ул кулымны тартып алгандай алып, шытырдатып кысты. — Мондыен күрешүдән соң кулымны егерме җиде ай юмасам да риза! Ха-ха-ха! — Аннан абзыйга борылды: — Әгәр минем хакта язып та чыкса, ә? — Сары тешләрен кояшта ялтыратып, авыз чите белән генә елмайды да кулын селтәде. — Әй, язса тагын! Хәзер халык барыбер укымый!..

Мин атны бәрәңге бакчасының сазланып яткан урталыгында мүк кебек күпереп үскән кондырак үләнгә тышаулап җибәргән арада ишегалды ягында аларның тавышлары тынды. Кире килгәндә — карлыган бакчасының зәңгәрсу очында хуш исле ыс, күңелгә якын бу аңкытып утырган мунча кырыеннан тыныч кына үтеп китә алмадым. Аһ, авыл мунчасы!.. Көн саен керсәм дә, ике атна буе тозлы тир, печән вагыннан иза чиккән тән ашыктырды — күз ачып йомганчы чабынып һәм юынып, өс-башымны җиңги әзерләп куйган чиста киемгә алыштырып өйгә кергәндә, мәҗлес борынлап кына килә иде әле...

— Әллә мунча да кереп чыккан инде?! — Җиңги урыныннан күтәрелеп, иңемә йөнтәс тастымал салды. — Сөртенерсең. Санаулы көн тиз үтә дигәндәй, туганыбыз белән хушлашыр сәгать тә килеп җитте бит...

— Сәгать?! — Нәрсәдер келт итеп исенә төшкәндәй, ир ярты сүзендә өзелде, аннан серле карашын бер түшәмгә, бер хатынына юнәлтеп, тәүдә аның белән чәкеште:

— Әйдә, сандугачым.

— Әйдә, карлыгачым. — Хатын иренә бетеп карады. — Әйдә, исәнлеккә.

Псих Сәлимгәрәевич, ниһаять, безнең белән чәкештереп, җәһәт кенә эчеп җибәрде. Аның артыннан барыбыз да күтәрдек.

— Сәгать дисең, ызнаһит, Сәгыйдә? Менә бит, кем уйлаган сүзләрнең мәгънәсен, ә? — Ул ниндидер фәлсәфәгә кереп китим дигәндә генә әле эчелгән аракысы, күрәсең, башкалары янына барып җитеп, иснәшеп һәм танышып, карыннан барлык киштә-шүрлекләрен, эчәк юлларын ләззәт белән көйдереп алды, актарды булса кирәк, ирнең әфлисун йөзенә кызыллык йөгерде, кашлары таралып китте. — Әйе, Сәгыйдә, дөрес! Сезнең энекәшегезнең китәр сәгате, безнең кайтыр сәгать җитте... Йомышыбыз да әнә шул сәгать җитү белән бәйле, ызнаһит...

Мин тәмам бернәрсә дә аңламаган гаҗиз хәлдә идем.

— Без бит иң өлкән ядрәбез — Сәгать улыбызны башлыкүзле иттек! — Күңеле йомшарып китеп, ул йөгерек, кечкенә күзләрен челт-челт йомып алды. Зәлифә дә дымланган күз читләрен сөрткәләде. — Безне сиңа китергән йомыш та, Иниль Нәҗмиеч, шул туйга бәйле инде...

Инде бераз аңлашыла төште шикелле. «Өлкән улларының исеме Сәгать булса кирәк, — дип уйлап алдым мин. — Тик нигә... Сәгать? Нигә Минут түгел?»

— Һичтән кич яхшы дигәндәй, әнә шул туйга бер-ике баш сарык сөйләшү өчен Баязитка, Ишлегә барган идек. Сарыклары, малай, ташка үлчим, Маутхаузен әсирләре кебек арыклар. Үзләре, мин сиңа әйтим, маңкалаган, төчкерәләр, ызнаһит!.. Тәкәләре — бүлтерек, сарыклары — ябык!

— Алай ук булмас ла...

— Шулай шул, Иниль Нәҗмиеч. Сезнең «Чулпан»ның сарыклары симез, иткә дә тәмле була, дип ишеткән бар иде югыйсә... Ә, Иниль Нәҗмиеч?

— Мөмкин, — диде абзый бер сүздә. — Идарәдән яздырып куярмын. Ике башмы? — Теге ике бармагын күрсәтте. — Ике баш, безнекеләрне ул кадәр симез дип мактана алмыйм. Шулай да көрләр. Аннан, безнең колхозның печән белән урак өстенә диеп симертелгән тәкәләре дә бар...

— Печкән тәкәләрме? — Ир урынынннан сикереп торып, яңадан утырды. — Вәт-вәт! Нәкъ шуларны әйтәм дә инде мин!..

— Сиңа бүген үк кирәкмидер бит?

Кәефе килгән кунак соңгы сорау алдыннан гына табакта парланып, леркелдәп яткан симез сарык калҗаларын, алар артыннан эре итеп туралган суган телемнәрен сәнәк белән сәндерәгә печән ыргыткан сыман итеп авызына ыргытып өлгергәнлектән, шактый гомер эндәшә алмый тыгылып торды. Хатыны арка үзәген дөп-дөп төеп алгач, ниһаять, ул кабымнарын йотып җибәрде.

— Ю-ю-к... Без әле вәгъдәләшергә генә... Сарыклар артыннан бер атнадан... Син аларга, Иниль Нәҗмиеч, теге... ни... өстәмә азыкны кызганма инде...

— Колхозда булган — алар алдында булыр.

— Вәгъдә-иман, ызнаһит?

— Вәгъдә-иман.

— Килештек.

Алар кул бирештеләр.

— Сарык малын йөртергә кирәк аны... Йөртсәң, ите дә тәмле була. — Абзый яңадан аракы койганда сүз ара сүз өчен генә үз белеме белән уртаклашып алырга булды, күрәсең. — Вак мал эре малга караганда ике мәртәбә күбрәк төр үлән ашый, Псих Сәлимгәрәевич. Сарык, мәсәлән, йөз дә утыз алты төр үлән кимерә. Еланны да яратып ашый ул. Аның иң яраткан азыгы — елан!..

Псих Сәлимгәрәевичнең карынында нәрсәдер айкалды. Аның зур күзләре тирә-якны урап чыкты. Алдындагы аракысын чәкештереп тә тормыйча эчеп җибәрде.

— Кит аннан! Кичә үлгән булсам, бүген белмәгән булыр идем! — Абзый җибәргән «елан»ны яшел елан белән баскач, ул йөгерек, майлы карашы белән яңадан түшәмне ялап алды да сүзгә кереште. — Иниль Нәҗмиеч, сөйләнгән сүз яланга, эшләнгән эш яманга чыга күрмәсен. Йомышны йомабыз, изнаһит. Сатып алсаң да, үзең аңлыйсың, хәзерге кешенең бит аның авызына шайтан төкергән — пычратырга, берсен-берсе кабып йотарга гына тора, малайкаем. Менә бездә, ыртыеста, халык дигәнең ифрат та тәртипле, эшкә батыр, төскә

матур иде... Менә шул эшкә батыр, төскә матур халыкны... юк, юк, аракы да, совет власте да, компартия дә түгел, дүрт пешкәкле гади бер мотор эштән чыгарды, мин сиңа әйтим. Әнә шул мотор — механ-ни-за-ция аркасында авыл халкына эш җитми. Дөресме? Шуңа күрә ул тапкан малын эттән, аркасын беттән ашатып, бер-берсеннән үч ала, бер-берсен сата, сыта, ашый башлый, ызнаһит. Усаллык шуннан башлана, Нәҗмиеч. Менә мин егерме баш умарта тотам, әй-йе диген. Әй-йе. Әйтегез әле, бал кортлары кешене кайчан чага? Йә артык корылыклы, йә артык яңгырлы елда гына чага алар. Чәчкәдә ширбәт тапмаганга күрә хәрәкәттәге һәр нәрсәдән үч ала, ызнаһит. Чәчкәдә нектар булса, ул сиңа ыжлап та бирми — әйдә, шалтырмаларыңны шалтыратып, умарталыкта шәрә-бака утыр — якын да килми ул сиңа! Чөнки аның эше бар!..

— Син бераз арттырып җибәрмисеңме, карлыгачым? — диде Зәлифә, чак кына ишетелерлек итеп.

— Нинди арттыру ди монда? — Псих Сәлимгәрәевич, хатынына үтеп барышлый гына кыек караш ташлап: — Бәй, ышанмасаң, чишенеп ташлап, умарталыкта утырып кара, сандугачым!

Без бердәм көлешеп алдык.

«Значит» сүзе «ызнаһит» булып яңгыраган бу кеше миңа чынлап та ошый башлады. Мин кунакларыбызга беренче мәртәбә игътибар белән карадым. Бу мизгелдә минем өчен алардан да мөлаем кеше юк кебек күренде. Буйга хатыныннан ике башка өстен, киң маңгайлы, ничектер изелеп, йөзенең яртысын биләп торган җемшек танаулы, сирәк сары тешле, сүзгә килгәндә эчендәге тышында булган ир бу минутта үзен бик тә бәхетле тоя иде бугай; хатынының тешләре кайрак белән кайралгандай ак, уң күзе бераз гына кылый икән; әмма бу кылыйлык уймак кебек җыйнак гәүдәле Зәлифәнең түгәрәк йөзенә гарип җитешсезлек түгел, киресенчә, — иң сәере дә шунда! — тирән, яшеренеп яткан моңсулык, нindидер кызгандыручан камиллек һәм теләктәшлек өсти; ул кешегә турыдан текәлеп һәм чәнчелеп карамый, бәбкәләрен саклап йокымсыраган каз кебек, күзләрен җәһәт кенә ачып һәм ябып ала. Бу мизгелдә аның күз кырыйларында коңгырт сөрмә, куе моңсулык чагыла.

Дөресен әйтим, мин алардан көнләшеп тә куйдым. Инде егерме биш-утыз еллап бергә гомер кичергән, балалар үстереп, ачысын-төчесен бергә татыган ир белән хатынның әле һаман бер-берсенә яшь-җилкенчәкләрчә «сандугачым-карлыгачым» дип эндәшүләре мине бөтенләй буынсыз, һушсыз иткән иде. Гадәти бер авыл гидае, сала йолкышы дип уйлаган «ызнаһит» абзыеңны, кара әле, — карашы майлы булса да, фикере саллы бит!..

Җиңгинең чәе инде икенчегә актарылып кайнап чыкты.

Мунча-мазар онытылды. Өстәлгә башлы суган туралган бишбармак та куелгач, аннан, гадәтенчә, абзый үз тәлинкәсенә бер балкалагы кара борыч та тондыргач, өй һавасы, борынны кытыклап, сөйләшүне фәлсәфәлерәк ызанга юнәлдерде. Анда җиңелчә сәрхушлык, тормыштан кәнагатьлек тойгысы хөкем сөрә иде. Бу тойгыны тагын да үстереп җибәреп, төп кунагыбыз әфарин тәкъдим итте:

— Хәзер гәзитләрдә ничегрәк язалар әле? Хуҗабикә, диләрме? Төчерәк инде ул, кәнишне... Хуҗабикәбез Сәгыйдә хөрмәтенә, ызнаһит! Өендә — тәртип, табынында — муллык, ире, янагасы — янында!..

Җиңгине үз алдында мактауларын бик өнәмәгән абзый чәкешергә дип кулын сузган Псих Сәлимгәрәевичне туктатты:

— Зәлифәнең Сәгыйдәдән кайсы җире ким? Әйдәгез, хатын-кызлар өчен!..

— Килеш-шәм, Иниль Нәҗмиеч... Хатын-кызның барысы бер инде аның, тик мышнаулары гына төрле... — Ул җырлап җибәрде:

Атыгыз бурлы икән, йөгәне фурмы икән,
Мәкнең ал чәчкәсе кебек, йөзегез нурлы икән...

Без чәкештереп эчеп җибәрдек. Мине кичләтеп, дөресрәге, хәзер үк Ишлегә чыгару турында сүз чыккач, кунак абзыйны чын күңеленнән тирги башлады:

— Син моны, Иниль Нәҗмиеч, чынлап сөйлисеңме? Әллә мине кешегә санамыйча үпкәләтер өченме? Шушындыйлар да зур, укымышлы кешене, күз карабыз кебек карап торган бисәтелебезне... колхозның арык алашасында? Дыңгырдык арбасында? Ишлегә? Ха-ха-ха!.. Юк инде, ызнаһит. Үзебез белән алып китәбез. Шулай бит, сандугачым?

— Дөрес, карлыгачым! — диде Зәлифә, җанланып китеп. — Бу бит безгә — мәртәбә! Кунак итәрбез!..

— Аллага шөкер, тормышыбыз җитеш. Бер ун кило бал да алып китәр күчтәнәчкә!

— Анда, Ишледә, кем аңа чиста түшәк сала? — диде хатын.

Алар миңа алмаш-тилмәш көнкүреш хезмәте күрсәтә башлады:

— Кипкән гөмбә яратасыңмы? Кипкән гөмбә, чия, как!..

— Иртән кайнар аш белән тамагын туйдырыр, ичмасам... Юл кешесе аны да сирәк күрә!

— Иртәнге алтыга мин аны үзем тукталышка чыгарачакмын һәм утыртып җибәрәчәкмен. Шоферлар барысы да үземнеке минем. Килештек, ызнаһит?

Бал һәм кипкән гөмбәләрне калдырып торган хәлдә дә, миңа бу тәкъдим бик кулай күренде. РТСка барсам, беренчедән, минем юл утыз чакрымга алга сикерә. Икенчедән, печән

өстендә эт булып арган абзыйны һәм атны кара төндә җәфалап йөрисем килми иде. Өченчедән, синең өчен шулай өзелеп торган укучыларың бар чакта...

— Килештек, — дидем мин. — Сезнең белән китәм.

— Үзеңә кара, — диде абзый, тыныч кына. — Югыйсә Ишле әбине мин үзем дә күреп кайтырмын дигән идем...

— Ишле әбиеңне башка вакытта да күрерсең әле! — Псих Сәлимгәрәевич тәмам канатланган иде. — Илле ат көчле мотор барда синең бер атыңа әсир төшмәбез!..

Кичке шәфәкъның тәрәзәгә төшә башлаган алсу нурларын абайлап һәм вакытның кыса баруын чамалап, мин кунакка үземне баядан бирле борчыган сорауны бирергә булдым:

— Әйтегез әле, сезнең исемегез чынлап та Психмы?

— Нигә аптырыйсың аңа? Тапкансың аптырар нәрсә! — Псих Сәлимгәрәевичнең болай да җәйпәк танавы, тагын да җәелеп китеп, бөтен битен тутырды. — Габдулла белән Александрлардан аның ни ким-хуры бар? Минем әле партбилетым да үзем белән! Менә!.. — Ул кесәсеннән кызыл кенәгәсен өстәлгә шап итеп чыгарып салды да ялт итеп тыгып та куйды.

— Мин аны мичкә ыргыттым, — диде абзый, авызын бераз чалышайта төшеп.

— Аны мичтән кереп ала торган көннәр килер әле, Иниль Нәҗмиеч... Ха-ха-ха! — Кунак, күзләрен тәгәрәтеп, миңа килеп туктады. — Әйе, исемем чын, Псих мин! Фронтка китәр алдыннан әти кадәр әти калдырган исемне ниндидер домкрат-демократлар көлә дип үзгәртергә хакым бар идеме минем? Юк иде!.. Үзгәртмим дә, кирәкми дә... Минем чын исемем, ызнаһит, паспорт буенча — Психология. Гарифуллин Психология Сәлимгәрәй угылы булабыз. Юк, ниндидер наданнар аңлавынча, килде-китте, дуамал дигән мәгънәдән түгел... Син укыган, җитмәсә, бисәтель кеше, төшенәсеңдер, «Кеше җаны турында фән» дигән мәгънәдән алынган ул. Псих-хо-лог-гия!.. Ызнаһит, мин кешенең җаны!.. Аннан, айда җен-пәриләр түгел, адәм балалары йөреп яткан заманда безнең татар һаман да шул Габдулла, Сәмигулла булып кала алмый, ызнаһит!.. Кеше исеме заманча ор-ри-гин-наль булырга тиеш. Менә без сандугачым белән... — Ул хатынына үтеп барышлый гына кыек караш ташлап, инде очышта майланып өлгергән карашы белән түшәмне лач ялап алды. Үзенә ниндидер яңа фикер килгәндә ул югары даирә — түшәм белән киңәшләшә иде. — Кыз-кыз дип тырыша торгач, биш малай алып кайттык. Аларның исемнәре ничек, беләсезме? — Башына ярыйсы гына китеп өлгергән Псих Сәлимгәрәевич аерым бер канәгатьлек белән бармакларын бөгеп дәвам итте. — Өлкәненекен әйттек — Сәгать. Берме? Бер. Аның энекәше — Музсәгать. Ике. Музсәгатьнең энекәше — Минут. Өч. Ми-

нутның энекәше — Секунд. Дүртме? Дүрт. Секундның энекәше — Стрелка. Биш! Менә минем улларымның исемнәре. Алар барысы бергә кешелекне йөртә. Үзем куштым! Ник-кому не позвол-лим! — Псих Сәлимгәрәевич алдындагы тулы чәркәсен авызына аударды.

— Белмәгән идем, — диде абзый. — Кызык бит бу, ә?

— Әйе, үзе кушты, — дип өстәде Зәлифә. — Кызлар туса, мин кушармын дип сөйләшкән идек... Әмма тумады.

Җиңгинең чәе инде өченче катка актарылып кайнап чыкты.

— Кеше көлә, имеш. Төкерәм мин надан кешеләргә! — Ул карашы белән тагын түшәмне ялап алды, һәм бу караш бер мизгелгә түшәмгә ябышып катып калды. — Кеше сүзенә карап яшәсәң, иртән намаз, кичен намаз — каккан казыгың калмас...

Куера барган шәфәкъ нурлары пыялаларда сынып, без утырган бүлмә эче караңгылана да башлады. Урам тарафыннан бәәлдәп һәм мөгрәп ихата эченә килеп кергән малның ачык тәрәзә аша үҗәтләнеп кергән тавышы белән кайнаша иде ул хәзер.

Кунакларга «инде китсәгез дә ярар» дип әйтергә кыймаган хуҗалар көтү каршылау мәшәкатьләреннән кыбырсый башладылар. Шуны сизгән Зәлифә дә борсаланып куйды:

— Кузгалыйк, карлыгачым. Балалар көтәдер...

Эчкән аракысы күзенә дә чыкмаган, ап-айнык күренгән Псих Сәлимгәрәевич артыннан барыбыз да урыннан күтәрелдек. Өстемә үзем киеп кайткан ак күлмәгемне, костюмымны киеп, җитмәсә, муенчак-галстугымны бәйләп, кулыма күчтәнәчләрдән бераз бүлтәя төшкән портфелемне тотып урамга чыктым. Җилдән саклану өчен өсләренә җылы сырма, башларына мотокаскалар киеп алган кунаклар инде яңадан бакага охшап, мотоциклга оялап өлгергәннәр иде. Костюм өстеннән ниндидер җилән сыман нәмәстәкәй белән капланып, мин арткы ияргә менеп кунакладым. Псих Сәлимгәрәевич утырган уңайдан бер талпынуда ук «Урал»ны кабызды һәм без урам буйлап акыра-бакыра, иңри-мөгри кайткан көтүне, сигнал белән урталай ярып, соңгы елларда ташландыкка әйләнгән туры юл тарафына — авыл очына таба юнәлдек.

Безнең авылдан чыккач та өч үр бар. Кырлыган инешеннән соң, беренче үргә борылгач та — ни гаҗәп! — мотоцикл көпчәкләре күрер күзгә генә коры күренгән юлдан тая, чалулый башлады. Баксаң, без мәҗлестә утырган чакта җәйге, адашкан яңгыр, авылга кермичә генә, бу тарафны ярыйсы гына пешереп киткән икән. Калкулыкның иң текә тәңгәленә җиткән төшендә көпчәкләр бер урында чын-чынлап, хәтта кирәгеннән артык зырлап әйләнә башлады. Яшен тизлеге белән сикереп төшеп, аяк савытларым таюдан, урынында аяклана алмаган бозау шикелле, җәфалана-җәфалана, болай

да авыр, җитмәсә, ике гәүдә дә кунаклап алган мотоциклны эткән арада, шунысына да аптырарга өлгердем: әле генә апаек күренгән Псих Сәлимгәрәевич инде минем алдымда күзгә күренеп җепши, муртая, исерә иде; рульне каты тота алмаган куллар, юнәлеш бирә алмаган беләк мускуллары, үзләренең ирек бәясен югалтып һәм чокыр булмаган җирдә чокыр табып, әлсери һәм бәлҗери иде...

Икенче үрдә миңа инде сигез мәртәбә сикереп төшәргә, ләмгә батып һәм җен кыяфәтенә кереп пычранып, сигез мәртәбә мотоцикл этәргә, артта этүче барлыгын онытып, мине ташлап ук китүче Псих Сәлимгәрәевичне куып җитеп, сигез мәртәбә ияргә атланырга туры килде.

— Хәлләрең ничек, сандугачым? — диде Псих Сәлимгәрәевич, икенче үр түбәсендә хатынына борылып. — Хәлләрең ничек, сандугачым?

Ничәнче кабаттыр — җавап әзер иде:

— Әйбәт, карлыгачым!..

Безнең моторның өченче, соңгы һәм иң текә үрдәге гөрелдәве бөтен Җир шарын яңгыраткан булгандыр, күрәсең. Бер адым алга өстерәлеп, ике адым артка шуышып, үкереп һәм гүләп, тирләп-пешеп, без, ниһаять, Гималай түбәсенә менеп җитә алдык.

— Хәлләрең ничек, сандугачым?

— Әйбәт, карлыгачым!..

Халкы ташлап киткән һәм исеме генә калган кахул авылы Хлеборобка җитәрәк, сазланып яткан чокырда без, әлхәмдеки шөкер, тәмам баттык. Мотор сүнде. Ир белән хатын, таушалган-талчыккан, аракыдан изрәгән гәүдәләрен көч-хәл белән урыннарыннан бушатып, җиргә аяк баскан арада, мин авыр уйларга баттым. Нишләргә? Төн җитеп килә. Алда — егерме чакрымлык калын урман, канауга әйләнгән ташландык юл. Әгәр таң белән китә алмасам, бик тә җитди эшем өзелә бит!

— Әйткән идем мин сиңа, сандугачым, бу юлдан китмик, дип, — диде хатын. Аннан, мине күреп, бот чапты. — Кара әле, монауны! Бисәтель!..

Куерып җиткән караңгыда үз вазифасын аз-маз булса да үти алган мотоцикл көзгесеннән йөземне чамалап аһ иттем: Кафтау арты җеннәре дә минем белән ярыша алмас! Өс-башны инде карыйсы-нитәсе юк — чучка, дуңгыз инде дуңгыз, хряк!..

Бераз читтәрәк тышка чыгып азапланган Псих Сәлимгәрәевич, чалбар изүен каптыра-каптыра, мотоцикл катына килде.

— Нәрсә дидең син, сандугачым?

— Моннан кайтмыйк, дип әйткән идем бит мин сиңа... Бераз салып алсаң, кеше сүзен бер дә тыңламыйсың!..

— Син кайчаннан бирле этнекен чәйнәп йөрерсең икән? —

Псих Сәлимгәрәевич ашыкмыйча гына миңа таба борылды. — Борай якларына кияү дә булма, кәләш тә алма, кардәш!..

Һәм көтмәгәндә генә янә борылып, хатынын сугып очырды.

— Сбулыч! Падлы! Сбинжә! Әтәлге!.. — Хатын үксеп елый башлады.

Киемнәре белән чаштыр-чоштыр килеп, сазда бата-бата, яшел мотокаскасы тәмам караеп күренгән бакабаш Псих Сәлимгәрәевич ажгырып хатынына килә башлады.

— Юк, юк, якын килмә! — Ире белән тигез эчкән, авызыннан аңкыган суган һәм хәмер исе белән бөтен яланны тутырган сандугач карлыгачы алдына сыгылып төшеп инәлде. — Керфегемнең бөртеге син! Керфегемнең бөртеге!..

— Туктагыз! — дип кычкырдым мин, аларны аерырга тырышып. — Туктагыз! — Аннан, көтмәгәндә генә без килгән яктан, Каенлык урманыннан чыгып, авылга таба борылган печән йөге күреп, мотоцикл бишегендәге портфелемне эләктереп алдым да, әллә алдагыларга, әллә арттагыларга кычкырганымны белми-шәйләмичә, кирегә йөгерә башладым:

— Туктагыз! Туктагыз!..

Артта аңламыйлар, алда ишетмиләр иде.

Ниһаять, куып җитеп, портфелемне ыргыттым һәм бастырыкка асылынып, үзем дә йөк өстенә үрмәләдем. Йөкче сугыштан саңгырауланып кайткан Зәйни абзый булып чыкты. Хәтта куерып җиткән караңгыда да минем җен кыяфәтемне чыныннан аерып, ул тәүдә каушабрак калды. Вакыйганы колагына кычкырып сөйләгәч, Зәйни абзый, үзе дә ифрат шаян кеше, атын туктатып, йөк өстендә тәгәрәп-тәгәрәп көлде:

— Сандугач! Карлыгач! Сандугач! Карлыгач!..

...Яңадан мунча кереп, ике сәгать дигәндә, без абзый белән җиңел арбага кырын ятып, икенче тарафка — Имәнлек урманы үрләре аша Ишлегә китеп бара идек. Бу якта да җир-ялан коп-коры, яңгырның тамчысы да таммаган. Җәйнең җылы, тымызык киче. Күршебез Сәрби әбинең сары урагы булып күк йөзенә ай эленгән. Гүя ул кымшанмый, күзгә чалынмыйча гына эре йолдызлар уңышын ура... Рәхәт тә, моңсу да. Июльдә генә була торган төннең караңгылы-яктылы угызында нәрсәдер ялварып җирдән күккә күтәрелгән куллар, шәрә бармаклар чытырманын хәтерләткән урман авызына килеп кергәч, кайдадыр эчтәрәк гөрселдәп агач ауды.

— Корыган имән, — диде абзый. — Имән агачы нишләптер төнлә авучан. Тамырсыз агач, күрәсең...

Кайчандыр сугыш елларында үзенең өрәкләре, качкалаклары, ниндидер сәер казындылары белән халык күңеленә шом салган Имәнлек урманының бүген бер яфраксыз калган шәрә кәүсәләре миңа Маутхаузен, Освенцим концлагерь-

ларенда мунча кертелгәннән соң киендерелмичә суыкта тотылган тере сөяк әсирләрне хәтерләтте.

Йөрәк чәнчеп куйды. Мул уңыш хакына очкычлардан сиптерелгән агудан корыган Имәнлек урманы гүя минем сөякләрем һәм җелекләрем булып сызгыра, сызлый, иңри иде...

— Җырла әле, абзый...

— Карлыгач җырлаган җырнымы? — Ул кеткелдәп кенә көлде.

— Үзең теләгәнне...

Кара да гына лай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Матур җырлый минем абзый. Аның тавышы бик үзенчәлекле: ул җырлаганда бер сәбәпсез үксисе килә. Ә биредә урман юк иде. Тере яфракларга суклыгып саңгырауланырга, урынында һавага сеңәргә теләгән моң тирә-яктан мондый теләктәшлек тапмыйча корыган ботакларга, корыган ботаклардан корыган кәүсәләргә, корыган кәүсәләрдән корыган тамырларга үтеп зеңли, гүелди башлый... корыган агачлар гүя шәрә әсирләрнең оркестры иде. Мин яңадан авыр уйларга чумам. Сандугач белән Карлыгачны ташлап китеп дөрес эшләдемме? Нишлиләр әле алар? Һаман да әйткәләшәтарткалашамы? Әллә үз җайлары белән кайтып барамы? Әллә килешеп, кола яланда кочаклашып йоклыйлармы? Айныганчы йоклап, иртән берни булмагандай уянырлар да, юлга чыгарлармы? Минем зиһенемдә Психлар, Музсәгатьләр, Минутлар, Стрелкалар һәм тагын да әллә кемнәр кайнаша, бөтерелә башлый. Шайтан суын ике атом водород һәм бер атом кислород — судан да күбрәк куллана башлаган халык тора-бара нишләр? Чыга алырмы ул бу камалыштан? Әгәр Җир шарының киң билгеле биш мең милләт һәм шивәләре арасында үзләренең борынгы исемнәренә хыянәт итеп, сабыйларына мөмкин кадәр тозсыз, мөмкин кадәр мәгънәсез исемнәр кую буенча ярыш үткәрелсә, безнең милләт һичшиксез беренче урынны яулаган булмас идеме? Яулаган булыр иде. «Безнең милләтнең сәнгате юк, — дип пышылдадым мин үзүземә. — Үз фаҗигасен тасвирлый алган тирән сәнгате юк. Сәнгатьсез халык кына шундый була ала».

Колак төбендә гөрселдәп тагын бер имән ауды.

Кырлачтан төшкән электр утлары яктысында Ишле авылы шәйләнде.

Атыбыз түбән таба юырта башлады.

Сезгә ничектер, миңа 1995 елның печән өсте шулай тәмамланды.

*Гыйнвар, 1996 ел.*
*Переделкино*

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

# БӨРКЕТЛЕ БАГАНАЛАР

## ЭҢГЕР

### I

Уянып, күзләрен ачса: тышта көн уртасы җитеп бара түгелме?!

Кояшның кайралган кылычтай үткер нурлары ишекнең калҗайган такталары арасыннан сирпелеп, болай да күзсез келәт эчендәге караңгылыкны тагын да куерткан һәм андагы бар байлык, бар дәүләтне аерым бер илһам, аерым бер һиммәт белән тураклап ташлаган сыман. Бу нурлардан Җәүдәтнең күзләренә гүяки меңләгән кайнар энәләр чәнчелде, шулкадәр озак йоклаганына үзеннән-үзе оялып куйды. «Бохар ялкавы!» Башка вакытта, әлбәттә, сикереп торган булыр иде, әмма бүген түгел. Бүген ул — кунакта, ягъни Аллаһы Тәгаләнең үз яклавы астында көн күрәчәк...

Әйе, кичә кич, авыл утын басып, төнге ялга киткән мәлдә, дөресрәге, шактый соңлатып, яшьлек дустын, тагын да дөресрәк итеп әйтсәк, — аның гаиләсен, инде, соңгы чиктә, тәмам котылгысыз, лязем дөреслек белән әйтсәк, — үзенең утыз ел күрешә алмаган хәрби хезмәттәше Сабирны, әлбәттә, аның гаиләсен күрү өчен ерак Чаллыдан сабантуйга кайтып төште. Төньяк Башкортостанның гүзәл Бүә буйларына утырган Т. авылына күпме тапкырлар чакырды аны Сабир!.. Әмма юл төшмәде. Менә, ниһаять...

Дөя йонынннан сырылган юрган астында май кебек эрегән Җәүдәт ләззәтләнеп киерелеп куйды. Урынны ул үҗәтләнә-үҗәтләнә келәткә салдырган иде. Сабир белән Җәваһирә әллә нигә бер кайткан кадерле кунакларын: «Ата-бабадан калган ташкеләттә салкын тидерерсең, бүгенгә өйдә йоклап тор», — диеп, озак үгетләсәләр дә, чигенмәде: каладан салага бары тик бүгенге өлкәнлегеннән кичәге балачагына кайту өчен генә мондый «ярты як»ка юл сапкан Олыдөрес, ягъни Җәүдәт, тегеләрнең ай-ваена карамый, урынны, сиземләвенчә, кайчандыр иң читтә булып, соңгы елларда ихатадагы «үзгәртеп корулар»

нәтиҗәсендә карлыган һәм кура җиләк куаклары, алмагачлар уртасында торып калган ташкеләткә салдырды. Кулларын баш астына кушырып куеп, үзен уратып алган мохитнең рәвешен-моңын күздән һәм колактан кичерә башлады. Колакта — келәт төбәсенең кызган калаенда тыпырдашып шуа-шуа кышкы ревматизларын дәвалаган күгәрченнәр һәм чыпчыклар: күгәрченнәрнең чәлтерләре сабый чагындагы шикелле зәңгәр камәрдән чигелгән, ә менә чыпчыкларның күзләре бәс төртке белән бизәлгән булырга тиеш; күздә — кайсында күп еллаган арыш, бодай, арпа, көнбагыш, кайсында мал көрпәсе, ак он һәм кара он сакланган дистәләрчә әрҗә, ларлар, алар өстенә өеп куелган буаз капчыклар, азык-төлек, тупас кулланыштагы савыт-саба; келәтнең бердәнбер матчасындагы кадакларга эленеп киптерелгән сыер һәм ат ите; шунда ук, ишек катындагы борынгы, чүкеп ясалган чөйләрдә инде менә ничә ел файдаланылмаудан он кәтрәсе, иген һәм мөлкәт тузаны белән капланган камыт, ыңгырчак һәм көмеш сәдәфле эшлия; колакта — алдына куелган кычыткан һәм көрпә болгавын юньле-рәтле ашамый, тирә-юньгә чәчрәтеп, кайдадыр тавык офыгындагы кычытканнар арасында корт-корт килеп һәм горгылдап, гүя социализм чүплегендә капитализм энҗеләре эзләп тибенгән тук тавык-чебешләр, күркәләр һәм вакыт-вакыт чиркәү калакулы кебек тамак ярган әтәчләр; күздә — янәшәдәге лар өстенә кунак-лаган юкәгач тәпәндә чемердәп утырган әче катык булырга тиеш; ә менә бу вак күзле ак чүпрәк белән капланган яшел чиләктә, кашык тыгып каерсаң, билләһи, ишелеп төшәрдәй, тыгыз, куе, яшь катыктыр, шәт; матчаның аргы очында асылынып торып, зеңгелдәп кипкән былтыргы һәм, күрәсең, Җәүдәт кайту хөрмәтенә сындырылган быелгы сыек, яшел елак каен себеркеләре...

Җир идәннән, лар асларына түшәлгән зәңгәрсу ташлардан, почмаклардан күтәрелгән дымсу һава әле күптән түгел генә киткән язгы ташу тәме һәм аһәңнәре белән бергә кушылып, Җәүдәт күңелендә әллә нинди җилкенү, ләззәтле һәм үкенечле тойгылар уята, алдагы көннең никадәр мәгънәле, кызыклы һәм мавыктыргыч булачагын вәгъдә итәләр иде...

Юлы әллә ни газаплы булмаса да, үтелгән ара, барыбер үзенекен итеп, тәнне талчыктыра, күрәсең. Үтә дә изрәп йоклаган ул — мендәргә башын салганын гына хәтерли. Мондый сабыйларча изрәү, бәлки, дөя йонынннан килгән сихәттер? Аһ, күчмә бабаларыбыздан калган борынгы табигыйлек! Хәтерендә, Җәүдәтләрнең дә бар иде мондый юрганы. «Онытмагыз — без дөя ыруыннан! — ди торган иде инәләре, аларны йокыга түшәгәндә. — Бу юрган астында Бәдретдин балаларының бишенче буыны канат чыгара. —

Аннан өстәп тә куяр иде: — Дөя йоны искермәс — салкын тимәс, йөткермәс!» Тирәк мамыгы кебек җиңел дә, аңлатып бетерә алмас дәрәҗәдә җылы да, аннан гайре, инәләренең кулы кебек йомшак һәм шаукымлы да иде ул юрган... Астына чумып, күзеңне йомдыңмы — әвен базарына китеп тә бардың дигән сүз. Аннан, сугыштан соңгы ачлык елларында, бигрәк тә салкын, озын, шыксыз көннәрдә, җылысын җуйган мичкә аркасын терәп, инәсенең эштән кайтуын көткән Җәүдәтне биектән, буе җитмәгән киштәдән торып җылыта да иде ул — нindидер үтә шома, төсен югалта барган саен сирәк эре чәчәкләрен тагын да ачыклата, яктырта төшкән тукыманың — аны инәсе, атласи, ди иде шикелле — нәкъ әнә шул эре чәчәкләре аңа гүяки үзе беркайчан да күрмәгән, әмма җылылардан җылы тоелган серле дөянең күзләре белән карый... Көн кичкә авышып, караңгылык почмакларда куерып, өйне баса башласа, бу дөя күзләре йолдызлар сыман яна һәм шыксыз ялгызлыкны ут кылычлары белән телгәләп җанландыра башлый. Илле өч яше белән барган Җәүдәтнең әле картинәсеннән калган дөя юрганыннан башканы үз гомерендә бүтән бер тапкыр да күргәне булмады. Татлы йокысының ләззәтле томаннары һаман кан тамырларында шаукым булып тирбәлә, аның бу мизгелне сузасы, бар дөньясын онытып, яңадан йокыга таласы килә...

Иртәгәсе сабантуйның мәзәкләре, кем әйтмешли, иртәгә булса да, маза-кәҗәләре, гадәттә, бүген булучан. Сабир идарәдәге иртәнге нарядтан кайтмаган, күрәсең — ихатада аның көр тавышы әлегә колакка чалынмый. Күгәрченнәр әле һаман кайнар калайда таеп һәм корсаклары белән дөпелдәп шуып туплы уйный. Йортның ачык тәрәзәсе аша Мәскәү радиосы чечен фронтындагы уңышлары турында мактана гына башлаган иде — кемдер аны шартлатып япты. Чечен халкын яклап кулына корал алырдай чакларында чарасыздан бичара калган Җәүдәт Рәсәйнең оятсыз авызын үзе дә шулай томалый. Димәк, бу авылда, бу йортта аның кебек фикер йөртүче адәм бар? Кем икән ул?

Ул яшьлек дусты Сабирдан көнләшеп тә куйды. Җәүдәт укып кем булды да, «укымаган» Сабир кордашы кем булды? Белеме дә ун гына сыйныф бит аның! Нәрсә, ун сыйныф белем, әгәр ул чын белем, чын гыйлем булган булса, азмы? Бик күп бит ул ун ел буе эстәгән мәгърифәт! Дөрес, Сабир хәрби хезмәттән кайткач, Бәләбәйнең нindидер механизация мәктәбендә укып маташты маташуын. Үз авылының: «Мин түгәрәк йөзле, шундый ук кечкенә түгәрәк башлы, җыйнак йомры гәүдәле чын татар кызымын!» — дип, хәтта мең чакрымнан да кычкырып торган Җәваһирәсенә өйләнде һәм, аның белән чөкер-чөкер килеп, биш бала үстерде. Биш бала —

әйтүе генә ансат! Хәзер үзләре белән төпчекләре Зәбир генә торып калган бугай. Алтынчыда укый, диделәрме? Ә Җәүдәт ничә бала үстерде? Берне. «Бик җиткән!» — диде хатыны. «Бик җиткән!» — диделәр аның килендәшләре һәм барлык туганнар. «Бик җиткән!» — диде шәһәр трамвайлары, аның агулы һавасы һәм суы...

Әүвәлдә бригадир, аннан баш механик, инде менә ун-унбиш елга тартадыр — хуҗалыкның рәисе булып эшли Сабир. Белүенчә, начар да эшләми. Укыганнардан һич кенәләр дә ким түгел. Бәлки, урыны-урыны белән артыграктыр да. Йорт-җирен генә кара син аның! Бу унга ун итеп салынган нарат сарайда Җәүдәтнең Уфада унбиш ел буе тир түгеп, бил бөгеп яулаган тараканлы ике бүлмәле, аннан аны шул ук кырык бөгелеш һәм кырык сыгылыш аша Чаллының сигезенче катына алыштыра алган шул ук ике бүлмәле фатирын ун мәртәбә сыйдырып булган булыр иде. Абзар-курасын, ихата-җирен, мал-туарын ал. Җәваһирәсе дә, мин рәис бичәсе, дип купыраеп йөрмәде, кирәк икән бәрәңгесен, кирәк икән чөгендерен эшкәртте. Балаларын да аякка бастырды. Өстәвенә ике яктан да ата-инәләрен тәрбияләп җирләделәр, рәхмәт төшкерләре. Урыннары җәннәттә була күрсен! «Ә менә син кем булдың?» — дип сорады Җәүдәт үз-үзеннән. Һәм шунда ук, гадәттәгечә, үзен үк талый башлады. Журналист, имеш. Мондый чакларда ул үзен, көлеп, «йөрмәлист» дип атый. «Сүз остасы», имеш. Гомере буе авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә чабып, кеше аһ-зарын тикшерде, гәзит битләрендә надан баш мөхәррирләр белән талаша-талаша, мир пычрагын ялады. Гаделлекне таптымы? Тормышны юньлегә үзгәртә алдымы? Рәхмәт ишеттеме? Картлыгына дип мал-мөлкәт туплады мы? Юк. Мең мәртәбә юк. Шәһәрдә яши, имеш. Ут күршеләре дә юк бит аның. Аннан да фәкыйрь кем бар? Менә ун ел булыр — ут күршеләренең исемен-фамилиясен белә алмый ул. Зарурият тә, мәшгулиять тә, хаҗәт тә юк. Иренеке әллә Захар, әллә Нахал. Иртән ишекләре шарт ябыла — эшкә китәләр. Ир айнык. Кичен, бик соңлап, ишек шарт ачыла — эштән кайталар. Ир исерек. Кайда яшибез без: Татарстандамы, әллә Кострома-дамы? Ишек аша гүя икенче галәм. Ашаган икмәк, ит, эчкән су, сөт, яшәгән җир, сулаган һава гына бер. Әгәр ут күршеңә ут сорап керсәң, аңлармы ул? Шәһәр, имеш. Аның урамнарында кысталып-нитеп, сидек куыгың шартлап үлүең мөмкин. «Күрәчәгең булса — күркә талап үтерә», — дип, бабайлар юкка гына әйтмәгәннәр...

Дөрес, Җәүдәт үз эшен үлеп ярата. Эш дигәндә урык-сурык йөрмәде, шырды-бырды кеше белән сүз дә, табын да уртаклашмады. Әмма ул, әгәр «сүз остасы» икән, безнең

сүзнең күзе авылда бит әле! Җырның да җире бар бит әле! Ә җире аның — авыл. Димәк, җирнең чын хуҗасы Сабир булып чыга түгелме? Менә монда, келәттә, һәр әйбернең сүзеннән алда күзе бар. Күзе барның гына сүзе бар. Димәк, күзнең һәм сүзнең хуҗасы булып та Сабир, Сабир калка бит әле... Кем идек, кем булдык, ягъни мәсәлән?

«Әйтик, менә дүрт сүз, — дип дәвам итте үзенең фәлсәфәсен яткан җиреннән Җәүдәт. — Шуларның икесе ия: «йомырка» һәм «җөй». Икесе фигыль: «йөрү» һәм «эзләү». Алар әлегә ятим һәм хәлсез ялгызаклар. Чөнки әлегә үзара «никахлашмаганнар». Шәһәр бу сүзләрне бәйли алмый — җирлеге булып та, хөрлеге булмагач, бу сүзләрнең шәһәрдә песи балалары шикелле күзләре сукыр. Авыл люмпены шәһәргә күченүен күченде, әмма күзен — мәктәбен — авылда калдырды, димәк, шундый ук кара сөяк шәһәргә әсирлеккә төште. Шулай итеп, әсирлеккә төшкән бу дүрт сүз, урам себерүчеләр авызыннан үтеп, кырларга күтәрелә алмыйча, нәҗес, күзсез, мат-перемат язылган сасы подъездларда тончыгып үлә. Димәк, шәһәрнең күзе авылда калган. Мәктәп шул ук Сабир кулында! Сабырсыз булма, Сабирсыз беркая бара алмыйсың. Сабир аларны ялгый һәм менә шул ятим, никахсыз, песи баласы шикелле сукыр сүзләрдән даһилардан даһи әйтем иҗат итә: «Йөрисең йомыркадан җөй эзләп!» Бетте-китте. Бар, әйтеп кара, уйлап табып кара син аны! Югыйсә кулын кушарлап та чишмәдән су эчмәгән, ыштан бавын биштәрләп тә уракка төшмәгән, югын-барын эзләп, эш майтарган кыяфәт белән йөреп, тегендә-монда сугылган, кысылган, шуның белән үзен эшлекле күрсәтергә тырышкан әтрәгәләмнәргә сәгатьләр буе әдәп һәм иман турында вәгазь укыганчы, «Йөрисең йомыркадан җөй эзләп!» — дип кенә җибәрсәң, бик таман булып кала ул.

Элек авылның телсезе-чукрагы, тилесе-диванасы, сакавытыңкышы, хәтта теле ачылган-ачылмаган баласы да ничектер үзенә генә хас телле иде. Җәүдәт үсмер чорына кереп килгән елларда күршеләре Галирахман абзыйның сакау, җитмәсә, тыңкыш малае бар иде. Урак өстендә мич башыннан кайнап торган казанга төшеп үлде ул, мескенкәй. Исеме дә бик матур иде — Зирәк. Чынлап та, ифрат та сирәк булган Зирәк авызыннан гына чыккан күзле сүзләрне кем хәтерли икән бүген авылда? Ә менә Җәүдәт хәтерли.

— Әтиең нишли? — дип сорый иде ул, ыштансыз малайны очраткан саен.

— Табата кутый, — дип җавап бирә малай, бик җитди кыяфәт белән. — Табарга база, табатаката...

Чабата тукый, була инде, янәсе. Базарга бара, чабата сата. Җәүдәт пырхылдап көлеп җибәрмичә чак түзә.

— Әниең нишли?
— Амын баса.
Камыр баса, янәсе.
— Песиегез нишли?
— Пыртлый...
Мырлый, ягъни мәсәлән, йоклый була инде...
И сабый, сабый! Болай да сыек сөякләрең череп көлгә әйләнгәндер, рухың гына бу гөнаһлы җир өстеннән очып йөридер, и сабый!..
Ул юрган астыннан йодрыкларын төйде. Нигә? Ни өчен? Кем гаепле? Әллә шәһәрнең күп катлы баракларына төкереп, чынлап та авылга кайтыргамы югыйсә? Ул бит әле кәкшәңнәгән карт түгел. Авылда хәзер техника күп, әмма Өммениса әби әйтмешли, «халхуз ялкавы»на әйләнгән һәм якса газы, эчсә суы өенә килеп торган, мең сәбәпләр аркасында игенче булудан туктаган авыл прлетары бу техниканы тирән максат белән файдалана белми һәм иң үзәккә төшкәне — файдаланырга теләми — бер сыерлык печәнен бөкресен чыгарганчы һаман да шул кул чалгысы белән берәмтекли, һаман да шул тешсез тырмасы белән тырматып, япьсез сәнәге белән чүмәләләргә куя, йөк саен бастырыклык кисеп, урманны сирәгәйтә, чалыш фурманы белән ава-түнә сәндерәсенә ташый, җик күрә, әлхасыйл, йомыркасыннан җөй эзләп, үзен бәхетле тоя, ялкаулыгын һәм эшлексезлеген аклый һәм XX гасыр азагының галәми ирегеннән баш тартып, үз теләге белән XV гасыр коллыгында яши бирә... Авылга кайтса, ачка үлмәс ләбаса? Аннан, ел буе бет тә ач тора алганда, дөя ыруыннан булган Җәүдәт чыдар әле, шулай бит, җәмәгать? Көлдә ауна — көнеңне күр.
Бу фикереннән кәефе килеп, Җәүдәт өстендәге юрганын атып бәрде һәм урыныннан сикереп торып, кичтән әзерләп куелган зәңгәр спорт чалбарын, чүәкләрен киде, ашыгып-ашыгып, урын-җирен җыештыра башлады. Төсен аера да алмаслык хәлгә килгән дөя юрганын дүрткә бөкләп, аны агач караватның аргы түренә түшәде, өстен ак җәймә белән ябып, каккалап һәм суккалап, ике мендәрне бер-берсенә очтыклап куйды. Җәваһирә тарафыннан баш астына салынган кара төстәге ниндидер бишмәт сыман нәмәстәкәйне кулына алуга гүя җаны аша ниндидер шаукым йөрәгенә сукты, тын юлын буды. Юк, булмас... Гүяки җир айкалды, диңгез чайкалды, кояш исә кара торба эченә кереп кара янды. Юк, булмас ла... Ул сынган канат сыман асылынып төшкән куллары белән, тау актаргандай көчәнә-көчәнә, бишмәтне әйләндерә, караштыра башлады... «Булмас!» Егерме биш ел буе чыдый диме?! Бу бишмәт, һәрхәлдә, черергә, черемәсә, таушалырга, тузарга һәм кайдадыр чүплеккә, йә булмаса, чормага томырылдырылып, күз-баштан читкә олактырылырга тиеш иде югыйсә?!

Бәлки, бу нибары шуңа охшаган бишмәт кенәдер? Җәүдәтнең карашы микроскоптан ниндидер бөҗәкне тикшергән вакчыл аспирант карашы белән кара парусин тукыма өстеннән шуа башлады... Озак киелүдән кыршылып, майланып, чачакланып беткән яка һәм җиң очлары... Бишмәтне лезгелдәп кенә каптырып куя торган вак тешле каптырма, аның әле булса ялтырап торган шудырма йозагы... һәм... ниһаять... ни күзе белән күрсен!.. Моннан нәкъ егерме биш ел элек сул як җиң уртасына кояшта янмый, утта көйми, кислотада эреми торган буяу белән келәйгә катырылып, басма хәрефләр белән язылган ике сүз: «Строитель КамАЗа»...

Гүя үзәннәрне басып килгән язгы ташкын тар, ясалма буа авызына килеп тыгылды, күзле бозлар, берсе өстенә берсе менеп, җан ачулы тавышлар чыгарып һәм шытырдап уалды, кинәттән алар барысы да астан, тирәннән этәрелгән көч белән күккә аткарылды, аннан, хәлләре бетеп, җиргә тартылды, яр буенда бөреләнеп килгән таллыкларны имгәтте. Һавада иркен очып йөргән кошларга гүяки кемдер вак күзәнәкле ятьмә ыргытты, ятьмәгә эләккән кошлар берсен-берсе таптап, пычратып, бу дустанә поткынлыкта өерелде-өерелде дә, йөрәкләре ярылып, җиргә капланды. Гүяки ниндидер тупас көч галәмнең саф һавасын дустанә суырып алып, бер пешкәк эченә куып кертте дә, һава шартлар чиккә җитеп кысылды.

Җәүдәт куртканың җиңен шытырдатып кысты — күзләреннән келәтнең мүкләнеп беткән ташларына кан чәчрәде, тагын кысты — башыннан мие чәчрәп чыгып ташларга сыланды, яңадан кысты — авыллар, каберлекләр, чем-кара туфраклы басулар һәм йөз еллык урманнарны аммиаклы су басты, ай өстенә тәре һәм биш чатлы йолдыз кунаклады, ат юлы өстенә косыклы тимер юл ятты, чигүле ашъяулык ябылган, ак сөт өстенә үрмәкүчләр, кандала һәм тараканнар үрмәләде, шунда ук сабыйларыннан ваз кичкән ата-аналар, ата-аналарын белмәгән-танымаган сабыйлар, бер океаннан икенче океанга кадәр уникe мең чакрымга сузылган дустанә державаны дустанә пычратып җыелган эшлекләләр һәм әрәмтамаклар, бушкуыклар һәм кызыл авызлы каһарманнар, качкалаклар һәм шизиклар, исерекләр белән тулы вокзаллар һәм җимерек дебаркадерлар, очсыз талоннар, приват-чеклар, алдын алтын, артын бәдрәф биләгән купшы банклар — барысы да бергә буталды...

Кинәттән күз алды дөм караңгыланды. Калай түбәдә күгәрченнәр шуыша, ташкеләт эчендә эре чебеннәр гөжли. Җәүдәт күзләрен киеребрәк ачты.

Ул күрми иде. Әллә ялгышаммы диеп, күз кабакларын бармаклары белән киерде. Ул сукырайган лабаса...

Җәүдәт, тәмам хәлсезләнеп, караватка сыгылып төште.

## II

...1971 елның апрель урталарында Җәүдәтне, ул чакта Уфада чыгып килгән үзәк башкорт газетасы хәбәрчесен, Чаллыга җибәрделәр. Дөресрәге, ниһаять, җибәрделәр. Баш мөхәррир дип аталган кеше бик озак карышты. «Нимә калган унда бедгә?» — дия торган иде, сары кашларын җыерып, Җәүдәт мөрәҗәгать иткән саен. «Бу хакта бөтен дөнья шаулый. КамАЗда Башкортостан яшьләре дә шактый. Барып кайтыйм да язып чыгыйм әле!» — дип ялынуына матбугат эшенә очраклы гына килеп эләккән тупас партия шамакаеның җавабы әзер иде: «Ядһындар! Улардың башка ни эше бар? Хәдер сәсеүгә төшәбед!» Ахыр чиктә биреште баш мөхәррир: «Бар, күдемә күренмә!»

Кама ташкан, КамАЗда эшләрнең баштин ашкан чагы иде. Кая карама, әле башланып кына килгән төзелешләрдә очрый торган ташландыклык, актарылган, умырылган җир күзгә ташлана, кай тарафка колак салма, дөпелдәп, ухылдап һәм иңрәп, көчли-көчли, туң җиргә меңләгән, миллионлаган субай каккан бой-бабаларның тетрәткеч тавышлары ишетелә. Ирексездән күңелдә шундый сорау ярала: әллә КамАЗ заводлары вакыты җиткәч җиңел генә сүтелеп алыну ниятеннән шулай махсус рәвештә вакытлы субайларда төзеләме?

Җәүдәтне җылы каршыладылар. Кунакханәдән бер бүлмә дә бүлделәр. Ул гынамы? Сирәк кунаклар ядкаренә үз култамгасын да куйдырдылар. КамАЗ парткомында бу мәшәкать күз ачып йомганчы үтәлде. Бүгенгедәй хәтерли Җәүдәт, аның имзасы Франция коммунистларының «Юманите» газетасы хәбәрчесе Серж Лейрактан соң туры килде. Кызыл төстәге, калын дуңгыз тиресе белән тышланган бу кенәгәдә, шунысы сәер, Җәүдәт үзенең күптәннән таныш татар әдипләре һәм журналистлары исемнәрен очратмады. Казаннар, күрәсең, монда сирәк кунак санала иде...

Яшьләр тормышыннан тыш, Җәүдәтне Чаллы төзүчеләренең илдә беренче буларак кулланган «Йортларны тәгәрмәч өстеннән төзү» ысулы кызыксындыра иде. Бу хакта әйткәч, ысулның әйдәүчесе — «Жилстрой-2» идарәсе җитәкчесе Фәләхов белән таныштырдылар.

— Гегель Әфләтүнович булабыз, — диде Фәләхов, урыныннан чыгып һәм Җәүдәтне күптәнге танышыдай кысып кочаклап. — Әмма сезнең өчен генә. — Ул күз кысты. — Югыйсә безне монда «Платоныч» дип йөртәләр. Мөмкинме? Бик мөмкин! — Фәләхов сүзгә әвәс, хуш күңелле кеше булырга охшый иде. — Әфләтүн — урыслар өчен, үзегез беләсез, сәер дә, авыр да, уңайсыз да... Әти картны әйтәм, борынын җил уңаенда тота белгән бит, шайтан! Әйе, Әфләтүн картыбыз, теге хәтәр елларда, — Фәләхов соңгы сүзләрен пышылдап кына

әйтте, — белеме мәдрәсә сикесе кебек шакы-шокы гына булса да, исемне сайлый белгән, ә? Маркс, Энгельс, Лениннарның кендек бабалары Георг Вильгельм Гегельнең Гегелен генә чәлдергән бит, ә? Мөмкинме? Бик мөмкин! — Ул тагын күз кысты һәм шаркылдап көлде. Куе кашлары, үзләренә урын табалмый, маңгаена сикерде. Аңа Җәүдәтнең киләсен алдан хәбәр итеп куйганнар иде булса кирәк, ул сорау-фәләнне көтмичә, кыска гына итеп, үзенең тәрҗемәи хәлен дә сөйләп алды. — Әйтми дә торам, без дә Башкортостаннан бит. Кайсы районнан, дисезме? Сорап торасыз тагын! Каян чыга барлык акыллы кешеләр? Әлбәттә, Тәтешледән! Ха-ха-ха! — Кашлары тагын да маңгаена сикерде. — Әйе, Әнгам Атнабай — атна ярлы, атна бай — безнең якташыбыз... Безгә килеп никадәр дөрес эшләгәнсез бит, ә? Бер рәхәтләнеп, сайрашып та утырырбыз. Колхоз эше бетми ул!..

Гегель Әфләтүнович туган телендә сөйләшүне бик тә сагынган иде булса кирәк, ул җөмлә саен «без» белән «мин»не чамасыз бутап, «бик мөмкин»нәрне еш кабатлап, Җәүдәткә кыска гына вакыт эчендә бай мәгълүмат туплау өчен шартлар тудырачагына ышандырды. Төпсә кебек базык гәүдәле, бүдәнә кебек майлы йөзле Фәләховның күзләренә игътибар итте Җәүдәт: аларның төсен чамалау авыр булса да, йомран күзләре кебек йөгерек булуларын абайлау ифрат та җиңел иде. Кеше белән сөйләшкәндә, бу күзләр гүяки икесе ике якка карап аерыла, аннан аны келәшчәгә алып кыса һәм кинәттән, сул күздән «Мөмкинме?» дигән сорау билгесе атылып чыгып, уң күздән исә шундук «Бик мөмкин!» дигән өндәү билгесе калкып чыгып, әңгәмәгә нокта куя.

— Минем саф татар телендә сөйләшүемә аптырыйсыз? — дип дәвам итте сүзен Фәләхов. — Ә нинди телдә сөйләшергә тиешмен мин? Тукай бабай безне нәрсәгә өйрәтте? «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле», — дип өйрәтмәдеме ул безне? Без бит, ни дисәгез дә, данлыклы Таңгатар урта мәктәбен тәмамлаганбыз. Булганыгыз юкмы? Аһ, юк? Мөмкинме? Бик мөмкин!..

Фәләхов якташын, чынлап та, тулысы белән үз канаты астына алды. Кунак өчен махсус «Волга» машинасы бүлеп, аңа алмаш шоферы Володяны беркетте. Кая барсалар да, сыек ләм, баткакта йөзгән төзелешләр белән аны кайчагында беренче урынбасары Ковалев, кайчагында икенче урынбасары Абрикосов таныштырды. Аякларына шул ук Гегель Әфләтүнович бирдергән резин итекләрен киеп алган Җәүдәт эш сәгатен иртәнге планеркалардан башлап, көннәр буе ләм диңгезендә йөзеп, очтан очка, кешедән кешегә чапты һәм үз бүлмәсенә караңгы төшкәч кенә, җеп өзәрлек тә хәле калмаган рәвештә кайтып егыла иде. Мәкалә генә түгел, фәнни хезмәт язарлык

мәгълүмат тупланды аның язмаларында. Җәүдәт социалистик ярышта җиңгән өчен бирелгән һәм соңыннан ни өчендер күчә торган сәер байраклардан соң да күчми кала торган байлык — кешеләр, меңләгән язмышлардан, комсомол-яшьләр төзелеше дип илнең төрле тарафыннан акча, мал, дан, еш кына бер ударныйдан икенче ударныйга күченеп йөрүне кәсеп иткән суыгаякларның гомуми саныннан, аларның җирле халык белән мөнәсәбәтләреннән башлап, бүген-иртәгә КамАЗ төзелешләренә китереп аударылачак ком бөртекләренең гомуми күләменә кадәр белә иде. Тәмәкесен кабызган саен кашын көйдергән, шуның нәтиҗәсендә өтәләнгән тавыкка охшаган, мондагы вакыйгаларга даһиларча битараф булган Абрикосов та, авызыннан һәрвакыт — бигрәк тә иртәнге якта — көйгән аракы исе килеп торса да, туктаусыз сөйләгән һәм мотлак әңгәмәдәшенең авызына кереп сөйләгән Ковалев та нәкъ әнә шундый кырык-кырык биш яшьләр чамасындагы суыгаяк «комсомол-яшьләр» булып чыкты. Абрикосовны Куйбышев сусаклагычындагы авариядән соң, сирәк белгеч буларак, әле ике ай элек кенә чакыртып алганнар икән. Фатир көтә. Тегендәгесе кызы белән киявенә калачак, ди. Ковалев Ангарскийдан. Төрмәдә утырып чыккан. Шуңа күрә җитәкчеләр арасында бердәнбер партиясез. Монысы да Татарстан өчен тутыккан кадак кебек сирәк кадр. Чакыртып китергәннәр. Идел буе урманнарында үзе атып алачак җәнлекләрне, үзе җыячак гөмбә-җиләкләрне, гомумән алганда, комсомол-яшьләр төзелешләрен ифрат та ярата икән. «Сезнең монда кадрлар белән хөрт, — диде Җәүдәткә Ковалев. — Татарлардан бердәнбер Платоныч. Но зато какая глыба!»

Володя Украинаның Проскуров каласыннан. Татарстан турында ишеткәне дә булмаган. Монда тартып китергәне өчен бөтенсоюз радиосына рәхмәтләр укый. Ике балалы хатынын аерганнан соң, кая барырга дип торганда, дикторның ике-өч кәлимәсе коткара аны. Сидоровкада шулай ук ике балалы Мәликәгә өйдәш булып кергән булган. Әмма бер эчкече ирен — татарны гүргә керткәннән соң, икенче эчкече — инде урыска тап булып, ир кадерен күрмәгән Мәликә ханым Володяны озак тотмый, выжлатып та чыгарган.

Чаллыда адашасың килсә, Володя арбасына утыр. Ул чат саен Җәүдәттән: «Хәзер кая борылабыз?» — дип сорый. Шулай итеп, бер генә мизгелгә дә үзенең юл йөртүче — шофер икәнлеген оныттырмый...

Бермәлне Гегель Әфләтүнович аңардан сорап та куйды:

— Син, Володя, беләсеңме, ни өчен Чаллыда адашасың? Чөнки сиңа юл күрсәтүче кеше юк. Нигә өйләнмисең, ә?

— Хәлем юк, Платоныч, — диде тегесе, ачык беркатлылык белән.

— Ә син, хәлең булмаганда, җырла! — диде аңа Гегель Әфләтүнович, ярым шаяртып. — Мөмкинме? Бик мөмкин! Чөнки, армия гадәтенчә, хәлсез кешегә җырлатып кына хәл кертәләр. Ха-ха-ха!..

— Ничек җырлыйм ди мин? — диде Володя, күзләрен тәгәрәтеп. — Аның өчен бит яхшы ашарга кирәк!

— Бөтен фәлсәфә дә нәкъ менә шунда шул! — Гегель Әфләтүновичның якты тар маңгаена кашлары кереп тулды. — Яңа шәһәр һәм яңа кешене төзү, — ул «тәрбияләү» урынына махсус рәвештә «төзү» сүзен кулландымы, әллә шулай килеп чыктымы, — менә шул ач килеш җырлый алуга бәйле. Ул — беренче шарт. КамАЗ талоннары бездә даими рәвештә туклыкка, иминлеккә чыгу иллюзиясен сакларга тиеш. Әгәр яңа Чаллының иске кешесе елаудан җырлауга шундук күчә ала икән, димәк, ул — яңа кеше! Ха-ха-ха!..

Фәләховның нинди аң, кайсы як тарафдары икәнен чамалап алу бик читен эш иде. Шуңа күрә Җәүдәт аңардан сорамыйча булдыра алмады:

— Җырчы булган яңа кеше елак иске кешедән яхшыракмы, әллә начарракмы, Гегель Әфләтүнович?

— Мөмкинме? Бик мөмкин! — Фәләховның коңгырт төстән яшькелткә күчеп барган карашы Җәүдәтне ике яклап киләшчә эченә алды, кысты, аннан, шаяруга күчеп, ычкындырды: — Иң мөһиме — яңа кеше машина йөртә белә, шулай бит, Володя? Машинасыз кеше — Алласыз кеше. Хәер, Ходай Тәгаләбез үзе безнең «Жилстрой-2»нең парткомы әгъзасы бит әле! — Ул Володяга күз кысты. Җәүдәт аңлавынча, водитель үзләренә генә билгеле сәбәпләр буенча коммунист һәм партком әгъзасы булып чыга иде.

— Машинаны яңартасы бар, Платоныч! — дип кыстырып куярга кирәк тапты Володя. — Таракановлар кичә алыштырдылар...

Дүрт көн буена машинаның уң як ишеге җәфалады Җәүдәтне. Ачылса — ябылмый, ябылса — ачылмый. Баткактан өстерәлеп килеп, кабинага кереп утырдымы, әллә чыгарга кирәк булдымы, тәкатьсез каласың: алдында яткан тимер тукмагын алып, Володя, шул ук баткакта лаштырдап, салоннан чыга, ишек катына килә һәм үзенә генә билгеле булган ысул белән ишекнең йозагын тукмый, еш кына ачарга кирәк булса — яба, ябарга кирәк булса — ача... Кунак кешегә моны күрмәмешкә салышу уңайлырак иде. «КамАЗ ифрат бай оешма икән, — дип нәтиҗә ясады хәбәрче. — Өр-яңа машинаны тагын ничекләр итеп ватарга мөмкин? Нигә төзәттермиләр?» Хәер, йөз чакрымнарга сузылган Үзәк Комитетның күз карасында булган бөек төзелеш өчен бу бик тә вак мәсьәлә иде...

Иртәгә Уфага очам дигән көнне кичен Гегель Әфләтүнович

аны Башкортостан яшьләре яшәгән тулай торакка алып китте. Күп тапкырлар ишетеп, беркайчан да болай якыннан күрмәгән җитәкчеләре, аннан гайре Уфаның үзеннән килгән хәбәрче белән очрашуга төзүчеләр чиксез куанды. Ярым телсез тормыш, мат-перемат, авыр хезмәттән талчыккан Хәйбулла һәм Стәрлебаш, Күгәрчен һәм Яңавыл яшьләре үзләрен шулай бергә җыеп, җәелеп китеп туган телләрендә сөйләштергән Фәләховка зур рәхмәтләр әйтте. Сүз дә юк, аның абруе күзгә күренеп үсте. Әмма иң көтелмәгәне кичәнең азагында булды. Гегель Әфләтүнович алдан әзерләп куелган төргәкне чиште, аннан чем-кара, тимер биге буйдан-буйга ялтырап торган куртка чыгарып, халыкка мөрәҗәгать итте:

— КамАЗ гиганты башланып кына маташкан авыр чорда безгә килеп, яңа кеше — коммунизм төзүчеләрнең героик хезмәтен Башкортостан матбугатында язып чыгачак журналист Җәүдәт Биктимеров... менә үзегез күрегез... җиңенә... — Ул җиңне әйләндереп, залга күрсәтеп чыкты. — «Строитель КамАЗа» дип язылган махсус куртка белән бүләкләнә! — Якташлары котырып кул чапты. — Ягез әле, кидереп тә күрсәтим! — Фәләхов Җәүдәтне кочагында өйрелдереп, кыска бишмәтне кидерде, өйрәнелгән җитезлек белән тимер каптырманы очкыннар уйнатып каптырды һәм ычкындырды. — Менә бит, кып итеп тора. Җылы тәнегездә тузсын, безне онытмагыз!.. Нәрсә җебеп утырасыз, кул чабыгыз!..

Залның кул чаба-чаба кан тамырлары бүртте, шартлар чиккә җитте. Мондый алкышлаудан уңайсызланып калган Җәүдәт:

— Ышанычыгызны акларга тырышырмын... Мәкаләләр басылган гәзитләрне җибәрермен... — дип мыгырданды.— Насыйп булса, тагын да килеп чыгармын, туганнар...

— Мөмкинме? Бик мөмкин! — Фәләхов бу хәбәрне күтәреп алды. — Сез киләчәксез... Сез килергә бурычлы да! Сез бит хәзер «КамАЗ төзүчесе»! — Ут булып кызган залның мунча ташына әйтерсең лә су салдылар, ул чажлап кына калмады, учка уч, чуерташка чуерташ булып чәкәште.— Менә шулай! Ә сез, Җәүдәт иптәш, язганыгызда мактагыз, ягъни объектив булыгыз, дип әйтүем... Фәләховның түгел, идарәнең... идарәнең даны артсын!..

Кичәдән соң Гегель Әфләтүнович аны кунарга алып китте. «Нәрсә анда, салкын ятакта, берүзегез кандала симертергә? Гөрләшеп утырыйк әле... Колхоз эше бетми ул!..»

Кунакка барышлый Җәүдәт көтмәгәндә кулга килеп кергән бүләккә куанып та куйды. Аны җибәрми җәфалаган баш мөхәрриргә ихтыяри җавап бит бу. Мөхәрририят өчен дә абруй!

Зәвилә ханым аларны ачык йөз, Гегель Әфләтүнович әйтмешли, фронталь әзерлек белән каршылады. Аш-су бүлмәсе ризык белән тулган иде. Карыны ачканлыгын шунда

гына тойды Җәүдәт. Әмма ни сәбәпледер өйгә тәмле аш-су исе таралмаган иде. Чәчләрен никадәр тыйнаклык белән татарчалатып турыдан ачса, күкрәк уемын шулкадәр тыйнаксызлык белән тышка чыгарып, эре чәчәкле халат кигән хуҗабикә, чыгышы белән Буа кызы, теш табибәсе булып чыкты. Зәвилә кунакны өрмәгән җиргә утыртмаска тырышса да, Гегель Әфләтүнович, аны илтифатсыз гына эчкә үткәреп, аңа дүрт бүлмәле фатирын күрсәтергә ашыкты. Балалар йоклаганга, эчке бүлмәгә үтәргә читенсенделәр. Мондагы чисталык, пөхтәлек, тимер үҗәтлек һәм гармония Җәүдәт күңелендә хуҗаларга карата нindидер катлаулы теләктәшлек, сагыну һәм сагыну булудан туктаган арадагы ихтирам тойгысы уятты. Укыган кешеләр корган гаиләләрдә беркайчан да мондый ачу китергеч тәртипне күрмәгән Җәүдәт беравыкка тынсыз калды.

Көзгедәй шома, тайгалак Краков өстәленә Зәвилә ханым әүвәлдә ике катлап одеял, аның өстенә калын киҗеле ашъяулык, аның өстенә чыштырдавык элпә түшәде. Салкын тәмтомнар, аш-су салынган савыт-саба, елтыр эчемлек шешәләрен, нечкә һәм юан билле, тирән чокырлы һәм җәйпәк бәллүрләрне алар ярыша-ярыша өчәүләп ташыды.

— Безнең Чаллыда бернәрсә дә сатып алганыбыз юк әле, — диде Зәвилә ханым, үзен гаепле санагандай. — Болар барысы да Чапаевскидан кайткан җиһаз...

— Колагыгызга гына әйтәм, — дип пышылдады Гегель Әфләтүнович. — Мин анда... Чапаевскида... э-э-э... химик агулау кораллары өчен җир асты һәм җир өсте саклагычлары төзедем. Тәэминат — хәрбиләрнеке, бөтен нәрсә тулып ята иде...

Хуҗаларына гына түгел, мондагы мохиткә дә өйрәнә башлаган Җәүдәт арыган күзләре, алҗыган зиһене белән беренче ачышын ясады: фатир гүяки кичә генә сатып алынган байлык белән шыплап тутырылган. Икенче иң тетрәткән ачышы шуннан гыйбарәт иде: монда үз бәясен белмәгән яки белеп оныткан бер генә нәрсә дә юк иде. Әйе, сатлык хакларын йә күкрәкләренә, йә чигәләренә, йә тәпи-үкчәләренә чәпәгән һәм бары тик шуның аша гына үзләрен гражданин-әйбер итеп тойган карават, диваннар, кушеткалар, кәнәфиләр, алар өстендәге япмалар, кабарынкы мендәрләр, җәймәләр, юрганнар, чәй, аш-су, эчкелек сервизлары — өстәлгә куелган һәм чират җитмичә, куелмый калган бихисап фарфор, чех пыяласы, кытай бәллүреннән ясалган кыйммәтле савыт-саба, табаклар, әллә нинди шейкерлар, крюшоннар, рюмкалар, көрәгәләр, фужерлар, кычкырып торган чәчкәле чәйнекләр һәм чәйнүшкәләр, тоткычлар һәм кыскычлар, кыргычлар һәм угычларның берсенең дә бәяләмә хаклары куптарылмаган һәм алар, гүяки очып барышлый гына монда ялга туктаганнар да, озакламый нindидер сигнал буенча яңадан хуҗалары

белән бергә очышка чыгачак тере җан ияләре иде. Бүлмәләрнең кечкенә тәрәзәчекләренең томаланган булуын Җәүдәт хуҗаларның әле тиз генә очып чыгарга теләмәүләре белән аңлатты. Мондый әхвәл кызганыч та, миһербанлы да күренде: әйтик, үзеңнең нинди бәһале бәллүрдән эчкәнеңне ачыклыйсың килсә, салынганын авызыңа түнкәрәсең дә, бәллүрне әйләндереп, тәпиен карыйсың. Әллә шулкадәр галәми тәртип, әллә шулкадәр бәяле мохит күреп, Җәүдәт үзен дә очыш хәлендә тоя башлады...

Болай да соң башланган мәҗлес озакка сузылды. Җәүдәтнең ярыйсы гына җырлавын белеп алган Гегель Әфләтүнович аны җырлатты да җырлатты. Баксаң, Зәвилә ханым да мишәр җырларын шактый матур башкара икән. Әллә ашамый эчкәнгә күрә, Фәләхов тиз йомшарды, аннан, Җәүдәткә иртәгә китәргә дә булгач, яттылар.

Иртә белән — бу шимбә көн иде — башын җиңелчә генә төзәтеп алган Гегель Әфләтүнович аңа үз эшчеләре ясәгән үрнәк тулай торакны күрсәтергә булды. «Яш-шәмиләр, т-түшәмгә т-төкереп кенә ят-талар, — диде хуҗа, бераз тотлыгып. — Г-газ, с-су, б-бәдрәф б-бүлмә-дә... Ә б-бәдрәф эшче өчен к-кыз-зыл п-поч-мак бит ул! Ч-чүп-чарны да яткан җ-җирдән м-мусоропроводка гына ыргыт-талар, мин с-сез-гә әйтим!..»

Алар килеп җитүгә Җәүдәтне аэропортка илтәчәк Володя тулай торак каршында тора иде инде.

Фәләхов хәбәрчене каттан катка йөртте. Торакның тупсасыннан алып унберенче катына кадәр келәм түшәлгән. Юл өзеге булуга карамастан, бинада пычракның әсәре дә юк иде: монда яшәүчеләр — күбесе татарлар — күренүенчә, фикус кисмәге янында янбашы шул ук кисмәк кебек юан, шул ук фикус яфраклары кебек, озак вакытлар сөртелмичә, чаңланып беткән һәм мөгамәләдә үзен төрмә надзирателеннән дә кансызрак тоткан марҗа хатын белән сүз көрәштереп тормыйлар, аяк савытларын тышта ук салып, шым гына эчкә үтәләр дә, лифт эшләмәү аркасында салкын бетоннан оекчан килеш, арттан гына тын алып, унберенче катка кадәр күтәреләләр.

— К-күрәсез, м-монда т-тәртип бозучы юк. А-андый к-кешене үлгән дип исәпләгез. Эч-чеп күзгә ч-чалынса, ш-шундук... выжт Г-галиәхмәт!

Җәүдәтне вакыт кыса иде. Алар аскы катка төштеләр. Ишек катында, көтмәгәндә генә, Гегель Әфләтүнович үзенең аркадашы — «Жилстрой-1» җитәкчесе белән очрашты. Яков Ферапонтович Тараканов икән.

— Шәһәрдә даны таралган үрнәк тулай торак нинди була икән ул дип кенә кергән идем, — диде Тараканов. — Не обессудьте, Платоныч!..

Жанына ширбәт булып яткан бу сүзләрне, кемнән дисәгез, үзенең көндәше авызыннан ишеткән Фәләхов ачулана диме инде? Киресенчә, аның кашлары шатлыктан урын тапмый маңгаена сикерде һәм ул һич кенә дә буш куймыйча, машинасыннан шешә соратып, комендант бүлмәсендә, ашыгыч кына булса да, чәй мәҗлесе оештырып алды.

Эре сөякле, аксыл-сары йөзле Тараканов беренче карашка өрәккә, дөресрәге, әллә корт төшеп, әллә суда озак ятып, читчитләре агарынган-саргайган һәм бозыла башлаган өрек җимешенә охшаган иде. Бетон багана сыман почмаклы, сары кылчык кашлы, күзләре ниндидер оятсыз зәңгәрлек белән зәңгәрләнеп торган бу кешенең танау мөшкәләреннән генә түгел, хәтта эре җитәкчеләр генә кия торган затлы кыска тунының ачык изүе аша күкрәгеннән челек сыман эре кыллар тырпаеп чыккан. Җитмәсә, көннәрнең шактый җылынуына карамастан, ул аякларына унтылар кигән. Затлы мехлы җәнлек тиресеннән тегелгән бүреген салгач, аның муены белән башы бербөтенгә әйләнде. Гадәттә, мондыйлар турында: «Бите тулы авыз, җилкәсе тулы муен», — диләр бугай.

— Барысы да тәртиптә, рәхмәт, Платоныч, — диде кызып алган Тараканов әл-хәл сорашкан Фәләховка җавабында.— Мине монда чакырып китерүдә сезнең ярдәмегез зур булды. Татария меня встретила хорошо... Фатир булды. Ксюша да балалар белән күченеп килде. Мәктәпкә директор итеп назначили. Сезнең монда җитәкче кадрларга кытлык икән ләбаса!.. Әмма эштә... эчәләр, Платоныч!.. Татарлар эчә!..

— Мөмкинме? Бик мөмкин! — Гегель Әфләтүнович карашларының тимер келәшчәсе белән әңгәмәдәшләрен кысып алды. — Ә без аларны тыйдык, Яков Ферапонтович. Менә үзегез күреп ышангансыздыр: күзегезгә чалындымы берәр чалыш төягән төзүче? Без халыкны, ай-һай, к-каты тотабыз. Без, җ-җитәкчеләр, авыл ишегеннән б-бары тик шундый к-катылык белән генә үр-нәкле коммунистик шәһәр кешесе яс-сый алабыз. Әтү, ирененнән сөте кипмәгән м-молокосос, монда килеп, үзен т-тәм-мам җөгәнсез тота б-башлый...

— Сезнең белән килешәм, Платоныч. Әмма мин эчкечелекне тыя алмыйм, — диде аракыдан йомшарып теле ачылган Тараканов. — Аракы бетсә — одеколон, одеколон бетсә — лосьон!..

Кәефе яхшырган иде Фәләховның. Бүлдерде:

— Лосьон бетсә — стирол!..

Шулай итеп, эчкечеләр табынын алар алмашлап барлый башладылар:

— Стирол бетсә — полистирол!..

— Полистирол бетсә — аэрозоль!..

— Аэрозоль бетсә — БФ келәе, Платоныч!..

— Гм-м-м... БФ келәе — деликатес! Аңа чыбыкны тыгып болгатасың, э-э-э, сумала чыбыкка урала, савытта чиста спирт кына кала!..

— Үзе болай начар эчемлек тә түгел ул, ә, Платоныч?..

— Мөмкинме? Бик мөмкин!.. Аның әле нитхинолы да бар...

Алар көлештеләр.

Җәүдәткә кузгалырга вакыт җитеп килә иде. Кунак белән хушлашып, озатып калу өчен вестибюльгә чыктылар. Шулчак тыштан яшь кенә, күрер күзгә сөяк-сыны да катмаган, ирен өстеннән нәзек сызылган мыеклы егеткәй килеп керде һәм әле күптән түгел генә йә Минзәләдән, йә Мөслимнән бәхет эзләп, йорт-җирдән куптарылып, бөек комсомол төзелешенә урнашкан, әлегә үз теленнән башкасын юньле-рәтле белмәгән, тормышның никадәр хыянәтчел һәм тупас булуын бөтенләй күз алдына китерә алмаган һәм шуңа күрә дә үзен кара урмандагы тыныч өненнән якты аланга уйнарга чыккан риясыз аю баласы сыман тоткан, тирә-ягында бернинди афәт, хәвеф сизмәгән, мондый хәвеф өчен бернинди сәбәп бирмәгән бу сабый аракыдан кызгылт-көрән төскә кергән Таракановка җиң очы белән генә кагылып үтте булса кирәк...

— Өлкәннәрдән рөхсәт тә сорамыйча үтәсең, молокосос?! — Ул, изүеннән шакарып, егетнең болай да язгы күк гөмбәзе шикелле яшькелт җылаксып торган йөзен үзенең танавына китереп терәде. — Рөхсәт тә сорамыйсың, значит?!

— Бүлмәмә керәм, — диде егет, берни булмагандай тыныч кына.

— Что это за халя-баля? Значит, ты меня ултерям хочешь?! — Таракановның җимерелгән йөзе гүяки әллә кайлардан «Мин — Чаллы зираты!» дип кычкыра иде. — Ах, ты еще пьян?! — Ул егетне көрәктәй куллары белән сөрелдерде.

— Җибәрегез, мин сезгә нәрсә эшләгән? — Ап-айнык егет тегенең капкыныннан ычкынырга дип тартылды.

— Ах, ты еще и грубиян! Запомни, я Братскую ГЭС построил! — Һәм шунда Җәүдәт өчен көтелмәгән хәл булды. Кай арада уң кулына күн пирчәткә киеп өлгергән Тараканов, гладиаторларча киерелеп, егетнең күз төбенә томырды. Ул берничә адымга алга очып, вахтер янындагы гөл кисмәгенә барып бәрелеп, идәнгә гөрселдәде.

— Әни-әни-әни!..

— Няню вспомнил? И ты, сопляк, еще КамАЗ строишь? — Җанвар рәвешенә кергән Тараканов бу манзараны сүзсез, пәйгамбәрләр түземе белән карап торган өч адәм заты алдында ажгырып, тынсыз яткан гәүдәне уратып йөри башлады. Күз ачып йомган арада булган бу хәлгә өнемме-төшемме

дип аптырап торган Җәүдәт Гегель Әфләтуновичка күз сирпеде: ул, берни булмагандай авызын ерып карап тора иде...

Җәүдәт бу коточкыч күренешне мәңге онытмас: аяклана алмаган бозау кебек торырга азапланган егет, башын күтәреп, үзен җәзалаучыга текәлде — аның уң күзе агып чыккан иде... Бит алмасы буйлап саркыган канны сөртә-сөртә, ул һаман да дүрт аякта килеп ыңгырашты:

— За-а-а-чем? За-а-а-чем?

— А вот затем, гаденыш, чтобы ты знал, кто Братскую ГЭС построил! — Тараканов, ажгырынып, яңадан егеткә ташланам дигәндә, Җәүдәт яшен тизлеге белән аның өстенә ятты:

— Кирәкми! Алла хакы өчен кирәкми!..

— Чүп белән чүп булмагыз, Җәүдәт иптәш! Авыл сарыгы өчен КамАЗда гади процедура бит бу. Торыгыз! — Хәзер инде Фәләхов Җәүдәтне, якасыннан эләктереп, корбан өстеннән күтәрергә тырыша иде. — Без монда җинаятьчелекнең тамырын шулай итеп корытмасак, яңа кешене бервакытта да тәрбияли алмаячакбыз. Торыгыз!..

Җәүдәт, аягына басып, өс-башын кага башлады. Егет тә көч-хәл белән идәннән күтәрелде һәм агып чыккан күз, кан сугарган йөз, җимерелгән кыяфәт белән укталып, Таракановка таба атлады:

— За-а-чем, бра-а-ат? Зачем?

— По-русски заговорил, да? Заставим! — Тараканов әле һаман да котырган җанвар хәлендә иде. — А сам все выступаешь, стервец! — Ул егет янына килде, аны бушак капчык кебек кочаклап күтәрде һәм тышка алып чыгып китте... Җәүдәткә әллә нәрсә булды: тәмам ихтыярын җуеп киерелде һәм янында елмаеп басып торган Гегель Әфләтуновичның уң яңагыннан шаңнап җибәргәнен сизми дә калды:

— Рәхмәт! Исән булыгыз!..

Ишектән ике атлап, болдырдан бер сикереп, ул инде машина эчендә иде:

— Аэропортка!

Володя тимер тукмагы белән ишекне ябып маташкан һәм кузгалып киткән арада, аның күңелендә мәңгелек яра булып шундый күренеш калды: тупса баскычында ботларын аерып баскан Тараканов... тупса алдындагы баткак диңгезенә песи баласыдай ыргытылган һәм шуннан дүрт аякланып күтәрелергә азапланган егеткәй... аның чәчрәп чыккан күз алмасы күчәреннән ычкына алмаган кечкенә кояш булып бит алмасы өстендә чайкала... Йөзеннән кан ага, кан ага, кан ага! Җәүдәт күзләрен чытырдатып йомды...

— Ку, диләр сиңа!

Бу мизгелдә аның йөрәгендә нindидер иң газиз тамыр өзелде. Ул тамыр уртак Ватан дип аталган газизләрдән газиз

төшенчә булган, күрәсең. Барган уңаеннан Җәүдәт куртка төйнәлгән төенчекне шытырдатып кысты — күзләреннән дөньяның зәңгәр гөмбәзенә кан чәчрәде, тагын кысты — башыннан мие чәчрәп чыгып, ташларга сыланды, яңадан кысты — авыллар, каберлекләр, чем-кара туфраклы басулар һәм йөз еллаган урманнарны сидекле су басты, өй өстенә тәре һәм биш чатлы йолдыз кунаклады, ат юлы өстенә косыклы тимер юл ятты, чигүле ашъяулык, ак сөт өстенә дустанә үрмәкүчләр, кандала һәм тараканнар үрмәләде, шунда ук сабыйларыннан ваз кичкән ата-аналар, ата-аналарын белмәгән-танымаган сабыйлар, бер океаннан икенче океанга кадәр унике мең чакрымга сузылган державаны дустанә пычратып җыелган эшлеклеләр һәм әрәмтамаклар, бушкуыклар һәм кызыл авызлы каһарманнар, качкалаклар һәм шизиклар, исерек вокзаллар һәм җимерек дебаркадерлар, очсыз талоннар, приват-чеклар, алдын — алтын, артын бәдрәф билгән купшы банклар барысы да бергә буталды…

Барыр юлың базар булса да, кайтыр юлың тычкан тишеге, диеп юкка әйтмәгәннәр икән борынгылар. Бөтен державага билгеле бөек төзелешнең бөек мәгънәгә ия булган үрнәк тулай торакта кешеләр өчен ут, газ яна, салкын һәм кайнар су килә. Әмма анда кешеләр генә юк иде. Җәүдәт, үз гомерендә беренче тапкыр аэропортка барганда, машинада сукырайды. Бу хакта ул Володяга сиздермәде. Мондый вәхшәтлек хакында сөйләсәм, шофер үзе дә сукыраер диеп курыкты ул чакта. Һәм менә тагын кан басымы күтәрелде — күзләре күрми. Басым тигезләнү белән, иншалла, ачылачак алар…

Ул КамАЗ курткасын өенә алып кайтып маташмады, элемтә үзәгеннән төрдереп, яшьлек дусты Сабирга җибәрде.

Ахры, менә шуңа күрә кыска сырма, кырт киселеп тегелгән һәм шуның нәтиҗәсендә, күрәсең, урыска «куртка» исеме белән кергән кыска бишмәтне Җәүдәтнең һич кенә дә куртка дип атыйсы килми. Кыска бишмәт дияр иде — заманча түгел…

Язган мәкаләсен Җәүдәт «КамАЗны кем төзи?» дип исемләгән иде. Баш мөхәррир, аны туйганчы тураклап, «КамАЗны бөтен ил төзи» дигән сөмсез сөякле баш астында чыгарды.

Менә ул үзе хәзер Чаллыда яши. Кем уйлаган? Кайсы үрнәк тулай торакта булды икән бу КамАЗ өчен, Фәләхов атаганча, «гади процедура»? Төзәлмәде микән егетнең күзе? Бәлки, бераз булса да ачылгандыр, томанлы гына итеп булса да, акны карадан аерадыр егеткәйнең күзләре? Әллә һаман да бер күзе бер дә күрми, бер күзе шәүлә генәме? Чаллыда Фәләхов турында да байтак сораштырды Җәүдәт. Якыннан белүче юк. Өлкән яшьтәге төзүчеләр аның ниндидер кырын эштән соң, гаиләсен алып, каядыр чыгып олагуы турында сөйлиләр…

## III

Җәүдәт күзләрен ачып карарга курка иде. Әгәр чынлап та сукыраеп калса? Йөрәк кыллары нык нечкәргән, хиссияте нык таланган, каны кайнаган чакларда аның белән мондый хәлләрнең сирәк булса да булганы бар иде. Кояш кирәгеннән артык кыздыра, күрәсең, түбәдә шуа-шуа гөрелдәшкән күгәрченнәр каядыр кәрниз асларына барып елыштылар бугай — тып-тыныч.

Келәт ишеге киереп ачылды, аннан Сабирның тутыккан тавышы ишетелде:

— Син, гадук, әллә һаман йокы симертәсең инде? Юк, авылда болай дөнья көтеп булмый... — Ул онытылып һәм кеткелдәп көлде, аннан кулын кунакның иңенә салды: — Әйдә, малай, чәйгә чакыралар!..

Кордаш, елдаш дип әйтәсе урынга аңа Сабир шулай «годок» дип эндәшә. Үзенең нинди хәлдә икәнлеген сиздермәскә тырышкан Җәүдәт бу аһәңнән шыбыр тиргә батты һәм: «Нәрсә булса да булыр!» — дип тәвәккәлләп, күзләрен ачты — йә мәрхәбә, йә Хода, күзләргә вак иләк аша үтә алган эре он бөртекләре кебек итеп саран эңгер яктылыгы килә иде. Егылып китә күрмим дигәндәй, саклык белән генә урыныннан күтәрелде һәм әле генә камалыштан чыккан күз җәүһәрләренә көч китермәскә тырышып, керфек астыннан гына сирпеп карап, Сабир артыннан иярде. Карлыган һәм кура җиләк күзләренең яшькелт җимшәннәре кара көйгән. Әллә Җәүдәткә генә шулай күренде инде? Алар рәшәткәгә эленгән юынгычка якынлашканда гына, өйдән Сабирның төпчеге атылып килеп чыкты һәм чак кына әтисен бәреп екмады.

— Күзеңне чыгарасың бит, окаянный малай!

— Әти, әти! — диде малай, мондый вак-төяккә игътибар да итми. — Мин Коръәннең «Фатиха» сүрәсен ятладым! Әлхәмдү лилләһи раббил галәмин... Әррахманиррахим...

— На кой сдался ул сиңа? — диде Сабир, улын ярты сүздә бүлеп. — Әнә учебникларыңны, яхшы детективлар укы!..

Җәүдәт кырынган арада, Сабир авыл мәктәбенең торышы белән таныштырды:

— Элек укыту татарча гына иде. Соңгы ун елда, башкортча укытып, балаларның мозгасын череттеләр. Хәзер татары да, башкорты да кирәкми, дип, ата-ана белән совещаться иттек тә урысча гына укыта башладык. Дөрес эшләдекме, гадук?

Алар өйгә керделәр. Тышта чебен мыжлап торса да һәм бик эссе булса да, өйдә чебен дә юк, эссе дә түгел иде. Монда һәр тараф татар дөньясының бөтен төр ашларының исе белән аңкый. Алар арасында иң газизе һәм, борынны ярып кереп, авыл кешесенең йөрәгенә төшкәне — бары тик коры имән

яки каен утыны кызуында һәм бары тик авыл мичендә пешә торган икмәк әчесе иде. Әйе, күренүенчә, Сабиры авылга газ кертканнән соң да икмәген, бәлешен, коймагын һәм башка шундый камыр азыкларын пешерү ниятеннән иске мичен сүттерми калдырган икән Җәваһирә. Әнә инкубатор чебешенә охшаган кечкенә газ плитәсе янында мәһабәт Ак Әби кебек утыра ул — Җәваһирә исә ике мич арасында йөреп шактый пешенгән, ул иңендәге сөлгесе белән кызарган бит алмалары өстендәге чигә чәчләре очында көмеш алкалар кебек асылынып торган тир тамчыларын сөртеп куйды... «Күрәм бит, — дип уйлады Җәүдәт. — Аллага шөкер. Ташкеләттә тома сукыр калып, кешеләрне борчуга салмадым».

— Нишләп бу сәгать тагын алга киткән? — диде Сабир, алгы як стенасындагы сәгатьне туктатып.

— Син аны вакытында һәм дөрес итеп бормыйсың, әтисе, — диде Җәваһирә, һаман мич тирәсендә кайнашып. — Шуңа күрә йә туктый, йә алга китә, йә артка кала...

— Бәй, үзең заводить ит дөрес итеп, — диде риясыз җавабында Сабир, авыл мужикларына хас кырыслык белән. — Вакытың бардыр бит? — Аннан тагын кеткелдәп көлде. — Зато мине авыл көн дә иртән бик тә дөрес заводить итә. Заводкасы бер атнага җитә, мин сезгә әйтим...

Ул, урындык алып килеп, биектәге сәгатькә үрмәләргә иткәндә, Җәваһирә аны туктатты:

— Ярар, әтисе, соңыннан. Бер дә парадка барасың юк. Кешенең тамагы ачкандыр...

Алар тәмле пәрәмәч, майлаган коймак, яңа гына аертылган каймак, чияле атланмай, былтыргы кара бөрлегән, җиләк кайнатмасы һәм башка бихисап нигъмәтләр куелган табын янына утырдылар. Җәүдәт Сабирны утыз елдан соң күрә алуына һәм аның мондый бәхетле тормышта яшәвенә чиксез шат иде. Әмма аның һич кенәләр дә үзенең сөйлисе килми — тыңлыйсы гына килә. Шатлыкка каршы, Сабирның авызын йозак белән бикләп тә туктатырлык түгел иде. Ул икесе алдында торган бәллүрләргә аракы койды.

— Җәүдәт, гадук, мин һәм... әйдә, сезнеңчә, шәһәрчә булсын, әйе, супругам, синең безгә кайтуыңа бик тә довольныйбыз, менә, малай, аңлата алмыйм инде, — аның күңеле йомшарды, кулларын кушарлап күкрәгенә куйды, — от души инде, от души... Әйдә, кем әйтмешли, встреча хакына — фронтовой сто грамм!

— Һәм сабантуй хакына! — дип өстәп куйды Җәваһирә, йомшак кына.

Әмма Сабир салганын эчеп җибәргән иде инде.

— Сабантуй хакына — потом!.. Җәүдәт, гадук, сабантуй дигәннән. Без быелгы сабантуйга якты йөз белән киләбез. Бу фәләнен фәлән итим заманда язгы посевны благопалучны

тәмамладык. Симәнәсе дә җиргә калиброванный килеш кенә керде, удобрениесе дә достатычны булды... Күпләр сөрән салган иде, имеш, горючесмазочныйларга кытлык туачак дип. Ничего подобного! Ул бит үзеңнән тора, шулай бит, гадук? — Ул бәллүрләргә тагын аракы койды. — Аллага шөкер, горючие дә, смазочные да җитәрлек булды, механизаторлар да подкачать итмәде... Дискованиесен дә, боронованиесен дә, зябен дә срогында үткәрдек. Көзге парны инде әйтеп тә торасы юк, шулай бит? Әле күп кенә хозяйстволар малларын җәйге кардага чыгармаган, менә сиңа, Җәваһирә бәгырькәем, сабантуй!.. — Бәллүрен күтәреп, ул кеткелдәп куйды. — Эрәзве мөмкин? Хәзер безнең надой уникедән бара... Иртәгә, глава администрации праздникка үзе киләчәк. Кылган помощы өчен бөтен халык исеменнән рәхмәт әйтәчәкмен, Алла боерса! Әйдә, сабантуй хакына!

Алар күтәрделәр. Күзендәге кан басымының күтәрелүеннән куркып, Җәүдәт күтәргән бәллүрен яртылаш кына эчеп куйды.

— Процент Галләмне әйтәм... — Сабир Җәваһирәгә, син беләсең инде дигәндәй караш ташлап, эчкән аракысын, гадәтенчә, чияле атланмай белән озатып куйды. — Хе-хе-хе... Интересно бит, гадук, ә? Моннан өч ел чамасы элек президентыбыз телевидениедән выступать иткән иде — имеш, хозяйствоның һәр тармагына свобода бирергә кирәк, имеш, аерым хуҗалык, фермерлар, фәлән-фәсмәтән. Рәхим итегез, посевной площадь, трактор-механизмнар, кредит-ссуда, фәлән-төгән... Уртак тел табарбыз, имеш! Таптылармы? Таптылар! Ничек кенә таптылар әле, хе-хе-хе... Гомере буе процент исәбенә колхозны сауган Процент Галләм, авыл батракларыннан бердәнбер адәмзат, моңа алданып, «Минем үз фикерем бар!» — диеп, колхоздан аерылып чыккан иде, малай. Фермер, понимаешь! Кырлачтаудан сигез гектар йомран оясы бүлеп бирдек, ә менә механизациясен, удобрениесен, кредитын тоттырдык!.. Нигә, ахмакмыни ул президент болай да исерек колхозны таркатып, анда үз башына бәлагә бердәнбер кулак үрчетергә?! Буйсынамы кулак сиңа? Юк, буйсынмый. Нет, брат, мы вместе! Шулай бит? Бүген авылда партия юк, советлар юк, комсомол юк, народный контроль һәм башка ДОСААФ галәмәтләре юк, значит, колхоз власте президент һәм глава өчен авылда бүген шул ук партия, шул ук партия дисциплинасы, шул ук взнос, понимаешь! Зарплатаңнан тотып калалар аны — юк, син бирмисең!.. Хе-хе-хе...

— Чынлап та кызык кеше ул сезнең Процент Галләм, — дип өстәп куйды Җәүдәт, чәен җамаякка бүлеп.

— Кызык кына дисеңме? Бүген минем настроением дә нәкъ менә шуның өчен дә икеләтә күтәренке... Менә шул кулак булырга хыялланган Процент Галләм, мин сиңа әйтим,

бүген миңа, үзе төкереп чыккан колхозга... — ул буылып көлде, — ат сорап килгән. Юк, колхозсыз яши алмыйбыз без. Вот, үзең әйт: колхоз кем кулында? Минем кулда. Мин кем кулында? Глава кулында. Глава кем кулында? Президент кулында. Значит, партия кем кулында? Әйе, бүген иртән йомылып кына правлениегә килеп кергән Процент Галләмне күргәч, настроением күтәрелеп китте. Ни өчен дигәндә, гадук... аның аерым хуҗалык булып яшәгән картатасы колхозга нибары сугыштан соң гына керә, ә менә аның өч ел элек кенә колхозны ташлап чыккан батрак оныгы бүген... юк, трактор, «КамАЗ» сорап түгел, ат... ат сорап кире колхозга килгән! Бүген авылда кулак булу өчен посевной площадь, удобрение, механизация генә җитми. Җир эшкәртү өчен пләмә, нәсел-ыру кирәк! Ә кайда Процент Галләмнең балалары? Шул ук шәһәрдә, шул ук КамАЗда, гадук! Бәлки, ул КамАЗга утырган пеләмәшләрен авылга тартып, кулакка әйләнеп, картлыгын мәчеттә, намазлык өстендә үткәрермен дип уйлаган булгандыр? Тот капчыгыңны! Пеләмәшләр бит, КамАЗ батрагына әйләнеп, ленивый бизләрен симертә, әйеме, гадук?

— Әлегә авылда мәчетебез юк шул, — дип, моңсу гына өстәп куйды Җәваһирә. — Аллаһы Тәгалә тиз генә килеп җитә алмый...

— Син, Җәваһирә, гел шулайсың, понимаешь... Сөйләшүне, бурсык баласы кебек, читкә алып керәсең дә китәсең. На кой сдался ул безгә мәчет? Әнә Бохарайлар мәчет бетерде. Йә, шуннан нәрсә булды? Намазга йөрерлек картлары юк. Орлык киптерү өчен зерноскладларым, хранилищеларым минем болай да җитәрлек... — Үзе эчеп җибәргәннән соң, ул Җәүдәтне ай-ваена куймый кыстый башлады: — Тот, гадук, тот. Мин нәрсәдә туктаган идем әле? Иртәгә безгә глава администрации үзе килә дип әйтмәдем шикелле? Әйе, үзе киләчәк. Башкорт. Тау ягыннан үзе. Шулай да ничава егет. Агыйдел аръягы районнарында башкорт булмагач, без аны каян алыйк ди? Тау ягыннан китертәбез — и баста! Докладын үзе белән алып килмәсә дип, былтыргысын яңартып куйдык. Обычно ул урысча гына сөйли... Син, гадук, алай нәзберекләнеп утырма әле, әллә нигә бер кайтып!.. Ну, хәзер халык та, мин сиңа әйтим... Сабантуйга чиккән тастымалын, бүләген, тәкәсен түгел, кысыр тавыгын да бирми, малай. Кая ди ул безнең сабый чаклардагы шикелле колгага бәйләп бүләк җыю? Бар, тоттырырлар! Подарокларны колхоз бөтенесен үзе алды. Һәр колхозникка зарплата исәбеннән берәр ящик аракы бирдек. Әле без былтыргы иген хакын алмаганбыз, шуны беләсеңме син, гадук?!

Җәүдәт тышка күз салды. Анда Сабир күзеннән атылып чыккан яшь кебек караңгы иде.

Кинәттән сиздермичә генә кергән Зәбирнең кыңгыраудай зеңгелдек тавышы яңгырады:

— Әти, әти! Без, малайлар, Зөфәр хәзрәт белән йорттан йортка йөреп чыктык... Тәкбир әйтергә, әйе! Әлхәметдин абзый исерек, Гарәфетдин абзый: «Ул миңа кирәкми», — ди, Розалин абзый: «Мин тәкбир әйтә белмим», — ди, Шәвәли абзый: «Мин оялам», — ди... Шуңа күрә иртәгә, таң белән... — Малайның ашыгып сөйләүдән тавышы тыгылды. — Сабан туе алдыннан тәкбирне без, малайлар, үзебез әйтергә булдык. Әйе, әйе, алдан Зөфәр хәзрәт бара! Без арттан... Менә шулай итеп! — Ул идән уртасына басты. — Уң кулымны колак артына куям, башымны уңга борам һәм тәкбир әйтәм — ля иляһу илялаһу мөхәммәде рәсүлуллаһ!.. Аннан сул кулымны колак артына куям...

— Тапкансың эш! — диде Сабир, гадәтенчә кырыс кына. — Әнә сәгатьне төзәтер идең, ичмасам!..

Җәүдәт тагын тышка карады. Өйнең эче бик якты, тышта эңгер иде.

Иртәгә сабантуй иде.

*1993—1995 ел.*
*Чаллы, Чехово, Башкортостан*

## КАЗЫКТАГЫ ТАЛЬЯН

*Халык гармунчысы Фәйзи Биккинин истәлегенә*

### I

Казуыннан туктап, ул билен турайтты.

Аннан, иелә биреп, башын какты: кабадагы көнҗәләгә охшап тузгыган чәчләреннән энҗе тир бөртекләре сибелде. Бу тир, үзәккә төшеп, күзләрне кисә, каһәр. Әгәр хәзер көзгегә караса, йөзенең тартылып, хәнҗәр йөзе сыман төссезләнеп калганлыгын абайлар иде ул. Әйе, җир эше — ир эше. Димәк ки, тир эше. Көрәгенә таянган хәлдә кайчандыр колагына чалынган бер юләр мәзәкне дә исенә төшереп, авыз чите белән генә елмайгандай итте. «Әтиеңне җирләргә нигә кайтмадың?» — дип сораганнар, имеш, Донбасста яшәгән бер зимагур шахтердан. «Ә нигә кайтып азапланырга? — дип җавап биргән, имеш, теге. — Беләбез без җир эшен».

Уйлап чыгарса чыгара да куя инде безнең халык. Татарда була торган хәлме инде шушы?

Маңгаеннан саркыган тозлы тирен җиң очлары белән

сыпырып, кояшка күз салды. Ярыйсы гына үрмәләп өлгергән! Һава монда да, кояш әйләнешендә җайлап кына көн яктысына чыгып барган абзар күләгәсендә дә шактый җылына, хәтта бөркүләнә башлаган түгелме?

Ул тегермән ташы сыман шыгырдап кипкән телен чак-чак әйләндерде. Көрәген үзе чыгарган балчык өеменә кадап куйды, һәм, эссе капкан чыраен җиләсләргә теләп булса кирәк, янәшәсендәге ат башыдай әрекмән яфрагын өзеп алырга дип үрелгәндә генә, әрекмәннәр арасында агарып утырган пыяла чирекне* абайлап алды. Аның йөзендә шатлыклы сискәнү чагылды. Аһ, әйрән!

Ул үңәчләренә кадәр көйрәп сусаган иде.

Кем әйтмешли, «сәтсиәлистик ярыш ялкынында» чамасыз янып һәм ялкынланып китеп, ул картинәсенең борын төбенә генә салкын әйрән чыгарып куйганлыгын да онытып җибәргән ләбаса!..

Аның авызы татлы селәгәй белән тулды.

Әмма ул ләззәтне үз теләге белән суза иде.

Ул чокыган чокырыннан чыкты, моннан атна-ун көн чамасы гына элек Ихсан дусты белән Имәнлек урманыннан кое баганалыгына дип алып кайткан, әле булса каезланмыйча, кояш кызуында пешенеп, кайры әчесе аңкытып яткан имән агачына килеп утырды, аннан үрелә биреп, әрекмәннәр арасыннан әйрәнле чирекне әләктереп чыгарды. Савытны сырып алган салкын тир бөрчекләре аның сусавын тагын да үчекли һәм үсендерә иде...

Һәм ул бугазына, күкрәгенә капкан ялкынны сүндерә алмас сыман ашыгып, чаптыр-чоптыр китереп әйрән чөмерә башлады...

Боз кебек салкын, әремдәй хуш исле, дәрманлы, каймак сыман йомшак, тәмле һәм куе иде бу әйрән!..

Катыгына кашык өсте каймак, чеметем генә тоз, чеметем генә сода салып болгатылган һәм күбекләнеп күпертелгән иде шул бу газизләрдән газиз мал агы!..

Катык, әйрән дигән нәрсәгә бик тә талымсыз, комсыз иде шул ул. Әйрән аның тормышта тойган беренче тәм ләззәте иде. Әйрәннең авыз бозылу һәм күкрәк, ашказаны чирләренә каршы никадәр көчле шифа булуын ул әле бөтенләй белми иде югыйсә. Әйрәнне онытылып эчте дә эчте. Авыз читләреннән саркыла биреп, ачык изүдән иң башта киң, сум итләре бүселеп торган күкрәгенә, аннан күкрәге буйлап кендек чокырына агып төшүен дә сизмәде...

Әйе, үзләренең коесы суында болгатылганга шулай тәмле бит бу әйрән! Әле сез белмисездер дә, аларның бит үзләренең

---

* Чирек — өч литрлы пыяла савыт.

коесы бар! «Үзләренең коесы бар», — дип юкка гына җырламыйлар, әлбәттә. Югыйсә тәмам җәфаланган аның картинәсе коесыз. Әткәсе фронтка китәр алдыннан казый башлаган булган ла ул коены, әмма казып, эш итеп бетерә алмаган. Авыл җирендә коесыз яшәп буламы? Көянтәңне асып, айт диген дә күрше коесына йөгер, тайт диген дә күрше коесына йөгер. Әй куанды картинәсе, ул үзләренә кое казыйм дигәч! Ничек элегрәк килмәгән егетнең башына үзләренә кое казыту уе? Хәер, кое казу дигәч тә, ул сиңа онлаган тары коймагын майда йөздереп ашау түгел. Аңа бит дәрт-дәрман, көч, мачтырлык та кирәк. Гыймакай бабасы — Гыйльметдин бабаларын авыл халкы шулай гына атый — һәм Ихсан белән өчәүләп өч көн дигәндә казыдылар да куйдылар. Бура да төшерделәр. Бар тирә-якка даны таралган мич чыгаручы, бура бураучы Гыймакай бабалары яратмаган кешесенә эшләү түгел, сөйләшеп тә тормый. Теле дә аның чалгы кебек: кыеп кына ала. Ә менә Бәгъремне ул кочагын җәеп каршылады дип әйтергә мөмкин.

Юкәсен абзар баганасына чалып аркан ишкән карт белән аның арасында менә шундыйрак сөйләшү булып алды:

— Гыймакай бабай...

— И-и, агач тел! Сөекле Гыймалетдин бабабыз, диген!..

— Гыймалетдин бабай, мин сиңа...

— Мин сиңа, имеш! Нәрсә, без синең белән казлар көтеп үстекме? Гыймалетдин бабай, мин сезгә, рөхсәт итсәгез, дип башларга кирәк!..

— Гыймалетдин бабай, мин сезгә, рөхсәт итсәгез...

— Шуннан?!

— Гыймалетдин бабай, мин сезгә кое казышырга ярдәм итмәссез микән дип килгән идем...

— Һы. Кем кемгә ярдәм итәр бит әле. Кайсыбыз соң анда нәчәнник булачак, ягъни мәсәлән? Кем кое богазын үткәрәчәк, кем су алкымын эзләп табачак?

— Син, әлбәттә.

— Бәс, шулай булгач, син миңа: «Гыймалетдин бабай, сез безгә кое казып бирмәссез микән?» — дияргә тиешсең, агач тел!

Үсмер бабасының аның белән шаярып сөйләшкәнлеген аңлап алды.

— Сиңа бит без дә чокышачакбыз!..

— Бәй-бәй, син әле миңа ярдәм итмичә болдырдан гына карап торыр идеңмени? — Карт эче катып көлә башлады. — Кара син аны, каян килгән гөбернатыр! Ярар, килермен. Рәхмәт чакыруыңа. Тукта, ничә яшьтә әле син?

— Унбишем тулып, уналтыга чыгып барам.

— Алтмыш алты, диген! Маладис, улым! Күп кенә ирләр алтмыш алтыны ваклап та кое казыта алмыйча китеп баралар. Ә син... уналтыда гына! Болай булса, авылда бер җегет кеше

туа, димәк. Хәерле сәгатьтә!.. — Сугыш һәм сугыштан соңгы чорда ирләрне ифрат та сагынып өлгергән Гыймалетдин карт кәефе килеп сөйләнә иде. — Барам, бармый диме тагын? Ничек кенә барам әле! Син дигәндә — мин идәндә! — Аннан хәйләкәр генә күзләрен кысып алды. — Картинәңнең мич башын да караштыргалаштыр. Ачы балы бар микән? Син дигәндә, мин... шырпы кабыннан да егылып төшәргә әзер!.. Кхе-кхе...

Эшләре гөрләп барды. Тик шунысы гына, Гыймакай бабайларының хәтере генә тишек иде. Егетләр, аның хәтерсезлегеннән яшереп кенә булса да, көлгәләштереп алалар. Ничек көлмисең инде: ул бит кое төбендә салган үлчәмен сикереп җир өстенә чыккач, җир өстендә салган үлчәмен сикереп кое төбенә төшкәч оныта. Бәгърем белән Ихсан булмаса, ул, бәлки, барлык гомерен шулай өстән аска, астан өскә сикеренеп үткәргән булыр иде. Әйтик, бабалары кое төбеннән: «Әһә, бер метр да егерме сантиметр икән», — дип, җир өстенә чыга да, аннан шундук күзләрен тасырайтып: «Мин ничә дигән идем әле?» — дип, егетләргә уктала. Әкәмәт!..

Бәгъремнәрнең коесына суга елга аша Разия да килә башлады. Үзләренең коесы да бар инде югыйсә. Ләкин суы татырлы, тозлы. Бәгърем коесының суы бик тәмле булып чыкты шул.

Үзләренең коесы бар,
Безгә килеп су ала, —

дип, ничек кенә җырламассың инде. Разия искә төшү белән, Бәгъремнең йөзе шадраланып куйды. Бер уйласаң, Разия аңа беркем дә түгел. Бары тик күрше кызы гына. Каршыда, Өязе елгасы аша гына аларның өйләре. «Разия! Рәкыя! Дарига! Һәдия!» Раһиба җиңгинең шулай җәен дә, кышын да, көндезен дә, төнен дә кызларына эндәшкәнен тыңлап үсте Бәгърем. Нәкъ аның кебек фронт ятимәләре инде алар. Араларыннан өлкәннәре, Разиялары кияүгә чыгып маташа бит әле. Менә әле туй мәшәкатьләре бара шунда. Ул шул туйны озатырга чакырылган. Күрше егет буларак кына түгел, күбрәге — гармунчы буларак. Гармун уйный башлаганнан алып аның гомере икегә бүленде бит: гармун уйный башлаганга кадәр һәм гармун уйный башлаганнан соң. Бер кешедә ике кеше яши: «мондый гына кеше» һәм «бик тә кирәк кеше». Әй, нәрсәсен сөйләп торасың инде аның! — Егет, чәмләнеп китеп, кирәк йөзен сыртына кадәр балчыкка батырды һәм колагын торгызды: таллык аръягында әлегә шылт иткән тавыш та ишетелми иде. Кайдадыр Ашкадар, Ишембай якларында яткан авылдан килгән кода-кодачалар кунактан соң мырлап йоклыйлар, күрәсең. Егетнең күңелендә нindидер такмаза да яралып куйгандай итте:

Мырлап йоклап яталар, ди,
Мыр-мыр кодаларыбыз…

Бүген шул кодаларны, ягъни мәсәлән, туйны, ягъни мәсәлән, Разияны озатачаклар, имеш. Разияны кияү егете Агыйделнең аръягындагы авылга алып китә… Гарьлеге ни тора!..

Кайсыдыр күршесе ихатасында аяныч итеп тавык кытаклады. Ниһаять, аны чыркылдатып тоттылар. Ул тагын бер тапкыр аянычрак итеп кытаклады да тынды. Чалдылар.

Әй, алып китмәсә тагы!..

Кемне булсын, шул Разияны әйтә инде.

Уч төпләрен төкерекли салып, яңадан казый башлады. Коесының сиртмәле булуын, әллә кайлардан күренеп, чыңрау торна сыман сайрап, чакырып торуын тели ул. Атасы да коесын сиртмәле итәргә теләгән булган, имеш. Шул сиртмәнең баганасы өчен чокыр казый бит инде. Дөресен әйткәндә, бу эшкә бүген тотынырмын димәгән иде. Үзенә тынгы тапмаганга гына башлады аны. «Корал эшли — ир мактана» дигәндәй, эше җайлы гына бара югыйсә. Бу барыш белән барса, бер-ике сәгатьтән очына да чыгуы мөмкин.

Балчыгын өскә ыргытудан туктап, чокырны тирәнәйткән арада, ул балчык өемен сырып алган чыпчыкларга игътибар итте. Селәүчән эзлиләр. Өемгә көрәктән балчык килеп төшкәндә, дәррәү күтәреләләр дә, ул чокырга иелү белән, пырылдап, яңадан куналар. Быел балчыкта, ни гаҗәп, селәүчән аз. Табыш аз булган саен, мәхлуклар ерткычлана, берсе икенчесенең өстенә үк менеп бара…

Ул соры туфрак катламын күптән үтте. Кара туфрак катламын да үтеп, кызыл балчыкка җиткәч, берәр көрәк алганнан соң туктаса да була. Бәгърем белә: чокыр тирәнлеге кендек тәңгәленә җитсә, шул җитә.

Селәүчән дигәннән. Быелгы ел сәерлекләре аның белән генә чикләнми. Июнь уртасы да үтеп баруга карамастан, мәсәлән, туфракта боз салкыны саклана. Җәй быел, укытучылары Мәхмүт абый әйтмешли, «кискен континенталь» килде. Майда гына түгел, хәтта июньдә дә халык өстеннән бишмәт төшмәде: яңгыр яуды да кар яуды, яңгыр яуды да кар яуды. Авыр кургашын болытлар, гел генә җир өстендә асылынып торып, тереклекне өшетте. Баскан җирдә җир лычкылдады. Алмагач, шомырт, чия кебек җимеш агачлары июнь башларына кадәр чәчкә аталмыйча утырды. Чәчкә атарга йомарланган җиләкләрнең касәләренә кар тулып, төннәрен суык өч-дүрт градуска җитсә дә, алар, ни гаҗәп, өшемәде дә, туңмады да. Кырау да сукмады хәтта ки! Чәчкәгә йомарланган бөреләр елмаерга дип авызын ачып, елмаюдан тыелып калган тамашачыларны, сабантуйда җиңеп тә, бүләк көтеп катып калган көрәшчеләрне хәтерләтте.

Бәгъремнең иң яратмаган фәне — зоология. Аннары биология. Күз алдында кыелып кына очып кереп, туган абзарың бәпкәләренә оя корган карлыгач канатлары, әрекмән яфракларын тикшереп утыр инде шунда! Әмма өниме ул аларны, әллә өнәмиме, егетне кызыксындырган сорау җавабын көтә иде: нишләп үсемлекләрне бары тик алар чәчкә аткан чорда гына кырау суга? Гүяки Суык Бабай аларның чәчкә атканнарын көтеп кенә тора. Үсемлекләрнең чәчкә ату дигәннәре аларның шул беренче мәхәббәтләре буладыр бит инде ул? Нәрсә, тереклекне сынап чыныктырумы бу? Ныкларны гына сайлап алумы? Әгәр шулай икән, Ходай Тәгалә тарафыннан артык кансызлык күрсәтү булмыймы бу? «Алмагачлар чәчкә ата майның унбишләрендә», — дип җырласак та, нишләп быел алмагачларны хәтта кар астында да кырау сукмаган, чөнки алар әле чәчкә атмаган иде. Аларга карап, егетнең куркып калган чаклары да булгалады: табигать — бар төр үсемлекләр һәм чәчәкләр серкәләнмичә кысыр калса? Бөреләр яфракланмас борын саргайса? Үләннәр үсмәсә, печәннәр булмаса, игеннәр уңмаса?!

Әмма юкка гына борчылган Бәгъврем. Май азакларында кояш бер-ике көн бу җир кортларын тирләтимме, әллә өшетимме дип килделе-киттеле торганнан соң, шундый мөлаем итеп елмайды ки — ышанасызмы, ике-өч көндә һәммә нәрсә аякка басты, тәртәләрен киерде; акланнарда һәм болыннарда юан ботлы балтырганнар, кузгалаклар буынга сикерде, ниндидер эре сабаклы җир җиләкләре хәтта ат юлларыннан төртеп чыкты; ышанасызмы, гомердә чәчкә ата белмәгән кычыткannar ап-ак кыңгырау чәчкәләр белән гезгелдәп утырды; җирдән «инде үлде, инде югалды» дип саналган, дистә еллар буе хәрәкәтсез яткан дистәләрчә төр орлыклардан Ходай Тәгалә мәңге күрелмәгән үсемлекләр үстереп чыгарды...

Әйе, быелгы табигать чаманы белмәде. Май уртасындагы биш градус суык июнь башларында исә утыз градус эсселек белән алышынды, ышанасызмы? Кымызлык сабакларында гөжләп күпереп, ачы сут күтәрелде. Тын юлларына кадәр буып, бар дөньяны бал исе басты, моңарчы планын үти алмаган бал кортлары төнлә дә, фонарьсыз-нисез, вҗәткегә ширбәт ташыды. Көн эссесе йөзгә капты. Елгаларда су кайнады, салкын азык эзләгән балыклар ярга сикерде...

Әйе, башта суытса да, өшемәде, аннан ничек кенә кыздырса да, янмады-көймәде быелгы табигать. Шунысы тагын да кызык, һәркайсы яшел чүмәлә булып күпергән агачларга дикъкать белән карасаң, аларда кара чәчтәге бер учма чал кебек агарган, саргайган, каяндыр килеп чыккан утлы җил тарафыннан көйдерелгән, суык тын җепселләре белән өшетелгән аерым ботак, аерым учма, хәтта аерым яфракларны

шәйләргә мөмкин. Язмыш! Агач ябалдашы гөрләп яши, әменә аның бер тарафы, бер шивәсе йә чирли, йә бөтенләй үлек. «Җитмешкә җитеп, мондый җәйне күргәнем юк иде, — дип кабатлый иде еш кына Гыймакай карт. — Бер вәхи төштә керде әле үземә. Өязе буйлары ап-ак шомырт, имеш. Арыш уңачак быел, Алла боерса!» Икенче бер чагында карт: «Ахырзаман алдыннан табигать шулай үрә басар, дигән китап, — дип тә сөйләнеп ала. — Горур, шагыйрanә булыр, дигән. Игеннәр ифрат та уңар, җимешләр ишелеп өлгерер, Дәҗҗал дөньяга чыгар, дигән...»

Аның Дәҗҗалы нәрсә икән инде тагын?

Аерым кешеме ул, әллә һәркемдә дә булган бер котырынкы халәтме?

Кинәт тешләрдә кайралып, чыелдап, көрәге нәрсәгәдер төртелеп туктады. «Шушы мәллә Дәҗҗал дигәннәре?» дигәндәй, егет сискәнеп куйды. Көрәге, аннан бармаклары белән озак кына чокынып азапланганнан соң, ул ниндидер чылбырлы тимер тартып чыгарды. Тазартканнан соң аның чүкелеп ясалган борынгы йозак икәнлеге ачыкланды. Богау йозагы булырга кирәк. Бәлки, авылларына нигез салган Әкрикачкынга да катнашы бардыр әле аның. Укытучы Мәхмүт абыйларына күрсәтергә кирәк булыр.

Ул елмаеп куйды. Әгәр ул шулай чокына-төртенә Җир шарының теге ягына барып чыкса, юлында нинди генә хәзинәләр тапмаган булыр иде икән?! Хәзер инде ул тиле шикелле шаркылдап көлә иде. Күз алдыгызга гына китерегез: менә ул, тальянын күтәреп, җирнең аргы ягына барып чыга да «Сарман»ны уйнап җибәрә. Анда исә казан асканнар. Күз күреме җитәр тарафларга кадәр һәркайда казан асканнар. Учаклардан төтен күтәрелә. Ниндидер лампапуду дигән кыргый адәмчекләр аңа каурый агачлар астыннан: «Әйдә, безнең белән кеше ашарга! — дип кычкыралар. — Казанга якынрак кил, теләгән калҗаңны сайлап согын!» Үзләре ят җирләрен яфрак белән дә капламаган, оятсызлар. «Мин бит үзем Казаннан, — ди аларга Бәгърем. — Без, казанныкылар, үзебез, кеше буларак, кеше ашамыйбыз. — Ул тагын да тальянында сыздырып җибәрә, имеш. — Әгәр сез, безнең кебек, тальянда уйнасагыз, кеше дә ашамас идегез!» «Казаннармы кеше ашамый?! — дип шаулаша-көлешә, бөтенләй тузга язмаган нәрсәләр сөйли башлый лампапудулар. — Кеше итен кайнатучы казан сезләрдән чыккан түгелме? Ашыйсыз, бер-берегезне яшертен ашыйсыз! Ничек кенә ашыйсыз әле! Кавемнәрегез белән ашыйсыз, исемнәрен дә онытасыз, аннан соң, исерешеп, шушы лыгырдык гармунызда уйный-уйный, шул йолкыш «Чабата»гызга биисез! Шуңа күрә сезләрне дөнья белми. Ә безләрне бар дөнья белә. Чөнки без соклан-

гыч барабаннарда тукылдатабыз! — Тирә-якны тире барабан тавышлары баса. — Без яшермичә кеше ашыйбыз да барабаннарга биибез! Мабимбо-бомбо! Ашаганнан соң барабанга менеп сикерсәң, корсакка күбрәк сыя! Мабимбо-бомбо!»

Бр-р! Егет үз уйдырмаларыннан үзе үк чирканып куйды.

Аны кемдер чакырган сыман тоелды.

Ул колакларын шомрайтты. Аһәң елга аръягыннан — ул чакыру көткән тарафтан түгел, ә якыннан — үзләренең болдырыннан икән.

— Бәгърем! Канатым!

Чагу-сары күлмәгенең сарысы сыек читән аша саркылган, зәңгәр яулыклы башы исә читән өстеннән зәңгәрләнеп торган картинәсе аваз сала икән аңа.

— Нәрсә, картинәй?

— Туй озатырга барасыңны онытып җибәрмәдеңме дип кыбырсуым. Баярак тагын бер мәртәбә әйтеп чыктылар. Гармунын онытмасын, диделәр...

— Онытмадым ла... — Разияның туен искә төшергән өчен Бәгъремнең картинәсенә ачуы килеп китте. Аңардан башка белмиләр иде. Аннан, уч төпләрен төкерекли биреп, өстәп куйды: — Аларга шул гармун гына кирәк инде...

Берүзе ике кешедән тора бит ул хәзер. Берсе «мондый, прастуй», икенчесе «кирәк кеше, гармунчы».

Ул яңадан казырга тотынды.

Аңлагансыздыр: Бәгърем исемле ул. Бәгърем исемле бәгърем, димәк. Аңлагансыздыр: аның исемендә үк ниндидер гүзәл сер, әйтеп бетелмәгән мәгънә, матур шөбһә, хәтта куркыныч фаҗига яшеренгән иде. Уйлап кына карагыз: Бәгърем кадәр бәгъремне яратмаска, инкяр итәргә, аеруча ташлап китәргә мөмкинме? Мөмкин түгел. Шуңа күрә дә Бәгърем бит ул. Син Бәгъремгә: «Мин сине яратмыйм, Бәгърем», — дип әйтеп кенә кара!..

Үсмерлектән егет чорына кереп җитмәгән, туп кебек тыгыз, беләкләре, күкрәкләрендәге сум итләре түгәрәкләнеп, бүселеп торган егеткәй әле исеменең мәгънәсен үзе дә аңлап җиткерми. Әмма ул аның тарихын белә: әнисенең бердәнбер мирасы ул. Алты бала табып, Бәгъремнән башка берсе дә исән кала алмаган. 1939 елның кышында фин сугышына китеп хәбәрсез югалган аның әтисе. Ул чакта Бәгърем әле карында гына булган. Кызу печән өстендә, урманда, вакытыннан алда дөньяга килгән ул. Каны күп агудан әнисе урманда ук җан биргән, мескинә. «Исән калса, Бәгърем кушыгыз», — дип әйтеп өлгергән ул. Уйлап тапкач та тапкан инде югыйсә. Хәер, ул аны күптән алдан уйлап куйган булгандыр инде. Аның үз исеме дә бик матур, бик тә җилле булган: Тәнзилә! Ул бу көмеш исемне туктаусыз кабатларга риза: тән — зиллә!

Зиллә! Зеңлә! Җиллә! Таң җиле! Зилләр, җилләр, кыллар!.. Таңда кымыз пешергән сөян гөбе кебек зеңгелдәп торалар алар!..

Аны әнисенең бертуган апасы — Өммегөлсем картинәсе тәрбияләп үстергән. Ул аңа, аларда, көньяк Урал татарларындагыча, «карт инәй» дип әйтергә өйрәткән. Дөрес тә инде. Үз инәсе, «яшь инәсе» булмагач, аны аякка бастырган кеше кем дип аталырга тиеш инде «карт инәй» дип аталмыйча? Өммегөлсем картинәсе имезмәгән аны имезүен. Үз инәсен бер генә тапкыр да талкырга өлгермәгән малай актыгын беренче тугыз айда картинәсе имчәк балалары булган хатыннарга йорттан йортка йөртеп имезгән. Исемлек буенча, димәк. Аннан кәҗә сөтенә күчергән.

Балчык өеменнән селәүчән бүлешә алмыйча, тагын да чыпчыклар чыркылдашты. «Минем менә шулай бәхәсләшергә, кызык итеп кенә булса да, төрткәләшеп тарткалашырга, тапкан малны бүлешергә бер туганым да юк бит, ичмасам, — дип уфтанып алды егет. — Тома ятим бит мин. Инде менә Разия да китеп баргач...»

Аңа нишләптер үзе казыган чокырдан бихисап хәзинәләр чыгар кебек тоела. Гүяки чокырның теге очында, ягъни аның еракта, бик ерактагы төенендә ул нурлар уйнатып яткан Ак Йолдызга тап булачак. Көрәк очы шул Ак Йолдызга тиеп кайтарылу белән аннан гөрләп саф чишмә ургылачак...

Ул Ак Йолдыз — саф чишмәне кем белән бүлешер соң ул? Разия да китеп баргач...

Ул тирән итеп уфырды. Үзен биләп алган авыр уйларны куарга тырышкандай, ярсып-ярсып казый башлады. Дөп-дөп. Әмма ул мал эзләп һәм мал бүлешү өчен туган эзләп читкә китмәячәк. Авылын ташламаячак. Дөп-дөп. Бу келәт кебек алачыклары урынына ул алты почмаклы, калай түбәле, зәңгәр күтәрмәле йорт бетерәчәк, Алла боерса. Дөп-дөп. Ул Өязе буенда колхозның бер дигән яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасын булдырачак. Самавыр кадәр карбызлар, ат башы кадәр татлы кавыннар, беләк кадәр кыярлар, йодрык кадәр алмалар, бармак башы кадәр карлыганнар, кура җиләкләр үстерәчәк. Дөп-дөп. Тукта, тукта. Өйләнәчәктәме? Балалар да үстерәчәкме? Кит, юләр. Нинди балалар үстерү ди тагын? Ул бит әле үзе бала! Ә менә аның яшьтәше диярлек булган Разия бала түгел идемени? Ул менә кияүгә чыкты! Аны бүген җан-фәрман китереп каядыр Ашкадар буйларына алып та китәчәкләр... Тукта, тукта. Нинди туй? Разия шулай үскән дәмени инде?! Картинәсе әйтмешли, өлгергән дәмени?! Димәк, ул аңардан алда барган, алдынгы кеше? Беренче сорт, беренче кавемнән?!

Ул көрәк сабына таянган хәлдә башын артка чөйде дә,

тешләрен күккә ыржайтып, гадәти булмаган каһкаһә белән көлә башлады:

— Ха-ха-ха-ха-ха!..

Чыпчыклар өркеп һавага күтәрелде.

Бәгърем, көрәген ташлап, чокыр читенә тотынды һәм көлүен дәвам итте:

— Ха-ха-ха-ха-ха-ха!..

— Шашмагансыңдыр бит, канатым?

Болдырдан картинәсе кычкыра икән. Ул аңа шулай «канатым» дип эндәшә.

— Бисмилла әйтеп, як-ягыңа төкерен!..

Каһкаһәнең соңгы авазлары кинәт шиңде һәм сүнде:

— Ха-ха...

Чынлап та, шашкан мәллә ул? Монда, чынлап та, уйга калырсың!

«Өйләнү — сөйләнү түгел» диләр. Нигә алай диләр? Өйләнмичә сөйләнеп, сөйләнмичә өйләнеп булмыймыни? Өйләнү өчен нәрсәләр кирәк? Егет кирәк, кыз кирәк. Бу — бер. Егеткә дә, кызга да мәһабәт буй-сын кирәк. Баш кирәк, әлбәттә. Аннан, ызначитсы, йөрәк кирәктер. Өйләнү дигән нәрсә ике ятып, бер тапкыр да күңеленә кермәгәч, димәк, Бәгъремдә аларның берсе дә юк булып чыга түгелме?! Ә менә кичә генә чикерткә кебек чекерт-чекерт сикеренгәләп йөргән Разияда алар барысы да бар булган булып чыга, имеш.

Буй-сынны, баш дигәнне тотып карап була. Ә менә йөрәк белән нишләргә? Аны бит тотып карап булмый. Нәрсә ул йөрәк? Бәгърем моны тәгаен генә әйтә алмый шул. «Йөрәк» дигәндә аның алдыннан тиен кебек нindидер йомшак йомгак тәгәрәп киткәндәй була. Бу йомгак каршыдагы таллыклар артына кереп яшеренә, анда шундук йөзен зәңгәр шәл белән каплаган кызга әверелә дә ягымлы гына итеп эндәшә, имеш: «Мин — мәхәббәт... Мин — ярату... Мин — сөю... Мин — гыйшык...» — ди. Гүяки Бәгърем өчен аларның соңгы өчесе мәхәббәткә кадәр барып җитәргә тиешле булган өч баскыч, өч фасыл, кешенең эчендә аның үзеннән бәйсез яшәгән өч аерым кеше иде. Әйе, яратусыз, сөюсез, гыйшыксыз-мәхәббәтсез кияүгә чыгып булмагач, димәк, алар барысы да кешенең үзендә яратыла торган шаукымлы сихәтләр. Менә Бәгъремдә әлегә аларның берсе дә юк. Бәгърем дигән кешенең эчендә әлегә Сөю, Ярату, Гыйшык дигән төшенчәләр яратылмаган. Гашыйклар аның күңелендә калак сөякләреннән канатлары үсеп чыккан фәрештәләр булып сурәтләнә. «Гашыйклар барысы да канатлы халык, аларның канатлары күренми генә, — дип нәтиҗә ясады егет. — Алар җир буйлап түгел, җир өстеннән бераз гына югары очып йөри торган шаукымлы затлар...»

Гашыйк булган кызың синең өчен үләргә әзер торганда гына җир өстеннән очып йөреп буладыр ул. Кичә генә син бөтенләй белмәгән кеше сиңа бүген гашыйк булсын да синең өчен шундук үләргә әзер торсын, диген, ә? Менә нинди булырга тиеш ул чын мәхәббәт. Бик кызык бит бу! Бәгъремнең хәтеренә моннан биш-алты ел элек караган «Падение Берлина» дигән кино килеп төште. Әй, аптыраган иде ул чакта. Ничек аптырамыйсың ди, Гитлерның сөяркәсе Ева Браун дигән туташмы, ханыммы шунда, камалышта калган Берлинның таш базында бер-ике сәгатьтән агу эчеп үләчәген белә торып, Гитлер белән никахка керә. Моның өчен никадәр яратырга кирәк, әйеме? Абау, тәннәрең чемердәп китәрлек, әйеме? Бу бит инде кинога төшү өчен генә шулай эшләнмәгәндер, әйеме?..

Бәгърем бармак чуклары белән үзенең калак сөякләрен капшап карады. Канатлар үсмәгән иде әле. Әмма ул моның өчен үкенми дә, гарьләнми дә. Чөнки мәхәббәт ашыктырмыйча үзе килә торган могҗиза булырга тиеш. Баш җитмәс могҗиза. Гарьләнүен гарьләнмәсә дә, аптыравын яшерми. Димәк, Разия Бәгъремгә сиздерми-нитми генә шул канатларга ия булган, ул аларны төннәрен нииндидер хушбуйлар сибеп, яшерен догалар укып үстергән; димәк, Разия, аның балачак дусты, үсмерчак ахирәте — Разия кадеркәе Бәгъремгә күрсәтми-нитми, әйтми-нитми генә мәхәббәтле булып өлгергән?! Ә менә Бәгърем әле булса мәхәббәтсез кала килә?! Кара әле, бик кызык, бик мәрәкә икән бу кыз-кыркын халкы! Яшерен генә түл җыя, яшерен генә өлгерә, яшерен генә чәчкә ата, яшерен генә канат чыгара һәм... яшерен генә ярәшелеп, синең борын төбеңнән генә китеп тә бара! Син исә каласың лышык-лышык танавыңны тартып!..

...Разия кияүгә чыкты да куйды шул. Могҗиза түгелме? Бәгъремне гүяки аяз көндә яшен сукты. Алар бит әле кичә генә бер агачның ике ботагын, бер үләннең ике кыягын, бер атның ике күзен тәшкил иткән, аларның кайсысы малай, кайсысы кыз икәнлеген аерып та өлгермәгән, әле һаман балачакларында каз көткән ике җанның берсе — Разиясы, әйе, шул кара-чутыр Разиясы кияүгә чыкты да куйды. Имеш, унҗиде яшен тутырган икән. Нигә, тутырса ни! Тутырса, ташлап китәргә дигәнмени? Ә менә Бәгърем әле уналтынчысына чыгып кына маташа, имеш. Бара шул. Әмма ул авылын беркайчан да ташламаячак!

Сез, җәмәгать, игътибар гына итегез: нииндидер эт алып олаккан Ашкадар буйларындагы нииндидер Аллагуәт авылы тарафларыннан күрмәгән-белмәгән нииндидер кысык күзле бер фиргавен токымы нииндидер бер чалыш тәпиле яучы җибәрә дә моңарчы күрмәгән-белмәгән кызны алып та китә!..

Иң кызыгы шул бит әле: китә кыз бала, ике дә уйламыйча, үзе теләп китә. Әле курчакларына күлмәк тегәргә тиешле кыз, кичә генә суга барган сукмакларын, чишмәләрен, җиләк җыеп үскән болыннарын мәңгелеккә калдырып китә дә бара. Бөтенләй белмәгән-күрмәгән якка, белмәгән-күрмәгән авылга, белмәгән-күрмәгән кешегә бит. Шулкадәрле көчле микәнни бу мәхәббәт дигәннәре дә, шулкадәрле татлы микәнни бу кияүгә чыгу дигәннәре?!

Ә син менә көзге яңгырларда быжыган гөмбә кебек торасың да каласың каеннарың арасында. Гүя күрмәгәнский дә, белмәгәнский. Нигә ул чакта бу кыз бала үзе белән чишмәләрен дә, Бәгъремен дә алмый?

Менә шулай тормышның иң гади, иң каттый канунын аңлый алмый өзгәләнә иде Бәгърем. Бер-береңне белми, йөрешми-күрешми торып, кияүгә чыгып була микәнни дип аптырый иде ул. Аннан ниндидер озын колак Разия киявен мөкиббән китеп яратмый, ә бары тик «ошата» гына, яши башлагач берегеп китәрбез әле, дип әйтә икән дигән сүзләр дә җиткереп алган иде. Бу нәрсә аның бавырын тәмам ачытты: әллә шулай яратмыйча да «яшәп китү» мөмкин микән?

Бәгъремнең гармунда уйнавын ярата ул Разия. Уйнап та җибәрә, Разия челт-челт китереп күзләрен йомгалый да башлый. Нигә шулайдыр инде. Моң дигән нәрсә ул бер Бәгъремдә генә түгел инде. Ул һәркемдә бар. Гармунның үзендә дә бар. Гармун дигәнең кем кулга алса да, моңланырга гына тора бит ул. Телләренә басу белән яшен сыта. Дөресен әйткәндә, Разия гына дәртләндерде аны гармунчы булырга. «Сугыш авылны гармунчысыз калдырды, әйдә, безнең буынның гармунчысы бул!» — дип тәкрарлады ул туктаусыз. Әллә чынлап, әллә юри: «Шәп уйныйсың!» — дип мактады да мактады. Йөккә мендерде. Бер йөккә менгәч, кайсы гармунчының төшәсе килсен? Ә менә беренче көйләрне аңа шахтадан алып кайткан тальянында Карамысла Рәис абыйсы өйрәтте. Кушаматы шундый аның. Ундүрт телле, күрегенең алгы ягына ак буяу белән ромбик төшерелгән гармун әле дә бар ул. Кичке уеннарда Рәис абый уйнап җибәрү белән, әнә шул ак шакмактан чәчрәгән нурлар бар тирә-якны яктырта, малайгынам. Көмеш телләрдән коелган моңнардан кыз-кыркынның аслары күл була, мин сезгә әйтим.

Гармун дигәне төшләренә керә, моңы тешләренә сылаша башлады Бәгъремнең. Ул, ничек кенә булса да, үзенә гармун алырга тиеш иде. Әчтәт Минәхмәтенә рәхмәт: унике яшьлек малай кисәген ялланып урман кисү өчен үз бригадасына алды. Стәрлебаш ягындагы Ново-Николаевка урманнарында ай ярым буе черки ашатып, урман кисте, агач ботады, ботак ташыды ул. Учына сайрап торган җитмеш сигез сум акчаны да төшерде.

Кайтышлый Мулла-Гөлем авылына туктап, гармун ясау остасы Мөстәкыйль абзыйсыннан култык астына унике телле, шыңгыр бакалы тальян да кыстырып чыкты. Калган егерме сигез сумына картинәсенә бумази күлмәклек, бер кило каһвәле кәнфит тә алды. Унике чакрым арада унике тапкыр туктап уйнап карады ул гармунын. Туган Колтамагына арып-талып, серәеп түгел, ә башын югары чөеп, хәрби җиңүче адымнары белән кайтып керде. Гармун бит ул, җәмәгать!..

Беренче эш итеп ул гармунының күреген Рәис абыйсыныкы кебек ак шакмаклы итеп буятты. Күрекне сузгач, күрек кабыргаларының кара өслегендә агарып яктыра бу шакмак. Күзгә төртсәң күренмәс караңгыда да күренә ул. Рәис абыйсы да яратты аның гармунын. Уйнап та карады. «Гармуның настояшный күренә, гомерле булсын», — диде дә көтелмәгән киңәш бирде: «Син, яңа көйләр өйрәнәм дип, гел генә миңа чапма. Иң мөһиме — мин сине уйнарга өйрәттем. Көйләрне үзең өйрән, үз моңыңны үзең эзләп тап. Гармуныңны күтәр дә мунчага сыпырт. Чын гармунчы мунчада туа».

Ифрат та мач булып чыкты бу киңәш. Мунча ләүкәсенә шытыр-бытыр килеп «Ком бураны», «Корт чакты»лар белән менгән Бәгърем озак та үтми аннан «Җанкай-җанаш», «Кара урман», «Вәсби-Камиләкәем»нәр белән баеп төште.

Үзе моңлы булгангадырмы, белмим, нәрсәдәндер, моңлы уйныйсың гармунны, диләр иде аңа. Әмма моңга тирәнрәк кергән саен, ул тизрәк арый кебек, күрәсең, моң аның йөрәгенә төшә дә татлы итеп талый...

Өч ел эчендә күрмәгәне калмады тальянның. Ташуда да акты. Ындыр табагында бушаткан иген астында да калды. Колхозга яңа рәис булып Мәскәүнең үзеннән үк килгән Хрущев «утыз меңчесе»* Айсин абзый аны кырандасы белән дә таптатты. Хәзер юк инде Айсин. Колтамак халкының башын ике ел чамасы каңгыртты да үз башын алып олакты ул. Әллә нинди әкәмәт капма-каршылыклар төене иде ул бәндә: танкка кылыч белән каршы бара торган бер комиссар инде шунда. Ул адәм затына балык кебек ниндидер кызыл күз белән кылыйлатып карый. Белеме белән дә, һөнәре белән дә ат духтыры икән. Аны өлкәннәр фронтка барып җитмичә, кайдадыр Рязань тирәсендәге «райком мич башында танклар шартлатып» майор булган дип тә сөйлиләр иде.

Былтыр урак өстендә булды бу вакыйга.

Ындыр табагына икенче эсминәгә эшкә чыккан яшьләр басудан игеннең агылып килмәгән сәгатен чамалап, булмаса,

---

* Сүз КПСС Үзәк Комитеты Беренче секретаре Н.С.Хрущев башлангычы белән илленче еллар уртасында колхоз-совхозларга эшкә җибәрелгән утыз мең партия вәкиле турында бара.

бераз селкенгәләп алыйк дип, клубка төшеп, биешә генә башлаганда, кулында зәһәр камчысын уйнатып, Айсин килеп кермәсенме!

Усак яфрагы сыман күкрәгендә саргайган ике медален, урын җитмәгәндәй, кителенең ике як түшенә таратыплар таккан бу. Галифеләрен урамга да сыймаслык итеп җилфердәткән.

Телеграф чыбыкларындагы чыпчыклар сыман тезелешеп утырган яшьләрне чыр-чу китереп, авызларыннан төкерекләрен чәчә-чәчә, камчысы белән каезлый башламасынмы!

— Ындыр табагында иген череп гнить итя, ә сез терәлләлләм?! Адя, марш моннан!..

— Тукта, абзый, ипләп, — диде урыныннан күтәрелә биреп Бәгърем. — Бередә ат абзары түгел!

— Азбар гынамы! Сарай! — дип тартты ул Бәгърембнең җиңеннән. — Адя, марш!.. Әрмийски паррядык!

— Клуб бу. Клуб — ул совет халкын тәрбияләүдә...

— Әле син мозга сатасын? — дип җикерде Айсин. Аның күзләре каш өстенә сикергән иде. Ул камчысы белән берне тальян күрегенә тамызып алды. — Циткә бас, уняштан туган!.. Әрмийски паррядык!..

Разия аларның арасына керде.

— Сезнең яшьләрне биюдән тыярга хакыгыз юк!

Айсин аны этәреп җибәрде. Кемгәдер орынып булса кирәк, башыннан фуражкасы очып төште, баш түбәсендә авыр хәрби фуражка салган бәҗра эзе генә торып калды.

Бәгърембнең эче кайный, айкала иде.

Ул карашын, кая куярга белми, түбәнгә юнәлтте. Айсин аягының баш бармагы янындагы сөяле хром итеге эченнән башмак тоягы сыман бүлтәеп тора.

Ниһаять, аларның күзләре очрашты.

Айсин аңа балык кебек кызыл күз белән чекерәеп карый иде.

Гармун күтәргән үсмер ике медален ике як күкрәгенә таратып таккан ат духтыры алдында учка кунган сандугачны хәтерләтә иде.

— Мин уйнаштан туган түгел...— диде үзен чак кына тыеп торган Бәгърем. — Син ул! Бу хакта кичә ырадиудан әйткәннәр. Бүген кабатлаганнар...

Айсинның күзләре маңгаена сикереп, әллә ничә тапкыр әйләнеп чыктылар.

Ул Бәгърем тирәсендә өерелә башлады.

— Бакцы, нәстә сүли-и-и? Минне аскарблядь итәсен! Мин сине авылдан цеберткән, ызбаңны зимерткән! — Ул бер омтылыш белән гармунны умырып алды һәм тышка томырылды. — Зиде бабаңны таныткан, авылдан цеберткән!.. Әрмийски паррядык!..

Моның юньле бетмәвен сиземләгән яшьләр, сарык көтүе

кебек дәррәү кузгалып, ишеккә ташланды. Иңендәге өзелеп төшкән гармун каешы һәм Разия белән башка бер яклаучысыз калган Бәгърем дә тышка чыкты.

Клубта ут гөлт сүнде. Күктәге йолдызлар тагын да эреләнеп яктырды. Тышта август азагының пар җиренә көзге арыш чәчә торган куе караңгы, әмма йолдызлы-айлы төн иде.

— Вот-та сина гармун! — Күзләре аларган Айсин тальянны капка төбендә тоягы белән җир төйгән айгыр астына ыргытты. — Пущщай поет!.. Уборкада гулять итмәссен!..

Ала каз кебек каралып-агарып һәм каңгылдап тояклары астына барып төшкән тальяннан өркеп, айгыр да күзләрен алартты һәм кырандасны алып олакты. Арткы тәгәрмәч астына туры килгән гармун кыр казы кебек соңгы мәртәбә каңгылдады да тынды. Аның күреге нәкъ ак шакмагы уртасыннан урталай өзелгән иде...

Бәгърем күзләрендә шул минутта яшьтән яшен яралды. Ул шуннан соң елый алмый — яшьни генә ала.

Тальянның өзек гәүдәсен култык астына кыстырып, келәт янына менде ул. Тешен кысып булса да, төне буе триерда иген җилгәрде.

Шунысы кызык, ул нишләптер Айсинга кинә сакламады, үч тә йөртмәде. Моңсыз кешегә үпкәли дә, үч тә тота алмый иде Бәгърем. Кызгана гына белә иде.

Тальянга килгәндә, төзәттерде аны Бәгърем. Шул ук Мулла-Гөлемдәге гармун мачтыры Мөстәкыйль абзыйсына, көзге уңыштан биш пот бәрәңге хакына, эшеннән аерылмыйча, төнен барды да, яңа күрек алыштырып, таңында әйләнеп тә кайтты.

— Кайгырма, — диде Мөстәкыйль абзыйсы. — Тальяныңның көмешенә зыян килмәгән. Мин аның телләренә тагын да бераз көмеш сипкелләдем. Син тирә-якта бер дигән итальянчы булачаксың, парин. Сукыр Сәгыйтьтән дә арттырачаксың...

Сукыр Сәгыйть — күршеләрендәге Яңа Ишле авылыннан атаклы гармунчы. Бар, җиткерерсең, җиткерми ни Сукыр Сәгыйтькә!

— Нигә «итальянчы»? — дип сорады аптыраган Бәгърем. — Тальянчы түгел?

— И-и-и, син әле шуны да белмисеңмени? — дип аптыраган булды Мөстәкыйль. — Кара, син бигрәк тә надан икәнсең, парин. Тальян безгә румнар, германнар аша Италия дигән җирләрдән килгән. Башта ул, татарларның хәлен белим әле дип, итальян булып, Донбасс шахталарына төшкән дә аннан, тальян булып, җир өстенә чыккан. Шуннан гына таралган ул безгә, татарларга, тальян булып. Ышанмасаң, үзең укып кара. «Кызыл Таң» гәзитәсе дә шулай дип яза...

Очып кайтты егет Мулла-Гөлемнән. Аякларын җиргә ти-

дермичә, аны гармун очыра иде бугай. Юләр дисәң дә, юләр инде ул: бар тирә-якка сызылып таң ата, ә ул Карлау Башы яланы түбәсендә, аннан Кыңгырау Чишмә буйларында, кыскасы, кайда тели, шунда туктап, гармунында сыздыра...

Баштарак Бәгърем Мөстәкыйль абзыйсы сөйләгәнгә ышанмыйчарак йөргән иде. Ниткән итальян итальяны булсын инде ул татар тальяны? Тальян ул мәңгелектән татарның уен коралы булган, чөнки ул, ягъни мәсәлән, тальян — «тал»дан, «тал җан»нан алынган, чөнки Италиядә безнең Өязе буйларындагы шикелле көмеш таллар юк. Һы, әйтерсең татар мондый уен коралын тудырырга үзе сәләтле түгел. Әйтерсең!.. Безнең халыкның гомергә шул инде аның: башкада, ягъни Шаляпинда күрсә — котлы булсын, үзендә, ягъни Сәйдәштә күрсә — каян алдың?

Егет ачуыннан көрәген дөпелдәтеп, үзеләнеп кызара башлаган мәтегә кадады, әрекмән арасыннан пыяла чирекне чыгарды һәм, башын артка аударып, әйрән эчә башлады.

Нинди матур бүген һавалар!

Күк йөзе чәчәк аткан җитен басуы кебек җете зәңгәр икән ләбаса. Бу җете зәңгәрдә ак мамык эскертләре булып болытлар йөзеп йөри икән.

Нинди матур аның туган иле!

Туган нигезе, картинәсе, шундый киң күңелле авыл халкы, ерып чыгалмаслык урманнары, киң иген басулары, якты чишмәләре, инде менә килеп, күз карашларына да сыеп бетә алмаслык ап-ак болытлары булган кешене ятим дип буламы? Бардыр ул ятимнәр, ләкин тик Бәгърем түгел!

Ул тавышсыз-тынсыз гына җырлый, бармаклары зиһененнән генә гармун төймәләреннән йөгерә иде.

Көтмәгәндә ул кычкырып Тукайны укый башлады:

Зурмы? — дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә.

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава;
Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява...

Чокырның тирәнлеге кендеккә үк якынлап бара түгелме? Арытып та килә. Әнә аның күз алдыннан нииндидер кызыл черкиләр очып уза. Әллә аның канын эчеп шулай корсак күперткәннәр, әллә күзгә генә шулай күренә...

Куандырганы тагын да шул булды: Бәгърем гармуны белән Рәис абзыйсының гармуннарының яңгырашы берберсенә охшаган булып чыкты. Бәйрәм кәнсиртләрендә алар еш кына бергә парлап уйныйлар. Әле менә үткән Май бәйрәме кәнсиртендә «Ай, былбылым» белән «Көймә килә»ләрне шундый итеп урып салдылар, халык аһ итте.

Бәгъремнең башына җиттем дип уйлаган шул ук гармунында уйнаганын белсә, Айсин нишләр иде икән? Гафу үтенер иде микән? Ай-һай, ай-һай. Айсин дигәннән. Килешә алмады ул халык белән. Китеп барды «утыз меңенче» комиссар. Безнең халык шундый инде ул, аның үз ягына ятмасаң, сине бөгә дә сала. Хәзер ул халык дигәнең үзе дә аңлый: бу якның гадәтләрен белмәгән, чыннан да, яхшы эшләргә теләгән Айсинга һич кенә дә җиңел булмагандыр. Кайвакыт кызганып та куялар бу партиянең чираттагы корбанын. Кызык телле һәм холыклы, үз бурычын үтәр өчен теләсә нинди пычракка кереп барган беркатлы, эчкерсез кеше иде ул. Шул беркатлы эчкерсезлеге аркасында кыен хәлләргә дә кала иде. Ачыла алмады ул монда. Аннан еллары нинди булды бит аның. Сталин бабай үлгәннән соң, авыл тарихында сабантуйларны бары тик Айсин килгәч кенә үткәртми башладылар. Хәер, ул югарыдан, халык әйтмешли, Крючок бабайлардан төшкән булгандыр инде. «Халыклар дуслыгына зыян китерә», — имеш. Быел да үткәртмәделәр. Ул ниткән «халыклар дуслыгы» икән? Колтамакта да, барлык колхозда да татарлар гына яши дә бит югыйсә.

Кайчагында Сталин бабасын сагынып та куя Бәгърем. Аны хәзер хурлыйлар, әлбәттә. Хурлый диме?! Алар бит Сталин бабалары белән җиңделәр, Сталин бабалары белән беркемнән дә, бернәрсәдән дә курыкмадылар. Бәгъремгә килгәндә, ул хәтта дөм караңгы төнге мунчага да Сталин исеме белән генә бәреп керде. Әйтик, бәләкәй чагында картинәсе онытылып калдырган ләгәнен, йә булмаса комганын алып кайтырга дип, аны төнлә мунчага җибәрсә, ул тәүдә, ишекне каерып ачып: «Сталин!» — дип кычкыра, гүяки, граната ыргытып, ләүкә астындагы җеннәрне егып салганнан соң гына мунчага атылып керә иде. Гармунда уйнарга төнге мунчаларда өйрәнә башлагач, бу гадәт аеруча ярап куйды Бәгъремгә...

Җитмәсә, Айсин гомергә дуңгыз күрмәгән Колтамакка үзе белән егермешәр имчәге булган өч баш ана дуңгыз да алып килде. Моңа кадәр мыркылдык күрмәгән халык Сәми картларның ташландык саман өйләрендә мыркылдап яткан чучкаларны карарга килә һәм сасы истән танауларын кысып кире йөгерә иде. «Мин чучкага нераунадушный, минем чучкаларга сабый чактан ук ыслабыс, чучка фермасыз низзя», — дип, хатын-кызларны өйдән өйгә чыркылдата-чыркылдата яңа оешып килгән чучка фермасына куа иде Айсин. Тегеләр аннан төн буе ком белән ышкып кулларын юа. Бәлки, Айсинның «чучкага ыслабысы» да шул Крючок бабайлардан килгән булгандыр әле...

Әйе, эчкерсез ташбаш, сирәк ташбаш иде Айсин. Кол-

тамакның ул «хәлен белешергә» өлгергән үрге очы аны «әрмийски паррядык» дип атады. Хәл белешергә үзенең хәле җитмәгән түбәнге оч аңа «олылап» «Дуңгыз Иваныч» дигән ләкап чәпәде. Гыймакай бабай әйтүенчә, ул үзе дә шул «паррядык» корбаны булды. Аны еш кына мәзәк итеп искә алалар. Шулай авылга килгәч тә, райком кушуы буенча йорттан йортка хәл белеп йөри бу. Мондый төчелекне күрмәгән халыкның күзе маңгайга менә, йоны киредән торып тырпая. «Хәл белүче»дән кызык табып ләззәтләнә болар. Беренче итеп ул авыл башындагы Кылтайган Сабирга керә. Имгәнгән иңбашын канаты сынган каз кебек бераз сулга янтайтып, сузылып кына басып тора икән Сабир.

— Халегез ницек? — ди Айсин.

— Шөкерле-бөкерле — бертөрле,— ди Кылтайган.

— Улыцы нәстя?

— Янбашымны әйтәм, — ди Кылтайган. — Чана табаны бөккәндә станга тыгып иңбашымны тарттырдым.

— Атя, шылай үзен самоличны тыктын да тарттырдын?!

— Шулай шул, — ди инде кылтая да башлаган Сабир.— Бик кызыксынсаң, әйдә, синең янбашыңны да тарттырып бирәм!..

Шулай ди дә өенә керә дә китә.

Аннан ул Зимагур Зиннәтуллага юнәлә.

— Халегез ницек?

— Кешедән хәл сораганда кулыңны кесәңнән чыгар, — ди Зиннәтулла. — Нихараша...

— Ницөн?

— Кесәңнән чыгарып, берәр төргәк акча бирерсең кебек, — ди Зимагур. — Аннан синең белән мәҗлес корасы булачак...

Бу авылда җыен сукбай-сәрхуш, сәер мәзәкчеләр генә яши икән, дип уйлый башлаган Айсин, медальләрен ялтыратып, Көнчел Әгъләм ихатасына үтә.

— Хәлләр бик тә хөрт, — ди танавын салындырган, иренен сәлендергән Көнчел. — Әле син ишетмәдеңдәмени?!

— Нәстя? — ди коты очкан Айсин. — Адя, сүлә шибык!*

— Мин булганда печән белән, күршем булган бичәм белән!

— Китце!

— Иске йортта унбер ел яшәп, сүзгә дә килмәдек. Яңа йортка да күчендек — хатын азды!

— Китце!

— Кара тавыштан чыккан юк!

— Китце!

— Син дә минем бичәм артыннан себерелергә кермәгәнсеңдер бит?! — дип кычкыра аңа яңа рәис икәнлеген дә

* Шибык — тиз («шибко»дан алынган).

ишетеп өлгермәгән Әгъләм. — Бар, чыгып тай моннан, мунча төкерегеннән яралган нәрсә!

— Юк, юк, боже паси! — дип чыгу ягын каера Айсин. — Мәтри аны, ызбагызда әрмийски паррядык булсын. Бәхетле катыгыз!*

— Бәхет ул малай түгел, аны тотып карап булмый!

Ниһаять, Мәңге Төшрифүн Мөхлискә барып керә бу.

Мөхлис бер ноктага караган да катып калган, имеш.

— Нәстя югалттын? — дип сорый Айсин.

— Кичә башымнан бер шөребем төшеп калган, шуны табалмыйм, — ди хуҗа. — Эзләш әле.

— Шарик?! — дип кычкырып җибәрә Мөхлисне аңламаган Айсин. — Ышту за Шарик тагин?!

— Эт! — ди Мөхлис, тегене үртәп. Аннан эт булып өреп сикеренә башлый. — Һау-һау! Һау-һау-һау!..

— Мин кочыкца талашуцы** адям тигел, — ди икән Айсин. — Мин сезгя яңы персидәтел. Вот-та!..

— Бәй-бәй, синмени әле ул, — дип кабынып китә Мәңге Төшрифүн. — Синең кебек персидәтел булмады, булмас һәм булса да кирәге юк!.. — Черек тешләрен ыржайтып көлә-көлә Айсинның кесәләрен капшый башлый. — Мин синнән бер бай баш төзәттерүче көткән идем! Ха-ха-ха!.. Ә син персидәтел генә икәнсең... Көтеп-көтеп кунагың килмәсә, көтеп-көтеп хатының үлмәсә, шуннан да аянычы юк, малайгынам!..

Төшрифүн Мөхлистә туктатты үзенең хәл белешүен Айсин. Ары таба теләге дә, җегәре дә сүнде Үзәк Комитет җибәргән комиссарның. Ике елга якын халык миен изгәннән соң тайды ул моннан. Шул ук Үзәк Комитет, имеш, аны Бәгъремнәрнең Өязе буендагы Буденный исемендәге колхозыннан кайдадыр Ашкадар буендагы Ворошилов исемендәге колхозга күчергән. Кемгә кирәк инде аның кая китүе. Иң мөһиме — котылдылар. Колтамак урынында калды. Әмма Айсин, шул Айсин күреген өзгән гармуны исенә төшкән саен, Разия да исенә төшеп бәгърен өзә Бәгъремнең.

Их, беләсе иде, ничек була икән ул кияүгә чыгу һәм кәләш алу!

Егет тирән итеп уфырды. Разияның чәчләре ак сызык калдырып, бүген дә уртадан ачылган, сул як битендәге уймак чокыры бүген дә елмайган саен чокырая, алтынсу сипкелләре бүген дә сизелер-сизелмәс кенә таралып ята микән? Әллә Разия хәзер бөтенләй елмая белмиме?! Әллә, киресенчә, авызын җыя алмыймы? Килен! Разия килен! Исәнме! Бәгърем аны күңеленнән генә үчекләде. Бәгърем, нәзек биллә-

---

* Катыгыз — бу урында «яшәгез» мәгънәсендә.
** Кочыкца талашуцы — көчек кебек өрүче. *(Автор искәрмәләре.)*

рен тагын да нәзегәйтеп, килен-киленчәк алъяпкычын буган, яулыгын колаклары өстеннән генә кыеп, ничектер очыртып бәйләгән Разияны күз алдына китерергә тырышып җиткелди башлады. Кил-лен, имеш. Кет-кет-кет. Разияның кияве, имеш. Кет-кет-кет. Бәгъремнең ул кияү-баланы күз кырые белән бер генә күрәсе итте һәм — яратмады. Яратмады һәм вәссәлам. Кет-кет-кет. Өязебаштан килеп йөри торган Имиле Чуаш кебек җилсенгән йөзле, зур колаклы, юеш, җепшек, пычкылдык, кысык күзле, бер оешмаган нәмәстәкәй шунда. Ияге дә ниндидер дүртпочмаклы. Бу аның теш казнасының азык чәйнәүдәге мөмкинлекләренең чиксез булуын раслый.

Ә менә Разия өчен ул Җир шарында иң чибәр кеше, ди. Авылда шулай сөйлиләр. Шулайдыр. Шулай булмаса, кияүгә чыга диме кыз кеше. Кызлар бит алар кызык халык: акыллымы, дип сорамыйлар, чибәрме, диләр. Кеше утырып елар чакта көләләр. Әгәр Разияның бу кешегә кияүгә чыгуы турында уйланса, бөтен Җир шары утырып елар иде, билләһи газыйм!

Бәгърем үз күзләре белән күрде Разияның авызын җыя алмыйча көлгәнен. Шул кияү дигән ишарәте белән урманнан җитәкләшеп кайтып килә иде. Нәрсә, җитәкләшмәсә адашыр иде микәнни? Агач мылтыктан атасы килеп китте Бәгъремнең хөрәсән кияүнең түшенә. Шул минутта күрше кызы, якыннардан якын булган, җил-яңгыр тидермәгән, салкыннарда җылыткан Разиясы аңа ниндидер чит-ят кеше булып күренде. Разия бу җавапсыз адымга бару өчен ни өчен Бәгъремнән, аларның серләрен белгән таулардан һәм яланнардан рөхсәт сорамаган? Разияны бит алар да үстерде! Нәрсә, ул Разияны көнлиме? Юк, Алла сакласын! Йөргән кызы да түгел ләбаса! Аның әле кызлар белән гомумән дә йөргәне юк. Ул Разияның туен да озатырга бармас иде гармуны белән, тагын да шул авылдашлары, гармунчы булу хакына гына бара...

Егет казуыннан туктады. Чокырының тирәнлеге күкрәгенә җитеп килә иде. Тирәнлекнең артыгы кирәкми. Тирәнлекнең һәммәсе таманча гына булырга тиеш. Кешеләрнең үзләрендәге тирәнлек тә. Көрәк сабына таянып, ул бер омтылыш белән чокырдан сикереп чыкты. Көрәкнең өндәү билгесен хәтерләтеп балчыкка кадалган сабы һәм аның гәүдәсе дә бөтенләй дип әйтерлек күләгәсез иде. Кояш нәкъ баш очына кунган да, балавыз булып эри. Төш җиткән икән.

Елга аръягында кыңгыраулар чыңлап куйды.

Егет сискәнеп китте.

Кузгалырга ниятлиләр булса кирәк.

Ул, дилбегә бәйләнгән кое чиләген тоткасыннан гына эләктереп алып, кое янына килде һәм, бурага капланып, чиләкне төшерә башлады. Су көзгесеннән аңа зәңгәр күкнең ак мамык болытларын башына чалма итеп ураган, табак битле, җиз

маңгайлы бер кеше карап тора. Әйе, авылда аны юкка гына «Җиз маңгай» дип йөретмиләр икән шул. Аның маңгае, чынлап та, гүяки сандалда чүкеч белән чүкелгән җиз кебек эзле һәм батынкы икән. Баксаң, теге зур колаклы, тир тозында җепшегән, кысык күзле кеше һич кенә дә Разия кияве түгел, ул үзе икән! Ияге дә дүртпочмаклы, теш казнасы да бары тик азык күшәү өчен яратылган!..

Менә аның буш чиләге шушы чәчләре тузгыган баш, чүкелгән җиз маңгай, шушы табак бит һәм пычкылдык күзләр чайкалган су көзгесенә төшеп килә... Чиләк төбе су өстенә кагылу белән, аның йөзе, килеш-килбәте тынычлыгы бозылган су көзгесеннән таралган түгәрәкләргә төялеп киңәйде, таралды һәм кое бурасына гына сыеша алмый, кайдадыр билгесезлеккә этәрелеп юкка чыкты...

Ул коедан күтәргән суын читән буена алып килде. Чабаталарын, оекларын салып какты, кыска җиңле күлмәген дә салып, читәнгә сөйисен сөяп, эләсен элеп куйды да юына башлады.

— Теге Качаган бадарыннан алган күлмәгеңне киярсең, яме, канатым.

Бөкресен чыгарып болдырда кош-кортка болгау болгаткан картинәсе гүяки аңа үзе белеп эшли торган эшләрне дә исенә төшереп тору өчен яратылган җан иясе инде. Ул болгауга чемердәп ачыган катыгын күпмерәк микъдарда салу турында гына уйласа, яхшырак булган булыр иде дә бит. Югыйсә аның тавыклары ачы катык эчеп исерә дә әтәчне талый башлый, йолкышлар.

— Теге Качаган күлмәген киярсең, дим, ишетәсеңме...

Егет эндәшмәде.

Бәгъремнең нерв җепселләре киеренке, кан агышы кызу иде. Үлән сөтендә яшәреп һәм елкылдап шомарган тырма тешен хәтерләткән картинәсе, колакка бераз каткан карчык, бәләген шапылдаткан арада, сүзләрен өченче мәртәбә тәкрарлады:

— Качаган күлмәген ки. Чалбарың үтүкләнгән. Урындык өстендә.

— Беләм.

— Кем баласы дигәндә, шуның баласы диярләр. Әтиең дә, әниең дә бик ыспай кешеләр иде, мәрхүмкәйләр. Авыр туфраккайлары җиңел булсын. Яңа тәпичкеләреңне ки. Спут башындалар.

— Беләм.

Әле быел язгы карага басу белән генә тегелгән малюскин чалбарын, сөлгелек җитен тукымадан тегелгән күлмәген, картинәсе әйткән «тәпичкеләрен» киеп алгач, Бәгърем бөтенләй бөтәеп калды. Ул көзгегә карады. Ул элекке халәтенә кайткан Бәгърем иде. Ияге дә дүртпочмаклы, күзләре дә пычкылдык түгел. Нәкъ үзенеке. Чиста кием эченнән кып итеп тора-

лар. Елга аша әллә ат тояклары тавышы килә, әллә күкрәк читлегендә йөрәге дөпелди. Ул арага кыңгырау чыңнары да сипләнеп алгандай тоела. Тальянын култыгына кыстырып чыгып барганда, аның юлына яшел үлән тырмый-тырмый яшәреп беткән тырма теше кебек тагын да шул картинәсе калкып чыкты һәм органик химия буенча соңгы дәресләрен биреп алды:

— Бүген иртән көтү куганда, Одын Дәйнәпләр тәңгәлендә...

Аның картинәсе, авыл картларына хас булганча, шулай борынгы Минзәлә типтәрләренчә «з» урынына «д» куеп сөйләшә. Элегрәк барлык авыллары белән шулай сөйләшә иде алар. Хәзер казанча чиста «з» белән генә сиптерәләр.

— Одын Дәйнәпләр тәңгәлендә сеп-сбижи эт тидәге күрдем. Мәтри аны, баса күрмә. Эт тидәге яңа эрдинкәне дә эт сигәнче ашый ул...

— Беләм.

— Белсәң, бик әйбәт, белмәгәнгә бишәр әйт.

Гармунын аркасына ышырып, Озын Зәйнәпләр тәңгәлендә эт тизәгенә басмаска тырышып, Өязе ярыннан чалулый-чалулый Разиялар турындагы басмага юнәлгән Бәгъремне картинәсенең җилдә өзгәләнгән сүз бәйләнешләре озата килә иде:

— Пәйгамбәребед... ахырдаман алдыннан...

Ул, яшь таллыклар яшеленә күмелеп, басмадан чыга башлады.

— Дөнья... эт вә дуңгыз тидәгенә батар дигән!..

Кызык та инде бу картлар. Берсе ахырзаман алдыннан Дәҗҗал чыгара, икенчесе дөньяны эт-дуңгыз тизәгенә батыра.

Сукмак буйлап таллыклар мәгарәсенә баткач кына ишетмәс булды ул картинәсенең фетнәви тәкрарларын. Адәм биеклеге булып үскән әрекмәннәр, шау чәчәккә төренеп, зәһәрләрен коеп утырган җете яшел кычытканнар — әйе, Бәгърем үзенең кыска гына гомерендә беренче тапкыр ап-ак кыңгырау чәчәкләргә тиенеп утырган кычытканнарны күреп таңнар калды! — арасыннан килде, килде дә тар сукмак аны Разияларның тау күтәренкелеге башланган тәңгәлдәге ихаталарына алып керде.

## II

Кайчандыр серле күренгән йорт-җир — бүрәнәләре муртаеп беткән менә бу дүртпочмаклы өй, менә бу уенчык кебек кенә җыйнак келәт, менә бу янтайган читәннәр, хәтта ихатага яртылаш кереп туктап калган менә бу карт өянкеләр дә аңа бүген чит-ят иделәр. Көн кызуында пешенеп әлсерәгән, саф сулышлы җилләр көтеп җәйрәгән ишегалдын ул кешене кызганган кебек кызганып куйды.

Күләгәгә бәйләнгән атлар, арба-кырандасларга, читән буйларына анда-монда салыштыргаланган яшел печән күбәләреннән үлән берәмтекләгәндә, вакыт-вакыт, койрыклары белән

чәнчеп-чәнчеп, чебен-черкиләрне кугалаштырып ала. Лапас астындагы кырандастан бер исерек коданың гәүдәсе салынып төшкән. Аяклары сыер ләпәгенә тиеп тора. «Моны инде озатасы калмаган», — дип, авыз чите белән генә елмаеп куйды Бәгърем. Тәрәзә капкачлары яртылаш ябылган өйнең бүрәнәләре аша чишелеп сөйләшкән, көлешкән һәм җырлашкан тавышлар ишетелә.

— Син, күрше, нигә алай соңлап йөрисең? — Ике кулына ике чирек ачы бал тотып келәттән килеп чыккан Мәсгуть абзый — Разияның әнисенең туганнан туган энесе — аны алдан үткәрде. — Разияның туе бер генә тапкыр була лабаса!..

Өйнең алгы, аш-су ягы мунча сыман эсселәгән булса да, тәрәзәләре ябулы кунак ягы ярыйсы гына чамада җиләс иде. Кояшның тәрәзә капкачлары ярыкларыннан үтеп кергән нур кылычларыннан телгәләнеп киселгән кунаклар — өч көн буе мәҗлестән мәҗлескә йөреп таушалган, бүртенеп кызарган кодалар һәм кодачалар, балдызлар һәм каенишләр, каенигәч, каенсеңел һәм каенагалар, туй озатырга дип чакырылган күршетирә, авылдашлар һәм туган-тумача идәнгә җәелгән асалы паласка стена буйлап мөселманча аякларын бөкләп утырып алганнар да, бербөтен булып укмашып, мәҗлес корганнар. Мәҗлес исә Бәгъремнең кергәнен абайламады да. Әгәр аны түбәндәге, безнең якларда әйтүләренчә, «шәлия табынында» утырган яшьтәшләре Ихсан белән Сабирҗан шәйләп алып:

— Әйдә, безнең янга! — дип аваз салмасалар, бөтенләй күрмәгән дә булырлар иде, билләһи.

Гыймакай бабай исә бу авазны эләктереп алды. Кулындагы яшел чәйнегеннән ачы бал коеп, хәтеренең начар булуы аркасында чиратны бутый-бутый кунакларны сыйлаган арада:

— Гармунчының буыннары саен мәхәббәт аның! — дип кычкырып җибәрде. — Әйдә, бирегә үт, урының уртада, малайгынам! Чират кемдә иде әле?

— Үзеңнән башла, Гыймалетдин абзый, — диде Чулак Гамир. — Ялгышмассың. Ялгышкан саен үзеңнән башла, яме!

Берничә ел элек карчыгыннан ятим калган, бүгенге көндә улы-килене белән бергә яшәп яткан карт, яшьләрчә тәвәккәллек белән, табынның көрәгәчесе булырга җөрьәт иткән, ә?

Бәгъремнең Гыймакай бабасы тәкъдим иткән түргә үрләргә батырлыгы җитмәде. Гармунчының урыны, ул ничек кенә яхшы уйнамасын, ишек катында. Ул кунак сыйлаучылар исәбеннән. Аннан моң дигәнең түбәннән күтәрелә. Шулай кирәк. Шулай дөресрәк һәм уңайлырак. Ул, мичнең казнасына аркасын терәп, Ихсан белән Сабирҗан арасында урын алды.

— Гармунчыга ыштрафнуй, ыштрафнуй! — дип кычкырды кемдер.

Гармунчыны эчерергә тырышу шушы урында тынды.

Разияның әнисе Рәһиба җиңги, алгы яктан кереп, Гыймакай бабайдан бал тулы ике көрәгә сорап алды, көрәгәнең берсен Мәсгуть энесенә тапшырып, түр башында утырган төп кодасы белән кодагыена атап борынгы көй — «Зәңгәр капка»ны башлады. Аңа Мәсгуть тә кушылды. Бу йола җыры иде һәм кыз ягыннан ата вазифасын Мәсгуть абзый башкара иде. Бәгърем, бу көйне белсә дә, гармунын тулы хутка яңгыратмыйча, ипле генә итеп арттан озата барды.

Рәһиба җиңгинең тавышы бик тә матур. Моңы аның ничектер гел генә өзлегеп тора. Ул кышкы озын кичләрдә еш кына Бәгъремнәргә кич утырырга керә, һәм алар, җеп эрләгәндә, картинәсе белән бергә җырлыйлар. Бу юлы моң Рәһиба җиңги күкрәгеннән чишмә булып чылтырады. Гүяки ирен сугышларда югалткан, дүрт ятимәсен берүзе үстергән солдатка турысын әйтмичә, читләтеп кенә, шушы җыры белән баласының язмышын чит кулларга тапшыра һәм аны какмаусукмауларын үтенеп үкси иде...

Казаннардан килгән күк көймә, ай, кода,
Безләр барыбыз да бер төймә, ай, кодагый,
Җыйдым ла җиләк, койдым как
Бөрлегәннәре берлән шул.
Без катнаштык кодаларның
Бер дигәннәре берлән шул,
Бер дигәннәре берлән!..

— Лән-лән-лән! — дип күтәреп алды табын.

— Афәрин! Шулай кирәк, Рәһиба кодагый! — дип гөрелдәде кемдер өске табыннан. — Афәрин, мин сиңа әйтим! Таг-гын! Таг-гын!..

Безләр барыбыз да бер төймә лә, ай, кода,
Җырлап кына яшик бер көйгә, ай, кодагый!..
Урман алдында куаклар шул,
Куакларда күп атлар, ай,
Балларга салдык колмаклар,
Җырлашаек, кода, кунаклар, ай!..

Рәһиба җиңги белән Мәсгуть абзый көрәгәләрен кода белән кодагыйга тапшырды.

— Афәрин, кодагый, афәрин, Мәсгуть кода! — диде, кәефе килеп, төп кода. — Амин, шулай булсын!

— Мондый җыр хакына туң агач та эчәр! — Күзләрен ата каз кебек бер ачып, бер йомып утырган бер яшь кода, айнып киткәндәй, аек омтылыш ясап, кулындагы көрәгәне тамак төбенә койды. — Әйдә, хатын, син дә калышма!

Ул да булмады, түр яктагы уң почмактан бик тә таныш аһәң ишетелде:

Кыз баланың назы бар,
Ир баланың мазы бар.
Безгә килгән яучының
Түбәсендә тазы бар!..

Табын гөрселдәп көлде.

— Таз булса ни, булсын! — диде Ихсан да, сүзгә кушылып. — Тазга таз килми, кем килсен тагын. Без, колтамаклар, барыбыз да тазлар, шулай бит, Җиз Маңгай?

Бәгърем, ачуы килеп, дустының касыгына каты итеп төртте. Сәбәхетдингә ияреп, ул да шаяра, имеш.

— Ни җитмәгән тагын сиңа? Авылны яманлап утырасың, — диде ул, пышылдап кына.

— Мин бит болай гына...

— Болай гына булса, болынга барып сөйлә...

Ә теге такмакны почмакка урнашып, җәмәгать күзеннән читтә шактый кызып алган Сәбәхетдин җырлаган иде. Халыкта аны кыскартып Сәбәкәй генә диләр. Тагын да кыскарагы — Сәбәк. Иң дөресе — Сунарчы Сәбәк. Әнә ул Сәбәхетдин абзый. Очларын майлап бөтергән озын, кара төрек мыегы чак-чак кына күршеләренә тими тора. Һәрвакыттагыча Мәстүрә җиңгине үзеннән калдырмаган, әлбәттә. Исерә, кем әйтмешли, чыгырыннан чыга башласа: «Әйдә, карт, кайтыйк, кайтыйк, буласы булды, буявы сеңде», — дип, аны юмалап алып кайтып китә бу акыллы хатын. Бер караганда, бер дә чыгырыннан чыкмый инде Сәбәхетдин. Рәхәтләнеп, тартынмыйча ашыйэчә, чишелеп сөйләшә, исергәләгәнче озын җырулар да җырлаштыргалый. Шунысы гына: исерә төшсә, аны беркем дә көтми, беркем белән исәпләшеп тормый торган «энҗеләр», такмазалар ыргыта торган гадәте бар. Менә ул әле дә үзенең күңел хәзинәсеннән бер тамчы «энҗе»сен ыргытты:

Ике төркемгә бүлене-е-е-еп,
Маймылла-а-а-ар күңел ач-ча-а-а-а...

Беркем көлмәде. Хәтта ки ишетмәде дә. Бу «энҗе», беренчедән, шау-шу астында күмелеп калды, икенчедән, аны ишеткәннәргә, мәгънәсен аңлау өчен бик тирән агымсуларга карап уйланырга кирәк иде. Бәгърем бик тә ярата Сәбәкәй абзыйсын. Эчкерсез, риясыз кеше ул. Мәгәр аны алдамасалар. Алдаганнарын тойса — женгә әйләнә дә куя. Соңгы елларда кышкы сунарга ул Бәгъремне дә алгалый башлады. Әрлән, йомраннарга язгы-җәйге сунар вакытында яратты ул Бәгъремне. Бу вак «мал»ны тунарга үзе бер дә яратмый. Ә менә Бәгърем белән Ихсан аларны тунарга шулкадәр остарып киттеләр ки, тиреләрен сыдырып кына төшерәләр. Утильчимал җыючы Суфиян картта бер тире егерме тиен тора, җәмәгать, шаяртмагыз. Шуннан җыела ул. Кайчакларда,

сунары уңышлы чыкса, ул үзе тоткан җанварлардан цирк күрсәтеп, халыкны шырык-шырык көлдерә. Былтыр, мәсәлән, ана һәм бала торналарны авылга биетеп алып керде. Бөтен бала-чага терекөмеш кебек урамга эркелде...

— Әйдә әле, туган, монавында кунаклап ал да, «Шомыртым»ны сыздыр! — диде Мәсгуть абзый һәм, сорап-нитеп тормыйча, аны көчләп диярлек кулыннан тартып, урыныннан куптарды. Ул аны ишек катындагы артсыз урындыкка утыртты. — Тәүдә менә минем шушы җылы кулларымнан монавы көрәгәне тондыр! Дөрес әйтәмме, кодалар?

— Дөр-рес! Дөр-рес булмыйча ни!

— Юк, юк, этәрмә, парин, утырып эчәсеңме, ятып эчәсеңме, — бу көрәгә синеке! Үзе кызып алмагач, гармунчы башкаларны ничек кыздыра алсын?

Бәгъремнең әле моңа кадәр бер тапкыр да эчкәне юк иде.

— Эчмим, — диде ул, Мәсгутьнең көрәгәле кулын яңадан этәреп. — Эчкәнем юк.

— Син нәрсә?! Разияның туе бер генә була!

— Эч тә җибәр инде! — дип пышылдады аңа Ихсан. — Менә без эчеп җибәрдек тә — шундый рәхәт!..

— Мәсгуть абзый дөрес әйтә, — дип өстәде Сабирҗан.— Безнең яшьтиләрдән беренче туй бу, малай!.. Әйдә, үкенечен калдырмыйк!.. Бәлки, Разия белән бүтән күрешеп тә булмас. Озакламый армиягә, аннан кем белгән...

«Разияның туе бер генә була», «бәлки, бүтән күрешеп тә булмас» дигән гыйбарәләр аның бәгъренә гүя утлы шаукым булып утырды.

— Эчмим. — Ул көрәгәне читкә этәрде. — Эчмим, дигәч эчмим.

Бәгърем «Шомыртым»ны уйнап җибәрде. Мәҗлес үз агышы белән дәвам итте. Кунак кода белән кодагый, җыр эзләп артык җәфаланмады бугай, алар Раһиба кодагыйлары белән Мәсгуть кодаларына артык көчәнмичә генә «Ал булмый, булмый, булмый» дигән такмакны җырлап, җавап көрәгәсеннән котылдылар.

Бәгърем гүя беркемне күрми, бернәрсә ишетми иде. Аның куллары үзләреннән-үзләре мәҗлес кушкан ызаннарга алып кереп, «Шомыртым»нан «Донбасс»ка, «Донбасс»тан «Идел»гә күчте. Егетне моң шаукымы суккан иде. Аның моңында йөзгән гадиләрдән гади авыл туенда кодалар кодачаларны, кодачалар кодаларны, каенигәчләр һәм каенагалар яшь кодача белән каенишләргә кадәр берсен дә онытмыйча сыйлады. Монда дус та, дошман да юк, ә бары тик тигез туганлык, бер-береңә изге теләкләр генә хөкем сөргән бу даирәдә беркем дә күрә алмаган, күрү мөмкин дә булмаган бер бөек сәхифә ярала иде: ул да булса, Бәгърем дигән егет,

гармунын күтәреп, үз гадәтләре, үз холыклары белән үз тормышының яңа ызаннарына чыгып килә иде...

...Кинәт аның күз алдында тулган ай хасил булды. Айның тирә-ягын вак кына күзле челтәр уратып алган. Аларның айлары да әле, үзләре сыман, күп дигәндә беренче-икенче генә сыйныфта укып йөргәндер. Ул ай Разияның кырпак сибелгән чәчләренә ак калфак булып укаланган. Урыны-урыны белән ямь-яшел үлән сикертеп яшәргән, урыны-урыны белән кары да эреп бетмәгән чокыр-чакырлар аша, бер яшелдән икенчесенә сикергәләп, алар Питырпаул кахуллары җиренә төштән соң гына килеп җиттеләр. Черек бәрәңге артыннан авылдашларның беркайчан да бу кадәр ерак биләмәләргә кармак салганы юк иде. Әйе, ачлык — картинәң түгел, йөгертә бирә.

Ә менә күтәреп кайтачак табышлары белән барысын да аһ иттерергә теләгән Бәгърем белән Разия, черек бәрәңге уйдыгы эзләп, ун чакрымдагы Питырпаулга киттеләр дә бардылар.

Ни дисәң дә, кахуллар иркен яшиләр шул. Моннан нибары илле ел чамасы элек кенә Полтава якларыннан татар-башкорт җирләренә китертеп утыртылган хуторчыларның бакча мәйданнары кырык-илле сутыйдан да ким булмас. Ә колтамакларда ул нибары ун-унбиш сутыйдан да артмый югыйсә. Кахуллар черек бәрәңгене үзләре түгел, малларына да ашатмыйлар. Кәлҗемәлек бәрәңге күп иде мондагы бакчаларда. Әмма бирми аны кахуллар. Кызганудан түгел, татарны кимсетеп бирмиләр. Ничәмә-ничә тапкыр кыйналып кайттылар колтамаклар Хлебороб, Будяновка кахулларыннан. Берүк көрәкләрен тартып алып, базга гына ябып куя күрмәсеннәр. Разия белән Бәгърем, мавыгып китеп, караңгыга калуларын да сизмәгәннәр. Кайтыр якка кузгалырга дип торганда гына йөзе белән татарга охшаган бер кахул дәдәй килеп чыкмасынмы! Хәзер үк базына ябып куя дип шыр җибәрде чакырылмаган кунаклар. Юк, татарга охшаган кахул абзыйларының аларга бары тик ярдәм генә итәсе килгән икән. Сабыйлар үз күзләренә үзләре ышанмады. Кахулда да бар микәнни татарны яраткан кеше? Ул, әллә нәрсәләр сораштыра-сораштыра җирне үзе казып, бәрәңге чыгарышты. «Картушка» дигән сүздән башканы белмәгән кунаклар кахул сөйләгәннәрдән бернәрсә дә аңламадылар. Аннан, өенә үк алып кереп, сөт белән ниндидер сары ипи дә ашатты. «Кукурузный хлепец» диде шикелле ул аны. Аннан ниндидер фикергә килеп сикереп торды һәм базын ачты... Андагы бәрәңгеме, андагы бәрәңге! Ул, куллары белән боталый-боталый, капчыктагы черек бәрәңгене чыгарып бушатырга һәм баздан яхшысын тутырырга боерды бугай. Барамы инде татар Колтамагының баласы мондый әрсезлеккә? Ипи белән сөт тә аша, җитмәсә, капчык тутырып бәрәңге дә алып кит! Сабыйлар аптырап калды.

Бәгъһрем бу адымга әзер дә иде бугай, Разия гына: «Монавы кадәр һәйбәт черек бәрәңгене чыгарып түгә диме кеше, — дип, борынын лышкылдата башлады. — Әйдә, ычкыныйк моннан тизрәк, юньлегә түгелдер бу».

Кахул дәдәйләре нәүмизләнеп калгандай күренде. Бәгъремнең аның күңелен күтәрәсе килде. Әмма аның күңел күтәрерлек бер генә байлыгы да юк иде. Кахул, шуны аңлап алгандай, кинәт кенә:

— А ти спивати може? — Ул җырлап та күрсәтте.

Широка страна моя родная...

— Беләм, беләм! — дип кычкырды Бәгърем һәм, кешене шатландыра алу шатлыгыннан, үзе белгән бердәнбер «урысча» җырны җырлап та җибәрде:

Жултый, жултый, жуп-жултый,
Жултый пәке саплары.
Мин жултаймый кем жултайсын,
Килми привет хатлары...

Дәдәйләре эче катып көлә иде.

Көтелмәгән уңышны ныгыту өчен, Бәгърем идән уртасында биеп тә алды:

Сербиянка, сербиянка,
Сербияночка моя,
Кичә ыштаның бар иде,
Бүген ыштаның кая?

— Кит, оятсыз! — Разия, оялуыннан үпкәләп, аның аркасына сугып алды. — Шундый җыр җырлыйлармы сөт эчергән кешегә?

— Молодцы, хлопци! — диде кахул, аларны аркаларыннан сөеп. — Ваши нашим за рупь пляшем. И завтра приходьте!..

Карыннары тук, капчыктагы черек бәрәңгеләренең туңы, җылыдан эреп, арка чокырыннан саркып төшкән үсмерләр, Имәнлек үренә җиткәнче, бу кахулның һичшиксез татар булуы-булмавы турында бәхәсләшеп кайттылар.

Күк йөзендә сары май булып тулган ай йомарламы озата килде аларны. Үрне төшкәндә, чак-чак кына үлемнән калдылар. Эрегән кар астыннан барлык урманның күпереп калыккан былтыргы яфраклар юрганын берьюлы хәрәкәткә китереп, шабырдатып һәм дөбердәтеп, арттан аларны ниндидер гаммәви гөрелте куып килә иде. Алар төн карасында агарып утырган каенны икесе ике яктан шатырдатып кочты. Һәм, үзләре дә сизмәстән, күзләрен йомдылар. Дәһшәтле дөбердәү алар турына җиткәч кенә, Бәгърем күзләрен ачса — ни күзе белән күрсен! — Имәнлек чокыры язгы өеккә чыккан ач бүреләрнең янып ялтыраган күзләре белән кайнап тора!.. У-у-у, исләренә төшсә, тәннәре өшеп китә!..

Гүя хәзер шушы мәҗлес даирәсеннән, аның бүгенгесеннән ниндидер утлы ыргаклар күк гөмбәзенә ыргылды, аннан бу ыргаклар Разия чәчләренә калфак булып кайтарылган ай элпәсен, аннан Разияның үзен дә упкынга өстери башлады… Бәгърем мондый халәтендә, гадәтенчә, күрмәскә тырышкандай, күзләрен йомды һәм «Сарман»нан «Җомга» көенә күчте. Аңа ияргән Гыймакай карт сыек кына тавыш белән такмагын сипләп куйды:

Бульнисләргә барган идем,
Йөрәккә йөрәк, диләр.
Ике йөрәк арасына
Йөз грамм кирәк, диләр, их!..

Һәм менә шушы Разия, Бәгърем белән бергә бүре тамагыннан исән калган Разия, Бәгъремнәрне ташлап каядыр китә… Шул ай артыннан шул ук упкынга түгелдер бит? Ул аны ничек булдыра? Ничек йөрәге җитә? Бәгъремнең кинәт кенә Разияны күрәсе килеп китте. Ул Бәгъремнән «Коткар!» дип ярдәм сорый, имеш. «Мине бу Кысык Күзгә көчләп кенә бирәләр бит, — ди ул. — Әле мин курчак уйнап та туймадым!»

Разияның төсе-сыны сулыгып калган, имеш. Шомырт кара күзләре өстеннән ак яулык бәйләгән нәзек талга охшап калган, имеш. Бит алмаларының алсулары янган, имеш…

Әле Разия кайда икән? Кияве белән келәттә микән?

Ул ток суккандай сикереп куйды. Тәне чемердәде егетнең. Бу чемердәү кан юллары буйлап астан өскә, өстән аска йөгерде.

Бәгъремнең борчулы кичерешләрен тупас бүлеп, кайсыдыр кода каты һәм бик озак итеп кикерде.

— Нәрсәдер җимерелде,— диде янындагы кодачасы, уңайсызланып. — Барыгыз да исән-саулар гынамысыз?

— Аллага шөкер, исәнбез! — диде Гыймакай карт.

Табын тагын да бердәм көлеште.

Бармакларын гармун күрекләреннән йөгерткән арада, Бәгърем мәҗлестәгеләрне яңадан күзеннән кичерде. Ул замандашлары арасыннан матур, таушалмаган, илһамлы йөзле кешеләрне эзләде һәм аларны табалмый җәфаланды. Тыгыз рәт булып тезелеп утырган замандашлары арасыннан илаһияте балкып торган бер генә чырайны да күрмәве гүя ул аларның үзләренең газабы түгел, Бәгърем газабы, үзләренең фаҗигасе түгел, бары тик Бәгърем фаҗигасе иде. Ул үзенең моңа кадәр сизмәгәнчә өлгерә, ничектер нечкәрә баруын тойды. Икенче караганда, колтамаклар аңа күзгә күренеп матур, затлы, ә менә килгән кода-кодагыйлар ягы күзгә күренеп ямьсез, затсыз иде. Йа Хода! Әле генә кикергән коданың ямьшек танавын ул озак тапталудан чокыла төшкән тупса тактасына охшатты. Ул килүчеләр арасыннан, гомумән, чибәр кешеләрне таба алмады. Аларның кайсы чалыш, кайсы полыш

күренде. Гүя алар икенче бер планетадан килгән папуаслар. Гүя алар да, нәкъ җиләк-җимеш кебек, берсе саф һава җитмәүдән әлсерәгән, икенчесе дымсызлыктан кипшенгән, өченчесе артык дымнан бәлҗерәгән, караеп черегән. Күрде инде, аларның җигеп килгән атларының янбашлары да, күтәрткән сыман, очланып тора...

Бәгъремгә бу ямьсезлектән куркыныч булып китте. Юк, бәлки, алар кайчандыр бик матур кеше булганнардыр да, аларны бу тормыш шулай үзгәрткәндер? Бәлки, алар бары тик Бәгъремгә генә ямьсез күренәләрдер? Бәлки, бу... аларның кайгыларын, булган зар-моңнарын аракыга батырып булса да онытырга тырышулары, моның исә бер кыргый тәртипкә әйләнеп, чама югалтып эчүләре, шуның нәтиҗәсендә йөзләренең чөгендер кебек кызарып бүртенүенә генә бәйледер? Бәлки, бу ямьсезлек... вакытлычадыр? Шулай гына була күрсен иде! Бу кешеләр әгәр чынлап та табигый матурлыкларын югалткан булса, бу тигезсезлек даими дәвам итсә, ул алар белән бергә, алар арасында яши алырмы?

— Эч әле берне!.. — Бу юлы Бәгъремне үз итеп карт шайтан Гыймакай белән Күпер Төбе Гыйндулла көчли башлады. — Уйнавыңны куеп тор. Мондый көндә утын да эчә!

— Эчмим, дидем бит инде... — Бәгърем үзенә дип сузылган көрәгәгә яны белән борылды. — Нәрсә, табын дигәч тә, эчмәгән кеше калмаска тиеш дип, социалистик йөкләмә алдыгыз мәллә?

Ихсан белән Сабирҗанның башлары сабагы сынган арыш башагы кебек янтайганнар иде.

Бәгъремгә бу дөнья, бу чынбарлык эчкелеккә күчә барган саен, аның күз алдында ямьсезләнгән, картайган һәм тилергән кебек күренә иде. Болай барсак, кая барып, нинди чокырларга очарбыз? Гыймакай карт әйткән ахырзаман Дәҗҗалы шушы стаканда түгелме? Дәҗҗал шушы мөлаем, шаян картның үзендә, безнең барыбызның да күңелендә аягын салындырып утырмаганмы?

Аның тагын да Разияны күрәсе килеп китте. Гүя аны ул гына коткара ала: аның кулбашларында канатлары бар! Егетнең бәгърен нәрсәдер бик назлы һәм бик ләззәтле итеп чеметеп алды.

Уйнавын куеп торырга теләмәгән Бәгърем «Агымсу»дан «Баламишкин»га күчте. Аның артыннан табын да «Баламишкин»га сикерде...

Бәгърем тагын да истәлекләр упкынына убылды.

Моннан ике ел элек булды бу хәл. Соңыннан ул көн бишенче март — Сталин бабай үлгән көн булып хәтердә калачак. Ягарга утыннары беткән иде. Бәләкәй чаналар өстерәп, алар Каенлык урманына киттеләр. Иртәдән үк

җепшек, үтә дә авыр, кара сөмсерле көн иде ул. Көн яктысын тагын да сүрәнәйтеп, иртәдән үк ниндидер кара канатлы, лычкылдык кар яуды. Аяк-куллары урманга барып җиткәнче үк лычма су булды. Билдән көрт ерып, эчкә үттеләр. Ничек табасың ди көрт астыннан мич аслык утын? Әре агач аударырга пычкылары, аннан бигрәк, палищциктан рөхсәтләре дә юк. Кая ди ул? Беләк юанлыгындагы нәзек каенны да балта белән кискән хәлдә аның тукылдавы әллә кайлардагы Ырымбурларга ишетеләдер кебек. Шуңа күрә иң кулае — агач башына менеп ботаклар ботау иде. Алар моңа өйрәнеп беткәннәр иде инде. Бәгърем, агачка үрләп, тукран кебек тукылдап кына утыра, Разия исә мәтәлеп төшкән ботакларны өстерәп чаналар янына чыгарып тора.

Инде кайтырга дип «Кыргыз юлы»на чыккач, алар палищщик Госманның нәкъ үзенә тап булдылар. Нишлисең инде, черек бәрәңгегә дип барсаң — кахул кыйный, урманга утынга дип барсаң — палищщик кыйный, саламга дип барсаң — пүләвәт кыйный, гармун уйнасаң — персидәтел Айсин кыйный. Тегесе кирәк, монысы ярамый, көн «кирәк» белән башлана, «ярамый» белән тәмамлана. Кая барырга? Авылны корыту, авылны халыксыз калдыру өчен махсус эшләнәме бу?

Авызыннан аракы исе аңкып торган Госман башта чанадагы ботак-сатакны кире урманга ташытты. Үсмерләр хәлдән тайды. Аннан балталарын тартып алды. Ничек яшисең ди авылда балтасыз? Ул бит ирсез ихатадагы бердәнбер дип әйтергә мөмкин булган тимер корал — ирләр коралы! Аннан, халык әйткәндәй, балтасыз татар — гомер-гомергә хокуксыз татар булган бит инде ул. Шуңа күрә дә бит инде ул бары тик иң мескеннәрне генә балтасы суга төшкән кешеләр белән чагыштырган. Кат-кат сорады, инәлде Бәгърем. Госманны йомшартырлык түгел иде. Ниһаять, кузгалып китәм дигәндә генә, Бәгъремнең Госман чанасындагы балтасына сузылуы булды, әмма теге имансыз аны шундук җилләп очырды. Чәме килгән үсмер палищщикның өстенә сикерде. Ул да булмый, Разия кечкенә йодрыклары белән аның тун кигән симез гәүдәсенең гөбе кебек күпергән аркасын дөпелдәтеп кыйный башлады:

— Балталарны бир! Балталарны бир!

Әмма көчләр тигез түгел иде. Госман исә ерткычларча кыйланды. Ул чыбыркысын Бәгъремнең күз турысында ук шартлатты. Бер ай буе яшькәзеп йөреде. Ярый әле ак төшмәде. Шул вакыйга исенә төшкән саен, хәзер Бәгъремне бер сорау бимазалый: «Әгәр Госман шул көнне Сталин бабай үлгәнен белгән булса, бу кадәр кансыз кыйланган булыр иде микән?» Бәгърем белә, бу сорауның, бәлки, бөтенләй дә мәгънәсе юктыр, әмма, нишлисең, борчый, бик тә борчый ул аны.

Шушы Разия ташлап китәргә итәме аны? Шушы тауларны, яланнарны ташлап китәргә дип, шушы Разия җыенамы?!

Кияүнең атасы — төп кода игълан салды:

— Ягез, туганнар, кода-кодагыйларга рәхмәт әйтеп, юлга кузгалыйк, булмаса. Туйның килен төшерү өлеше инде безнең якта дәвам итәчәк, Алла боерса. Әйдәгез, ашка дога кылыйк...

— И кода, сезләрне күргән кебек, кунак иткән кебек тә булмадык, — дип сүз башлады Рәһиба җиңги. — Тагын берәр кич кунасыгыз бар иде дә бит...

— Юк, юк, кодагый, рәхмәт. Кунак булмый диме! Туйның кыз ягындагы өч көне бүгенге заманда башыннан ашкан. Калган өч көне бездә дәвам итәчәк бит. Аннан ферсидәтелебез Айсин атларны да өч кенә көнгә дип биргәние...

— Ниткән Айсин ул тагын?! — дип, Гыймакай карт танк башнясы кебек йомры башын төп кода ягына борды. — Ниткән Айсин турында лыкылдыйсың син, кода-а-а?

— Габидулла Айсинны әйтүем. Ялгышмасам, аны безгә сезнең яклардан килде, дигәннәр иде...

— «Әрмийский паррядык»мы?

— Нәкъ үзе! — Төп кода урынында кыбырҗып алды. — Каян беләсез?

— Белми диме! Тагын да «Дуңгыз Иваныч», шулаймы?

— Монысын әлегә ишеткән юк. Бездә аңа Синтральни Телеграф диләр бугай...

Авызларына капкан азыкларын да чәйнәргә оныткан колтамакларның йөзләре чалшаеп катты. Гыймакайны очкылык тота башлады. Болай да хәтерсез карт, Айсин турында ишеткәч, чиратны тәмам бутады.

— Ә ниг-гә? — дип укталды ул, төп кодага күзләрен шар итеп. — Ниг-гә ал-лай дил-ләр?

— Нигә дип. Бер-бер хәл булса, телефунга утырып ала да «Синтральни! Синтральни!» дип кычкыра башлый. Аңарчы районны ике урарга мөмкин, мин сезгә әйтим...

Айсин аркасында бер ел төрмәдә дә утырып чыккан Чулак Гамир бу юлы тыела алмады, күрәсең:

— Сез аны берүк безгә кире кайтара күрмәгез инде, — диде. — Киленнәрегез кебек, төшкән җирендә таш булсын...

— Горурланыгыз, аны сезләргә без җибәрдек,— диде почмактан Сәбәхетдин. — Таракан агуы урынына...

Кемдер пырхылдап көлде.

— Бәй, бәй, алай булгач, бөтенләй туганлашкан булабыз бит! — диде аңа-моңа игътибар итеп бармаган төп кода. — Безне озата баручы кода-кодачалар сез Габидулла Солтанморатович белән Аллагуәттә күрешерсез әле!.. Әйдәгез, ашка фатиха кылыйк, булмаса...

Ишеткәннәреннән Бәгъремнең сыны каткан иде. Гүя кы-

рандас тәгәрмәче астыннан кыр казы кебек аның тальяны каңгылдады.

Эчке ашына әйләнгән мәҗлестәшләрнең теләгәне дога кылып, теләмәгәне битен дә сыпырмыйча, урыннан кузгалды. Шундук туйны озату ыгы-зыгысы башланды. Бу ыгы-зыгының нинди вак һәм нинди эре мәшәкатьләрдән торуын бар тирәнлеге белән аңлатып бетерү мөмкин түгел. Күрәсең, шуны күздә тотып, борынгылар: «Туй үпкәсез булмый»,— дигәннәрдер инде...

## III

Атлар җигелгән иде. Кияү белән кәләшкә тәгаенләнгән кырандас тәртәләре арасыннан кара айгыр, тояклары белән җир төеп, дугадагы кыңгырауларны бимазалый һәм йөрәккә әллә нинди моңсулык тамыза. Аш арбасына кызның бирнә җиһазлары салынган ак семәрле сандык, ак җәймәләргә төрелгән мендәр-юрганнар, озата баручы кода-кодагыйларның арбаларына сугыштан соңгы елларда ачлыктан чыга башлаган халыкның затлы азык мөлкәте — мичкә-мичкә ачы бал, шакмаклы ашъяулыкларга төрелгән ак күмәчләр, балга гына катырылган бавырсак һәм атланмайда йөздереп пешерелгән җәймәләр, таба күмәчләре төялә иде...

Чынлап та ярыйсы ук кызып алган Ихсан белән Сабирҗан шундук Бәгъремгә ябырылдылар:

— Җиз Маңгай! Безне, «Бүләк» урманына барып, кодаларны озатып калырга җибәрәләр. Мәсгуть абзый безгә сине дә калдырмаска кушты. Әйдә, киттек!

— Юк, мин бармыйм, — диде Бәгърем. — Мин моннан гына озатып калам...

— Син нәрсә, шаштың мәллә? Гармун кирәк бит! — Ихсан аның иңенә сугып куйды. — Үзебезнең Разиябызны соңгы тапкыр тау башыннан да озатып калмагач!

— Гармун гына кирәкмени? Гармун белән Бәгърем аерым булалмый, аңладыңмы? Бармыйм, дигәч бармыйм.

Егетләр белә: Җиз Маңгай ике сөйләми.

— Әллә ничек итеп бозылдың әле син бүген, гадук*, — диде аңа үпкәләп өлгергән Ихсан. — Аңламыйм мин сине бүген...

— Бүген аңламасаң, бәлки, киләчәктә аңларсың ... — Җанында кайнаган давылларны кеше аңлау түгел, әлегә үзе дә аңлый алмаган Бәгърем сүзләрен теш арасыннан сыгып кына чыгарды. — Аның каравы мин синең мине аңламавыңны аңлыйм!..

Ул Разияның әтисе Миңнебай абзый әле сугышка китәр

---

* Г о д о к (урыс.) — кордаш, чордаш, елдаш мәгънәсендә.

алдыннан урманнан кайтарган, инде яртылаш череп, муртаеп беткән усак бүрәнәләр өстенә менеп утырды һәм «Их, алмагачлары»н сайратып җибәрде. Әмма шундук кайсыдыр коданың бии башлаганын күреп, «Корт чакты»га күчте. Барлык ишегалды бер булып тузан күтәреп бии башлады.

— Ас-са!

Хатынынннан башка бернәрсә эшләргә яратмаган Сәбәхетдин абзый, түгәрәккә Мәстүрә җиңгине дә өстерәп чыгарып, тузан күтәрергә тотынды.

— Әйдә, карчык! Өязедә биек тал, мин барында биеп кал!..

Кемдер Бәгъремнәрнең «шәлия» табыныннан шакмаклы сары ашъяулыкны чыгарып җилпеде. Моңарчы тузанда коенган чыпчыклар, тагын да тузан порхылдатып валчыкларга ташландылар, әләгәсен томшыкларына эләктереп, кабаттан тузан порхытып һавага күтәрелделәр.

— Бәгърем, «Колхоз бию»н уйна!

— Бәгърем, «Чабата»ны сиптер, давай!

Әгәр гармун уйный белмәгән булса, ул, чабата үреп булса да, авыл тарихына кергән булыр иде. Яшь кенә булуына карамастан, чабата үрүдә Колтамакта аңа чыккан кеше юк. Чабата үрү — гармун уйнау кебек нечкә нәрсә бит ул. Разия да Бәгърем үргән чабаталарда гына үсте инде югыйсә. Җир йөзендә өч чабата бар: җәелгән мукшы чабатасы, тупас урыс чабатасы, ыспай татар чабатасы. Әйе, теләсә кем әйтер: алар арасында иң матуры — татар чабатасы. Менә шул татар чабатасын Бәгърем абзагыз коеп кына куя. Аның сурәте затлы, атламы вак тешле. Җиде юкәдән. Чәчүргеч кебек нәзек, балавыздай якты сары, озын юкәләрдән тезеп тә җибәрсә, карап кына торырлык була, билләһи. Разия шуңа күрә дә башкалар үргән чабаталарны яратмады. Бер тапкыр ул хәтта Бәгърем чабаталарыннан да баш тартты. Яңа уку елы иртәсендә булды бу вакыйга.

Бәгърем, Разияны алып күрше авыл мәктәбенә юлга чыгарга дип, аның артыннан кереп килә иде. Өй эченнән ниндидер үксү тавышлары ишетеп, ул мич ягы тәрәзәчегенә елышты.

— Ән-некәем, ән-некәем! Кимим, үтерсәң дә кимим! — дип, бөгәрләнә-бөгәрләнә елый иде Разия. — Чит авылга мин чабата киеп бармыйм!.. Мин хәерче кызы түгел!..

— Канымны кыздырма! Каян килгән хан кызы! — дип, каеш белән сыптырып алды аңа әнисе. — Нибуч, киярсең!..

— Кимим! Мин чабата киеп күрше авылга укырга бара торган ата баласы түгел!

— Нәрсә, атаң калдырган малың бар мәллә? — дип җикерде җан ачуы чыккан ятимә солдатка. — Сөякләре дә череп беткәндер инде!..

Һәм Раһиба җиңги, сәкесенә бөгелеп төшеп, үзе дә елый башлады.

Бәгъремнең ике күзенә дә пылт итеп яшь типте.

Ул елга аша бер атлап, ике сикереп чыгып, картинәсенең аягына ташланды:

— Картинәй, бир Сафа абзыйның былтыр Донбасстан сиңа дип җибәргән теге эрзинкәләрен!..

Картинәсе бераз карышып маташса да, артык каршы тора алмады.

Әй, килеште Разияга бу кызыл эчле, хуш исле, ялтыравык эрзинкәләр. Бөтен мәктәпнең күзе аңарда гына булды шикелле.

Әле үзенең Разияны бөтенләйгә авылдан озату мәҗлесендә утыруын исенә төшергәч, ул яңадан сискәнеп куйды. Нинди китү? Нигә кайту түгел? Менә Бәгъремнең бу гармун моңнарын шушы тал яфракларыннан аерып алып китеп буламы? Булмый һәм булмаячак. Егет кеше җаны да, кыз кеше җаны да бер түгел микәнни? Ничек инде ул: шушыннан җан ал да, шул җанны алып, ә менә бар нәрсәне калдырып кит тә бар! Җан калырга тиеш. Хәтта гәүдә китсә дә. Әйбер китсә дә. Чөнки җан барыбер кайтачак. Егет чорына кереп кенә барган, кызларның егетләргә караганда иртәрәк өлгерүен, егетләрнең китү-кайтуы белән кызларның китү-кайтуының икесенең ике төшенчә булуын әлегә аңламаган, үзендә булган балаларча якынлык, бергәлек тойгысының нәкъ шул сөюнең, саф сөюнең — ул көткән канатларның үзе икәнлеген һәм нәкъ үзе булачагын әлегә башына да китерә алмаган Бәгъремнинди дер фәлсәфи кануннар белән җан һәм тән бердәмлеге турында уйланып өзгәләнә иде...

Шат тавышлар белән тулган ишегалды биеп арыган иде.

Бәгърем «Озата барма»га күчте. Кемдер, күкрәк киереп, җырлап та җибәрде:

Озата барма, иркәм, озата барма,
Олы юл бит, бәлки, адашмам...

Тальян телләре астыннан моң көрәлеп, актарылып чыга иде. Башын бераз читкә борып, Бәгърем уйнады да уйнады. Гүя аның бу моңга бернинди катнашы да юк. Болай да аңлашыла бит: Җир йөзендә татар кебек талы һәм тальяны бу кадәр бергә береккән, бер җанны, бер тәнне тәшкил иткән, үзара шулкадәр тәңгәл килгән, бер-берсеннән башка яши алмаган, бер-берсенә кендеккә кендек, йөрәккә йөрәк сарышып яшәгән кавем юк. Тальянның талпынуы була — тал, хәрәкәткә килеп, аңа таба җилпенә. Тальян бары тик тал көмешеннән генә көмешләнә. Тальянның тал җаны һәм татар җаны. Татарның тальяндагы тал җаны. Тальянның татардагы тал

җаны. Татар талларына килеп кунган итальян гармун! Йа Ходай, бу тәгъбирне ничек кенә төрләндереп булмас иде. Кыскасы, татар тальянсыз калса гына бетәчәк.

Туй озатырга дип килгән халык, ишегалдына сыеша алмыйча, урам буендагы читәннәргә сарылган иде...

Йомшак кына җил исте.

Йөрәктәй тамчылы тал яфраклары шыбырдашып куйды.

Өязе елгасы шадраланып тынычсызланды. Аның өстеннән агымга каршы вак дулкыннар йөгерде.

— Чыгалар!..

Бәгърем күзен керфекләрен сындырырлык итеп каты йомды һәм, үзе дә сизмәстән, соңгы чорда гына тарала башлаган «Хуш, авылым» көен уйнап җибәрде.

Читәнгә сарылган халык башланган көйне солдатка Раһибаның авылдан китүче беренче ятимәсе һәм чибәре Разия хөрмәтенә кумәкләп җырларга тотынды:

Хуш, авылым, миннән сәламнәр көт,
Таң җилләре искәндә...

Көйнең яңгырашы борылышларга, борылышлары сөзәк кенә итеп агышка әверелеп, Өязе талларыннан кайтаваз булып кайта иде. Аһәңнәр тыела алмыйча үкси, үкси дә, Бәгърем гә буйсынудан туктап, баш түбәсендә тургай булып атылып менә. Бәгърем нең аларны төшерәсе, яшерәсе, сүндерәсе килә, әмма ул аны булдыра алмый, вәкаләте җитми. Егет бу авазларны гүя юеш тастымалны сыккан кебек үз тәненнән, үз җаныннан сыгып чыгара, аннан, көйнең буыннарында сыгылмаган бер генә тамчысы да калмагандай, калтыранып ала.

Сандугач гөлләрдә сайрый,
Көен ничек отасы?
Бергә уйнап, бергә үстек,
Шуны ничек онтасы?
Сандугач, күгәрчен,
Гөлләр үскән, күрәмсең?

— Хәзер чыгалар!..

Ул башын тавыш килгән якка борды, әмма күзләрен ачарга көче җитмәде.

Гүя ул үзенең тәнендә үзе әсир, үз җанында үзе мәхбүс иде.

Менә ул, ниһаять, авыр йөк күтәргән йөкче кебек, көчәнеп һәм өзлегеп, аскы һәм өске керфекләрен аера төште, аннан керфекләренең тыгыз рәшәткәсе аша күз алмасына сыек кына көн яктысы сирпелде һәм ул бу яссылыкта, еракта-еракта, әллә кайларда булып шәйләнгән келәт ишегеннән чыгып килүче Разияны төсмерләде.

Бәгъремнең карашы торган саен ачыла, офыклары киңәя төште.

Аның артыннан теге Кысык Күзнең гәүдә ишарәте дә оешты, бу ишарәт Разияны җитәкләп алып, җил капка алдында торган кырандаска таба алып китте...

Разия бәбәй итәкләп тегелгән ак борчаклы яшел күлмәк, күлмәге өстеннән эре чәчәкле алъяпкыч, аякларына яп-яңа ялтыр эрзинкәләр кигән иде.

Болар Кысык Күзнең мәһәре булырга тиеш.

Бәгъремгармун күрекләрен өзәрдәй булып әйләндерә-тулгандыра тартты.

Колтамак таулары артыннан күтәрелгән сүрән кояш кебек, Разия күзләрен җирдән күтәрмичә генә елмая иде.

Ышанасызмы, бераз гына тартылып, агарып калган Разия елмая иде!

Димәк, ташлап китү — бәхет?!

Кучер егет, кырандас кузласына менеп утырган да, дилбегәләрен җәя керешедәй тартып тотып, кара айгырны чак-чак тыеп тора.

Бәгъремгмондый хушлашу — кыз озату йоласының башка бер генә мизгелен дә күрми дә, ишетми дә, аның бар дикъкате бары тик шушы кырандас тирәсенә генә тупланган иде.

Менә Разия Кысык Күз ярдәмендә кырандасның тимер күперчегенә басып, вак кына ак талдан үрелеп, тиз генә черемәсен өчен кара буяуга буялган кырандас үрәчәсенә менеп утырды, аның белән янәшәдә, тирә-ягына каранып баш селкегәннән соң, Кысык Күз дә урын биләде. Кичә генә кыз белән егет булган, бүген инде кияү белән кәләшкә әйләнгән яшьләрне туганнары, авылдашлары, күршеләре, ахирәтләре уратып алды. Болар арасында Бәгъремгенә юк иде. Хушлашу, теләкләр теләү башланды. Арттагы арбаларга кәләшне озата баручы кода-кодагыйлар, кода-кодачалар утыраша башлады.

Бәгъремуйнавыннан туктады.

Ул, галәмәт зур авырлык белән өстерәлеп, урыныннан күтәрелде. Аның үзе, аның гармуны белән әйтерсең үз тирәсендә типченгән чыпчыклар гына түгел, гүя барлык Җир шары күтәрелә иде. Аһ, авыр, шуңа күрә авыр иде бу гармун белән бергә күтәрелү!

Ул вак, чеметем адымнар белән кырандас каршысына килеп туктады. Беренче мәртәбә кияү-балага якыннан дикъкать белән карады. Ошатмады ул аны. Чынлап та, кысык күзле икән ул. Карабодай орлыгы кебек әллә нинди почмаклы, күпкырлы икән ул күзләр, чынлап та.

— Хушлашмыйча да китеп барасыңмыни, Разия? — диде ул, чак-чак ишетелерлек итеп.

Разия эндәшмәде. Ул күтәрелеп карарга тартына иде бугай.

Бәгърем соравын тагын да кабатлады.

— Хуш, — дип пышылдады Разия, алсулыгыннан сытылып чыгардай булып. — Хуш, Бәгърем...

— Кем бу? — дип җикереп җибәрде Кысык Күз. — Бу нинди бәгърем ди тагын?! Бу нинди молокосос минем кәләшемнән дапрус ала?! — Ул утырган җиреннән генә итегенең табанын Бәгъремнең күкрәгендәге тальянга терәп, бар көченә этеп җибәрде. Бәгърем артка этәрелде. Тальян кыр казыдай каңгылдап куйды.

Калганы күз йомганчы булды. Күргәне күрде, күрмәгәне күрми калды.

Кысык Күз кесәсеннән бер кушуч тимер акча чыгарып сипте. Ул яңгыр булып Бәгърем өстенә коелды. Бала-чагалар, бер-берсен таптый-таптый, аяк астындагы тәңкәләрне җыярга абырылды.

Бәгъремнең җене кузгалган иде.

Аның зиһенендә яшенле тамгалар калдырып, күк белән җир бергә кавышты. Аңа күк нәрсәдер пышылдагандай булды.

Бармакларын гармун телләренең, бакаларының төбенә кадәр батырып, күреген чамасыз киереп, иләмсез акырта-акырта тарта, аннан тагын да акырткан уңайга, күрекне бер учмага җыя, аннан тагын киерә салып, Бәгърем хәлиткеч адымнар белән ишегалдындагы читәнгә таба бара иде. Күрек уртасындагы ак шакмак, үзенә урын тапмагандай, бер зурая, бер кечерәя иде. Менә ул, ниһаять, читәннең янына ук килеп җитте һәм гармун күреген яңадан акыртып сузып, көтмәгәндә генә һәм, ике дә уйламыйча, татар тальянын күрегеннән Разиялар читәненең казыгына кидерде.

Күректән пошкылдап һава чыкты.

Халык аһ итте.

Тальян гармун соңгы тапкыр кыр казы каңгылдаган тавыш чыгарды да канатсыз коштай казыкта эленеп калды.

Җене котырган үсмерне туктату мөмкин түгел иде. Ул, яшен тизлеге белән атылып, кырандас янына килде һәм Кысык Күзнең изүенә ябышты:

— Измәңне изәм! Бирмим Разияны! Бирмим!..

Ишегалды чайкалды. Каенишләр белән балдызлар, кодалар белән кодачалар, каенигәчләр белән каенагалар барысы бергә буталды.

— Ку атыңны, нәрсә карап каттың! — дип җикерде Кысык Күз кучер егеткә. Аннан, үрелеп, дилбегәне какты. — На! Әйдәгез, кузгалдык!..

Кара айгыр җил капка аша урамга ыргылды. Авылны дугадагы кыңгырау чыңнары басты.

— Исерек бит ул! Туктатыгыз!..

— Бер стакан балны күтәрә алмаган егет егетмени ул?
— Туйны бозды, маңка малай!..
Ишегалдын йөзләгән авазлар басты.
— Тукта, Бәгърем! — Бер төркем ирләр егеткә ташланды.
— Син бит аның белән йөрмәдең дә... — Каяндыр килеп чыккан Ихсан дустының иңенә асылынды. — Син нәрсә? Шулай ярый диме?!
Аны җиргә сузып салып, өстенә атланып утырдылар. Авазлар хәзер кайнар җир өстеннән шуышып, туп-туры Бәгърем колакларына савыла иде.
— Үзегезгә җитмәгән акылны кешегә өйрәтмәгез әле! — Гыймакай карт Бәгъремне якларга тырышты. — Йә бөтенләй җиңеләеп калырсыз. Яшь чакта алай гына була инде ул... Яшь, тиле, каны кайнар...
— Мондый җегетләр булганда яшибез әле... — диде берәү, тыны кысылып.
Ул читән артында басып торган Зимагур Зиннәтулла булды бугай.
— Көнләшә ул... — диде кемдер, ап-ачык итеп. — Балак бете үргә үрләсә, шулай тилерә ул.
— Көнләшмим мин! Көнләшмим! — Нахактан рәнҗегән Бәгърем янга бәргәләнде. — Гарьләнәм мин!.. Әрним мин!..
Исерекләр айный, айныклар исерә төште.
— И-и-и, ахмаклар, шуны да аңламыйсыз,— диде Сәбәкәй, тыныч кына. — Ярата ул аны. Җан сөюе белән сөя, беләсезме! Сез аңлый да алмыйсыз мондый сөюне...
— Ә нигә соң аны, алай булгач, Разиясы яратмый? — диде бер чәрелдек тавыш. — Нигә яратмый да, нигә әллә кайдагы әтрәгәләмнәргә тормышка чыга?
— Ахмак син! Бәгъремне яратмау мөмкин түгел... — диде Гыймакай карт. Аннан бериш уйланып торды да өстәде: — Бәгъремгә: «Мин сине яратмыйм, Бәгърем», — дип әйтеп булмыйдыр ул... Моның өчен нинди йөрәк кирәк!.. Мәсьәлә, җәмәгать, монда башкачарак тора шул...
— Бәгъремне... Бәгъремне аны... барлык авыл имезгән!..
Монысын Чулак Гамир әйтте.
— Авылның тарихка керерлек беренче чибәре китә... Шуңа жылый җегетебезнең җаны...
Монысын ихластан шул ук Зимагур Зиннәтулла әйтте.
Ул ара да булмый, җиргә боргычлап салынган Бәгърем башы белән җирне төя-төя үкси иде:
— Тал җаным китте, талларым да китә! Тал җаным китте, тауларым да китә!..
— Һич тә көтмәгәнне... Берәрсе котыртты мәллә безнең туйны бозарга? — Кызын озата барырга дип менеп утырган арбасыннан кире төшкән Рәһиба җиңги оялуыннан нәрсә

эшләргә белми бөтереләә иде. — И Ходаем, нинди гөнаһларым өчен генә... Туйны бозма, Бәгърем, бозма, ишетәсеңме!..

— Гафу ит, Раһиба җиңги... гафу гына итә күрче...— дип ялварды Бәгърем анасы сыман якын күрше җиңгәсенә. — Мин түгел бит! Аңлагыз... Күкләр шулай куша!..

— Дөр-рес, туган! Безгә күкләр шулай куша! — дип әйләнеп йөри башлады аларга якын да килмәгән Кое Төбе Гыйндулла. — Мин — исерек, мин — чучка, әтнәке тоям — безгә күкләр шулай куш-ша!..

Инде җил капкадан туй олавының башка атлары да чыгып җитеп килә иде.

Кызын берүзе төп кода һәм төп кодагый буларак озата барырга тиешле Раһиба җиңги, олаудан калмыйм дигәндәй, йөгереп барып, арбасына утырды.

Бәгърем зиһененнең бик еракташы офыгыннан ике медален ике як түшенә таратып таккан, галифе чалбарының ике як канаты белән бар тирә-якны баскан Айсин күләгәсе күтәрелде. Әнә ул кайдадыр Ашкадар буйларындагы Аллагуәт авылы башында авызын ыржайткан да, кабып йотарга дип, Разияны күтәреп тора...

Гыймакай карт әйткән Дәҗҗал гүяки хәзер Бәгърем үзе иде.

Ул шайтан көче белән җирдән этәрелде һәм, үзенә менеп атланган авылдашларын иңеннән коеп төшереп, туй олавы артыннан йөгерә башлады:

— Кайт! Разия, кайт! Аерылып кайт!..

Кемдер аны сугып екты.

— Авызыңнан җил алсын, мәлгунь!..

Бу Разияның туганнан туган абыйсы Мәсгуть иде.

Бәгъремнең авызыннан кан китте.

Ул, берни булмагандай, яңадан сикереп торды һәм туй олавы артыннан авыл очына таба йөгерде:

— Разия-я-я!.. Ка-а-айт! Разия-я-я, ка-а-а-айт!..

...Бу вакыйгаларга инде илле ел гомер үтте.

Менә илле ел инде тальян гармун әле һаман да казыкта асылынып тора һәм Ашкадар, Ырымбур тарафларыннан искән ярсу җилләрдә чайкалып ыңгыраша, кыр казыдай каңгылдап куя сыман.

Бәгъремгә килгәндә, ул менә илле ел инде туй олавы артыннан йөгерә кебек.

Шул еллар истәлеге булып, Бәгърем ихатасыннан әллә кайларга торнадай озын муенын сузып сиртмәле кое баганасы күренә. Гүя ул, үрелеп, офыклар аша кемнедер эзли һәм эзләгәнен табалмагач, алдагы гасырларга үзе дә очып китәрдәй булып талпына.

*Июнь — сентябрь, 1999 ел.*
*Переделкино — Чаллы*

# КӨНБАГЫШ ЧӘЧКӘСЕ

*(Чын хикәя)*

*Украин язучысы, халык артисты*
*Григорий Булахка багышлана*

## КЕРЕШ

«Чын хикәя». Шулай дип яздым да, үзем дә уйга калдым. Гади, әмма бер-берсенә каршылыклы бердәмлектә яшәгән бу ике сүзнең мәгънәсе турында уйланган укучыда «Башка язучылар чынбарлыкта булмаганны, кем әйтмешли, «тузга язмаганны» язалар микәнни» дигән сорау тумасмы? Әйе, һәр әсәр тукымасының аркавы-буе тормышның үзе тарафыннан тукыла, сипләнә һәм мүкләнә, әлбәттә. Әмма гомумиләштерелгән чынбарлык — бер, ә менә вакыйганың ничек булган шулай язылуы — икенче нәрсә. Минем бу хикәямдә, әдәбиятчы галимнәр теле белән әйтсәк, әнә шул чынбарлыкны гомумиләштерү, образларны «кораштыру»ның бөртеге дә юк. Вакыйгалар чынында ничек булган, шулай сурәтләнде.

Укучым шушы кечкенә шартлылыкны исеннән чыгармаса, зыянга булмас иде кебек.

## Юлда

...1996 елның июль азаклары иде.

Мин украин кояшы астында янып, тыштан, чынлап та, кысла сыман тутыгып кызарган төстәге, эчтән исә тирләгән-пешенгән Казан–Симферополь поездында Кырым тарафларына китеп барам. Дөрес, язучыларның Ялтадагы иҗат йортында иҗат та, ял да итмәячәгем билгеле: минем уй-хыялым туган җирләренә кире кайтып, яңа нигезләр кора башлаган кырым татар кардәшләребезнең хәл-әхвәле белән тәфсилле танышып, кулымнан килсә, алар хакында кечкенә генә булса да китап язу...

Поездыбыз җир катламнарыннан чыгарылган ком-таш таулары — ташландык терриконнарның очлы уклары күк йөзен тишкәләп беткән дастани Донбасс аша үтә. Ихтыярсыздан башыма килгән Кременчугның төрки-татар «кирмән, кирмәнчек»тән, Донның «тын, тын елга»дан, хәтта румнарның Танаисының да шул ук төрки-татар «тын агыш»тан алынганлыгын уйлыйм да, «Донбасс — тынбас», ягъни «тыныч бас»тан алынгандыр дип елмаеп куям, чөнки, ни өчен дигәндә, җәмәгать, кайчандыр өч олуг милләт — украин, урыс, кыпчак-татар яралган бу борынгы кыпчак далаларында, шул ук өч олуг милләт — украин, урыс, татар тире һәм каны белән сугарылган «тыныч бассейн»да һич кенә дә тыныч түгел бу

араларда. Әле берничә көн элек кенә биредә, бөтен иске мәмләкәттәге шикелле, эш хакын түләмәү, акчасызлыктан ачыккан шахтерларның фетнәсе булып алды; алар кулга-кул тотынышып, барлык юлларны, шул исәптән тимер юлларны да япты; «теге килүебездә Горловкада туктатып, безне унсигез сәгать буе үткәрми тордылар, — дип пышылдый колагыма титанда су кайнатып маташкан хуҗабикәбез — татар хатыны. — Инде бу юлы да туктата күрмәсеннәр иде, Ходаем!»

Донбасс... Донбасс... Донбасс...

Коңгырт күкерт булып каткан, килеш-килбәтләре белән Хеопс корылмаларыннан кайтыш булмаган очлы комташ-күмер косыгы тауларына оялчан, моңсу караш ташлыйм да тагын уйга калам: бу пирамидаларның кимендә өчтән берен безнең татарның күкрәк көче җир йөзенә күтәргән бит!..

Кайчандыр борынгы кыпчак далаларында — нәкъ менә шушында гомер кичеп, атта-иярдә Европага китап һәм язма хәреф илткән кыпчак балалары — татар, гасырлардан соң, бүгенге Донбасс киңлекләрендә яңадан бистә-бистә булып укмашып, мәдрәсә-мәчетләр, урта мәктәпләр, мәдәният сарайлары тоткан, гәзит-журналлар чыгарган татарлар үзләренең йөзек кашы саналган «Шахта» җырын да шушында иҗат иткән бит:

Шахтер егет эшкә бара,
Кулларында лампысы.
Сиксән сажин җир астында,
Күрми дөнья яктысын.
Шахталарга син төшәрсең,
Җырлап күмер кисәрсең.
Әгәр мине бик сагынсаң,
Бик саргайсаң, нишләрсең?..

Ничәмә-ничә гасырлар таланып изелгән, уңдырышлы туфрагын икмәккә ягып ашарлык туган җирендә ачыгып, авылын ташлап качкан, әмма бәхетне «инде таптым» дигәндә генә «нишләптер» туган җирен «бик сагынган, бик саргайган» татар, менә бит, җәмәгать, суларга һава да җитмәгән җир астында, газ-тузан эчендә дә «җырлап күмер кисә» бит! Менә кайда ята безнең милли карахтерның серләре! Бу иске татар карахтерын җир өстендә күреп, бер дә ошатмаган, инде килеп, тагын бер тапкыр, инде «яңа татар»ны «коммунизм кыры күренгән» шартларда җир астында күрергә теләгән зур йөрәкле Такташ, моннан нәкъ җитмеш ел элек, башына калай кәтәлүк киеп, кулына тычкан уты тотып, Донбасс шахталарына төште. Җир астында «яңа татар»ны табу түгел, ул аннан үзе дә чыга алмады диярлек. Казан мохитенең тарлык, көнчелек, күрә алмаучылык шахтасы утыз яшенә җитәр-җитмәс шагыйрьне эһ тә итмичә ашады.

Җитмеш ел эчендә Такташтан соң татар шагыйрьләреннән,

язучыларыннан Донбасс шахтасына төшүче булдымы? Мин вагон тәрәзәсенең аркылы тимер тоткасын шытырдатып кысам. Күз алларым караңгылана. Нәрсә, төшеп калыргамы югыйсә?! Җитешерменме, соңламадыммы?! Мин төшмәгәч, миннән соң төшүчеләр һәм күтәрелүчеләр табылырмы?!

Кинәт, янгын чыккандай, тәрәзәгә сары ялкын сарылды диярсең. Йә Ходай — көнбагышлар!.. Кара-күкерт таулар, юл буйларыннан, чаң эченнән безне озатып калган моңсу акация, шыптагай тау-дала тирәкләре, каштан агачлары, шахтерларның караеп, калтаеп җиргә сеңешкән шәхси йорт-алачыклары, бараклары һәм төрле бина-корылмалар күкрәген яктыртып, урталай кисеп кул болгый иде безгә бу сары яулыклар... Әнә, урыны-урыны белән тар гына ызан булып калкып чыгып, инде беттеләр, күздән югалдылар дигәндә генә, һәм һич тә көтмәгәндә, яңадан зур-зур басу булып күтәрелә бу миһербанлы җан ияләре! Гүяки кемдер чарда әллә пычак, әллә кылыч кайрый һәм кайралган корал астыннан йөз яктыртып, аксыл томанланып һәм гөжгелдәп очкыннар көлтәсе сирпелә... Үзем көнбагышлар ялкыны эчендә үскән авыл малае булсам да, бу үсемлекнең бу кадәр мәгънәгә, илаһи көчкә ия булуы турында башыма китереп тә карагамыз юк иде. Бәлки, һәр җирнең, һәр төбәкнең, һәр милләтнең дип әйтсәк инде — иман шартын тәшкил иткән, шуны гына тансыклаган, үзенә генә хас фигыльле, үзенә генә сөйкемле сөяк булган үсемлеге, гөле, агачы, аш-тәгаме бардыр? Бу нинди иске авыздан яңа сүз ди тагын?! Бар, әлбәттә, бар! Әйтик, татарның яран гөлен, кына гөлен таба аласыңмы син калмык халкында? Таба аласыңмы шул ук калмыкның дала мәкләрен татарда? Юк, таба алмыйсың. Әйтик, урысның җитене, чуашның колмагы, башкортның курае, молдаван һәм башка бик күп җылы як халыкларының йөземе, татарның — милләтпәрвәрләребез гафу итә күрсен! — җылак талы-тальяны, американнарның акациясе, кукурузы... Туктагыз, әгъла бер үсемлек-нигъмәтнең чит-ят туфраклардан кызлар кебек утырма-кунакка гына килеп, шунда бөтенләйгә утырыптөпләнеп калганы юкмыни? Кешелекнең тәгам тарихы тоташы белән шуны раслый бит! Америкалардан ковбой кебек атта чаптырып безгә килеп җиткән кукуруз шушы ук украин җиренең милли зәменә әйләнмәдеме? Тукаебыз, дистәләрчә шагыйрьләребез данлаган бәрәңгене алыйк. Татарның йөрәк парәсенә әйләнмәдеме? Әйләнде! Ничек кенә әле! Әйтеп кара син бүген татарга «Бәрәңге синең милли ризыгың түгел» дип. Ни генә димәгез, җәмәгать, минем көнбагышның башка беркайда да украин туфрагына үзләшкән кебек үзләшкәнен, шулкадәр берекәнен, аның белән шулкадәр туганлашканын, су молекуласындагы бер атом кислород, ике

атом водород сыман кавышып, җирнең шулкадәр аерылгысыз җан иясенә әверелгәнен күргәнем юк иде. Нинди магнит көчләре тудыра бу могҗизаны? Җир йөзендә тагын да берәр шундый үсемлек бармы?

Әнә сары яулыкларын колак артларына чөйдереп бәйләгән кыйгач кашлы, ниндидер серле, кыпчакый тәнле украин кызлары кебек елмая, елмайганда бит алмаларында сөйдергеч уемнар хасил иттерә, аннан тагын ниндидер сөйдергеч бөти ыргытып, ниндидер нечкә теләк-тойгылар да уяттыра беләбит алар, чукынчыккайларым!..

«Тукта, — дим мин үземә. — Тукта, малай!» Бу серне милләтең әле син туганчы ук ачкан түгелме? «Көнгә баккан көнбагыштай сиңа тартыла күңел...» Ничек кенәләр әйткән, ә? Урган да салган, ә? «Көнгә баккан көнбагыштай... сиңа тартыла... күңел...» Таң туган саен, кояшны таулар-урманнар артыннан җир өстенә өстерәп чыгару, көне буе шул кояш артыннан тотам да калмый, үзеңне-йөзеңне йөз дә сиксән градуска бору һәм шул мәшәкатьләр өстенә берьюлы бердәнбер һәм бер кочак чәчкә ату өчен үзеңдә көч табу... Үзе түм-түгәрәк, үзе алтын табак, алтын табагында бер өем мәмәй бит әле аның!.. Исемен кара син аның, исемен! «Подсолнух». Урысча мәгънәсен алай ук тирән дип әйтмәс идем мин. Кояш астында үскән, ягъни кояш үсемлеге генә була түгелме? «Соняшник». Украинча да шул ук мәгънә кебек, әмма «со-ня» кисәкчәләре мәгънәгә теге сары яулыкларын колак артларына чөеп бәйләгән украин кызлары ишарәтен өсти кебек. Миңа калса, татарча «көн-багыш, көн-балкыш, көнбак-кычы, ай-багар»ы күпкә мәгънәлерәк: көнгә бага; айга бага; кояшка тотынып, кояш тезгенендә яши; кояш баю белән таҗ элпәләре-керфекләрен йома, көндезен изрәгән сабагына сумит утыра, яфраклары тартыла, җыйнаклана төшә, өченче әтәч белән уянып, кояшның беренче нурлары әле Җир шарының теге ягыннан сирпелү белән керфекләрен күтәрә, сабак һәм яфраклар җирдән яңа сут белән тулышып, яңадан изри һәм кешелеккә мәмәй җитештерә башлый... Татар хатыны кебек эшчән, сүзсез тыңлаучан, әдәпле һәм түземле ул көнбагыш. Шуңа, күрәсең, аның урак өсте дә көзнең соңгы чорына — еш кына көннәр бозыла башлагач, татар бәрәңгесе белән бер чоргарак туры килә... «Көнбагыш турында берәр шигырь яисә берәр хикәя язмыйча булмас», — дим мин, Донбасс көнбагышлары уяткан хисләрдә кайнап. — Ашыгырга кирәк. Моңа кадәр ничек башыма килмәгән? «Бирәм дигән колына — чыгарып куяр юлына» дигәндәй, көтмәгәндә күңелдә дүртьюллык кына шигырь кисәге ярала. Чүпчар дип атыйм мин мондый корамаларны, чөнки шагыйрь «мин»е бик еш кына «Мин тауларга мендем, мин таулардан

төштем» кебек «зур» гомумиләштерүләр дәгъва иткән «мин»-нәрне язарга да, укырга да яратмыйм. Шулай да, бер кирәге чыкмаса, бер кирәге чыгар дип, әле үземне алда нинди вакыйгалар көткәнен күз алдыма да китерә алмыйча, иренеп, теләр-теләмәстән генә куен дәфтәремә теркәп куям:

Кояш артыннан башкаен
Борган көнбагыш сыман,
Минем бу алтын йөрәккә
Бөтен Җир шары сыйган...

Язучыларның Ялтадагы иҗат йортында минем моңарчы булганым юк иде. Дөресен әйтим, бер дә ошамады. Кайчандыр, хәзер «торгынлык» дип аталган чорда язучылар ширкәтенең күпсанлы җитәкчеләрен, сәркатибен зиннәтле автоларда алып килеп, алып китеп кенә ял иттерүгә исәпләнгән, безнең ише җәяүле язучыга диңгездән еракта, тау канатына карлыгач оясы кебек ничектер чәпәп төзелгән бу ундүрт катлы йортта көн челләсендә чайканып, битне-тәнне җиләсләп алыр өчен салкын суы да сәгатьләп кенә бирелә, җылы суы бөтенләй диярлек юк иде. Ярар, без, ир-ат, бака кебек судан чыгарга яратмаган хатын-кыз түгел — анысына түзәр дә идең; иң теңкәгә тигәне шунысы — язучылар йорты исәпләнеп, кинаяле рәвештә А.П.Чехов исемен йөртсә дә, анда язучыларның әсәре дә күренмәде. Кан косып дөньядан киткән Антоше Чехонте, Ялтада кулга алынып, архивы туздырылып, Казан төрмәсендә кыйналудан шулай ук кан косып үлгән Галимҗан абзый Ибраһимов рухлары тынгы бирми иде миңа; кайчандыр Брежнев заманнарында танылган язучылар гына килә алган кунакханәләрдә бүген Мәскәү, иртәгә Киев, берсекөнгә Казан көннәрен үткәргән әдипләр бүген бирегә килә алмый һәм, килгән хәлдә дә, үзен хуҗа итеп тоя, ягъни элекке әтрафлы мохитне тудыра алмыйлар икән... Шуңа күрә, ахрысы, ашханәнең, күптән ялга чыкса да, һаман шунда эшләп, түзеп тора алмаслык олы яшькә җиткән һәм, ахрысы, үзен шуның өчен бераз уңайсыз тоткан мөдирәсе Фаина Лазаревна Файнберг, вакыт һәм көч-хәл табып, үзе үк минем югары каттагы бүлмәмә керде — хәлемне белеште, рәхмәт төшкере:

— И-и-и, күгәрченкәем! — диде ул, иңемнән сөеп. — Сез безгә чәйдәге чәер кебек газизсез! Сез бит язучыларның иҗат йортында бердәнбер язучыбыз! Тамагыгызны туйдырып йөрегез. Тартынмагыз. Җитмәсә, өстәмә сорагыз! — Аннан стена аша ишетмәсеннәр дигәндәй, колагыма кеткелдәде һәм күз кысты. — Сатин балаклы сәүдәгәрләр күтәрер әле!..

Сәүдәгәрләр хакында дөресен сөйли иде Фаина Лазаревна. Иномаркаларда үзләреннән күпкә яшь хур кызла-

рын, елтыр бауллар, каплар, торбышалар, крокодил тиресеннән тегелгән чумаданнарын күтәргән хезмәтчеләрен ияртkән һәм авыз кырыйларында «Мальборо» биеткән, аннан бигрәк үтүк-фәлән күрми Босфордан Европага чыккан киң сатин балакларын җилфердәтеп, люксларга үткән сәүдәгәрләр көне буе затлы шәраблар эчеп, диңгез ярында корсак кыздырып яталар да, төне буе музыка акыртып, мартның гыйшкый мәчеләре сыман азгын бакырышып, бу йортның иманын качыралар, җитмәсә, төнге ике-өчләрдә автосигналлары белән һаваны кычкыртып суеп, озатыша, таралыша башлыйлар…

Көннәрдән бер көнне, мин, ишегалдында Лувр залларына эләккәч, үзен бик тә уңайсыз тойган папуас хәлендәге кешене очраттым. Ул Мәскәү шагыйре булып чыкты. Сугыш һәм хезмәт ветераны. Озын-озын бәетләр яза. Ике ятим бала кебек, без бик тиз аңлаштык. Ул миңа Мәскәүнең ниндидер РПБ дигән, язучы Гобәй Дәүләтшин әйтмешли, «капратифнай лафка»сы чыгарган һәм аз да түгел, күп тә түгел — нибары җиде генә шигырьдән торган «Тебе, Россия!» дигән җыентыгын да бүләк итте. Аптырамадым мин җиде санына. Бәхетле сан ул: Тарас Шевченконың беренче китабы «Кобзарь» дә җиде генә шигырьдән торган бит!..

«Бүләк ашы — кара каршы» дигәндәй, аңа мин дә ялга китәр алдыннан гына Чаллыда чыгып өлгергән, әле беркемгә дә бүләк ителмәгән һәм кирәге чыкса дип үзем белән алган «Этот непобедимый чеченец…» дигән китабымны тапшырдым. Китапны ул бер тын белән укып чыкты, әмма ниндидер тарафтан торып фикер әйтү аңа авыр булды, күрәсең. Мин көчләмәдем. Тормышыбыз хәрбиләргә генә хас булган анык тәртипкә ятты: мин көндез Массандра берләшмәсенең куян каны сыман куе кызыл «Кагор» шәрабын җитәрлек итеп әзерләп куям, кичке аштан соң каләмдәшем миңа керә һәм кич саен бер үк шигырьләрен укый:

Отменна гулкость свежего металла.
Внимая звону, русская земля
К Москве тянулась
И великой стала!..

Мин елыйм. Бу шигырьдән соң еламый мөмкин түгел. Каләмдәшем дәвам итә:

Совсем завял родной язык
От ваших инвестиций.
А как, басистый, был велик!
Какие брал границы!
Скажи по-русски —
— Баш на баш!
В расчет возьми и пену.
Без проволочек кружку пива дашь, —
Плачу двойную цену!..

Мин тагын елыйм. «Башка — баш» та урыс сүзе булып чыккач, хәтта үксисе килеп китә. Әмма озакка сузылмады безнең бу бәхет. Җитмеш яшеннән узган, беркатлы, эчкерсез, нәрсә әйтсәң, шуның белән килешә торган бу чын урыс абзые кайтып китеп, мине тагын да ятим итте...

Ә мин исә һәр сатин балакта язучы эзләвемне дәвам иттем. Менә беркөнне, үрдән күтәрелеп, диңгез буеннан төшке ашка кайтып киләм. Тамак туйдырып алганнан соң, Бакчасарай тарафларына — кырым татар кардәшләрем янына юлга чыгачакмын, Алла боерса. Кайчандыр сирәк субтропик агачлар гына үстерелгән булып, бүген ташландыклар күргәзмәсенә әйләнгән бакча сукмагыннан җитәкләшеп төшеп килүче ир белән хатынга тап булдым.

— Гафу итегез, без юлдан гына... Диңгез моннан еракмы? — дип сорады көнбагыш сабагыдай какча, озын зифа буйлы, аксыл кылган чәче учма булып маңгаена төшкән ир.

Мин аңлатып бирдем.

Алар рәхмәт әйтеп түбән таба юнәлде.

Мин артыма борылып карадым һәм нишләптер шундый фикергә килдем: бикәче дә үзенә охшап көнбагыш сабагыдай озын зифа буйлы, шулай ук таралып торган аксыл-соры чәчле икән, ире кебек ул да тоташ актан киенгән. Бу ханымның ире язучы булырга тиеш. «Ул, һичшиксез, язучы, — дидем мин үз-үземә. — Башкача булуы мөмкин түгел».

Һәм алар, көткәнемчә, кичке ашка килделәр. Ашханәдән чыкканда, уңайлы форсат табып, мин алар белән таныша да алдым.

— Әйе, язучы, — диде ир кеше. — Григорий Булах. Хатыным — Оля. Киевтан булабыз...

Мин дә үз исемемне һәм каян икәнлегемне әйткәч, ул мине күптәнге танышыдай кысып кочаклады.

— Үзегез белән берәр китабыгыз юкмы?

— Бар, — дидем мин, тартынып кына. — Мин үзем шагыйрь кеше. Әмма ул публицистика. Бик тә коры китап...

— Коры булса, чылатабыз аны, — диде Григорий, киная белән елмаеп. — Диңгездә су җитәрлек...

Мин аңа, кыяр-кыймас кына булса да, «Этот непобедимый чеченец...»ны бүләк иттем. Ни өчен дигәндә, украин әдәбияты һәм публицистикасының тамырлары бик тирәннән. Аннан китабым да бизәлешсез-нисез, ашык-пошык кына нәшер ителгән...

Икенче көнне иртәнге ашта Григорий булмады. Оля аны «чирләп тора» диде.

Төшке аште көтелмәгән хәл булды: ашханәнең шар ачык ишегеннән уң кулының учына кечкенә чүлмәк утырткан, сул кулы белән чүлмәктәге нәзек, озын буйлы чәчкәдәге көнбагыш тоткан Григорий килеп керә, тантаналы адымнар белән

бөтен залны, рәт араларын сары ялкында алтынлап, минем өстәл каршына килеп туктый һәм мондый кеше ышанмас адымны башына да китерә алмаган, киресенчә, мондый сирәк егетлекне юләрлек санарга әзер торган, чынында исә күзләре маңгайга менгән замандашларыбыз алдында аваз сала:

— Рәсәйнең изелгән халыкларының хокукларын яклаучы татар язучысы... атаклы «Этот непобедимый чеченец...» китабының авторына... украин халкының милли мирасы — көнбагыш чәчкәсе бүләк итәм!..

Һәм ул аны өстәлем янәшәсенә идәнгә утыртып та куя...

Минем, ятим үскән, кечелекле, беркайчан да мондый олылаулар күрмәгән татар баласының нинди хәлдә калуын аңлыйсыздыр. Ара-тирәдә сыек кына кул чабулар яңгырады, аны-моны аешмаган сатин балаклыларның, аларның азгынлыкка чакырып торган кыскадан да кыска шортиклар, ниндидер иблиси күкрәкчәләр кигән сөяркәләренең күтәрелгән кашыклары авыз тирәсендә катып калды. Урынымнан торып кулын кысканда, Григорий колагыма пышылдап та өлгерде:

— Шул кирәк аларга! — диде ул, сатин балаклыларга ымлап. — Ашың тәмле булсын, туганкай!..

Инде үз милкемә әйләнгән украин халкы мирасы — чүлмәктәге көнбагыш чәчкәсен күтәреп кайтканда, мин Григорий белән Оляны үземә кичке чәйгә чакырдым.

...Григорий Булах танылган язучы, публицист, дистәләгән киносценарийлар, фильмнар авторы гына түгел, Украинаның халык артисты, Украина дәүләт телевидениесенең «Туган тел» тапшыруларын алып баручы да икән, болардан гайре украин милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, моңа да өстәп, Леонид Кучманы Президент итеп сайлаулар чорында аның шәхси ышанычлысы да булган икән. Иң мөһиме — ул ифрат та ачык, тыйнак, эчкерсез һәм мавыктыргыч әңгәмәдәш иде. Җәмәгате Оля Булахова чыгышы белән словак кызы, француз теленнән тәрҗемәче, әтисе — славян әдәбиятлары буенча танылган белгеч, филология фәннәре докторы Неврли Микулаш белән бергә Братиславада яши. Аны урысча акценты өчен генә дә онытылып тыңларга мөмкин. Григорий белән һәр өч ай саен йә Киевта, йә Братиславада очрашып торалар. Оленька словак һәм украин балаларын даими рәвештә Киев, Братислава һәм Парижга сәяхәткә йөртә икән...

Чүлмәккә күчсә дә, туган туфрагыннан аерылмаган көнбагыш чәчкәсен өстәлебез каршына ук утырткач, без бүлмәдә дүртәү булып киттек. Мин бәллүр чәркәләргә үтә күренмәле кырым шәрабы койдым.

— Оляга һәм аңа кирәкми, — Григорий көлемсерәп көнбагышка ымлады. — Алар — хатын-кызлар, эчми...

Тәрәзә аша, югарыда, Кырым күгенең нәкъ шушы көнба-

гыш чәчкәседәй эре йолдызлары берсе икенчесенә алтын җеп сузып, галәм харитасын чигә иде... Григорий күкрәк кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды һәм, күзлеген киеп, укый башлады:

*«Минем сөекле кардәшем Айдар!

Синең легендар чечен милләте алып барган азатлык көрәшенең алгы сызыгыннан язылган «Этот непобедимый чеченец...» дигән утлы китабыңны укып чыктым. Рәсәй империясе аны гасырлар буе үз тарихын, югары әхлак канунnarын, азатлыгын олылаганы һәм шушы сыйфатларны үзендә мәңге саклый алганы өчен талады. Безнең гүзәл җиребез — планетабызның бөтен цивилизациясе каршында үрнәк булып тора алган бу буйсынмас милләтнең гайрәте һәм гаярьлеге алдында мин башымны иям.

Чечен милләтенең җаныя сыкравын бөек украин шагыйре Тарас Шевченко да тирәннән төшенгән иде. Ул үзенең шигырьләрендә баскынчының христианлык шигарен башка милләтләрнең диненә-иманына каршы басым чарасы итеп сайлап алып, бу очракта үзенең махсус урыс Алласын уйлап табып, Кафтау халыкларының «кыргыйлыгы» турында шулай ук үзе уйлап чыгарган уйдырмалар нигезендә башкаларга карата ясалма тәгълимат — мессианлык кулланып, аларны үз диненә күчереп, көчләп «цивилизациягә» куып кертү белән даими шөгыльләнүен беренчеләрдән булып Тарас Шевченко ачып салды. Алла — хакыйкать ул, ә хакыйкать христианмы, буддамы, мөселманмы — барлык милләтләр өчен дә берәү генә. Хакыйкатьнең милли күрсәткеч-сыйфатлары һәм төсләре булмый, чөнки ул — Вакыт һәм Аралык даирәсендә яшәгән бар нәрсәнең доминантасы.

Кансыз диктатор һәм җәлладларның, әйтик, бигрәк тә Алла төшенчәсен байрак итеп күтәреп, вайнах халкын кырырга хокуклары бармы соң? Йөзләгән халыкны изеп-талап, гасырлар дәвамында аларны тупас көч ярдәмендә басып алып, каннарындагы борынгыдан килгән нәсел тамгасын — изге яшәеш кодын харап итәргә хокуклары бармы? Бармы? Юк! Бу — бүгенге көн алдында гына түгел, барлык киләчәк буыннар алдында җинаять.

Дөнья җәмәгатьчелегенең, бигрәк тә Америка Кушма Штатлары, Европа илләренең, авызына су капкандай, тыныч торуы мине аеруча рәнҗетә, Айдар! Күз алдында милләт кадәр милләтне — тоташ бер этносны баштанаяк кыру бара, ә алар тыныч! «Рәсәйнең эчке эше», имеш. Чечен халкын кыру

---

* Урыс телендә язылган бу хат-мөрәҗәгать бернинди үзгәртү-кыскартусыз тәрҗемәдә бирелә. Кульязманың төп нөсхәсе минем архивта саклана. *(Автор.)*

«Рәсәйнең эчке эше» икән. Чөнки Америка монда үзенең «тынычлык урнаштыручы» легионнарын кертә алмый. Әгәр гарәп җирләрен басып алган Израильдә берәр гарәп бер генә яһүдне үтерсә дә, бу, Америка карашынча, бөтендөнья тынычлыгына куркыныч белән яный, ә менә монда, Рәсәйдә, теләсә нинди халыкны кырып салу — «Рәсәйнең эчке эше» икән... Шулай итеп, без таш мәгарә гыйфритләренә әйләндекмени? Әмма мәңге болай булмаячак, дөреслек җиңәчәк, Айдар!..

Мин гаделсезгә һәм бер сәбәпсез һәлак булган чечен һәм урыс балалары — Каф тауда һәм башка «кайнар нокталар»да башларын салган замандашларым хакына зар җылыйм. Шул ук вакытта мин үз халкы азатлыгы өчен гадел көрәштә оккупантлар танкларын яндырган ун-унике яшьлек чечен сабыйларының колак яфракларын кисеп алып, аларны аерым бер империаль горурлык белән кесәләрендә йөрткән урыс башкисәрләрен аңламыйм: аларның баш савытында ми дигән нәрсә бармы, әллә анда тиресме? Кешелек белән нәрсә булды?! Өченче меңьеллыкка аяк басканда, бүген, компьютер заманында, безнең белән нәрсә булды, Айдар туганкай?! Сөекле дустым, мин газап чигәм, мин үксим!!!

Мин бу хатымда синең «Этот непобедимый чеченец...» китабын укыганнан соң, сиңа багышлап «Көнбагыш чәчкәсе» дигән хикәя язачагымны хәбәр итәм. Анда минем шул китаптан соң күргән-кичергәннәрем сурәтләнәчәк. Шунысын да өстим: үз гомеремдә синең китабыңны укыганнан соң булган кебек газаплы төн кичергәнем юк иде. Миндә кинәттән Кырым августында, Ялтада, син һәм Чеченстан күргән газапларга теләктәшлек йөзеннән туган җирем — бәйсез Украинамның билгесе булган, Украинаның зәңгәр күге астында чәчкә атып, үзенең алтын таҗ элпәләре белән минем Ватанымның азат байрагын, төсен гәүдәләндергән көнбагыш чәчкәсен бүләк итәсем килде. Монда, Ялтада, Кара диңгез ярында, шактый җәфалар, тетрәнүләр аша эзләп табылган бу көнбагышым белән минем барлык украин өммәте исеменнән азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәшкән чечен һәм синең — үз язмышында искиткеч басымнар һәм кыерсытылулар кичергән туганым, татар өммәте вәкиле — татар Хэмингуэйы алдында баш иясем килде.

Көнбагыш чәчкәсенең таҗы кипкәч, син аның элпәләрен китабыңның бит араларына таратып чык. Элпәләр кипсә дә, алар беркайчан да дәүләтебез байрагының төсләрен җуймас. Алар — минем туган җирем һәм генерал Дудаевның сөекле Полтавасының аерылгысыз бер өлеше. Мин аны үле итеп түгел, украин көнбагышлары арасыннан елмайган тере пәйгамбәр итеп күрәм. Каһарманнар үлми!

Туган җиремнең бу тере авазы — көнбагышның ялкынлы элпәләре — милләтебезнең атаклы улы Тарас Шевчен-

коның мең елдан соң да искермәс шигъри кәлимәсен тагын бер кат искә төшерсен иде:

Көрәшегез, җиңегез,
Ярдәм итсен Аллаһ!
Сездә хаклык, шөһрәт,
Изге ихтыяр да!

*Т.Шевченко, «Кавказ»,*
*1848 елның көзе.*

1996 елның көзенә кергәндә — синең Григорий Булах. (Имза.)

Ялта шәһәре».

Бүлмәдә черки очкан тавыш та ишетелә иде.

Без Җир шарының төрле төбәкләрендә туып үскән, өч милләт анасының күкрәк сөтен имгән өч милләт баласы, сиздермичә, бер-беребездән оялган кыяфәттә, яшьләребезне сөрттек. Арабызда утырган көнбагыш чәчкәсе таҗының алтын үзәгеннән дә бер тамчы бал булып сытылган иде ул яшь. Бәллүрләребезне сүзсез генә чәкештереп, шәрабны йотып җибәрдек. Минемчә, ул гади су иде...

Григорий ике сәгать чамасы көнбагыш чәчкәсе эзләгән чакта үзе күргән-кичергән дастанны түкми-чәчми сөйләде. Кичәбезнең азагында украин дустыма багышлап шулай ук мин дә «Көнбагыш чәчкәсе» дигән хикәя язачагымны әйттем. Без, диңгез буена төшеп, милләтләребезне көтелмәгән җирләрдә тоташтырган, инде килеп минем гаиләмнең тулы хокуклы, хәтта, әйтер идем, гадәттән тыш тулы әгъзасына әйләнгән бу кешене уртабызга алып, сурәткә төшәргә һәм, әгәр заманалар мөмкинлек бирсә, һәркайсыбыз үзенчә тасвирлаган хикәяләребезне татар, кырым татар, украин, чечен, урыс телләренә тәрҗемә итеп, аерым китап рәвешендә чыгарырга сүз куештык. Әлбәттә, ниятебез тормышка ашса, хикәяләрдәге бер үк вакыйгалар агышында, тәртибендә һәм сурәтләнешендә ниндидер аерымлыклар да күзгә ташлануы мөмкин, чөнки, ни өчен дигәндә, без язучылар — рухият рәссамнары бит. Шул ук черки безелдәве бер язучы әсәрендә бөтенләй чагылыш тапмыйча, икенче язучы әсәрендә нигезгә әйләнүе мөмкин. Чынлап та, вакыйгаларны үзе кичергән язучының бер вакыйгага, аларны нибары ишеткән генә икенче бер язучының икенче вакыйгага күбрәк игътибар бирүе йә бөтенләй бирмәве, ниндидер дәрәҗәдә гомумиләштерүе табигый нәрсә ул. Шунысы шиксез: бу — хакыйкать. Ә хакыйкать, Григорий дустымның хатында әйтелгәнчә, бер генә була.

Хикәяләүгә керешкәндә, Ходай Тәгаләдән мин үземә тел ачкычлары, сәләт бирүен, ә олы йөрәкле укучыма түземлелек, зиһен яктылыгы һәм миһербан телим.

* * *

Калебендә кузгалган дәһшәтле ярсу-ачудан ул шартлар чиккә җиткән иде. Бер караганда, чын чәчмә әсәр — нәфис тукыма булудан ерак торган, гади, куелган мәсьәләне ашыга-ашыга, бер кинаясез ерып чыгарга тырышып язылган бу язмаларда көннең кайнар сүзе — публицистикага гына хас бер сихри сыйфат бар — һич көтмәгәндә ниндидер ләззәт белән йөрәкне өтеп ала, гүяки ул сине кытай энәсе белән дәвалый. Шушы кечкенә яшел тышлы китапчык аркасында Григорий, ниһаять, бер сәбәпсез үзен, аннан язучыны, аннан бөтен җәмгыятьне талый, ләгънәтли башлады...

Ул соңгы җөмләне кабаттан укыды һәм, ниндидер авыр җәзадан котылгандай, китапны япты, үзен биләп алган хисләрдән тизрәк арынырга теләгәндәй, китапны төнге шәмдәл янган өстәлчеккә ыргытты; китап яраланган кешедәй шапылдап идәнгә төште; үз илтифатсызлыгы өчен борчылып, янәшәсендә генә йоклап яткан хатынына уянмады микән дип борылып карады һәм, урыныннан бераз күтәрелә төшеп, китапны алып куйды, өстәлдәге шәмдәлне сүндереп, балконга чыкты.

Таң аткан икән... Тау түбәләрендә куерган алсу тукыма Ялта өстенә шуыша, һавадан җылы сөт, биләүдәге сабый исе аңкый. Игътибар итсәң, диңгездә дулкыннарның чайпалып ярны ялаган тавышлары ишетелә. Кайдадыр сыер мөгрәгәндәй итте. Әйе, чынлап та, сыер мөгри иде! Ялтада сыер асраучы бар, димәк! Асраучысы булгач, аның савучысы да бардыр әле? Григорийга моңсу да, күңелле дә булып китте. Ул, күкрәген тутырып, иртәнге һаваны сулады. Аннан әле балачактан күңелгә сеңгән газиз тәм — җылы сыер абзары, печән исләре белән кушылган шундый ук җылы сыер тизәге исләре борынны ярып керде. Күз алдына ерак Полтава якларындагы туган авылы, әнисенең кояш җилендә янган йөзе чагылып үтте... Кинәт ул очып китәрдәй булып тартылды һәм карашы белән алсу-зәңгәр киңлеккә төбәлеп, нәрсәдер эзли башлады. Әмма эзләгәне күренми иде. Кулындагы сәгатенә күз төшереп алды — дүрт сәгать кырык минут икән. Әле генә килгән фикер белән канатланган Григорий песи саклыгы белән кире бүлмәсенә керде, хатынына сиздермәскә тырышып киенде. Юынгыч янына үтеп, крандагы суны шарылдатмый гына ача төште, авызын ашык-пошык чайкап, бит алмаларына җиңелчә генә су тидереп алды да, сөртенеп, өстәл янына килде. Китап аны көтеп ята иде шикелле. Урындык аркасына эленеп торган кызгылт пакетка китапны тыкты, тавыштынсыз гына ишекне ябып, бүлмәдән чыкты. Иртәнге сигезләргә, Олясы уянганчы, әйләнеп кайтачак ул, Ходай кушса.

Григорий кызу адымнар белән гадәтенчә диңгез ягына —

Манагаров урамы буйлап аска түгел, бөтенләй кирегә — кипарислар рәтен сулда калдырып, гүяки тау кырлачына игәүләп салынган Пролетар урамыннан китте.

Көне буе кызган Кырым һавасы җир өстендә әле таңга кадәр дә суынып өлгермәгән иде. Әйтерсең кояш аңа төнозын җиләсләнергә ирек бирмәгән, киресенчә, Җир шарының теге ягыннан үрелеп булса да соскы-соскы утлы күмерләрен ыргытып, һавадагы кислородны мич кебек гөжгелдәтеп яндырып торган — бөркү инде, бөркү, бик тә бөркү; бу бөркүлек ташларга сеңгән, ихаталарга, хәтта кәүсәләренә энәләре белән кадалып, агачларга үрләгән тау мүгенең яшел тамчыны хәтерләткән яфракларына тир булып калыккан...

Григорий болай да ачык изүен ачкалап куйды. Йөрәге дөрс-дөрс тибә. Кан басымы күтәрелгән, күрәсең. Соңгы президент сайлаулары алдыннан алны-ялны белми, авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә чабып, ул кан басымы дигән яңа бер авыруга дучар булды — президент сайлаганга ике ел, ул гына кан басымы дигән йөгәнсез кырыкмышны тәртә арасына кертә алмый...

Диварларыннан ара-тирә төрле-төрле оҗмах җимешләре, йөзем тәлгәшләре асылынып төшкән, шулай да кеше кулын, хәстәрен тоеп та, йөзләрендә ярым кыргыйлык ярылып яткан үсемлекләр, агачлар — тоташтан бакча куелыгы аша нечкә, тузан көмешләгән үрмәкүч җебе сыман сузылган тар урамнан барганда, ниндидер ялгызлык, ташландыклык, үлем тынлыгы тойды ул. Ихаталардан чыгып, койма буйларына, алай гына дисезме, урам күзенә, урам йөзенә сибелгән, чәчелгән, түгелгән чүп-чардан гаҗиз булды. Ялтада бит, Ялтада!.. Төрле заманнарда, төрле чимал, төрле зәвык-мөмкинлектән чыгып салынган, соңыннан һәркемнең үз белдеге нигезендә дөньяның дүрт тарафыннан тәртипсез, сызымсыз-плансыз кораштырылган верандалар, өй аллары, өй артлары, исәпсез-сансыз төкәтмә-бөтәйтмәләр белән уратып алынган таш, кирпеч, агач йортлар үзләренең бер катлы һәм ике катлы матурлыклары һәм гариплекләре белән тере тарих иде, күрәсең — Григорий онытылып укып барды аларны. Монысы исән калган кыпчак-татар, монысы — юнан-грек, монысы тегеләренең өсләренә менеп кунаклаган славян катламы булса кирәк. Җиргә сеңешкән һәр тәрәзә, һәр капка канаты, һәр таш баласы, һәр ком онычыннан бердәмлек, тәртип, өмет — уртак омтылыш, мәдәни төрлелек эзләде ул. Урамда гына түгел, ихата эчләрендә дә адәм заты бөтенләй диярлек күренмәсә дә, үз биләмәләре чикләрендә аяк тавышы җанлану белән, һәр йорт маэмайлар ләңе белән яңара иде. Их, бу манзараны һәм ләңнәрне тасмага төшереп, яздыртып алырга иде! Яңа фильм өчен бернинди өстәмә мезансцена да, аһәңнәр дә кирәкми!..

Бурзайларның ике тарафтан да куера барган күмәк гаммасы аша ул муенын сындырырдай булып башын әле уң, әле сул тарафка борып каранды, этләрне үзе котыртырга теләгәндәй, коймаларга якын килде, кайда атланып, кайда үрелеп, кайда аяк астына ташлар түшәп, дистәләрчә ихатаның эчен тикшерде, шулай да эзләгәне күзгә чалынмады. «Кызык, — диде ул, үзенә генә мәгънәле нәтиҗә ясап. — Бик тә кызык булмакчы әле бу».

Тау юлыннан үзен тыя-тыя төшеп барганда, бар тирәюньне тузан һәм сасы ис белән сугарып, чүп-чар җыю машинасы үтеп китте. «Чүп-чар җыю мизгеле — гомереңнең тагын бер тәүлеген яшәдең дигән сүз. Бигрәк тә бездә — элеккеге СССРда...» Бу фикердән аңына килгәндә, ул артына борылып карады — каршыдагы тау кырлачының нәкъ түбәсендә диярлек соры шәм кебек сөрәеп, язучыларның ундүрт катлы бинасы күренә. Шактый гына китеп өлгергән икән ләбаса! Ерак сәяхәткә җыенгандай, ул үзенең ашыкпошык кына киелгән өс-башын тикшереп алды — туфли шнурлары бәйләнмәгән дә икән. Юлдан читкәрәк чыгып, ualучан ташка аякларын терәде һәм аерым бер ләззәт белән шәлберәп килгән шнурларны бәйләде.

Таута күтәрелгән саен, тын алуы тагын да авырлашты. Җитмәсә, юлның бу өлешенә әллә кичә генә мул итеп асфальт, дөресрәге, асфальт ишарәте булган сумала түшәгәннәр — табаннарын ябыштыра-ябыштыра атлаган саен, тирәякны гүя мылтыктан аткандай шартлата-шартлата баруын дәвам итте. Моның бер чиге булырга тиеш иде. Сумалага батып барган кеше кебек, ул тагын да артына борылып карады — каршы яктагы тау түбәсендә масаеп утырган телеантенна манарасын күреп, үзенең Ялта чигенә чыгып баруын аңлады. «Дөрес бармыйм, күрәсең, — дип уйлады ул. — Миңа кемгә булса да керергә, сорашырга кирәк. Югыйсә көнне бушка үткәрергә һәм Олясыннан шелтә дә алырга мөмкин».

Ул, олпат өрек агачы ихатасыннан чыгып, ярты урамны күләгәләгән йорт каршында кискен сулга борылды. Әмма биек койма аша йорт та, ихата эче дә күренми иде. «Нәрсә булса да булыр». Капка тоткасын сак кына борды — келә җиңел генә, кем әйтмешли, көлә-көлә ачылды, капкадан керү белән, багана сыман катып калды: бакчаның аргы башында, ялт итеп тазартылган җиз самавыр кебек елкылдап, иртәнге кояшта кайнап һәм ялкынланып, чәчкәдәге көнбагыш утыра!.. И-и, исәнме, җаныкаем!.. Менә син моннан соң Ходай Тәгалә юк дип әйтеп кара инде!

Куанычыннан башы әйләнеп китеп күзен йомды Григорий. Кинәт ниндидер нәмәстәкәйнең лачкылдатып ялавыннан айнып, кулын тартып алды — яңа таныш белән очрашу шатлы-

гын кая куярга белмәгән бозау кадәр зур карт эт, әйтерсең ничә ел адәм заты күрми, кешелекне тәмам сагынган эт, тирәсендә сырпаланып, шыңшып, шартына килсен дигәндәй, хәлсез генә өргәләштереп, аны сәламли һәм йортка таба өстери иде... Көнбагыштан күзләрен алалмыйча, ул эт артыннан тупсага күтәрелде, инде эт тә тырмап-тырмап, ачучы булмагач, ишекне үзе ачты. Бөтен дөньяга даны таралган курорт шәһәрендә ниндидер могҗиза белән сакланып калган урыс миче каршындагы өстәлгә арты белән сеңеп, тыныч кына тамак туйдыруын дәвам иткән адәм заты гүяки аның керүен ишетмәде дә, сизмәде дә...

— Исәнмесез...

Адәм заты ике кулы белән тотып нәрсәдер кимерә иде. Эт аның балагыннан тартты. Ул кулларын өстәлгә куйган килеш карашын эткә юнәлтте һәм, берни булмагандай, яңадан табагына иелде...

— Исәнмесез! — дип кабатлады Григорий кычкырыбрак.

Ул, башын күтәреп, тынлыкка колак салды. Аннан ашыкмыйча гына Григорийга таба борылды. Шактый изрәгән карт бу лабаса. «Тере Евстигнеев! Профессор Знаменский!» Көнгә чыкса, ул бөек актерлар йә алар уйнаган образларга охшаган замандашларын эзләп мәш килә. Әйе, карт, ниһаять, ишек катында ачык изүле ак күлмәк, җиңел ак чалбардагы, озын буйлы ир-егетне күреп елмайды, урыныннан күтәреләм дигәндә генә уңайсыз хәрәкәт ясады, күрәсең, борын очындагы күзлеге лап итеп ашына төште һәм ул, кинәт сукыраеп калып, кулы белән изәде:

— Кил... Монда кил!..

— Исәнмесез! — Җитез адымнар белән килеп, Григорий аның кулларын тартып алып диярлек күреште. — Исәнмесез! — Һаман да ашта яткан күзлекне чыгарып, юып кидерим дип табакка үрелгәч, карт, «үзем!» дип, урыннан күтәрелде, аны сүзсез-нисез генә почмактагы юынгычта чайкатып итәгенә сөртте, яңадан борын очына элде, кунакны баштанаяк сөзеп чыкты, утырырга тәкъдим итеп, үзе дә урындыкка сеңде, аннан оч-очлары чәнечкеле тимерчыбыкның чәнечкеләре кебек чәбәләнеп беткән кашлары астыннан Григорийга текәлеп:

— Александр Игнатьич булырмын. Ну-с, ни йомыш?

— Беләсезме, Александр Игнатьич... Мин... язучы... — Григорий үзе белән таныштырганда, сүзен каян башлап китәргә белмәгәндәй, «язучы» тәгъбирендә таптанып торды. — Украин язучысымын... Язучыларның Ялтадагы иҗат йортында ял итәм... Анда минем белән Татарстаннан, дөресрәге... КамАЗны ишеткәнегез бардыр!.. Чаллы шәһәреннән бер татар шагыйре дә бар...

— Татарстаннан? — Карт аны шундук бүлдерде. — Шагыйрь? Беләм мин татарларны. Яхшы халык. Батыр, эшчән,

әйтер идем, законопослушный, покладистый халык. Донбасс шахталарында күп күрдем мин татарны. Авылларыннан паспорт-метрикасыз да чыгып качкан унөч-ундүрт яшьлек татарчонокларны десятниклар рәткә тезеп кенә эшкә алалар иде, әйе! Култык асларына җон чыга башласа — марш забойга, син — шахтер!..

— Әнә шул татар шагыйре...

— Мин аларның җырларын да беләм! — Иртәнге сәгатьтә хәлен белергә кергән юньле кеше белән очрашу куанычыннан картның теле чишелде. Ул ике кулын күтәрде һәм бармакларын шартлатып такмаклый башлады:

Ах, заняшим, заникаем,
Сюйгян калам Рум-кала.
Тапкан малим, сюйгян ярим
Бар да ятларга кала!..

— Якши, бик якши, Александр Игнатьич! — дип куәтләде картны Григорий татарчалатып һәм сөйләшүне тиешле ызанга кертергә ашыкты. — Менә шул шагыйрь элеккеге СССР, бөтен Рәсәй халыкларыннан бердәнбер әдип, чеченнарның азатлык көрәше турында бик шәп китап язган... Менә ул!.. — Григорий, капчыгыннан яшел китапны чыгарып, картка бирде. Җыерчыклары әле генә тигезләнә төшкән, битләре алсуланып, хәтта чәбәләнгән каш чәнечкеләре дә чишелеп киткән Александр Игнатьичның йөзе кинәт караңгыланды, ул нәрсәдер әйтергә азапланды, әмма хәленнән килмәде булса кирәк, ниһаять, авызыннан ике генә сүз кысып чыгарды:

— Миңа... калдыр...

Григорийга уңайсыз булып китте. Ул мондый борылышны көтмәгән иде. Автор белән киңәшмичә, әлеге Ялтада бердәнбер булган һәм юлга үзе белән алып чыккан китапны ул, хәтта бик теләсә дә, калдыра алмый иде.

— Насыйп итсә, Александр Игнатьич, без шагыйрьнең үзе белән бергә килербез, — диде Григорий. — Ул аны сиңа язып та бирер... Менә мин шул шагыйрьгә рәхмәт йөзеннән туган Украинабызның сөекле шигарен — көнбагыш чәчкәсен... — Аның тамагына ниндидер кылчык кадалгандай булды һәм ул, үзе дә сизмәстән, украинчага күчте. — Соняшник родимый... Що я йому хочу — тильки одарити соняшником як символом ридна мами Украін... Це дуже важливо, розуміьте?*

— Көнбагыш чәчкәсе дисеңме, кайнеш?! — Картның йөзенә яңадан алсулык йөгерде. — Тапкансың эзләр нәрсә,

* Бертуган көнбагышымны... Туган анам Украина билгесе итеп, минем аңа көнбагыш чәчкәсе бүләк итәсем килә... Бу никадәр мөһим, аңлыйсызмы? *(укр.)*

кайнеш! Әнә — бакчада берьялгызы сөрәеп утыра... Әллә кайлардан килгән шагыйрьгә бүләк булсын! Әйдә, хәзер үк чыгабыз да кисәбез дә алабыз!..

Мәсьәләнең болай җиңел генә хәл ителүенә ышанып та бетмәгән Григорий картны шундый итеп кысып кочаклады, аның какча тәне майламаган арба кебек шыгырдап куйды.

— Рәхмәт сезгә, Александр Игнатьич! Дякую вам, дякую!* Әлбәттә, бушка түгел! — Ул кулын кесәсенә тыкты.

— И-их, барысын да боздың, кайнеш!.. Шундый матур гына барганда... Соң син миңа көнбагыш чәчкәсе сатып алырга гына кердеңмени? Соң син минем, карт кешенең, хәлен дә белергә кермәдеңмени? — Ул мышкылдап куйды. — Көнбагыш өчен акчаны мин сиңа үзем түлим! — Александр Игнатьич чалбар кесәсенә кулын тыга башлады. — Юләр!..

— Юк, юк, Александр Игнатьич! Гафу итегез... — Григорий аның кесә авызына керә башлаган кулын тоткарлады. — Сезнең кәефегезне һич кенә дә кырырга теләмәгән идем...

— Юләр!

Карт, күңеле күтәрелеп, шаркылдап көлеп җибәрде. Григорий исә көлә алмый иде. Көн яктылыгы почмакларына сипләнеп өлгермәгән, баш очында бердәнбер электр лампасы янып маташкан ярым караңгы бүлмәдәге бу ялгызак карт алдында Григорий үзен ни өчендер гаепле тоя иде. Ул аның гаилә хәлләрен сорашырга базмады. Кем белә, көтмәгәндә генә кешенең йөрәген яралар?

— Ә нигә мондый сарай кебек иркен йортыгызга ял итүчеләрне кертмисез? — диде ул, малайларча беркатлылык белән сөйләшүне икенче яссылыкка күчерергә тырышып. — Быел курортчылар куак төбе саен бит!

— Кандала, кайнеш, кандала! — Александр Игнатьич тирән итеп уфырды. — Бер ел булыр инде менә, кызыл урда басты... Иза чигәм. Миче гүя кандала инкубаторы. Хет иприт газы сиптер. Сүтеп атар идең, хәлдән килми... Чәй дә тәкъдим итмәдем, ә, кайнеш?

— Юк, юк, Александр Игнатьич! Әгәр мөмкин булса, шул көнбагыш чәчкәсен генә алыр идем дә китәр идем. Югыйсә хатыныма да әйтми киттем...

— Бай кешеләрнең хатыннары да бар... Теге шагыйрь белән килгәндә, хатыныңны да иярт. Әнә чияләрне, алычаларны җыяр идегез, ичмасам... — Карт урыныннан күтәрелә башлады. — Син аны, көнбагышны, ничегрәк алып китмәкче буласың соң?

— Ул миңа төбе-тамыры белән кирәк булыр...

---

* Рәхмәт сезгә! *(укр.)*

— Төбе-тамыры белән? Туфрагы белән, димәк? Савытың бармы соң?

— Юк.

— Әнә кара шунда... — Карт мич арасына күрсәтте. Григорийга озак эзләргә туры килмәде. Өй келәтенә әйләнгән бу аралыкта бераз актарынганнан соң, ул кайчандыр гөл савыты булган кызгылт чүлмәкне тартып чыгарды.

— Таптым, Александр Игнатьич! Төсен кара син аның, төсен... Үтергән дә каплаган!

— Тапсаң, ярар. — Карт төсләрне танып маташмады. — Чыгабыз алайса...

Григорий бары кояш яктысында гына аның куе чал чәчле, үзеннән зуррак, як-ягыннан кызыл кант төшкән әфисәр чалбары, иңендә погон эзләре сакланган кительдә, кунычы киселгән киез итекләрдә икәнен абайлап алды. «Әйе, торганы белән Евстигнеев. Әзер Хоттабыч — төшер дә ал!»

— Сезнең монда никадәр иркен һәм рәхәт!

— Әйе, кайнеш, рәхәт, куярга урын гына юк...

Сиксән чамасына чыгып барса да, әле шактый нык, адымнарын аркан ишкән кебек бөтереп атлаган Александр Игнатьичны үзе белән алып китәсе килде Григорийның. Үз гомерендә, сәхнәдән торып, аз уйнадымы мондый сөекле картларны? Әллә чынлап та «уйнады» гына микән? Ә менә үзе дә шундый хәлләрдә торып калса, «уйный» алыр иде микән? Егетләрчә җитезлек белән кулына көрәк эләктереп алып, аның көмеш йөзен кояшта ялтлата-ялтлата көнбагыш суярга китеп барган Александр Игнатьич кебек яшәргә генә кирәк булган, шайтан алгыры! Халык артисты, имеш. Әле сорашып та китсәң, ниләр генә күрмәгәндер ул...

Үзе кебек картайган, өрүнең нәрсә икәнен дә оныткан бурзай хуҗасы тирәсендә сырпаланды. Менә алар таҗының бер генә элпәсе дә имгәнмәгән, меңләгән сөт чүлмәкләре эчендә озакламый бала теше кебек ап-ак төшләр-җимешәннәр өлгерәчәк көнбагыш янына барып җиттеләр. Таҗны бал кортлары биләп алган иде. Григорийга кояш бу мизгелдә күктә түгел, нәкъ менә шушы көнбагыш җәясенә кереп ялкынлангандай тоелды. Ул көн челләсендә янган күк гөмбәзенә карады. Аксыл сазлык булып эрегән кайнар рәшәдә кояш күренми иде...

— Менә шулай... Читтәнрәк алыйк... — Карт көрәкнең пычагы белән көнбагыш тирәсен сызгандай итте. — Тамырлары киселмәсен...

— Александр Игнатьич, әйтегез әле, сез нигә миңа кайнеш дисез? — Бу бөтенләй урынсыз соравы белән Григорий гүяки инде эзләп табылган көнбагышның туган җирендәге гомерен бер секундка булса да озайтасы, үзен җәллад вази-

фасыннан азат итәсе килә иде. — Әллә үзегездән яшьрәк һәр ир кешегә шулай дисезме? Минем андыйларны да очратканым бар...

— Юк, сине генә шулай атыйм мин, кайнеш... Ә син бит миңа турыдан-туры кайнеш кеше... — Картның тавышы өзлекте, ул күзләрен ял иттерергә теләгәндәй, карашын каядыр Массандра якларына төбәде. — Минем җәмәгатем... Наталья Петровна... Минем сөекле Наталкам да украин кызы иде... Полтавщинадан иде...

Авызын ачып катып калган Григорий аңа бик мескен күренде бугай.

— Син нәрсә, Лысенконың «Наталка-Полтавка» операсын да белмисең мәллә?!

— Я також з Полтавщіни! — дип кычкырып җибәрде Григорий. — То ви Полтавщіну знаэтэ?*

— Беләм генәме әле! Һәр җәйдә кайта идек. Ә мин синең сөйләшүеңнән үк шул як егете икәнлегеңне аңладым, кайнеш!.. Авыр туфраккайлары җиңел булсын мәрхүмәкәемнең. Әйбәт яшәдек. Алты бала тапты. Икесе исән иде... — Карт, тыела алмый, яшьләрен сөртте. — Кече кызым, Светлана, гаиләсе-ние белән былтыр хәрабәләр астында калды. Әйе, Сахалинда, Нефтегорскида... Олысы, улым, нәкъ синең шикелле, Григорий атлы иде, полковник... Быел гыйнвар аенда гына чечен фронтында корбан булды... Җирләргә гәүдәсен дә бирмәделәр...

— Үзебезнекеләрме? — дип сорады Григорий, федералларны күз уңында тотып. — Үзебезнекеләрме?

— Нинди үзебезнекеләр булсын ди, дошманнар алар! Хезмәттәше кайтып сөйләде. Минем Гришкам, артиллерист, чечен авылын утка тотудан баш тарткан һәм шуның өчен аркасына кургашын алган. Менә сиңа үзебезнекеләр... Мондый җанкыярларга каршы көрәшкән чеченнәр була миңа үзебезнекеләр, кайнеш... — Башын көрәк сабына салган карт инде сулкылдап елый иде. Кинәт ул башын күтәрде, кояшта пыяла кыйпылчыгы кебек тагын да зәңгәрләнә төшкән күзләре белән Григорийга укталды. — Нигә, шулай түгелмени?!

— Тынычланыгыз, Александр Игнатьич... Су кирәкмиме?

— Нинди су ди тагы, кайнеш?! Ялкын бир син миңа, менә шушы көнбагыштан көрәгеңә салып ал да ялкын бир!.. Наталкам быел яз, шушы кайгыларны күтәрә алмыйча, мине ташлап китте... — Карт яшьле күзләре белән тирә-якка ымлады. — Бар нәрсәдә аның төсе... Бөтен нәрсә аның кулы белән утыртылган. Их! Бакчасын чүп баскан дип уйлый күрмә, аның төсе булганнары, аны күреп белгәннәре өчен

---

*Мин дә Полтавщинадан бит! Сез Полтавщинаны беләсез? *(укр.)*

утамыйм мин ул чүпләрне... Менә бу ялгыз көнбагышны да әллә ул утырткан, әллә аның кесәсеннән төшеп калган орлыктан үскән бу ятимә... — Александр Игнатьич бер омтылыш белән көрәген көнбагыш төбенә батырды.

— Юк! — Григорий, киселгән тамыр — кан юлын канатырга теләмәгәндәй, яшен тизлеге белән көрәкне җирдән тартып чыгарды. — Юк, Александр Игнатьич, минем Наталья Петровнадан калган бердәнбер көнбагышны суярга хакым юк!.. — Аның йөрәген нәрсәдер чәнчеп алды, түш кесәсеннән сиздерми генә валидол төймәсе чыгарып йотып җибәрде. — Бу көнбагышның орлыкларыннан киләсе елга күбрәк итеп чәчәрсез. Ә мин, насыйп итсә, сезгә тагын да килермен, җизни!..

— Менә шулай диген, бал авыз! Җизни диген! Рәхәт булып китте... Юк, син ал аны, кайнеш... Миңа инде хәзер тегендә генә китәргә калды...

— Юк, Александр Игнатьич, булдыра алмыйм. Намусым җитми.

— Соң, үзеңә алмыйсың бит син аны, Алла бәндәсе! Татар шагыйренә. Яхшы халык ул татарлар — эшчән, законопослушный, покладистый... Әгәр дә син бу көнбагышны алмасаң, мин аның төбендә ачлык игълан итәм дә куям. Өйгә дә кермим. Ал, диләр сиңа!.. — Ул көрәген тагын да көнбагыш төбенә батырды.

— Юк, дигәч юк, Александр Игнатьич. Ялта зур бит. Табармын әле. Ә менә бу чүлмәкне, рөхсәт итсәң, үзем белән алыр идем...

— Чүлмәк... Мин сиңа чүлмәкне генә түгел, бөтен йортымны-җиремне бирәм. Бар, хатыныңны, шагыйреңне алып кил дә, шушында гына яшәгез. Мине җирләр кешеләрем дә булыр, ичмасам...

Григорийга хәзер йә шушында ятып үләргә, йә, картны ияртеп, бөтен Җир шары буйлап көнбагыш чәчкәсе эзләп чыгарга гына калган иде. Александр Игнатьичны ничек кенә ташлап китәсе килмәсә дә, ул үзен көчләп диярлек кузгалырга булды. Ул аны тагын бер кат кысып кочаклады, кырынмаган сакал төкләреннән сыйпады:

— Хуш, җизни!.. Күрешергә язсын!..

Чүлмәк салынган пакетын җирдән күтәрде, кисәк кенә борылды һәм капкадан чыкты. Арттан Александр Игнатьичның йөрәк ярып кычкырган тавышы ишетелде:

— Тапмасаң... ки-и-ил! Тагын ки-и-ил!.. Кө-тә-ә-әм!..

Григорий җай, салмак адымнар белән түбәнгә, үзәк урамга таба төшә башлады. Троллейбуска утырып, шәһәрнең теге башына — тагын да шәхси хуҗалыклар ягына чыгарга кирәк...

«Без, язучылар, мондый кешеләрне, гадәттә, «гади кеше»

дип кенә җибәрәбез инде, — дип уйлады Григорий. — Нинди була соң ул гади кеше? Иң мөһиме, чын кешеме — шәхесме ул? Чын кеше беркайчан да гади булмый, даһи гына була. Минә Александр Игнатьич, ичмасам, чын кеше. Шәхес. Кара син аны, ничегрәк фикер йөртә «үзебезнекеләр» турында, ә? Һәр милләтнең ашы тозлылыгы ул Игнатьичлар. Менә ул, язучы һәм, шартына туры китереп әйткәндә, халык артисты Григорий Булах, сәнгатькә хезмәт итүнең бурычын кеше гомерен озайтуда күрде. Сәхнәгә чыкканда, ул гүяки кесәсенә кеше гомерен озайта торган детектор салып чыга иде. Тамашачы залын шул детектор нуры белән нурландыра, нурны исә кем күпме тели, шул күләмдә сеңдерә — сәнгатьтән ләззәт алган кеше гомерен озайта, ала алмаганы, киресенчә — кыскарта. Димәк, аларның беренчесе — шәхес, икенчесе кеше генә... Атаклы француз табибы, фикер иясе Жюльен Ламетри да гомере буе кеше гомерен озайтучы магнит кыры уйлап табу турында хыялланган. Әйе, артыгы белән нурландыр син дөньяны, кешеләр арасында шәхесләр күбәйсен! Алар бит бик аз. Шуңа күрә дә шәхесләр кешеләргә караганда кыскарак гомерле. Алар аз булганга шулай бит ул. Үзенә охшаган шәхес таба алмый өзелә бит алар!.. Кешенең гомер буе кешелек корты булып яшәп, бер мизгелдә шәхескә әверелеп, шушы мизгелнең гомеренең соңгы мизгеле булуы мөмкинме? Әлбәттә, мөмкин! Ничек кенә әле! Игнатьичның полковник улының «сәер» үлеме аның шәхескә әверелү корбаны булуын расламыймы?»

Уйларыннан изелеп, тукталышка җиткәнен сизми дә калган. Беренче маршрутта вокзалга барып, эзләгәне күзгә чалынмаса, Ялта — Симферополь юлыннан авылларга чыгарга карар итте ул.

Троллейбус күренми иде әле. Ике пальма арасына йөз елда да аумас-черемәслек итеп корылган тимер витринага күзе төште аның. «Правда», «Советская Россия», «Труд» кебек гәзитләрнең исемнәре генә сакланган иде анда. Гәзитләрне көннекен-көнгә ябыштырып барырга шәһәр хакимиятенең акчасы юк иде, күрәсең. Витринада шулай да ниндидер нәмәстәкәй күзгә чалынды,— түш кесәсеннән күзлеген чыгарып, ул шуны караштыра башлады. Кара коңгыз сыман свастика чәпәлгән иде баш өлешенә. Ниндидер «Русский взгляд» дигән гәзит ишарәте булып чыкты ул. «Путешествие из Москвы в Крым» дигән мәкаләгә күзе төште аның, күзе дә төште, һәм, үз күзләренә үзе ышанмагандай, йотлыгып укый да башлады. Мәкалә аның турында иде!.. Әгәр ул, алтмыш яшенә чыгып барганда, Кырымга килмәгән һәм шушы хөрәсән гәзиткә юлыкмаган булса, үзенең кем икәнлеген белмичә үлеп тә киткән булыр иде, бәлки! «У украинцев

глаза шакалиные, ржавые, выпуклые и на выкате, головы как у неандертальцев... У них главная задача — истребление русского народа... На всех митингах украинцы, обры и жиды требуют уничтожения русичей... Русские имеют полное право расстрела украинцев и полного изгнания их с Киевской Руси... В Крыму поют и пляшут одни крымские татары и украинцы; почему запрещено петь и плясать русским?!»*

Григорий кул аркасы белән маңгай тирен сөртте. Мавыгып китеп, троллейбусны да үткәреп җибәргән икән ул. Кызык бит! Чеченстаннан соң сугышны тагын да кайда чыгарырга белмәгән Яков Сусленский дигән бер бәндә «Обращение русскому народу» дигән язмасында барлык халыкларның тетмәсен тетә иде: «...украинцы как микробы, мало того, они вечно грязные и от них вечно пахнет. В поведении их сказывается то, что называется быдлостью и неполноценностью. Это — нация-паразит... Казахи — крохоборы, трусы и неполноценны... Невежество впиталось в мясо и кости этого народа вместе с материнским молоком и выело у них человечность. Чем казаха, лучше откармливать свинью, у нее хоть прибывает жиру...»

Григорийның күзләре кызарып әрни башлады. «В ходе воссоединения с Россией крымские татары никакой колонизации не испытывали, — дип укыды ул өченче мәкаләдә. — Татары показали свою неполноценность, неспособность трудиться и облагородить исконно Русский Крым... Депортация крымских татар Сталиным была исторически правильным шагом...»

Ул өшүдән тартышып куйды. Ары таба укырга хәле дә калмады, ихтыяры да җитмәде. Таныш урында томанда адашкан кеше кебек иләс-миләсләнеп, күзенә ак-кара күренмәс хәлдә тукталышка кире килде һәм әле генә тормозлары белән шыелдап, тыелып маташкан троллейбусның ачык ишегенә сикерде. Сәгать тугызынчы яртыны күрсәтә иде. Олясы уянгандыр, аны югалтып ут йотадыр, мескенкәй. Ичмасам, язып та калдырмады бит. Шәһәр кадәр шәһәрдә чәүкә кадәр көнбагыш чәчкәсе эзләп тапма әле син! Хәер, ул аны эзләп тирә-ягына каранмады да. Гүя биредәге барлык көнбагышлар дегет белән сыланган иде. Тәрәзәләрдә чагылып киткән истәлекле таштакталар, Леся Украинка, Антон Чехов, Максим Горький һәйкәлләре дә дегеттә йөзә кебек. Ачык тәрәзәләрдән керердәй булып артка шуышкан магнолияләр, кипарислар, пальмалар, төрле-төрле, ачулы һәм ачусыз агачлар, агулы һәм агусыз җимешләр, эт һәм бүре җиләкләре,

* Ышандыру һәм дәлиллек көчен саклау ниятендә өзекләр тәрҗемәдә түгел, оригиналда бирелде. *(Автор.)*

салонда утырып, басып, тупсада чак кына эләгеп, эшкә, базарга баручы замандашлары — барысы-барысы аңа хәзер ниндидер тутыккан карашлы шакал күзләре белән карагандай тоелды. Григорий хәзер, бу гәзитне укыганнан соң, үзе дә милләтче иде...

Халык дәррәү кубарылып чыга башлады — вокзалга килеп тә җиткәннәр икән.

Рәхмәт төшкере, Ялта–Симферополь троллейбусын йөртүче абзыкай кузгалырга торуына карамастан, ишеген яңадан ачып, Григорийны салонга үткәрде һәм троллейбус кузгалып та китте. Исәпсез-сансыз бормаларда янтаеп, үрләрдә уфылдап һәм көчәнеп, Массандра тауларына күтәрелгәч тә, уңнан диңгезнең хыялый зәңгәр манзарасы ачылды. Тәрәзәләрдән кергән тыгыз җил моңа кадәр йорттан йортка чабып, үзәннең бар кайнарын, бар бөркүен үз даирәсенә туплаган, шуңа да кишмиш-күрәгә сыман пешенгән Григорийга рәхәтлек алып килде. Куе тау карамасы, карагачлар күләгәсеннән троллейбус яңадан ачыклыкка чыкты. Кояш аңа гүяки бүген беренче мәртәбә замандашларының йөзен яктыртты: соңга кала күрмим дигәндәй, юлдашларының йокымсыраган, битараф йөзләреннән, ачык һәм ябык күзләреннән шәхес, илаһи чалымнар эзләде, эзләде, эзләде — таба алмады; салонда гүяки бихисап кешеләр түгел, ә шул кешеләрне изеп гыйфриткә әйләнгән ниндидер әчеле-төчеле оеткының бердәнбер һәм бар нәрсәгә битараф чырае йөзә иде... Юк, юк, ул шыттыра, арттыра бугай. Заманга һәм замандашларга карата бу кадәр катгый, бу кадәр кансыз булырга ярамый. Кинәттән бу гыйфритнең йөзе мөлаем Александр Игнатьич булып елмайды. Әйе, Григорий белә һәм моңа инана — кыяфәтләренә вакытсыз җыерчыклар чыгуга, вакытсыз картаюга, юк-бар мәшәкатьләр аркасында бер-беренә олпат түземлелек, теләктәшлекләрен югалтуларына карамастан, алар тамырдан-тумыштан барысы да матур һәм камил кешеләр булганнар... Аларны уятырга, уйлатырга, шәхесләр генә ясарга кирәк. Нәрсә уйлыйлар алар бу мизгелдә? Уйлыйлармы, гомумән? Уйламасалар, нигә уйламыйлар? Әйтик, әгәр дә хәзер Григорий, рәтләр арасыннан үтеп: «Сезгә кияргә кием, ашарга ризык, аңлашу өчен Ходай биргән телегез, басып торырга җирегез, суларга һавагыз, эчәргә чишмә суларыгыз кирәкме?» — дип сораса һәм алар, аптырап, бертавыштан «Әлбәттә, кирәк!» дисәләр, димәк, алар милләтче булып чыга? Ә менә Григорий, шуларны басып алган һәм пирамида очына менеп атланган фиргавен, үзен аларның бердәнбер хуҗасы, өлкән агасы, атасы дип инандырган Григорий дәдәй «Юк, басып торган җирегез, сулаган һавагыз, эчкән мәгъдән суларыгыз, аңлашкан-сөйләшкән телегез — болар барысы

да минеке!» дисә, ул да милләтче булып чыга түгелме? Нигә, басып алучыларның үзен якларга, милләтче булырга хокукы юкмыни? Аңа бит мондый «миссия» күктән төшкән, ул — пәйгамбәр, Ходай Тәгаләнең үзе белән галәми элемтәдә тора!.. Ул авыз чите белән генә елмаеп куйды: көчлеләр көчсезләрне алар турында кайгыртучанлык күрсәтеп басып ала. Җирне, суны, һаваны үз хуҗаларына сатып бирә башлый. Кол баш күтәрсә, «бандит, сепаратист, басып алучы» дигән атама-ләкапләр тага һәм үтерә-кыра башлый. «Тигезлек, туганлык» хакына дип, дөньяларның астын өскә китергән миллион инкыйлаблардан кеше нәрсә алды соң ул чакта? XXI гасырга аяк басарга җыенган адәм баласын кеше дип таный алабызмы?

Кинәт астарак, тау-таш арасында сөрәеп күтәрелгән ниндидер төзелеш, яшелле-сарылы бакча ишарәтләре шәйләнде аның күзенә. Григорий төшеп калырга булды.

Сары кәрәз булып изрәгән Кырым кояшының кызыл тузанында изрәгән сукмактан ике-өч адым атлауга, ул үзе кебек озын буйлы кара әрем, күке җитене, ниндидер кызыл борчаклы сәер үсемлекләр лабылыгына чумды. Катлам-катлам булып тупланган хуш исләрдән тыны кысылды аның. Сукмак шулкадәр текә иде ки, ул йөк белән төшкән ат кебек үзен тыя алмый азапланды һәм җәфаланмаска карар итеп, аска, үзәнгә кадәр дөпелдәп йөгереп төште. Хуш исләр монда тагы да куерак, тагын да зәһәррәк иде. Бу дару катламнарын, әгәр теләсәң, соскы белән сосып, көрәк белән көрәп йөккә төяргә мөмкин иде. «Менә ни өчен генә дә ябышып ята икән җыен сукбай бу Кырым җиренә», — дип уйлап алды ул.

Сукмак тора-бара юлга килеп чыкты һәм бу юл аны, ниһаять, тегеннән-моннан бульдозер, авыр техника белән тәртипсез таптаган, кемнәрдер әллә төзеп җимергән, әллә җимереп төзегән, һич тә аңлашылмас, ниндидер килде-киттеле мәйданга алып чыкты. Тау кырлачларыннан җим көткән кош баласы кебек ачык авызлы казынды-зимләнкеләр, төсе уңган палатка-куышлар, төзелә башлаган, төзелеп беткән кечкенә җәйге өйләр, алачыклар, беренче катыннан икенче катына күтәрелеп, әлсерәп, хәле беткәндәй, төзелүдән туктап калган йортлар, казылган, таш, авыр плитәләр түшәлгән нигезләр, һәркайда кемнәрнеңдер иҗтиһатлы кулы белән өелгән төзелеш кирәк-яраклары утарында, эш көне булуга карамастан, кабер тынлыгы хөкем сөрә иде... Монда көнбагыш чәчкәсе һич кенә дә булыр кебек күренми. Инде борылып, кире китәргә диеп торганда гына, янәшәдәге төзелеш кишәрлегеннән ирләр тавышы ишетелде:

— Решид, мәһлүл үчүн су кутарды!..*

— Гюн уртадан суңра Осман гәтерәчәк!** — дип җавап бирде икенче бер тонык тавыш. Ул базда иде булса кирәк.

Гәпләшүчеләр күренми иде.

Григорий уң яклап икенче катына күтәрелеп килгән таш йорт белән сулдан инде әзер дип әйтергә мөмкин булган җәйге алачыкны тоташтырып сузылган зәңгәр бау астыннан иелеп эчкә үтте. Ни күзләре белән күрсен, артыш куагына сөйкәтеп үк кораштырылган ап-ак такта станга бөтен гәүдәсе белән диярлек менеп яткан сигез-тугыз яшьлек малай актыгы, авызына тутырып су капкандай, пуф-пуф килеп, пыяла кисеп ята!.. Пыяла йөзе һәм малайның пыялада иҗат иткән якты, кылдай нечкә эзе яхшырак күренсен дип, ул тагын да бераз алгарак үтте һәм чүгеп утырды. Пыяла табагын кояш тигез һәм тулаем яктыртты, һәм малай, өстенә тетелеп беткән иске майка, ямаулы чалбар, аягына кечкенә кара кәвешләр эләктереп алган малай, үзен күзәткәнлекләрен башына да китермәгән бу Чәнтибармак-оста, алмазын нәкъ кояш уртасыннан чыжылдатып үткәзде, авызындагы тынын пуфылдатып чыгарды һәм ниндидер бер могҗизаи төгәллек белән пыяла табагын ике өлешкә аерды да стенага сөяп тә куйды:

— Ата, йәнә гәтер!***

Каяндыр, кыйратылган, кеше тәненнән сынган сөяк сыман тырпаеп чыккан ак кәүсәләре, ботаклары белән агарып, еламсырап торган җимеш агачлары артыннан пыяла күтәргән ир күренде. Башын марля белән уратып бәйләгән, өстеннән җете кызыл кәләпүш чәпәгән, чалбар балакларын кирза итекләренә кыстырып кигән, кашларыннан цемент, төзелеш тузаны коелып торган бу кеше, көтмәгәндә, үз ихатасында, аңардан өч-дүрт адымда гына басып торган ят адәмне күреп туктап калды. Туры, бераз гына югары чөелгән танаулы, түгәрәк йөзле ир килеш-килбәте белән суеп каплаган актер Кирилл Лавров.

— Кисәме? Кулын яралар дип курыкмыйсызмы? — диде Григорий, малайга күрсәтеп.

— Кисә генә дисезме! Кыя гына. Кистертмәсәң, елый. Күрәсең, минем Дәүләтхан пыяла кисүче булып яратылган! — Рәшид — аның исеме чынлап та Рәшид икән — улының мүк кебек куе бөдрәләреннән сыйпап алды. — Бар, улым, абыеңа урындык алып кил!..

— Юк, мин тизгә генә...

— Сезне беркем дә көчләп тотмас. Кеше килгәч, аның

---

* Рәшит, измә өчен су бетте! *(кырым татар.)*

** Төштән соң Осман китерәчәк! *(кырым татар.)*

*** Әти, янә китер! *(кырым татар.)*

тәртибе бар. — Ул төзелеп яткан йорт ягына борылып аваз салды. — Галимә, чәеңне яңарт!..

Малай алмазын өстәл өстенә куйды, аннан бер мизгелгә уйга калып, аны кире алды һәм чалбар кесәсенә шудырды да урындык артыннан торып китте.

Григорий үзе белән таныштырды һәм килүенең максатын аңлатты.

— Көнбагыш... көнбагыш... — Рәшид бу сүзне берничә тапкыр кабатлады. Гүя ул аңардан telendә май яза иде. — Көнбагыш, дисез инде... — Ул кунакны култыклагандай итеп бакча тарафына алып китте. — Әйдәгез, үз күзләрегез белән күрерсез.

Алардан берничә йөз адымдагы өемнән Хәнәгән мәгарәсеннән мәрмәр чыгарган пәйгамбәр сәхабәләре кебек, ак онга батып, соңыннан белүенчә егерме килодан да ким булмаган зәңгәрсу күбекташлар күтәргән кешеләр күренде. Алдан яшь кенә хатын белән ир, бераз арттарак чатан Ак Бабай белән Ак Әби килә иде...

— Имгәнмәсләрме?

— Без имгәнүдән узган инде, — диде Рәшид кырыс кына. — Сөрген кырым татарының ике сыйфатын көчәйтә төште — эшчәнлекне һәм сәяси көрәш рухын. Кырым татарының һәркайсы диярлек академик Сахаров... — Ул көлемсерәп туктап калды һәм Григорий кебек вазифалы кешегә ышаныч йөзеннән, күрәсең, чишелеп китте. — Әле берничә көн элек кенә Ялитә карагруһлары утарларыбызны җимереп ташладылар... Монда без нибары утыз ике генә гаиләбез дә бит — сыйдырмыйлар. Инде менә өч ел буе кабатлана бу хәл, өченче тапкыр, туганкай... Төзелешне башлап кына җибәрүебез, яшелчә-җимешләребезнең өлгерүе генә була, киләләр дә... — Рәшиднең керфек очлары дымланды. Ул, башка кеше ишетмәсен дигәндәй, пышынга күчте.

— Гомумән алганда, соңгы елларда Кырым базары татарлар кулына күчә бара. Тырыш бит ул безнең халык. Моннан бер-ике атна элек базарга мин дә кәбестә-помидор алып чыккан идем... Саттым бераз. Куаныч, ә кәк же! Әмма иң куанганым, туганкай, икенче нәрсәдә булды. Юынмаган, кырынмаган урыс картлары һәм әбиләре, христа ради хакына Симферополь базарында хәер сораша... «Авызыбызга бүген катрә дә азык алганыбыз юк!» — дип инәлә алар. Бирдем. Итәкләренә тутырып помидор салдым. Ә бит алар минем милләтемне басып алган, аннан сөргенгә озаткан! Бүген минем йортымда, гөлләр бер төндә үсә торган туган җиремдә яшиләр. Бер караганда, хәерне алардан мин үзем сорарга тиешмендер. Юк! Корьән намуслы хезмәтне генә зурлый. Бар, эзләп тап син Кырым буйлап хәер сорашкан берәр татар кешесен!..

— Әйтегез әле, Рәшид, сез калдырып киткән йортлар арасында сакланганнары бармы?

— Алар барысы да диярлек. Туксан меңгә якын йорт. Безнең халык таштан төзи бит ул. Әлбәттә, аларда яшәүчеләр, әзердән бәзергә генә килгәч, йорт-җирне карамаган... Иң рәнҗеткәне шул, туганкай, безгә үз авылларыбызга кайтырга да, үз йортларыбызны яңадан сатып алырга да рөхсәт итмиләр. Эшкә дә алмыйлар. Пропискага да керттермиләр. Минем ата-бабаларым Морза-Нияттән. Хәзер Красноармейский дип йөрткән булалар. Бу адәми түгел, козгын да кунмас тау кырлачын да без даулашып, самозахват белән алдык...

Рәшид тирән итеп уфылдады да тынып калды.

— Утыз ике гаилә, дидегез. Ихаталарда кеше күренми.

— Күренерлек иттеләрмени? Бульдозерлар йорт-җирне, бакчаларны кырды, мильтоннары тәпәчләр белән халыкны тукмады. Балаларны, әби-сәбине дә кызганмады. Менә миңа да шул алышта эләкте инде...— Рәшит кәләпүше астыннан кан саркытып торган бинтына ымлады. — Үзебез тау куышларында яшәсәк тә, әүвәле таштан мәчет төзеп, манарасын да күтәргән идек. Шул ошамады. Башта мәчетне җимерделәр... Алла белән сугышалар, имансызлар. Юк аларның үз алласы, әгәр бар икән — анысы да Сатана, Иблис!.. Әй, сез көнбагыш сораган идегез бит әле, һаман телемә салынып торам икән! — Ул, Григорийны яңадан култыклап алып, бакча башына таба бара башлады. — Алты авылдашыбыз кан косып ята. Аягында басып торганнарыбыз кайсы хакимияттә, кайсы прокуратурада гаделлек эзләп йөри. Ә мин, аяктагы янбалит... — Ул көлемсерәде. — Гаиләм белән кизүдә торам, ягъни мәсәлән. Әнә алар сезгә кирәк көнбагышлар! — Ул, оялгандай, читкә карап, бармагы белән төртеп күрсәтте. — Шул телсез сабыйларның ни гаебе бар, ә, туганым?!

Григорийның аунап-аунап елыйсы килеп китте — ихатадан ихатага уртак бер зур бакча булып сузылган йөзем, груша, слива агачлары, барысы җимерелгән, кыйратылган, алар арасындагы кызыл помидорлар, кәбестәләр, кишерләр, кабак һәм патиссоннар, бакча кырыйларында күптән түгел аның держава байрагы булып ялкынланган көнбагышлар трактор чылбырлары астында сулкылдап изелгән, ә җир урыны-урыны белән сытылган йөземнән — яшькелт, сытылган помидорлардан — кызыл, сытылган көнбагыш таҗларыннан — сары төскә кергән иде...

— Аларча базар мөнәсәбәтләре менә шулай була инде, — дип дәвам итте Рәшид. Әмма Григорий, аны тыңламыйча, гомерләре вакытсыз киселгән көнбагышлар белән хушлаша иде. — Биредә атаклы экономист Мильтон ачкан законнар түгел, тәпәчле мильтон законнары хәл итә... Тәүдә менә бу

куышта яшәп азапландык. — Рәшид авызы яшел хәрби тукыма белән капланган зимләнкегә күрсәтте. — Тернәкләнеп китсәк, мин аңардан кар базы ясыйм, Алла боерса!.. Авылга да Морза-Ният дигән исем кушарга килештек. Исем туена сезне дә чакырабыз!..

— Әйе, киләм... Киләчәкмен. Мин сезгә Украина җиләк-җимешләренең иң яхшы сортларын алып киләчәкмен.

Алар бөтен авылны карап чыктылар. Григорий куен кесәсенә языштыргалап та барды. Вәхшилекнең чиге юк иде.

— Көнбагышларны басуы белән биргән булыр идем. Бигрәк тә үзебезнең татар шагыйренә. Әйткәнемчә, минем хатыным да Казан татары бит...

— Әтисе, керегез, чәй пеште! — Җәйге алачыктан Галимәнең тавышы ишетелде. — Юл уңаеннан урындыкны да алып керә күр!

— Юк, юк, Рәшид, рәхмәт. — Григорий сәгатенә карап алды. — Вакытым бик тә кысты.

— Безнең халыкта чәйдән баш тартмыйлар да инде ул...

— Башка вакытта... Мин сезгә махсус рәвештә парламент комиссиясен алып киләчәкмен.

— Алланың амин дигән чагына гына туры килсә иде! Без сезне зурлап каршылар идек! — Рәшиднең күзләре очкынланып китте. — Менә шулай тау-ташта булса да тырышып ятабыз. Ут юк, су юк, телефон юк, транспорт юк. Нәрсә кирәк — берсе дә юк. Җәйге өемнең тәрәзәләрен генә пыялалыйсы калды. Эш инде хәзер Дәүләтханга гына терәлеп калды. — Ул шаркылдап көлеп җибәрде. — Шулай бит, улым?

Григорийның бу ихатадан бер рәхмәтсез чыгып китәсе килмәде. Өстәлгә менеп ятып диярлек һаман да пыяла кискән Дәүләтхан яныннан үткәндә, ул, исенә килеп, кесәсеннән янчыгын чыгарды һәм малайга биш йөз мең корбованец акча сузды.

— Күп түгел. Шулай да алсаң иде, энем.

— Кирәкми! Кирәкми! — дип тыпырчынды малай.

— Мондый зур акча кирәкмәс иде, Григорий, — диде Рәшид. — Бездә бер тиен дә хәер... — Григорий башын кагып, Дәүләтханнан акчаны алуын үтенде. — Ал, улым, хәердән баш тартмыйлар. Мосафир абыеңа рәхмәт әйт!

— Рәхмәт!

— Дәүләтханга күлмәк-ыштан алырсыз. Малай белән ата утырып дога кылдылар.

— Әти, әти! — диде Дәүләтхан, битен сыпыргач. — Минем ыштаным әлегә бар, яңасын үскәч алырбыз, әйдә, миңа яңа алмаз алыйк, ә?

Григорий белән Рәшид пырхылдап көлеп җибәрделәр. Аларга кушылып, Дәүләтхан да көлә башлады.

Бау аша иелеп, ихатадан чыккач, Григорий аларга кул болгады.

Тегеләр дә болгый иде. Арттан Рәшиднең тавышы ишетелде:

— Көнбагышны сез Симферополь тарафындагы авыллардан гына таба алырсыз!..

Тукталышта халык юк диярлек. Шундук килеп җиткән троллейбуска алар нибары ике генә кеше утырды. Гастрольләрдә бөтен СССРны йөреп чыккан, әмма беркайда да очратмаган, бары тик Кырымда, атап әйткәндә, Ялта белән Симферополь — алтмыш чакрымлык арада гына йөреп яткан бердәнбер мондый маршрутның никадәр уңайлы булуына куанып бетә алмаган алтмыш яшьлек халык артисты Григорий Булах инде Симферополь тарафларына дәвам итә иде сәяхәтен. Иртәнге хатирәләр онытылмаса да, алар күңелдә ничектер тигезләнгән һәм тоныкланган. Ут булып янган асфальтны чыжылдатып үтеп киткәндә, артта калган һәр куак, һәр сабак, һәр ботак аңа зәңгәр диңгез күбеген хәтерләткән ташлар күтәргән чатан Ак Бабай һәм Ак Әби, сытылган йөземнәр, изелгән көнбагышлар арасында тере тамыр эзләгән Рәшид, өстәлгә менеп ятып диярлек пыяла кискән Дәүләтхан булып күз алдына килә... Их, эзләп табарга иде аларның гомерен озайта торган бер детектор, бер генә перпетуум мобиле!..

Салонга бергә кергән теге кешенең урыны Григорий белән янәшәдән туры килде. Алар сөйләшеп-танышып китте. Җитмәсә, ул украин һәм Григорийны ишетеп, хәтта телевизор аша төсмерләп тә алган кеше булып чыккач, әңгәмә, Днепр сыман киңәеп китеп, украин телендә генә акты. Микола Ялтадагы кызыннан Симферополь аша Перекоп ягына кайтып бара икән. Чыгышы белән Черниговщинадан. 1946 елгы ачлыкта аларның гаиләсен куылган кырым татар җирләре һәм йортларына күчереп утырткannar. Әти-әниләре монда җирләнгән. Туган якларына бөтенләйгә кайтасы килә, әлбәттә...

— Ось тут тепер я і живу тих пір. А ви куди дорогу тримате?

— Я щукаю соняшника розцвіченого.

— Для чого?*

Григорий аңлатып бирде. Якташына ничек кенә булса да ярдәм итәргә теләгән Микола аны үзенә — ниндидер Раздольноега чакыра башлады. Көнбагышлары да бик күп икән. Аннан, бераз ял да итеп китәр...

---

* — Менә шул заманнардан алып мин монда яшим дә инде. Ә сез кая юл тоттыгыз?

— Чәчкә аткан көнбагышны эзлим.

— Ни өчен? *(укр.)*

Ялтадан егерме чакрым чамасы киткәч, мактаулы троллейбус ватылып туктады. Юлчылар тышка чыкты. «Васильевка» дигән юл күрсәткеч тактаны күреп, Григорий, нәрсә булса да булыр дип, шул тарафка барырга ниятләде.

Васильевка, җилләр әчесендә ятса да, шактый төзек, зур гына авыл булып чыкты. Беренче йортка ук керергә карар итте. Капкасына «Виктор Сергеевич Троемордин» дип язылган иде. «Фамилиясе бигүк куандырырлык булмаса да, исеме матур — Виктор, — дип уйлап алды Григорий. — Викторлар арасында әле аңа начар кешеләр очраганы юк».

Бәйләнгән такта алачыгын өстерәп чабардай булып, аңа теге очтан эт ыргылды, тезгененең боҗрасын капкага кадәр сузылган баудан зеңгелдәтеп килеп, амалап алам дигәндә генә Григорий читкә сикереп өлгерде. Койманы урам яклап көнбагышлар рәте чиккән иде — әле генә ияге күкрәгенә ишелеп төшкән эт авызыннан котылган мосафир бу манзараны күреп, майдай эреде:

— Агов! Люди е?*

Болдырга биленә кадәр шәрә, биленнән аска таба кыска шорты кигән, май йомарламы сымак әвәләк, киметеп кенә әйткәндә, бик тә симез ир, аның артыннан шундый ук ит чүмәләсе булган хатыны чыкты. Алар Григорийның сәламен алып маташмады.

— Хайдер, урыныңа! — дип җикерде хуҗа этенә.

Исәнләшү шушы булды, күрәсең.

Бау буйлап боҗрасын яңадан зеңләтеп, Хайдер оясына таба китте. Зур башлы, ябыштырып куйган шикелле кечкенә колаклы, шалкан сыман агарып, тәгәрәп торган күзле, күкрәген җон карурманы баскан ир, алпан-тилпән итеп, җай гына, ашыкмыйча, табаннары белән гүя җир ныклыгын капшап, артыннан җимерелеп төшкән күкрәкле хатынын ияртеп, Григорийның борын астына килеп туктады да акайган күзләре белән чәнчелде:

— ???

— Мин... ни... Гафу итегез, Виктор Степанович... Татарстаннан шагыйрь дустым...

Чылбырлары белән такта кыйнап, эт өрде. Григорийның кече теленә гүяки тагын кылчык кадалды, шул кылчыкны йота алмый азапланган ара хуҗага аның бер дә юкка кермәгәнлеген раслаучы дәлил булып күренде булса кирәк, — ир башын икенче якка янтайтты, чынлап та, өч иякле Троемординның ияkләре икенче якка күчте.

— Әйе, Татарстаннан шагыйрь дустым... Чеченнарның азатлык көрәше турында тетрәткеч китап язган...

* — Әй, кешеләр бармы? *(укр.)*

Тагын да эт өрде. Эте дә иясенә охшаган иде.

Сөйләнгән сүзләр буш иде. Григорийга бары ышандырырга кирәк иде.

— Менә ул китап!.. Теләсәгез, актарып та чыга аласыз, Виктор Степанович...

— Пычагыма да кирәкми миңа ул поганый китап!.. — Григорий гүя аны ишетмәде.

— Мин менә шул шагыйрьгә мөстәкыйль Украинабызның шагыйранә билгесе итеп, милли чәчкәбез — сабактагы көнбагыш чәчкәсен бүләк итәргә уйлаган идем... Әмма берничек тә таба алмыйм...

Троемординның йөзе тәмам чалышайган иде.

Эт өрде.

Аларган күзләргә һаман да кан кайтмавын күргән Григорий яңадан дулкынлана, тотлыга башлады, бу кешеләр, ичмасам, тамырлары белән украин җиреннән түгелләр микән дип, берничә кәлимә украинча да кыстырды:

— Розумíьте... Соняшник! Менi потрiбно квiтку! Поетовi! Як символ Украiни!..

— Чаво?* — Троемордин чайкалып артка чигенде.

Эт өрүдән туктады.

Үзеннән күпкә яшь хатыны Григорийга күзләрен мыймылдатып елмая иде.

— Нинди Украина ди ул тагын?! — дип гыжгылдады, ниһаять, аңына килгән Троемордин. — Монда гомер-гомергә урыс җире! Соняшник, имеш... Чечен-татар бандитларына соняшник!.. Тоттырырмын мин сиңа соняшник монавы сыргавыл белән! — Ул коймага сөяп куелган көрәк саплыгына үрелде...

Григорий баскан урынында катып калган иде.

— Бир, Витек, бер көнбагышыңны, — диде елмаюы һаман да йөзеннән китмәгән хатын. — Аңардан гына кимемәссең... — Ул иренең иңенә сарылды. — Бир инде, үтенәм!..

— Цыц, беләткә! Мин синең үзеңне куып чыгарырга да күп сорамам! Анда чечен бандитлары ядрәсеннән газиз энем үләргә ята, ә мин аларга букет җибәримме?! Канга — кан, үлемгә — үлем! А ну, пшол отсюда воровская хохляцкая рожа, а не то спущу собаку! Кырым беркайчан да татарларныкы да, хохолларныкы да булмаячак!..

Авыр гәүдәсен почмаклатып борып, ул этенә таба китте. Хатын гүя үрә катып җан биргән дә, аны бары җирлисе генә калган иде. Григорий малай чагындагыча, теш арасыннан черт итеп төкерде дә капкадан чыкты.

---

* — Аңлыйсызмы... Көнбагыш! Минем дустыма кирәк! Шагыйрьгә! Украина билгесе итеп!..
— Нәрсә? *(укр.)*

Койма аша хатынның чәрелдәп елап җибәргән тавышы ишетелде.

Алар сугышалар иде шикелле.

Григорий урам буйлап үргә менеп китте.

Троемордин аның уйларын, теләсә-теләмәсә дә, иртәнге кичерешләр белән тоташтырды. Бу бәҗрадан чыгып булмый иде. Украинча һәм урысча укыган, урыс телен су кебек эчкән, кирәк санаса, шул телдә китап язган, аны ифрат та яраткан, совет власте шартларында коммунистик беркатлылык белән урыс мәдәниятенә, әдәбиятына чиксез сөюдә тәрбияләнгән Григорийның соңгы очрашудан соң йөрәге һәм мие беркайчан да ябышмастай булып икегә ярылган иде: әллә урыс халкының күңел табигате, чынлап та, теге гәзит аламасы язганча, бозык һәм сасыганмы? Элеккеге һәм бүгенге Рәсәйдә, аңа чиктәш тирә-як илләрдә, кыйтгаларда тотрыклылыкның булмавы, йә тегендә, йә монда сугышлар, фетнәләр кубарылып торуында урыс милләтенең шундый күңел табигате гаеплеме? Нишләп ул гомере буе башка халыкларны, аларның җирләрен кемнәндер «азат итеп» басып ала, бу җирләрне борынгыдан «исконный» урыс җирләре дип игълан итә? Нишләп ул басып алынган җирләрнең киңлеген, байлыгын, барлыгын ярата, ә менә аларның чын хуҗасы булган халыкларны яратмый, киресенчә, кимсетә, төрле ләкапләр тага? Чүмәләдәге эт кебек, печәнне үзе да ашамый, малга да бирми? Нишләп ул үзе дә яши белми, башкага да юньле тормыш күрсәтми? Нишләп ул үзен генә Җир шарының ашы тозлыгы, кабатланмас күренеше булган халык дип игълан итә дә, бу хакта кемдер бер генә сүз белән шик белдерүгә, куык кебек шартлап чыга, авызга суга, башкаларга суларга һава, басып торырга җир, эчәргә су бирми һәм гел генә үз бәхетсезлегендә башкаларны гаепли? Нигә ул, әгәр үз файдасына булса, дуңгызга да җизни дияргә әзер? Әнә бит алманнардан, акча кирәк булгач, кичәге кан дошманы Гитлерны аклап, аның «Майн кампф»ларын басып чыгара, нацистик фиркаләр оештыра, ә менә моннан җиде йөз ел элек үлеп, урыска дәүләтчелек бүләк иткән, инде сөякләре дә көлгә әйләнгән, бүген килеп, бернинди куркыныч белән янамаган Чыңгызханны онытмый, монгол-татарларны «җиңүенең» җиде йөз дә җитмеш җиде, кирәк икән җиде йөз дә җитмеш җиде ярым еллыгын да шау куптарып билгеләп үтә?

Нишләп ул мари җирен, татар җирен, калмык җирен, чукча җирен һәм башка йөзләгән халык җирләрен һәм байлыкларын чиксез сөя, ә менә мариның үзен, татарның үзен, калмыкның үзен, чукчаның үзен, бер сүз белән әйткәндә, үзеннән башка беркемне дә сөйми? Җир йөзендә үз-үзенә бу кадәр дошман эзләгән җәнҗалчы кавем бар микән?

Григорий аңлавынча, бу сыйфатлар хезмәт сөймәүдән килә.

Бу уйлардан башымдагы мием черемәде микән дигәндәй, ул тагын бер тапкыр җиргә черт итеп төкерде. Аның фикерләре Тарас Шевченко язмышына барып тоташты. Кара син аларны, ә? Бер генә сызат: хуҗасы алпавыт Энгельгард белән Петербургка күчеп килгән кол шагыйрь — хокуксыз «малоросс» дусларының ярдәме белән нибары җиде генә шигырьдән торган «Кобзарь»ен бастырып чыгара. Куанырга кирәк иде дә бит җитмеш илне басып алып, җитмеш төрле канны эчеп, җитмеш илдән таланган алтын исәбенә теттереп яшәп яткан Петербург хадимнәренә югыйсә, ничек кенә булмасын, үз телендә белем алудан мәхрүм украин халкының яңа әдәбияты, даһи шагыйре дөньяга килде бит! Ә, юк. Сатлык журналистиканың сәмруг кошлары Шевырев, Сенковский, Греч, Булгариннар Шевченконы эт итеп талый, «Кобзарь»дән «үлеп барган телдә язылган мәктүп» дип көлә... Ә менә карагыз, украинның милли уен коралы кобза һәм дистәләгән кыпчак-татар милләтенең кумус, кумыз, комыз, кубыз дип аталган моң кораллары белән бер тамырдан яралган. Григорий тел тарихчысы түгел, әмма һәр бераз гына булса да укымышлы украин «кобза» сүзенең кыпчак далалары, комлыкларында җил-давылда комдай гөжләп һәм иләнеп, бия сөтеннән әчетелгән кымыздай чыжлап килеп кергән кебек, «украин» сүзенең дә «кыр, кырым, кыры иле», ягъни «поле» сүзеннән алынуын аңлый; бу үзара баегу бәхете; нәрсә, кумыз йә кобзага ат кылын беренче итеп син түгел, мин тарттырдым, бу корал минеке генә дип, бүген украин белән кыпчак халыклары сугышырга, тфү-тфү, бер-береңнән хәер хаһ — контрибуция түләтергә тиешме? Алайга китсәң, кем кемгә генә түләмәскә тиеш контрибуцияне? Аллага шөкер, мең еллар буе кыз алып, кыз бирешкән, бергә яу чапкан һәм яу кайтарган, еш кына үзара бәргәләшеп тә алган бу ут-күршеләр һич кенә дә дошманлашмый, бер-берсенең җирен «исконный минеке» дип җәнҗал куптармый...

Башын күтәреп, ул карашы белән тирә-якны күзеннән үткәрде — һәм, ниһаять, ышанасызмы, бәлки, бүген соңгы тапкырдыр! — көнбагышлы ихатаны күрде. Әмма эчкә үтә алмады. Койма ифрат биек, капка бикле булып чыкты. Григорий күршедәге ихатага керде. Яшь кенә ир белән хатын бакчада казынып маташалар иде. Ирнең кыяфәтендә артист Краморовка хас сөмсезлек, оятсыз үҗәтлек күреп, ул тагын пошаманга калды — уңамы, әллә туңамы? Ул аларга инде менә ничәнче тапкыр үзенең кем икәнлеген, нәрсә эзләвен, ничәмә-ничә йорттан буш чыгуын сөйләп аңлатты.

— Ә нигә сезгә бары тик көнбагыш чәчкәсе? — диде ир, артист Краморов чырае белән елмаеп.

— Букетка. — Григорийның аны сугып очырасы килә иде.

— Көнбагыштан букет буламыни? Менә без хәзер хатын белән үз бакчабыздан сезгә менә дигән букет җыеп бирәбез. Карагыз әле, бездә күпме чәчкә!..

Бакча, чынлап та, чәчкәләр патшалыгы иде. Юлчының эченә җылы йөгерде.

— Юк, рәхмәт. Миңа бары тик көнбагыш чәчкәсе кирәк... Татар шагыйренә... Украин җиренең... — Юл йөреп, газап чигеп алҗыган Григорий килүенең төп мәгънәсен аңлатырга да онытткан икән. — Сезнең күршегездә көнбагышлар чәчкә атып утыра, әмма хуҗа үзе өйдә юк, күрәсең. Дөбердәтеп тә карадым, ачмый. Әгәр сез шаһит булсагыз, мин бер генә төп көнбагыш алып чыгар идем...

— Бәй, аны баштан ук шулай диләр! — Ир йөзендәге елмаюын җыеп алды, әмма җитди чагында ул тагын да үҗәтрәк күренә иде. — Койма аша сез ничегрәк үтәрсез соң?

— Әгәр рөхсәт итсәгез, мин хәзер!.. — «Вәт, артист!» дип уйлап алган Григорий коймага ыргылды, ләкин кире шуып төште. — Сезнең баскыч бардыр, бәлки?

— Бар, әлбәттә. Сорамыйсыз бит.

Григорийның аны сугып очырасы килә башлады.

— Юра, ташла кылануыңны! — диде хатын йомшак кына. — Күрәсең бит, кеше бик җитди эш артыннан йөри. Бар, үзең кер. Василий Захарович өйдәдер ул!..

Юра, хатыныннан гына күрсәтмә көткәндәй, абзарыннан баскыч алып чыгып, «эһ» дигәнче теге якка сикереп тә төште. Бер минут үттеме-юкмы, кире килеп, Григорийга урам як капкадан керергә кушты.

Аның алдында какча, бик тә җыйнак гәүдәле, мөлаем аксыл йөзле, уң аякка аксак Василий Захарович басып тора иде.

— Рәхим итегез! — диде ул елмаеп. — Колакка катыракмын. Сугышта алган контузиядән калды. Кычкырыбрак сөйләгез...

— Мин — украин язучысы... Татар язучысына...

— Беләм, — диде ул бүлдереп. — Миңа Юра барысын да сөйләде. Көнбагышны кисеп аласызмы, әллә төбе-тамыры беләнме? Колакка катыракмын, кычкырыбрак сөйләгез!

— Төбе-тамыры белән! — дип, колак пәрдәсен ертырдай итеп кычкырып җибәрде Григорий куанычыннан. — Төбе-тамыры белән, Ва-си-лий Зах-хар-ович!..

— Ул хәтле кычкырмагыз! Чукрак дигәч тә... Алыгыз, улым, алыгыз! Изге эшкә дигәндә, икене, өчне алыгыз...

Менә алар Юра, Василий Захарович һәм Григорий сабыйны биләүдән арындырган саклык белән көнбагышны казып чыгардылар, чүлмәк төбенә туфрак салдылар, тамырны зәгыйфьләми һәм җирне кирәгенчә генә калдырып, аны чүл-

мәккә төшерделәр, янә туфрак өстәделәр һәм су белән сугардылар. Шатлыгын кая куярга белмәгән Григорий көнбагышның сабагын, яфракларын сыйпап чыкты, күзенә бәргән яшен ярсу җилгә җилләде, аннан сугышта аягын югалткан картның күңелен күрим дип, акча сузды.

— Кире тыгып куймасаң, чәчкәне бирмәм дә әле, — диде карт, ачуланган кыяфәттә. Аннан үләндә яткан яшел тышлы «Этот непобедимый чеченец...» китабына төртеп күрсәтте. — Менә монысын калдыр!..

— Аны автор миңа култамгасын куеп биргән иде... — диде Григорий уңайсызланып. — Бердәнбер китап ул, Василий Захарович...

— Бәй, син миңа нәкъ әнә шул бердәнберен бир! Колак ишетмәгәч, радионы тыңлый, телевизорны карый алмыйм. Аллага шөкер, күзем бөркетнеке әле минем... Сукыр күп күрә, чатан күп йөри дигәндәй, мин, чатан, күп йөрим шул... Укып чыккач та, илтеп бирер идем...

— Чынлап та, әгәр мөмкин булса, калдырыгыз, — диде Юра. — Адресыгызны әйтсәгез, мин аны Сезгә үзем илтеп бирермен. Ялтада мин көн саен диярлек булам...

Шулай килештеләр дә. Василий Захарович укып чыккач та, Юра китапны иҗат йортына илтеп тапшырачак, татар шагыйрен Григорий белән икәүләп кунакка да чакырып кайтачак...

— Рәхмәт сезгә, Василий Захарович, — диде Григорий хушлашып. — Рәхмәт сезгә, Юрий. Дякую вам, дякую!*

— Син бу чәчәкне тапшырганда әйтергә онытма, — дип кычкырды Василий Захарович капкага юнәлгән Григорий артыннан. — Анда минем йөрәгемнең дә бер өлеше бар!..

Юра аны капкага кадәр озата килде.

— Ә син, Юра, артист! Чын артист! Син Краморовның үзе! Тышкы кыяфәтең белән эчтәлегең каршылыкта яратылган. Киевка кил, яңа кинофильмнан синең өчен рольне сугышып булса да алырмын.

— Рәхмәт! Фильмнарга төшү өчен минем йөземне яңадан тугыларга кирәк...

— Аннан соң синең кирәгең калмый. Йә, хуш!

— Хушыгыз!..

Чүлмәкне уң кулының уч төбенә куеп, сул кулы белән сабагыннан тотып, аерым бер саклык һәм илтифат белән Григорий капкадан чыкты. Көнбагыш чәчкәсе дөньяның алтыдан бер өлешен биләп яткан илдән, чәнечкеле тимер чыбык артыннан, лагерьдан, бөтен кешелек алдында үзе кылган гөнаһлары өчен шул ук дөньяның алтыдан бер өлешендә тә-

* — Рәхмәт сезгә, рәхмәт! *(укр.)*

муг газаплары, ахырзаман сиратлары кичергән сәер кыйтгадан исән-сау котылган ирек кошы — карбонарий булып янаялкынлана иде...

...Үзе дә сәер кыяфәттә, бер чәчкәдән торган сәер чәчкә гөләндәме тоткан, тирләгән-янган, соргылт чәчләре учма-учма булып маңгаена ябышкан Григорий Ялта–Симферополь юлын ике яктан да сырып алган милиция хезмәткәрләрен, штат киемендәге асаба ыспайларны күреп, аптырашта калды.

— Нәрсә булды, туганкай? — дип сорады ул колгадай озын буйлы милиционердан. — А хто ж тут буде ехати?*

— Сорап торган буласың тагын! Шул инде, синең баш хохолың!..

— Әгәр ул чынлап та ул икән, ул чакта «синең хохолың» түгел, ә безнең Президентыбыз була!..

— Хәзер, абзыкаем, безнең президентларыбыз булмаган Тамбов һәм Еврей автономияле өлкәләре генә калды инде. — Милиционер сирәк араталы арба кебек сирәк тешләрен ыржайтып көлде.

— Сез чамалап, чамалап... Ат кәнүшниендә бет үтергән Шүкәр карт түгелсездер бит?

Колгага барып җитте, күрәсең. Уңайсызлана төшеп, ул тел уйнашына бирелде.

— Ярар инде, абзыкай. Монда гаепләрлек бернәрсә дә юк кебек. Сез безгә, урысларга, «кацап» дигән кебек, без дә сезгә, украиннарга яратып кына «хохол» дибез... Дөресен генә әйткәндә, хәзер бу юлдан Украина Президенты Кучма Үзбәкстан Президенты Кәримовны Форостан Симферополь аэропортына озатачак... Монысы тагын нинди операдан? — Колга көнбагышка күрсәтте.

— «Наталка-Полтавка»дан Макогоненко ариясе...

Милиционер, әлбәттә, «Наталка-Полтавка»ны да, Макогоненконы да ишеткәне юк иде. Әйе, бер-ике көн элек кенә ул Президентларның ялда очрашуы һәм Кырым татарларына кайтып урнашуда ярдәм итү буенча уртак комиссия төзергә килешүләре турында укыган иде шул. «Леонид Данилович аны күрмәс микән? — дип уйлап куйды Григорий. — Их, күрсә иде ул үзебезнең көнбагыш чәчкәсен Симферополь юлында!»

Хәрәкәт тулысы белән туктатылган иде. Көнбагышын җиргә куярга да кыюлыгы җитмәгән Григорий әрәмгә киткән вакыты өчен нишләргә дә белми. Колга сыманның миен эшкәртергә булды.

— Менә шунысы начар да инде аның! Нәрсә, татар халкының Президентын булдырырга хокукы юкмыни? Ә үзегез, ялгышмасам, хокук сагында торабыз дип, дәүләт җилкә-

* — Ә кем моннан үтәчәк? *(укр.)*

сен кимерәсез. Хохол да хохол! Мин сезне хөкемгә бирергә дә күп сорамам әле! Фамилиягез-исемегез?

— Ә сезнеке? — диде Колга эре генә.

— Рәхим итегез. — Григорий Украинаның халык артисты, язучылар ширкәте әгъзасы, Украина Президентының шәхси ышанычлысы булуы турындагы таныклыкларын кулыннан ычкындырмыйча гына күрсәтте.

Милиционерның йөзе суда җебетелгән җитен төсенә кереп агарынган иде. Аны хәзер тактага салып, бәләклисе генә калган.

— Фамилиягез-исемегез, дим?

— Ярарыгыз инде, абзый кеше! Мин бит болай гына, шаярып кына...

Менә Ялта тарафыннан хөкүмәт машиналары кәрваны күренде.

Кырым җирендә үз ышанычлысы Григорий Булахтан бигрәк Президент үз дәүләтенең, милләтенең шигарен, сөенечле төсен күрә күрсен иде дип, Григорий көнбагышлы чүлмәкне югарырак күтәрде. Яшен тизлегендә узып барган өченче машинаның ачык тәрәзәсеннән аңа кемдер кул болгады.

— Соняшник, Леонид Данилович, соняшник! — дип кычкыра иде Григорий. — Дякую вам, дякую!..

Юл ачылды. Троллейбус килеп туктады. Милиционер аны салонга үзе алып керде, урын хәстәрләп, үзе үк утыртты. Троллейбусның эче бал исе белән тулды.

— Исән булыгыз, — диде милиционер, кулын чигәсенә ялт итеп куеп алып. — Теге нәрсәне онытыйк инде, ямегез...

— Хуш, — диде Григорий һәм күзен кысты. — Ә мин сине шулай да хөкемгә бирәчәкмен...

*Октябрь–ноябрь, 1996 ел*

## КЫЙБЛА

*Фатих Хөсни истәлегенә*

### I

Июль башлары иде.

Өммегөлсем карчык гомерендә кичермәгән җиңеллек, канатлы тойгы белән уянды. Кичәге ниятләрен хәтерләп, күңеленнән генә кабатлады: «Ходавәндә, Хәлиулла, догаларым кабул әйлә...» Күз кабакларын күтәрер-күтәрмәс, керфек аша гына тәрәзәләргә күз сирпеп алды — Ярабби Ходай! — таң аткан. Кадимге көннәрдәгечә, аны кабат-кабат уятып һәм уйларга салмыйча, ничектер песи тәпие кебек йомшак тәпиләрдә сиздермичә кергән бүгенге таң аларның йорт-

курасына. Ул үзе дә, карт буыннарын бер учка җыйгандай җыеп, шыгырдатмый-нитми, песиләрчә йомшак басып, шым гына урыныннан күтәрелде, гүяки мамык табаннары белән идәнгә сарылды һәм тәрәзә пәрдәсен бер читкә шудырды — әйе, таң аткан, аткан гына дисеңме, баеп аткан: гадәттә, Юкәле Кул өсләреннән бүселеп чыгып, шактый вакытларга оеп калучан таң сарысы бүген инде сөт өсте булып тәрәзәләрдә агарып та килә; Өязенең вак таллы үзәнлегенә куе томан ишелеп төшкән; тигезлеккә чыккан, бу тарафка якынайган саен, томан кояшның әлеге күренмәгән ерак нурларын күктән тотып алып, сиздерми генә сеңдереп, үзен шактый гына сыеклый һәм шау чәчкәдә утырган бәрәңге бакчасы гүя вак җиз иләк аша межмелдәп зәңгәрләнә; ә менә якында — ишегалдындагы бәбкә үләне өстендә томанның әсәре дә юк, анда сәйлән сыман чык тамчылары тәгәрәп ята...

Урын өстен бармак очлары белән генә элдктереп алып, җыештырып, кыштырдамый, иске агач караватсаңакларын шыгырдатмый-нитми, ул үзе яткан алгы якны түрге як белән бүлеп торган канатлы ишек катына килде һәм колагын куйды — Гарифулласы зыянсыз гына гырлап йоклавын дәвам итә иде...

Киез олтыраклы калушларын эләктереп, җәһәт кенә тәһарәт алып керде һәм каз тәпиләре чигелгән намазлыгын кыйбла тарафына җәеп, иртәнге намазына керешге. Шөкер, Ходай саулык-сәламәтлектән аермаганда, биш вакыт намазын да, башка фарызларын да калдырмый. Ә менә Гарифулласы бу фарызларны... Юк, юк, үти алмый, үтәргә теләми дип әйтергә теле бармый Өммегөлсемнең! Әллә ничек инде шунда, бер сүз белән генә әйтүе дә читен. Югыйсә намаз-тәкбир мөселман йөзендә нур булып чагыла да бит. Әмма Гарифулла белән мәсьәлә икенчерәк шул. Инде ничә мәртәбәләр ялынып-инәлепләр дә карады. Гарифулланың теңкәсенә дә тия алмый Өммегөлсем, ни дисәң дә — ир кеше, рәвешләре, холыклары, күргән-кичергәннәре икенче... «Гомереңне иблискә табындырып үткәрсеннәр дә, инде гүр якасына җиткәч кенә намазлык өстенә менү, кемнәрдер кебек, кичә коммунист булып, бүген ишанга әйләнү — моннан да зуррак иблислек бармы?» — дип кырт кисә дә куя ул.

Искене яхшы белә белүен. Аңа, мәзин баласына, ислам кануннары ана сөте, бишек җыры белән сеңдерелгән, Иман шарты, Коръән Кәрим сүрәләре, догалыкларны да яхшы хәтерли, Аллага шөкер, тел дә тидертми... Әмма күңеле каткан. Ә кеше күңеле бер катса, тиз генә җебеми, йомшармый икән ул. Ярар, нишлисең, Ходай Тәгалә булган гөнаһларын ярлыкасын, урыннарын җәннәттә итә күрсен иде... Кеше уйлый — тәкъдир йөртә, дип юкка гына әйтмәгәннәр бит. Югыйсә аның Гарифулласында пәйгамбәрләргә хас гыйзмәт,

явызлык эшли алмау сыйфаты бар. Шуңа күрә ул үз авылында танылa алмады. Алла алдында акыллы кеше генә җаваплы, акылсыз җаваплы була алмый, ди китап...

Гарифулланың күңелен балачактан ук сындырганнар шул. Дәһрилек кузгалып кына килгән заманнарда табын артында амин тотып утырган җиде-сигез яшьлек сабыйны актив Өтәләү Зариф наган төеп куркыта, аңа хәтта өянәк тә ябыша — баланы бу авыр хастадан Тәүәтәй мулласының им-томы гына коткарып калды, дип сөйлиләр иде Өммегөлсемнең бианасы белән биатасы. Бахыркаем догасын инде сәке астына качып укый башлый. Монысын да күреп калган комсомоллар сәхнәдән генә түгел, Садретдин мәзиннең өе каршына килеп әйтәләр оятсыз такмакларын:

Ак та була, күк тә була
Шатманнарның туласы.
Сәке астында әппәр итә
Садрый Гарифулласы...

Намазын онытылып, мөкиббән китеп башкарырга тырышса да, карчыкның башында кырыкмаса-кырык уй иде. Гыйбадәтенең һәр тәкбире, һәр авазында Ходай Тәгаләгә бер генә теләк, бер генә үтенеч, бер генә гозер иде: бүген әнә шул Әкчин дигәннәренә барып, ниятне җиренә җиткереп үтәрлек дәрт һәм дәрман гына бирсәң иде, и Тәңре!.. Гарифулласы кире генә уйламасын иде, и Тәңре!.. Иртәнге намазы адәм балалары буй-сынындагы өч йөз алтмыш буыны хакына кояш чыкканда биргән садакасы булсын иде! Бу якты дөньяда барча адәмзатларга күрсәткән ачык чыраем, тәмле сүзем, сәламем дә садака булып барып ирешсен иде!.. Бу иманның үзе түгелме? Иман булмаса, җавап юк — димәк ки, савап юк, җәннәт юк, җәһәннәм юк. Димәк ки, иман булмагач, адәмзат бер үк куллар белән дога кыла һәм кеше үтерә... Йа Хода, адәмнәреңне ярлыка! Динемне тулысы белән кабул әйлә, ярты мөселман — ярты иблис, ярты шайтан дигән сүз!..

Әкчингә барып кайту соңгы вакытларда аеруча тынгы бирмәде Өммегөлсем карчыкка. Теге вакыйгаларга илле ике ел үтүгә карамастан, аның беркайчан да бу кадәр ярсыганы-йөрәксенгәне юк иде. Югыйсә Әкчин станцасы Шатманнан әллә ни качкан җирдә дә түгел — җитмеш чакрымда гына. Хәзер машинасы тыз-быз килеп торган заманда «әһ» дигәнче генә барып кайтасы булган да бит... кеше уйлый — тәкъдир йөртә, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул. Насыйп итмәгән, тәкъдир дәфтәренә язылмаган булган, күрәсең. Аннан, нигә ди аның автобусы — авылда, үзләре белән бер канат астында яшәгән дип әйтерлек ике улының, җитмәсә, кияүләренең дә ялт итеп торган җиңел машиналары бар, әйт кенә! Әмма

карчыкның бу изге, сирәк йоланы берүзе, кеше-кара күзеннән читтәрәк башкарасы килә шул. Сугыш янбалиты Гарифулласын да бу өзлеккән заманнарда юлга ялгыз чыгарга курыкканга күрә генә алырга мәҗбүр үзе белән... Быелгы йөрәксенүен карчык Мәскәү хөкүмәтенең ырадиусыннан да, тилевизорыннан да бертуктаусыз: «Бөек Җиңүгә илле ел! Бөек Җиңүгә илле ел!» — дип кычкыруы белән бәйли. Бу кадәр кан коеп, бу кадәр үгисетелеп җиңүне карчык үзенә бирелгән табигый акылдан чыгып, һич кенә дә бүгенге телсезлек-денсезлек белән бер мыскалга сала алмый аптырый һәм җәфалана иде. Кем җиңде соң монда? Урысмы, нимесме? Ватан сугышы аның өчен бары тик сугыш, рәнҗеш, мәгънәсез канкоеш кына иде югыйсә. Әгәр Әкчингә быел да бара алмаса, ул анда беркайчан да бара алмаячак кебек тоела иде Өммегөлсемгә...

Намазын тәмамлап, дөньяның дүрт тарафы, барча тереклек, барча милләт-шивәләр, балалары, балаларының балалары хакына дога кылды. Аннан, гадәтенчә, картын уятмас өчен, моңлы тавышын үзеннән әллә кая җибәрми, тыелып кына мөнәҗәт әйтте. Сайланылган җәүһәр сүзләр белән кабатланмас мәкамнең кушылуыннан бар булган бу әсәр, кызганычка каршы, әлегә кадәр Өммегөлсемнең һәм бары тик Өммегөлсемнең генә байлыгы иде. Әнисеннән отып алган бу җыруны ул инде менә ничәмә еллар җырлый — иртәсен һәм кичен; яңгырда һәм кар-буранлы көннәрдә; күңеле күтәренке һәм бик тә төшенке чакларында; әмма мөнәҗәт аның күңелен туйдырмый да, маемлатмый да иде...

Ходавәндә, Хәлиуллла, догаларны кабул әйлә,
Өметем күп, рәхим Аллаһ, гөнаһым күп — гафу әйлә!
Әкерен алсаң җанымны иманымның нуры берлән,
Кыямәт көнем мөшәррәф кыйл сигез оҗмах нуры берлән!
Ля иляһа, кыйл гыйнаять барча эшкә сәйкәфил,
Әнтә раббым, әнтә хәсби, әнтә нигъмәти вәкил...

Тыкрык очыннан терлек-туар тавышлары ишетеп тышка чыкты һәм абзарын ачып, ике сарыгын, ике кәҗәсен көтүгә куып керде дә чәен куйды. Вак күзле онга йомырка сытып камыр туглады һәм карты яраткан кәгазь сыман юка битле коймаклар пешереп алды. Чәе кайнап, коймакларын таба төбендәге майда йөздергәч, сак кына, иркәләп һәм ярым пышылдап, картын уятты:

— Гарифулла... Гарифулла, дим... Чәй әзер...

Әчкелтем арыш ипие кебек гади игенче гаиләсендә «Хәерле кич! Хәерле иртә!» дигән теләкләр кулланышта булмаган һәм ул төчеләнү, кәнфитләнү саналганлыктан, күрәсең, Гарифулла абзый сүзсез генә урыныннан күтәрелде, сүзсез генә тышка чыгып керде һәм сүзсез генә, мич аралыгында электр утын чек итеп кабызып, юынгычның су агыза торган

тимерен шалдыр-болдыр китерә-китерә, ач яңакларын, ияк асларын сабынлый башлады...

Бөркет танаулы, үткер карашлы, кар кебек ак башлы, бар тирә-якта килеш-килбәте, хәтта какчалыгы белән дә президент Рузвельтка охшаган мәһабәт, үзенчә ифрат дәрәҗәдә укымышлы, зыялы бу кешенең һәр иртәдә ничек кырынып азапланганын күрсәгез иде! Их, шул көндәлек кырынулар!.. Тагын да канга батып, ертылып бетәр микән? Тәүлек дигәндә, камыт энәсе шикелле эре, кыл кебек шыртлап торган сакалмыек баса да китә бит, шайтан алгыры! Тирән буразналар, сай ерымнар белән ермакланып беткән яңакларны, шундый ук өзлеккән, муртайган тиреле ияк асларын, бугаз тирәләрен, бигрәк тә берсе өстенә берсе менеп беткән җыерчыклы бугаз төере тәңгәлендәге каты кылны кыру аның өчен гүяки үз тәнеңне кайрак белән кайрау, телеңне аркылы тешләп, тау чарлагындагы җиз үлән, кылган кыру кебек авыр эшләрнең берсе иде. Менә ул әле дә, идән башын кимергән тычкан, кемнеңдер җиткән тырнаклар белән тупас киндер тукымасын тырнаган авазлар чыгарып, кырына башлады. Кайчагында ул эченнән генә, шаярып, көн саен болай газапланганчы, елына бер тапкыр бала табып карауны җиңелрәк түгел микән, дип уйлап көлемсерәп тә куя...

Шулай ук сүзсез генә чәй эчтеләр алар — өйдә иреннәрнең чынаяк читендәге чепелдәүләре генә ишетелә иде. Күп сүзне гомумән җене сөймәгән Гарифулласына Өммегөлсем карчык чәен яңарткан арада сирпеп кенә карап ала алуын — бу караште һаман да шул бер өмет, бер теләк, бер гозер яшерелгән: хәтереннән чыгармаганмы кичәге вәгъдә-иманын аның картыкае?!

Белә, Гарифулла сүзне үзе башламаячак. Чәйне тәмамлап, тирән табакта шылтырдатып чынаяклар чайкаштырган Өммегөлсем карчык күкрәк төбеннән чыккан нәзберек, газаплы аһәң белән сорап куйды:

— Йә, карт, әйт соңгы сүзеңне... Кузгалабызмы?

Гарифулланың кырынганнан соң ике урынына гәзит кисәге ябыштырылган йөзе буйлап бугалак төеннәр йөгереште, күзләре яшәреп китеп очкынланды.

— Сөйләшкән идек бит инде, Гөлсем, — диде кырыс кына.

«Өмме»ләрен кыскартып ташлап, ул аны шулай Гөлсем дип кенә йөртә. Карчыкның эченә җылы йөгерде.

— Әзерләник алайса...

— Әзерлән, бәй.

Мәсьәләнең болай җиңел хәл ителүеннән Өммегөлсемнең куллары үзләрен тыңламас булып бәлҗерәп төште. Ул мич арасына керде, калтырана-калтырана кичә үк әзерләп куйган төенчеген яңадан актара, казына башлады — аңа кирәк була-

чак бирәр нәмәстәкәен онытмаганмы, Илаһым? Ул аның өчен бары тик зур хәрефтән әйтелә һәм языла торган УЛ, АҢА, АНЫ, АНЫҢ иде. Аһ, дисбесе онытыла язган түгелме?

— Җилгә җиләнләп, бозга бозаулап йөрергә вакыт юк, — диде киенеп тә беткән карт. — Кичкә әйләнеп кайтырга кирәк. Йорт-җир күз-колаксыз кала. Юлныкын белмәссең, бер-бер хәл булса, балаларга да әйтеп куймадык аны, югыйсә…

— Булмас, карт, булмас… Дөбер-шатыр әйләнеп кайтырбыз, Ходай кушса…

Озак та үтми, өстенә маршал Брежнев заманнарында ук тегелгән, якасына тимер әчесе чыгып күгәргән ике Бөек Ватан сугышы ордены беркетелгән, сирәк кулланудан бераз накыслана, тарая төшкән куе зәңгәрсу пинжәк, башына эчтән түбәтәйле ак салам эшләпә кигән, сары путаллы таякка таянып адым бирәмтекләгән җитмеш сигез яшьлек Гарифулла карт, аның артыннан эре чәчәкле яшел-зәңгәр кәшемир яулыгы, яшькелт озын күлмәге, шундый ук яшькелт бәйләм кофтасы белән әллә кайлардан күренеп, кулындагы төенчеген җилли-җилли атлаган җитмеш биш яшьлек Өммегөлсем карчык тәүдә ике чакматаш бөртеге булып тыкрыктан яктырып, аннан, үзәк урамнан, яшелле-зәңгәрле ике йолдыз сыман зурайганнан-зурая барып, Шатман очындагы автобус тукталышына якынлашып киләләр иде…

## II

Бәләбәй — Бөгелмә калкулыклары…

Җир асты сулары урталай бүленеп, чишмә-елгалар калкулыкларның иң биек тәңгәлләрендә ярала, бары тик көньяктан төньякка, төньяктан көньякка гына ага бу тирәләрдә. Автобус тәрәзәләрендә койрыкка койрык, яурынга яурын тәңгәл килеп, Европаның кысан тигезлекләреннән Азиянең иркен далаларына, Азиянең иркен далаларыннан Европаның кысан тигезлекләренә таба ялларында ут ташыган ат-аргамаклар ташкыны сыман тау-калкулыкларның өзлексез чылбыры чаба… Җир шарының ниндидер меридианнары, экваторлары, калалары һәм салалары өчен Вакыт төшенчәсе төрле булган кебек, бу калкулыклар чылбыры өчен дә Вакыт бүленеше бердәм һәм котылгысыз бердәм иде…

Атлар чаба: үткәннән — киләчәккә, киләчәктән — үткәнгә…

Аһ, бу төбәк һавасының татлылыгы, суларының салкынлыгы!..

Кайчандыр кешелек таңында Алты Ай һәм Урхан-Йәнәсәй киңлекләреннән һау-һаулап чыгып, бормаланып аккан Иртешләр һәм Урал-таулар тезмәсе аша Европага ашкан, үзара ызгышта хөкем сөргән халыкларның бөек күчешен барлыкка китергән төрки-татарлар, шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй

кыяларында «Туган йирим — мәңгү бал!» дип, ташка чукып, кешелеккә бөек ядкарь язып калдырган төрки-татарлар, гасырлар аша шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй бишегеннән «ур-ра»лап чыгып, ярты дөньяны уратып, биләп алып, тарихы яңа гына борынлап килгән мәҗүси милләтләр һәм шивәләргә иман һәм дәүләтчелек бүләк иткән, Идел һәм Хәҗәр, Урта диңгез буйларындагы мәгъмүр шәһәрләре, Атлантидалары, фәст дисбеләре белән күккә очкан һәм су астына киткән төрки-татарлар, Эгей ярларына, кыйтгаларның бөек чукындыручылары — Рум башкисәрләре каршына басып, «Эһе-һе-һей!» кычкырып, мондый көчләү, мәйданнарда асу-кисүләргә чик куйган, кайчандыр шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй туңдыраларыннан Чукыт ярыматавы аша Америка лабылыкларына үтеп, әстәк, әнкә һәм рухи маябыз — мая мәдәниятләрен тудырган Атуалып — Ата Алып варислары — төрки-татарлар, кайдадыр Океания утрауларында төтенләп утырган Крәкәтау янартауларында яңа дәүләтләр барлыкка китереп, үзләре дәүләтсез калса да, юкка чыкмаган төрки-татар кавеменең ике гөнаһсыз баласы, төрки-татар капусының ике чакматаш йолдызы — Гарифулла карт һәм Өммегөлсем карчык, һәркайсы үз уен уйлап, Әкчин станцасына китеп бара...

Аларның фикер алышыр нәрсәләре күп булса да, бәхәсләшер нәрсәләре юк. Гарифулла белә һәм беркайчан да онытмый: аты булса — дилбегәсе кулда; түбәтәй ничек кенә күркәм һәм түгәрәк булмасын, аның астына шулай ук күркәм һәм түгәрәк баш кирәк. Өммегөлсем карчык та белә һәм беркайчан да исеннән чыгармый: һәр киемнең ата һәм ана каптырмасы була: ал тәгәрмәч кая тәгәрәсә, арт тәгәрмәч тә шуннан тәгәри...

## III

СССР да таркалды. Нибары өч кеше тарката алгач, димәк, аның үзен дә шул өч кенә кеше оештырган булмады микән?

Тукта, бу ел ничәнче ел соң әле? Мең тугыз йөз дә туксан бишенче диләр шикелле. Булмас ла... Ә ничек исән калган ул? Бәлки, ул үзе теге, чын Гарифулла түгелдер? Бәлки, чын Гарифулла инде әллә кайчан козгыннарга азык булгандыр? Бәлки, бүгенге Гарифулла ул нindидер икенче, җен алыштырган Гарифулладыр?

Карт ирексездән көлемсерәп куйды.

Бигрәк тә өзек, төсе-башы качкан, эче-карыны киселгән заманнарга туры килде шул аның гомер башы һәм, гомумән, язмышы! Октябрь түнтәрелеше көннәрендә дөньяга килеп, тәүдә авыл мәдрәсәсендә, әтисе Садретдин мәзиннән өч сыйныф сабак алганнан соң, яңа мәктәп ачабыз диеп, мәдрәсәне яптылар. Гарәп имлясы — искелек калдыгы, имеш. Шул мәктәпне көтеп, буразнага төшкән Гарифулла латинга күчкәндә

ундүрт яшендә иде инде. Күмәк хуҗалыклашу дигән убыр утының Өязе буйларына шактый соңлап тәгәрәп килеп җитүе нәтиҗәсендә микән, утызынчы еллар башы Гарифулла күңелендә чагыштырмача тыныч еллар булып калган. Гарәп имлясыннан латинга сикереп, яңа язманы үз укучылары — шул ук Гарифуллалар белән бергә сөргән-тырмалаган кичәге мөгаллимнәр кулында тагын өч сыйныфны ордым-бәрдем тәмамлагач, авылда инде ак карачкыга әверелә башлаган әтисенең киңәшен тотып, ул мыштым гына Бәләбәй укытучылар техникумына керә алды. Таныклыгының хәлиткеч бүлемтегенә шул ук әтисе хәстәре белән, күрәсең, «дин әһеле баласы» диеп түгел, ә «ярлы керәстиән» диеп язылган иде. Ул укырга кергән 1934 елны Садретдин мәзинне шул «халхуз дигәннәре»нә аеруча көчли, кул-аякларын бәйләп диярлек өстери башладылар. Ай саен салына башлаган салымны түләп өлгерә алмагач, аларның өенә кулындагы шомполын талчыбык сыман итек кунычына шапылдатып, Өтәләү Зариф, Ак Керфек Сөнгатуллалар килеп керде. Авылда гына түгел, бар тирә-якта бердәнбер булып, идәнгә беркетелгән «Зингер» тегү машинасын сайгагы-ние белән куптарып алып чыгып киттеләр. Авылның яңа хакимияте күптән түгел генә бөтен халыкны үз авызына каратып торган гаять дәрәҗәдә абруйлы Садретдин мәзин белән сүз көрәштерүдән качып, аның гаиләсенә, бигрәк тә хатыны — Мәүлидә абыстайга каныктылар. Әйе, техникумга урнашып кайткан төнгә каршы кичтә әнисе өйдә юк иде. «Кәнсәләргә мине түгел, һаман да шул әниеңне һәм Зәбих энекәшеңне алып киттеләр. Миңа күзгә чалынмаска куштылар», — диеп, әтисе балтасы суга төшкән кеше затында аптырап утыра иде. Гарифулла кәнсәләр ягына китте. Әнисе белән энесен утсыз-нисез бүлмәгә шартлатып бикләгәннәр һәм сак куйганнар иде. «Бар, юньле чакта югал, югыйсә үзеңне ябарга да күп сорамабыз». Төне буе шул кәнсәләр тирәсендә йөреп, ай янындагы якты йолдыз кебек таң аттырды Гарифулла. «Ай янында якты йолдыз, минем йолдызым гына, таң алдыннан ул да сүнә, калам ялгызым гына» дип җырланган халык сүзләренең мәгънәсен шактый аңлады ул төндә яшүсмер. Иртән, көтү куганда, аларны чыгардылар. Толымнары көмеш чулпылары белән бергә кисеп алынган, карашын җирдән күтәрергә оялган әнисе елап шешенгән һәм берничә дистә елга картайган иде. Ул чакта авыл һавасы шартлар чиккә җитеп кызды, анда төнге мунчаларда яндырылган изге китапларның әче сөреме йөзде, мең ел эчендә тупланган рухи байлык көн эчендә хәерче кулына калудан куркып, черү һәм юкка чыгу өчен каберлекләргә, базларга, алмагач төпләренә күмелде һәм еш кына ачык авызлы чормаларга менде...

Үзе җырчы, үзе шигырьче Гарифулла техникумның җан шифасына әверелде. Алар куйган тамашаларның исәбе-хисабы булды микән? «Зәңгәр шәл», «Галиябану», «Беренче театр», «Асылъяр», аннан тагынниндидер бер билгесез язучы Кадермәтнең «Дөрес алдакчы» дигән әсәре дә хәтердә калган. Бәләбәй төрмәсендә Туктаров атлы Казан артисты утыра икән дигән хәбәрне ишеткәч, җитәкчелеккә махсус хат язып, Туктаровны сак астында булса да репетиция һәм тамашаларга китертә алуга ирештеләр. Менә шул тамашалардан соң ике яктан да винтовка астында залдан чыкканда, режиссер күзләрендәге моңны күрсәгез иде! Исән түгел микән Туктаров абзый? Их, бер Казанга барып чыгып, балаларын булса да эзләп табарга иде... Кая ди инде ул?

Булачак җәмәгате Өммегөлсем белән дә шул сәхнәдә табышты ул. Көлгән чакта бит алмаларында сөйкем чокырлары ярала торган ифрат та матур тавышлы, теремек Шаран кызы Гарифулла укуын тәмамлыйсы елда кыска вакытлы курсларга килгән иде. «Галиябану»да алар Хәлил белән Галиябануны башкардылар. Тамаша алдыннан егет бик тә мәгънәле төш күрде: имеш, ул куенында карчыга баласы йөртә икән. Томшыгында хаты да бар, җитмәсә. Өйләнүгә юрады. Һәм ике яшь йөрәк, озын-озак уйлап тормыйча, уч төбендә генә яткан Шаранга кайтып, никах укыттылар да куйдылар. 1937 елның җәендә ике яшь укытучы Шатманга кайтып төште. Бер генә ел укытып өлгерделәр алар. Күк йөзендә болытлар куерганнан-куера иде. Менә авылда алтын-көмеш алка, чулпы, беләзек, хәтта җиз комган җыю, аларны ярыша-ярыша дәүләткә — Кызыл Армия фондына тапшыру галәмәте башланды. Ике йөз йортлык авылдан биксән биш җиз комган тапшырган Шатман тирә-якта беренче урынны яулады. Һаман колхозга кермәгән мәзин килене, өстәвенә комганын да тапшырмаган укытучы Өммегөлсемне педсоветта тикшерделәр. Районнан килгән мәгариф бүлеге вәкиле аның эштән куылу мөмкинлеге белән дә янап куйды.

Урак өсте иде. Садретдин мәзиннең Җилдәр авыл советында эшләгән чыбык оч туганы, кич караңгыда атын ак күбеккә батырып килеп керде һәм әтиләренең колагына нидер пышылдап, шундук юк булды. Гарифулла сизенде: күк йөзендә исән калган йолдызлар чатный иде. Әтисе гаиләне бер йодрыкка җыйды һәм куркыныч хәбәр җиткерде. Көтелмәгән чапкынчы аңа әйткән икән: «Садретдин абзый, бүген төнлә күзегез кая карый, шунда чыгып олагыгыз. Иртәгә барыгызны да кулга алачаклар».

Соңыннан сөйләвенчә, әтиләре бу хәлне көтеп йөргән булган икән. Мәчет манарасын кисеп төшерткән Өтәләү Зарифның йөзенә төкергән икән ул бер ай чамасы элек.

Киткән баш киткән дип, хатынының чулпылы толымнары, авылның җиз комганнары өчен шулай үч алган да куйган Садретдин мәзин.

Аларның йорты авыл очында — нәкъ ай янында якты йолдыз калка торган төштә иде. Әтисе әнисенә юлга төйнәлү өчен дүрт сәгать вакыт бирде. Ут сүндерелде. Унсигез яшьлек сеңлесе Рабига белән әнисе кулга нәрсә эләгә, зиһенгә ни килә, шуны җыештырына башлады; әтисе исә кулына ике үткен чалгы пычак, утсыз фонарь алып, Гарифулланы, килене Өммегөлсемне, унбиш яшьлек Зәбих энесен ияртеп, абзарга чыкты. Сукыр тычкан күзе сыман гына ут алынган фонарь, ниһаять, абзарның эчке почмагына эленде. Әтисе мөгезле эре терлек, кәҗә малы һәм бәрәннәргә кагылмады. Дүрт баш сарыкның авызларын бисмилла тастымаллары белән уратып, мекердәтми-мөгрәтмичә генә тыннары каткан алмагачлар аша мунча артына сөйрәттереп, берсе арты берсен чала, Гарифулла исә туный торды. Үткен пычак йөзләрен ай нурында ялтыратып хәләл малын чалган әтисенең: «Аллаһы әкбәр! Аллаһы әкбәр!» — дип пышылдаганы һәм аңардан да көчлерәк тыелып, ничектер пышылдап һәм сызгырып үләнгә шыбырдаган кан тавышы гына ишетелде. Иманлы тормышта гел көн яктысында, көндез чалынган корбан малының да хәтта үз сиземләве бар, күрәсең: төнлә, вакытсыз, кемнәндер качып суелган сарыкларның күзләре ай яктысында якут ташы кебек зәңгәрләнеп сөякләнгән иде. Әзер итнең юыласы Өммегөлсем куллары белән мунчада юылды, Зәбих куллары белән тозланып, чиста чүпрәк капчыкларга салынды. Тире-койкаларга әтиләре үзе тоз сипте һәм чыптага төреп, арбага салды. Кирәкләре чыгар. Эш тәмамланды дигәндә генә, ул тагын бер йола башкарды. Гарифулла моны беркайчан да онытмас: алмагач төбенә кечкенә чокыр казыды да суелган мал тоякларын, эчәк-карынын, йөрәк-бавырларын укына-укына чокырчыкның бер кырына төшерде, ә менә сарык башларының һәркайсын әле суынып та бетмәгән сөтле иреннәреннән үпкәндәй чупылдатып алып һәм кыйблага каратып, чокырчыкның икенче кырына ипләштерде һәм укына-укына күмде...

Абзарга кергән әниләре сөтле сыерын һәм башмагын калдырып китәсе килмәде:

— Мин бит аларга быел күпме алма ашаттым! Ярылып яткан алмалар! — дип пышылдады ул. — Алыйк, сиңа әйтәм... Үзе сөтле, үзе буаз да!..

— Тамакларына утырсын, бәдбәхетләрнең! — Садретдин мәзин хатынын утлы караш белән көйдереп алды. — Мондый хәтәр юлга мөгезле эре терлек белән чыгарга башыма тай типмәгән ләбаса!.. Чегән табырына бармыйбыздыр бит? Качып китсәң дә, чәчеп кит, дигән борынгылар!..

Сыерның саран яктыда тәгәрәп торган күзләре упкын кебек төпсез иде. Мәңгегә аерылуны сизеп елый иде, мескенкәй. Алъяпкыч чите белән сыер яшьләрен сөрткән әниләрен күреп, әтиләренең дә күңеле йомшарды булса кирәк, әмма аның сүзе сүз иде:

— Үзебез шырпы кабына кереп ятар мәлдә... Шул шырпы кабына сыер кадәр сыерны ничек сыйдырыйм мин?! Исәп белән баемаган халхуз усрак җылысы белән генә баемас!..

Әйе, шулай диде әтиләре. Гарифулланың үз гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр әтисе авызыннан ишеткән тупас, сүгенү сүзе шул булды.

Ниһаять, бурлы ат фурманга җигелде. Җылы, ямьле, җиһаз тулы өйләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган хуҗалар инде өшегән, күшеккән хәерчеләр, мөһаҗирләрне хәтерләтеп һәм бер-берсенә елышып, хәерле юл догасы кылды. Таң алдыннан, дөресрәге, сәгать өчтә, ала алган кадәр китапларын, малмөлкәтен, казанын-таганын төяп, арба артыннан абыстаен, өч баласын һәм киленен ияртеп, Садретдин мәзин кайчандыр үзе укыган Ырымбур тарафларына юлга чыкты. Ишеккә дә, капкага да, абзарга да бик салмадылар. Хәер, аларда йозак дигән нәрсә юк та иде.

Бүгенгедәй хәтерендә Гарифулланың, алар авылдан чыкканда, ай янында шул ук якты йолдыз иде.

— Атасы, атыңны беразга гына туктат әле, — диде әниләре, Ташлытауга күтәрелгәч. — Авыл, туган җир белән хушлашыйк. Без булмасак, балаларга, кайтып, үз нигезләребездә яшәргә насыйп итсен...

Таң сарысы белән чорналган алты җан иясе кыйблага тезләнеп, олы юл догасын укыды. Дога укый белмәгән бурлы атның шомрайган колаклары ай бөҗрасын тишеп кергән иде. Алар көндез туктап ял иткәндә, казан-казан ит пешереп, атналык, кояшлы һәм җиләс тәртә-дугада җилләтеп һәм киптереп, учакта ыслатып, тагы да ике атналык азык әзерләп, салкын чыклы төннәрдә сарык койкасы белән ябынып йоклап (соңыннан аңлавынча, урысның «койка, койкоместо» дигән сүзләре көне-төне далада яу чабып арыганнан соң, ябынып йоклый торган татар-монголның тире-койкасыннан чыккан икән), алар Илкүлмин, Илек, Каргалылар аша Ырымбурга, аннан казах далаларына юл тотты. Сәфәрнең егерменче көнендә купкан ком гарасаты гаиләне Чалкар дигән станцада туктатты...

Юк, аларны ком бураны түгел, ә аяусыз, кансыз язмыш туктаткан булып чыкты. Әгәр белгән булса, моннан ничек кенә булса да котылу — юлны дәвам итү өчен Гарифулла барлык чараларны күргән булыр иде. Әле төзелеп кенә яткан тимер юлдан атнасына нибары бер тапкыр үткән поездны көтеп акылдан шашкан мөһаҗирләр даирәсе — чегәннәр,

тегеннән-моннан җыелган качкалаклар, бохар ялкаулары, бушка килгән мал исен сизеп ябырылган әтрәгәләмнәр һәм алыпсатарлар, ата-анасыз калган ташландык балалар, бала-чагасыз кемсәләр, тагын да әллә нинди, әллә нинди кавем һәм шивәләр белән тулган Чалкар станцасы үзенә күрә яңа хакимият алып килгән нәҗәсәтлекнең, яшерен алыш-бирешнең һәм җинаятьчелекнең бер кабатланмас оясы иде. Атларын, сатарга мөмкин булган бар нәрсәләрен күпме бирсәләр, шул бәягә сатып өлгергән Гарифуллаларга — Ходай үзе сакласын! — үзләрен генә сатасы калды... Мондый куркыныч юк та түгел иде — әнә аларга дүртенче арба булып ияреп Ырымбурга кергән татар Гәрәй, мәсәлән, көннәрдән бер көнне үзенең унике яшьлек кызын бер казах баена егерме кадак арпа онына алыштырып кайткач, Садретдин мәзиннең, йөрәге ярсып, Гәрәйне каеш чыбыркы белән ярганы хәтердә:

— Йөзең кара! Оятсыз! Тәүбәгә кил! Нишләп без дә бала сатмыйбыз?!

Казах далаларында ак чебеннәр очып, кыш та якыная башлагач, һәм башка чара калмагач, муллалыгын яшергән әтиләре үзләре көн күргән зимләнке һәм тамак ялы хакына Чалкардагы казах баена, Гарифулла белән Өммегөлсем исә йөз егерме чакрымда яткан Җандыктагы Сөендек байга елына ун пот арпа һәм ике куй исәбенә куй көтәргә ялландылар. Көтүдәге куй — мең баш. Бүреләр — дала тулы. Син ялгыз. Их-х, андагы йокысыз төннәр һәм тынгысыз көннәр!..

Алар әйләнеп кайтканда, Чалкарда башка сыймас мәхшәр иде: урамнарда корсаклары күпкән, йөзләре шешенгән, күз чокырлары бет һәм эрен баскан үле һәм тере гәүдәләр аунап ята; тирәләрендә өер-өер күселәр кайнаша; һавада ниндидер сасы куыклар, селәгәй тамчылары очып йөри; шундый ук шешенгән һәм күзләре акаеп бетләгән, билгә кадәр шәрә калган бәндәләр, бер-берсен авызларыннан очкан мөһмәләт, төкерек белән агулап, корсаклары гөптәй, аяклары җептәй ниндидер шәүләләр, тимер башлы таяклар, чукмарлы камчылар, тимер чылбырлар белән коралланып алып, үзләрен-үзләре кыйный, кара канга туздырып җәзалый һәм, әллә нинди авазлар чыгарып, җир тырнап, мәйдан тирәли гү килә... Инде менә ничәнче ай котырган гөбән (ваба) чире җенен менә шулай куалар, имеш. Бу кадәр караңгылыкны һәм наданлыкны аңлатырга бер укымышлысы, бу чирдән дәваларга бер табибы булмаган даирәнең үләсе кешесе үлгән, үлмәгәннәре, украсын чабып тилергән башмак кебек, ярга очарга әзерләнә иде...

Чалкар читендәге җир белән тигез зимләнкене чак-чак таптылар Гарифуллалар. Эзләп тә таптылар, мәңге җуелмас кара кайгыларга да баттылар: сөекле энесе Зәбих һәм сеңлесе

Рабига гөбән чиреннән дөнья куеп, җирләр кешеләре булмагач, гәүдәләре «туганнар каберлеге» дигән чокырга ыргытылган; әти белән әниләре дә үлем хәлендә, әтиләре, җитмәсә, телсез иде...

— Без бу тәмуггтан ничек котылдык икән, Гөлсем? — Гарифулла карт янында утырып барган карчыгына карады. Гөлсем эндәшми. Гөлсем, телсез генә дисбе тартып, үз уйларын уйлый...

Урам дисәң урам, мәйдан дисәң мәйдан булмаган чарлак җирдә очраган бер табак битле төрекмән кардәш — рәхмәт төшкере! — шешәсеннән, голт-голт китереп, ниндидер саргылт сыекча салып бирде:

— Ич! Ечсан, ишин гайдар!*

Гарифулла аны ике дә уйламый эчеп җибәрде. Соңыннан белүенчә, спирт булган ул.

— Аелыңа да ичир! Мән унынтмасан!**

Эчерде аны Гарифулла Гөлсеменә дә. Ат сыман авызын шакарып эчерде.

Әтиләре аңына килә алмыйча җан тәслим кылды. Бераздан әниләре дә якты дөньяны ташлап китте. Шулай итеп, бер атна эчендә бер зимләнкедән ике мәет чыкты. Хәтерендә, үлем белән якалашкан телсез әтисе, нәрсәдер аңлатырга тырышып, биш бармагын күрсәтте — ни әйтергә теләде ул? Биш баласы кала дип аңлатырга тырышса — аның балалары өчәү генә, аларның да икесе кабердә иде... Нәрсә, нәселебезне ишәйтегез, бишне иш итегез, дияргә ымсындымы, мәрхүмкәй? Әниләре үз аңы белән үлсә дә, сөйләшә алмады. Телен чак әйләндереп, ул бер генә сүзне кабатлый иде:

— Кайтырга... тырышыгыз... Кайтырга ты...ры... шы... гыз...

Шулай итеп, көтелмәгән Чалкарда өч кабердә дүрт мәет калдырып, кырыгынчы елның яңа ел башында ачык платформада Урта Азиягә чыгып сыза алдылар. Соңыннан, аеруча сугышта, Гарифулла үлемне күп күрде, әмма бер генә үлем дә аның күңелендә әти-әнисе үлеме кебек аңлашылмас дәрәҗәдә сәер тойгы калдырмады: ул бу үлемгә ышанмый, аның хакында уйлый алмый, уйлый алган хәлдә акылдан язар кебек иде. Вакыйгаларга илле җиденче ел китеп барса да, Гарифулла һаман да шул халәттә — ата-ана үлеменә ышанмау, башына сыймау сәерлеген ул бары тик чиксез ярату белән аңлатырга тырыша. «Без чынлап та исәнме ул?» дигәндәй, ул тагын да карчыгына карап алды. Гөлсеме исә күзләрен йомган да, ике кулы белән дисбесен берәмтекләп, авыз эченнән нәрсәдер укына...

Сәмәркандта көткән кешеләре юк иде. Бер рәхимле үзбәк-

---

* Эч! Эчмәсәң, бетәсең! *(Төрекмәнчә.)*

** Хатыныңа да эчер! Мине онытмассың! *(Төрекмәнчә.)*

кә тап килеп, ул яшьләрне үзенә сыендырды. Өстәвенә үзбәк мәктәбенә мөгаллимнәр итеп тә урнаштырды. Ләкин бу бәхет озакка бармады, Гарифулланы хәрби хезмәткә алдылар һәм, укыган кеше буларак, Томскидагы хәрби училищега курсант итеп җибәрделәр...

Автобус Дим елгасын кичеп, юл зур татар авылы Никифордан соң кисәк кенә уңга борылгач, Гарифулла уйларыннан арынып, өлгереп килгән иген басулары, үркәч-үркәч тауларга, Дим ярларына сипләнеп йөгергән әрәмәләргә сокланып барды. Барысы тере, барысы үзенеке... Игеннәргә аеруча куанды Гарифулла. Кызык, әкәмәт җәй булды быел: кәккүк кычкыра да яңгыр ява, кәккүк кычкыра да яңгыр ява. Менә соңгы көннәрдә генә бераз корытты һава. Әйтерсең кояш таздагы сабый кебек чәптер-чөптер килеп коена да, йөгереп чыгып, тымызык һавада кәккүкләрен кычкырта-кычкырта тагын да кыздыра башлый...

— Игеннәр саргая, — диде Гарифулласыннан күреп тирәякны күздән кичереп барган Өммегөлсем. — Саргаялар...

— Саргаялар... — диде Гарифулла. — Әле агарасылары бар...

Бу аларның җитмеш чакрымлык Шатман — Әкчин юлында сөйләшкән бердәнбер сүзләре булды.

...Укулар ни сәбәпледер бик нык кыскартылып, курсантлардан ашык-пошык кече офицер әвәләп, Гарифулланы Алма-Атадагы яңа хәрби училищега укытучы-тылмач итеп җибәрделәр.

— Сез әле һаман коммунист түгел? — диде аны үзенә чакыртып алган политбүлек начальнигы Бема. — Сез нигә партиягә кермисез? — Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Комиссар, күзләрен чекерәйтеп, кичә генә офицер таныклыгы алган курсантка текәлде: — Ә?

— Бу хакта уйланганым юк иде әле, — диде Гарифулла тыйнак кына.

— Эрәзве бу хакта уйланмаска мөмкин?! Үсәсегез, чиннан чинга күтәреләсегез килмимени? — Бема алдында яткан исемлектән Гарифулланың фамилиясен эзләп тапты. — ...Гарифулла... Садретдинович?! — Әтисенең исемен шундый зур хәрби авызыннан ишетеп, ул кара тиргә төште. — Юк, артык хафаланмагыз, барысы да тәртиптә. Мин болай гына, сыйнфый иминлек дигән нәрсәдән чыгып кына... Әйе, сезнең әле һаман коммунист булмавыгыз безне бераз сагайта төшсә дә, ышаныч күрсәтеп, сезне Алма-Атага җибәрергә булдык. Көнчыгыш халыкларыннан — мин беренче чиратта казахлар, үзбәкләр, төрекмәннәр, кыргызлар... эээ, тагын кемнәр әле анда... каракалпакларны күз уңында тотам — хәрби кадрлар аз. Алардан совет властена лояль булган катлам тудыру —

стратегик бурыч. Сез, татарлар, гомер буе урыс идеясен көнчыгышка илткән укымышлы, ышанычлы, тылмач халык... Ә болар, наданнар, урыс боерыкларын һич кенә дә аңламый һәм аңларга да теләми. Где солома, где сено, ә? — Ул авыз читен чалышайтып көлемсерәде. — Сезнең бурыч: хәрби фәнне, урыс командаларын үз телләрендә аңлатып, совет офицерлары үстерү...

Алма-Атада эшкә башлап, хатынын үз янына алдырам дип йөргән көннәрдә генә сугыш башланып китте. Август азагында, Гарифулланы хәрәкәттәге армиягә озатырга дип, Өммегөлсем үзе дә килә алды. Фронтка ул панфиловчылар белән бер эшелонда барды. Гарифуллалар дивизиясе, Воронежга чигенеп, шәһәрне дошманга сугышсыз бирде. Беленькая дигән авыл янында яраланып, Мичуринскида өч ай госпитальдә ятып чыкты. Бот битендәге сум итне кәтәлүк сыярлык итеп умырып алган ярчык сөякне зарарсыз калдырган иде. Икенче кат яралануында дошман тырнагына капты. 1943 елның февралендә, Гродно янындагы концлагерьда, ит комбинатында төнге смена вакытында Талип дигән Буа татары белән ташланырга әзерләнгән мал эчәгесе, карын тизәге эченә башларына капчык киеп кереп ятып, боз булып туңдылар һәм, ниһаять, чокырга бушатылдылар. Хәтерли Гарифулла, алар әсирлектән котыласы төндә дә ай янында якты йолдыз иде. Әйе, якты йолдыз аларны ташламады: өч көн буе кышкы урман эчендә, эзсез-сукмаксыз, азыксыз-сусыз куырылганнан соң, бер авылга тап булып, урам очындагы йорт тәрәзәсен шакыдылар алар. Ышансаң ышан, ышанмасаң ышанма: соңыннан белүенчә, Гродно тирәсендә таралып яткан дистәләгән татар авылларының берсе — Якубовичи булып чыкты ул. Анда яшәгән кешеләрнең барысының да фамилиясе Якубович иде. Урысча, белорусча, хәтта ләхчә яхшы сөйләшкән, әмма татарча бер сүз белмәгән, шулай да биш вакыт намазларын калдырмаган Сәлмән һәм Мәрьям Якубовичлар соңгы чиккә җиткән ике әсир милләттәшләрен аякка бастыру өчен барысын да эшләделәр. Их, барып чыгарга иде шул якларга... Кая ди инде ул. Соңыннан татар авылларын Гарифулла Вильнюс тирәсендә дә, ләх, румын, болгар җирләрендә дә очратты. Әмма аларның берсенә дә Гродно өлкәсендәге татар авылына аптыраган кебек аптырамады.

Аерылганда Якубовичлар елап калды. Аларның кылган догалары ярдәм иткәндер, күрәсең, юлсыз калын урманнар, ялан-кырлар аша бер ай чамасы җик күргәннән соң, Гарифулла белән Талип, фронт сызыгын исән-имин үтеп, үзебезнекеләргә кушыла алды. Ике сәгать үттеме-юкмы, «үзебезнекеләргә кушыла алган үзебезнекеләрне үзебезнекеләр», атап әйткәндә, армия контрразведкасы капитаны Енушкевич кулга

алды һәм ике атна буе фашистлар да сава алмаган эчәгеләрне сауды: «Кем сез? Документларыгыз кая?» Исән түгел микән аның михнәттәше Талип Сибгатуллин? Их, барып кайтырга иде Буа якларына... Кая ди инде ул?

Лейтенанттан рядовойга төшкән һәм рядовойдан өлкән сержантка күтәрелгән Гарифулла Аппаков сугышны Мекленбургта тәмамлады. Җиңүдән соң да ике ел ярым буе солдат сукасын тарткан фронтовик туган Шатманына 1947 елның ноябрендә генә кайтып керә алды. Аның бик тә укытасы килә иде. Мәгариф бүлегендә барысын да искә төшерделәр. Сугышта кан кою, әлбәттә, изге нәрсә... тик менә... тс-с!.. авылдан качып киткән мәзин малаена, хәрби әсиргә ничек итеп балалар тәрбияләү эшен йөкләргә мөмкин? Аның чәчләре сугышта түгел, унбиш минут эчендә мәгариф бүлегендә агарды. Әйе, нишлисең, аңа балаларга төрки һуннар турында да, су астына киткән төрки Атлантида, фәст дисбесе турында да, Америка төркиләре әнкә, әстәк һәм мая халыклары турында да мәгълүмат бирергә насыйп итмәде...

Тәмам җен ачуы чыккан Гарифулла, уңга-сулга карамый, иң авыр эшкә алынды — ун ел буе Җилдәр белән Шатман арасындагы Актаудан акбур ташы чыгаручы, аннан яшелчәчеләр бригадиры булып эшләде. Олауларда, соңрак машиналарда ул озаткан акбур коммунизмның ничәмә-ничә бөек төзелешен агартты икән? Агартты микән? Болай да акбаш Гарифулла эшеннән тегермәнче кебек бөтенләй агарып кайта иде. Авыл башына килеп керү белән, бала-чага уратып ала һәм озата бара:

— Ак бабай килә! Ак бабай килә!..

Менә егерме елга якын инде ул хаклы, үзе әйтмешли, таяклы ялда.

Ул кайтканда авылда икенче кампания — татар авылын сарыкчылык, атчылык һәм кошчылыктан коткарып, дуңгызчылыкка күчерү бара иде. Аларның алты почмаклы иркен өйләрен бар тирәне сасытып, мыркылдатып ята торган дуңгыз фермасына күчерткәннәр. Гарифулла иске урынга, Җилдәр ак ташын шакмаклап кисеп, авылда беренче таш йорт бетерде. Үлеме алдыннан әтисе ишарәләгән биш бармакны васыять дип кабул итеп, Гөлсеме белән шул нигездә биш бала үстерделәр. Өчесе үзләре белән авылда, икесе Уфада. Барысы да гаиләлеләр. Әле яңа гына шәһәрдәге улының кызы, кызының улы аларда кунак булып киттеләр. Татарча белмиләр. Әтиәниләрен әйтер идең... Әмма үз балаларың бит, димәк, төшендерү, сеңдерү җитмәгән. «Мәктәп, балалар бакчасы гаепле», имеш. Сәбәп эзлиләр. Урыстан күреп, татар да сәбәп эзләргә өйрәнде. Үз балаңа туган телеңне дә бүләк итә алмау җинаятен нинди сәбәпләр белән аңлатырга мөмкин? Ул шәһәр

сабыйлары белән кызык та, кызганыч та. Гөлсемгә алар «абика» диләр. «Мин сезгә әбикә түгел, картәни!» — дигән була да бит тегесе, әмма сорау әзер: «А что это такое картани?» Шулай беркөнне кызчыкка карт әнисенең утызынчы еллардан сакланып калган алка-беләзекләре бик ошаган икән. «Дай мне!» дә «Дай мне!» ди бит бу. «Мин үлгәч алырсың», — ди картәнисе. Гарифулла исә — тәрҗемәче. «А когда она умрет?» — ди бит, күзен дә йоммый! Икенче бер көнне, оныгын ияртеп, ике сарыгы һәм ике кәҗәсе өчен чираттан көтүгә чыкты Гарифулла. Күрә, Әхмәтгалинең азгын сыеры басуга кереп бара. «Бар әле, — ди Гарифулла. — Анауы сыерны борып кил!» «Который сыер?» —ди бу. Сыер инде, башкаларын да ияртеп, басуга кереп тә китте. «Анаусын, — ди Гарифулла. — Койрыксызын». «А что такое койрык?» Менә сиңа мә! Аптырагач, кулындагы чыбыркы сабыннан артына койрык ясап, сикереп күрсәтте Гарифулла: «Вот так, сикерт-сикерт!»

Алла дигән, иман дигән инануны җаннан гына түгел, каннан да кысрыклап чыгарырга тырышсалар да, гыйфритләр аны тынычта һәм сугышта намазсыз итсә дә, имансыз итә алмадылар. Әйе, көне-төне гыйбадәттә булып та кеше үтерергә мөмкин. Һәм үтерәләр дә. Син соңгы вакыйгалар — бүшнә һәм чечен мөселманнарының хәлен генә кара. «Йа Хода, нинди яшерен көчләр кырдыра бөтен дөнья күз алдында бу мөселман өммәтен? — дип газапланды авыл «мажигы» булса да, бик күп китаплар, Рум империясе тарихларына кадәр укыган җаныя интеллигент Гарифулла. — Кем кулы уйный монда? Носраниларны мөселманга католик Америка, католик Ватикан котыртамы? Румның яһүдиләргә каршы башлаган урта гасырлар инквизициясе, инде яһүдиләрнең үзләре тарафыннан уйлап чыгарылмадымы микән бу нииндидер мөселман фундаментализмы?..»

Автобус урман эченнән үргә күтәрелеп, яңадан ачыклыкка чыккач, ерактан электровоз кычкыртты. Өммегөлсем карчык дертләп куйды. Менә алар әле генә җәелеп, агарырга да өлгермәгән кап-кара яшь асфальт мәйданга, нәкъ вокзал каршына килеп туктадылар. Алда, ишек катында утырсалар да, урыннарыннан дәррәү кубарылган яшьләрне алар алдан үткәрделәр һәм иплән, сакланып, чиркланып кына чиста асфальтка бастылар.

— Сәгать ничә, Гарифулла?

— Ун, — диде Гарифулла, Җиңүнең илле еллыгы уңаеннан бирелгән бүләк сәгатен карап.

— Әйбәт. Бик әйбәт. Теге чакта да җомга һәм нәкъ иртәнге ун иде...

Өммегөлсем карчык көнен белә иде: бүген, чынлап та, җомга иде һәм ул әллә кайчан билгеләнгән иде.

Башка мәшәкатьләре, керер кешеләре булмагач, алар перронга күтәрелделәр. Һәм барыр юллары шунда тәмамланып, шып туктадылар. Гарифулла карчыгын ашыктырмаска, юк-бар кыбырсу сораулар белән борчымаска карар итте. Үзе монда алып килде, үзе йөретсен.

— Сиңа әйтәм, — диде һаман һушына килә алмый басып торган Өммегөлсем. — Багзалы шул ук иске күренә... Аешмыйчарак торам — Уфа кайсы тарафта да, Кинәле кайсы тарафта?

— Һы, — диде Гарифулла, илле ике ел зур юлларга чыкмаган карчыгының зиһенсезлегенә чын-чыннан аптыраган булып. Аннан куллары белән ишарәләде: — Монда — Уфа, монда — Кинәле!..

— Әйдә, менә шушыннанрак чыгып карыйк әле...

Алар, составлар үтми-сүтми торган арада, чуен юллар аша аргы якка үттеләр. Мәтрүшкә кебек яшелле-зәңгәр карчык алдан китте. Шулай тиеш иде. Сукмак аларны чуен юлыннан илле-алтмыш адымнарда төзелгән авыл йортлары каршына алып чыкты.

— Монда элек буш җирләр иде... Үзенең уңны-сулны аера башлавына чиксез куанган Өммегөлсем карчык сүзгә юмартланып китте. — Ничек кенәләр бөтәеп киткән Әкчин, ә? Буш урында авыл диген, ә?

— Без эзләгән урынны табу шикле инде, болай булгач, — диде Гарифулла, адымнан адымга җаны ярсый барган Гөлсемен тынычландырырга тырышып. — Шул тирәне чамалый алсаң да ярар...

— Бәй, син тагы... Үз алтынымны күмгән төшне дә тапмагач, адәм тәганәсе булам түгелме соң мин? — диде карчык, кыбырсып. Тараф төшенчәсен югалтса да, саф акылындагы Өммегөлсем нәкъ шул төшне, нәкъ шул урынны, нәкъ шул аршын җирне табарына ышана иде булса кирәк. — Урман сыман нәмәстә бар иде дә бит... Каеннар, пар каеннар бар иде... Әллә күзләрем күрми, әллә төпләгәннәр... Анавында тыкрык сыман ара шәйләнә түгелме?

Карчык Гарифулласын җилтерәтә салып шул тарафка алып китте.

— Урман ишарәте бар иде... Пар каеннар бар иде...

Аларга яшь кенә, сипкелле битле бер чуар хатын очрады.

— Сеңлем, — диде карчык, аны туктатып. — Бу авыл... күптәнме?

— Күптәнме, дип... Мин монда туып үстем инде. Бер утыз-кырык ел булыр...

— И-и-и, рәхмәт төшкере... Син, сеңлем, үзебезнең татар кызы да икәнсең... — Өммегөлсемнең күңеле күтәрелеп китте. — Соң, монда кемнәр яши — татарлармы, урысلармы?

— Татарлар! — диде җавабында чуар хатын, атлый башлап. — Арабызда урыслар да бар, әлбәттә...

— Мөселман зираты бармы соң? — дип кычкырып өлгерде карчык.

— Белмим, әби! — Хатынның җавабын инде җилләр генә алып килде. — Бар шикелле!..

Ничек кенә булмасын, куанычы чиксез иде Өммегөлсемнең. Аның Тансыгы — йөрәк алтыны — мөселман җирендә, мөселман куенында — иманлы төбәктә йоклый икән...

## IV

...Өч ел бала тапмады Өммегөлсем. Түземсезлек белән бала көткән ирен бәхетсез итәрмен микәнни, дип, эчтән сызып, үзе уйлавынча, каралардан коелып йөрегәндә ул, ниһаять, көмәнле булды. Гарифулла бу шатлыклы хәбәрне белеп китте. Сөенече аңлатырлык идеме — әгәр сугыш яланнарында ятып калса, аның нәселе дәвам итәчәк. Садретдиннең бердәнбер оныгы, онычкасы булачак бит ул. Әгәр ул ир бала да булып куйса? Гарифулласы, яраланып, Мичурин каласы госпиталендә ятканда, Өммегөлсем 1942 елның 19 апрелендә дөньяга исән-имин, бар әгъзалары да сау-сәламәт ир бала табуы, корбан ашы үткәреп, алдан сөйләшкәненчә, Тансык исеме кушуы турында хәбәр итеп өлгергән иде аңа. «*Тансыкны сакла, Гөлсем,* — дип язган иде җавап хатында Гарифулла. — *Сугыш хәлен белеп булмый, әгәр һәлак булып куйсам, Тансык улыма васыятем шул: авылыбыздагы туган нигезебезне ничек кенә булса да сүндермәсен, яңадан тергезсен иде. Мөмкинлек туу белән авылга кайтыгыз. Илдә чыпчык та үлми. Анда туган-тумача да җитәрлек әле, ярдәмнәреннән ташламаслар...*

*Тансык улымның туу хәбәре мине бик тә әсәрләндерде. Шигырьгә һәвәслегем булса да, Бәләбәйдән соң кулыма каләм алганым юк иде. Менә монда бер бәет ише нәрсә күңелемнән кәгазьгә түгелде...*

*Укыгыз бәнем яуда язган сүзебезне,*
*Күргән кебек булырсыгыз үзебезне.*
*Менгән атым җирән түгел, шомырт-кара,*
*Яурынында мылтык-кылыч ялтырап бара.*
*Килеп җиттек Донец дигән су буена,*
*Гаҗизләндем сугышның ык булуына.*
*Дошманнарның туплары бик ерак ала,*
*Ерак ала, төшкән җирдә чокыр кала.*
*Сайрый былбыл, сайрый аккош бу җирләрдә,*
*Җөмлә агач яфрак яра тугайларда.*
*Кайтыр көнем булса икән туган илгә,*
*Хәсрәтләрем барчасы да бетәр имди...*»

Кая ди ул заманда хатын-кызга хәзерге кебек еллар буе

өйдә утырып бала үстерү бәхете? Ике атна үттеме-юкмы, Тансыкны үзе фатирда яшәгән үзбәк хатыны карамагына калдырып, эшкә дә чыкты. 1942 елның декабрендә Гарифулласының хәбәрсез югалуы турында хәбәр килде. Өммегөлсем өчен кояш сүнде. Елгалар корыды. Үләннәр кара көйде. Аның бердәнбер өмете, юанычы булып әтисенең йөзен дә күрмәгән Тансыгы калды. Үләннәр кебек үзе дә киптекорыды Өммегөлсем. Төннәрен елый-елый шешенеп бетә дә, иртәсен йөзе, маңгаендагы җыерчыкларын җылымса су белән тигезләп, эшенә йөгерә. Шулай очны очка ялгап яшәп ятканда, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, хатын-кызны гына эзәрлекли торган бер афәт килеп чыкты — яшь, эшчән, көче-дәрте ташып, чибәрлеге әллә кайлардан күзгә бәрелеп торган һәм, хәзер инде күпләр уйлавынча, тол хатынга үзбәк ирләре тәмам юл бирми башлады. Алар бит Рәсәй тарафларыннан килгән хатын-кызга аеруча каныгалар, күзләрен тоҗырайталар да, кайда мөмкин, шунда тозак куеп, эзәрлекләргә тотыналар һәм еш кына үзләренең түбән ләззәтләренә ирешмичә туктамыйлар. Авыр кабул итсәләр итәрләр, инде дистә еллар аша шунысын да әйтми калдыралмый Өммегөлсем: үзбәк өчен хатын-кыз чүпрәк-чапрактан да ваграк мәсьәлә. Җитмәсә, мәктәп директоры, сөйләүләре буенча, бакыш* төртеп, фронттан котылып калган Абдулло әкә аңа тәмам тынгы бирми башлады. Үзбәк өчен түрә хакы — Тәңре хакы. Бер яклаучысыз калып, намусын күз карасыдай саклаган хатынны үзенеке итү өчен нинди генә түбәнлекләргә бармады ул, кабахәт җан. Эшеннән куу белән яный башлады. Фатирыннан сөреп чыгару белән куркытты, мөртәт. Кая, кемгә барып егылырга? Эч серләреңне кемгә бушатырга? Чит җирнең кечке шәфәгы, иртәнге таңы биздерә башлады. Совет иле киң дә бит ул, әмма басып торыр, яшәп торыр урынны гына күрсәтми иде ул Өммегөлсемгә. Гарифулласының васыятен үтәү ниятендә ул, ничек кенә булса да, Шатманга кайтып егылырга кирәк дигән фикергә килде. «Җәйгә кадәр түз, бала, Рәсәйдә әле бик тә салкын», — дип, фатир хуҗабикәсе еландай телен чыгарып ялынса да, бернәрсә дә тота алмады хатынны. Ул туган ягын сагынып ярсыган һәм үзен эзәрлекләгән адәмчекләргә карата нәфрәттә кайнаган иде. Әгәр Гарифулласының Шатманында кабул итмәсәләр, үзенең Ташлысына — әти-әнисенә кайтырмын, дип тә юанды ул.

Февраль урталары иде. Сатыласы әйбер-сәйбер ашык-пошык һәм ярты хакка сатылды. Моннан бер ай чамасы элек кенә кызамыктан көч-хәл белән котылган, инде хәзер тәненә ит утыртып, Гарифулласына охшап бит алмалары,

* Бакыш — ришвәт. *(Үзбәкчәдән.)*

иреннәре алланып-балланып үсә башлаган ун айлык Тансыгын һәм авылдан чыккан мәһәр савыты — фәнир сандыкка чүпрәк-чапрагын, бер сүз белән әйткәндә, таланудан калган кирәк-ярагын алып, ерак юлга чыкты. Кая ди ул вагонда утырып йоклап бару — мичкәдәге тозлы балык кебек шыплап тулган иде ул мосафирлар белән. Һавасы да ифрат тынчу, сасы һәм тозлы-тирле иде. Җитмәсә, юлга дип алган азыгын беренче көнне үк төенчеге-ние белән урладылар. Түзсә дә түзә икән адәм баласы: ун көн буе ач килде Өммегөлсем. Станца саен төшеп-менеп, алышынып торган юлчылар синең хәсрәтеңне аңлый аламы? Дөрес, юлдашлары аны ике мәртәбә ризыкландырдылар. Сатып алырга дисәң, ни вокзалларында, ни вагонында бернәрсә дә юк. Ун көн эчте ул кайнаган суны һәм аңлады: су туклыклы икән. Инде Тансыгы да азыксыз кала күрмәсен дип, күкрәгенең сөт бизләрен корытмас өчен дә мул эчте ул суны...

Әмма төп фаҗига азыксыз калуда түгел, бөтенләй икенче нәрсәдә иде. Сәфәрнең өченче көнендә үк кайнары күтәрелеп, эч китү белән чирләгән һәм мондый уңайсыз шартларда ананы чиксез җәфаларга, газаплы мәшәкатьләргә дучар иткән, бер гаепсез булып, шул гаепсезлеге белән әнисенә мең мәртәбә җаваплылык өстәгән Тансык күкрәк сөтен дә сорап бармады: мич кебек кызган, табада орлыктай куырылган, төсе качкан сабыйны һәр имезү үзе газапка әйләнде. Аның иреннәреннән гүяки ялкын ургыла һәм бу ялкын Өммегөлсемне вакытсыз юлга чыкканы өчен үкендереп, аяк табаннарыннан баш түбәсенә кадәр көйдереп ала иде. Дарулар һәм табиб эзләп, ана поездның бер башыннан икенче башына чапты, әмма табибы да, кирәкле даруы да табылмады. Соңгылары күп җыелды җыелуын, ләкин эч китүдән, кайнар хастадан гына юк иде. Машинист киңәшен тыңлап, берәр станцада төшеп калмаганына соңыннан бик тә үкенде Өммегөлсем, нишләптер төшеп калмады шул — күрәчәкләре шул булган, ахрысы. Тәнен кызгылт törткеләр, тимгелләр басып алган сабый күз алдында сула, сүнә иде... Мәскәү — Ташкент поездыннан Уфа тарафына китә торган Мәскәү — Чиләбе поездына күчеп утырачак Кинәле станцасына җитәрәк... кочагында тәмам хәрәкәтсез калган биләүне чишсә... инәкәйгенәм!.. аның Тансыгы, аның йөрәк парәсе, аның бөек һәм бердәнбер әсәре — ни күзләре белән күрсен!.. күзләре ачык килеш якты дөнья белән хушлашкан иде... Бөтен тәне аша үткән кара шаукым йөрәккә китереп сукты, акылыннан язар... аһ!.. үзбәк, марҗа хатыннары шикелле, фаҗигасен яшерми, ачыктан-ачык җир тырнап елар, поезд кадәр поездны туктатыр хәлдә дә һушын җыеп, авызын томалый алды Өммегөлсем. Ул, корама юрганга капланып, тавышсыз-тынсыз гына үкереп-үксеп елады. Һәр-

кемдә үз кайгысы гына булган юлчылар янәшәләрендә секунд эчендә булган фаҗигане сизмәделәр дә шикелле. Өммегөлсем аны сурәтли алмаслык түзем белән сиздермәде. Аптыраган, тәмам канатлары сүнгән ана, яшь каен чаукасы кебек сыгылып, үле баласын вагон бәдрәфенә алып кереп бикләнде һәм шашкан күзләр белән сабыйның кара көйгән иреннәренә авызын куеп тын өрә башлады:

— Китмә, Тансыгым... Китмә, Тансыгым!.. Китмә, алтыным!..

Әмма Тансык кайтмас җиргә киткән иде шул инде. Шул мизгелдә ана күкрәге сөтсез калды. Үзе тамактан язды. Бер тәүлеккә якын барды ул үле баласын кочаклаган һәм аны имезгән булып кыланып. Менә Кинәлегә дә төштеләр. Тәүлекләр буе поезд көтеп вокзал идәнендә аунаган юлчылар арасыннан үзенә сукмак хәстәрләп, туктаусыз йөренеп торды һәм бары тик унсигез сәгатьтән соң гына утырып китә алды. Аһ, андагы үле сабыйны күтәргән килеш кәмпәстиргә чират торулар!.. Шулай да юлның иң читен өлеше Кинәле белән Әкчин арасында булган икән: кышкы эшсезлектә Куйбышев каласыннан чуен казаннар, әлүмин савыт-саба ташып көн күргән алыпсатар татар хатыннары — өйдә ятимнәре көткән солдаткалар һәм нәселсез калган киленчәкләр, кыз-кыркын — матур корама юрганга төрелгән сабыйны күреп һәм хатын-кызга бигрәк тә якын бала исен сизеп, тәмам котырдылар: «Балаңны күрсәт!» тә «Балаңны күрсәт!», «Бер генә сөйдер!», имеш. Аннан: «Балаңны нигә имезмисең?» — дип теңкәгә тия, җәзалый башладылар. Монда да бер тәүлек буе диярлек вагонның бер башыннан икенче башына йөренеп торды. Хатын-кызлар үзара чышын-пышын килә башлады. Берсенең икенчесе колагына әйткәнен ачыктан-ачык ишетте Өммегөлсем: «Бимазаламагыз инде, акылга бер рәвешлерәк хатын күренә...»

Әкчиннән җитмеш чакрымда яткан Шатманга кышкы зәмһәрир суыкта, үле бала күтәреп, ничек кенәләр кайтып керергә мөмкин? Туганнары нәрсә әйтер? Кайткан-киткән кеше анда бит болай да тәүлекләр буе олау көтеп ята! Үз гомерендә бер генә тапкыр да булмаган, күзе күрмәгән Әкчиннән, олавы туры килгән хәлдә дә, ат адымы белән, юл уртасында кемгәдер куналар төшеп кайту өчен генә дә тагын ике тәүлек вакыт кирәк түгелме? Юрганга төрелгән сабый гәүдәсе дүрт тәүлек эчендә нишләр? Исләнеп, муртаеп бетмәсме? Бу әрвахлар рухын рәнҗетми, үз сәгатендә, хәтта ки ашыгып ләхеткә кертүне фарыз күргән мөселман кануны өстеннән, фәрештә килеш теге дөньяга китеп барган сабый хәтереннән көлү, адәм баласын җир куеныннан мәхрүм итү түгелме?

Өммегөлсем Тансыкны ничек кенә булса да Әкчиндә җирләргә карар итте. Иртәнге сәгать унда поездан чыкканда,

дөнья буран гарасатында йөзә иде. Бер кулы белән үле баласын, икенче кулы белән агач сандыгын күтәргән, күз ачкысыз буран караңгысына уралган һәм күзенә болай да ак-кара күренмәгән Өммегөлсем кая барырга белмичә, тегендә-монда сугылды да каршы очраган бер ападан зиратның кайда икәнлеген сорады. Ул марҗа булып чыкты. Барлы-юклы теле белән аңлата торгач, шунысы ачыкланды: Әкчин — урыс авылы икән, мөселман каберлеге юк икән, булган мөселманнар мәетләрне ун-унбиш чакрымда яткан Слак, Айдагол авыллары зиратларына җирли икән. Бу исә Өммегөлсемнең хәлен тагын да кискенләштерә иде һәм бу мөмкин дә түгел иде. Сабыйны кичке шәфәкъ сүнеп, кояш баеганчы җир куенына тапшырып өлгерергә кирәк. Көтмәгәндә генә башына гаярь фикер килде. Тукта, Өммегөлсем башы түнүдән уйлап та өлгермәгән түгелме: Әкчин мөселман авылы булмагач, теләсә кайсы төштә ул каберне кем казыр да, кем ясин чыгар?

Минутлар сәгатьләрдәй озын һәм газаплы тоелды. Ул шулчак кочагында боз булып суынган Тансыгының тавышын ишеткәндәй булды. «Әни җаным, җәфалама үзеңне, — диде аңа бу өзлеккән аваз. — Минем җаныя тән-шәрифләремне дә җәфалама. Син үзең ясин чыгып, җылы кабергә куйсаң, миңа җир йөзендә һәркайда да мөселман зираты булыр. Тик урынымны япа-яланнан сайлама. Якындарак урман, баш очымда агач булсын. Җәен шуның күләгәсендә син миңа Коръән чыгарсың...»

Өммегөлсемдә ниндидер кискен үзгәреш булды. Гүя ул шушы мизгелдән башлап баласы өчен ана да, ата да иде. Аңа иңнәренә кәйлә-көрәк күтәргән бер төркем хатын-кыз очрады. Ул җан ачуы, әллә нинди кыргый көч белән алга тартылды, бар булмышы белән хәзер, менә хәзер шартлаячак шартлаткычны хәтерләтеп, ашык-пошык сөйли, үз хәләтен аңлата башлады.

— Кая ди ул монда кешегә кабер казу? — диде араларыннан күмеләчәк мәетнең яшь ана кочагында икәнлеген башына да китермәгән бер татар хатыны. — Үзебезне чак йөретәбез, сеңелкәем! Эшебезне кара! — Ул иңендәге кәйләне чак кузгатып куйды. — Өйдә балаларыбыз ач утыра! Син ир-ат белән сөйләшеп кара инде...

Буран исә һәр такта киртеге, һәр тимер очы, һәр агач башында сыбызгы табып сызгыра, гүли, үкерә иде. Ике адымнан кешене малдан, малны кешедән аерып булмаслык бу гарасатта кулларындагы биләү баласы, такта сандыгы белән бер сәер сынны хәтерләткән Өммегөлсем авыл буйлап түбәнгә таба төшеп китте. Буранда йөзеп, алдына кемдер калкып чыкты.

— Татарлар кайсы йортта яши монда? — диде хатын, инәлеп, гүя ул хәер сорый иде. — Татарлар кайсы йортта яши?

— Татары, говоришь? — диде ир. — Вот по этой улице, слева крайний дом. Там Зулейка с Мухамметом живут…

Пәйгамбәребез Мөхәммәт хәзрәтләре һәм аның беренче хәләл җефете Зөләйха исемнәрен ишеткән Өммегөлсемнең эченә җылы йөгерде. Ул кочагындагы сабыйның үле икәнлеген онытып, сөеп куйды:

— Оештырырлар, Алла боерса… Безнең халык — оешкан халык… Бердәм халык… Ярдәм итми калмаслар…

Ул өйгә хуҗаларча ышаныч белән шакымый-нитми генә килеп керде. Алгы яктагы кырык яшьләр чамасындагы хатын көтелмәгән мосафирәгә бер аптыраса, ашыгып-ашыгып, аңлашылыр-аңлашылмас рәвештә, өстәвенә кеше ышанмас нәрсә турында сөйләгән хикәятенә ике тапкыр аптырады. Ул сүзсез генә түр якка үтте, кемгәдер пышын-пышын тәфсилли башлады…

— Берәр телем икмәк бир дә куып чыгар син аны, — диде эчке бүлмәдән ир тавышы. — Акылдан язгандыр ул. Татарча аңламаса, урысча аңлат. Сугыш заманы… Кем генә йөрмәс. Бәлки, ул нимес ышпиуныдыр?

— Мы не знай, — диде хатын, кире чыгып. Һәм икмәк савытында актарына башлады. — Ничауа не знай…

Икмәк савытыннан әле һаман кечкенәрәк телем эзләп маташкан хатынга кырт борылып урамга чыкканда, Өммегөлсем күзеннән сыгылып чыккан ачы яшь тамчысы тупса сайгагын көйдереп алды.

— Болар оешмаганнар, сабыем… — Ул Тансыгын туктаусыз сөя һәм аның белән сөйләшә иде. — Болар безнең халык түгел… Татарлар мондый булмас…

Ул кирегә борылды һәм сул рәттән мөселман санагычы буенча изге сан — җиденче йортка керергә булды. Иншалла, ярдәм итәрләр. Ярдәм иттермичә, ул шуннан чыкмаячак.

Капкасыз-нисез ихатага үтү белән, тәбәнәк кенә абзар эченнән ап-ак сакалы биленә кадәр төшкән карт күренде. Тырышып-тырмашып аңлата торгач, Никодим карт — исеме шулай икән — аны өенә алып керде. Мәсьәләне үзе төшенгән микъдарда әбисенә җиткергәч, тегесе, кулларын җәеп, үксеп елап җибәрде:

— О боже! Возможно же такое! И в такую ненастную погоду!..

— Не время плакать, Марфа, — диде карт чишенеп. — Надо людям помочь. Война всему счет ведет…

Өстәлдән әйберләр җыештырылды. Өммегөлсем, өстен салып ташлап, юрганны сүтте, аннан өшегән куллары белән биләүне чишеп, сабыйның туңа башлаган шәрә гәүдәсен күрү белән әллә нишләде. Чир һәм җан бирү газапларыннан котылган Тансык исә берни булмагандай елмаеп ята иде…

Үзен-үзе кулга алып, ул сандыгыннан ак җәймә суырып чыгарды һәм җәяр өчен өстәлгә кире килгәндә почмак үрендәге Изге Мәрьям ана кирәмәтен күреп, буынсыз калды, йомгак булып төенләнде һәм газиз баласының өстенә капланып, бу газаплы ун көн эчендә беренче тапкыр аналарча ләззәт белән елый, үкси башлады.

— Успокойся, кизим, — диде Никодим карт, үзе дә яшьләрен эчкә йотып. — Бог един... Мы его похороним по мусульманскому обычаю...

Марфа түти, мич арасына кереп китеп, мышык-мышык елый иде.

Кар белән катнашып авырайган, җепшегән җил ташкыны күтәреп алып китәрдәй булып өйгә китереп сукты, ул хәтта селкенеп куйды.

Өммегөлсем гүзәлләрдән гүзәл сабыеның зәңгәр тамчы гөлне хәтерләткән күзләрен ачып һәм ябып, күз кабакларын, колак бөгәлләрен, суыкта алсуланган бит алмаларын, иреннәрен йомшак куллары белән сыйпады, үпте, тагын үпте, алсу гөлдәй кечкенә иреннәрен кузгата биреп, үсеп өлгергән җәүһәрләрен — нәкъ унбер сөт тешен санап карагандай барлады, инде хәзер үзләреннән-үзләре кайнарланган бармак чуклары белән бөтен тәнне, барлык буыннарны исәннәр микән дигәндәй капшап чыкты, сөйде, үпте, тагын да сөйде, тагын да үпте һәм аңына килеп сорады:

— Сезнең монда кыйбла кайда икән?

Кыйбла дигәнне аңлаучы-белүче юк иде.

Өммегөлсем, Ходайга тапшырып, сабый гәүдәсен башы белән үзе фараз иткән кыйбла тарафына борды һәм өстенә ак җәймә япты. Марфа түтигә су җылытырга кушып, ана белән Никодим, кулларына кәйлә, көрәк алып, ихатадан чыкты.

— Эздис...

Хатынкай картны вокзал ягына тартты. Аның исәбенчә, санда алдашмас, яланда адашмас өчен, Тансык вокзал тирәсендәрәк җирләнергә тиеш. Бая, акылыннан шашып перронда йөргәндә, ул — әгәр буран күзне бумаган булса — чуен юлы аша, нәкъ вокзал каршында, ниндидер урман куелыгын хәтерләткән шәүләләрне дә шәйләп калган иде шикелле...

— Эздис...

Өстенә Марфа түтинең инде буран акшарлап та өлгергән сырмасын кигән Өммегөлсем, көньякның җиңел бутыйлары белән калын көрттә бата-чума, картны шул агачлыкка алып керде. Менә бит, Тансыгының колакка ишетелгән теләге тормышка аша түгелме — куш каен лабаса! Әйе, каеннар шул. Өммегөлсем өчен маяк, Тансыгы өчен сәхрә. Җитмәсә, ике-өч йөз адымда урман сыман нәрсә дә куерып торган кебек. Бәлки, ул чынлап та урмандыр? Хатын, кар ерып, куш каен һәм бер

төптә үскән өч каен арасын исәпләде — егерме биш адым иде. Куш каеннан биш адым алга атлады һәм туктап калды.

— Эздис... — Өммегөлсем, үксергә җитешеп, икенче тапкыр сорады: — Кыйбла эгде, кыйбла?

Карт аңламый иде.

Кыйбла сүзенең урысчасын белмәгән, Шатманда һәм Сәмәркандта кыйбла тарафын яхшы аерган Өммегөлсем, туган җиренең көтелмәгән хуҗабикәсе, Әкчиндә гүелдәп һәм ажгырып котырган буран эчендә иртәдән бирле кыйбласын табалмый газаплана иде.

— Что такое кибла? — дип сорады көрәгенә таянган карт.

— Кояш кайда?

— Кош, говоришь? — Никодим, аңларга тырышып, күзләрен челт-челт йомгалады. — Птица, что-ли?

Бәхетсезлегенә каршы, ул кояш сүзенең урысчасын белеп тә оныткан иде. Күк йөзендә кояш булмау, аны кара буран ятьмәләре каплаганлыктан көнчыгышны һәм көнбатышны аныклый алмаган хатын тилергән күзләре белән ак өермә аша күккә юнәлде:

— Кояш... Кояш... Син кайда?

— Луна, что ли? — Хатынга ярдәм итәргә тырышкан Никодим төпченүен дәвам итте.

— Нит... Нит! — Ул үрсәләнеп кычкыра иде. — Хлеб дилает! Вуда дилает! Дин дилает! Нуч дилает!

— Солнце, говоришь?

— Дә! Дә!..

— Она у нас отсюда выходит. — Никодим кулы белән төртеп күрсәтте.

— Ыспасибы, ыспасибы! Чичас...

Өммегөлсем җиде кат күк гөмбәзен тишеп чыгардай караш белән күккә төбәлде. Әллә күзенә күренде, әллә чынлап та шулай иде: баш түбәсендә котырынган карлы бөҗралар арасыннан ак салган башмак күзе сыман кызыл агарып ниндидер йомарлак шәйләнде. «Вакыт өйлә намазы чамасында бугай, — дип нәтиҗә ясады ул. — Димәк, көнчыгыш — бу тарафта, көнбатыш — бу тарафта, көньяк — бу тарафта. Көньяк тарафтан бер карыш уңга борылдың — кыйбла! Мәккәи Мәдинә!»

Ул кыйблага аркылы казылырга тиешле кабер урынын билгеләде.

— Эздис... Әссәламегаләйкем йә әхләл күбүр...*

Алар карны көрәп ыргыттылар. Өммегөлсем, телен аркылы тешләп, ач ана бүреләргә хас җан ачуы белән, җирнең өстәге туң катламын кимерә башлады. Йөрәкне телеп паровоз

* Сәлам сезгә, әй, кабер әһеле. *(Гарәпчәдән.)*

кычкыртты. Кыш салкын булса да, җир җылы, туфрак ике илледән дә тирәнрәк туңмаган булып чыкты. Кабер авызына актарылып төшкән буранда тирләп һәм пешеп, ике яктан җәһәтләгәч, эш тиз, җайлы барды — ике сәгать үттеме-юкмы, кабер әзер иде диярлек. Никодим да, Өммегөлсем дә үз гомерләрендә ләхет алган кешеләр түгел иде.

Сырмасын салып ташлап, Өммегөлсем кабергә сикереп төште.

— Ты что, дура, простудишься еще!..

Сабые гәүдәсе өчен иң җылы, иң иманлы уемның — ләхетнең нинди булырга тиешлеген үзенчә чамалап, үзенчә билгеләде. Аннан ләхетне алмаш-тилмәш уйдылар. Станцада тагын да паровоз кычкыртты.

Кабер әзер иде.

Марфа түти аларны сулар җылытып каршылады. Өммегөлсем сандыгыннан сабыйның авыз-борынын чистарту өчен актан-ак чүпрәк кисәкләре, исле сабын, Гарифулласының бүләге булган хушбуй, инә-җеп алды. Кан җылысы итеп кенә җылытылган суга һәм Никодим алып кергән сабый юылачак тактага хушбуй да бөркелгәч, моңа кадәр бүрәнәләренә арпа, чөгендер исе сеңгән өй эче затлы хуш ис белән тулды. Ул хәзер еламый, хәтта сәер дәрәҗәдә тыныч иде. Яше гүяки каядыр тирәнгә, кеше-кара күрми торган җиргә киткән егерме өч яшьлек хатын Марфа түти ярдәмендә үз гомерендә беренче тапкыр мәет юа башлады.

— Иляһи ният кыйлдым ахирәт госелен коендырмакка... Тәннәрен пакьләмәккә! — дип пышылдады ул. — Әшһәд әл лә иләлләһа әннәә мөхәммәдән гөбедөһү вә рәсулүһү...

Марфа түти кәфенлеккә ак тукыма эзләп урамга чыгарга дигәндә, Өммегөлсем аны туктатты:

— Нит, нит... Сбая... Сбая...

Үзенчә бөтен шартына китереп, ул сабыеның гәүдәсен кат-кат юды. Ак җәймәне кәфенлек итеп ике кат аска салды. Гарифулласы һәм үзе хакына. Сандыгындагы вак борчаклы чиста күлмәген сабыйга ахирәт күлмәге итеп киендерде. Җылыда яктырып, тәмам алсуланып киткән кадерле ит кисәге — йөрәк парәсен аста җәеп калдырылган кәфенлеккә кат-кат төрде. Бөркет күзе белән инәсенә җеп саплап, җеназага барганда сүтелеп, таралып китмәсен өчен кәфенне берничә урыннан типчеп чыкты. Никодим карт каяндыр табып керткән юкә кабыкны ислемай белән хушландырды. Кабык өстенә корама юрган, корама юрган өстенә мәетне аягы белән ишеккә таба каратып салды һәм, җил-буран керерлек урын калдырмыйча, илтифат белән төрде; болай да тын өйдә гүр тынлыгы урнашты; тешләрен кысып, бер омтылыш белән Марфа түтинең сырмасын киде һәм, мәет янына килеп, тагын дога кылды:

— Баламның гүр эчләре җылы, ләхет эчләре иманлы, урыны оҗмахта булсын! Ходай Тәгаләм, фәрештәңне кабул ит! Тәүбә, Ходай Тәгаләм! Үзең ярлыка!..

Кабыкка салынган гәүдәне күтәреп, култык астына кыска такталар да кыстырган Никодим карт белән Өммегөлсем яңадан буранның күгелҗем дәрьясына чумды. Вокзал тирәсенә җитәрәк давыл айкаган телеграф һәм электр чыбыклары бер-берсенә чорналып, җиргә тубал-тубал очкыннар чәчрәп төште. Кабер авызын, ике яклап өелгән кызыллы-кара балчыкны кар каплап өлгергән иде.

Өммегөлсем мәетне кабер белән янәшә, башы белән көнбатышка каратып урнаштырды. Баскан килеш кенә үзе белгән «Фатиха» һәм «Ясин» сүрәләрен укырга кереште...

Җил-давыл кабер төбенә үк төшеп айкала, ләхет авызларына кереп, курайларда уйный. Йөзләгән тальяннарда сызлыра, иңри, оркестр булып гүли, улый, ниндидер чатлы йолдыз сыман эре кар бөртекләре бөтерелә, уйнаклый, шунда ук давыл тагын үзенең җепшегән җилкәне белән аяктан егардай булып арттан китереп суга һәм бер мизгелгә ышыкка кергән кебек тынып кала; көрәгенә таянып, күзен йомган Никодим карт кайчандыр мең ел элек гарәп аргамаклары канатында Идел-Урал буйларына килеп, Евразия чикләрендә беренче булып караңгы, тупас, кыргый мәҗүси тормышны яктылык белән сугарган изге канун, мәңгелек рухият һәм кешелек моңын сугышта йөргән ике улы хакына багышлап тыңлый иде шикелле; туңган җир өсте, парланып яткан кызыл балчык, инде яңадан суынып барган сабый гәүдәсе, бураннарда чәбәләнгән күк гөмбәзе, якында гына үксегән паровозлар, кабер катында катып калган шушы ике адәм шәүләсе — бар тирә-як далада яңгыраган азан авазы белән төйнәлеп бәйләнде:

— Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!.. Әшһәдү әл лә илаһә иләлләһү! Аллаһу әкбәр!..

Өммегөлсем кабергә үзе төште. Кесәсенә кыстырып килгән «Һәфтияк» китабын бисмилла әйтеп улының башы ятачак күтәренке төшкә куйды, гәүдәне Никодим кулларыннан кабул итеп, ләхеткә урнаштырды, сул кырыена балчык түшәп, башын бераз гына кыйблага янтайтты һәм инде хәзер кәфенне яңадан ачып, улының нурлы йөзе, гаҗәеп сыны белән тагын бер генә тапкыр — соңгы тапкыр хушлашырга хокукы булмаганлыгын аңлап, ләхет авызыннан авырлык белән башын алды һәм кара җир куенында ак башак булып яткан Тансыгы өстенә капланды... Юк, ул еламый да, беркемгә, бернәрсәгә ялвармый да иде. Инде аның йөрәге җир өстеннән җир астына күчеп һәм колак пәрдәләрен ярырдай булып суга, дөпелдәп катламнарны яңгырата иде. Аның башыннан куркыныч уй үтте: «Әллә үземә дә шушында гына калыргамы?»

— Ты что-то долго, кизим, — диде югарыдан Никодим. — Пора выходить…

Кабер төбенә лапылдап такта кисәкләре төшеп ләпәште. Аларны ләхет авызын каплау өчен Никодим ташлый иде…

Кыл өзәрлек тә хәле калмаган Өммегөлсемне кабердән Никодим күтәреп диярлек чыгарды. Калганнарын ул юньләрәтле хәтерләми. Каберне кемнәр казыды һәм ничек итеп күмделәр? Өйгә кайчан һәм ничек кайттылар? Өммегөлсем алты төн һәм алты көн эссе табада кайнаган май шикелле куырылды, саташуыннан өн белән төш бергә буталды. Мең рәхмәтләр, Никодим абзый белән Марфа түти тәрбиясендә ул ун көн дигәндә аякка баса алды. Улының каберенә кабат-кабат барып, күңелен бушатты. Белгән догаларын, Коръән аятьләрен укыды, кабернең өстен рәтләп, язлар җиткәч килгәндә табуы җиңел булсын диеп, туң җиргә хәле барынча казык та төртеп куйды… Ниһаять, изгеләрдән изге күңелле хуҗаларына рәхмәтләр әйтеп, ул авылдан килгән олау белән Шатманга — Садретдин мәзиннең бертуган энесе Гайнетдиннәргә кайтып төште. Кире Шаранга китү уена алар якын да килмәде. «Кем белә, килен, — диделәр туганнары. — Бәлки, Гарифулла да кайтып төшәр. Соңыннан күз күрер. Әйдә, үзебездә яшәп тор — урын җитәрлек!»

Аны мәктәпкә эшкә алмадылар. Ул башта сарыкчылыкта, аннан дуңгызчылыкта, аннан Гарифулласы белән яшелчәчелектә эшләде. Гарифулласы исән-сау әйләнеп кайтмаган булса, аның җаны һәм тәне шул хәсис дуңгыз фермасында чериячәк иде. Мәктәпкә эш сорап барган яшь мөгаллимәнең иске «гөнаһларын» онытмаганнар иде шул. Киресенчә, моңа кадәр ясалма күренгән каршылыклар хәзер табигыйләшеп кискенләшкәннәр иде. Шулай итеп, заманы өчен шактый белемле мөгаллимә авыл интеллигентыннан алдынгы колхозчыга әйләндерелде. Мәдәният-мәгърифәт сәясәтеннән шактый артта калганлыгын сизә Өммегөлсем, кайбер яңа сүз-атамаларны әйткәндә, дөрес әйтәм микән, дип борчылып, үзе өчен оялып та куя…

Һәр җәйдә сабыйны зиярат кылу, иң зур хыялы — гәүдәсен Шатманга күчереп күмү уе беркайчан да тынгы бирмәде Өммегөлсемгә. Күмәк хуҗалыкның ул чактагы рәисе Сабира апа хатынның кайгысын тирәннән аңласа да, мондый җаваплылыкны үз өстенә ала алмады. Авыл советына барырга кушты. Каберлек, күмү-җирләү алар карамагында, диде.

— Сез нәрсә?! — дип җикерделәр инде хакимияткә үрләп алган Өтәләү Зарифларның уллары. — Әле сине, качкалакны, үз-үзен атып үтермичә әсир төшкән сатлык җан хатынын авылдан кумаганга рәхмәт әйт! Күчереп җирләү, мөселман йоласы, имеш!..

Соңгы тапкыр 1947 елның җәендә барды ул авыл советына. Анда ач балалар өчен аерым приют оештыру белән шөгыльләнәләр иде.

— Чит-ят җирләрдә яткан бер гаепсез фәрештәгезне кайтарып күмү турында кеше мәшәкатьләп йөргәнче, менә берәр баланы алып тәрбияләгез! — диделәр, үзе дә ачлыктан шешенгән хатынның үз сүзләрен үзенә кабатлап. — Бездә чит-ят җир юк. Барысы да совет җире. Кеше кадәр кешене күчереп җирләү өчен НКВДның махсус рөхсәте кирәк! Ә анда пәйгамбәрләргә дә, фәрештәләргә дә исемлек тутырылган...

Курыкмас җиреннән курыкты ялгыз, яклаучысыз хатын. Алла сакласын, тыныч яткан җиреннән куптарырсың, ә монда күмдермәсләр дә. Ничә мәртәбәләр кырык «Ясин» һәм ничә мәртәбәләр Коръән чыкты икән ул сабые рухына? Ярлы булса да, буе гарьле Өммегөлсем әти-әнисенең, биана-биатасының дини кешеләр булып, аңа ислам рухын — бердәнбер табыну һәм көч алу кыйбласын сеңдерүләренә куанып бетә алмый иде.

Гарифулласына да әйтеп-әйтеп карады. Фронттан шактый басылып, сынып кайткан, бу хәтәр заманнарда үзе дә як-ягына каранып яшәргә мәҗбүр булган ир мәсьәләне нишләптер куертмады. Ачлык-ялангачлык дәвам итте, аннан берсе артыннан берсе балалар туа башлады. Болар, бәлки, сәбәп кенәдер? Әллә дөньяны битарафлык, имансызлык бастымы? Шулай гомер үтә торды. Яраларны еллар томаны япты. Һәм менә...

## V

Өммегөлсем Гарифулланы эре сабаклы әрекмәннәр, зәңгәр кыр җитене баскан тыкрыктан алып керде. Бәрәңге бакчалары очына барып чыккач, алар туктап калды. Өммегөлсем эзләгән агачлар юк иде. Илле ике ел дәвер эчендә кешеләр генә түгел, җир кыяфәте дә танымаслык булып үзгәрә икән. Аннан кышын, буран эчендә үткән ике-өч сәгать вакыт эчендә нәрсәләрне генә хәтерләп өлгерәсең? Өммегөлсем кечкенә чөйләргә бәйләнеп, чиста, ямь-яшел үлән кырган бозауларны күреп куанды. Аның улы яткан җирләр мөселманча пөхтә, яшел, мал-мөлкәтле һәм җыештырулы иде. Әнә бит Ходай Тәгалә рәхмәте белән бәрәңгеләре дә зәңгәр чәчкәле күлмәктә утыра!..

Җил тегермәнедәй җилкенеп һәм дәртләнеп, шуның нәтиҗәсендә Гарифулласын шактый артта калдырып, Өммегөлсем карчык үзе чамалаган кишәрлекне берничә тапкыр әйләнеп чыкты. Моннан бер өч-дүрт йөз адым чамасында урман бар икән барлыкка, тик менә каеннар юк. Кая ди ул каеннар — төпсәләре дә эзсез югалган. Бар тирә-якны,

җирнең катламнарын тоташтан күрә торган күз нурлары белән үтәли тишеп, шул төшне, шул урынны, шул өлешне, шул ноктаны табасы килә иде... Аның бердәнбер кыйбласы булып вокзал туры калды. Бакча башларындагы читән-каертма, киртәләр буйлап ул шул тарафка китте.

— Нәкъ паравызлар каршында иде... Нәкъ паравызлар кычкырта торган җирдә иде...

— Хәзер паровозлар түгел, карчык, — диде артыннан килгән Гарифулла. — Хәзер электровозлар. Алар безнең яшьлектәге шикелле җанны илертеп кычкыртмый. Моңсызлар...

Әйе, моннан нәкъ кырык ел элек корымлы, йөрәк ярып кычкырта торган паровозларның пөхтә, ыспай һәм ялкау гына сызгыртучы электровозларга алыштырылганлыгын белми һәм белә дә алмый иде.

— Вокзал турысында гына... Менә шушы чамадарак...— Атлый-атлый карчык үзе белән сөйләште. — Каеннарын түгел, төпсәләрен дә калдырмаганнар, ичмасам... Менә мондарак... биредәрәк булырга кирәк...

Һәм Өммегөлсем карчык кисәк кенә туктап калды. Гүяки аңа Тансыгы җир астыннан: «Тукта, әни, син бит мине нәкъ менә шушында калдырып киттең...» — диеп эндәште. Буыннары таралган ана дерелди-дерелди төенчегеннән намазлыгын эзли башлады...

— Ярар, Ходайга тапшырдык алайса... — Ул, күк йөзендә ярсып янган кояшка карап, җиңел генә кыйбласын тапты, нәкъ вокзал турысына һәм нәкъ вокзалга каратып намазлыгын җәйде. Киез олтыраклы калушларын бер читкәрәк салып, намазлык өстенә менеп басты да сорап куйды:

— Тәһарәтең бардыр бит, Гарифулла? Миңа кирәкми...

Дистә еллар буе ишетелмәгән мондый сорау Гарифулланы дәррәү какшатты.

— Бисмиллаһир-рахман ир-рәхим! Әра әйттәлләди йүнәзибү биддин...*

Әкчин станцасының яшел хәтфәсендә, Тансыгының сөякләре яткан яланда, Тансыгына багышлап, шау чәчкәдә утырган бакчалар аша меңләгән төп бәрәңге куакларына, җир-ихаталарга, урман-тауларга, барча кешелеккә иминлек теләп, Өммегөлсем карчык «Кәүсәр» сүрәсеннән «Мәгавен» сүрәсенә күчте.

Өммегөлсемнең бик ерактан, тирәннән, Ташлысының, Шатманының Юкәлетау, Ташлытау, Кырынтау буйларыннан шарлап аккан мәшһүр чишмәләрен хәтерләткән көмешле, бәрхет кылганлы мәкаме күптәнге хуҗасы булып бар тирәякка сарылды. Гарифулла нәрсә эшләргә белми катып калды. Гаепле һәм оятлы тойды ул үзен. Аның бәгърендә нәрсәдер

* Күрдегезме, ул дин бозучыларны? *(Гарәпчәдән.)*

айкалды-чайкалды, ташып түгелде һәм аның иреннәре, үзүзен тыңламыйча, ниндидер сихри көчкә буйсынып, моңа кадәр уйламаган-нитмәгән тәкбирләрне пышылдый башлады:

— Җанымның каны... Канымның җаны... Минсез һәлак булган бердәнбер Тансык улым... Тәүбә!.. Гафу ит...

Кайчандыр сабый чакта ятланып, күңелгә сеңдерелеп тә, алтмыш-җитмеш ел буе таш астында тотылган борынгы, бер караганда бик тә аңлашылган, икенче караганда бигүк аңлашылып та җитмәгән сәер, серле, беркатлы һәм катлаулы мәгънәләр һәм авазлар аның телендә тегермән ташы шикелле авыр әйләнеп һәм бөтерелеп яңара башлады... Эссе кояш астында җылы яңгыр яугандай тоелды Гарифуллага. Гүя таушалган тән, каткан буыннар шул җылы яңгырда җеби һәм йомшара иде. Ул битенә, муеннарына кадәр тамчылап шыткан тирләрен сөртеп алды. Юк, яңгыр-фәлән яумый икән. Бу мәгънәләр, бу мәгънәләрнең һәр буыны бүген аның өчен күптән онытылган гарәп телендә түгел, ә ни өчендер туган телендә яңгырый иде кебек. Нәрсәдер урталай ярылды: сабый чак — алдан колын, ә колын маңгаенда ярым ай үзе чаба!

— Аллаһы Тәгалә бар! Галәмдә бер Алладан башка Алла юктыр! — дип кычкырып җибәргәнен ул сизми дә калды.— Аллаһы Тәгалә, барлык гөнаһларымны ярлыка! Мине рәнҗеткәннәргә дә якты вә ачык юл күрсәт, ялгышларыннан арындыр! Мине рәнҗеткәннәргә мин рәнҗемим, әгәр алар, шайтаннан котыртылып, ни сәбәпледер миңа рәнҗи икән, Ходай Тәгалә, сиңа ялварсыннар!..

Аңа рәхәт иде. Кайчандыр кеше булып туып һәм тәрбияләнеп, партиягә кермичә, шул ук партия тарафыннан котылгысыз рәвештә сугышчыга, азат итәм дип басып алучыга әверелдерелгән, таш базларында да җанын издермичә ташчы-интеллигент булып кала алган Гарифулла гүяки бүген яңадан үзенең төп сыйфаты — кешелегенә кайта иде...

— Аллаһы Тәгалә! Җирдәге кошларыңа, киекләреңә, барлык милләтләреңә, диннәренә карамастан, канат һәм куәт, саулык һәм сәламәтлек, күңелемнең җаный садакасын җибәр! Кеше җанын коллыктан азат ит, җир йөзендә коллык челпәрәмә килсен!..

Өммегөлсем, намазының дүртенче рәкәгатендә бәрәңге бакчасына карап, сәҗдәгә киткән иде. «Кыйбланы дөрес сайладык микән без? — Картның миеннән яшен тизлеге белән фикер үтте. — Кыйбланы дөрес сайладык микән?!»

— Йөзен күрмәгән сабыемның урыннары оҗмахта булсын! Аның өч йөз алтмыш буыны җир куеннарында миңа рәнҗемәсен һәм пәйгамбәр тырнаклары булып чәчкә атсын!..

Шул ук сихри көч аны Гөлсеме артыннан сәҗдәгә тезләнгәндә. Җитмеш ел буе диярлек бер рәкәгать намаз укымый каткан буыннары кораб колгасы шикелле шыгырдады. Ике

рәкәгать сөннәт һәм ике рәкәгать фарыздан соң алар, бер-бер артлы очкан аккошлар кебек парлап, сәҗдә кылды һәм тәкбир әйтте:

— Аллаһу әкбәр ля илаһә иллаллаһә вәхдекү ля шәрикә ләһ. Ләһелмөлкү вә ләһе...

Өйлә намазларын барча әрвахларга, шул исәптән күптән инде мәрхүм булган чит кавем Никодим абзый һәм Марфа түтигә багышлап, Өммегөлсем карчык белән Гарифулла карт озак итеп дога кылдылар.

Башларын күтәрсәләр — аларга, ихаталарга менеп атланып, бала-чага карап тора.

— Вы слышали, как они красиво поют! — диде салам чәчле кызчык башкаларына. — Хором пели!..

— Карчык, без кыйбланы дөрес сайлаган булганбыз микән? — диде Гарифулла, калушларын киеп, каз тәпиле намазлыгын җыештырып маташкан Өммегөлсемгә.

— Дөрес, нишләп дөрес булмасын ди? — Иңеннән тау төшкәндәй иркенәеп, җиңеләеп һәм яшәреп калган Өммегөлсем намазлыгын төенчегенә салган арада зур ышаныч белән кулларын болгаштырды. — Менә — көнчыгыш, менә — көнбатыш, теге якта — кыйбла, Мәккәи Мәдинә! — Ул кулларына кәнфит учлап, эре генә кыяфәт белән сабыйларга таба юнәлде. — И-и, сабыйларым... Татар балалары бит алар...

— Они — татары, — диде салам чәчле кызчык, башкаларга күрсәтеп. — Я — русская...

— Вча рауна... Вча рауна... — Өммегөлсем балаларга кәнфит тарата башлады. — Татарча беләсезме соң?

— Алар юк, — диде чая кыз. — А мин татарча билям. Татарлар татар урогыннан кача. Мин — русская. Мин татар урогына калам. Минем мама: «Уйрянерга кирәк», — ди. Шулай дурыс ведь?

— И-и, бәбекәйләрем... — Карчык, аларның иңнәреннән сөеп, хәер тарата башлады. — И-и-и, йөрәк парәләрем...

— Кирякми! Не надо! — дип шаулашты сабыйлар. — Кирякми!..

— Хәердән баш тартмыйлар, алыгыз, — дип өстәде Гарифулла. — Һәм менә шулай итеп әппәр итегез! — Ул, дога кылгандагыдай итеп, битеннән сыпырды.

Хәер алган балаларга бу ифрат та кызык иде. Алар кат-кат әппәр итте.

Карт белән карчык үзләренә генә билгеле зиратта һәм Әкчиндә күпме йөргәннәрдер, монысы билгесез. Кичен исә, шәфәкъ ялкынына төренеп, алар автобус тукталышына якынлашып килә иде...

*Февраль — март, 1996 ел.*
*Переделкино — Чаллы*

# АВЫЛДАШ

*Чаллы рәссамы*
*Миңнехан Шәйдуллинга багышлана*

Моңсу. Бик моңсу.

Сезгә бу кадәр моңсулыкны ничек аңлатырга, ә? Алдан ук кисәтеп куярга тиешмен: гөлләр, үсемлекләр һәм, әлбәттә, агачлар үстерү буенча белгеч, ягъни, заманча әйткәндә, яшелләндерү буенча инженер — мөһәндис мин. Кешеләр дөньясын бик белеп бетермим, шуның аркасында әллә нинди көлке хәлләргә калам. Нәрсәне яшелләндердек соң без, яшеллек мөһәндисләре, гомеребез буе? Әлбәттә, яшеллекне яшелләндердек. Әүвәле корыттык-саргайттык та, аннан яшелләндерергә маташып карадык.

Мин менә әле дә яшелләндереп ятам. Тольятти шәһәренә яшелләндерүчеләр киңәшмәсенә килгән идем. Бөтенрәсәй күләмендә үткәрелгән һәм килүе-китүе белән өч көнгә сузылган бу искиткеч моңсу песнәкләр базарында хәтта бүген, апрельнең егерме икесендә, бер генә бөрене дә яшелләндерә алмыйча, Калуга, Новосибирскилардан килгән Николай Ивановичлар белән бергә, теләсәм-теләмәсәм дә, кем әйтмешли, «компания хакына», байтак кына яшел шешәләрне яшелләндереп, ашказаным чирен кузгатып, тау күчергән адәм сыман арып-талып, кунакханәгә кайтып егылдым әле менә-терәк. Һәм менә шул сәбәпле, нәрсә эшләргә белми, түшәмгә төкереп ятам.

Башыма әллә ниткән уйлар килә башлады.

Әйтегез әле, мин, яшелләндерү мөһәндисе, ошбу шәһәрне беренче тапкыр күрмәгән булсам, үз гомеремдә «кичерү» сүзенең күптармаклы мәгънәләрен аңлап өлгергән булыр идем микән? Ай-һай, ай-һай, дим мин. Шулай да аларны аңлау өчен миңа мотлак Тольятти шәһәренә килергә кирәк иде микән? Аннан, бу сүзнең катлы-катлы эчтәлеген төшенү өчен, бернинди сәбәп, чыгырдан чыгарырлык вакыйга да булмады бит әле. Юк, башымнан чыкмый гына бит бу шайтан котырткан «кичерү» — тукмак белән тукмап, сыргавыл белән сөреп чыгарасыңмыни аны?! Юк, җәмәгать, миннән көләргә ашыкмагыз әле. Төпченеп китсәң, үзегез дә аңлап җиткермисездер әле бу кәлимәнең бихисап мәгънә нечкәлекләрен, шулай бит? Әйтик, менә сезгә гомумән «кичерү» — хиссияти хозурлану, ярсу-яралану, ярга сугылып, тынычлыгыңны югалту, шартлар хәлгә җитсәң дә сиздермәү һәм башкалар, һәм башкалар. Бу бер булдымы? Менә сезгә тагын «кичерү» — һәммә җанлы кемсәне һәм җансыз нәрсәне, әйтик, мәһабәт агачларны, бостандагы гөлләрне күздән кичерү, ягъни

мәсәлән, беренче мәртәбә күреп, моңсыз сыер сыман күз сирпеп булса да, нәрсәгәдер ышану-инану, фикер туплау. Монысы ике булды, шулаймы? Менә сезгә янә бер «кичерү» галәмәте — гомер кичерү, бу халәтне инде, җәмәгать, теге, бая телгә алган моңсыз сыер кебек кенә кичереп булмый, үзегез дә чамалыйсыздыр. Гомер кичергән кешеләр мондый кичерүне шактый катлаулы, четерекле нәрсә, диләр... Һәм менә, ниһаять, тагын бер «кичерү» — кемнедер ярлыкау, җир тырнап җылап, үз гаеп-гөнаһларын йолуны ялварган кешене гафу итү, кичерү... Аллага шөкер, бу тарафтан күңелем тыныч, Тольяттида мондый ярлыкауны миннән, йә булмаса, үземнән көткән адәм юк. Әмма нишлисең, барасы җире, бер танышы-дусты, туганы булмаган чит-ят шәһәрнең ташландык кунакханәсендә аунап яткан башны нинди генә килде-китте уйлар измәс!..

Кайда гына булсам да, чагыштырырга яратам мин. Хәер, үземнең үткән юлым да чагыштыру аша алга атланган аралык булды бугай. Үзем гомер кичергән Чаллы һәм соңгы көннәрдә генә күземнән кичергән Тольятти арасында тырышыптырмашып, аларның аеры, кабатланмас, үзенчәлекле чалымнарын эзләсәм дә, әллә ни һуш китәрлек нәрсәләр таба алмадым: аларның беренчесе, Тукай бабай язганча, «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәгән «урыс җирендә»ге Татарстанда, икенчесе, тарихи хәтергә тугры калып әйткән очракта, татар җирләрендә кара кан булып оешкан Рәсәйдә, тагын да аныграк итеп билгеләгән хәлдә, Идел уртасында, Жигули дип йөртелгән Җигүле таулар укасында урнашкан булуына карамастан, бу ике автобашкала, КамАЗ һәм ВАЗ вилаятьләре, игезәкләр сыман охшаш булып чыкты.

Тольятти дигәннән, алтмышынчы еллар башында Италиядән сатып алынган ФИАТ автозаводы төзелә башлаганчы аның исеме Ставрополь иде. «Бу нинди Ставрополь?» диярсез сез. «Кафтау итәгендә бер Ставрополь бар иде бит инде, монысы каян килгән?» Һәм соравыгыз дөрес булыр. Алтмышынчы еллар уртасында Италия компартиясе җитәкчесе Пальмиро Тольятти үлгәч, Ставропольне Тольятти исеме биреп яшелләндерделәр. Кайчандыр унсигезенче гасыр башында каракытайлар басымы астында Жунгариядән Рәсәйнең Идел түбәненә, Кафтау капкасы — Ставрополь казаклары җирләренә килеп төпләнә башлаган калмыкларны, тышкы чикләрдән аерып, ил эченә, аның ашказаны булган Иделгә куып чигендерү, шулай итеп, империя өчен яралып килгән куркыныч көчтән арыну ниятендә Җигүле таулар җәясендә калмыклар өчен төзелгән резервациягә матур алдак итеп Ставрополь исеме бирелә. Әмма патша калмыкларны биредә көчләп тота алмый. Унтугызынчы гасыр урталарында

барыбер Түбән Идел-Кафтау арасындагы далаларга күченеп бетәләр алар. Хәзер Ставрополь-Тольяттида галәми телескоп белән эзләсәгез дә, бер калмык әсәре таба алмассыз. Ул бүген, әлбәттә, чын урыс шәһәре.

Әйе, ике автобашкала игезәкләр сыман охшаш булып чыкты: гүяки нindидер милләтсез, телсез һәм денсез газраилләр булачак яңа Чаллы шәһәренең генераль сызымын сызып та тормаганнар, җитез яһүди абзыйлар моның өчен бүленгән акчаны Израиль дип аталган илләрендәге кесәләренә күчергәннәр дә Тольятти шәһәрен Чаллыга утыртканнар да куйганнар.

Аларның икесендә дә иң кыерсытылган сыйныф — чәчәкләр. Аларны үстерү өчен түтәлләр бөтенләй диярлек каралмаган, каралса, алар кара тузан туздырып, җәй буе иңрәп ята; аларның икесе дә адәм баласын йорттан йортка, урамнан урамга мөмкин кадәр турыдан йөртү өчен түгел, ә мөмкин кадәр башын әйләндереп, миен миңкетеп, уратып йөртү өчен салынган; аларның икесе дә урам, сукмак, тротуар дигән төшенчәләрдән азат — Чаллыда, мәсәлән, тыныч кына һава алыштырып йөрергә дип урамга чыккан авырлы хатын, тротуар эзләп, тора туар; аларның икесендә дә киң автострадалар гына хакимлек итә — безнең кебек җәяүле, мобильсез хадимнәр бу автостраадаларның як-ягына сылашып, бәреп-имгәтеп китә күрмәсеннәр дип, башларын артка борган килеш алга барырга, җәен көмеш тузанда, газ-ягулык төкерекләрендә тончыгып, көзен исә ләм-пычрак яңгырында коенып хәрәкәт итәргә мәҗбүрләр.

Бу ике шәһәрдә агачлар да иң кыерсытылган кавемнәргә керә — аларны буйга җитә башлау белән кисә-аудара башлыйлар, күләгә, күрәсең, иң куркыныч нәрсә; йортларны да йортлар дип атау дөрес булмас иде — күп катлы, ишекләре тычкан тишекләрен хәтерләткән, диварлары ата-анасыз, теге милләттәге сүгенү сүзләре белән бизәлгән сукбай куначалары — ночлежкалар алар; биредә урамнар исемсез, биредә нindидер күмпликсләр, бу күмпликсләрдә һәр ун кешегә биш мильтон, җиде эт, төрбә-төрмә хөҗрәләрен хәтерләткән, кимендә ике кат тимер ишекле фатирдан сезгә әүвәле нәселле маэмай, аннан соң гына нәселсез адәм зат өрер; әгәр урамнарның исемнәре бар икән, алар Чаллыда артык шагыйранәрәссами — Пушкин, Есенин, Шишкин, ә Тольяттида артык сугышчан-милитаристик — Ворошилов, Буденный, Блюхер һәм тагын нindидер маршал Плюхер булыр.

Күмпликсләрдә кешеләр тыныч әңгәмәләшер, шагыйрьләр шигырь язар, гашыйклар оялып кына кочаклашыр, яшерен үбешер өчен иркә күләгәле, мәхәббәтле бакчалар, сквер, бульварлар юк — биредә һәр куак, һәр йорт арасы, һәр

күләгә исәпкә алынган, кирәксә-кирәкмәсә дә кыек электр яктысы, тәртип сакчыларының күз-колагы белән тәэмин ителгән; аларда мәһабәт һәйкәлләр дә күрмәссез — ниндидер гарип-гораба, төшеңә керсә, куркытып уятырлык гыйфритләр; бишәр-җидешәр йөз мең халыкка нибары бер гомуми, димәк, йогышлы чирләр таратучы мунча — ул да Политбюро карары һәм ул раслаган сызым буенча салынган...

Аһ, бу күмпликсләр! Аһ, бу күмпликсләрдә мәгънәсезгә булса да почмак алу өчен бушап калган мәһабәт авыллар, суелган мал-туар, черегән кызыл маллар, хуҗасыз калган уңдырышлы җирләр, кияү-кәләшсез картайган егетләр-кызлар, ватылган язмышлар, тәнен сатып, азгын чир тараткан зифа буйлар, урамда ата-анасыз калган ятим балалар, фатир алалмау, эшсез калу кайгысыннан эчкелеккә сабышкан әзмәвердәй сукбайлар, авыл белән шәһәр арасында мәгънәсез юл йөреп, җирдә, суда һәм һаваларда бәрелешеп, челпәрәмә килеп, вакытсыз әрвахлар исәбенә тулып калган авыл зиратлары!..

Аһ, бу күмпликсләр! Колакка «кәмпүтер» сыман гайре табигый яңгыраган бу нәмәстәкәйне татарчага «бистә» дип тәрҗемә итәргә мөмкиндер. Әмма аны урам дип тә, бистә-мәхәллә дип тә булмый. Кеше башын каңгырту, аңардан иҗтимагый сарык ясау өчен төзелгән мондый йортлар өере атамасы, кайчандыр французлдан урыска бары тик күмәклек мәгънәсендә генә кереп, соңгы елларда мәгънәсен бик тә киңәйтте — ул акылга зәгыйфьлек, күмәкләп тилерү, бергәләп акылдан язу мәгънәсендә дә яңгырый башлады. Әйтик, кемгәдер ымлап, сезгә: «Анау кешедә күмпликс», — дисәләр, димәк, белеп торыгыз — тегеңә «җитешми», ул «ычкынган», ул «того». Әгәр сезгә кемдер: «Мин уналтынчы күмпликстә яшим», — ди икән, сез, кинаяне аңлый торган кеше, һич тә икеләнмисез — аңа уналты тапкыр җитешми. Димәк ки, егерме алтынчы күмпликстә егерме алты, кырык бишенче күмпликстә кырык биш тапкыр җитешми икән бу Алла бәндәләренә. Аптырамагыз, көлегез дә куегыз.

Минем үземә, мәсәлән, ундүрт тапкыр җитешми. Мин чагыштырмача байлар күмпликсендә яшим. Әйтергә онытып торам тагын, кеше баерак булган саен, яшәгән күмпликсенең саны кечерәк була. Яшеллекне яшелләндерәм дип, чынлап та, ундүрт тапкыр ычкындым һәм яшәү урыным да ундүртенче күмпликстән әләкте.

Әлбәттә, бу шәһәрләр политбюро калдыклары. Шулай да «ленинчыл» политбюрога рәхмәт укырга кирәк: илне бөтенләй урлап-талап бетергән һәм моның өчен хәтта сукыр тычканга да орден тараткан заманда, ярый әле, безгә, фәкыйрьләргә, шундый булса да күмпликсләр төзеп калдырган...

Кайчандыр иске Чаллы үзе дә бары тик Чаллыдан гына торган. Ни сөйләвем аңлашылмый, шулай бит? Ашыкмагыз, хәзер аңларсыз. Яңа Чаллыны төзибез дип, мең еллык тарихы булган Иске Чаллыны су астына җибәргәч, алмашынган кешеләр яңа Чаллының исемнәрен ифрат та ишәйттеләр һәм камилләштерделәр. Сидоровка бистәсен алыйк. Анда сирәк-мирәк кенә пенсионерлар, күбрәк кәҗә-сарыклар һәм этләр яши. Ул бердәнбер урамнан тора. Анысы да Сидоров урамы. Ә Сидоровны кем булган дисез сез? Ай-һай зур, ай-һай бөек кеше булган ул Сидоров әфәнде. Большевикларның нәрсә икәнлеген дә аңлап өлгермәгән, гомерендә мәптек бусагасын күрмәгән батрак-чекист Сидоров бер үк көпшәдән ике контраны — православие атакаен һәм мөселман мулласын дөмектергән. Әлбәттә, бу батырлык эзсез югалмаган — каһарман хөрмәтенә бистәгә, җитмәсә, аның бердәнбер урамына аның исемен биргәннәр. Дөрес эшләгәннәр. Һәм бу каһарман мөстәкыйль Татарстанны үз байрагы астында өченче мең елга алып чыгып килә. Рәхмәтләр төшсен аңа.

Яңа Чаллыда тагын бер бистә бар. Аны татарлар ЗӘП, урыслар ЗЯБ ди, ягъни «Завод ячеистого бетона» була инде. Татарчага әйләндерсәк, күзәнәкле бетон, юк, гафу итә күрегез, бака күзле бетон бистәсе. Матур бит, җәмәгать? Әлхасыйль, «Сез ЗӘПкә бармыйсызмы?» дигән сорауны тулы итеп биргәндә, «Сез күзәнәкле бетон заводы бистәсенә бармыйсызмы?» дияргә туры килә. Әлбәттә, әле күптән түгел генә бу урыннарда дистәләгән Баллы Каен кебек гүзәл авыллар шаулап утырган. Әмма яшеллекне корытып яшелләндерүчеләр, тишекле бетончылар кабиләсе хакимлек иткән Татарстанда бистәләргә эзсез югалган Баллы Каен исемнәре биреп утырып булмый бит инде!.. Аннан безнең атаклы Чаллыбызда тагын бер бистә бар икән бит әле — анысын татарлар ГИС, урыслар ГЭС диләр. Ягъни, паспортына туры китереп әйтсәк, «Гидроэлектрическая станция бистәсе». «Сез су белән электр барлыкка китерүчеләр бистәсенә бармыйсызмы?» була инде монысы. Әлбәттә, борынгы заманнарда, әйтик, моннан егерме-утыз ел элек бу җирләрдә матур-матур Тубылгытау авыллары гөрләп торгандыр. Әмма су белән электр җитештерүчеләр хакимлек иткән азат Татарстанда нindидер Тубылгытаулар белән вакланып торалармыни!..

Моңсу миңа. Аһ, бик тә моңсу!..

Күземне йомам. Көзге өзектә пычрак чәчрәтеп, бистәдән бистәгә чапкан Чаллы автобуслары алдыма килә... Биш гасырга якын урысча укып, наданлашканнан-наданлаша барган милләттәш хатын — кондукторның игъланы ишетелгәндәй була:

— Гражданый, прәбритәйти билити! Салуный рабутаит ыс талуный... Ыслидуши астануфка — Хлипзабут!..

Йа Хода, чит шәһәрдә япа-ялгыз калсаң, нәрсәләр генә башыңа килмәс!..

Нәкъ шул мизгелдә, кемдер касыгыма төртте диярсең, сикереп тордым, калтыранган бармакларым белән пинжәк кесәсендә кармана-актарына башладым. Бәй, кесә шәрифләремдә Тольяттига китәр алдыннан гына авылдан, бертуган абыемнан килгән хат ята лабаса! Киңәшмә мәшәкатьләре белән мин аны онытып җибәргәнмен икән. Яшибез болай булгач! Хатны тартып та чыгарам, яшәргән күзләрем белән йөгерә дә башлыйм: «...*Син Тольяттига барсаң, Хәбир туган, Сөендекләргә керми калма. Аның хатыны марҗалыкка марҗа, әмма Сөендеккә, бәхетенә каршы, марҗаның бик тә уңганы, кәттәсе туры килгән. Үзең беләсең, Сөендекнең әнисе Фатыйха абыстай безнең әнинең гомерлек ахирәте иде. Әтисе Закир абзый исә әтинең җан дусты булган. Аннан алар, чыбык очы булса да, безгә туган тиеш кешеләр. Керсп күреп чык. «Туганның азары булса да, бизәре булмас», — дигән борынгылар. Сөендекләр авылга еш кайталар. Ул кайткан саен сине сораша, утыз елга бер булса да күрешергә иде, ди. Адресы...*»

Барам, әлбәттә, барам! Бармый була диме? Авылдашка бармый буламы? Без, татарлар, бөтен дөнья буйлап авылдашлар бит! Кара әле, мин дә инде, адәм актыгы, шундый бәхет-сәгадәтне онытырга мөмкинме?! Үзем дә сизмәстән, шатланып китеп, йодрыгым белән өстәлгә суктым. Әлү-әлү!.. Авырткан кулымны һавада селкетеп киенә дә башладым. Әйе, әти белән Закир абзый бер кашыктан ашап яшәгәннәр. Әти сугыш яланында ятып калган, ә менә Закир абзый, кулын өздереп, исән-сау урап кайткан. Фатыйха абыстайга ул сугышка кадәр өйләнсә дә, нәсел маясы калдырырга өлгерә алмый. Сөендек аларның сугыштан соң беренче һәм соңгы сөенече. Шуңа күрә малайга безнең якларда сирәк очраган Сөендек исеме кушалар да. Ул миннән алты-җиде яшькә бәләкәйрәк булыр. Һәрхәлдә, Баллы Елга буйларында казлар көткәндә, безгә тагылып үсте ул. Дәфтәр битеннән ясалган кәртләр белән уйнарга да өйрәттем әле мин аны. (Укучым моны берүк бозыклык саный күрмәсен!)

Безнең кояш чыктымы-юкмы, анысын әйтүе авыр, әмма шунысын беләм: Сөендек сигезенче сыйныфтан ары укымады. Колхозда башта төрле эшләрдә, аннан яңа төзелгән «Дуслык» дуңгыз күмпликсендә эшләп азапланганнан соң, хәрби хезмәткә китте һәм авылга бүтән әйләнеп кайтмады. Фатыйха абыстайга килсәк... Фатыйха абыстай... Туктагыз әле. Йөрәкне нидер чәнчеп алды. Бер генә минутка туктагыз. Рәхмәт, үтте. Закир абзый туксанны әвәләп барса да, Ходайга шөкер, яшь карчыгы белән матур гына дөнья көтеп,

җон тетеп дигәндәй яшәп ята. Яшь җиңгәчәйнең балалары ярдәмендә үзенә җитәрлек мал да асрый, умарталар да тота. Авылның мулласы вазифасын да башкара әле ул Закир абзыкайгынам.

Фатыйха абыстайга килсәк... Фатыйха абыстай...

Мин урындыкка бөгелеп төштем.

Сөендекләргә барыргамы, юкмы? Әниләренең фаҗигале язмышын көтмәгәндә хәтерләренә төшереп, уңылган яраларын яңартмаммы? Корымаганмы Сөендек энекәшнең күңел агачы? Аның тамырларына җир катламнарыннан шифалы мәгъдән киләме? Корымаган хәлдә, бәлки, аларны борчымаска кирәктер? Мин дертләп куйдым, гүяки миңа Сөендек белән очрашу өчен аның күңел агачының коруы, газиз әнкәсен онытуы хәлиткеч шарт иде...

Хәер, Сөендек, әйткәнемчә, миннән алты-җиде яшькә генә кечерәк булса да, безнең буын кешесе түгел иде. Илленче-алтмышынчы еллардагы искиткеч кыска аралык безнең буыннарны танымаслык дәрәҗәдә ераклаштырды да куйды. Без — Сталин, алар — Хрущев, без — балтырган, алар — икмәк, без — чабата, алар — итек, без — тальян гармун, патефон, алар радио-телевидение буыны иде. Соңыннан аңлавымча, минем Казан авыл хуҗалыгы институтының яшелләндерү һәм җир-сазлык киптерү бүлеген тәмамлап, яшелләндерү буенча мөһәндис булып китүем дә шушы аерымлыкка каршы фетнә, бездән соң корый башлаган буыннар агачын яшәртү теләгенә бәйле булган икән. Мин аны ниндидер алтынчы тоем белән тойганмын, күрәсең. Яшәртү-яшелләндерү теләге үземнән соң тормышка юл алган буынны, фәлсәфи тел белән әйткәндә, инкяр итү аша яшәртү булган...

Хәлсез генә күтәрелеп, урыныма барып аудым. Кичке сәгать алты да икән инде. Язгы озын көн, әле караңгы төшәргә иртәрәк иде. Тәрәзәдә ниндидер иртәләгән шәфәкъ һәм офыкны алсулатып кискәләгән болытлар. Әйе, вакыт дигәнең ага. Ага, чөнки аның эше юк. Ул кеше кебек ашыкмый, каударланмый, чәбәләнми. Чарасызлыктан һәм эшсезлектән бетәшкән карашым белән бүлмәмне күздән кичердем. Бәй, биредә бер генә гөл дә юк икән. Радиосы өзек — акча юк, телевизоры, телефоны эшләми — акча юк. Боларын аңлыйм, ә менә гөл юклыгын һич тә аңлый алмыйм. Аһ, хәзер гөл үстерергә дә акча кирәк бит әле! Хәер, бу унике катлы бинада, беренче катта, байбичә шикелле җәелеп утырган, тузаны айлар буе сөртелмәгән карт фикусны исәпкә алмаганда, гөл заты юк та шикелле. Бәй-бәй-бәй, аның каравы минем шыр ялангач торагым җан ияләре белән тулы икән ләбаса! Ярыклардан, тәрәзә яңакларыннан, шыксыз стеналардан, урыс кардәшләребез инануынча, һәр өйгә байлык-

мөлкәт ташучы җанварлар — тараканнар карап тора. Җитмәсә, һәркайсы мыеклы. Мин чирканып куйдым. Ике төнемне монда ничек үткәргәнмен? Әйе, әйберләрне җыештырырга, Сөендекләргә барырга, шунда кунарга һәм шуннан ук кайтып та китәргә кирәк!..

Үзем исә һаман урында ята бирәм. Әйе, абыем дөрес язган, әнием Шәмсекамәр белән Фатыйха абыстай бер тамырдан яратылган ике гөлдәй яшәделәр. Бала чагымда кич утырганда аларның үз язмышлары турында пышын-пышын сөйләшкәннәрен хәтерлим. Фатыйха абыстай, Айдаруленең унсигез яшьлек Коръәнхафизәсе, утызынчы еллар азагында безнең Айтуганга килен булып төшә. Соңыннан белүемчә, таулар арасына сыенып яткан Айтуганга качып котылган ул. Закир абзыйга рәхмәт инде. Югыйсә Фатыйха абыстайның башын да әтисе Суфиян мулла белән бергә Себердә черетәселәре булган. Үз гомерендә чебенгә дә кул күтәрмәгән әтисе, кызу печән өстендә, көтмәгәндә халык дошманына әйләнә дә куя. Шулай, Келәвеш урманы аланында печән чабып яткан мулла абзыйларына авылдашлары үтеп барышлый әйтеп куймасынмы:

— Ай-һай, чалгың шәп чаба, хәзрәт!

Хәзрәт исә, Ходай шомлыгына каршы:

— Шәп чапмаска, Николай чалгысы бит ул! — дип җавап та бирмәсенме!

Алты гына кәлимәдән торган шушы җөмлә җитә дә куя Суфиян мулла башына...

Фатыйха абыстай да, минем әни дә гүр ияләре инде. Дөрес, әнием баш мие өянәге белән ахирәтеннән нәкъ чирек гасырга алдан китеп барды. Гомере буе ялгызлык кичерде ул Шәмсекамәреннән башка. Ел саен Коръән чыкты ул Шәмсекамәре рухына!

Авылга кайткан саен мин аны күрми китми идем. Шулай бер тапкыр, урамнан үтеп барганда, ул мине чакырып алды.

— Кара әле, Хәбир, сиңа монавындый асалы паласлар ошыймы? — диде ул, сандык өстенә таслап куелган өч паласны аерым-аерым идәнгә җәеп. — Монысы рауза чүпләме. Якты, зиһенле сурәт, әйеме? Монысы канәфер чүпләме. Өзелепләр тора, шулай бит? Ә монысы әүхәдия чүпләме. Бөгелешләренә игътибар ит!..

Мин тынсыз калдым. Асалы палас сугучы остабикәләр авылында туып үссәм дә, минем мондый гүзәл сәнгать әсәрләрен, валлаһи-билләһи, дип әйтәм, күргәнем юк иде.

— Бәй, макта инде, нигә мактамыйсың? — Фатыйха абыстай көнбагыш мәмәе сыман ак, вак тешләрен җемелдәтеп кеткелдәде. — Берсен — Сөендегемә мәһәргә, икенчесен — булачак киленемә бүләккә, өченчесен булачак онык-онычкама

истәлеккә дип суктым. Әйдә, егерме беренче гасырга чыксын минем бүләкләрем!..

Ул бу мизгелдә гадәттән тыш шат иде.

— Сүз таба алмыйм, Фатыйха абыстай, — дидем мин, чынлап та уңайсызланып. — Сиңа, сүз остасына, сүз табуы да читен!..

— Табарсың әле, табарсың! Хәзер чишәбез аны, синең телеңне! — Ул сөйләнә-сөйләнә мич аралыгына кереп китте һәм мин яраткан балавыз сыман сап-сары ачы балын күтәреп чыкты. — Мә, эч әле. Үзе салкын, эчендә ялкын!..

Аның теленең байлыгын, сихри сыгылмалылыгын белсәгез иде сез! Тукайны, хәтта Сәгыйть Рәмине яттан сөйли иде, мәрхүмәкәй. Үзе дә бәетләр, шигырь-җырулар чыгара иде. «Үзең чыгардыңмы? Үзең түгелдер лә!» — дип үртәүчеләр булса, һич тә аптырамас, «Әйе, әти мәрхүм әйткәнчә, Тукайныкы булырга тиеш ул!» — дип кенә авызларын яба иде.

Хәзер сез ишетәчәк «Самавыр бәете» дә үзенеке аның. Ялгышмасам, алтмышынчы еллар азагы, тагын да шул печән өсте иде булса кирәк. Яланнан кайтышлый сугылдым мин аларга, бик тә сусаган идем. «Сусауны басарга яхшы, мә әле, авыз ит!» — дип, ул бу юлы да миңа ачы бал сузды. Аннан җәйге челләдә тәрәзә капкачлары ябылган салкынча өйнең алгы ягына алып керде, терсәк астыма мендәр ыргытып, асалы паласка янтайтып яткырды, үзе дә, артына мендәр җайлаштырып, аякларын бөкләп утырды. Гел актан гына киенергә яраткан, зәңгәрсу яулыгын биленә төшереп, турыдан ачылган чәчләренең алдагы көмеш учмасын гына күрсәтеп бәйләгән, аксөяк чырайлы, тәрбияле йөзле, зыялылыгы кыяфәтенә чыккан Фатыйха абыстай бу мизгелдә май урталарында котырып чәчкә аткан ак сиреньне хәтерләтә иде. «Халхуз эше беркайчан да бетми, Хәбир ыланкаем, әйдә әле, монавы нәмәстәне тыңлап карыйк, бер кирәге чыкмаса, бер кирәге чыгар», — дип, бәетне укырга әзерләнде. Бу аның өчен үзе бер бөек, илаһи йола иде, күрәсең. Әүвәле кара җирдә, кара җирдән соң балда һәм майда, актан-ак сөттә һәм сөзмә-катыкта җепшенеп буынланган ак бармаклы кулларын тез очларына куйды, борынгы чичәннәр, һун философлары сыман күзләрен йомды һәм, зиһенен җыеп, беравыкка тынып калды. Бу мизгелдә ул үзе дә комда ышкып ялтыратылган самавырга әверелгән иде. Тәрәз капкачлары арасыннан үткән кояш нуры кылыч булып бу алиһәне урталай ярган иде. Мин нәрсәдер сизендем. Бүлмәдә «Бәдәвам»ны хәтерләткән мәкам яңгырады:

Самавырның шарты алтый:<br>
Ки, эче — гәүһәр, тышы балкый<br>
Ки, самавыр берлә чәй эчсәң<br>
Ки, гамең артыр, йөзең яктый...

Бу чәйнең шартлары бардыр:
Ки — таң вакты берлә кайнар
Ки, килеп яныма утырса
Ки, чәй берлә керә гамь-дәртләр...
Чәй эчмәсәң, хәлең начар
Ки, чәй эчсәң, йокың качар
Ки, гамьле чәй — ямьле әсәр
Ки, укысаң — кайгың басар...
Чәй эчәргә утырдым мин
Ки, калагымны тутырдым мин
Ки, калакны катык түгел,
Баллар берлә тутырдым мин...

Озак та үтми, миңа, институттан КамАЗга юнәлеш алган яшь белгечкә, Сөендекнең хәрби хезмәттән соң, комсомол юлламасы буенча, икенче бер бөек коммунизм төзелешенә — ВАЗга кайтып төпләнүе, марҗага өйләнүе турында хәбәр килеп ирешге. Күз алдыма ни өчендер кара кырау суккан ак сирень кебек Фатыйха абыстай килеп басты. Мин ул чакта үземне бераз битәрләп тә алдым: «Нишләп әле ул сиреньне кырау сугарга тиеш? Халыклар дуслыгының өлгесе булган илебездә катнаш гаиләләр һәм мондый бәхетле гаиләләр азмыни хәзер?» Шулай да бу уй мине эзәрлекләп газаплаудан туктамады. Гүяки марҗа белән Сөендек яшәргә тиеш түгел, ә аңарга, мин белмәгән кавем хатынына, ак сирень бакчалары белән Фатыйха абыстай өйдәш булып керергә тиеш иде. Икенче бер кайтуымда мин аны гадәттән тыш йончыган, таушалган кыяфәттә күрдем. Әллә нинди яңгырлы-бозлы, эре чебеннәр гәүдәләрен күтәрә алмый, җирдән сөйрәп йөри торган ел иде ул. Фатыйха абыстайның йөзләре сулган, әле күптән түгел генә ак сөт кебек якты, тәрбияле, зыялы чыраен нәселсез җыерчыклар баскан, сүнеп калган күз төпләренә кара божралар кунаклаган... Мине күрү белән ул җанлана төште һәм, кеше ишетмәсен дигәндәй, шикләнеп һәм як-ягына каранып сөйләнергә кереште:

— Син җылама, Хәбир ыланкаем. Җылама. Авыр булса да җылама. Түз. Мин менә шулай түзәм. — Ул ун бармагын, йодрыкка төйнәгәндәй яртылаш бөкләп, амин тоткандай итеп борын очына китерде. Шул мәлдә мин аның сул кулының атсыз бармагыннан сабый чакларымнан күреп өйрәнгән яшел ташлы балдагының ни сәбәпледер салынган булуына тетрәндем. Ул исә, сөяк булып каткан карашы белән шул йодрыкларына тупланып, ялвара башлады:

— И Раббым, сабырлыккайлар бир! Сабырлыккайлар!.. Ун бармагым, ун фәрештәмнең канатлары бул! Ун фәрештәм, ун тапкыр төшереп, ун тапкыр күтәр! Ун тапкыр төшереп, ун тапкыр күтәр!..

Аның күзләре бер бөек эш башкарган кебек тәмам пыяла-

ланды. Кинәт ул миңа таба борылды, әле генә төссез күзләреннән кайнар очкыннар очырып, шаркылдап көлә башлады:

— Ха-ха-ха-ха-ха! Хәбир ыланкаем, синең дә Ликсәндрең бармы? Безнең бит Ликсәндребез бар!..

— Нинди Ликсәндр, Фатыйха абыстай? Син нәрсә сөйлисең?!

— И-и-и, белмәгән кеше булып кыйлана тагын? — диде ул, көяләнеп. — Бу хакта бөтен дөнья сөйли бит! Әле генә ырадиудан әйттеләр, кич белән тилебизырдан әйтәчәкләр. Минем Тәләттидәге Сөендегемнең улы бар бит — Ликсәндр кушканнар. Ха-ха-ха-ха-ха! Көл, нигә көлмисең, ыланкаем? Аны миңа сөяргә рөхсәт итәрләр микән? Әй, итмәсәләр, мин Брежневка хат язам! — Ул мич арасындагы кисәү агачын алып, кочагында тирбәтә һәм шырды-бырды такмак әйтеп, идән уртасында бии башлады:

Уңар микән, уңмас микән
Яңа онның белене.
Исән булсам, булам әле
Брежневның килене!..

Мин күзләремне йомдым. Аларны кан баскан иде.

Фатыйха абыстай биюен дәвам итте.

Кызыл фылаклар җилферди
Мәсҗед манарасында.
Мәсҗедләрне хылуб иттек
Сәвит заманасында...

Фатыйха абыстай тилергән иде.

Ун бармагымны күз алдыма төйнәп, Ходай Тәгаләгә инәлдем: «Сабырлыккайлар бир! Ун бармагым, ун фәрештәмнең канатлары бул! Ун фәрештәм, ун тапкыр төшереп, ун тапкыр күтәр! Ярабби!»

Ниһаять, тынычланып, ул үз хәленә кайтты.

— Тигез генә яши күрсеннәр! Киленебез, марҗа булса да, бик һәйбәт, бик уңган ди, ыланкаем. Бәлки әле, кайтып та күрерләр. Мәһәрләрем, асалы паласларым күтә! Ничек инде ул, марҗа да булсын ди, уңмасын да ди, шулай бит? Мин аны ничек кенәләр хурлыйм ди, шулай бит? Бар, хурлап кара! Кемне хурлыйсың — үзеңне хурлыйсың, шулай бит? Мин, хак мөслимә, шул түбәнлеккә барам диме?!

Фатыйха абыстай бүлмәне балкытып елмаеп җибәрде.

Ул үз акылында иде.

Өченче бер кайтуымда мин аның сөян кебек аксыл, кипкән гәүдәсен кемнеңдер ихатасында күреп калдым. «Бөтенләй алмашынды, бахыркай, — диде күршеләре Гыйззәт. — Тәки сүнеп бара бит кеше дигәнең. Шулай йорттан йортка йөреп, мәтрүшкә күзе җыя...»

Йорт ихатасына үттем. Бәбәй итәкле күлмәген кигән, аның өстеннән чәчкәле алъяпкыч бәйләгән Фатыйха абыстай миңа каршы чыкты.

— Ә-ә-ә, кайттыңмыни, Хәбир ыланкаем?! — диде ул, минем белән исәнләшмичә дә. — Бик әйбәт булды әле бу!.. Мәтрүшкә күзенә синңа да налук салам!.. Һәркемнән бер әчмуха мәтрүшкә күзе! Бер карасаң, күп тә түгел, шулай бит, ыланкаем? Әмма шуны да бирмиләр... Авылдашларны әйтәм! Син дә бирмәссең микән?

— Ә нәрсәгә ул сиңа, Фатыйха абыстай? — дидем мин, кызыксынып.

— Бәй, Тәлләттигә, бәбкәйләремә җибәрәм!.. — Ул кулындагы эскәкне уйнатып алды. — Һәр күзне эскәк белән чүплим!

Берничә ел авылга юл төшмәде.

Әмма хатларда Фатыйха абыстай турында хәбәрләр килә торды. Аның кояшлы-караңгылы булып алмашынып яшәве авыл өчен күптән инде сер түгел иде. Авылдашлар аны үз итеп кызганды, аның кайгысын үз кайгысы итеп эчкә яшерде. Хатынының җәй көне кар көрәп, кыш көне тырма күтәреп печән җыярга чыгып китү очракларын Закир абзый сиздермәскә тырышты, дөньясын шул хатыны белән өстерәде, зиһене ачылган чакларда аны, берни булмагандай, сугым ашына да, Коръән ашына да, кунак-мазарга да үзе белән йөртте. Менә, ниһаять, туган яклардан үкенечле хәбәр килеп иреште: үзе Тольяттиларга барып йөри алмаган, балалары кайткан хәлдә дә Сөендегә генә кайткан Фатыйха абыстай, баласының баласын сөюдән, аңа үз телен, үз иманын, үз бисмилласын сөендерүдән мәхрүм ителгән Фатыйха абыстай, якты кайгысыннан бер генә бөртек кара чәче дә калмаган, үзе дә самавыр сыман саргайган, зиһен белән зиһенсезлек, акыл белән акылсызлык, бербөтенлек белән алмашыну арасында тирбәлгән Фатыйха абыстай, Коръән битләре арасындагы зәгъфран чәчкәсе кебек кипкән-корышкан Фатыйха абыстай әбиләр чуагы өстендә үзенең ахирәте Шәмсекамәр кабере өстендә җан тәслим кыла...

Бу хәбәрне ишеткәннән соң, йөрәк өянәге булып, мине шифаханәгә салганнар.

Аны алмашынган чакларында чыгып китеп югала торган урман эчләреннән, су-басу буйларыннан, җәйләүләрдән өч көн буе эзлиләр. Бу көннәрдә үлем-китем булмаганлыктан, зиратка кереп тә карамыйлар — мәетне көньякка китәргә дип туплана башлаган кара каргалар туплавы табып бирә. Алар яу булып каберлек өстендә өереләләр, кар да кар килеп, авылга шом салалар һәм гәүдәне күтәреп, зираттан алып чыккач кына, авыл өстендә хушлашу боҗрасы ясап, ерак сәфәргә чыгалар.

Фатыйха абыстайны, баш астына әтисенең Коръәнен салып, зур хөрмәт белән җирлиләр.

Менә мин хәзер аның газиз улы һәм шул газизенең гаиләсе белән очрашырга тиешмен.

Әйберләремне алып, кунакханәдән чыктым. Яз тәмамланып баруга карамастан, агачлар быел яшәрергә ашыкмый. Җир әле булса җылынып бетмәгән, күрәсең, табаннарга туфрактан салкын сылаша. Һич кенә дә яфрак ярырга теләмәгән куаклар миннән, яшелләндерү мөһәндисеннән качканнар — артка чигенгәннәр кебек күренә. Ворошилов урамын кисеп, Луначарскийга үткәч, мин кирәкле йортны тиз таптым.

Лифт сигезенче катка йөгертеп күтәрде. Ишектә мин көткән «Мәкәримов С.З.» урынына нindидер «Макаренко С.З.» дигән язуны күреп, мин бик гаҗизләндем — бутамаганмындыр ла? Шикләнеп кенә кыңгырау төймәсенә бастым. Зеңгелдәү бик көчле булып чыкты, ахры, мәйданчыктагы дүрт фатирның дүртесеннән дә яшелле-зәңгәрле аһәңнәрдә этләр өрде:

— Һау-һау! Гав-гав! Бр-брр! Ләң-ләң!..

— Пош-шол, Барсик! — Каршысында мин басып торган фатир эченнән ир тавышы ишетелде. Келә ачылуга, ишектән бик нык үзгәргән, әмма әле балачакта, гафу итегез, маңкасын агыза-агыза безнең арттан тәпиләгән авылдашымны танып булган адәм заты күренде:

— Е-мое! Кемне күрәм!.. Исән генәме, Хәбир абзый!..

Сөендек мине ишек аша тартып алып диярлек кочаклады.

— Әйдә, чишен!..

Мин аның кулына күчтәнәчләремне сондым.

Өс киемемне кайсы чөйгә эләргә, аннан мине кайсы бүлмәгә алып керергә, аннан кая утыртырга белми бөтерелгән Сөендекнең авызыннан яшь, әле генә эчелгән аракы исе килеп куйды. Аяк астында уралган эт белән залга үткән арада, йокы бүлмәсеннән йокының үзе сыман чайкалып, симез, билсез-нисез генә турыдан төшкән квадрат гәүдәле, өстенә капланган мул халаты белән нindидер хәрби мөлкәтне хәтерләткән ханым килеп чыкты.

— Хатыным Әлефтинә Петрауна була. — Сөендек миңа таба ымлады. — Ты не мужеш, Әли, пристәвит, авылдашыбыз, туес землягыбыз, дәдә Хайдар сам пришул!..

— Ага. Вижу.

Алевтина Петровна шундук аш-су бүлмәсенә чумды, суыткычны шалтыр-болтыр ачкалый, газ плитәсендә чаж-чож килә башлады.

Фатирда болыт астына бер кереп, бер чыгып торган эт кояшы яктысы һәм ачыган эт исе иде. Биредәге тормышның

чагыштырмача җитешлеге, хатынның безнең турыда кайгыртучанлык күрсәтеп, аш-су әзерләп маташуы күңелемдә разыйлык тудырды булса кирәк, телемә беренче күрешүдә гаилә башлыгына әйтелергә тиешле хушбүләк сүзләре килде:

— Бичәнең тәгаенен тапкансың, Сөендек туган. Маладис. Күзең очлы икән.

— Безнең күзләр, Хәбир абзый, үзең беләсең, солыдан әбчүк* эзләп очланды бит. — Сөендек мут елмаеп куйды. — Е-мое! Онытып торам тагын!.. Хәзер!..

Һәм ул тышкы ишектән юк булды.

Мин фатирны күздән кичердем. Гөлләр монда да күренмәде. Җиһазлар арасында Фатыйха абыстайның асалы паласларын, тәрәз кашагаларына элә торган чүпләмле тастымалларын эзләдем. Идән, хәтта стеналар келәм белән капланган булса да, асалы паласлар күзгә чалынмады. Күкеле сәгатьнең ике як канатында хуҗаларның ялгызак, парлап, балалары белән төшкән фотосурәтләре. Фатыйха абыстай белән Закир абзыйга гына урын табылмаган иде монда. Кечкенә китап киштәсе аллы-гөлле тышлыктагы чит ил детективлары белән шыплап тутырылган. Алар арасында Пушкин да, Тукай да шәйләнмәде. Кеше кулында майланып, таушалып беткән бу үтереш-суеш әсбапларыннан яңгырлы елда тозлап өелгән, җилдә җилләнмичә, сәнәктән үткәзелмичә сырсыган печән исе аңкый иде.

Шешәләре белән шалтырап, ниһаять, Сөендек килеп керде. Аның тирле борыныннан бөтен өй эче тирләгәндәй итте.

— Әйдә, Хәбир абзый, чәй әзер!..

Өстәлдә безне җылытылган кәбестә ашы, йомыркада куырылган дуңгыз ите, кәбестә бөккәннәре, тагын да тозлы кәбестә һәм Сөендек әле генә токчаеннан чыгарып куйган аракы шешәсе каршылады.

— Ничек кенәләр Тольяттига килергә иттең дә, ничек кенәләр безгә керергә иттең, Хәбир абзый! — дип өзгәләнде мине түргә утырта-утырта Сөендек. Аның һичбер тартынусыз саф татар телендә сөйләшүе, саф мәкамендә Фатыйха абыстай чалымнары ялтырап китте. — Рәхмәт, Хәбир абзый, яме!.. Әйдә, Әли, и ты с нәми!..

Газ плитәсе белән өстәл арасын шыплап тутырып, урталыкка киленебез Алевтина да утырды. Аның йөзендә кунакка булган куаныч та, үкенеч тә чагылмый иде. Киресенчә, ул үтәгән мәшәкатьләр көндәлек, табигый канунны тәшкил иткәнлектән, килен кеше миңа карата тәмам битараф иде. Мин

---

* Овсюг — кара, чүп солы. Сугыштан соңгы елларда, кыш айларында, чүп солыдан арындыру өчен һәр гаиләгә кеше башына берәр центнердан орлыклык солы тараталар иде. *(Автор искәрмәсе.)*

аның өчен сорау билгесенә дә, өндәү билгесенә дә әверелә алмадым, күрәсең. Мин аның өчен гүяки сөекле иренең авылдашы, карындашы түгел, әле кайчан гына буш булган урындыктагы «Бу бәндә кайчан китәр икән?» дигән артык җиһаз гына идем...

Сөендек аракылы бәллүрләрне минем хөрмәткә тәкъдим итте. Сары чәчләре меңләгән вак, сырга сыман бөдрәләр белән калтыранган, бер күзе — бер, икенчесе гүяки икенче басуда урак урган күзләрен уйнаклаткан Алевтина Петровна белән Сөендек өйрәнелгән алымнар белән эчеп җибәрделәр. Мин үземне уңайсыз тойдым: ашказаны хастасын яңадан кузгатуым турында укучыма әйткән идем шикелле инде. Хәлемне аңлатырга тырышсам да, Сөендек ай-вайга куймады:

— Е-мое, Хәбир абзый! Син нәрсә, пнимаешь? Как не раднуй!..

— Бергәлек хакына! — Алевтина Петровна беренче тапкыр елмаеп җибәрде. — Сез инде бөтенләй! Бергәлек хакына яһүд тә асылынган.

Сөендек мине чын-чынлап буа, көчләп эчерергә кереште:

— Син аны, Хәбир абзыкаем, ашаганчы эч. Ашагач, исертми ул!..

Кешегә каршылык күрсәтә белмим. Шул сыйфатым аркасында күпме тапкыр көлкегә калдым инде мин? Бу юлы да бирештем булса кирәк. Нәрсә булса да булыр дип, ялкынлы суны бугазымнан эчкә үткәрдем. Ашказанымда нидер көйдереп алды, баш миемә, арка үзәгемә җылы шаукым йөгерде. Мин, көне буе диярлек кайнар аш күрмәгән мосафир, ипиләп кәбестә ашын менгезә башладым.

Бәллүрләр яңадан тутырылган иде. Мин хуҗалардан авыл, әтиләре, вафат булган әниләре — Фатыйха абыстай турында бер генә булса да сүз көттем. Әмма алар сүзне миннән көтә иде.

— Хөрмәтле Сөендек туган һәм Алевтина Петровна! Сезнең белән очрашуга мин ифрат та шатмын... — дидем мин, һәр сүзне авырлык белән сытып чыгаргандай. Мин бу минутта мөнбәрдән нотык тоткан райком вәкилен хәтерләткәнмендер дип уйлыйм. — Сөендекне утыз елга якын күргәнем юк иде. Соңлап булса да, сезләрне кавышуыгыз белән кайнар котлыйм. Сез вакытыгызны бушка үткәрмәгәнсез. Бик матур гаилә коргансыз, балалар үстергәнсез...

— Балаларыбызның икесе дә музыка мәктәбен тәмамладылар! — дип бүлдерде Сөендек. — Татарча да беләләр!..

— Мин бу бәллүрләрне сезнең тигез мәхәббәтегез, балаларыгызның матур киләчәге өчен тәкъдим итәм!..

— Е-мое, Хәбир абзыкаем! Рәхмәт сиңа, яме! Мәхәббәт — это... За мәхәббәт пьем, Әленушка! — Сөендек сыеклыкны

авызына койды да, урындыгын шыгырдатып, хатынына үрелде һәм, чупылдатып, битеннән үбеп алды. — Минем Әлиям... Минем Әлиям исән генә булсын! Танышкан чакларда, кхе-кхе... мине: «Татарин мой, йәдрүний мой!» — дип кенә сөя иде... — Сөендек көтмәгәндә ике йодрыгы белән өстәлгә шап итеп сукты, теге бүлмәдә тыныч кына яткан эт, бу тавышка лүрт-лүрт йөгереп кереп, Алевтина Петровнаның бот аралларында урала башлады.

— Акылсызланма, Саша!.. Ычкындың мәллә? Мин сине беркайчан да татар дип атамадым, ә бары тик «Тыгыз тәнлем минем, сөннәтлем минем!» генә дия идем.

Өстәл астында дау күтәреп, эт тынычлыгыбызны алды.

— Яле, урыныңа, Мәкәримов! — диде Алевтина Петровна, эткә аягы белән тибеп. — Урыныңа бар, дим!

Нәселле пинчер стенага елышып кына үз урынына чыгып китте.

— Минем фамилиямне эт белән бутама, Әли! — диде Сөендек, хатынына куркыныч караш ташлап. — Шашма, дим!

— Син мәзәкне аңламыйсыңмыни? Шаярырга да ярамыймы?

Минем башта әллә нинди сораулар, уйлар кайнаша башлады. Кулга гармун аласы, «Карурман»ны сузасы, эчебездәге барлык сагышларны бушатасы, рәхәтләнеп үз телебездә сөйләшәсе, әрләшкән хәлдә дә үз телебездә генә әрләшәсе, барлык туган-тумачаларны, танышларны искә төшерәсе килеп китте.

Сөендек бушаган шешәсен өстәл астына шудырды да аннан икенчесен тартып чыгарды.

— Авылга кайтканыгыз бармы соң? — дип сорадым мин Алевтина Петровнадан. — Сагындырамы?

— Балалар белән бер тапкыр кайткан идем. Миңа нәрсә калган инде анда? Сашаның әнисе үлгән. Әтисе яңадан өйләнгән...

Фатыйха абыстайның улы кадәр улын бүләк иткән Айтуганда килене үз гомерендә бер генә тапкыр булган икән. Бик тә аңлашыла бу — нәрсә югалткан ул анда? Туганнарын югалтмаган бит! Сөендекне үз итеп «Саша» дип кенә атавы да, иренең нәселдән килгән фамилиясен үз итеп эткә кушуы да аңлашыла. «Әни» дими, «Сашаның әнисе», «Әти» дими, «Сашаның әтисе» ди бит ул шулай ук «үз итеп».

Кәбестә ашын, кыстамасалар да, урынына менгезеп куйган идем. Күлмәгенең изүе имчәкләренә кадәр ачылган, итәкләре тез башларыннан итләч бот урталарына менеп җыерылган Алевтина Петровна мине йомыркада куырылган дуңгыз ите белән сыйлый башлады:

— Ашагыз сез! Дуңгыз ите белән минтай — безнең төп азыгыбыз. Кибеттә бит барысы да кыйммәт хәзер...

Залда күкеле сәгать сукты. Санадым — тугыз тапкыр. «Миңа бик озакларга ярамый, — дип нәтиҗә ясадым мин үземә. — Иртәнге алтыдан да калмый Чаллыга сыпырырга кирәк!»

Шуны гына көткәндәй, Алевтина Петровна тагын бер бәллүрне үзәгенә сеңдерде дә, өстәл тирәсен ду китереп, урыннан күтәрелде һәм: «Сезгә, ирләргә комачауламыйм», — дип, бүлмәсенә кереп ауды.

Ярыйсы гына кызып алган Сөендек бәллүрләргә яңадан аракы салды, миннән тагын бер илаһи сүз көткәндәй, күзләремә текәлде. Иманым камил, җир йөзендә хәзер аңардан да бәхетлерәк кеше юк иде. Кайчандыр мин Баллы Елга буйларында күргән зәп-зәңгәр, инде хәзер зәңгәрлеге шактый сыекланган шул ук күзләр. Алар мин килгән шатлыктан елмаялар. Күзгә күренеп картая, тиресе бәлҗери, көпшәкләнә төшкән шул ук табак бит, шул ук, әмма әле генә аракыда җепшеп, үз абруен белеп иркенли, йомшара башлаган бәрәңге танау, шул ук, әмма алсулыклары уңган калын иреннәр — барысы да мин килгән шатлыктан куана иде...

Мин бу куанычның серен эзләп талчыктым. Бу «Нәрсә ул бәхет? Сөендек чын дәрәҗәсендә бәхетлеме?» дигән сорауга җавап табуга тиң иде.

Дөресен әйткәндә, мин бит Сөендек-Сашаның онытылган, үзе килеп күрмәсә, исенә дә төшмәгән авылдашы гына идем. Туганы, якын кардәше дә түгел, билләһи газыйм! Нидән иде бу куанычның сере? Җирдәнме? Җирдән булса, җирдә нинди сер бар? Суданмы? Судан булса, суда нинди сер бар? Һаваданмы бу? Һавадан булса, һавада нинди сер бар? Каннанмы бу? Каннан булса, канда нинди сер бар?! Мин шул сер иясе Фатыйха абыстай авазларын көтеп утырдым Сөендектән. Әмма бу авазлар ишетелмәде.

Залда тагын сәгать сукты. Инде ун тапкыр.

Заман ничек кенә киеренке һәм файдасыз булмасын, вакыт ага.

Әйе, ага, чөнки аның эше юк. Шуның белән артык булдыклы, эшлекле булырга яраткан кешеләрне урынына утырта ул. Заман белән вакыт тигез, туры килүчән мөнәсәбәттә булса, тормышның кызыгы, җырның мәгънәсе калмаган булыр иде. Заман белән вакытны тигезләргә теләп, шәхес урталай ярыла. Дөресрәге, алар шәхеснең үзендә урталай ярыла. Әмма кайчан? Кешесенә карап. Акылына карап. Хиссиятенә, мөмкинлегенә карап. Вакыт бирәүгә тулы файдага акса, икенчегә тулысы белән файдасызга агуы мөмкин. Бу инде тормыш — «торып тормыш» дип атала.

— Тормышлар ничек, Сөендек? — дидем мин, икәүдән-икәү калгач. — Бик читен түгелме?

— Әйбәт, Хәбир абзый... Әйдә, тәүдә күтәреп куйыйк әле... Син дә инде, әллә нигә бер килеп, утырасың как нерадную... — Ул эчеп җибәрде. — Кәбестәсеннән җитеш. Минем Әлия тозлау-мозлауга ифрат оста ул. Кар эреп бетми, гөмбә ташый башлый. Анавы көнне, мин сиңа әйтим, безнең авылдан Хәкимҗан танавы шикелле эре гөмбәләр алып кайткан, әй!.. Тормыш дигәннән. Аллага шөкер, Хәбир абзый. Үзем ВАЗда автомобильләр җыючы, хатыным аларны буяучы булып эшлибез. Алты ай акча алган юк, әмма, үзең күрәсең, ач-ялангач яшәмибез. Дүрт бүлмәле фатирыбыз, машинабыз бар. Улыбыз Әлександерга егерме биш, кызыбыз Светланага егерме бер. Соңрак кайтырлар, үзең күрерсең әле... Гаиләле булырга йөриләр, Хәбир абзыкаем. Ике туйны берьюлы чәпәсәләр, ниләр генә эшләрмен, дип, төннәрен йоклый алмыйм... Балаларым бик тә әти җанлы, тәрбиялеләр, Хәбир абзыкаем! — Аның күзләре дымланды. Күңеле йомшарып китеп булса кирәк, керфек очларындагы яшьләрен сөртеп алды. — Минем балаларым!.. Әйдә, күтәр әле, е-мое, утырасың как нерадную!..

— Улыңның исеме Александр бит әле?

— Әйе, Әлександер. М-малай туса, син кушасың, кыз туса, м-мин кушам, дип килешкән идек хатын белән. Шулай иттек тә куйдык. Кызыма м-м-мин куштым. М-монысы татар исеме — Светлана. Беркемгә дә әбидне түгел, шулай бит? — Ул нишләптер «м» хәрефендә, бигрәк тә «мин» дигән сүздә тотлыга башлады. — Тигезлек кирәк, взәимне сагласи кирәк, шулай бит? Ә м-минем м-малай — е-мое! — миннән күпкә озын, таза, берне чүкетсә, шифер кадагы кебек сеңәсең дә куясың! Ха-ха-ха!.. Ә-әй, бер утыргач утырыйк әле, Хәбир абзыкаем. Тот әле, тот! — Ул, артка янтая биреп, тагын берне эчеп җибәрде. — Исем дигәннән. Без бит, Хәбир абзыкаем, урыслар арасында яшибез. Кем арбасына утырабыз, шуның җырын җырлыйбыз, шулай бит? М-менә м-м-минем исем-фамилиямне алыйк. Уңышсыз,шулай бит? Ну, ыхту такуй Мәкәримов? Ну ышты такуй Сөендек? Урыслар «с» урынына «х» өстиләр дә пырх-пырх көләләр. Хатынның фамилиясен алдым да куйдым. М-м-мак-ка-рен-ко! Матур бит? Яңгырый бит? Юк, авыл өчен, синең өчен мин мәңгегә Мәкәримов! Бу бит суща фурмы. — Ул миңа фетнәчеләрчә күз кысты. — М-монда, Тәлләттидә, шәһәрнең ике йөз илле еллыгы уңаеннан бигрәк тә котыралар. Эстинкә Рәзин, Тимәфи Йәрмәк — аталарыбыз, пнимәете ли!.. «Выплывают эрәсписние Эстинки Рәзинә челны...» — Ул тавышын калынайтып җырлап та маташты. — «Татар, чыгып тай моннан!» дип, алар безгә турыдан-туры бәйләнми бәйләнүен, әмма кысалар, малай, кысалар! Фатир алганда, аны киңәйткәндә,

балаларга садик-мадик, сәтсиәл зашита мәсьәләләрендә М-мәкәримовларны искә төшерәләр!..

— Мондагы татар җәмгыяте мәчет салдыра, диләр. Татарлар белән аралашканың юкмы?

— Юк, Хәйдәр абзый. Андый нәбхәдимесне күрмим. Алар турында шәһәр гәзитендә еш язып торалар торуын. Мижнәтсәнәлний рузен тараталар, дип. Мәктәп-фәлән, афтанумия таләп итәләр, дип. Һич аңламыйм, нәрсәгә кирәктер инде алар. М-менә без, Айтуган м-малайлары, югалып калдыкмы? Син, институт бетереп, бик зур инжинир булдың. М-мин инде сигез класс белән ВАЗның күренекле афтамабиль җыючысы булдым. Исемем ун ел буе пирдәвикләр тактасыннан төшмәде. Кирәк икән ике сминә, кирәк икән ял көнне дә эшләдем. М-монавы үләтләр Ысысырны таркаткач кына, партияне аяктан еккач кына китте ул тактаның кадере. Бик тә кирәкле такта иде ул югыйсә! Әйдә, тот әле берне, утырасың как нераднуй!..

Минем алда авылдашым — татарның бөек, мең еллык байлыгының бөек исраф итүчесе — мөртәте утыра иде. Тагын да ачыклабрак әйткәндә, иленнән, теленнән, диненнән ваз кичкән папуасы — ләштер-лөштер кабиләсе вәкиле. Аһ, моңсу, бик моңсу иде миңа! Кунакханәдәге чактан да моңсурак. Нигә килдем? Ә нәрсә көтә идем мин? Юк, яшәү мәгънәсе миллионлаган кешеләре белән бергә упкынга очкан бу ахырзамани чорда минем кемнедер милләтен, динен алыштырганы өчен генә гаепләргә хакым да юктыр? Кем мин үзем — галәми хөкемдар түгелдер бит? Ярый, булды. Мин бүтән бу хакта уйланмаячакмын да. Кирәкми миңа яшеллеге дә, милләте дә, чурты да!.. Бүгеннән үк. Шушы минуттан, шушы секундтан ук. Менә тынычландым да. Тынычландым да шикелле. Шундук миемне тынычландыра торган уй сызып үтте: «Бу адәм татар дөньясында берәү генә. Берәү генә булырга тиеш. Әгәр алар икәү икән, миңа элмәккә керергә кирәк. Әгәр алар чынлап та икәү икән инде, димәк, татар милләте мөртәтлек чорына күчкән». Менә сиңа мә! Мин әле генә үземне тынычландым дип уйлаган идем. Эчемдәге халәтне мин һич кенә дә аңлата алмый идем. Мондый халәтне шул ук татарның «Әти үлеп ята — көлеп эчем ката» дигән мәкале белән җиткереп булыр иде шикелле.

Сөендек терсәкләренә таянды, башын учларына салып, күзләрен йомды. Аның башы гүяки киселгән башак сыман кыелды да төште. Мин нишләргә белми, урынымда кыбырсып, Сөендекне һәм тирә-ягымны күздән кичердем. Аһ, шушы һич кенә дә кирәкмәс күзәтүчәнлек! Закир абзыйдан мирас булып калган чабата кашлар. Итләч түгәрәк йөз һәм озынча итләч

танау. Чынаяк тоткасы кебек кечкенә колаклар. Ачык изүдән дөнья күрергә чыккан йонлач күкрәк. Ә Фатыйха абыстайдан? Бит алмаларында сакланып калган уймак чокырлар. Әлбәттә, зәңгәр күзләр. Әмма бу йөз, бу килеш-килбәт Закир абзый белән Фатыйха абыстайныкы, безнең авылныкы, безнең җирнеке кебек кара-кучкыл түгел, ә кәбестә суы кебек аксыл сары, дуңгыз ите шикелле шешенке иде. Йа Хода, ашаган тәгам тән төкләрен дә үзгәртә мәллә?! Шулайдыр, шулай булмаса, һәр кавемнең үз ашы, үз эчемлеге, үз яшәү тәгълиматы булмас иде! Хәтта үз тараканы да!..

Сөендек күзләрен ачты.

— Н-н-нәрсә, Х-хәбир абзый? — диде ул, тәмам тотлыгып. — Ә-әйдә, с-с-сүзеңне әйт!

— Тараканнар, — дидем мин, көтмәгәндә кунакханәдәге җанварларны исемә төшереп.

— К-күп шул. К-күршеләрдән к-керәләр. Ә-ә, т-тараканга да игътибар итеп т-торсаң!.. С-сүзеңне әйт!

Ул арыган иде. Бу гамьсез сөйләшүне тәмамлау ниятендә әйләндердем дә салдым:

— Мин бу тостымны, Сөендек туган, мөртәтлек хакына тәкъдим итәм!

— А-а-аңламыйм, м-монысы нәрсә т-тагын? Н-нинди м-мөртәтлек?

— Оптимизм аша килгән идиотизм хакына күтәрик, дим, яшәсен идиотизм!

— Әллә кайчан ш-шулай диләр аны! М-менә м-монысы өчен эчәргә б-була!..

Ул алдындагысын тагын эчеп җибәрде. Сүзләрнең мәгънәсен аңламады шикелле.

Ишектә кыңгырау челтерәде. Эт, гадәттәгечә чабып килеп, һау-һау өрде. Сөендек чайкала-чайкала ишекне ачарга китте.

Аннан, инде шактый соң булуга карамастан, шаулашып парлы егетләр һәм кызлар күренде. Сөендек егетләрнең иң озынын кулыннан өстерәп диярлек минем янга китерде һәм бер горурлык белән татарчалап таныштыра башлады:

— Хәбир абзыкаем, б-бу м-минем улым б-була. Абыеңа к-кулыңны суз. Руку пртәни! Ә әнә т-тегесе б-булачак к-киленебез В-валентина б-була. Әлександер, Х-хәбир абзыкаем дивирнә бывал, картатайку-картинайку видал. По-татарски «картинәй» эскажи, ә? Минем өчен эскәжи!

— Заткнись. — Егет әтисенә нәфрәтле караш ташлады. — Тагын исерек.

— Исерек түгел, бераз эчкән...

— Үз телеңдә бытылдыйсың икән, димәк, исерек.

Улының мондый шаянлыгына игътибар итмәскә өйрәнгән Сөендек, берни булмагандай, алпан-тилпән килеп, яңадан ишек

катына китте һәм кызын, кочаклап алып, минем тарафка тарта башлады.

— Монысы минем с-сөекле к-кызым С-светлана була...

— Кит әле, әти!

Светлана әтисенең кулын иңеннән ышырып төшерде һәм яшьләрне аш-су бүлмәсенә чакырды.

Алар кереп тулгач, кечкенә бүлмә кысанланды да куйды. Александр әтисеннән ашарга сорады. Үтенечтә татарчага «тыгыну» дип тәрҗемә ителә торган «пожрать» дигән тәгъбир яңгырады. Алевтина Петровна яткан урыныннан гына яшьләргә суыткычтагы йомыркалардан тәбә әзерләргә боерды.

Яшьләрне калдырып без залга үткәндә, Алевтина Петровнаның юан беләкле, ыргак сыман куллары Сөендекне үз бүлмәсенә өермә сыман суырып алды. Ул мыгырданып маташты маташуын. Әмма Алевтина Петровна аны ычкындырмады. Бүлмәдә нәрсәдер гөрселдәде — хатын ирен, этәреп, урынына аударды булса кирәк.

Мин, чишенеп, кәнәфидә җәелгән урынга барып яттым. Без эт белән бергә залга туры килдек.

Аш-су бүлмәсендә төне буе магнитофон үкерде. Ул төнге икедә генә тынды. Яшьләр, парлашып, буш бүлмәләргә кереп яттылар.

Мин шундук онытылганмын. Әмма бу йокы түгел иде. Гүя мин уяу килеш йоклыйм. Күз алдымнан Фатыйха абыстайның ак сыны китмәде. Әйтерсең мин аның турында очы-кырые булмаган мексикан фильмы карыйм. Имеш, аны үзенең авылдагы агач йортыннан шәһәрнең күп катлы ятагына көчләп кертергә итәләр. Ул тартыша. Менә барысы да югала. Баксаң, сөргән җир икән. Менә ул иңеннән шуып төшкән ак яулыгын намазлык итеп җиргә җәя дә намаз укый башлый. Түбәсендә җир кебек кара каргалар өерелә. Ул ун бармагын күз алмаларына терәп диярлек Ходайга ялвара:

— И Раббем, сагынычымны кире кайтар! Ун бармагымның ун фәрештәсе, Сөендегемә канатлар бирегез! Ун фәрештәм, Сөендегемне ун мәртәбә төшереп, ун мәртәбә күтәр!..

Каргалар югала. Фатыйха абыстай исә, ак фәрештәгә әверелеп, кара җир өстеннән бөтерелеп-бөтерелеп, мәңгелеккә сеңә...

Бу манзарадан мин тәмам уянам, күзләремне шар ачам. Нәрсә җитми бу өйгә? Фатыйха абыстай җитми. Биленә кадәр төшереп бәйләгән ак яулыгы, йөзендәге яктылыгы, иманлы теле җитми. Тукта, ул бит бердәнбер Сөендегенә тел биргән булган?! Сөендектә ул тел бар бит, ул бит телсез түгел. Шулай да кая киткән соң ул тел? Әлбәттә, Фатыйха абыстайның иманы җитми. Тукта, дим мин, ул бит бердәнбер

Сөендегенә бисмилласына төреп, иманын биргән булган. Кая булган соң ул иман һәм үзәк матдәсе? Минем тәнем өзгәләнә, ачыргалана, чәнчешә башлый. Сеңдерә, үз иттерә алмаганмы ул аларны? Сеңдерттереп җиткермәгәннәрме? Сеңдереп җиткерттермәгәннәрме? Кинәт күз алдымда, һавада, утлы гөрзиләр белән барыбер дигән тәкъдир сүзе языла. Арыган чакларымда шундый күренешләр килгәли шул миңа. Барыбер. Ягъни нинди телдә укысаң да, кем чанасына утырып, кем җырын җырласаң да, кем белән кавышсаң да, барыбер. Ул барыбер булачак, чөнки бу илдә бары тик бәхетле генә булырга мөмкин. Туган җирендә яшәсәң дә, яшәмәсәң дә, чәчкә үстерсәң, үстермәсәң дә, барыбер. Илленче-алтмышынчы еллар арасында тормышыбызда хасил булган афәт — *интербарыбер*. Шушы барыбер тигезлеген тәрбияләгән туган телсез мәктәп, туган телсез радио-телевидение, туган телсез урам ашамаганмы Сөендекнең телен һәм иманын? Бәлки, ул дистәләгән миллион татарда бердәнбер нөсхәдәге мөртәттер? Мин эсселе-суыклы булып китәм. Эт, аш-су бүлмәсенә чыгып, су эчә башлады. Сөендек ыңгырашты. «Юк! — дим мин, тешләремне шыгырдатып. — Ул бердәнбер булырга тиеш. *Барыбернең бердәнбере*. Әгәр мондый мөртәт икәү булса, миңа асылынырга асыл агач эзләргә кирәк».

Эт урынына кереп ятты.

Өч бүлмәдә дә гырлап йоклыйлар иде.

Күкеле сәгать дүртне сукты.

Эт шыңшып куйды.

Сөендек мөртәтлегендә Алевтина Петровнаны гаепләү гадел булмас иде. Киресенчә, аны мактау гына фарыз. Алар Ходай Тәгалә алдында икесе дә тигез, әмма бу тигезлек арасындагы кечкенә аерма шунда: Алевтина Петровна уйламыйча-нитмичә элмәк үрсә, Сөендек бу элмәккә тирәнтен уйлап, үз теләге белән барып кергән. Алевтина Петровнага, бу мәсләктән чыгып караганда, хатын-кызга, ни дисәң дә, ир кирәк — гаилә кирәк булган һәм ул аны, милләт-кавемгә бүлмичә, үзе инануынча, «сөюе» аша тапкан, ул тел, иман аерымлыгы турында уйлап та тормаган, чөнки бу мирас аңа, ул уйлавынча, күктән һәм мәңгелеккә төшкән. Тел һәм иман бары тик аныкы гына булуы мөмкин. Сөендек тә, үзен-үзе ышандыруынча, булачак хатынын «сөюе» аша тапкан, әмма ул мондый җаваплы адымны кат-кат уйлап ясаган, үзен аклауның шартларын ачыклаган: аның теле дә, иманы да бүген-иртәгә бетәчәк вакытлы нәрсәләр. Барыбер бетәчәк байлыклар. Мәңгелек байлыгын — «сөюенең» җимешен сатып, ул үзеннән дә хәерчерәккә әҗәткә кергән. Барыбер бетәчәк патшалыкта патша булган һәм бөлгән.

Алевтина Петровна белән Сөендекнең кавышуы Төньяк

котып белән Африканы бергә кушып, яңа табигать, яңа климат, яңа кыйтга барлыкка китерү белән бер иде. Мәңге кушылмаска тиешле бу ике кыйтга, кушылып, яшәешнең тигезлеген югалта. Алар ике мөстәкыйль йолдыз, ике тәгълимат, ике иман, ике яшәү рәвеше. Мөстәкыйль булганнары өчен аларны кимсетү дә, гаепләү дә дөрес түгел. Бу ике яшәү рәвешенең бер булып төйнәлүе үзе генә дә бәхетсезлек инде.

Күрәсең, без, кешеләр һәм милләтләр, чәчәкләр һәм үсемлекләр үстергәндәге шикелле, чынбарлык шартлылыкларын инкяр итәбез һәм отылабыз. Әлбәттә, табигать кануннарын кешелек кануннары белән төгәл тәңгәл куярга ярамый. Ә шулай да, шулай да... Без, кешеләр, тормыш чәчәкләре түгелмени? Бер чәчәкнең икенчесен үтерү аша гарип чәчәк атуы — мәгънәсезлек. Кабатланмас, төрле чәчәкләр берберсен рәттән куйганны яратмый. Роза белән канәфер үзара көнләшкән сыман, бер-берсен хуш исләре белән үтерә, тончыктыра. Ландыш исә барлык чәчәкләр белән дә дошман мөнәсәбәттә. Чаган, өрәңге янындагы алмагач беркайчан да мантый алмый. Мичурин карт алмагачта чия үстереп карады, әмма кеше көлдерүдән уза алмады. Елкы малы белән дуңгыз бер абзарда яши алмый — ат унбиш-егерме көннән ашказаны агуланып үлә...

Сәгать бишне сукты.

Мин сикереп тордым һәм киенә башладым. Эт тагын шыңшып куйды. Безнең бимазадан уянган Алевтина Петровна төрткәләде булса кирәк, күзләре шешенгән, чәчләре пумаладай тузгыган авылдашым, мин юынып-кырынып азапланган арада, аш-су бүлмәсенә үтте, чәй куйганнан соң, шатыр-ботыр килеп кичә калган шешә төбен эзли башлады.

— Е-мое! Эчеп бетергәннәр, Хәбир абзыкаем. — Аның тамагы карлыккан иде. Безгә баш төзәтергә дә калдырмаганнар. Күршеләргә кереп чыгыйммы?

— Кирәкмәс, Сөендек. Миңа алтыда юлга чыгарга кирәк.

— Суыткычтан йомырка алып, дуңгыз маенда кыздыр! — дип кычкырды Алевтина Петровна. — Әгәр бүген дә аракы тыгынсаң, өйгә кайтып керәсе булма, хайван!

Без җиңелчә генә чәй эчтек.

— Аракы белән ничек? Еш кабасыңмы?

— Соңгы вакытта эчкәлим шул, Хәбир абзыкаем. Бөтенләй дә эчмәс идем... Нәрсәдер җитми. Кемдер җитми. Бушлык, дим микән инде... Әллә ниткән үч котыра җанда. Югыйсә гаиләдә дә тыныч. Әллә картая бару галәмәте микән бу, Хәбир абзый? — Ниндидер теләктәшлек көтеп, ул минем күзләремә текәлде. — Шул нәрсә көчәя барса, нишләрмен икән?

Егеттә өмет бар иде әле. Ул җанындагы чирнең исемен эзли иде.

— Авылга кайтып тор бераз, — дидем мин. — Сагынганнар анда сине.

— Быел кайтып булмас шул. Ике туй бергә килергә тора бит…

Урамда безне җылы җил каршылады. Көн инде тәмам яктырган булса да, күк йөзе чекерәеп янган йолдызлар белән мыжгыган иде. Агачлар бу җылы төндә дә яфрак ярып өлгермәгәннәр икән.

Менә Ворошилов урамы буйлап уяулы-йокылы автобус күренде.

Хушлашканда ул мине кысып кочаклады.

— Килгәндә керергә онытма! Менә ничек рәхәт булып калды!

— Исән бул, Сөендек. Тагын күрешергә язсын.

…Чаллыга кайтып җиткәнче мин үземне битәрләдем: бәлки, миңа җылы сүзләрне кызганырга кирәкмәгәндер? Бәлки, мин авылдашыма ниндидер рухи ярдәм дә күрсәтә алганмындыр? Сорыймы соң ул аны? Татарстанга таба яшәрә барган урман акланнарында Фатыйха абыстай ак алъяпкычына Сөендегенә эскәк белән мәтрүшкә күзләре җыйган сыман күренде миңа. Бәлки, чынлап та шулайдыр? Бәлки, ул мәтрүшкә күзләреннән Сөендек тә, аның балалары да савыгыр?

Камышлыны чыккач булса кирәк, әле балачагымда Фатыйха абыстай авызыннан язып алынган бәет хәтергә килде. «Кызын попка оттырган Мостафа мулла бәете» дип атала ул.

Зөлхәбирә күлмәк, әй, тектергән,
Итәгенә ыштуф тоттырган.
Әй, Мостафа мулла, ил мулласы,
Кәрткә уйнап кызын оттырган.
Кызыл гына тәпиле, әй, күгәрчен,
Сөбханалла, диеп лә оча ла.
Озын гына чәчле Микулай поп,
Сөйгән ярым, диеп лә коча ла.
Чиркәү баскычлары бигрәк биек,
Тез буынкайларым тала ла.
Әнкәемә минем һич үпкәм юк,
Әткәемә хәтерем кала ла…

Мин ул чакта, әлбәттә, яшелләндерү буенча мөһәндис түгел идем әле.

«Юк, бу барыбер мөртәт, — дидем мин, Чаллыда автобустан чыкканда. — Һәм татардагы бердәнбер мөртәт. Әгәр алар икәү булса, миңа, һичшиксез, асылыну өчен асыл агач эзләргә кала».

*Май — август, 1997 ел.*
*Чаллы — Чехово, Башкортстан*

# БЕРЛИНГА ХАТ

*Рейхстаг түбәсенә беренче*
*булып байрак кадаган*
*Гази Заһитов истәлегенә*

Әгәренки Таифә җиңги белән Садриҗәләл абзыйның гаилә язмышын күз алдына китерә алган булсалар, Гитлер белән Сталин икенче бөтендөнья сугышын башламаган да булырлар иде, бәлки. Әгәренки-бәлки, дибез, чөнки ни дисәң дә, әгәренки-бәлки шул. Садриҗәләл абзыйның үзен, яше иллене узып киткәнлектән, строевойга алмадылар алуын, әмма ниндидер сукыр закун нигезендә, әллә берәр кылый писарь ялгышы белән тагын, хезмәт армиясенә алынып, бер ел чамасы кайдадыр Әүҗән урманнарында изгән-имгәткәннән соң, тере мәет хәлендә туган Колтамагына кайтарып ыргыттылар. Ә менә гаиләне кызганмады, ай-һай аямады сугыш афәте: өрлектәй җиде улын йотты да куйды бу аждаһа. Ичмаса, Ходай Тәгалә башкаларга биргән кебек, ир бала белән сирәк кенә булса да аралаштырып, кыз баласын да насыйп итмәде бит! Ун бала — һәм унысы да ир бала! Нух пәйгамбәр заманнарыннан күрелгән хәлме бу?! Бу бәхет үзе үк бәхетсезлекне әзерләмәгәнме? Ике-өч ел аралаш тупылдап кына туып торган малайларның кайсы, ир корына кереп, өйләнеп, йорт-җир торгызып, үзләре дә бала үстерә, кайсының, танавына ис кереп, кызлар күзли башлаган чагында гына кубарылды бит яңа ярман кыйралышы! Бар микән, булды микән икенче бөтендөнья сугышы, Җир шарының барлык гавамы, барлык милләтләре тарихында бу кадәр үкенечле югалтулар кичергән нәсел, ә?! Бәлки, булмагандыр да. Бәлки, юктыр да. Моны ачыклау өчен бөек җиңүләрне данлау гына түгел, тарихның канлы боткасында казынырга, чокчынырга, тикшерергә, өйрәнергә, ә чокчыну-өйрәнүләр өчен милләтнең, тарих буенча мөхтәрәм фән кандидатлары, могтәбәр фән докторлары, әгъзаи мөхбир-академикларыннан тыш, бер генә булса да чын гади галиме булырга тиеш, күрәсең.

Әйе, Кутуевлар нәселен бөтенләй корыта язды бу каһәр суккан сугыш. Тумышы белән унҗиденче елгы булып фин кампаниясеннән исән чыккан Гаделҗан һәм егерменче елгы Рәхимҗаннары сугышның беренче көннәрендә үк хәбәрсез югалды. Уникенче елгы иң өлкән Галимҗаннары исә Харьков камалышында, ундүртенче елгы Сәлимҗаннары Смоленский өлкәсенең 408 нче биеклеге өчен барган алышта һәлак булды. Егерме икенче елгы Гарифҗаннары Польшада — Бреслауда,

егерме дүртенче елгы Сабирҗаннары Берлин янындагы Зеелов калкулыгында ятып калдылар. Җиденчеләре — егерме алтынчы елгы, әле өйләнергә дә өлгермичә утка кергән Әхмәтҗаннарына гына Җиңү көнен күрергә насыйп иткән икән. Ул әле дә ярман җирендә, алай гынамы, хатларында пышылдап кына «каракошның башкаласында», «дошман оясында», «үзебез ашкынган җирдә» кебек хәрби цензура аша үтә алган тәгъбирләр аша аңлатуынча, Берлинның үзендә хезмәтен дәвам итә. Әмма шунысы кызык, өчпочмаклы хатның тышына «Пүләвәй пучты 423810, Кутуев Әхмәтҗан» дип язып җибәрсәң, шушы хат Берлиндагы уллары кулына бара да керә! Кайчан бөтенләйгә кайтачагын уллары шулай ук пышын-пышын гына аңлатырга тырыша юл араларында: әле тиз көннәрдә генә булмас кебек; ни өчен дигәндә, ярман җиренең яртысын умырып алган әмрикләр Ысысысырга яңа сугыш белән яный, имеш...

Әмма корыта алмады сугыш Кутуевлар нәселен. Таифә җиңги белән Садриҗәләл абзыйның әле авылда, үз канатлары астында өч балалары — уналты яшьлек Сәгыйтҗан, унөч яшьлек Салихҗан һәм унбер яшьлек Кадерҗаннары бар. Хак Тәгалә исәнлек, озын гомер генә бирә күрсен үзләренә!

Менә әле, таң фәрештәсе канатларын җыйган иртәнге сәгатьтә, нәкъ шул унбер яшьлек Кадерҗан, чәче чалгыдан ясалган үткер пәке белән кырып алынган шар башына иске түбәтәй чәпәгән, аяклары исә тезләренә кадәр чебиләп, ярмакланып беткән, өстенә, еш юылудан һәм алмашы булмаудан изрәп, муртаеп беткән кызгылт киндер күлмәк, кыска киндер ыштан кигән малай, мичнең алкымына капланып, төтен юлының иң өске, иң югары бугазыннан алсу бармаклары белән карманып, җиде абзыйсы арасыннан исән калган бердәнбер абзыйсы — нәкъ әнә шул Әхмәтҗан абзыйсына хат язу өчен корым хәстәрләп маташа. Кырган корымын төбендә җылымса су ялтыраган җамаякка китереп сала, бармаклары белән изә, бер уңайдан, юк, һич кенә дә махсусан түгел, мәшәкать кызуында шул ук бармаклары белән үзенә дә мәрәкә мыеклар, сакалтыклар, миңнәр сурәтләп ала. Ул моны сизә, ләкин нишләсен, килеш-килбәтен карар, төзәтер өчен көзгеләре юк. Менә ничә ай булыр көзгесез яши алар... Моңа кадәр инәкие аңа хатларны әйтеп яздырта торган иде. Бүген исә инәкиләре дә, абзыйлары да өйдә түгел шул. Менә шуңа күрә инәкие хатны үзенә язарга кушып китте. Яза алыр микән? Дүртенче сыйныфны тәмамласа да, хат язарлык куәте бар микән аның? Ай-һай, авырдыр, җаваплыдыр ул хат язу! Ул бит кемгәдер атап китап язу белән бер! «Нәрсә языйм?»

дигәч, көтү куу белән өйдән чыгып китәргә ашыккан инәкие, әле күзләреннән татлы таң йокысы да җуелмаган Кадерҗанның аркасыннан сөеп: «И-и, сине өйрәтәсе бармы, син бит үзең мачтыр. Бар белгәнеңне яз да куй инде шунда, — дигән булды. — Хатыңны көн яктысында сырлап бетер, мин кайтып житешмәсәм, кәрәчинне әләф-тәләф итәсе булма. Налук кәгазьләре арасында Әхмәтҗанга дип яздырткан гомер догасы бар, шуны да хәстәрләп куй, бергә җибәрербез, — диде аннары кисәтеп. — Хатыңны соңыннан миңа кычкырып укырсың. Әтекиеңне дә караштыр, тегендә-монда китеп югала күрмәсен!»

Әйе, хат дигәч тә, бик җиңел нәрсә түгел шул ул. Аңа бит килешле итеп барлык бөтен яңалыкларны сыйдырып бетерергә кирәк. Кадерҗан белә, Кадерҗан хәтерли: сугыш башланган көннәрдә, бигрәк тә җиде абзыйсы да фронтка алынгач, әтекие белән инәкие кайсы улына кайсы имля белән язарга дип аптырап бетәләр иде. Хәер, дөньялары буталгач, имляда буталу алар гаебе дә түгел иде. Галимҗан, Сәлимҗан абзыйларына хатны инәкие йә әтекие гарәп язмасында гына сыдырып салалар иде. Әй шундый йөгерек, шундый житез, шундый сөйкемле һәм дә бик тырыш ул гарәп хәрефләре! Җәйге болындагы колыннар кебек томырылып торалар. Укуның бернидие дә тәтемәгән Гаделҗан абзыкаена ничек язсаң да ярый иде, чөнки ул хатны барыбер берәр мөселман кешесеннән яллап укыта һәм яздыра иде. Ә менә Рәхимҗан, Гарифҗан, Сабирҗан абзыкайларына хатны инде латин имлясында Әхмәтҗан абзыйлары язып чиләнә иде. Әй купшы, әй әфисәрләр кебек гасаби ул латин хәрефләре! Рәттәге солдатлармыни! Сәгыйтҗан абзыкайларын, ике сыйныф латинга йөргәннән соң, чебен кебек урыс язуына куып төшерделәр. Салихҗан белән Кадерҗанга исә әнә шул урысныкы гына эләкте. Кайчакта туганнар кайсы язма яхшырак, дип, үзара сүзгә кереп, бәхәсләшеп тә китәләр, юк кына урында. Бер гаепсездән кызышып, бәргәләшеп тә алалар иде. Менә шулай, бер гаиләдә өч язу үрнәген танып белеп тә, телдән бер-берсен аңлап та, язмада бер-берсен аңлый алмыйлар, укыганда да бик җәфаланып, иҗекләп укыйлар, бозлы таугa менә алмый торган беренче трахтыр кебек төртелеп торалар иде...

Хат кадәр хат язу бурычын үз гомерендә беренче тапкыр әнисе аңа тапшыргач, малайда кеше исәбенә керү тойгысы шактый үсте, канатланды һәм ул язылачак хәбәрләрнең кайнар учагында исереп, ләззәтләнеп карасын изде. Ниһаять, кара әзер дә иде. Болдыр ишеге аша күренә — тышта май кояшының җылы нурлары бәбкә үләннәрен

колакларыннан тартып үстерә, ике тәрәзәсе белән урамга, ике тәрәзәсе белән як-якка, бер кечкенә, ватык пыяласына иске чүпрәк тыгылган мич алды тәрәзәчеге белән ихатага караган өйнең салам түбәле кыегыннан бала чыгарып чыркылдаган чыпчыкларның гаугасы ишетелә. «Чыпчык ояларында да шундый ук тәрәзәләр бардыр, — дип уйлап алды малай. — Тәрәзәсез килеш чыпчыкның да күзе ачылмыйдыр ул». Шул ук ишек аша як-якка янтаеп, кыйралып беткән, урыны-урыны белән кычыткан басып киткән читәннәр, иске каертма абзар, аның артыннан караеп күренгән бәрәңге җире, бакча артында гына шарлап агып яткан Өязе таллыкларыннан өйгә кайры әчесе керә. Өйдә болдыр аралыгында эре май чебеннәре безелдәшә.

Малайга рәхәт иде. Берничә көн элек кенә каникулга чыккан Кадерҗанның, корымлы караларын атып бәреп, тышка чыгасы, күрше малайлары белән пыр тузышып, балчыкка батып уйнап керәсе килде. Әмма корым кара аны җибәрми, гүяки шушы өстәлгә кадаклап куйган иде. Кадерҗан карайган кулларын комганнан су агызып лакан өстендә юды һәм бөтен өйне пыран-заран китереп, кәгазь табу кебек «халыкара» әһәмияткә ия булган мәшгулиятькә кереште. Чиста, якты, шома кәгазь бите табу түгел, кайчандыр кулланылган, әмма чит-читләрендә язылмаган урыны калган дәфтәр, хәтта иске гәзит очтыкларына кадәр киселеп алынып, бәрәңге келәендә ябештерелеп, өсте-өстенә менми, юл салырлык кәгазь кисәге табу да читен иде. Шүрлектә, сәке асларында күпмедер казынганнан соң ул, ниһаять, сандык белән мич аралыгыннан Сәгыйтҗан абзыйсының мәктәп токчаен* өстерәп чыгарды. Әмма нинди генә дәфтәрне алса да, кызганыч иде малайга: гүя бу язуның, бу дәфтәрнең киләчәктә кирәге чыгачак кебек. Абзыйсының математика һәм матур язу дәфтәрләренең чагыштырмача чиста тышлыкларын тимер атламаларыннан аерып алды. Үз токчаеннан әле мәктәп карасы да кибеп бетмәгән 86 нчы корыч каурыйлы ручкасын эзләп тапты да аларны бер газиз йөк сыман саклык белән өстәлгә китереп куйды. Аннан өстәл астына кереп ауган тумәр урындык тартып чыгарды, урындыгына лап итеп утырды, ручкасын кулына алды, каләмен карага сугарды... Һәм үзен хат яза башлау өчен тәмам әзер итеп тойды...

Бер мизгел тын торды. Тышта чыпчыклар чыркылдаша, чыпчык балалары исә нәзек, сыек тавышлар чыгарып сыкрана иде. Хатны башлап китү өчен иң мөһим, иң кадерле сүз җитми иде аңа. Ниһаять, ниндидер газиз фикер килгәндәй, уры-

* Токчай (диалект.) — капчык. *(Автор.)*

нында талпынды һәм, күлмәгенең җиңен өскәрәк күтәреп, зәңгәр дәфтәр тышлыгының эчке ягына, иң өске тәңгәленә *«Бисмилләһир-рахманир-раһим»* дип куйды да, күзләре ачылып китеп, борынын мышкылдата-мышкылдата, вак кына хәрефләреннән сүзләр тезә башлады:

*«Хат башы — языгыз каршы.*

*Исәнме, сезки нимес-фашистларын тар-мар итеп, пүләвәй пучтыда хезмәт итеп ятучы кадерлеләрдән кадерле Әхмәтҗан абзыкаем. Сиңа хат язучы энекәшең Кадерҗан дип белерсең. Май аенда яңа җирдән үсеп чыккан хәтфә үләннәр һәм дә ки матур итеп ярган агач яфракларынча, һәм дә ки матур аткан чәчәкләр санында күптин-күп, чуктин-чук сәламнәремне иртән искән таң җилләре аша сезнең тарафларга озатып калам, һәм дә ки әрме сафларыннан тиз көннәрдә исән-сау котылып кайтуыңны теләп калам. Һәм дә ки әтеки-инәкидән, туганнарың Сәгыйтҗан, Салихҗан абзыкайлардан, һәм дә ки Галимҗан абзыкайның җәмәгате Рәзифә җиңгидән, аларның уллары Мәгъруф белән Хәйдәрдән, һәм дә ки Сәлимҗан абзыкайның җәмәгате Шәмсорур җиңгидән, балалары Зәлифә белән Хәернастан, һәм дә ки Гаделҗан абзыкайның җәмәгате Сабира җиңгидән, уллары Зарифтан, һәм дә ки башка барча туган-тумачалардан, күрше-тирәләрдән күптин-күп, чуктин-чук сәлам. Сәламнәремне тәмам итеп, түбәндә язылачак сүз төркемнәренә күчәм...»*

Кадерҗан авыр итеп сулыш алды. Беренче үр менелгән һәм, сизүенчә, шактый җиңел менелгән иде. Гүя аның яурыныннан тау төште. Сүзләре тезелеп кенә тора, ә? Әйтерсең аның артында инәкие басып тора һәм сүз тезмәләрен әйтеп тора... Маңгаена, җемшек борынына бәреп чыккан тирне күлмәк җиңе белән сөртеп, ул, йөк кенә түгел, бөтен дөньяны сөйрәп менгән ат сыман пошкырып һәм фырылдап, яңа биеклекләрне яулый башлады. Аның тамырларындагы каны кайный, баш түбәсендәге түбәтәе йөренә, тирләгән маңгаеннан бу күтәрелә, ә күзләре исә биш чатлы йолдыз сыман очкынлана иде...

*«...Үзебезнең хәлгә килсәк, бер көйгә дөнья көтеп, җон тетеп ятабыз. Мал-туар кышны исән чыкты. Курмы җитте, бераз артып та калды. Артканын да ашаттык. Хәзер инде бер сыер да ике сарык кына калды. Буаз сарыкны Карамал базарында саттык та акчасына ашарга чөгендер алдык. Бүгенгә тамак туклык итәргә шул чөгендер дә бетте. Ашарыбызга бернәрсә дә юк...»*

Малайны нindидер шаукым суккандай итте, ул туктап

калды. Арттырыбрак җибәрмәдеме? Алар өчен чит-ят мәмләкәтләрдә болай да җаны өзгәләнгән абзыкаена шулкадәр хакыйкатьне ачып салырга, бу кадәр мәрхәмәтсез булырга ярыймы? Әнисе әйттереп яздырган булса, бу кансыз сүзләр аның авызыннан чыккан булыр идеме? Иң мөhиме — алар исән бит, исән! Димәк, алар ач түгел! Әле базларында берничә көнлек чөгендер дә, чәчкәннән соң калган ике-өч бидрә вак бәрәңге дә бар... Малай «ашарыбызга бернәрсә дә юк» дигән тәгъбирне сызарга итте, әмма сызмады. Абзыйсы әллә нәрсә уйлар, аннан язмасы да пычрана, болай да бик чикле кәгазь дә әрәмгә китә. Ул бу җөмләне бераз гына йомшартырга, уен сүзләргә төрергә булды.

*«...Өс бөтен, тамак тук — ашарга юк, дияргә дә була. Быелгы кыш ифрат та җылы килде. Абзыкайлар март уртасыннан ук халхуз басуына, Хлибарут* кахуллары бакчаларына барып, черек бәрәңге чокып алып кайтып, шуннан аның кәлҗемәсен күмәч итеп пешереп, тамак ялгап килдек...»*

Кадерҗанга күңелсез, моңсу булып китте. Иште инде ишәк чумарын, болай булгач! Аны фикер җебе, чыгымчы үгез кебек каерып, әллә кая алып кереп китте. Гүя аның зиһене үзен тыңламый, үзенә буйсынмый иде. Нидән шулай була бу? Батырлыкмы бу, әллә куркаклыкмы? Гаделлекме, әллә сатлык җанлылыкмы? Аның һич кенә дә ачлык, черек бәрәңгеләр турында язасы килмәгән иде. Әйтерсең Әхмәтҗан абзыкае ул хакта белми! Их, бик тә, бик тә куандырасы килә иде аның абзыкаен! Ул куанычлы хәбәрләрне каян алырга соң? Шушы түбә кыегында чыркылдашкан чыпчыклар, баш өстендә өерелеп безелдәшкән чебеннәр турында язарга түгелдер бит?! Малайның башына күптән түгел булган бер гадәттән тыш вакыйга килде. Ручка сабын кысып тотудан тагын да алсулана төшкән бармаклары зәңгәр дәфтәр тышында шушы гадәттән тыш вакыйганы сурәтли башлады:

*«...Берничә көн элек кенә Кәркәле тавындагы Ташлы Елга кырлачына ниндидер ефәк парашут төште. Авыл халкы аны кием-салымга дип ерткалый, бүлгәли дә башлаган булган. Шундук ниндидер кешеләр авылыбызга килеп җитте. Бу парашут Әмрикә ышпиуны булган, ди. Парашутны беренче булып күргән малайлар Зәйнәгәбдин, Борһан, Сибгатләрне, парашут ефәген эләктерә алган абзый һәм җиңгиләрне милитсия, килеп, районга алып китте. Әлегә берсенең дә кайтып җиткәне юк...»*

---

* Хлебороб — авыл исеме. (*Автор искәрмәсе.*)

Менә сиңа куандырды! Кем, нинди иблис яздыра аңа бу тузга язмаган сүзләрне?! Телеңә тилчә чыккыры! Йолдыздай очкынланып янган күзләре бер мизгелгә сүнеп, төссезләнеп калгандай булды. Дөрләп янган маңгаена салкын боз куярга теләгәндәй, ул мич аралыгына керде һәм агач ужау белән ләгәннән салкын суны ат кебек шамбырдатып эчте. Әйе, биллаһи газыйм, нindидер сихри, инәкиеннән дә көчлерәк көч, аның ихтыярын биләп, кулларын шакарып алып, бу юлларны үз телләре, үз куллары белән яздыра! Бик тә күңелле, җанга бал булып ята торган хәбәрләр кирәк бит аның абзыкаена! Әһә! Менә ул яңалык! Яңалык дисәң дә яңалык! Ничек итеп ул әлегәчә бу хакта язмый утыра?!

*«...Хәзер инде көннәр җылынды,* — дип дәвам итте ул хатын. — *Быел ташу бик шәп булды. Сыразы китте. Априлнең берендә үк ташу ташый башлады. Ышанасыңмы, Кәркәле белән Өязе сулары, урамнарга чыгып, Нәһар карчыклар янында маңгайга-маңгай чәкешеп кавыштылар.* (Малайга «чәкешеп кавыштылар» дигән сүзбәйләнеш бик тә ошады. Ул, ирене белән иренен кымтып, җаныя ләззәт кичерде һәм Ходай Тәгаләнең мондый тел ачкычлары бирүенә чиксез куанды.) *Өязе ташуы Кәркәле ташуын җиңеп, әрәмә очына таба алып китте. Әрәмәдәге йортлар су эчендә утырып калды. Безнең Колтамакның да, Качаганның да тегермәннәрен, мал-туарларын агызып алып китте. Әрәмәләрнең идән сайгакларын күтәреп атты, үзләренә һәм малларына торыр урыны калмаганнары безнең очка күченде. Кәгазь калынлыгындагы юка гына кардан да шундый ташу булыр икән дип аптырый авыл картлары...»*

Кадерҗан үзеннән бик тә канәгать иде. Аның эшләре гөрләп бара!

*«...Сыер бозауламаган әле. Җилен башлаган инде, Алла боерса, урак өсләренә үзебезнең сөт-катык та булыр. Безнең өчен бик...* — күзләренә яшь типкән малай лышык-лышык танавын тартып куйды. — *...Кайгырма, абзый җаныкаем, шулай итеп әкренләп килербез әле. Өс-башыбыз шул син бардагыча. Бер дә яңартып булмады. Инәки әтекинең дуплы толыбын сатып булса да юнәтербез, дип торган була. Халхуз бодайны чәчеп бетерде. Хәзер солы чәчәләр. Чәчүчеләргә сталавай да бар, көненә 150шәр грам ипи дә бирәләр. Быел көзгә без дә баербыз, юньле адәмнәр арасына керербез дигән өмет бар. Әле син белмисең, Сәгыйтҗан һәм Салихҗан абзыкайлар күрше Җидегән авылына сарык көтәргә яллана дылар. Халхузныкын да, халыкныкын да бергә көтәләр. Халыктан чират башына дүрт кила он, бер пот*

*бәрәңге, шуларның яртысын хәзер үк бирә башларга тиешләр, яртысын — яңасы өлгергәч. Ул гына дисеңме? Чират башына 20 сум акча, бер бидрә сөт, ашау үзебездән.* — Малай тәмле итеп иреннәрен ялап куйды. — *Халхузныкы — карга басканчы 250 тырут, ай саен тугыз кила он биреп торачаклар. Абзыкайларның үзләренә төшке умачлыкка саварга бер кәҗә бирделәр, аякларына оеклык җон да бирәчәкләр. Катык-сөт тә биреп торырбыз, диделәр. Тик шунысы яман, үзебезнең халхуз ферсидәтеле Саескан Галирахман Салихҗан абзыкайны көтү көтәргә чит халхузга җибәрмәскә итә. Үзебезнең халхузда тырутка эшләсен, ди. Тырут нәрсә — коры таяк бит ул. Ә тегеләр, бәләкәй дип, Салихҗанның үзенә генә көтүне бирмиләр. Саескан Галирахман инәкине: «Балаларыңны алып кайт, кайтмасаң, авылдан кудырып, гаиләгезне катыр озатам», — дип, ярты көн кәнсәләрдә ябып тотты. «Монда ачка үтерер хәлем юк», — дигән инәки. Син шул Саескан Галирахманына берәр управа табалмассыңмы, абзыкай?*

*Туганнарым хәерче көненә калып, көтүгә ялланганнар дип хафаланма. Без куанып бетә алмыйбыз. Күпләр андый эшне таба алмыйлар, сез эшләп ашыйсыз, ди инәки. Дөрест инде, әйеме? Күпләр, ачка каңгырып, урлашырга мәҗбүр була. Урлашу зерә дә күбәйде. Зәбихның әнисе Сара түти, халхузның келәт идәнен борау белән бораулап, өч пот симәнә бодае агызгач тотылды. Бәләбәй өтермәсендә черетәләр. Гаиләдә берсеннән-берсе яшь дүрт бала тома ятим калды. Әле халхуз блгадиры Әмир абзый, трахтыр блгадиры Гани абзый, читават Әүдәгый абзыйларны — андыйларның иге-чиге юк — ярты авылны кулга алдылар. Әмир абзый, чәчүгә төшкән трахтырисларны кызганып, берәр пот иген өләшкән булган. Пркаруллар килделәр дә, йорттан йортка упыска кереп, игеннең булганын-булмаганын кырып-себереп алдылар. Минебай, Ярый бабайларның былтыр көз бал сатып алган игеннәрен дә кәнфискәвәйт иттеләр. Безгә дә керде упыс. Хет чакыр, хет акыр — безнеке такыр.* (Малайга бу җөмлә дә ифрат ошады.) *Әмир, Гани абзыйлар әлегә кулдалар.*

*Шулай, абзыкай, без урлашып түгел, эшләп ашыйбыз. Әле инәки, абзыкайлар белән таңнан торып, Җидегәнгә китте. Чират башыннан шул безгә тиешле азыкның беразын җыеп булмасмы дип.*

*Үзебез дә тәк ятмыйбыз, былтыргы арыш урынына түгелде арыш чыкты. Ташлыкка бераз арпа, калган урыннарга бәрәңге, берәр күлем кишер, чөгендер, суган утырттык.*

*Үзеңнең ашау-эчү, кием-салым ничегрәк соң? Тамагың тук, өстең бөтенме? Берлиндагы халыклар, балалар безнең шикелле ачка тилмермиме? Инде аларга Ходай күрсәтә күрмәсен мондый җәфаларны. Бәрәңгеләрне халыктан җыеп ала алсак, мин аларга Хәкимҗан бабай танавы кадәр эре бәрәңгеләр җибәреп торыр идем. Менә мин сиңа, әлегә хатта булса да, нәкъ әнә шундый эре бәрәңге җибәрәм. Пүләвәй пучты малайларына авыз иттерерсең, яме?»*

Малай үз табышына үзе куанып көлеп җибәрде һәм кәгазьнең бер читенә эре күзәнәкле зур бәрәңге сурәте төшерде.

Кинәт касыгы астыннан нидер бөтереп алды. Татлы итеп суырды, аның үтереп ашыйсы килеп китте. Ручкасын куеп, бармакларын язды, мич каршысына йөгереп килеп, чуен чүлмәкне тартып чыгарды. Аны, куш куллап күтәреп, авызына китереп терәде һәм, кызарган күзләре белән чүлмәк эченә ук кебек кадалып, кызыл байрак кебек кып-кызыл чөгендер шулпасын чүмерә башлады...

...И сабый, и үзе дә ак кәгазь кебек чиста, садә, эчкерсез җан иясе! Киләсе сентябрь башында чукланып беткән чабатада, бер кат ыштанда, иске куфайкада, токчаена, китап-дәфтәрләре астына, булса, көлдә тәгәрәтеп пешерелгән бер-ике бәрәңге салып, яңгырда һәм буранда, карда һәм әче җилдә көн саен ун чакрым юл үтеп, күрше Олы Кәркәле җиде-еллык мәктәбенең бишенче сыйныфына гыйлем эстәргә барачак шат җан Кадерҗан әле үзенең нибары 120 йорттан торган туган Колтамагының 270 ятим баласының нибары берсе, Җир шарындагы иң изелгән, иң каһәрләнгән, иң алданган халык баласы икәнлеген әлегә аңламый һәм аңлый да алмый иде. Кайчандыр шат бала-чага, көр күңелле ир-ат, хатын-кыз, гармун тавышлары, җыр яңгырап, ап-ак балан, шомырт чәчкәләре эчендә йөзгән йөз дә егерме йортның ни өчен, ни сәбәпле, нинди сәяси уен аркасында хәрабәләрдә ятуын, иясез, телсез-язмасыз калуын, шушы йөз егерме ихатадан гына да 190 баһадирның сугышка алынып, нибары кырыгының гына, кайсының аяксыз-кулсыз, кайсының күзсез һәм гайрәтсез-орлыксыз калып кайтып егылуына, шушы ихаталарда гына да алмадай җитмеш хатынның гомере буе тол яшәячәкләренә дөрес нәтиҗә ясамый һәм ясый да алмый иде Кадерҗан. Әйе, алты абыйсын корбан итеп, җиденче Әхмәтҗан абзыкаена гына түгел, «пүләвәй пучтыдагы» барлык халыкларга, барлык сабыйларга авылдашы «Хәкимҗан бабай танавы кадәр эре бәрәңгеләр» озатырга хыялланган Кадерҗанның күрәселәре һәм аңлыйсылары, кызганычка каршы, алда, бик алда иде.

Әле балигъ та булмаган малай актыгы кичә генә тук эчәгесенә сарышкан майны, тирә-юнендәге байлыкны, неон-электрны, ялтыравык автоларны кая куярга белми тилергән, үзара талашып, бөтен Җир шарын алданрак басып алырга җыенган «бөек» державаларның, инде килеп, шуның нәтиҗәсендә бүген хәрабәдә яткан Европаны Гитлер фашизмын җиңү байрагы астында яңадан өзгәләргә, бүлгәләргә, илләрне, милләтләрне дошманлык сәясәте белән агулап, Европаны гына түгел, бөтен Җир шарын кап урталай бүлеп, капма-каршы лагерьларга куып кертергә җыенган кичәге җиңүче — «азат итүчеләр» СССР, АКШ, Англия даирәләренә аның ни өчен, ни сәбәпле алыш-биреш, алыпсатарлар, сәяси маклерлар мәйданына әверелгәнен белми һәм белә дә алмый иде. «Социализмның бөтен дөньяда җиңүе өчен» алты газиз абзыкаен корбан иткән, кирәк икән, моның өчен үзенең җанын да фида кылырга әзер булган Кадерҗан туган Колтамак чокырында социализмның никадәр «оҗмах» икәнлеген бөтен дөнья күләмендә раслау өчен җиңүче илнең — СССРның миллионлаган Кадерҗаннары авызыннан өзеп, келәт идәннәренә кадәр себереп, соңгы бөртек игеннең, соңгы бәрәңгенең, соңгы әчмуха чәйнең, соңгы шакмак шикәрнең һәм ит-колбасаның «социалистик система» буларак оешырга тиешле Көнчыгыш Германия, Венгрия, Чехословакия, Румыния һәм башка илләргә эшелон-эшелон озатылуын, бу байлык, бу ризыкларның, бихисап ит-колбаса, каклаган казларның ни сәбәпле Көнбатыш вокзалларында бушатылмыйча череп ятуларын, нәтиҗәдә үз иленең, үз халкының, үз авылдашларының талануын, хәерчелеккә, бөлгенлеккә төшүен, ачлыкка дучар ителүен, шул ук вакытта, капитализмның социализмнан никадәр өстен икәнлеген дөнья алдында раслар өчен, Американың «Маршалл» планы буенча Европаны ни өчен азык-төлек белән дыңгычлап тутыруы сәбәпләрен әлегә төшенми һәм төшенә дә алмый иде бу сабый.

Түгелде иген башагыннан агуланып, кан косып үлгән, гарип калган корбаннарның берсе генә булган Кадерҗан өстәвенә авылының гына түгел, Ватан кадәр Ватанның үги милләте булган милләтнең ятиме иде. Бирелгән корбаннар, түгелгән каннарны ул шуңа күрә Ватан халкына кылынган бөек бер илаһият, бөек бер зарурият, бөек бурыч дип кенә кабул итә һәм үз үгилеге, үз ятимлеге аңа гади, бер табигый чынбарлык булып кына күренә иде...

Алты бертуганның Европа мәйданнарында бер сәбәпсез, бер гаепсез суелуларының нигезендә ялган, сәяси, иҗтимагый-эстетик тәгълиматлар һәм кануннар ятуын һич кенә дә

алдан искәртми һәм искәртә дә алмый иде сабый!.. Ватанында ватансыз милләтнең дә ятим баласы буларак, ул үз кавеменең бу ялган Ватанның иң яхшы урман кисүчесе, бетон салучысы, чуен коючысы, урам себерүчесе, йөк төяүчесе, иң батыр сугышчысы, хәтта шуның аркасында иң беренче булып башлап кырылучысы, ачлыктан интегүчесе, иң алдан бетерелүчесе икәнен дә белә алмый иде шул сабый!.. Бу ялган Ватанның тарихының да ялган, җиңүләренең дә ялган, җырларының да ялган, сүзенең, гәзитләренең, китабының, радиосының да, хәтта диненең дә ялган, башкалардан урлап алынган икәнлеген исәпләми иде сабый!.. Моннан нәкъ бер генә ел элек йөзләгән милләт катнашкан икенче бөтендөнья сугышында Рейхстаг түбәсенә беренче булып байрак кадаган каһарман Гази абзыйсы Заһитовның милләттәш кенә түгел, якташлары, үз абзыкайлары кебек абзыкайлары булып чыгачагын, бу «серенең» «Бөек» Җиңүгә кырык биш ел тулган көннәрдә генә ачылачагын һәм иң мөһиме — Гази абзыкаена дигән Советлар Союзы Герое Алтын Йолдызының аңа түгел, маршал Жуков киңәше, генералиссимус Сталин күрсәтмәсе буенча Сталин милләттәше — грузин Кантарияга, Жуков милләттәше Егоровка биреләчәген, бу алдакның икенче бөтендөнья сугышының иң бөек аферасы буларак тарихка керәчәген, шуңа өстәп, әле Кадерҗан хат язып утырган минуттан исәпләп, нәкъ сигез ел үткәч, туган авылында механизатор булып эшләгән өлкән сержант Гази абзыкае Заһитовның режим тарафыннан юк ителәчәгенең мөмкин булуын күз алдына да китерә алмый иде шул сабый!..

Әле мич аралыгындагы эңгер зәңгәренә сеңеп, чуен чүлмәктән алсу-кызыл чөгендер суын чөмергән сабый үз гаиләсендә бер каннан яратылган ун баланың ике кавемгә бүленгәнлеген — алты абзыкаеның милләте ягыннан татар, өч абзыкаеның һәм үзенең милләте ягыннан башкорт булып язылуы мөмкинлеген башына да китерә алмый иде...

Хаты бераз суынды, җәелде булса кирәк. Кәгазе дә накыслана бара иде. Хатының язылачак өлеше сыймый калуыннан шикләнеп, ул хәрефләрен кечерәйтә, юл араларын кыса төште.

*«...Абзыкайларның пинсәсен әле булса юллап ала алмыйбыз. Әллә ниткән пахарункалар, әллә ниткән дуәкәмәтләр кирәк, дип, инәкинең башын катыралар. Безгә бары тик Рәхимҗан абзыкайның гына пинсәсе килә. Мондый дуәкәмәтләрне син үзең безгә әтмәлләп җибәрә алмассыңмы? Инәки сорарга кушкан иде — туган-тумачалары күп кырылган гаилә кешеләрен әрмедән вакытыннан алдарак җибәрәләр, диләр, син тизрәк кайта алмыйсыңмы соң?*

*Әтеки шул Сабирҗан абзыйның үлем хәбәреннән соң һаман да зиһененә кайта алмый. Һаман саташа, һаман көнетөне җылый — безнең аңа «акылдан язган» дип әйтергә телебез бармый. Авыл фиршылы аңа «алмашынган» дип тә спрафкы бирми, Уфага алып барырга, тикшертергә куша. Барысы да бер инәки өстенә төшә. Күптән түгел бөтен авылга даһи Ысталин төшкән жиңү мидалы тараттылар. Инәкигә дә бирделәр. Әтекигә әлегә бирми торабыз, дигәннәр. Сугышта бердәнбер улы хәбәрсез югалган Сәгъди мәзингә дә бирмәгәннәр. Аны халхузның ата бурлары, эт ялкаулары да алды, хәзер, шул мидалны тагып, бөтен Ысысысырны әйләнсәләр дә була, ди инәки. Хатымны шушында туктатып торам. Әтеки нишли икән анда, карап кына керәм, яме?»*

Бер сәгать чамасы вакыт үттеме-юкмы, Кадерҗан, җанфәрманга чабып, өйгә килеп керде һәм, ут капкандай, сандыкта актарына башлады. Ниһаять, ул тышына патша сурәтләре ябыштырылган, кайчандыр хәлле, бик тә хәлле булган ерак бабаларына акча кумтасы булып хезмәт иткән катыргы тартма китереп чыгарды, анда байтак казынгач, ниндидер язулар, кәгазьләр алып, урынына килеп утырды. Кәгазьләренә яңадан күз салгалаштыргач, бер мизгелгә уйга калды. Инәкиенең озак кайтмавы борчый иде аны. Күзләрен челт-челт йомып, татлы хыялларга чумды. Әнә аның сөт өсте кебек акты чырайлы, ипи йөзе кебек кояшта янган йөзле, яулыгын уртадан ачылган чәчләрен бераз гына көнгә күрсәтеп бәйләгән, алтын йөрәкле, җылы куллы, җиз аһәңле инәкие һау-һаулап Җидегән юлыннан Колтамакка карап дөяләр кәрваны куа: дөя өркәчләрендә капчык-капчык бәрәңге, подаука-подаука иген, бәйләм-бәйләм тукыма, әрҗә-әрҗә перәнник, кап-кап киемсалым, кәнфит, манпачыйлар... Малай татлы итеп селәгәен йотты һәм яңадан хатына тотынды...

*«Әтекине көч-хәл белән табып алып кайттым. Әле ишегалдындагы ак ташта үз-үзе белән сөйләшеп утыра. Мин аны чучка фермасыннан эзләп таптым. Син белмисең дә бит әле. Сарыклары кырылып беткәч, безнең Колтамакта чучка фермасы оештырып маташалар. Шундагы тирестә сәнәге белән казына бу. «Килмә, улым, килмә, сине дә аждаһа ашар!» — ди бу миңа. «Нинди аждаһа?»— дим мин. «Бәй, күрмисеңмени, менә монавы тишеккә кереп китте бит, — ди әтеки. — Шуның башын сәнәктән үткәзмичә, өйгә кайтмыйм, — ди. — Тәүдә силсәүиткә, аннан Уфага, аннан Мәскәүгә барып, аждаһаның башын Ысталинның өстәленә салам», — ди. Көлсәң көл, еласаң ела. Шулай, көн*

*тудисә, каядыр чыгып китәргә генә чамалый. Күз-колак кирәк. Син, абзыкай, әтеки өчен артык борчылма, Ходай Тәгалә язган язмыштыр, ди инәки. Фиршыл апа әйтә, Әхмәтҗан абзыегыз кайткач, менә күрегез дә торыгыз, әтекиегез үз акылына кайтачак, ди. Шатлыктан шулай була, ди. И Ходаем, шулай гына була күрсен иде! Кайт инде, абзыкай, тизрәк кайт, югыйсә безне монда...»*

Малайның язасы сүзе өзелде, ул тавышын чыгармыйча үксеп елый иде. Түбә кыегында бала чыпчыклар, тыелып кына чыелдашып, туган телләрен өйрәнә, тәрәзә тупсаларында тамчы гөлләр тамчылап-тамчылап чәчкә ата иде. Малай, мич арасына кереп, бит алмасы буйлап ургылып аккан яшьләрен чүпләм тастымалга сөртте. Кызарган күзләрен уа-уа урынына утырды. Кәгазьләр арасыннан шәмәхә кара белән догалык язылган тар кәгазь кисентесен эзләп табып, хатының соңгы өлешенә кереште.

*«...Инәки сиңа Сәгъди мәзиннән тыныч тормышта үзеңне бәла-казалардан саклый торган гомер догасы яздырып алды. Мин аны сиңа хатка тыгып җибәрәм. Син аны теге сугышка алып киткән бөтиең эченә салып тек, ярыймы. Инәки шулай кушты».*

Кадерҗан инде хәзер кәгазьләр арасыннан абыйсының соңгы хатын, ниндидер квитанцияләр алып, алдына куйды.

*«...Хәзер синең хатыңдагы сорауларга җаваплар. Базар хаклары бик кыйбатланды. Арыш оны — 450—500гә кадәр, бодай оны 550—600гә кадәр җитә. Бәрәңге — 55—60 сум. Итнеке — 30—35 сум. Май — 40—45. Мал ягына килсәк, алар тагын да күтәрелде. Олы сарыклар — 1000 сум, бозаулар — 1500 сум, бозаулыйсы таналар — 3000гә кадәр, сыерлар 4000—5000 сумга җитәләр.*

*Син налуклар турында да сорагансың.*

*1. Хузналук — 493 сум. Шуңардан 211 сум бирәсебез бар. Барлыгы 282 сум түләнгән. Шуның йөз сумына син җибәргәнне, 182 сумына Рәхимҗан абзый пинсәсен сук-тырдык. Июльгә кадәр түләмәсәгез, көн күрсәтмибез, төн йоклатмыйбыз, дигәннәр инәкигә.*

*2. Ит — 40 кила. Шуңардан ун киласын инәкинең теге аяклы бирнә көзгесен сатып түләдек. 30 кила түлисе калды. Акча булса, күп калмады инде.*

*3. Ике сарыкка — ике кила 800 грам җон. Ике киласын инәкинең көмеш беләзеген сатып түләдек. Сигез йөз грам калды. Акча булса, күп тә түгел инде.*

*4. Күкәй — 100 данә. Быел кыштан алты гына тавыгыбыз исән чыкты. 60ын түләдек. 40ын түлисе калды.*

*Калганына чебеш үстерәбез. Көзен шуларны бирергә торабыз.*

*5. Заем 100 сум иде. Пинсә белән түләп бетердек.*

*6. Май — алты кила. Сыерыбыз тана гына булгач, алты гына кила салганнар иде налукны. 4 кила алты йөз грамын түләдек. Бер кила дүрт йөз грамын түлисе калды.*

*7. Бәрәңге 1 синтнир 50 кила иде. 1 синтнир 10 киласын ике казыбызны биреп түләдек. Кырык киласы калды. Бәрәңгебез былтыр вагы-төяге белән нибары 160 бидрә генә булды. Абзыкайлар Җидегәннән чират башына җыя алсалар, шуннан түләрбез дип торабыз.*

*Быел өстәп тирес, көл налугы да салганнар иде. Кышын налукка өч бидрә көл, ике чана тирес бирдек. Үзебезнең бакчаны ашларга да калмады. Инде тагын яңа төр налук — зелпе тамыры налугы салынды. Җан башына бишәр кила зелпе тамыры. Аннан забутларда эрзинә ясыйлар, имеш. Аның тамырын тарта-тарта, халыкның күзе-күтәне чыга.*

*Синең яшьтәгеләр кайта башлады. Шәмсүн абзый кайтты. Хаберъял абзый кайтты. Ниязгали абзый кайтты. Тимергали абзый кайтты. Син дә кайт инде!* — Малай яңадан үксеп җибәрүдән чак тыелып калды. — *Хәзер, егетләр кайткач, кызлар да өннәреннән чыга башлады. Хлуппта көн саен диярлек вичыр.* — Бу сүзләрне язганда малай кояштай балкып елмаеп җибәрде. — *Абзыкай, менә сиңа истәлеккә алмалар җибәрәм!* — Кадерҗан кәгазенең сул кырыена алмалар төшерде. — *Берсе үзеңә, калганнары пүләвәй пучты балаларына.*

*Хатым бик тә озынга китте, ярый, син аны бер китап итеп укырсың. Бер-ике җыр белән хатымны төгәллим.*

*Иртән торып тышка чыктым,*
*Бүрегем бәйләмичә.*
*Вөҗдансыз, кансыз табигать*
*Аерды җәлләмичә.*

*Хатлар яздым, хатлар яздым,*
*Хатлар яздым тутырып.*
*Хатым китте, үзем калдым,*
*Язган җирдә утырып.*

*Абзыкаем, хуш, сөйләгәндә безне дә куш.*
*22 май, 1946 ел. Хат көтеп, энекәшең Кадерҗан».*

*Апрель, 1998 ел. Алабуга, «Наратлык» ял йорты*

# БӨРКЕТЛЕ БАГАНАЛАР

*(Казакъ далаларында)*

1956 елның ноябре иде.

Күкчәтау драма театры бинасында беренче чирәм җир уңышын урып-җыю йомгаклары буенча җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы бара.

Бүләкләрне партия өлкә комитетының Беренче секретаре Җалкын Җакшылыков, мөнбәр артыннан торып, үзе тапшыра.

Әле генә Сәдитләрнең «Каравыл-Түбә» совхозыннан Кривошапка дигән комбайнчы күкрәгенә Хезмәт Кызыл Байрагы орденын кададылар.

Сәдит әле шул вакыйгадан һушын җыя алмый утыра.

Менә тантаналы җыелышның рәисе чираттагы бүләкләнүченең исемен атады:

— Сәхнәгә беренче уңышны югалтусыз җыеп алу өчен барган социалистик ярышта җиңеп чыккан... һәм... һм... барлык өлкә буенча беренче урынны яулаган һәм... һм... — алып баручы, кәгазен укый алмагандай, «һәм»не «һм-һм»га әверелдереп, телендә тәмләп, яңадан төртелеп торды. — ...хезмәт уңышлары өчен «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнгән «Мәмләкәт» совхозы комбайнеры Сәдит Гәбдерәүф улы Гатиятуллин чакырыла!..

Монда, кичә генә компартия ихтыяры белән иксез-чиксез казакъ даласына җыйналган йөзләгән милләт балалары, ниндидер Сәдитнең ниндидер атасы Гәбдерәүф, атасының ниндидер бабасы Гатиятуллаларны түгел, Сәдитнең үзен дә белмәгән һәм белергә дә ашкынып тормаган, аннан гайре яхшы оештырылуыннан ук ясалмалык бөркелеп торган бу тантанадан шактый арый, талчыга төшкән зал гадәттәгечә иренеп кенә кул чабарга тотынды.

Арткы рәтләрнең берсендә утырган Сәдит, күрер күзгә егерме биш-утыз яшьләр өстендәге ир, башкалар шикелле ут капкан сыман кыбырсымый, ашыкмыйча урыныннан күтәрелде һәм өстендәге соргылт пинжәген тәртипкә китерергә теләгәндәй, аннан-моннан тарткалап, келәм буйлап президиумга таба юнәлде. Аның адымнары вак, әмма ышанычлы, бераз артка чөелгән йөзендә киләчәккә ышаныч, өмет һәм ихтыяр көче сизелеп тора иде. Сәдитнең «сәтсиәлистик ярыш йомгакларына» мотлак ашыкмавы Беренченең ачуын китереп куйды. Авыз суын корытып, күпме кешегә таратасы бар мондый бүләкләрне, ә ул, кара син аны, җәйләүдәге нәсел тәкәсе сыман, ничегрәк кенә текә басып килә!.. Ленин орденлы халык акы-

ны, туксан тугыз яшьлек Җамбыл бабай Җабаев* та үзен болай иркен тотмаган мондый мәртәбәле залларда!..

Ул якынлашып килгән механизаторны карашы белән җиз иләктән или, ниндидер, үзе генә белгән нурлар белән тикшерә, үтәли чыга иде. Беренченең бит мускуллары тартышып куйды. Ул, таныгандай булып, үткер карашы белән яңадан Гатиятуллинга кадалды. «Шул түгелме бу? — дип уйлап алды ул. — Бункеры өстенә бишек элеп, ашлык өемнәре белән басуны тутырган нугай малае түгелме соң бу?»

Гүя аның алдыннан ялкынланып яна-яна агарган кояш үзе тәгәрәп килә иде. Бер карады — ул кайнардан иеште. Икенче карады — ул салкыннан өшеде. Аннан көтмәгәндә генә елмаеп куйды. «Татар малае» әле һаман килеп җитә алмый иде.

Аны тизрәк тартып китертергә теләгәндәй, Беренче үзе дә сизмәстән кул чаба башлады һәм алкышлаудан әле генә туктаган, бу пошмас бүләкләнүченең, ниһаять, сәхнәгә күтәрелүен көткән залны артыннан ияртеп алып китеп, яңадан кул чаптырырга, дәррәүдән алкышлатырга тотынды. Менә ул килеп җитеп килә... Менә ул килеп тә җитте. Әйе, шул. Нәкъ үзе. Кыска, туп шикелле җыйнак буй-сын. Үзе ашыгып бармаса да, дәрте-дәрманы ташып торган хәрәкәтчән тән-бәдән. Иген басуы кебек киң, якты маңгай. Кояшта янып, кавын төсенә кергән йөз. Һәм... шуның капма-каршысы: җиткән арыш сабагы сыман аксыл-сары чәчләр учмасы. «Бу кеше җәй буе баш киемен салмаган, күрәсең, — дип уйлап куйды Беренче. — Моның чәчләре быел җәйге кояш белән бөтенләй танышып та өлгермәгән...» Гомерендә меңләгән «социалистик ярыш» алдынгыларын күргән-белгән Беренченең бу кешене истә калдыруының, онытмавының үз сәбәбе бар шул. Ярар, анысы хакында, әгәр насыйп итсә, соңыннан искә алырлар. Хәзергә партия гозерен үтәгез, иптәш Җакшылыков.

Беренче үзе басып торган мөнбәр артыннан чыкты һәм Сәдит Гатиятуллинны кысып кочаклады, аннан, тәртип кушканча, орденны кечкенә каптан чыгарып, пинжәк якасына беркетә башлады. Бүләкләнүченең күзенә карап, ата-бабаларының нинди нәселдән булуын аныклау, зал каршында озаклап гәп куертып тору регламентта бөтенләй каралмаган каралуын. Әмма бу юлы Җакшылыков, үзен регламент белән чикләп, бу бурычтан котыла алмады. Гатиятуллинга орденның таныклыгын һәм буш кабын тапшырып кулын кысканда, аларның карашлары очрашты. Комбайнчының җете зәң-

* Җамбыл Җабаев (1846–1945) — казакъ халык акыны, Сталин премиясе лауреаты (1941).

гәр күзләре нindидер боз биләү эчендә яна, аңа нindидер бер куркыныч белән янап ялкынлана, бәгырен бораулый иде... «Зәңгәр күзле нугайлар, гадәттә, аксөяк нәселле, тирән тамырлы, кабилиятле нугайлар була торган иде, — дип уйлап алды ул. — Ә бу туескан* карашы белән мине ашап бара, әтнәке. Вагаймаганнармы?»

Уйлаганы озак көттермәде.

Комбайнчы еларга җитеп авызын чалшайтты, Җакшылыковның кулын үз кулының мамырлы ыргагы белән әләктереп кысып, пышылдады:

— Ниг-гә?! Пач-чам-му?!

«Вагайганнар икән». Секретарь бер нәрсәне аңламады һәм бер үк вакытта күп нәрсәне аңлады да кебек. Иң мөһиме, аңа бу «Ниг-гә? Пач-чам-му» дигән сүзләрне зал гына түгел, СССР компартиясенең беренче секретаре иптәш Хрущев үзе, Казакъстан компартиясенең беренче секретаре иптәш Брежнев үзе, Казакъстан Министрлар Советы рәисе Димәш әкә — Динмөхәммәд Әхмәд угылы Кунаев үзе, алар гынамы, Җир шарының барлык коммунистик һәм эшчеләр хәрәкәте җитәкчелеге, дөньяның барлык прогрессив җәмәгатьчелеге ишеткән кебек тоелды.

Берничә секундка гына югалып калган Беренче үзен кулга алды:

— Тс-с!..

Комбайнчы җегет аңа, бертуган энесе сыман, яшьтән дымланган күзләре белән өздереп карый иде.

Җакшылыков үткер карашы белән тирә-ягын чумырып алды.

Аларга барлык кешеләр аңлаган-белгән һәм мотлак аңларга-белергә тиеш булган рәсми, милләтара дәүләт телендә сөйләшергә ярамый иде. Бу телдә аларны мөнбәрләр генә түгел, диварлар да тыңлыйлар иде шул. Аларга шул мизгелдә онытылып барган телләре ярдәмгә килде. Алар, беркем дә аңламасын дигәндәй, татар һәм казакъның уртак гомумтөркиендә ике-өч кенә кәлимә сөйләшеп алды:

— Бавырым, ол сезбе?.. Ә-ә-бү-га-лис!.. Бункердагы бисек... Кечкен-тәй бала... Кырык градус кояш... Ол сезбе?

—Мин, иптәш секретарь! — диде тыны куырылган Сәдит. — Мин булмыйча!.. Кем булсын тагын?!

— Өзелестә** яныма килче! Жду!..

Ялкыннарга чорналган Сәдит, гүя үзе артыннан бар дөньяны да яндырып, урынына төшеп утырды. Орден таныклыгын эчке күкрәк, аның кызыл катыргы кабын исә аскы кесә-

* Туескан (казакъча) — туган, энекәш.
** Өзелес (казакъча) — тәнәфес.

сенә салганнан соң, үз горурлыгын башкаларга сиздермичә генә, кулын сул як түшеннән шудырды. Орден урынында иде. Металл салкыны аны өшетеп алгандай булды.

Сәдит әле үткән җәйдә генә булган, әмма көтелмәгәндә генә менә бу, аңа хәзер бер караганда сөенеч, икенче караганда көенеч булып күренгән, инде теләсәң-теләмәсәң дә тарихка әйләнгән вакыйгалар өермәсенә чумды...

...Алар оештыра башлаган яңа «Каравыл-Түбә» совхозының җирләре чынлап та иксез-чиксез иде. Татарстанның Сарман якларында туып-үскән Сәдитнең бу кадәр киң һәм иркен яланнарны күргәне юк иде. Мондагы бер совхоз җирләре бөтен Сарман районы җирләренә тора. Әгәр үзең җитәкчеләрең һәм синең бункердан иген ташучы шоферларың белән килешеп, басуны кишәрлекләп-бүлеп алмасаң, загонның бер башыннан икенче башына бер тәүлек эчендә дә барып җитә алмассың кебек. Яратмый Сәдит мондый моңсулыкны. Нәкъ әнә шул казакъ акыны Җамбул Җабаев айтыслары* кебек инде. Башы да, азагы да юк. Нәрсә күренә, шуның хакында җырлыйсың да җырлыйсың. Җырлый-җырлый барасың да барасың. Әмма дә ләкин аның нәселе, каныннан килгән кешелек табигате, Сарман, Минзәлә тарафларындагыча, борылышларның, манзараларның яңарып торуын ярата. Нишләп шулайдыр инде ул?

...Совхозга быел кыш, дөресрәге, ыжгыр февраль суыкларында килеп урнаштылар алар. Яшь бала белән. Кеше ышанмаслык нәрсә инде бу. Имеш, язгы чәчү башлануга өлгерәләр. Бераз гына соңласалар да, харап булалар югыйсә. Аны авыз тутырып «урнашу» дип тә булмый инде югыйсә. Бер сүз белән, Теләнче Тамак комсомолы биргән путевка буенча инде, ташка үлчим инде ул мондый «урнашу» дигән нәрсәне. Әй, тора-бара барысы да булыр әле. Түзәргә кирәк. Германиядә танкист булып хезмәт иткән һәм шулай итеп, көтмәгәндә, механизатор һөнәренә ия булган егеткә туган авылы Теләнче Тамакта трактор да, комбайн да бирмәделәр. Бер карасаң, үпкәләргә дә урыны юк инде. Анда инде, ходаем, күптән түгел генә өч авылны берләштереп эреләтелгән колхозда, ике трактор, бер кәлүсний У-2 һәм НАТИ аламасы. Бер комбайн. «Сталинец-4». Алары да иске, төртсәң, таралырга тора... Әмма шундый сирәк һөнәре булган ирегетнең төрле эшләрдә, труттинле Нуреттин сыман, кәгазьдәге таяк хакына бушка йөрисе, алданасы килмәде. Җитмәсә, гаиләләре дә ишле. Егет өйләнеп тә ташлады. Менә балалары да булып куйды бит әле. Беренчеләре. Рәмзияләре. Ка-

* Айтыс (казакъча) — акыннар ярышы, әйтеш.

закъстан якларында чирәм җирләр турында шау-шу купкач, Сәдит ике дә уйлап тормады — нибары яше тулып маташкан кызы белән хатынын «култыгына кыстырды» да чыкты да тайды менә шушы тарафларга. Хуш, Теләнче Тамак! Син теләнеп яшәсәң дә, без теләнмәбез, Алла боерса!

Бөтен ил шашты бит ул көннәрдә. Урамнардагы барлык радиобаганалар «Чирәм җир! Чирәм җир!» дип бакырды. Һәр яшь йөрәкнең таза тешләренә шул көннәрдә чыккан атаклы җыр эленде. Аңлар-аңламас булса да, Сәдит белән Шәфыйка да җырлады ул җырны:

Едут новоселы
По земле целинной.
Песня молодая
Далеко звучит.
Ой ты, зима морозная,
Ой ты, земля целинная!
Скоро ли я увижу
Свою любимую в степном краю...

Әйе, Аллага шөкер. Җан сөйгәннәрен көтеп ятмады Сәдит далада, урыннарыннан кубарды да үзе белән бергә өстерәде дә алып килде. Тормыш җиңелдән булмаса да, теләнеп яшәмиләр. Килүләренә нибары сигез ай — өс-башларын энәсеннән җебенә кадәр бөтәйттеләр. Үзенә өр-яңа комбайн эләктерде. «Сталинец-6». Монда үзйөрешле комбайннар да күренгәли инде. Әгәр монда ошамый башласа, җитәкчеләр үзләренең «Яшәргә почмак та бирәбез» дигән вәгъдәләрендә тормасалар, ул совхозның бирәр үзйөрешле комбайнын чәлдерәчәк тә Теләнче Тамакка таячак! Шәфыйкасын, Рәмзиясен, тапкан бар «җиһазын» төйиячәк тә качачак! Фью-фью! — Ул мондый чакларда сызгырып та җибәрә. — Әйе, киләсе сезонда үзйөрешлегә күчәргә хыяллана әле ул. Бар, Теләнче Тамакта күреп кара син мондый яңа техниканы!..

Менә «Бирәсе килгән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, көтмәгәндә генә бу орден да килеп кунды әле аның киң күкрәгенә. Орден турында уйлаганда аның күзләренә ачы яшь бәреп чыкты. Шатлык катыш гарьлектән ул, әлбәттә.

Быел, әле оешып кына ятсалар да, «Мәмләкәт»ләрнең, кем әйтмешли, бүресе улады. Чирәм җирләрдән беренче уңыш алынды һәм нинди генә уңыш әле! Теләнче Тамакта елның елында иң зур уңыш гектарына ун центнердан артмагандыр. Ә монда? Монда, егетләр, Җир-ана гүяки милли-

он еллар буе безне генә көтеп яткан. Әйе, җирдә миллион еллар буе тупланып килгән аш һәм татлы тоз чирәмнең беренче елында ук гектарыннан, ышанасызмы, кырыгар-иллешәр центнер уңыш бирде. Күрелгән нәрсәме бу?! Киләсе елларда ничегрәк булыр, анысын бер Алла белә, әмма быел игеннәр ишелепләр, котырыплар үсте. Совет Армиясенең ярты техникасы иген җыйнарга, ярты брезенты урылган игеннәрне явымнардан капларга китте. Куярга урын калмагач, кешеләрнең ишегаллары, ихаталарына, ат һәм сыер абзарларына, мәктәп, клуб идәннәренә бушаталар иде. Мондый уңыш Америкада да булмагандыр. Башак буйга — бер карыш, иңгә — имән бармак кебек юан, бөртек үзе төш кебек эре, саллы һәм эчтән яктыртылып якты иде. Кайчакта, эштән арып, бераз күзне, билне һәм тез буыннарын язырга дип җиргә төшкән чакларда, Сәдит куанычын кая куярга белмичә, берничә башакны өерелтеп, учма итеп өзеп ала һәм кояшка күрсәтә — югарыда вакыты-вакыты белән кырык, ә бәлки, вакыты белән илле дәрәҗәгә дә җитеп кыздырган кояш нурларында башаклар шәмдәлләр кебек эчтән яктыра. Бер карасаң, алар Мәскәүнең киножурналларда, сурәтләрдә сурәтләнгән Кремль шәмдәлләрен хәтерләтә. Нигә, чынлап та шулай. Әйе, әйе, әгәренки дә шул башаклар булмаса, Ватанның гербы каян килә ди дә, теге Кремль шәмдәлләренең төссез һәм хәлсез пыяла кисәкләре ничек итеп илне эчтән яктырта, аңа көч бирә алсын ди? Икенче карасаң, анда гүяки түбәтәйле аксакал картлар һәм ак яулык бәйләгән мөслимә әбиләр тезләрен чәнчеп китап укыйлар һәм мөнәҗәт әйтәләр. Әйе, чынлап та шулай! Игътибар белән карый гына, аларны күрә генә белергә кирәк. Ул бер тапкыр мондый башакларны штурвалда торучы ярдәмчесенә дә күрсәтеп карады. Ярдәмчесе дигәч тә, әллә кем түгел инде ул. Үзенең хәләл хатыны. Шәфыйкасы, ягъни мәсәлән. Совхозда кеше җитмәгәч, ул минем хатыным, әле күкрәктән аерылып та өлгермәгән балам-багалмам бар, фәлән-төгән дип тормады, баласы-ние белән үз экипажына алды да куйды. Штурвалчы булу өчен әллә ни белем кирәкми бит инде. Санга бар — исәпкә юк. Кем әйтмешли, коданың кардәшлеге, кәҗәнең маллыгы, штурвалчының һөнәрлеге. Экипажда алар өчәү, мин сезгә әйтим. Сәдит, хатыны Шәфыйка һәм ике яшькә җитеп килә торган кызлары Рәмзия. Өч танкист, ягъни мәсәлән. Ул кайчакта кәефе килеп җырлап та җибәрә: «Тырри танкиста, тыр-ри вес-селых друг-га, ек-кипаж маш-шины

бай-йа-вай!» Шулай «экипаж» түгел, армиядә өйрәнгәнчә, «екипаж» ди ул. Юк, күрми хатыны башакларда теге Кремль шәмдәлләрен. Мөслимин бабай белән әбиләрне ул гүпчим дә күрми инде. Вәт, надан!.. «Күр, — мин әйтәм. — Әгәр күрмисең икән, үзеңне салып та очырам, екипаждан да куып чыгарам!» Чак сугышып китмәделәр башактагы яктылыкны күрү мәсьәләсендә. Күрде, ниһаять, тегесе. Хатын булгач, күрми кая барсын ул?!

Беренче секретарь Җакшылыков белән танышлыгы да аның нәкъ әнә шул «екипаж» аркасында булды да бит инде.

...Уракка төшүнең беренче көннәре генә иде әле. Мондагы загоннарның озынлыгы берничә чакрымга сузыла икән шул. Күзне талчыктыра, җанны арыта мондый бертөрле манзара. Барасың да барасың. Иге-чиге юк бу баруның. Аннан, эһ итәргә дә өлгермисең — бункер тула. Игенне кая куярга? Ташырга йөк машиналары җитешми. Аны бит уч төбенә аударып булмый. Балтасы суга төшкән ир кебек, хет утырып ела. Юк, иң зур иген басулары алтмыш-җитмеш гектардан артмаган Теләнче Тамакның егетләре монда, бер басуы гына мең-ун мең гектар мәйдан биләгән совхоз шартларында да утырып елар өчен тумаган. Алар ятып калганчы атып калыр өчен туганнар, мин сезгә әйтим.

Сәдит, җитәкчеләрдән беркем белән дә киңәшми-нитми торып, теге чакрымнарга сузылган загонны кишәрлеккә бүлеп ура башлады. Чөнки ул аларның моңа барыбер рөхсәт бирмәячәкләрен белә иде.

Ул шушы юл белән совхоз җитәкчелегенә иген ташучы машиналарны файдалырак файдалану мөмкинлеген аңлатырга тели иде. Теленә көтмәгәндә «файдалырак файдалану» дигән сүз килгәч, кәефе килеп елмаеп та куйды ул чакта. Әйе, машиналарны загонның бер башыннан икенче башына ягулык яндырып чаптыру кирәкми. Игенне җиргә бушаткан хәлдә бу аеруча уңайлы. Ә менә меңәрләгән гектарларны вак кишәрлекләргә ничегрәк итеп бүләргә соң? Сәдит, кояшның кайнар рәшәсен күз зәңгәре белән үтәли үтеп, тирәягына караш ташлады һәм куанычыннан кычкырып җибәргәнен дә сизмәде: — Яшибез, болай булгач!..

Ул комбайнында чайкала-чайкала үзе килгән юлда дала юлы буйлап сузылган телефон баганаларын шәйләп алды. Бәй-бәй, моңа кадәр ул аларны ничек күрмәде икән?! Әгәр дә... Әгәр дә аралары якынча йөзәр метрдан торган биш багана арасын бер кишәрлек итеп бүлсәң?.. Ул баганалар-

ны яңадан күзеннән кичерде. Үз күзләренә үзе үк ышанмыйча, берьюлы ике күзенең дә кабакларын уыштырды: шунысы кызык, һәр бағананың очы гүя киртләп очлаган чук белән чукланган иде. Нәрсә булыр бу?! Казакъ элемтәчеләре һәр бағананы шулай киртләп утырта мәллә югыйсә?! Әгәр шулай икән, Теләнче Тамакка кайткач сөйли торган бер әкәмәт нәмәстәкәй бит бу! Татарстанда да шулай киртләсеннәр элемтә баганаларын!

Егет, комбайныннан сикереп төшеп, баганаларга таба йөгерде.

Багана башында яшел күзләрен чекерәйтеп дала бөркете утыра иде...

Сәдитнең җаны өшеп, арка үзәге чемердәп куйды. Курkуы юкка булган икән. Соңыннан бу бөркетләр Сәдитнең иң якын дусларына, җан сакчыларына, һава торышын алдан хәбәр итүче кошларга әйләнделәр.

Ул икенче, аннан өченче, аннан дүртенче баганага чапты. Арыды. Бөркетләрне өркетеп, аларның чынлыгын раслау өчен ул җирдән кечкенә таш кисәге эзләде. Иксез-чиксез далада ташның ишарәте дә юк иде. Ниһаять, ул күзенә чалынган туфрак төеремен кулына эләктерде һәм бөркеткә атты.

Бөркет томшыклары белән җиңелчә генә ыскылдау авазы чыгарып җилпенде һәм һавага күтәрелде.

Сәдит комбайнына таба юнәлде. Бераз баргач, артына борылып карады: бөркет үз баганасына кире кунган иде. Башка бөркетләр исә, берни булмагандай, шундый ук багана башларында чук сыман оеп калганнар. Соңыннан белүенчә, аларның чын исемнәре дәшти, ягъни дала бөркетләре икән. Дәшти бөркетләр туган баганаларын ташламыйлар да, бирмиләр дә икән...

Күп күрде Сәдит баганалардагы дәшти бөркетләрне. Ул аларның сыннарын гына түгел, җаннарын да күрде. Бөркетләрнең җанын, ир-ат җаннары кебек үк, карбыздай ярып, тиз генә карап булмый икән. Алар каты биктә икән. Әмма аларның җаннары изге икән. Ул бөркетләрдән ярдәмнән, теләктәшлектән башка бернәрсә дә күрмәде. Кайчакларда аларга Шәфыйкасы белән нәниләрен кишәрлек башында бөркетләр карамагына калдырып китәргә дә туры килгәләде. Комдай кызгылт дала төлкеләре, аксыл сары дала барыслары, чиядәй куе кызыл чиябүреләр — дала шакаллары — аның шул ук далада йөзгән иген корабына якынлашкан очракларда, дәшти бөркетләр һавалардан төшкән шәүләләре белән

хәвефле өркетеп ыскылдыйлар, хәбәр бирәләр. Кайвакыт томшыкларыннан дала еланнары салынып торган бу дәһшәтле кошлар Сәдитнең хәләл җефете һәм кечкентәй генә кызчыгыннан торган гаилә экипажын төрле күренгән һәм күренмәгән афәтләрдән саклап калалар иде...

Ул бөркетле биш багана калдырып, загоннан озынлыгы чама белән биш йөз метрдан ким булмаган кишәрлек бүлеп алып, ура башлады.

Озакламый кишәрлек башларында кечкенә ындыр табаклары хасил булды. Ниһаять, басу тоташ бер ындыр табагына әйләнде. Игенне көн кызуында урып калуны изге бурычы итеп санаган Сәдит үзенең гадел эш итүен белә һәм шуңа күрә дә үзен тыныч һәм ышанычлы тота иде. Нигә, чынлап та шулай түгелмени: комбайнны аның кулына якты көндә иген янында елап утыру өчен түгел, ә ул игенне уру өчен биргәннәр. Йөк машиналарының җитмәвенә ул гаепле түгел бит. Комбайн биргәнсең икән, машинасын да бир. Нәрсә, көзге быжык, кара яңгырларны көтеп утырсынмы ул?! Шуңа күрә бит ул урак өсте «урак конвейеры» дип атала. Бер боҗрасы булмаса, чылбыр өзек булып чыга түгелме?

Кишәрлек башларында кирегә яңа борылыш ясаганда ул еш кына бөркетле баганаларга карап ала. Бөркетләр гүя урыннарыннан кузгалу, аерылуның нәрсә икәнен дә белмичә шул ук баганаларын саклыйлар. Гүяки алар оеп, баганалары белән бербөтен сынга әйләнгәннәр. Шулай ук соңыннан аңлашылуынча, дәшти бөркетләр, ябалакларга охшап, көндезгә караганда күз бәйләнгән мизгел, иләс-миләс эңгер, тома караңгыда күбрәк күрәләр икән. Шуңа күрә алар көндез даими очышта булырга бик яратмыйлар, күк тирәнлекләренә сирәк, ихтыяҗ булган очракларда гына күтәреләләр. Аларның күз бәллүрләрендә төнлә күрә торган нурлар бар димәк? Бу фикер Сәдитне әллә нинди истәлекләргә алып кереп китте. Моннан өч ел элек танкистларның Магдебург полигонында аларга, яшь танкистларга, бер яшерен җайланма — яңа танкларга куелырга тиешле булган төнлә күрү приборларын күрсәткәннәр иде. «Т-54» дип аталачак бу танкларны алар төнлә йөртеп тә карады: тышта күзгә төртсәң күренмәс караңгы, ә триплексларда исә бераз яшькелт нурга чумган яп-якты җир өсте, мин сезгә әйтим...

Дәшти бөркетләрдәге Туган Ил тойгысы аның җылыйсыларын китерде. Яшь тулган күзләрен ул челт-челт ачыпйомгалап алды.

Сагынган, бик сагынган иде үзенең Теләнче Тамагын яшь чирәм җирче.

Сәдитнең урактагы мондый башбаштаклыгын белеп алган җитәкчелек тәмам котырды. Эссесе белән якты көнне берьюлы ак һәм кара мунчага әйләндергән кояш бер яклап кыздырса, урындагы түрәләр Сәдитне икенче яклап кыздырды. Башта аның янына директор урынбасары Чабатенко килеп тәрмә белән янап китте. Аннан директор Алмаченко үзе килде һәм урылган игеннең хакын түләтү белән куркытты.

— Ти у мене на карачках ползать будеш! — диде ул аңа, күзләрен алартып. Аннан кояш ялкынында табак битеннән эреп аккан маен тастымал кадәр кулъяулыгы белән сыпырып алып, козгын сыман талый башлады: — Запамятуй, татарове, ти у мене кажну ридну пшиницю языком лызать будеш!.. Я тоби сказав, кажиця, татарове...

Рәнҗетте, бик тә рәнҗетте Сәдитне Алмаченконың бу сүзләре.

Күп тә үтми, аның урып барган комбайнын куып җитеп, каршысына ук бер төркем җиңел автомобильләр килеп туктады. Кызган рәшә ялкыны аша кулын болгап, Алмаченко аңа туктарга һәм моторны сүндерергә дигән ишарә ясады. Сәдит агрегатны шып туктатып сүндергәнче һәм җиргә сикереп төшкәнче, аның комбайны тирәсен ул белмәгән һәм күрмәгән җитәкчеләр сырып алды.

Араларыннан берсе — озын буйлы, алсу шома йөзле, бүгенгедәй кырык градуслы эсседә дә өстенә карасу зәңгәр төстәге, түшендә орденнар шакмагы ялтырап торган китель, галифе кигән, милләте белән казакъ икәнлеге чакрымнар аша кычкырып торган кеше — аңа кулын сузды:

— Исәнмесез. Өлкә комитеты секретаре Җакшылыков булам.

Сәдит үзенең исем-фамилиясен әйтте.

— Эшләр барамы соң?

— Ничек дим икән инде. Бара шунда. Дөрес оештырган хәлдә ун мәртәбә яхшырак бара алган булыр иде...

Беренче Алмаченкога карап алды.

— Дөрес оештыру дигәндә сез нәрсәне күздә тотасыз?

Сәдит барысын да үз каланчасыннан торып аңлатып бирергә тырышты.

— Бу егет ничегрәк эшли соң?—дип сорау бирде Алмаченкога секретарь. — Яхшы эшлиме, әллә...

— Болай алганда, начар түгел. Тырыш. Әмма бик тә үзсүзле, кирегә беткән кеше...

— Ничек... кирегә беткән?

Алмаченко үз роленә кереп Сәдитне сүгәргә тотынды. Имеш, ул иген конвейеры закончалыкларын бозып, барлык басуны тәртипсез ындыр табагына әйләндерде. Нәтиҗәдә, имеш, совхоз күрелмәгән зур югалтуларга юл куярга мәҗбүр булачак... Тагын да шунысы... Бытыр-бытыр... Тагын да шунысы... — директор Беренченең колак төбендә бытырдавын дәвам итте: — Әйткәнне тыңламый. — Тагын да бытыр-бытыр...

Җакшылыковның ирен читләре тартыша башлады. Ул Алмаченконы шып туктатты:

— Евгений Христофор малае, тукта. Әтеү әрләшеп китәрбез. Шунысын гына әйтәм: егетләрең районда искиткеч зур уңыш үстергән. Урыны-урыны белән алтмыш центнерга җиткән бүлекчәләр бар. Нәрсә, алар синең егетләрең түгелмени? Алар хәзер шул уңышны тизрәк җыеп алу өчен көрәшмиме? Без аларга барлык шартларны тудырырга тиеш түгелбезмени? Әгәр син кеше кулына комбайн штурвалы тапшыргансың икән, аның игенне ташу өчен синең машинаң булуы-булмавында ни эше бар? Нигә сез өлкә комитеты резервыннан өстәмә транспорт сорамыйсыз? — Ул Алмаченконың күзләренә текәлде. — Сезнең иген ташырга автомобильләр җитми икән ләса! Ә минем бу хакта ишеткәнем дә юк. Ә сез, оят булса да әйтим... — Ул җиңелчә генә сүгенеп куйды. — Безгә әллә кайлардан килеп, иген үстерергә өйрәткән бу уңган егеткә яла ягасыз! Әйтегез әле, совхозга бүгеннән ничә йөк машинасы кирәк?

— Йөз, — диде баягы өшкерүдән әле айнып та җитмәгән Алмаченко, аны-моны уйлап тормыйча.

— Бәлки, ике җүздер тагын? Какой умница нашелся. Бәлки, урынбасарыгыз беләдер?

Җакшылыков тирәсендә кара шәүлә сыман кемсә пәйда булды. Аның фото кәгазе кебек соры чырае ничектер истә калырлык түгел иде.

Йөзе саргаеп каткан Алмаченко нәрсәдер мыгырданып маташты.

— Сезнең агрегатка шәхсән ничә автомобиль кирәк булыр иде? — дип сорады Сәдиттән Беренче.

Егетнең башына шаукым бәрде, шатлыгыннан кан басымы күтәрелде.

— Алты, — диде ул, комбайн белән ындыр табагы арасы-

ның шактый ерак булуын исәпкә алып. — Әлегә мине нибары ике «ЗИЛ» хезмәтләндерә. Аның да берсенең брезент япмасы юк. Игеннәре юлга коелып бара... Миңа алты «ЗИЛ» булса яхшы булган булыр иде..

— Җитешәчәксезме?

— Нигә җитешмәскә? — Егет үзе дә сизмәстән шаркылдап көлеп җибәрде. — И-и-и, җитешми диме, бирсеннәр генә! — Аннан ул Алмаченко ягына утлы караш ыргытты. — Без, татарлар, яуда да, хезмәттә дә беренчелекне бирмибез. Не чабата же я какуй, чтобы я и мой хатун у кава-ты как чабата на хбасту мотатсы...

Сәдитнең соңгы сүзләренә игътибар итүче дә, аңлаучы да булмады кебек. Аларны бары тик совхоз директоры — бирегә Брежневның шәхси чакыруы буенча Днепропетровскидан килгән Алмаченко гына бар кинаясе белән аңлый иде. Әйтелгән сүзләрне бары тик үзенең тупас алабарманлыгы аркасында гына илтифатсыз калдырган кебек тоелса да, ул аларны игътибарсыз калдырмаячак һәм бер килеп үчен алачак иде бу фиргавен токымы.

Нишләптер гел бәйләнеп кенә торды шул Сәдиткә бу Алмаченко дигән җитәкчеләре. Башта ул аның исемен ошатмады — Сәдитне Александрга әйләндереп маташты. Аннан фамилиясен, аннан әтисенең исемен кабул итмәде. «Без, татарлар, исемне әҗәткә алмыйбыз, үзебез аны башкаларга бүләк итәбез, — дип әйтергә мәҗбүр булды аңа бер тапкыр йодрыкларын төйнәгән Сәдит. — Менә сезгә дә фамилияне без бирдек. Сезнең Алмаченкогыз ул безнең «Алмачы әнкәй» дигән сүзебездән алынган, аңладыңмы? Урысча, яблучная мать, ызначит. Чабатенкогыз — чабатадан, пүнәл, лапти, ызначит. Кахулчасын үзең беләсеңдер... — Аннан күзләрен кысты да армиядә ишеткән бер мәзәгендәге татарның урыска әйткән сүзләре белән җөпләп куйды: — Не забудь, тбой тринадцатый прапрадед мене прикурить дулжын...»

— Жазып куй һәм контрольгә ал, — диде янындагы Шәүләгә Җакшылыков. — Совхозга резервтан өстәмә егерме биш «ЗИЛ» кайтартырга, шуларның алтысын урып-җыю тәмамланганчы Гафиятуллин агрегатына беркетергә. Сынап карыйк, өлгерер микән? — Беренче Сәдиткә таба борылды. — Туктагыз әле, миңа сезнең фамилиягез бик тә таныш күренә. — Гүя ул «таныш фамилияне» телендә тәмәйтеп карый иде. — Гафиятуллин... Гафиятуллин бит, шулай бит, Гафиятуллин? Сез Советлар Союзы Герое Газинур Гафия-

туллинның туганы, йә булмаса, алыстан туесканы... э-э... берәр чыбык очы түгелме?

— Юк, без Гатиятуллиннардан булабыз, — дип төзәтте комбайнчы. — Безнең аерма... — Ул берни булмагандай эчкерсезлек белән тагын да шаркылдап көлеп җибәрде. — Бер хәрефтә генә... Гафиятуллин — Гатиятуллин. Газинур абзый Гафиятуллин исә минем бик якын якташым була, мәрхүмкәй... Ул — Сугышлыдан, ә мин...

— Ә-ә-ә, менә эш нәрсәдә! — дип кычкырып җибәрде Җакшылыков. — Менә шул син әйткән бер хәреф бутаган да инде мине!.. — Ул кулын Сәдитнең иңенә салды. Йөзенә бер мизгелгә уйчан шәүлә яткан секретарь, күзен бер ноктадан күтәрмичә, сүзен дәвам итте: — Без аның белән бер армиядә хезмәт иттек... 22нче армия, Икенче Балтыйк буе фронты... Әмма таныш түгел идек. Кая ди анда? Армия кадәр армия бит ул!.. — Ул авыз чите белән көлемсерәп куйды. — Әйтергә генә җиңел, йөз мең солдат... Ә ул безнең армиянең беренче шундый бөек герое... — Җакшылыков соңгы сүзләрен үз тирәсендә басып торучылар өчен өстәп куйды шикелле: — Беләсездер инде, Газинур Гафиятуллин — дошман амбразурасын күкрәге белән каплаган татар каһарманы... Псков өлкәсенең Овсище авылын алганда... Озакламый, бәлки, безнең казакъ даласында якын карындасымыз Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин исемендәге совхоз да күтәрелер әле, шулай бит, туганнар?

Бу сүзләрдән соң Сәдитнең җаны күккә ашты. Әмма шундук җиргә төште — җиргә башаклардан иген, алтынланып өлгергән иген коела иде!..

Баш өстенә менеп кунаклаган дала кояшы чеметеп алып, өздереп кыздыра, җир йөзендәге аз гына симез нәрсәне дә аяусыз рәвештә өтә, эретә һәм юк итә. Аның гаебе белән шулай туктальп, вакытны — кадерле минутларны заяга очырганы өчен оялып, Сәдит урынында таптанды, аннан, башка кайберәүләр кебек, мондый чакларда хәйләләгән булып, кунакларга аерылышырга, эшкә башларга вакыт икәнлеген төшендерү өчен кат-кат сәгатенә караган булды. Тик аның кул беләзегендә әлегә сәгате юк иде. «Алла бирсә, баесамнитсәм, камалы тун тектерәм», — дигән кырыктартмачы үсмер кебек, ул сәгатьне, чынлап та баеган хәлендә, сатып алырга гына җыена иде. Кыскасы, вакыты кыскан Сәдитнең вакытны белү өчен үз вакыты юк иде...

Якында гына чыелдап йомран сызгырып җибәрде.

Сәдитнең йөрәге ярылгандай итте.

Ул күк гөмбәзендә, нәкъ үзенең баш түбәсеннән шәм сыман эреп аккан кояшка карый алмаган карашын җиргә төшерде.

Ләкин мондагылар ашыкмады, чөнки Беренчеләре бу юлы ни сәбәпледер ашыкмады. Сәдит ашыккан саен ашыкмады мәллә ул? Юк, армия дәрәҗәсендәге политработник булып авыр сугышларны үткән казакъ Җакшылыков ашыкмавының сәбәбен башкаларга караганда яхшырак белә иде: яу алдыннан һәм яу барышында адәм баласына булган игътибар аны күккә күтәрә, дәрәҗәләрне тормыш офыклары белән тигезли һәм адәм баласы биеклеккә эленгән байрак, күкрәгенә кунган шөһрәт, кочагына тулган мал-мөлкәт белән җиргә төшә. Дан мондый адәм баласына! Ул, галифе кесәсеннән эре зәңгәр шакмаклы кулъяулыгын чыгарып, инде ничәнче кат битендәге тирләрен сөртте.

— Бая сине бүлдердем бугай. Ә син өзеңде кайсы авылдан айткан идең әле? Теге... Сугыслыдан алысмы ул?

— Теләнче Тамактан мин. Сарман ягыннан. Сугышлыга, булса, шул җитмеш-сиксән чакрым булыр.

— Тукта, тукта... Сарман... Сарман... — Секретарь кояшның бу кайнар мичендә нишләргә белмәгән җолдасларының һушын алып җырлап җибәрде:

Сарман буйларыннан үткән чакта
Тыңларсыңбы жырулар жырласам?
Күзләреңде тултырып карарсыңбы,
Зәңгәр таудан жаулык болгасам?..

Сәдит куанычыннан үкси иде. Ул үзенең мондый җебегәнлеген башкалар күрми микән дип оялгандай итте һәм яшь бөртекләрен җиң очы белән сыпырып алды.

Алмаченко моны шәйләде. Ул үзе дә сизмәстән кулындагы чыбыгы белән хром итеген чәбәкләп алды.

Җакшылыков боларның икесен дә күрмәмешкә салышты. Болар аның җиңүе иде.

— Безнең 37нче укчылар дивизиясенең яртысы татарлардан торды, — дип сөйләп китте ул. — Хәер, Россия армиясе гомер-гомергә яртысы белән татар армиясе бит инде ул... «Сарман» исә безне иң хәтәр хәлләрдән коткара торган авральный җыр... юк, тантаналы марш иде! Һич тә арттырмыйм, яудашларымның күп чакларда һөҗүмгә шушы җыру белән күтәрелгәнен хәтерлим... — Секретарь, истәлекләреннән арынып, яңадан Сәдиткә таба борылды. — Теләнче Тамак, дисең. Ул урысчага ничек кайтарыла?

Сәдит аңламый торды.

— Переводится?

Сәдит монысын да аңламады.

— Теләнсе Тамак. Орысча кандай?

— Не знай. — Сәдитнең бу хакта беркайчан да уйлаганы юк иде. Урысчасы да чамалы булгач, ул беразга югалып калды. — Них-харуший сүз инде ул, егетләр. — Теләнче... Теләнче... Ул нишший була микән инде? Нишший, — диде ул аннан, ике дә уйламыйча.

— Немае, ни нищий, — дип тезеп китте Алмаченко. — Һолодный, буде!.. Пипрошайка! Батрачни!

— Таптым! Таптым! — Сәдит, алтын күргәндәй сөенеп, урынында таптанды. — Ачлык! Гулыт, ызначит! Гулытный! «Тамак» дигәне... «Тамагы» инде аның «гурлы» була шикелле...

— Ни. Ни һорло, — ди малороссларга хас булганча, «г»-ны «һ» белән каплап. — «Рит» я вам кажу!

— «Теләнче Тамак» ызначит «Гулытный гурлы», — дип раслады Сәдит.

— «Һолодный рит», — дип раслады Алмаченко.

— Хохол белән татар бәхәсе — басмадагы ике кире тәкә бәхәсе инде ул, — диде кемдер.

«Моңа билләһи дә акыл кермәгән икән, — дип уйлап алды Сәдит. — Тагын акыл утыртырга туры килер, ахрысы».

— Икесе дә дөрес, — дип төзәткән булды Җакшылыков. — Авылыгызда, нәселегездә кемнәр бар?

— Авылда сугыш янбалиты әтием, әнием, өч ир, ике кыз туганым бар. Тирә-якка атаклы балта осталары, бетончылар нәселеннән без. Галимҗан абзыкаебыз Березникида атаклы бетончы, Сәлимҗан абзыкаебыз Магниткада атаклы балта остасы...

— Акча белән ярдәм иткәлиләрме соң?

— Кая инде ул? Кайвакыт елына бер тапкыр посылка салгалыйлар.

Анысына рәхмәт.

— Татарстанда тормыш авырмы?

— Күтәреп карасаң, авырдыр инде ул. Әлегә кайда җиңел соң? Җиңел булса, мин яшь баламны, хатынымны ияртеп, шушы күз күрмәгән якларга чыгып олагыр идемме? Дөрес, халык ызан башында ачка үлеп ятмый ятуын, тырышкан була, түзә... Безнең авылның вербавай кызлары-егетләре бер пар эрзинкә, бер күлмәклек хакына Сахалин-

нан Мәскәүгә кадәр урман кисә һәм турыф чыгара. Һәм, мин сезгә әйтим, бик һәйбәт чыгаралар... — Сәдит тешләрен ыржайтып һәм шаркылдап көлә башлады. — Хәер, безнең халык Явыз Иван заманнарыннан алып лашманчы инде... Ха-ха-ха-ха!..

— Ә син нигә...көләсең жылаудың орынында?

— Көләм, бәй. Көлеп кенә исән калам бит мин. Ә бу хакта көлмичә сөйләп буламы соң?

Нәкъ шул чакта каяндыр яшь бала елаган тавыш ишетелде.

Бу тавыш якында, бик якында, гүяки кемнеңдер кесәсеннән чыга иде.

Адәмнәр барысы да тирә-якка караштылар. Анда чиксез казакъ даласыннан, күктә эреп аккан кояштан башка бернәрсә дә юк иде.

Елаган тавыш кабатланды. Адәмнәр бер-берсенә караштылар. Беренче янындагы Шәүлә карашы белән һәркемне тентеп чыкты. Араларында беркем дә еламый иде.

Кинәт Сәдитнең комбайны артыннан өстенә зәңгәрсу комбинезон, башына чөерелтеп шундый ук яулык бәйләгән хатын йөгереп килеп чыкты һәм ут капкандай ашыгып бункерга күтәрелә башлады.

— Кем бу? — дип сорады Беренче Сәдиттән.

— Хатыным.

— Тукалың?! Ул биредә нистәп йөр?

— Эшли. Минем белән.

— Кем болыптыр?

— Кем булсын, — диде Сәдит аптырап. — Пешекче түгел инде. Штурвалчы. Монда бүтән эш юк.

— Штурвалчы? Хатын-кыз. Штурвалчы?!

— Әйе. Заман кушканча, мин аннан ир-ат ясыйм. — Ул көлемсерәде. — Үземнән хатын-кыз ясыйм, бала карыйм...

Җакшылыков бу кинаяне төшенеп җитмәде.

— Болай ер тетрәтеп әле нистәп йөр?

— Нишләсен, баласы янына күтәрелә.

— Бала?! Кечкәнтәй? Кайда ол?

— Бункерда.

— Нистәп ол анда?

— Нишләсен, йоклый, бәй. Аның бишеге шунда.

— Бисек?!

Беренченең күзләре маңгайга сикерде. Аның кулыннан папкасы төшеп китте. Янында басып торган адәмнәрнең дә

күзләре дүрт булган иде. Әмма алар барысы, күрәсең, үзләренең күзләре турында оныткан иде, алар шапылдап төшкән папканы камылдан күтәреп хуҗасына тапшыру өчен ташландылар.

Ул арада бала бар тавышына елый башлады. Далага ниндидер ямь, көрлек һәм дәрт өстәлде. Кояш эссесе сүрелгәндәй, җил искәндәй итте. Ана бункер өстенә иелде. Инде баланың анда, бары тик анда икәнлеге беркем өчен дә сер түгел иде. Беренченең терсәге белән Шәүләсенә төртүе булды, Шәүлә шундук ак барс тизлеге белән бункерга ыргылды. Шәүләнең бункерга күтәрелүе булды, нәкъ шул мизгелдә ана сабыеның елавын тагын да көчәйтә биреп, тагын да елата биреп, алтынсу рәшә уйнаган бункердан алтын бодай көлтәсен суыргандай суырып чыгарды, аннан бу кадерле көлтәсен күкрәгенә кысып, аңа нидер сөйләп маташты, аннан мотор ягына китеп чүгәләде һәм баласына имчәген каптырды.

Сабый тынып калды. Далада моңсу булып китте. Гүя анда баланың ычмык-ычмык килеп имгән авазлары гына саркыла иде.

— Здесь — махонький!.. Монда бишек ба-а-ар! — Бункерның эчен караган Шәүлә бугазыннан җиз торба тавышлары чыгарып кычкырды. — Бишек ба-а-ар!..

— Төш аннан, баланы куркытырсың тагын! — дип җавап бирде аңа Җакшылыков. — Тавышың кеше тавышы кебек булса тагын...

Әмма бу хәбәр инде беркемне дә кызыксындырмый иде.

— Бисек... — Ни әйтергә дә белмәгән Беренче башта Сәдиткә карады. — Бисек элеп, батырлык эшләдем дисең инде... Лихо, ничего не скажешь. — Аннан ул Алмаченкога иелде һәм аның колак куышын кайнар тыны белән өттереп алды. — Сез мондый бардак өчен бюрода җавап бирәчәксез. Нәрсә, комбайнга бишек асып, уракка чыгарга Суматра джунглиләре түгелдер бит монда?! Советлар Союзыдыр, шәт?! Әгәр идеологик дошманнар комбайн бункерындагы бишекне фотога төшереп, берәр «Нью-Йорк таймс»та бер егерме миллион данәдә бастырып чыгарсалар?! Советлар чирәм җир уңышын балаларның саулыгы, күз яше белән яулыйлар дип бераз күпертеп тә җибәрсәләр, ә ?!

Җакшылыков комбайнга таба юнәлде. Йөзендәге аклыкүкле төсләрне сары камылга коеп, аның артыннан Алмаченко һәм башкалар да иярделәр.

Сәдит, каккан казык сыман, урынында калды.

Секретарь комбайнга күтәрелде һәм күләгәле булсын өчен өсте ясалма брезент белән капланган бункер өстенә иелде. Һәм елмаймыйча түзә алмады: эре, якты, чүпсез, кара солысыз, кем әйтмешли, чип-чиста бодай белән тулып килгән бункерның эченә беркетелгән аркылы агачта, кырык дәрәҗәдәге кояш астындагы күләгәдә, карлыгач оясы кебек биектә һәм җил җиләсендә тияккә төенләнеп, чиста, ак җәймәләр белән тулган бишек тирбәлә иде...

Бункер мәйданчыгының аргы очында бераз чүгәли биреп бала имезгән тукалга караш ташларга да кыенсынып, ул җиргә сикереп төште. Беренче артыннан, ашаган ат сыман гөп-гөп килеп, башкалар да сикерделәр.

Беренченең күңеле тулган иде. Бугазына төелгән төенне тизрәк йотарга, дулкынлануын сиздермичә генә басарга теләп, ул бер сәбәпсез комбайнны әйләнеп чыкты. Аның артыннан кайсы хром итек, кайсы җиз кадаклы штиблетлары белән эре сабаклы, сөян төсенә кереп саргайган камылда чаштыртап, башкалар да комбайнны урап әйләнде.

Ул әле һаман кадалган казык сыман басып торган Сәдит янына килде. Аңа ияреп башкалар да килделәр.

— Ай-бай, бавырым, үзең дә булдырасың икән... Әбүгалис син, мин сиңа әйтим! Әбүгалисина! А-ви-цен-на!

— Кем була ул? — Сәдит, күзләрен тоҗырайтып, Беренчегә карады.

— Шуны да белмисеңме? — «Шуны да» дигән каһәр суккан сүз бәйләнешен ничек ычкындырганын сизми дә калган һәм мондый гакылсызлыгы өчен кешене рәнҗетә күрмим дип уйлап өлгергән Беренче авызын каплап куйды, һәм мизгелне йомшарту өчен ашыгып-ашыгып сөйли, шомарта башлады: — Моннан мең ел элек яшәгән бөек табиб, тылсымчы, гыйлем иясе... Безнең бөек төрки бабабыз Әбүгалисина!.. Тутырып ук әйткән хәлдә, Габдел Гали Хөсәен ибне Габдуллаһ ибне Гали ибне Хәсән диләр аны. Күрәм, син дә аның кавеменнән икәнсең бит!.. Кана, бавырым, син бу бисегең белән безнең барымызды да савыктырдың бит әле... — Җакшылыков шундый ләззәт белән көлде, инде яшереп тә тормыйча күзендәге яшен сыпырып алды. Аның артыннан башкалар да көлде. — Ә синең белемең нинди?

— Безнең якта әйтүләренчә, коридорлары белән дүрт класс...

— Һәйбәт бу. Бик һәйбәт. Чынбарлык шуны раслый, Рәсәйнең дүрт сыйныф белеме әлегә Казакъстанның урта белеменә тиң. Димәк, синең, бавырым, бездә урта белемле адәм булып исәпләнергә хокукың бар... Төпләнеп, тамырланып китсәгез, Күкчәтау авыл хуҗалыгы институтына керерсез. Үзем тәкъдим итәрмен. Инженер-механик булырсыз. Армия һөнәрегез нинди?

— Танкист.

— Шулай булгач... — Секретарь бер мизгелгә уйга калды. — Шулай да әйт әле, Гатиятуллин, ничек итеп... Ничек мөмкин бу? Комбайндагы шнек шавы астында ничек итеп кечкәнтәйне йоклатырга мөмкин?.. Күптәнме?

— Күптән түгел әле. Булса, бер атна чамасы булыр. Башта без кызыбыз белән яшел печәнгә дип кукруз чаптык. Кукруз чапкан чакта, беләсез, бункерга берни дә акмый, шау-гөр юк. Бодай урагына төшәр алдыннан сиртмәле бишеккә, чүп-чар кермәсен өчен, чыбылдык юнәттем дә, бәбине бишеккә салып, сынау үткәрдем. Ничауа, йоклый!.. Гөрелтегә игътибар итмәскә ул кукруз урагында өйрәнеп калды, ахрысы. — Сәдит майлы кул сырты белән танау астын себерде. — Аннан, иптәш секретарь, артык борчыла башласа, әнисенә дә ял кирәксә — әнә, минем куыш! — Сәдит камыл уртасында торып калган салам куышка күрсәтте. Анда мендәр-юрган, башка кирәк-ярак та бар... Икесен дә күтәрәм дә, илтәм дә салам!..

— Кечкәнтәй канча жаста?

— Ничә яшьтә дип... Бер яшь тә сигез ай.

— Һы. Үзегез дә тәвәккәл, үзегезгә охшап, сабыегыз да тәвәккәл икән.

— Йоклыймы? — диде Секретарь әле һаман ышанмыйча. — Ыжламыйдамы?

Сәдит багана башларындагы бөркетләргә карап алды. Алар урынында иде.

— Йоклый. Ыжламый да. Ярдәм дә итәләр.

— Кемнәр тагын? Моны бездән көлеп әйтәсезме?

— Бөркетләр, — диде Сәдит, баганаларга таба ымлап. — Дала бөркетләре.

— Ә-ә-ә. Танышып өлгердегезмени инде? Бездә аларны дәшти бөркетләр дә диләр. Бик хуп, бик хуп. Димәк, сабый дала бөркетләре яслесендә тәрбияләнә... Тәвәккәл! Тәвәккәл! — диде кәефе килгән Беренче һәм аннан нәрсәнедер

исенә төшереп сорап куйды: — Ә сез нигә... исеме ничек әле... Рәмзияне яслегә бирмисез?

— Биргән идек тә, кире алдык та бирегә алып килдек. Монда, басуда, бет тә, микроб та юк.

— Ни сәбәптән кире алдыгыз?

— Бетләде, бәй. Өченче көнендә үк. Андагы зимләнкедә бала түгел, ат та бетләр. Монда бет чүпләп утырырга килмәдек бит без...

— Ишетәсезме, Алмаченко, яслегездәге бетләр уңышын комбайн белән уралар.

— Тикшерербез, Җалкын Сарбаевич.

— Тикшерергә кирәк имәс. Бетләрне үтерергә кирәк.

— Әйткәннәрегез үтәлер, Җалкын Сарбаевич.

— Бөҗәкләргә каршы тиешле санитария чаралары үткәргәннән соң, Гатиятуллинның кечкәнтәен яслегә урнаштырыгыз. Кирәк булса, тәүлек әйләнәсенә. Кирәк булса, атналыкка. Карагыз аны...

— Карарбыз, Җалкын Сарбаевич.

Бөҗәкләр турында барган мондый уңайсыз сүздән соң авыр тынлык урнашты. Сәдит бу кунаклардан шактый туйган иде. Эшкә башларга теләген белдергәндәй итеп, ул, комбайнына карап, урынында таптанып куйды.

Моны Секретарь да тойды шикелле. Сүзне югары кәефтә тәмамлау ниятендә ул, тәҗрибәле «партия мулласы», мондый чакта «тырыш хезмәт хакына утка керергә әзер булган совет кешеләре даирәсендә» бирә торган сорауның иң үтемлесен бирергә уйлады:

— Ә син бит инде... — Җакшылыков Сәдиткә туган-тумачаларча күз кысты. — Яратасың бит инде, әйеме? Ул да сине ярата, әйеме?

— Сез... нәрсә турында? — Аптыраган Сәдит сораугa сорау белән җавап бирде. — Эшнеме? Комбайннымы?

— Юк... Кхе-кхе... — Секретарь бункерга иелеп баланы бишеккә салып маташкан Шәфыйкага ымлады. — Киленне әйтәм...

— Яратмый нишләсен, монысы булгач, — диде Сәдит, үз кочагында бала тирбәткәндәй итеп. — Аннан, яратмаса, аптыраган юк, Җалкын Сарбаевич. Икенчесе бар...

— Ничек... икенчесе бар? — Җакшылыков, дөрес ишеттемме дигәндәй, колакларын уды. — Ничек... икенчесе бар?

— Мине хатын-кыз бик тә ярата, — дип сөйләп китте

Сәдит, берни булмагандай. Әллә ул дөресен сөйли, әллә бераз гына кылана — моны аеруы читен иде хәзер. — Мине эзләп авылдан икенчесе, Сәвиясе дә килеп җиткән әле, мин сезгә әйтим... Әле совхозда, ындыр табагында эшли...

Беренче секретарь, бу сүзләргә ышаныргамы-юкмы дигәндәй, бераз урынында чайкалып торды да кеткелдәп кенә көлеп куйды:

— Ну кызык адәм дә сез!..

Аңа кушылып Сәдит тә, башкалар да көлә башлады.

— Теләнче Тамактан ук килгәнме ул?

— Әйе. Теләнчедән үк. Яраткач, нишләсен? Алар икесе дә мине... теге... үлеп яраттылар шул. Әмма мин Шәфыйкага насыйп булып куйганмын... — Ул тагын да кочагында бала тирбәткәндәй итте. — Ә менә Сәвия бәгырькәем... Алма гөлем... — Сәдитнең йөзе борчулы төс алып томанланды. — Безнең авылдан юл ике тарафка гына чыга шул — йә Уралга торф чыгарырга, урман кисәргә, йә казакъ далаларына чирәм җирләр күтәрергә. Сәвия менә чирәм җирләрне сайлаган...

— Афәрин! — дип кычкырып җибәрде Җакшылыков. — Сезнең өчен килгән бит ул!.. Менә саф мәхәббәт нишләтә!.. Без ул Сәвия карындасымызга чирәм җирләрдә менә дигән кияү табармыз әле! — Аннан шапылдатып Сәдитнең кулбашына сугып куйды. — Шулай бит, ә, Гатиятуллин?

— Шулаен шулай ла ул, — диде ни әйтергә белмәгән Сәдит урынында таптанып. — Шулай булырга тиеш лә ул...

...Сәдит белән Җакшылыковның менә шуннан соң очрашканнары юк иде.

Яхшы эшләде Сәдитләр. Җакшылыков бүлеп биргән «ЗИЛ»лар килеп җитүгә алар башта совхоз, аннан район буенча беренче урынга чыктылар. Кечкенә Рәмзияләрен атналыкка дип теге «җанвар»лардан тулаем арындырылган яслегә дә урнаштырып алгач, Сәдит белән Шәфыйканың гаилә экипажы инде бөтен өлкә буенча беренчелеккә күтәрелде. Алар турында язмаган гәзит, сөйләмәгән радиобагана, аларны сурәткә төшермәгән фоторепортер калмады.

«Урак өсте елга бер килә торган бөек мәшәкать, аны сызланмыйча үткәреп җибәрергә кирәк», — дип исәпләгән Сәдит, кем әйтмешли, алны да, ялны да белми эшләде. Таңнардан таңнарга кадәр, күзләре кызарганчы урды ул беренче чирәм җир уңышын. Таң йокысы теңкәләргә тиеп күзләрне

буа башлаганда гына төртеп ала иде ул башын җылы, сөт исләре килеп торган салам күбәсенә. Мондый чакларда багана башындагы дәшти бөркетләрнең томшыкларын кайрап ыскылдауларыннан уянып китә иде ул. Әйе, бу бөркетләр каркылдамый да, гөрелдәми дә, бары тик даланы, иркә генә сискәндереп, уятырга чамалап ыскылдыйлар. Мондый сәер һәм җанга газиз аһәңнәрне Сәдитнең беркайда да ишеткәне юк иде. Аның һәм аның кечкенә гаиләсенең тән сакчыларына әверелде бит бу дәшти бөркетләр. Рәмзия киң басуны яслегә алыштыргач һәм бу тарафларда күренмәс булгач, бөркетләр алмашлап комбайн өстендә әйләнә-тулгана башлады. Гүя дәшти бөркет халкы, үз тавышы белән «Әннә, әттә!» дип даланы яңгыраткан татар кызчыгын юксынып, күк гөмбәзендә бөтерелә, аны эзли һәм яңадан баганалары башына барып кунаклый иде...

Кишәрлек башында зәңгәр сүстән ишелгән аркан булып төтен күтәрелә. Бу — Шәфыйка яккан учак. Учакта чәй һәм итле аш пешә. Озак та үтми, артларыннан даланың соргылт җиләне өстендә шундый ук сыек зәңгәр төтен киндерәләре калдырып, ашлык ташучы машиналар да килеп җитә. Аларның әрҗәләренә ун бункерны бушатуга аш та өлгерә. Яшерми Сәдит, кәефен күтәрү, беләкләргә көч һәм дәрт өстәү ниятендә ул бер йөз грамм чамасы теге нәмәстәкәйне дә җибәреп ала. Шәфыйкасы йөзен чыта, Шәфыйканың йөзе сытылуы Сәдит өчен теге, нәстә диләр әле, закуска гына инде ул. Ул кәгеп кенә куя. Мондый авыр эштә ансыз була диме? Ансыз дөнья сансыз! Әлбәттә, ул моны беркайчан да башкаларга күрсәтеп эшләми, гәрчә кайчандыр фронтта, хәлиткеч һөҗүм алдыннан, солдатларга геройлык өстәп, йөзәр грамм «наркомовский»ларның махсус бирелгән булуын белсә дә. Үзләре «һорилка»дан чучка кебек күбенеп йөргән Алмаченко, Чабатенколар бу эшеңне сизеп алсамы? Аларның үзләренә ярый ул яравын, ә менә башкаларга, башка ирекле гыражданнарга... Ул чакта сәтсиәлистик ярыш тактасыннан очып төшкәнеңне көт тә тор, менә шул.

Аннан аракы, тәмәке дигәнен табуы да җиңел түгел әле монда. Бер карасаң, әллә нинди сирәк әйберләр дә булмаска тиешләр дә бит инде алар. Нишлисең, башта нәкъ әнә шул «юклык»ны тудыру, аннан бу «юк»ларны «яшерен» юллардан табу белән бара бит инде безнең тормыш. Бер өйрәнгәч, шул «юк»лардан башка яшәүнең кызыгы да юк

кебек. Бу «юк»лар, тора-бара алдавыч льготаларга әйләнеп, адәм баласын капкынга каптыра. Мәскәүнең ниндидер Мытищи дигән җиреннән ашлык ташырга килеп чыккан шофер егет Володя гына ярдәм итте аңа хәмер мәсьәләсендә. Моннан бер илле чакрымда яткан ниндидер Сары Арка авылы янында чегәннәр табыры бар икән, имеш. Бу «әҗәл даруларын» шул чегәннәр сата, имеш. Дөрес тә булган ул имеш-мимеш. Володя хәзер ике арага тузан төшереп тормый. Бара да алып кайта. Яшерен-батырын түгел, кайсы чакларда, ару-талудан күзләре бәйләнеп, барасы юллары элҗе-мелҗе килә, мотор тавышларыннан баш миләре изелә, савыла башлаган мизгелләрдә Сәдит урындыгы астыннан чүпрәккә төрелгән теге ак башлы зәңгәрсу шешәне тартып чыгара, биләвеннән баласын сүткән кебек иркә генә итеп аны чүпрәгеннән арындыра, пухылдатып бөкесен чыгара, аннан ап-ак сыеклыкны чынлап та «әҗәл даруы» микъдарында гына кечкенә зәңгәрсу савытка сала һәм, савытны авызына каплаганнан соң, телләре белән аңкавын бераз тәмәйтеп тора да, авызына бер нәрсә дә капмыйча, бу сыеклыкны ашказаны тарафларына зәңгәр күзләренең татлы челт-челте белән генә озатып җибәрә. Шушы «челт-челт»не дә «закуска» дип атый ул. Тагын шунысы да хак, артык мавыкмый Сәдит ул нәрсә белән. Тәүлегенә ике, бик матавыкланганда өч тапкыр бирә ул үзенә мондый мөмкинлекне. Илле-алтмыш грамм бодай аракысы, аның шушы ук бодай уңышын күтәреп арыган, талчыккан тәнендә, кан юлларында бер шифалы дару сыман эреп югалып, дәрт-дәрманны күтәрә...

Менә шулай Шәфыйкасының турыдан-туры штурвалчылык ярдәме, аның тәмле аш-суы, җан җылысы һәм, әгәр шулай әйтергә яраса, йөрәк мае, дәшти бөркетләрнең илһамлы ыскылдаулары астында яулый алды Сәдит сәтсиәлистик ярыштагы беренче бу җиңүен. Менә бүген ул шул җиңүе өчен Беренче секретарь Җакшылыков кулыннан менә шушы «Почет билгесе» орденын алды. Сәдит орденны капшады. Ул урынында иде. Тимердән килгән гүр салкыны аны өшетеп куйды. Ул тешләрен шыгырдатты. Ир, ике кулы белән тотып, түшендәге орденны ычкындырды, кире кабына салды һәм кесәсенә шудырды.

Егерме минуттан концерт булачагын әйтеп, тәнәфес игълан иттеләр.

Ачуын кая куярга белмәгән Сәдит, шатлыкларын кая куярга белми кайнашкан, бер-берсен котлашкан, кулларындагы орден капларын, төргәкләрен җилпуч сыман селки-селки буфетка таба чабышкан бүләкләнүчеләрне ера-ера, залның президиум чыгачак очындагы ишеккә таба юнәлде. Җакшылыков аны табарга үзе кушса да, ишекне үзе бәреп керергә кыенсынды ул. Бераз көтәргә булды. Гадәттәгечә, башта аның температурасы, аннан кан басымы күтәрелә башлагандай итте. Ниһаять, аякларына ап-ак фетр итек кигән, башындагы чәче шома итеп кырылып алынган, күрер күзгә колхоз рәисе, йә булмаса, совхоз директоры кебегрәк бер адәм зат ишекне ачып үтәргә дигәндә генә, аңа сылана салып, Сәдит тә эчкә үтте дә куйды. Пеләш баш артыннан эчтәге икенче бер зур гына залны аркылы чыгып, ул ишеге ачык бүлмә каршында туктап калды. Бүлмә алсу йөзле, канәгать чырайлы, тулы карынлы җитәкчеләр белән тулган иде. Сәдит, кайнар карашы белән капшап, алар арасыннан Җакшылыковны эзләде. Әнә ул! Әле генә дәүләтнең зур бүләген тапшырган комбайнчыны Беренче үзе дә шәйләп алды һәм, кулы белән изәп, үзенә чакырды:

— Гатиятуллин! Бире кил!..

Әмма барлык дәһшәте белән агарынып калган Сәдит урыныннан кузгалмады. Гүя ниндидер көч аны басып торган җиренә кадаклаган иде. Җакшылыков аңа таба юнәлде һәм бөркеттәй кочагына колачлап алды:

— Чын күңелдән!.. Чын күңелдән котлыйм!.. Килеп урнашуыгызның беренче елында... и такой орден!.. «Почет билгесе»! Безнең өлкәдә бердәнбер мондый батыр бит сез!..

Сәдит бер сүз дә эндәшмәде.

Секундлар сәгатьләргә тиң иде.

Секретарь Сәдитне күздән кичерде. Ул куркыныч иде.

Секретарь аңардан нәрсәдер көтте.

— Пач-чам-му?! — Ниһаять, Сәдит хәнҗәрдәй үткен күзләре белән Беренчегә кадалды. — Ниг-гә?!

Аның күзләре чынлап та куркыныч иде.

Монда ниндидер бер зур, котылгысыз сөйләшү барлыгын аңлап алган Җакшылыков, янәшәсендәге берәүгә башын какты да, кулын Сәдитнең иңеннән төшерми торып, аны күршедәге икенче бер бүлмәгә таба алып китте. Алар артыннан, мунча яфрагы сыман аркага ябышып, бүлмәгә теге дә

керде. Сәдит аны таныды: ул урак өстендә очрашкан Шәүлә иде.

Алар икесе өстәл артында урын алды. Шәүлә өч-дүрт адымда баскан килеш катып калды.

— Нәрсә булды, Гатиятуллин? Сөйләгез. — Ул Шәүләгә ымлады. — Тартынмагыз, безнең кеше...

Бу кеше үзенең карадан-кара киеме белән бүлмәне тутырган иде.

Тәмам агарынган Сәдит орден кабын һәм таныклыгын, кесәсеннән чыгарып, өстәлгә салды:

— Миңа мондый... билгесе булып та хөрмәте булмаган бүләк кирәкми. Мин бик тә рәнҗедем, Җалкын Сарбаевич...

Шәүләнең маңгаена бөрчек-бөрчек тирләр шытып чыкты. Ул агарынып хуҗасына карады.

— Ничек... хөрмәте булмаган? Моны ничек аңларга? — Беренченең кандай кызарган йөзе буйлап ниндидер төеннәр йөгерде. Ул, сүз таба алмагандай, бер мизгелгә тынып калды. Аннан үзе дә сизмәстән өстәп куйды: — Бездә орденны сорап алмыйлар. Нәрсә бирсәләр, шуны алалар, гуй...

Менә сиңа мә! Иште ишәк чумарын! Ул, коммунистик идеянең тәҗрибәле көрәшчесе, ерак Татарстаннан яхшы тормыш һәм социаль гаделлек эзләп килгән гади бер комбайнчыга шулай дип әйтергә тиеш идеме? Кызу урак өстендә бункерга бишек асып, чирәм җир игенен урган егетнең хакы шулай очсызмыни?

Әмма дилбегә кулдан ычкынган иде. «Гади комбайнчы» исә бу дилбегәне шундук кулына алды:

— Ә менә бездә алай итмиләр... Бездә тиешлесен бирәләр...

Сәхнәдән әле генә таулар актарырлык күтәренке кәеф белән төшкән Беренченең гүя эчендә тегермән ташлары дөбердәп кузгалды. Ул кашларын җыерды. Сәдит беренче тапкыр аның тырпаеп торган чәчләренең шомырт кара, ә кашларының чал булуын абайлады.

— Нәрсә, бүләгебез кечкәнтәй мәллә?

— Эш бәләкәйлектә,йә булмаса, зурлыкта түгел.

— Нәрсәдә соң? Тиешенчә бәһаләмәгәннәрме?

— Әйе. Нәкъ шулай.

— ???

Сәдит пинжәк кесәләреннән бер төргәк гәзит кисемтәләрен чыгарып салды һәм, алар өстеннән күзләрен йөгер-

теп алганнан соң, чак-чак ишетелерлек тавыш белән дәвам итте:

— Орден тапшырганда сез мине сәтсиәлистик ярышта җиңүче дип атадыгыз. Мин дөрестән дә җиңүче булганмын икән шул... Менә бу гәзиттә язуларынча, игенне мин Говоровка караганда... — Ул, тамагы төелеп, эндәшә алмыйча торды. — ...ике мең центнерга, Зельцерга караганда... өч мең центнерга, Жумабаевтан исә... — Аның күз алдыннан дәшти бөркетләр кунган баганалар йөгереп үтте. — ...дүрт мең ярым центнерга артыграк суктырып, беренче урынны яулаганмын лабаса! Әмма... «булганмын» гына! Әмма җиңүчеләр итеп икенчеләрне раслагансыз икән... Ә безнең «Каравыл-Түбә»дән бүген орден алган Кривошапка исерек килеш яңа үзйөрешле комбайнны яндырган кеше... Аны утыртырга иде дә бит, әмма... Сез мине әләкче дип уйлый күрмәгез, болай, сүздән генә әйтәм. — Сәдит бер мизгелгә тынып калды. — Сәтсиәлистик ярышта җиңүен мин җиңдем, ә менә сез бүген иң югары бүләкләр — Ленин орденын Говоровка, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнарын Кривошапка, Зельцер һәм Жумабаевка тапшырдыгыз, шулай бит? Миңа «Почет билгесе», шулай бит?.. Ягъни мәсәлән, хөрмәтсез билге, хөрмәттән көлү билгесе... Мине дөрес аңласагыз иде... Мин сезнең янга орден дауларга дип килмәдем. Минем бары тик беләсем генә килгән иде: нишләп болай килеп чыкты икән ул, Җалкын Сарбаевич?

Секретарь кайнар тиргә батты. Аның һәрчак ярдәмчел, алып бирергә, илтеп куярга, хәбәр итәргә, сакларга, утыртырга, азат итәргә, пычратырга, агартырга әзер торган, әмма бу мизгелдә онытылган гына түгел, иң мөһиме — хуҗасына бернинди дә ярдәм итә алмаган ярдәмчесе Шәүлә исә гүя бу һавада үтә күренмәлегә әверелеп эрегән иде. Җакшылыков үткән җәйнең бар тирә-юньне шәм итеп эреткән июль кояшы астында, даланың беренче чирәм уңышын җыйганда, көтмәгәндә генә каяндыр Татарстаннан бәхет эзләргә килеп чыккан бер гидай комбайнчы белән танышуы өчен хәзер хәтта үкенә дә иде кебек... Мондагы, бу бүлмәдәге кояш теге чактагы дала кояшыннан күпкә эссерәк һәм рәхимсезрәк иде. Аны аңлау, йә булмаса, аңларга тырышу бүгенге тантанадан алган ләззәтне җиргә салып таптау, алдагы якты идеаллардан баш тарту, җиңүләрнең бәясен юкка чыгаруга тиң иде...

— Иптәшләреңә карата алай ук кансыз... алай ук рәхимсез булырга кирәк имәс иде, Сәдит... кем малае әле?

— Гәбдерәүф малае.

— Әйе, Сәдит Гәбдерәүфович. Алар да бит эшләгән, хезмәт иткән, тир түккән... Кешеләрне бердәй күрүемез кирәк...

Секретарь мондый җебегәнлеге өчен үзен ертып ыргытырга, чәйнәп өзәргә әзер иде. Шушыларны сөйләп торырга тиеш идеме ул хәзер, ат-тасының б-б-баш б-б-бал-ласы!..

— Кеше буларак, без, әлбәттә, тигез, — дип эләктереп алды политграмотасын Магдебург танк полигоннарында ныгытып өлгергән яшь механизатор. — Ләкин, абзыкаем, мой харуший, кешеләрнең тигезлеге аларның хезмәтен тигезләү дигән сүз түгел әле, шулай бит? Хезмәт тигез була да алмыйдыр ул. Шуңа күрә бит партиябез үзенең программасында «Һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хезмәтенчә» диелгән. Дөр-рес бу!.. Ул бит «Һәркайсын тигезләгез» димәгән, шулай бит? Аннан «сәтсиәлистик» дигән сүз, минемчә, «гаделлек» дигәнне аңлатадыр кебек. «Сәтсиәлистик хезмәт ярышы» дигәне инде «гадел хезмәт ярышы» буладыр, шулай бит?

Әйе, «шулай бит», «шулай бит» дия-дия, комбайнчы иптәш Казакъстан коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты әгъзасы, аның күренекле әһелләренең берсе булган иптәшне диварга китереп терәгән һәм бу иптәшнең бу кадәр төгәл мантыйк, аек акыл, ышандырырлык, дәлилле итеп сөйли белгән комбайнчы иптәшен үзенә лекторлар төркеме җитәкчесе итеп эшкә аласы килә башлаган иде...

Әйе, комбайнчы иптәш Казакъстан коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты әгъзасы, аның иң күренекле әһелләренең берсе булган иптәшне бик тә куркыныч, кагылырга да ярамаган, рухи, әхлакый, идеологик бәхәснең чыга алмаслык баткагына алып кереп батырган, инде аның борын тишеге бу сазлыкның соргылт-сасы массасы эченнән беренче куыкларын чыгара башлаган иде...

Ул, котылырга теләгәндәй, урындыгына чат ябышты һәм Сәдитнең күзләренә карады. Алар нәкъ басудагыча садә зәңгәрлек белән ялкынланалар. Комбайнчының сүзләрендә ачу зәһәре булса да, шунысы сәер, күзләрендә бернинди ачу да, зәһәрлек тә юк, татарның бары тик теге, Җакшылыков үзе искә төшергән затлы нәселлелегенең асаба зәңгәрлеге генә бар. Бу аның күңелен нечкәртеп җибәрде.

Гәрчә ул күпне күргән, солдат белән ат тоягы эзендәге сазлык суын да, сасы аракысын да бергә чүмергән армия политработнигы түгел мәллә?! «Бәлки, бүләкләнү хөрмәтенә... чынлап та бер иллешәр грамм тяпнуть что ли?» дип уйлап куйды Беренче.

Хуҗасы өчен бу җәзаның да җәзасына, бер комбайнчы кисәгеннән түбәнлекле, үкенечле, моңа кадәр күрелмәгән хөкемгә әйләнгән бу бәхәстән котылып, моннан ничек чыгып сызарга белмәгән Шәүлә идәндә катып калган шәүләсен кузгатып маташты. Әмма хуҗасы бу ишарәгә игътибар итмәде. Шәүлә бүлмәдәге кизүлеген дәвам итте.

— Мондый истәлекле көндә... мондый гадәти сорауларга җавап эзләп, вакланып маташасы да килми, Сәдит туесканым, — дип башлады сүзен Секретарь, саклык белән алга барып. — Казакъ әйтмешли, ат аунаган җирдә төк калмый булмый, гуй. Аннан, без бит — солдатлар. Ир-егетләр, туесканым. Нәкъ менә шул ир-егетләрчә синең беренче җиңүең хакына берәр йотым кайнар хәляльне тотсак, барча үпкәләрне онытсак, ә? Аннан юлыбызны, партия кушканча, яңа җиңүләргә таба дәвам итсәк, ә? Яшь гаиләң хакына, гүзәл тукалың хакына, ә? — Секретарь элекке халәтенә кайтып батырайды һәм, хәлиткеч хәрәкәт ясап, өстәлдә яткан орден кабын Сәдит алдына шудырды. — Кечкәнтәең... бункерда үскән бодай баласы хакына... Әйткәндәй, исәнме, исеме-аты кем әле аның?

— Эчмим, — дип алдалашты Сәдит. — Кызның исеме Рәмзия анысы.

— Һмм... Ярар алайса. — Секретарь уңайсызланып куйды.

— Авызыма да алган нәрсәм түгел. — Сәдит шундый ук боерыкчан хәрәкәт белән орден кабын Беренченең алдына ук күчерде һәм чекерәеп яңадан күзләренә текәлде. — Социализм «тигезлек» дигән нәрсә түгелмени?

— Тигезлек. — Сәдит таккан бәхәстән, ул алып кергән сазлыктан котылу мөмкин түгел иде. Секретарь тирән итеп сулыш алды һәм уфылдап куйды. — Мин синең белән килешәм. Тигезлек, туесканым.

— Мине, беренче урынны яулаганны, иң түбәнгә тәгәрәтү тигезлек буламыни?

— Э-э-э... Карагыз әле, безнең республикада ике иң зур халык бар — казакълар һәм орыслар. Бүләкте беренше

итеп орыска биру безнең халкымызның күңел киңлегенә тап киләдер, гуй. Бездә милләтшелек имәс. Болар барысы да халыкларымыз дуслыгы бола ятыр, гуй.

— Ә мин, татар, шул дуслыкның кайсы тирәсендә инде? — дип сорап куйды Сәдит.

— Ярар инде, арттырма, туесканым, — дип каршы төште аңа Җакшылыков һәм ягымлы итеп елмайды. — Ортасында, нәкъ аманат ортасында, гуй!.. «Почет билгесе»! Орыстан, казакътан кала, татар туесканымыз өченче болып орден алып ятадыр, гуй!..

— Кахулдан кала, — дип төзәтте Сәдит.

— Әйе, бу мисалда украиннардан кала. Ярар инде, орден нисбәтеннән һәр халыкны мыскалга салып булмайды... Ул гадел дә булмас иде... «Почет билгесе»! Йә, әйт, бу бүләк кемнәрдә бар тагын? Татар карындасымызда! Мин, мәсәлән, моның белән бик тә горурланам! — Ул орден кабын яңадан Сәдит алдына шудырды. Шәүлә, аякларын алыштырып, урынында таптанды. — Килгән елыңда ок мондаен һәдия алуың белән котлаемдыр, гуй...

Ул сикереп торды, Сәдитне кочты, сөякләрен он итәрдәй итеп шатырдатып кысты һәм, кап эченнән орденны чыгарып, калтыранган куллары белән Сәдитнең түшенә яңадан беркетә башлады:

— Без аны шулай итәбез, туесканым... Хөрмәт орденыннан башлаек... Аннан — Кызыл Байрак. Аннан Ленин бабамызның үзен үк чамаларсың, гуй...

Сәдит белән әллә нәрсә булды. Нәкъ шушы мизгелдә кемдер аның үзе белән дә киңәшми-нитми, ризалыгын сорамый торып, аның корыч ихтыярын сындырды диярсең: ул хәзер үз-үзе белән дә идарә итә алмый, имеш. Гүя ул үз күкрәгенә үзе хуҗа да түгел. Гүя анда бишек. Гүя аның бишекле күкрәген кемдер арендага алган да шунда җир сөрә, тырмый, чәчә, ура, анда тамырдай каты куллары белән туфрак йомшарткандай итеп, үзенә кирәк максатларда файдалана, тик Сәдитнең үзен генә кертми иде... Менә ул якасына нәрсәнедер каптырган, нәрсәнедер боргычлаган пинжәген Җакшылыковның кысла сыман капшаучы кулларыннан арындырасы, азат итәсе, аннан бер читкә этеләсе килә, әмма ничек кенә тырышмасын, моның өчен аңарда — әле генә көч-куәт чәчеп торган баһадир ир-егеттә — батырлык та, ихтыяр көче дә җитми. Хәтта багана башларында

ыскылдап утырган дәшти бөркетләр дә ярдәм итми. Бу нинди хәл? Ул Җакшылыковның фиркави һәм дәүләти кочагында балавыз сыман эри һәм эрүен дәвам итә иде.

Сәдит кинәт кенә, тиле кеше сыман, шаркылдап көлә башлады.

Бу көлү исә Беренченең күңеленә аеруча хуш килде.

Ниһаять, орден яңадан Сәдит күкрәгенә менеп кунаклады.

— Менә ничек бөтәеп киттең, гуй!.. — Беренче аңа сокланып карап куйды. — Әтеү, алмыйм, имеш! Әтеү, онытма, бездә дә «бирмим, имеш» булуы мөмкин, гуй...

Ул тынычланды. Кемне нинди орденга билгеләү буенча хакимиятнең гадел эш иткән булуын раслау өчен меңләгән ялган дәлилләр китерә, әгәр бик тели икән, үзенә генә билгеле булган юллар, чаралар, чамалар, шомартулар, куркытуөркетүләр аша ышандыра, инандыра алган, инандыра алмаган очракларда, үз сүзен барыбер сүз итеп, маңгае белән дивар җимергән Беренче бу юлы, — ә бәлки, бу барлык тормышында, партия эшендә эшләү дәверендә беренче мәртәбә булгандыр — комбайнчы белән артык кызылланып, шомартынып, татлы телләнеп тормады, Сәдит туесканы биргән сорауның иң аска яшерелгән җавабын ачты да салды:

— Алмаченко теләмәде, Евгений Христофорович. Без аңа Ленин орденын да, Хезмәт Кызыл Байрагы орденын да тәкъдим иткән идек. Кирәк имәс, диде. Безнең совхозда әлегә лаеклылар юк, диде...

— Рәхмәт... рәхмәт, — дип пышылдады шалкан сыман агарынган Сәдит. — Мин җавабыгыздан канәгать... Миңа шул гына кирәк иде... Миңа орден һич кенә дә кирәкми иде...

«Бу Алмаченко һаман акылга утырмаган», — дип уйлап куйды ул тагын.

Әле күптән түгел генә Теләнче Тамагындагы оясыннан очып чыккан татар бөркете шунысын аңлады: бу шартларда орден — адәм баласының хезмәте өчен алган горурлык билгесе — ул хосусый милек икән. Ул лаеклы булган бүләкләр арасындагы иң «түбәндәге»сен алу да аның өчен зур батырлык икән. Сәдитнең күңеле уйнап куйгандай итте. Ул читкә карады. Шул мизгелдән алып Сәдит өчен Тукайлардан килгән саф, чиста милли хиснең милеккә, шәхси хуҗалык сыман нинди дер бер матди, гаса-

би хиссият чыганагына әйләндерелгән булуы аңарда мәңгелеккә тар, тынчу милләтчелеккә карата мәңгелек җирәнгеч мөнәсәбәт тудырды.

Аның җавабыннан канәгать булучыдан үзе үк канәгать булган Беренче кәефе килеп елмайды, кәнәфиендә төендәй чишелеп, бәдәнен язды һәм Сәдитнең колагына ишетелер-ишетелмәс итеп кенә пышылдады:

— Аннан, туесканым, һич тә аптырама: мондый тантаналар ниндидер микъдарда театр... концерт рәвешен алалар. Син алдагы зур тантаналарга репетиция генә үтәсең... Синең юлың — Социалистик Геройлыкка!..

Сәхнә ягыннан «Ой ты, зима морозная»ны күмәкләп җырлый башладылар. Бу бүләкләнүчеләр хөрмәтенә концерт башлануы иде.

Беренче Шәүләсенә баш какты. Менә ярты сәгать инде күрсәтмә көтеп урынында кара баганага әйләнгән, йөзендә — йөзе, авызында теле булмаган һәм кеше хәтерендә шәүләсеннән башка бер нәрсәсе белән дә истә калмаган телсез аппарат чиновнигы, саздан аерылгандай, аякларын чак кузгатып һәм кергәнендәге сыман елышып кына, бүлмәдән чыкты. Аның артыннан бүлмә киңәеп, яктырып киткәндәй булды.

Әмма Шәүлә аларны бөтенләй ташлап китмәде — бүлмәдән чыгу белән, икенче бер уңайлы урынны сайлап, тагын да катып калды. Хәзер ул күзәтә дә, бер үк вакытта концерт та тыңлый иде.

— Ә син кайгырма... Алмаченкога да кинә саклама. Җаманлыкта нан үстереп болмыйдыр, гуй. — Секретарь болай да бик тәртипле итеп ятып торган шомырт кара чәчләрен сыйпады. — Таррак адәм ол, әлбәттә. Бездә озак калалмас ол...

— Тар түгел. Татарны яратмауда татарның үзеннән дә... татарырак кеше...

— Нишләтәсең, һәркемнең үз холкы. Аннан, җитәкче халкы үзенчә чирли бит ул... Аларны вакытында кашып торырга кирәк, шулай бит? — Беренче елмайгандай итте. — Кайгырма, барысы да рәтләнер. Исәнлек кенә кирәк. Тукалың, теге бункердагы бишектә үскән кызың ни хәлдә соң? Исән-аманнармы?

— Исәннәр, Аллага шөкер. Әнисе йөгереп, кызы сикереп, әтиләре кикереп йөри. Малайга да нигез салдым. Бишкә кадәр туктамаска исәп.

— Менә монысы өчен... бездән сиңа һәм тукалыңа тагын бер орден. Ә теге... авылдан, синең арттан килгән кызкай... Исеме кем иде әле... Ну, синең икенче хатының...

Даңгыр-доңгыр мичкә тәгәрәткән, ниндидер чинашкан тавышлар чыгарып, сәхнә ягыннан җыр яңгырады.

Сәдит бу концертка кереп тә тормаячак. Мондый шома, моңсыз җыр ишарәтләрен, шырды-бырдыны аның җене сөйми.

Беренче сәгатенә карап куйды.

Сәдит тә, җиңен ышырып, сәгатьсез беләгенә карап куйгандай итте.

Аннан, нәрсәнедер исенә төшергәндәй итеп, сискәнде:

— Нишләп ул минем икенче хатыным булсын ди?! — Сәдит, уянып киткәндәй, кап урталай ярылды. — Сез... чамалап! Бездә бер генә тапкыр яратырга кушылган!..

— Гафу ит инде! Ялгыш ычкынды... Сине һич тә рәнҗетергә теләмәгән идем дә бит...

— Мактарга теләгән идегезмени?

— Һәрхәлдә, һич кенә дә кимсетермен дип уйламаган идем. Аннан, шартыннан чыгып, кулыннан килгән, булдыра алган ир-егеткә ул кадәр хөкемгә тарттырырлык җинаять тә түгелдер инде ул...

— Нич-ча-уа сиб-бә! — дип кычкырып җибәрде Сәдит. — Болай булгач, сезне зеррәгә генә Беренче секретарь итмәгәннәрдер, абзый!.. Сездә, Казакъстан компартиясендә ничектер, ә менә бездә, Татарстан компартиясендә, көпәкөндез ике хатын белән яшәү мактала торган нәрсә түгел. Ул ике аягыңа ике ыштан киеп чабу белән бер, мин сезгә әйтим! Андый чакларда райкомга чакыралар да түзәлмәсәң дә түзеп торырга кушалар...

— Син бит коммунист түгел... — дигән булды Җакшылыков, Сәдитнең бары тик «Почет билгесе» орденына гына тәкъдир ителүенең бер сәбәбен сиздерергә тырышып. — Совхозыңа кайту белән партиягә кер. Син бит... һаман да коммунист түгел!..

— Булмаса ни! Аның караввы мин — партия баласы!.. — дип җавап бирде аңа Сәдит. — Партиясезләрнең балалары да мәм-мәм сорый, мой харруший!

— Анысы хак. Минем ул кызкай хакында беләсем генә килгән иде. Совхозда калдымы ул? Китмәдеме? Кем булып эшли?

— Китмәде. Ындыр табагында үлчәүче булып эшли.

— Кияүгә чыкмагандыр бит?

— Чыкмады әле. Сезне көтә.

— Ну, кызык та инде син, Гатиятуллин!

— Шул кызык коткара инде мине... Югыйсә элмәккә керергә кирәк...

— Нигә алай бик кискен әле?

— Ничек кискен булмаска ди? Алдан да, арттан да мәхәббәт камалышындамын. Ә менә яшәргә, ике хатын белән түгел, берсе белән дә йокларга урын юк...

— Кит аннан! Нигә әйтмичә торасың? Әле кайда яшәп азапланасыз?

— Ат абзарында.

— Ат абзарында?! Булмас ла!

— Килеп карагыз, бәй. Ат караучы алачыгында. Рәмзиянең бишеге хәзер шунда күчте.

— Һм. Хуҗалыкның ат караучысы юкмыни?

— Бар иде. Хатыны бу шартларга түзә алмыйча алып кайтып китте. Ат караучы булып әлегә мин эшләп торам. Әле кичә генә Шәфыйка белән ике колын кабул иттек...

— Кит аннан!.. — Җакшылыков, йодрыгыннан ут чыгарып, өстәлгә сукты һәм, ялкын капкандай, урыныннан күтәрелде. — Кайтуыңа совхоз сине фатирлы итәчәк, Гатиятуллин!.. Туесканым!.. Йә мин, йә бу Алмаченко!.. Әйдә, концертны карап алайык, гуй...

Кәефләре җиңеләеп, фикерләре сукыраеп калган Сәдитнең бер йөз генә грамм булса да төшерәсе килеп китте. Бая Секретарь үзе тәкъдим ясаганда җиффәрмәгәненә үкенеп тә куйды.

Орденыннан баш тартып, Секретарь белән кайнар бәхәсләшкән Сәдит һәм инде менә орденын түшенә тактырган Сәдит гүя икесе ике кеше иде.

Алар агылыйга-тагылый бүлмәдән чыктылар һәм, фойены үтеп, концерт залына юнәлделәр. Артларыннан, дивар буйлап шуыша-шуыша, теге Шәүлә дә озата барды. Татар моңын, аның «Шахта» һәм «Сарман»нарын сагынган Сәдитнең бу колак тондыргыч, уйлавынча, моңсыз һәм җиде ят тамашага һич кенә дә керәсе килми иде. Ләкин ниндидер пошаманлы көч ирне шунда тарта, калебенә каршы килеп булса да, керергә, мондый бергәлектән читтә калмаска боера иде...

Буфет каршында шактый кызып алып, кайсы кайда изрәгән, шаулашкан, сүз куерткан замандашларын ерып, ул гүя үз күкрәгенә бишек итеп орден таккан Сәдит, артыннан майлы комбинезон киеп ир-ат рәвешенә кергән штурвалчы Шәфыйкасын да ияртеп, һәлакәтенең, бөек тарихының азагына, аның гына түгел, үзеннән соң калачак балаларының, балаларының балаларының, барлык нәселенең, милләтенең яңа бер мәҗүси сыйфатына таба үзе теләп атлагандай, Беренче секретарь ачкан ишек аша залның шау-шулы ят авазларда, хәмер исләрендә чайкалган томанлы караңгылыгына, туган җыруларыннан җиңелчә, моңсыз «Ой ты, зима морозная»лар аша якын киләчәкнең меңләгән шырды-бырды такмаклары патшалыгына кереп чумды.

Кайчан чыгар ул аннан?

Чыгар микән?

Чыккан хәлдә, аның үзен дә икенче бер бишеккә салып чыгармасलармы?

*Гыйнвар — февраль, 2001 ел.*
*Чаллы*

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

# ЭЧТӘЛЕК

Күңелне кузгаткан моң. *Рәшит Фәтхрахманов*. ....................5

**I. Калеб яратылганда**

Кылганнар чәчкә атканда .................... 20
Теге малай .................... 52
Трофей ашъяулык .................... 63
Китап .................... 74
Калеб яратылганда .................... 86
Җырлар вакыт .................... 94

**II. Саный башлаганда**

Саный башлаганда .................... 117
Беренче укучы .................... 124
Булачак әртис .................... 127
Нуль турында баллада .................... 128
Уянып аңлашу .................... 135
Габделгафур хәзрәт шатлыгы .................... 138
Гадәттән тыш вакыйга .................... 141
Телеграмма .................... 144
Ыгдыбыгды чокыры .................... 147
Кара кышта .................... 151
Сәүит сәүдәгәрләре .................... 160
Милиционер үлеме .................... 163
Сандугач белән Карлыгач .................... 167

**III. Бөркетле баганалар**

Эңгер .................... 179
Казыктагы тальян .................... 201
Көнбагыш чәчкәсе .................... 241
Кыйбла .................... 277
Авылдаш .................... 310
Берлинга хат .................... 334
Бөркетле баганалар .................... 348

Литературно-художественное издание

Айдар Халим

(Борис Назметдинович Халимов)

**КЫБЛА**

Рассказы, новеллы

(на татарском языке)

Редакторы *Р.Ә.Заһидуллина*
Художество редакторы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *А.Р.Таһирова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Л.З.Шиһапова, Г.М.Хәбибуллина, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.07.2005. Форматы 84×108 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 20,16 + форз. 0,21. Шартлы буяу оттиск 21,42. Нәшер-хисап табагы 22,79 + форз. 0,36. Тиражы 3000. Заказ А-497.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.